

Лирон Хәмидуллин

# КИЧКЕ ШӘФӘКЪ

*Документаль повесть, эссе, очерклар*

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2009

УДК 821.512.145-4
ББК 84(2Рос=Тат)-4
Х88

**Хәмидуллин Л.Х.**

Х88 Кичке шәфәкъ: документаль повесть, эссе, очерклар / Лирон Хәмидуллин; кереш сүз авт. Р.Фәйзуллин. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. — 255 б. — 1000 д. — ISBN 978-5-298-01734-3

Китапка язучының төрле елларда иҗат иткән, үз вакытында төрле җыентыкларда, журнал һәм газеталарда дөнья күргән әсәрләре — документаль повесть, эссе һәм очерклары керде.

УДК 821.512.145-4
ББК 84(2Рос=Тат)-4

ISBN 978-5-298-01734-3

© Татарстан китап нәшрияты, 2009
© Хәмидуллин Л.Х., 2009

## АКСАКАЛ ӘДИПЛӘРЕБЕЗНЕҢ БЕРСЕ

*Моннан җитмеш еллар элек үк Казандагы мәшһүр Матбугат йортының (Бауман урамы, 19) Тукай клубында язучыларның җыелышлары, төрле кичәләре, юбилей бәйрәмнәре һәм башка чаралар үткәрелеп киленгән. Сугыштан соң, бигрәк тә илленче еллардан соң, клуб эше тагын да җанланып китә. Алтмышынчы еллар башында язучыларның бу клубында аена берничә мәртәбә әдәби-музыкаль кичәләр уза иде. Татарның атаклы шәхесләре катнаша иде ул кичәләрдә. Биредә шулай ук әдәбиятка, сәнгатькә юл ярырга омтылган яшь-җилкенчәкләр дә күп була иде. Университетта һәм педагогия институтында укучы байтак студент-шагыйрьләрнең халык алдында беренче җитди чыгыш ясап «чирканчык алулары» да шушы кичәләрдә булды. Ул елларда мондый зыялы аудитория бүтән җирдә юк иде бугай. Шуңа күрә гадәттә җомга көннәрендә уздырыла торган ул кичәләрне күпләр көтеп ала иде. Кемнәрне генә очратмый идең анда! Нәкый Исәнбәт, Бакый Урманче, Мәхмүт Бөдәйле, Риза Газизов, Хәй Хисмәтуллин кебек XIX гасырда ук туган өлкән кешеләр дә; ул вакытта ук классик саналган, иҗатлары дәреслекләрдән өйрәнелгән Гомәр Бәширов, Хәсән Туфан, Афзал Шамов, Шәйхи Маннур, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Габдрахман Әпсәләмов, Сибгат Хәким; классик ук саналмасалар да, һәммәбез өчен абруйлы фронтовиклар — Салих Баттал, Гали Хуҗи, Мөхәммәт Садри, Әнвәр Давыдов, Зыя Мансур, Шәрәф Мөдәррис... Биредә мәдәнияткә битараф булмаган өлкән һәм урта буын кешеләрен дә, авылдан килеп, тиз генә Казанның мәдәни төркеменә керергә ашкынган яшьләрне дә, әлбәттә, күзләү органнары вәкилләрен дә күрергә мөмкин иде. Инде илле еллап вакыт узса да, шунда катнашкан байтак кешеләрнең гәүдә-кыяфәтләре, йөз чалымнары әле дә күз алдында.*

*Бер кичәне дә диярлек калдырмый торган бер кешенең төскыяфәте шактый ук ачык булып хәтердә калган. Безгә инде өлкән тоелган (үзебезне булачак шагыйрьләр дип йөргән күпләребезгә ул чакта әле егерме дә юк, ә аңа инде (!) утызлар тирәсе) бу кеше нишләп йөри монда? Безнең кебек сәхнәдән чыгыш та ясамый, килгән тамашачылар белән дә бик аралашмый... Безнең як кешесенә охшаган да, охшамаган да кебек. Аксыл йөзле, кысынкырак күзле. Борынгы бабаларыбызның бишеге булган Алтай ягы кешеләренә тартым... Кем бу? Яшь чак, төпченеп торырга вакыт та юк. Бу дөньяның кеме булмас!*

*Алты-җиде еллар үткәч, бу кешенең кем булуы яхшы ачыкланды. Ул Хәмидуллин Лирон Хәйдәр улы булып чыкты. Сугышта һәлак булган фронтовик баласы. Гомере буе татар дөньясы даирәсендә әвәрә килгән милләт улы. Язучы. Хуҗалык эшләрен яхшы оештыручы. Бүгенге көндәге статусы — татар*

*әдәбиятының аксакал әдипләреннән берсе. Кемнәр ничек кабул итәр — анысы икенче мәсьәлә — бу минем шәхси билгеләмәм. Лирон ага Хәмидуллин турында үз фикеремне ачык итеп әйтергә хакым да бар кебек: чөнки ярты гасырлап аның белән азмы-күпме аралашып яшәлде, өч-дүрт ел Язучылар берлеге аппаратында бергә эшләп тә алдык әле. Лирон аганың, иҗатыннан тыш, минем өчен кызыклы, кирәкле бер ягы бар: язучылар тормышының тышкы ягын да, эчке хәлләрен дә шактый ук яхшы белә ул. Унбиш елдан артык СССР Әдәби фондының Татарстан бүлеген җитәкләде. Ул оешманың төп вазифасы язучыларның матди-материаль базасын кайгырту иде. Ягъни каләм ияләренең иҗатын стимуллаштыру, шартлар булдыру, ярдәм итү. Кемгә фатир, кемгә санаториягә яки Иҗат йортына путевка-юллама кирәк, кемгәдер шатлык килгән, кемнедер кайгы сарган... Юбилей-бәйрәмнәре дә, үлем-китем мәшәкатьләре дә, кунак каршылау-озатулар да, гомумән, язучылар яшәешендәге төрле хәлләр һәммәсе Әдәби фонд катнашында уза иде элек. Әдәбиятның җәмгыятькә кирәк, язучыларның кадерле чаклары иде ул еллар! Алтмышынчы еллардагы язучылар тормышын яхшы белгән кешеләр бик сирәк калды хәзер. Яше җитмеш бишсиксәннәргә җиткәннәр ике дистәдән артмыйдыр. Аларның һәммәсе дә язучылар тормышының үзәгендә-казанында кайнамаган да бит әле! Журнал редакциясендә еш кына үткән гасыр урталарына яки аннан ераграк елларга караган язмалар, фотосурәтләр белән эш итәргә, редакцияләргә туры килә. Кайчак теге яки бу фактны төгәлрәк ачыклыйсы, теге яки бу сурәттәге кешене таныйсы, кемлеген беләсе килә. Кемнән сорарга? Кем белергә мөмкин? Р.Мостафин? М.Госманов? Ш.Галиев? Л.Ихсанова? Алардан яшьрәкләрдән Батулла? Г.Рәхим? Р.Харис? Менә шундый чакларда Лирон ага Хәмидуллинга мөрәҗәгать итәм мин. Шөкер, күп очракта сорауларыма җавап та табам. Язучылар берлеге тарихын чагылдырган «Гыйбрәтле үткән юл» дигән хезмәтемне язганда һәм бүтән очракларда (мәсәлән, «Аккош күле» иҗат йорты турында материаллар туплаганда) өлкән каләмдәшемнең ярдәмен күп тойдым. Шуңа күрә мин аны әдәбиятыбызның сирәк калган аксакал әдипләребезнең берсе дип саныйм да.*

*Лирон Хәмидуллин (Л.Хәйдәр) турында библиографик әдәбиятта беркадәр белешмә-материал булса да (мәсәлән, Р.Даутов һәм Н.Нуруллина әзерләгән «Татар совет язучылары» китабы, 1984), аның тормышын һәм иҗат юлын киң катлау укучы тиеш кадәр белмидер дип уйлыйм. Шуңа күрә аның хакында беркадәр мәгълүмат биреп китү урынлы булыр.*

*Лирон Хәйдәр улы Хәмидуллин 1932 елның 10 ноябрендә Ульяновск өлкәсенең Яңа Малыклы районы Иске Төгәлбуга авылында хезмәткәр гаиләсендә туа. 1941 елда шул авыл мәктәбенә укырга керә. Ә унбер яшьтән әнисе туган Иске Белогор авылы-*

*на, Оренбург өлкәсенә күчеп китәләр. Шунда җидееллык мәктәпне тәмамлый. Аннары укуын Казакъстанның Актүбә шәһәрендә тимерьюлчылар техникумында дәвам иттерә. 1951–1954 елларда Мәскәүне һава һөҗүменнән саклаучы гаскәрдә радиолокаторчы булып хезмәт итә. Аннан кайткач, Орск (Оренбург өлкәсе) шәһәрендә төп белгечлеге буенча эшли. Мәскәү политехника институтының Орск филиалында югары техник белем үзләштерүгә керешә (1960 елның июленә чаклы дүрт курс тәмамлый). Шул елда Уфа университетының татар филологиясе бүлегенә керергә талпынып карый һәм ярты ел чамасы Уфа шәһәрендә эшләвен дәвам итә. Орск шәһәрендә яшәгәндә татар-башкорт яшь һәвәскәрләре белән бергә әдәбимузыкаль кичәләр оештыруда катнаша.*

*1961 елдан Казан шәһәрендә яши. 1961–1967 елларда шәһәр транспорты оешмасында тимер юл бүлеге инженеры, баш инженеры, партком секретаре була.*

*Алтмышынчы еллар урталарыннан башлап Л.Хәмидуллинның тормышы турыдан-туры әдәбият, Язучылар даирәсе белән бәйле. Әдәбиятка бирелгән, шул ук вакытта хуҗалык эшләрендә дә зур тәҗрибә туплаган ир-егетне Язучылар берлеге аппаратына эшкә чакыралар. Л.Хәмидуллин 1967 елдан СССР Әдәби фондының Татарстан бүлеге директоры. Ул дәртләнеп яңа эшкә керешә. Ә ул яңа эш дигәннәре шактый ук дәвамлы булып чыга. Уналты ел эшләү дәверендә Язучылар берлеге идарәсе рәисләре Мирсәй Әмир, Ибраһим Гази, Зәки Нури һәм Гариф Ахунов белән бергәләп язучыларның тормыш-көнкүрешен җайлауда байтак игелекле гамәлләр башкарыла. Әдәби фондның Мәскәүдәге җитәкчеләреннән дәлилләп-даулап алынган акчалар исәбенә берничә дистә язучының фатир шартлары уңайлаштырыла.*

*Лирон Хәмидуллин 1977 елны СССР Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителә. Бу инде җәмәгатьчелекнең аны язучы итеп тануы дигән сүз. Бу урында, әдипнең иҗади хезмәтләре турында тәфсилләбрәк сөйләү алдыннан, беркадәр ретроспектив планда чигенеш ясап алу кирәктер, һәрбер аерым язучы хакында уйланганда, гомумәдәби хәрәкәт турында фикер йөртми мөмкин түгел.*

*Еш кына татар әдәбиятын Зур Иделгә тиңлиләр. Иделгә төрле тарафлардан эреле-ваклы бихисап күп елгалар һәм чишмәләр килеп кушыла. Аларның куе урман төпкелләреннән каралып агып чыкканнары да, тигез иңкүлек яктан сабыр гына агып төшкәннәре дә бар. Һәрбер инеш-елганың үз куәте, үз төсе һәм тәме булган кебек, татар әдәбиятына төрле тарафлардан килеп кергән иҗат әһелләренең дә үзләренә генә хас сыйфатлары һәм үзенчәлекләре сизелеп тора. Әйе, Зур Иделгә тиң татар әдәбияты мохитенә килүчеләр дә язмышлары һәм иҗатлары белән төрле-төрле. Бигрәк тә бу төрле-*

*лек узган гасыр әдәбиятына хас иде. Аңа төрле тарафлардан үзенчәлекле үз биографияләре һәм тормыш тәҗрибәләре белән бик күпләр килеп кергән, илһамланып иҗат иткән. Өлкән буын әдипләребезне тудырган җирлек бик киң. Күренекле язучылардан Шәриф Камал белән Кәрим Тинчурин — Пенза губернасында, Габдрахман Әпсәләмов белән Һади Такташ «Тамбов урманнары» төбәгендә туып үскәннәр. Гадел Кутуй мәктәп тәрбиясен — Самарада, Сәгыйть Рәмиев, Шамил Усманов һәм Муса Җәлил Оренбург шәһәрендә алганнар. Ибраһим Салахов, Нури Арслан, Мәхмүт Хөсәен — ерак Казакъстан җире балалары. Әнвәр Давыдов белән чордашым Рөстәм Миңгалим күрше Самара өлкәсе авылларыннан. Себер-Урал тарафларында үскән Сәрвәр Әдһәмова белән Абдулла Әхмәт, Нижгар якларында туган Кави Нәҗми һәм башка бик күпләр татар әдәбияты мохитенә урау юллар белән килгәннәр. Ләкин шунысы хак — башлангыч милли белемне алар үз туган төбәкләрендә үзләштергән шәхесләр. Үз авылларында, үз калаларында башлангыч белем алгач кына, Казан җирлегендә белемнәрен камилләштерә төшеп, язучы буларак танылганнар. Хәзер Татарстаннан читтәге төбәкләрдән килеп (Башкортстанны санамаганда), татар әдәбияты дөньясына кереп китә алырдай каләм әһелләре бик сирәк. Чөнки ул төбәкләрдә хәзер татар мәктәпләре бетерелгән, бик күпләр өчен үз милли телендә белем үзләштерү мөмкинлеге бик тә чикләнгән. Никита Хрущевның милли мохтариятләрдән читтә урнашкан мәктәпләрне ябуга юнәлтелгән мәгълүм карары чыкканчыга чаклы үз телендә бераз булса да белем үзләштергән кайбер олырак буын вәкилләре генә аратирә күренгәләп куя. Шундый язмышлы язучылардан без бүген берничә исемне генә атый алабыз. Алар арасында Лирон ага Хәмидуллин да бар. Әйе, җитмеш биш яшен тутырган язучы Лирон Хәмидуллин әнә шундый соңгыларның берсе инде.*

*Әдәби фондтагы хезмәтеннән соң Л.Хәмидуллин ун елга якын Татарстан китап нәшриятында матур әдәбият мөхәррире булып эшләде. Татар укучысы кулына кергән йөз иллеләп китапның саф әдәби телдә, зәвыклы булып чыгуы өчен тырышты. 1998–2005 елларда Татар энциклопедия институтында өлкән фәнни хезмәткәр вазифасын башкарды. Энциклопедиянең татар телле вариантын әзерләп чыгаруда катнашты. (Энциклопедик сүзлектә һәм томнарда егермеләп үз мәкаләсе дә бар.)*

*Аңа 1982 елда «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.*

*Лирон Хәмидуллинның әдәби әсәрләре алтмышынчы еллар урталарыннан күмәк әдәби җыентыкларда, газета-журнал битләрендә күренә башлый. Яшь һәм башлап язучыларның «Яшьлек таңы», «Кайнар хисләр» җыентыкларында дөнья күргән һәм башка хикәяләре җирлегендә 1968 елда аның беренче хикәяләр*

*китапчыгы басылып чыга. 1971 елда тимер юл төзүчеләр тормышын сурәтләгән «Дала иртәсе» повесте басыла. Бу китапларда дөнья күргән әсәрләргә карата үз вакытында вакытлы матбугатта уңай фикерләр әйтелә. Мәсәлән, 1972 елда басылган бер мәкаләсендә Хәсән Сарьян, каләмдәше иҗатына тукталып, түбәндәге сүзләрне яза: «Бүген үк инде күз уңыннан төшермәс яшь иҗатчыларыбызның берсе — Лирон Хәмидуллин. «Дала иртәсе» повесте аның икенче китабы... Әдәбиятка ул, кайбер яшьләребез кебек, институт яки университетның филология факультетыннан гына сикереп төшми, ә тормышның эченнән үз дөньясы белән килә. Бу да язучы өчен бик кирәкле шәйдер... Автор күзәтә белә, шул күзәтүләрен детальләр аша уйлый белә, шуларга үз сүзен таба белә».*

*Проза үзенчәлекләрен яхшы белүче әдәбият тәнкыйтьчесе Фәрваз Миңнуллин да соңрак язучы Л.Хәмидуллин хикәяләрен уңай бәяләп язды. Аның 1989 елда нәшер ителгән «Затлылык» китабында мондый юллар бар: «Матур әдәбият дөньясында «бу мин» дип әллә каян кычкырып торган талантлар арасында һәрвакыт тыныч һәм салмак кына үз эшен эшләп, шуңардан тәм һәм ямь табып яшәүче тыйнак язучылар була. Лирон Хәмидуллин — шундыйларның берсе. Ул безнең әдәбиятның күгәрчен күзе үләне... Әйбәт тәрҗемәче булу белән бергә Лирон Хәмидуллин үзенчәлекле прозаик та... Үзенчәлеге нидән гыйбарәт? Ышандырырлык һәм тормышчан булулары өстенә аның әсәрләрендә тел белән сөйләп, аңлатып бирүе кыен булган, әмма укучыны иләсләндерә, аның күңелен нечкәртә торган үзгә бер моң, настроение, эчке көй бар. Әйтик, «Кыш үткән юл буйлап» яки «Буранда» хикәяләрендә...»*

*Л.Хәмидуллин үз иҗатының кимендә яртысын тәрҗемә эшенә багышлагандыр, мөгаен. Шуңа күрә аның ул өлкәдә башкарган кайбер хезмәтләрен дә барлап үтү кирәкле шәйдер. Замнында, ягъни Язучылар берлегендә эшләү дәверендә, аңа кардәш әдәбиятлар белән элемтә тоту, тәрҗемә эшен җайга салу бурычлары да йөкләнә. Ун ел чамасы ул тәрҗемәчеләр секциясе җитәкчесе булып эшли. Җитмешенче, сиксәненче елларда ул Казакъстанда татар повестьлары китабын, Үзбәкстан белән Каракалпакстанда хикәя җыентыкларын туплап чыгара. Күренекле казакъ әдипләреннән Абайның шигырь һәм чәчмә хезмәтләре җыентыгы «Абай»ны, Әнүәр Әлимҗановның ике повестен берләштергән «Отрар хатирәсе» китабын, Сайын Моратбәковның повесть һәм хикәяләрен туплаган «Әрем исе» җыентыгын, Мохтар Магауинның «Кара кыз» повестен, үзбәк телендә иҗат итүче милләттәшебез Әсгать Мохтарның «Чинар» романын татар укучысы бүген Лирон Хәмидуллин хикәяләвендә укый. Мәшһүр белорус әдибе Василь Быковның сугыш темасына багышланган ике повестен берләштергән «Һәйкәл» китабы да Лирон аганың зур хезмәте булып саналырга лаек.*

*Бу уңайдан тәрҗемә турында язучының үз фикерләрен искә алып узу да кызыклы. Бүгенге көндә милли телләргә тәрҗемә итү эше бик актуаль һәм шул ук вакытта бәхәсләргә дә сәбәп булган мәсьәлә. Моннан берничә ел элек хәбәрченең: «Татар укучысына бүген дә тәрҗемә әсәрләре кирәкме?» — дигән соравына Лирон аганың җавабы мондый: «Бик кирәк. Бер генә әдәбият та үз-үзенә бикләнеп кенә яши алмый. Һәркемгә башкалар белән көндәлек аралашу зарур булган кебек, әдәбиятлар да үзара аралашмыйча зур уңышка ирешә алмый. Ә казакъ әдипләре әсәрләренә минем тарафтан өстенлек бирелүнең ике сәбәбе бар. Беренчедән, авыл мәктәбеннән соң мин дүрт ел Казакъстанда укыдым, казакъ яшьләре белән дә аралаштым. Икенчедән, мәктәп елларыннан бирле мин тарихи әдәбиятка өстенлек бирә килдем. Борынгы төрки дөнья мине элек-электән кызыксындыра. Татар әдәбиятында төркиләр тарихын чагылдырган әсәрләргә юл ябык булган елларда казакълар бу өлкәдә алда баралар иде. Шул сәбәпле мин иң әүвәл казакъ әдәбиятына мөрәҗәгать иттем... Бүген дә тәрҗемә әсәрләре бик кирәк. Шул ук төркиләр тарихына багышланган әдәби яки иҗтимагый эчтәлекле күпме китап басылып чыга хәзер? Бездә аларны язардай әдипләр дә, галимнәр дә сирәк. Ул өлкәне яхшы белеп һәм бирелеп эшләгән Миркасыйм Госманов, Нурихан Фәттах, Мөсәгыйт Хәбибуллиннар гына ул эшне башкарырга өлгерә алмыйлар».*

*Тарих һәм әдәбият галиме, академик Миркасыйм Госманов Лирон аганың эшчәнлегенә багышланган мәкаләсендә болай дип яза: «Аның әдәби иҗатында махсус тәкъдир итүгә лаек бер юнәлеш бар. Ул — элекке чор күренекле әдипләребезнең тормыш юлларын, мирасын өйрәнүгә багышланган эзләнү һәм бастырып чыгару эшләре. Мәгълүм драматургыбыз Мирхәйдәр Фәйзи белән атаклы шагыйребез Дәрдемәнд хакында махсус эзләнүләр башкарылу, шул максат белән алар эзеннән йөреп, Башкортстандагы Җиргән, Юлык авылларына, Баймак шәһәренә барып чыгулар, Чиләбе өлкәсендәге Балкан, Требия авылларында, Уфа, Оренбург шәһәрләрендә эзләнүләр, әлеге әдипләрнең оныкларын, туганнарын эзләп табу, алар белән хат алышулар, ниһаять, архивларда казынулар. Шулар нәтиҗәсендә җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп иткән «Офыктагы рәшәләр» китабы һәм «Галиябану туган якларда» исемле юлъязмасы барлыкка килә... Бал корты кебек гел эзләнүләрен, шау-шусыз гына нәтиҗәле эшләвен дәвам итә».*

*Әйе, Оренбург өлкәсенең Орск шәһәрендә эшләү дәверендә үк Лирон Хәмидуллин тормыш-яшәешләре шул шәһәргә бәйле булган кайбер олуг шәхесләрнең иҗаты һәм мирасы белән кызыксына, аларны белгән кешеләр белән аралаша. Шул рәвешле, үзенчәлекле шагыйрь, атаклы нашир һәм җәмәгать эшлеклесе Закир Рәмиев-Дәрдемәндкә, күренекле драматург Мирхәйдәр*

*Фәйзигә, узган гасыр башында «таңчылар» хәрәкәтендә актив катнашкан Г.Исхакый, Г.Тукайларга сердәш-дус булган Шакир Мөхәммәдъяровка, герой-шагыйрь Муса Җәлилнең Орск, Оренбург чоры эшчәнлегенә мөнәсәбәтле документаль әсәрләре барлыкка килә. Ул хезмәтләрнең бер өлеше язучының 1990 елда нәшер ителгән «Офыктагы рәшәләр» китабында урын алды. Дәрдемәндкә багышланган «Офыктагы рәшәләр» документаль повестен үз вакытында «Казан утлары» журналы да бик теләп бастырып чыгарган иде. Соңрак шул вакытта тупланган язмалар һәм Дәрдемәнднең дүрт оныгы белән аралашулар нәтиҗәсе буларак, «Тарихта үз эзләре бар» һәм «Рәмиевләр матбагасы» документаль очерклары да языла. Алар «Бертуган Рәмиевләр» күмәк җыентыгында дөнья күрде. (Күпсанлы фотолар белән баетылган ул җыентык Миркасыйм Госманов җитәкчелегендә 2002 елда нәшер ителә.) Дистә еллар дәвамында Дәрдемәнд баскан эзләрдән йөрү, аның рухы сакланган җирләрдә һәм архивларда булу нәтиҗәсендә Дәрдемәндкә багышлап фотоальбом чыгару хыялы туа. 2003 елда, ниһаять, ул хыял да тормышка аша, «Дәрдемәнд» альбомы басылып чыга. Альбомдагы төп текст авторы — Лирон ага Хәмидуллин.*

*Лирон Хәмидуллинның соңгы ике китабына кергән яки вакытлы матбугатта, шул исәптән «Казан утлары» журналында басылган соңгы дәвер әсәрләренең төп темасы милләт язмышын кайгыртып яшәгән шәхесләр эшчәнлегенә бәйле. (Укучыларның исенә төшереп китик: мәшһүр гармунчы Фәйзулла Туишевка багышланган документаль повесте журналыбызда басылды.) Үз милләтенең киләчәге өчен җан атып яшәгән зыялыларыбыздан Дәрдемәнд, Галимҗан Ибраһимов, Габделбари Баттал, Йосыф Акчура, Камил Мотыйгый һ.б.га багышланган документаль повесть, очерк, эссе кебек әсәрләрен автор, минем карашымча, шулай ук үз халкына файда китерим дигән максаттан чыгып башкара. Әйтик, Г.Ибраһимовның биографиясен һәм иҗатын барлаудагы кайбер проблемаларны күтәргән бер язмасы туксанынчы елларда безнең журналда дөнья күргән иде. Хәзер ул хезмәт җитди бер фәнни басмада да урын алды (кара: «Галимҗан Ибраһимов», 2007).*

*Әйе, әсәрләре геройларына хас рәвештә, авторның үзенең дә тоткан төп мәсләге — үз халкына хезмәт итү. Узганнар мисалында яшь буынга дөрес юл күрсәтергә тырышу. Хәер, һәр җитди иҗат иясенә — прозаикмы ул, шагыйрьме, абруй казанган журналистмы — хас бер изге максат инде ул. Кулына каләм алган күпчелекнең хыялында халкы күңеленә хуш килердәй әсәр иҗат итү. Алда әйтелгәнчә, һәркем ул максатка үз юлы белән килә. Зур Иделгә койган инеш-елгалар төрле булган кебек, һәр каләм иясенең дә иҗат юлы төрлечә булуга карамастан, төп максаты — әдәби мохит дигән зур диңгезгә халкы өчен мәгънәле дип тапкан үз сүзен ирештерергә теләү. Лирон*

*аганы шул максатына ирешүгә якын торучылар исәбенә кертеп буладыр, шәт. Иҗат юлын иртәрәк башлаган булса, бәлки, иҗат хәзинәсе күбрәк тә булган булыр иде... Нишлисең — язмыш. Булганына шөкер итеп, куаныргa кала. Шунысы куандыра: ул һаман эштә, хәрәкәттә, иҗат юлында. Аның әле башлам чорын үткән, әмма дөнья күрергә өлгермәгән хикәя һәм повестьлары да бар.*

*Кеше, әгәр ул шәхес дәрәҗәсендә икән, аның максаты иманнан, сүзе эшеннән аерылмаска, үткәне хыялдагы киләчәгенә табигый һәм эзлекле тоташкан, гамәлләр төене бербөтен булырга тиеш. Бу җәһәттән Лирон аганы мин шәхес дип саныйм. Ул үзенең гаиләсен, якыннарын үз кыйбласына юнәлтә алды. Хатыны Дания ханым гомере буе әдәбият-сәнгать кешеләрен хөрмәт итеп яшәде, озак еллар Язучылар берлегендә исәп-хисап өлкәсендә эшләде. Булдыра алганча язучыларга ярдәм итәргә тырышты. Бер сүз белән әйткәндә, үзебезнең кеше. Улы — Булат Хәмидуллин — хәзер инде үзе күренекле зат. Ул — галим, тарих фәннәре кандидаты, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, «Фән» нәшриятының баш мөхәррире. Күп кенә фәнни хезмәтләр авторы. «Казан ханлыгы халыклары» дигән зур хезмәте рус (2002) һәм татар (2008) телләрендә Татарстан китап нәшриятында аерым китаплар булып чыкты. Ул, әтисе кебек үк, тәрҗемә өлкәсендә дә уңышлы эшләп килә. Кызы Зөһрә Хәмидуллина, КДУны тәмамлап, дәүләт оешмасында эшли, милли рухта бала үстерә... Күренеп тора: гаиләдә уртак максатта дәвамчылык бар. Димәк, киләчәккә өмет-ышаныч бар.*

*Лирон аганың 2002 елда нәшер ителгән «Ак төннәр хәтере» китабына соңгы елларда иҗат ителгән әдәби очерк, эссе, хатирәләре кергән иде. Русча ул китап «Белые ночи памяти», ягъни йокысыз төннәр хәтере буларак тәкъдим ителә. Ул китапның тулы эчтәлегенә тукталып тормастан, андагы әсәрләрнең дә башлыча татарның күренекле вәкилләре эшчәнлегенә багышланган булуын әйтеп үтү кирәктер. Андагы язмаларның исемнәре үк шул хакта сөйли: «Онытылган якын исем», «Милләт хадименең көрәш юллары», «Күләгәдә калган шәхес», «Тираннан типкән чишмәләр» һ.б.*

*Бүгенге көндә Лирон Хәмидуллинның нәшер итүгә әзерләнгән ике китабы бар. Берсе — документаль эчтәлекле очерк, эссе һәм хатирәләре тупланган, Татарстан китап нәшриятына тәкъдим ителгән әлеге «Кичке шәфәкъ» җыентыгы. Төрле җыентыкларда, журнал битләрендә дөнья күргән хикәя һәм повестьлары да чиратта. Иншалла, аларның тиз көндә нәшер ителәчәкләренә өметләнеп калыйк.*

*РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН,*
*Татарстан Республикасының халык шагыйре*

# Офыктагы йолдызлар

# ӘЙ ГАРМУН, ГАРМУН...

*(Документаль повесть)*

## Һәр җирдә тансык кунак

Мәшһүр гармунчы артист Фәйзулла Туишевны, мөгаен, үз вакытында сәхнәдә күрмәгән, һичьюгы, аның бик тә үзенчәлекле, дәртле, моңлы итеп уйнавын радио аша ишетмәгән бер генә татар кешесе дә калмагандыр. Ник дисәң, илле елдан ашып киткән иҗат гомерендә бу тынгысыз музыкантның концерт белән бармаган җире, төрле зурлыктагы чеңгелдәп торган үз гармуннарын уйнамаган сәхнәсе калмагандыр. «Фәйзулла Туишев милләтебезнең горурлыгы, халык арасыннан чыккан чын талант», — дип язды аның турында күренекле язучыбыз Фатих Хөсни.

СССР дип исемләнгән дәүләт оешканчы ук әле ул көмеш телле гармуннарын иңенә асып Каф таулары артындагы Баку, Тифлисләрне дә, Мәскәү белән Петербургларны да, ерак Себер шәһәрләрен дә йөреп, урап чыга. Йөри-йөри җир читендәге Владивостокка да барып җитә, чит мәмләкәт шәһәре булган Харбинда да торып кайта. Болар белән генә чикләнмичә, Европаның мәдәни үзәге саналган Парижның үзендә зыялы тамашачы алдына чыгып, татар белән рус халыкларының моң-көйләрен уйнап дан ала. Анда ул икенче бер мәшһүр якташыбыз Федор Шаляпин белән бергә бер сәхнәдә чыгыш ясау бәхетенә ирешкән артистларның бик сирәгедер. Фәйзулла Туишевны һәр җирдә бик теләп, яратып кабул иткәннәр. Ул җитәкләгән артистлар бригадасы Татарстанның һәм аңа чиктәш өлкә һәм республикаларның барлык татар авылларында булып кайткан диярлек. Әйе, аның җитез бармаклары күңел түрендәге халкы моңын, сагышларын бик мул өләшкән. Аның уйнау осталыгына сoклануларын милләтебезнең бик мәгълүм шәхесләре Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал һ.б. бик күпләр әйтеп һәм язып калдырган. Тиешле бәяне үз вакытында ук биргәннәр.

1950–1960 елларда урамда очраган һәрбер татар кешесеннән: «Син гармунчы Туишевны беләсеңме?» — дип сорасаң, ул кеше ике дә уйлап тормас, «беләм» дип җавап бирер иде. Кайсы як авылыннан, кайсы шәһәрдән килгән булуына карамастан.

Артист чордашларының искә алуларына һәм сакланып калган афишаларга таянып, Фәйзулла Туишевның кайсы зур шәһәрләрдә һәм кайчан булганлыгын күз алдына китерә алабыз. Үзе туып үскән төбәктәге Сембер, Самара, Казан, Түбән Новгород һәм Идел буендагы башка барлык шәһәрләрне ул иң беренче гастрольләре вакытында ук йөреп чыга. Аңа ул вакытта әле егерме яшь

кенә була. (1910 еллардагы артист кыяфәтен күзаллардай фото сакланган. Артист гитарада уйный, янәшәсендә гармуны чират көтеп тора.) Ә туган-үскән җирләреннән ерак-еракларга таралышып көн күрергә мәҗбүр ителгән милләттәшләребез исә сөекле музыкантны һәркайда да сагынып каршы алган. Мәһабәт буйсынлы, көләч йөзле артистның шат елмаеп сәхнә түренә чыгып басуын, шундагы өстәл өстенә тезеп куелган эреле-ваклы гармуннарның берсен алып уйный башлавын түземсезләнеп көтеп торганнар. Концертны алып баручы:

— Фәйзулла Туишев уйный! — дип белдерүгә үк, гөрләтеп кул чабулар башланган.

Хәер, Фәйзулла Туишевның гармунда уйнавын татар тамашачысы гына түгел, башка халык вәкилләре дә бик яратып тыңлаганнар. Аның уеннары аша татар халкының эчке рухын үз итеп күңелләренә сеңдерә торган булганнар. Моның шулай икәнлеген без матбугат битләрендә теркәлеп калган истәлек язмаларыннан да укып беләбез. Мәсәлән, танылган артистның илле еллык юбилеена багышланган бер мәкаләдә Муса Җәлил болай дип язган: «Фәйзулла ага төрле милләт көйләрен өйрәнүгә һәм аларны оста уйнап бирүгә күп игътибар куя. Ул казакъ, үзбәк, азәрбайҗан, кавказлы, чуаш, чегән һ.б. азчылык милләтләрнең хәзерге композиторлары әсәрләреннән һәм халык көйләреннән күп кенә үрнәкләр уйный. Шунлыктан Фәйзулла аганың музыка өлкәсендәге хезмәте интернациональ төс ала...» Мәкалә СССР Югары Советы нәшер иткән татарча «Коммунист» газетасында 1934 елның 30 декабрь санында басылган.

Совет хакимияте урнашуының ун еллыгы көннәрендә, 1927 елда Мәскәүдә СССР халыкларының сәнгать фестивале үткәрелә. Илнең төрле төбәгеннән килгән театр коллективлары үз осталыкларын, ә концерт бригадалары үз һөнәрләрен башта таләпчән комиссияләргә күрсәтергә, шуннан соң халык алдында чыгыш ясарга тиеш булалар. Татарстаннан килгән концерт бригадасына композитор Салих Сәйдәшев, танылган җырчылар Гөлсем Сөләйманова белән Газиз Әлмөхәммәтев һәм төрле халык көйләрен бер дәрәҗәдә оста башкаручы Фәйзулла Туишев керәләр.

1940 елның мартында классик әдибебез Шәриф Камалның иҗат итә башлавының утыз еллык бәйрәме Мәскәүдә билгеләп үтелә. СССР Язучыларының мәдәният сараенда уздырылган ул кичәгә Казаннан әдипнең иҗатташлары Афзал Шамов, Таҗи Гыйззәт, Гази Кашшаф һәм күренекле артистлар баралар. Алар арасында Ш.Камалның якын дусты, яшьтәше Фәйзулла Туишев та була. Мәскәүдә яшәүче мәгълүм язучылар һәм СССР Язучылар берлеге рәисе Александр Фадеев та ул кичәдә катнаша. Әдәбият белгече, шул тантана кичендә Ш.Камал иҗатына багышлап

нотык сөйләүче Гази Кашшаф соңрак язган мәкаләсендә «мәшһүр гармунчы Ф.Туишев»ның мәскәүлеләр тарафыннан аеруча җылы каршы алынганлыгын бәян итә. Кичәнең рәсми өлешеннән соң да артистны кабат-кабат уйнарга чакыралар. Шул кичәдә ул татар һәм рус көйләрен, кайбер композиторларның әсәрләрен баянда һәм башка төрле гармуннарда виртоузларча оста башкаруы белән дан казана. Шул хакта Гази ага Кашшаф: «Бу кичтә виртоуз гармунчы үз стихиясендә иде», — дип яза.

Татарстанның халык артисты Хәким Сәлимҗанов мәшһүр гармунчы белән бергә байтак кына концертларда катнаша. «Озак еллар чит җирләрдә йөргәч, ниһаять, сөекле, дәртле, моңлы Казанга кайтты. Татар дәүләт академия театрында Фәйзулла аганың Казанда беренче концерты булды. (Бу очракта сүз, әлбәттә, Совет хакимияте чорына караган беренче концерт турында бара.) Миңа бу концертта Туишевны тамашачылар белән таныштыру һәм кичәне алып баручы вазифасын үтәргә туры килде. «Хәзер, хөрмәтле тамашачылар, сезнең алдыгызда Фәйзулла ага Туишев», — дип белдерүгә, залдагы алкышларны язып та, сөйләп тә аңлатуы кыен. Тамаша залы гөр килде», — дип яза артист, оста гармунчы белән беренче очрашу кичәсен искә алып. Һәм болай дип дәвам итә: «Шул заманда ул иң зур баяннан алып шырпы тартмасы кадәр генә гармуннарда уйнаучы бердәнбер артист иде. Беренче бүлектә ул татар егете кыяфәтендә ыспай итеп киенгән. Чиккән кәләпүш, камзул, читектән — матур сынлы, соклангыч булып күз алдына килеп баса. Бу бүлектә фәкать татар көйләрен башкарды. Ә икенче бүлектә русча киенеп, рус халык көйләрен уйнады. Гармунда уйнау белән генә чикләнмичә, бик оста итеп биеп тә җибәрә иде. Минем аңа кадәр һәм аннан соң да Фәйзулла абзый кебек виртоуз башкаручыны очратканым булмады».

Хәким Сәлимҗановка соңрак та берничә мәртәбә Фәйзулла ага белән бергә концертларда катнашырга туры килә. Ә Мәскәүдә 1941 елда узарга тиешле татар әдәбияты һәм сәнгатенә әзерлек көннәрендә ул башкаладан килгән кабул итү комиссиясе вәкилләре белән аралаша. «Мәскәү комиссиясе алдындагы смотрда Фәйзулла ага да катнашты. Башкала вәкилләре аның иҗатына иң югары бәяне бирделәр. Мондый оста башкаручы безнең рус дөньясында да сирәк дигән фикергә килделәр», — дип искә ала Хәким ага. Сугыш башлану сәбәпле ул декада булмыйча кала. Шул сәнгать бәйрәмендә катнашырга дип сайлап куелган артистлар, аерым бригадаларга билгеләнеп, яу кырындагы сугышчыларны рухландырып, концерт куеп йөрергә мәҗбүр булалар. Алтмыш яшенә җитеп килүче Ф.Туишев та шундый төркемнәрнең берсен җитәкли. Аның «фронт бригадасы»на Татарстанның халык артисткасы Галия Кайбицкая да керә. Останың көмеш чыңлы гармун телләрен тибрәтеп

уйнавы сугышчыларның күңелләрен җилкендереп җибәргәндер. Туган-үскән якларыннан сәлам буларак кабул ителгәндер. Сәхнә ветеранының ике зур чемоданга тутырылган төрле зурлыктагы гармуннарын күтәреп Бөек Ватан сугышы фронтларына барып чыгуы, туп гөрселдәүләре тынып торган минутларда сугышчылар өчен ялкынланып уйнавы бик күп ветераннар хәтерендә сакланып калган.

Әйе, кайларда гына уйнамасын — фронт шартларындамы яисә кичерәк бер авылның кечкенә генә клубындамы, аны һәрчак үз итеп, якын күреп кабул иткәннәр, уйнавын бирелеп тыңлаганнар. Үзен яратып калганнар. Аның моңлы да, дәртле дә итеп төрле зурлыктагы, төрле тавышлы гармуннарда оста уйнавы кешеләрнең күңелләрен юаткан, тормышның гүзәллекләрен тоярга ярдәм иткән, сагышларын тараткан.

Кайларда, ничегрәк башланган соң олы дан-шөһрәт казанган бу артистның тормыш юлы? Кем аны шулай тәрбияләп үстергән? Кайсы төбәк җир-суының баласы ул? Истәлек-язмаларда бу сорауларга әлегә төрлечә җавап бирелә. Аңа багышлап 1939 елда «Гармунчы» повестен язган күренекле әдип Фатих Хөсни артистны Мәләкәс шәһәрендә туып үскән дип бәян итә. Соңрак дөнья күргән кайбер башка язмаларда да, «Гармунчы» авторына ияреп булса кирәк, Ф.Туишевның туган җире итеп шушы шәһәр күрсәтелгән. Ә бит Ф.Хөсни повестеның беренче бүлегендә үк, бу әсәр артистның тулы биографиясен чагылдырмый, дип кисәтә. Татарстан китап нәшриятында 1980 елда басылып чыккан күләмле «Народные артисты» китабында да: «Родился в поселке Мелекес ныне Ульяновской области», — дигән сүзләр язылган. Һәм иҗади-биографик белешмә урынына әлеге повестьтан кыскача өзек китерелгән. (Ул китапта башка төгәлсезлекләр дә байтак. Мәсәлән, танылган җырчыбыз Рәшит Ваһаповны да анда биш елга иртәрәк гүр иясе итеп күрсәткәннәр.)

Дөрес, кайбер очракларда артист үзе дә, мөгаен, оста гармунчы булып китүенә бәйле рәвештә, яшүсмер чоры Мәләкәсен ешрак телгә ала торган булгандыр. Әйе шул, Олы Чирмешән елгасы буендагы нәкъ шушы шәһәрдә ул беренче булып кулына гармун ала. Музыкант буларак шушында «туа». Икенче бер мәшһүр якташыбыз, рус әдәбияты классигы Максим Горький да бит әнә, Түбән Новгородта дөньяга килүенә карамастан, «шәхес буларак мин Казан шәһәрендә тудым» дип яза.

## Ямьледер Чирмешән буйлары

Фәйзулла Туишевның беренче мәртәбә тәпи баскан җире шул ук Олы Чирмешән елгасы янәшәсендәге Иске Төгәлбуга авылы була. Ул Мәләкәс (хәзерге Димитровград) шәһәреннән кырык чак-

рым чамасы үрдәрәк урнашкан. Артист туган вакытта авыл Самара губернасының Самара өязенә караган. (Югыйсә Ф.Туишевны «Сембер губернасында туган» дип хата язу очраклары да еш кабатлана.) Утызынчы елларда Иске Төгәлбуга, Урта һәм Иске Исәнтимер, Өчкаен, Әбдери, Алга, Төплистан, Зирекле Куак, Иске Җүрәй кебек бер төбәктә урнашкан татар авыллары Куйбышев өлкәсе карамагында булды. 1943 елдан алар Ульяновск өлкәсенең Яңа Малыклы районына керәләр (Төплистан белән Иске Җүрәйдән кала). Иске Төгәлбугада туган кеше буларак, миңа артистның балачак биографиясе бик тә таныш. 1939 елның март урталарында гармунчы туган авылында зур концерт куйды. Мин дә анда тамашачы булдым. Җиденче яшьтә чагымда. Ул вакыйганың кайсы көндә барганын төгәл хәтерләмим. Шунысы хәтеремдә: клуб диварларына еракtan күңелне җәлеп итеп торучы зур плакатлар эленгән иде. Анда чәчәкләр арасыннан шат елмаешып торучы хатын-кыз рәсемнәре һәм буйдан-буйга сузылган сигезле саны бар иде. Иске Төгәлбугада ике көн барган ул концерт, димәк, март аенда булган. Аңа күрше-тирә авыллардан да бик күп кеше килгән иде. Урта Исәнтимердә эшләгән әтием һәм аның юлдашлары да ул кичтә, берничә олауга төялеп килеп, Иске Төгәлбуга клубында Фәйзулла аганың уенын бирелеп тыңладылар.

1958 елда җитмеш дүрт яшендә Казанда вафат булган авылдашым Фәйзулла Туишевны башка вакытта күрмәсәм дә, аңа багышлы истәлекләрне балачактан ук ишетеп үсәргә насыйп булды. Алтмышынчы-җитмешенче елларда исә олуг артист белән бергә уйнап үскән яисә соңрак якыннан аралашкан кешеләрдән язып алган каралама язмаларым да бар. Ул елларда әле Иске Төгәлбуга авылында «Курай урамы Фәйзүге»нең бала чагын яки туган-үскән төбәгенә «концерт куярга» кайтып йөргән заманнарны хәтерләүчеләр байтак иде. Сугышка кадәр мәшһүр артист туган якларына еш кайта. Ул елларда авылда әле аның якын туганнары да исән була. Олуг артистның бер кайтуында булачак тарихчы Җәмил Гыйльманов аңа пионер галстугы да тагып җибәрә. Ул вакыйга клубта булганмы яисә мәктәп балалары белән очрашудан соңмы — ачыкламаганмын.

Чирмешән буйлары ямьле,
Ял итәргә килегез;
Эштә уңган егетләрне
Безгә килеп күрегез, —

дип җырлана халык җырында. Иске Төгәлбуга авылы да бик ямьле җирдә, Чирмешәнгә коя торган елгачык буенда урнашкан. Ул елгачык Иске Җүрәй янәшәсендәге үрдә башлана да, күрше чуаш авылы аша үтеп, Иске Төгәлбуганың кыйбла башына килеп керә.

Елга, аръяктагы урам буйлап бераз баргач, авыл эченә таба борылып ага башлый. Авылның төньяк очыннан Чирмешәнгә бер чакрым чамасы ара. Ул урында елга, дугаланып, бездән берникадәр ераклаша төшә. Елга белән ике арада күлле-баткаклы Чалу болыны, урман алды агачлыгы һәм урман колаксасы рәвешендә куерып үскән шомыртлык бар. Ә Чирмешәннән соң инде киңлеге егерме-утыз чакрымлы зур карурман башланып китә. Ә озынлыкка ул урман очсыз-кырыйсыз, Олы һәм Кече Чирмешәннең буеннан-буена килеп, Биләр тарафына таба сузыла. Әбиемнең Татарстан чигендәге туган авылы Пәраугa балачакта шул тоташ нарат урманы аша атта да, җәяү дә барганым хәтердә калган.

Үз төбәгендә Иске Төгәлбуга зур тарихлы авыл санала. Ул Казаннан элекке Нугай иленә һәм Самара каласына илтүче олы юл өстендә оешкан. Кайчандыр шунда булып киткән бер галим-сәяхәтче аның борынгы тарихлы авыл икәнлеген язып калдырган. Авылның исем-атамасында да борынгы кыпчак-мишәр чалымы чамалана. Ил, ыру башы булырдай ирләрне нәсел үгезенә тиңләп, төрле сыйфатлы «буга», шул исәптән «төгәл буга» (нәкъ үгез) дип атауларына тарихта мисаллар күп. Әйтик, урта гасырлар кыпчакларына нисбәтле «Кодекс куманикус» китабында да Төгәлбуга исемен йөртүче зат булуы теркәлгән. Димәк, бу авыл да кайчандыр Төгәлбуга исемле бер шәхес тарафыннан нигезләнгән. Дөрес, хәзер яшьрәк буын вәкилләре, исем әйтелешен беркадәр җиңеләйтеп, авылны Төгәлбай дип тә атыйлар. Ләкин аның чын тарихи һәм рәсми исеме Төгәл+Буга. 1917 еллардан соңгы үзгәрешләргә кадәр анда җиде йөз унбиш йорт исәпләнгән. Борынгырак заманда ул урман куеныңдарак, хәзерге шомыртлык артында, Олы Чирмешән ярында урнашкан була. Дүрт йөз еллар чамасы элек халкы, качкыннар бимазалавыннан котылыр өчен, көньяккарак күченә.

Авыл төньяктан кыйблага таба сузылган өч чакрымлы дүрт һәм берничә кыска урамнан тора. Аның як-якларында икешәр зират, Иске һәм Яңавыл дип йөртелгән оч-очлар аралыгындагы бушлыкта бишенче, иске зур зират бар. Зур һәм Курай урамнары арасыннан аккан елгачык, урталыктагы биек буага җитәрәк, зур күл хасил итә. Шул күл янәшәсендә унлап йортлы Күл почмагы бар. Шунда элек бәләкәй Фәйзук бер-ике кыш укыган Күл буе мәдрәсәсе булган. Без үскәндә ул мәдрәсә биналарында фельдшер бүлмәсе, китапханә ише җәмәгатьчелеккә хезмәт күрсәтүче оешмалар эшләде. Авыл советы, колхоз идарәсе йортлары һәм ике кибет тә шул тирәгә сыешкан иде. Зур урам белән Күл почмагы чатындагы олы мәчет клубка әверелдерелде. 1939 елда, Фәйзулла Туишев концерт куйганда, ул клуб әле мәчет рәвешен саклый, фәкать манарасы гына юк иде. Ә Курай урамы мәчете манарасы, бала-чага өстенә ишелеп төшмәсен дип, җитмешенче елларда гына сүтелә.

Сугыш алды елларында Курай урамы мәчетенең буш бинасы шул оч балаларының олылардан качыбрак уйнау өенә әверелгән иде. Ябык тәрәзә капкачлары ярыгыннан сузылган яктылык сөңгеләре сихри дөнья тудыра. Шул нурлы сөңгеләр аша сикерә-сикерә малайлар иркен идән буйлап чабышып йөриләр, качыш уеннары уйныйлар. Куышып арыгач, текә баскыч буйлап манарага менеп китәләр. Өркетә-өркетә андагы күгәрченнәрне очыралар. Яки Чапай батыр рәвешенә килеп, манара тәрәзәләреннән тирә-якны күзәтергә керешәләр иде. Иске Төгәлбуга бик тигез җирдә урнашкан. Якындагы дүрт-биш күрше авыл манзарасын шул мәчет манарасыннан күзәтеп торырлык. Зуррак малайлар аннан алтмыш чакрымнардагы Нурлат элеваторы да елкылдап күренә дип мактаналар иде. Ләкин аны күрү өчен бик иртә, кояш чыкканда ук торасы шул. Ә менә җилсез, тымызык көннәрдә мәчет манарасыннан ерак офык читеннән үтеп китә торган поездларның куе-кара төтене бөркелүен шәйләп була иде. Курай урамына классташым Өмид янына барганда малайларның ул уеннарында үземнең дә катнашкан чакларым хәтердә.

Бала чакта Фәйзүк абыйларга мәчет тирәсендә уйнау, манарага менеп паровоз төтене бөркелүләрен күзәтеп тору тыелган була, билгеле. Хәер, ул вакытларда әле Сембер белән Бөгелмә арасында поездлар да йөрмәгән. Хәтта әле «чуен юлы»ның да салынмаган чагы. Ул чор малайларының бирелеп уйнаган урыннары урам чирәмендә һәм су буйларында булган. Тавык-кошны өркетә-өркетә куе әрекмән арасында бер-береңнән качкан булып йөрү дисеңме, хәтфәдәй җәелеп үскән чирәмдә мәтәлчек атынгалап, тәгәрәшеп алулармы — берсе дә ялыктыра торган уеннар түгел. Урамда уйнап ялыксаң, кармак сабын күтәреп, су буена төшәсең. Кемнәрдер шунда су коена, кемнәрдер, бераз читкәрәк барып утырып, кармак сала. Зуррак малайлар исә күлдә балык начар чиртә дигән сылтау белән күңелне ымсындырып торган урман ягына карангалый башлый. Ике-өч малай, бер фикергә килсә, ашкын сулы Чирмешәнгә таба китеп бара. Анда чыннан да балык эре дә, еш чиртә дә. Кармакны салып, йөзеп баручы калкавычны күздән кичереп өлгермисең, ул бата да башлый. Бик уңган, җимне дөрес сайлый белгән оста балыкчылар кайвакыт берәр аршын буйлы җәен балыгын да каптырып ала. Әйе, андый бәхет һәркемгә дә эләкми. Җәеннең кайсы чоңгыл төпкелендә үз корбанын, үз ризыгын көтеп ятуын белү бик читен.

Фәйзүкнең дә керсез, ваемсыз-гамьсез бала чагы баштарак менә шулай узгандыр. Яңа әшнәсе Мөхәммәтша һәм агалы-энеле Биказаковлар белән бергәләп гамьсез генә йөргән чаклары еш булган. Олыларның вак-төяк йомышын үтәүдән бушаган арада, әлбәттә. Олы мәчет янәшәсендә, Зур урамда яшәүче Мөхәммәтша белән Фәйзүк мәдрәсәдә укый башлагач дуслашалар. Шул Кәри-

мев инде бервакыт, арада иң кечкенәләре булган Фәтхи Биказаковны үртәп: «Куян колак Биказак», — дип әйтә дә, шул әйтем Фәтхинең икенче гомерлек кушаматына әверелә. (Фәтхи картның колагы чынлап та чак кына тырпаеп тора иде шул.) Артист буларак танылa башлаган бер вакытта, егерме ике яшендә солдатка каралырга авылга кайткач та Фәйзулла башлыча шушы дуслары белән никрут җырлары җырлашып йөри. Авылдан егерме биш чакрымдагы Зирекле Куакка каралырга барганда аларга җырчы Гүләй Шәфигулласы да кушыла. Соңрак туган якларга кайтканда да гармунчы Мөбарәкша дусты белән күрешмичә китми торган була. Бервакыт алар, яшьлек еллары истәлеге итеп, бергә фотога да төшәләр. Бала чактан аларның серләре килешкән, уй-гамәлләре уртак булгандыр, күрәсең.

Фәйзулла ага туган елларда авыл халкы дүрт мәхәлләгә бүленә. Мәхәлләләрне Кизләү, Мәләкәс мәдрәсәләрендә белем алган муллалар җитәкли. Авылның мәчет имамнарын Иске Җүрәйдәге төбәк ахуны белән Пәраудa яшәүче ишан хәзрәтләре билгеләп куя торган була. Яшел мәчет белән Курай урамы мәчетенең соңгы имамнары да ишан хәзрәтләре нәселеннән чыккан Пәрау авылы кешеләре булган. Иске Төгәлбуганың ике зур мәчете карамагында мәдрәсәләр эшли, Яңавыл очында мәктәп була. (Ул 1934 елда, яңа зур мәктәпне төзегәч ябыла. Бинасында кече кибет — «лавка» ачыла.) Мәдрәсәләрдә кичләрен кычкырып китап уку, аларны күчереп язу үзенә күрә бер мәртәбәле, изге эш саналган. Иске Төгәлбугада борынгы китапларны күчереп язу белән мавыгучылар булганлыгын олы әдибебез Нәкый ага Исәнбәт тә бер әңгәмә вакытында раслаган иде. Утызынчы елларда ул, Татарстан биләмәсеннән көньяктарак калган авылларда булып, кешеләр кулында сакланган кульязмаларны барлап һәм халык авыз иҗаты үрнәкләрен туплап йөргән. «Сезнең Төгәлбугада да булдым. Ул авылның изге җаннары Гаделша, Гобәйдуллалар күчереп язып, тамга салган кульязмаларны соңыннан архивларда да очратканым булды», — дип әйткән иде ул.

## Курай урамы Фәйзүге

Авылның бу урамы башкалардан соңрак барлыкка килгән. Урам исеменнән үк чамаланганча, элгәре анда эре кура-сабаклы үләннәр котырып үсә торган урын була. Зур урам артындагы елгакүлгә янәшәдән генә агып төшүче инеш буе үзәнендә хәзер дә әле әрекмән, елан көпшәсе («елан курае») ише озын куралы үләннәр өер-өер булып утыралар.

Фәйзулла Кәбир улы Туишевның туган йорты Курай урамы мәчетеннән ерак түгел. 1972 елда чордашы Фәтхи ага Биказаков

белән ул урынны карап йөргән идек. Җиргә сеңеп баручы бер иске өй янына җиткәч, ул:

— Кәбир абзыйның төп йортта калган Хөснетдин энесе яңартып төзегән ызба шушы була, — дип төртеп күрсәтте.

Хөснетдин Туктаров Беренче герман сугышында, аның уллары Сәхаб белән Шәмси Бөек Ватан сугышында башларын салып, чит-ят җирдә ятып калган мәхруклар. Әйе, артистның авылдагы нәсел-нәсәбе Туктаров фамилиясен йөрткән. Дөрес, монда андый фамилияле ике нәсел булган. Зуррак тармаклы икенче нәсел башында Шәкүр байның бертуганы Туктар карт торган. Ул нәсел варислары бүген дә авылда һәм авылга якын тирәлектә ишле санала. Курай урамы Туктаровларыннан исә хәзер күрше чуаш авылына бәйле тармактан башка кеше юк. Хәзерге Яңа Чирмешән шәһәрчегендә Кәбир абзыйның кече сеңлесе варислары бар, ди озатып йөрүчем.

Димәк, каршыбызда торган өй чыннан да бик иске инде. Хөснетдин дә аны яңадан төземәгән, фәкать бераз яңарткан гына була. Фәйзүк туган өй элек урам башыннан икенче йорт саналган. Хәзер аларга тагын берничә йорт өстәлгән. Ә шулар артыннан авылны зур дөнья белән бәйләүче үзәк күтәртмә юл үтә. (Сиксәненче елларда ул юлга асфальт та җәелде. Авылдан дүрт-биш чакрымдагы Яңа Чирмешән шәһәрчегенә Самара, Ульяновскидан килүче зур автобуслар шуннан үткәләп тора.)

Фәйзүкләрнең бәрәңге бакчалары авыл аша аккан елга буена төшкән. Курай урамы очына җитәрәк ул елга капылт кына төньякка таба борыла да Олы Чирмешәнгә таба ага башлый. Яз айларында, Чирмешәнгә кушылыр алдыннан, болын буйлап җәелеп, эреле-ваклы күлләр хасил итә. Җәй урталарына ул күлләрдә маймыч балыклар үрчеп чыга. Ташу китүгә, авыл уртасындагы буа яңадан буыла. Күл суы әкренләп Фәйзүкләр бакча башындагы борылышка кадәр күтәрелә, җәелә. Элек ул күлдә бала-чага балык тота, ир-егетләр ат коендыра, хатын-кыз басмаларга басып кер чайкый, ул керне бәләкләп куя торган иде. Илленче еллар ахырларына чаклы Совет чоры авыл тормышы да шул рәвешле барды. Күл буендагы алачыкта чаң-чоң китереп тимер сугалар, иртә-кичен ике яр тарафыннан су чыпырдаган, сырлы бәләк белән кергә йомшак кына суккан авазлар ишетелеп куя. Кыр эшеннән кайткан ир-егетләр атларын пошкырта-пошкырта суга кереп китәләр. Көндезләрен күл өстендә бала-чага чыр-чу килә. Курай урамы тарафындагы текә яр тирәсендә яр буе керәшәләре чыр-чулап баш очында бөтерелешәләр. Кызгылт-кара балчыкка тирән итеп уеп тишелгән түм-түгәрәк ояларында ул кошларның чебиләре ишетелер-ишетелмәс кенә чикылдаша. Тәвәккәлрәк малайларның йомры учлары ул ояларга үрелә башласа, керәшәләр, бер өер бу-

лып, андый батырның өстенә ябырыла. Баш очында җан өркеткеч чинау-черелдәү авазлары күтәрелә иде.

Фәйзулла агалар заманында да ул шулайрак булган. Ат та коендырганнар, бала-чага чыр-чу килеп күл өстендә йөзеп уйнарга да яраткан. Авыл гадәтенчә, Фәйзүкнең апа-сеңелләре дә, мөгаен, иртән дә, кичен дә күбрәк шул төнбоеклы күл буенда, зур-зур өянкеләр тирәсендә кайнашканнардыр. Тирәкләрдә кош сайраган, яр буйларында хатын-кызның сабыр гына моңлану, җырлау авазлары ишетелеп торгандыр. Тар басмага басып алар юынып та алган, керләрен дә чайкаганнар. Утаудан яисә урактан кайткач, чабата белән тула оекны салып, аякны суга тыгып утыру да җангатәнгә рәхәт биргәндер.

Дөрес, Фәйзүкләр бакчасы башында су тирәнлеге, бәлкем, ат коендырырлык ук булмагандыр. Анда елга беркадәр саега һәм тарая төшә. Шул ук вакытта анда бала-чага рәхәтләнеп коенырлык иң шәп урын да иде. Чөнки язгы ташкын борылышның Курай урамы тарафына күп иттереп аксыл-сары ком китереп өя. Ул урынга Зур урам очы малайлары да бик теләп йөриләр иде. Ә борылыштан чак кына өстәрәк, Зур урам белән Аркылы урам башлары кушылган җирдә күлгә саф, салкын сулы Сыза кизләве килеп кушыла. Сыза чокырында элек чишмәләр ишле була, авылның яшь киленчәкләре элек анда чәй суына йөриләр. Яшьрәк чакта артистның әнисе Гөлҗамал да, апа-сеңелләре дә якындагырак чишмәләрнең берсенә суга бара торган булганнардыр. Искавыл очы бала-чагасы, хатын-кызлары ул заманда Сыза буендагы кече урманчыкка җиләк җыярга да йөргән. Авыл очында яшәгән Мокыч токымы да алардан калышмагандыр. Әйе, Фәйзүкнең бабасының халык телендәге исем-кушаматы — Мокыч. Алар — Мокычныкылар. «Мулла кушкан исеме Сафиулла иде бугай», — ди Фәтхи ага.

Без үскәндә инде Сыза буе урманчыгы беткән, тирән яр төбендә сабыр-салмак кына агып ятучы кизләү суын чыпчык атлап чыгарлык иде. Халык телендә Шалкан куагы дип йөртелгән урманчыкның булганлыгын раслап, авылның кырый урамнарындагы бәрәңге бакчалары ызаннарында анда-санда озын, төз нарат агачлары гына күренер иде. Төптән юан, озын, әмма ябалдашы бала башына кигән кәпәч кебек кечерәеп калган шундый бер карт агач Фәйзулла агаларның элекке ишегалды кырыенда да үсеп утыра иде әле.

Кечкенә Фәйзүкне дә, дан-шөһрәт казанган артистны да авылда иң яхшы белүче, ул чор вакыйгаларын яхшы хәтерләүче кеше — Фәтхи ага Биказаков. Курай урамы Туктаровларының элекке күршесе.

Иң әүвәл аның үзе белән чүт кенә танышып үтик. Ул — Фәйзулла агадан ике-өч яшькә кечерәк, шулай булса да аның белән

бик якыннан аралашкан кешеләрнең берсе. Чөнки аның абыйсы булачак гармунчы белән яшьтәш тә, сабакташ та була. Фәйзүк никрутлыкка каралырга кайткан көннәрдә дә бу ике яшьти берберсеннән аерылмый. Яшьтән чая, үткен булган Фәтхи энекәш тә һәрчак аларга иярергә тырыша торган була.

Фәтхи ага какча гәүдәле, уртачадан кечерәк буйлы, җитез хәрәкәтле кеше. «Хәрәкәттә — бәрәкәт» дип олылар тикмәгә әйтмәгәндер. Берәр вакыйга турында сөйли башласа, кем беләндер бәхәсләшкәндәй, шулай булды бит, әйе бит, дип, үз сүзләрен раслатып торырга ярата. Аның яшьтән үткен, чая һәм, үзе әйтмешли, чаманы белеп кенә усал да булганлыгын дәлилли торган мисаллар җитәрлек. Гражданнар сугышы чорында аңа атка атланып, кылыч айкап ярты илне гизеп чыгарга туры килә. Мәләкәс татар атлы эскадронында кече командир да, агитатор да була. Шул сугышта уң кулын гарипләтеп кайта. Колхозларга берләшү елларында берничә артельне оештыруда катнаша. Күрше Әбдери авылында колхоз рәисе булып та эшли. Кылыч яртылай өзгән уң кул чугы белән мылтыктан ата алмасын белгән хәлдә, илле яшендә 1941 елның көзендә үзе теләп сугышка китә. Мәскәү тирәсендәге сугыш мәхшәрен, әсирлек газабын батырларча күрәшеп кичерә. Без аралашкан 1970 еллар башында да әле ул, сиксәннән өстен яшьтә булуына карамастан, егетләрчә җиңеллек белән колхозның ревизия комиссиясе рәисе вазифасын үтәп йөри иде.

Әмма аңа иң зур дан китергән вакыйга 1920 елда Татарстан мохтариятен оештыру көннәренә бәйле. Булачак автономия чикләренә Иске Төгәлбуганың һәм аңа якын булган дистәләгән татар авылының кертелмәгәнлеге ачыклана. Яңарак кына иркле, тиң, тигез тормыш өчен дип төрле тарафларда сугышып, кан коеп кайткан узаман ир-егетләр мондый хәл белән килешергә теләмиләр. Берничә авыл халкы берләшеп, күкрәкләренә беренче Совет орденын тагып кайткан иң батыр ир-атларны Самарага озаталар. «Безнең авылларны да Татарстан биләмәсенә кертүгә ирешегез», — дип наказ бирәләр. Ләкин халык теләге үтәлми. Губерна комиссарлары: «Декретка кул куелган, хәзер соң инде», — дип акланалар. Ә җирле волость ревкомы рәисе Вечкомов «ходатайларны кулга алырга» дигән боерык бирә. Авылларда гауга чыга. Иске Төгәлбуга бунт үзәгенә әверелә. Атка атланып, кулына чалгы алган Фәтхи Биказаков аның әйдәүчесе булып таныла. «Совет өчен сугышып йөргән батырларны кулга алырга әмер бирүчене тоткарларга» дигән халык таләбен үтәп, җирле комиссарны авыл келәтенә китереп ябып куя. Халык белән аңлашырга дип Самарадан мөселман комиссары килгәнче, теге рәис шунда биш тәүлек утыра. Менә шундый тәвәккәл, чая, тапкыр кеше була яшь Фәтхи Биказаков. Әйткән сүзендә торучан, туры сүзле булганы

өчен дә авыл халкы аны үз итә иде. Район күләмендә дә абруе зур булды.

— Фәйзүк абыйлар белән безнең ызбалар янәшә иде бит, беләсең инде, — дип сүз башлады ул беренче очрашу вакытында. — Минем абый белән яшьтәшләр алар. Ярты көнне аларда уйнасалар, тагын ярты көнне бездә үткәрерләр иде.

Курай урамы — кырый урам. Анда авылга яңарак килеп төпләнүчеләр дә ишле булган. Фәтхи ага әйтүенчә, Мокыч баба нәселе дә, Биказаковлар гаиләсе дә кайсыдыр күрше авылдан элегрәк елларда Иске Төгәлбугага күчеп килүчеләр була. Бер оя бала үстергән Биказаковлар да, «бер ызбага сыешмаган Мокыч баба токымы» да ярлылар чутында йөргәннәр.

— Фәйзүк үскәндә алар да бик ишле булды, — ди дә Фәтхи ага бармакларын бөгә башлый: — Мокыч баба карчыгы белән — рас, Кәбир абзый, хатыны, ике кызлары, Фәйзүк — ике булдымы, яңарак өйләнгән Хөснетдиннәре — өчме, Мокыч бабаның кияүгә китәргә өлгермәгән кече кызы — дүрт булдымы. Әһә, вәт, дүрт сандык кына бар бер ызбада. Ә тавыш-тын чыгармаганнар, сыешканнар бит. Никме? Йорт башының талканы коры булган, ни дисә — шуны эшләгәннәр, — дип сөйли әңгәмәдәшем. — Аннары бит ул заманда төп йорттан тиз генә аерылып чыгу да катлаулы иде. Авыл җыены урын бирсә генә ага-брат бүленеп чыга алды. Ә җыенда утыручы авыл картлары кайсы йортта ир заты күп, шуңа өстенлек бирә. Имана кишәрлеге ишлерәк булган кешеләрне иң элек йорт-җирле итәргә тырышалар. Чөнки алардан авылга файда күбрәк тия.

Җан башларын санарга керешәбез. Фәтхи ага исәпләвенчә, Мокыч баба йортында унтугызынчы йөзнең туксанынчы елларында унике җан иясе була. Шулардан, Фәйзүкне дә санап, имана җиренә ия булырдай дүрт «душ» — дүрт ир заты чыга. Бик аз, әлбәттә.

— Староста Кумык бабаның, пример, унбиш җанның яртысыннан күбрәге ир затыннан иде. Туктар бай ызбасындагы нисбәт тагын да югарырак. Алар баемый кем баесын. Кырны тутырып иген игәләр, башак ашатып мал симертәләр. Кыш булды исә, ярминкәдән ярминкәгә йөриләр. Мәләкәскә илтеп ашлык, Юхмачы базарында көр мал-туарларын сатып акча туплыйлар. Янчыклары тулгач, ярлы-ябаганың эшкәртерлек рәте булмаган җирләренә кул суза башлыйлар. Вәт бит ул ничек...

Иске өйне караганда, Фәйзулла абыйларның авылдагы тормышын күз алдына китермәкче булам. Урам якка өч, ишегалдына ике тәрәзә уелган кечерәк бура өй, иркен генә такта чолан. Ул юкарак бүрәнәләрдән сипләнгән сыер абзары, ат араны белән тоташкан. Яз-көз һәм кыш көннәрендә хатын-кызга суыкка, кар-

яңгырга чыгып йөрисе түгел. Ишегалды почмагында җәйге чорда һәм көзге-язгы аяз көннәрдә мал ашата торган урын. Ул озын юка колгалар белән киртәләп куелган. Ул киртә янәшәсендә бәрәңге бакчасына, су буена илтә торган җилкапка.

Курай урамында ничегрәк булгандыр, белмим. Әмма, картлар сөйләвенчә, Иске Төгәлбуганың үзәк өлешендә баштарак арт бакчада бәрәңге үстерү гадәте күзәтелмәгән. Колгалар белән киртәләп алынган ул иркен урында көтү-көтү сарык асраганнар. Хәзер дә ул бакчаларны тирәнрәк казыган саен, шакмак-шакмак булып укмашкан кәҗә, сарык тизәкләре чыга икән. Бабаларымның төп нигезе янәшәсендә гомер иткән кардәшем Галимҗан бервакыт:

— Мунча өчен дип ишегалдымда дүрт метр тирәнлектә кое казыдым, шуннан һаман мал тизәге чыга, — дип зарланган иде.

Шул ук үзәк урамда Туктар байның ике тыкрык арасын биләгән утар урыны бар иде элек. Хуҗалары куылгач, утызынчы-кырыгынчы елларда ул бушлыкта алабута да иркенләп үсеп китә алмады. Җиргә мал тизәге күп керсә, үлән тамырына үсәргә ирек бирми икән.

Фәтхи ага һәм башка картлар сөйләвенчә, авыл җыены Кәбир Туктаров гаиләсенә төп йорттан аерылып чыгарга урын билгеләгән була. Курай урамы очындагы бушлыкта. Ләкин 1891 елгы зур ачлык башлану сәбәпле, Фәйзүкләр яңа бура корып, үзгәлеккә чыгарга өлгермичә калалар. Ә ике-өч елга сузылган ул хәтәр ачлык байтак кына кешеләрнең тормышын, яшәешен үзгәртеп ташлый. Ачтан, хәерчелектән үлүчеләр дә күп була. Мокыч карт нәселендә дә андый үкенечле үзгәрешләр булып ала. Шул елларда йорт башлыгының карчыгы, Кәбир абзыйның бер кызы вафат булалар.

## «Чукынган, чучка көтә...»

Әйе, мәшһүр артист биографиясендә андый этап та бар, дип искә ала авылдашлары. Һәм, мөгаен, артист өчен иң авыр кичерешле, һич тә искә аласы килмәгән, хәтер төпкелендә генә яшеренеп яткан бер үкенечле хатирә булгандыр ул.

Алда әйтелгәнчә, ата-бабадан килгән тәртип буенча, Мокыч бабаның төп йортының варисы кече улы Хөснетдин булган. Хөснетдиннән соң ул өй аның кече улы Шәмсетдингә кала. Сугыштан соңгы елларда ул өйдә балигъ булмаган улы белән Шәмсинең хатыны яши. Хөснетдиннең җәмәгате Бәнат апа да соңгы сугыш барганда шул килене кулында күзен йома. Егерменче-утызынчы елларда Фәйзулла ага шул җиңгәсе йортына кайта торган була. Унбиш чакрымдагы тимер юл станциясеннән ул һәрчак затлы тарантаста кайта икән дә, зур юлдан Курай очына борылуга:

— Бәнат тәчи, чәең куй! — дип көр аваз сала икән. Шул авазы

аның тиз арада авылның аргы очына да ишетелеп, бар халыкка сөенеч өсти торган булган, имеш.

Рәсми биографиясендә теркәлгәнчә, Фәйзулла Туишев 1884 елның декабрендә дөньяга килгән. Ләкин кайбер авылдашлары аны бер елга алданрак туган дип исәплиләр. Чордашлары Мөхәммәтша белән Фәтхи агалар да шул фикерне раслый. Узган гасыр башында писарьларча пөхтә киенеп, солдатка каралырга кайтканда да ул 1883 елда туган никрутлар белән бергә йөрде, бергә комиссия үтте дип санныйлар.

Димәк, ачлык еллары башланганда Фәйзүккә җиде-сигез яшьләр була. Берәүләр раславынча, бу вакытта инде аның Хафиз белән Җаббар исемле энеләре дә туа. Кәбир абзый гаиләсендә Фәйзүк белән Хафиз арасында кыз бала да булуын исәпләгәндә, икенче уллары чама белән 1890–1891 еллар тирәсендә тугандыр, мөгаен. Ә кечесе алар авылдан күчеп киткәч дөньяга килгәндер. Ләкин ул балаларның язмышы тиздән туачак яңа гасырның икенче яртысында яшәгән авылдашларына мәгълүм түгел.

Җирсезлектән интеккән, җир-сулары күрше мукшы, чуашлар тарафыннан даими рәвештә дауланып, кысрыклана барган Иске Төгәлбуга халкының ул ачлык елларын ничек үткәреп җибәрүен күзаллау да кыен. Әйе, көтүлек җирләре юк дәрәҗәсендә, сөрү җирләре кысан. Берәрсендә ир бала туган саен, авыл халкына бирелгән ул кысан җирне дә өстәмә имана-өлешләргә тагын бүләргә кирәк була ич. Бик зур авыл, халкы һаман ишләләнә, арта тора, ә имана җирләре өлешләре елдан-ел кими, кечерәя бара. Бу хәл исә еш кына авылдашлар арасында ызгыш-талашларга китерә. Күршекүләннең яңа туган балага көнләшеп карау очраклары да еш була. Әйе, күлмәксез-ыштансыз ир баланың күршедә тупырдап уйнап йөрүен берәрсе күрсә, сөенәсе урында көенеп:

— Бу ыштансызы да имана дәгъвалап йөгерә әнә, — дип сукраныр заманнар булган. Авылда ир бала туу ул заманда һәркемне «минем җир кишәрлегем кими» дигән уй-борчуга салган.

Шул ук вакытта һәр туган ир бала ата-анасына зур сөенечюаныч китерә, киләчәккә өмет өсти, әлбәттә. Бер-бер артлы ике ул тугач, Кәбир белән Гөлҗамалның да сөенеч-куанычларының чиге булмагандыр. Янәсе, артык кашык кына тумый, өстәмә сөрүчәчү җирен дәгъвалаучы да туа бит! Әмма ләкин аларның бу өметшатлыкларын күк иясе генә ни сәбәпледер күрмәгән, изге догаларын кабул итмәгән икән шул. Авыл, ил өстенә зур афәт җибәргән...

Хак, нәкъ шул заманда, шул елларда Иделнең урта төбәге авылларында коточкыч ачлык башланып китә. Иске Төгәлбуга кебек кысынкылыкта утырган зур авылларда аның афәте бигрәк тә сизелерлек була. Хәллерәк авылдашларына булышкалап көн күргән,

тормыш-яшәешен көч-хәл белән очын-очка ялгап килгән ярлырак катлауның ул афәттән тәмам гаҗиз калган чагы була. Ике-өч елга сузылган корылык, шуның нәтиҗәсе булган ачлык чорында бөтенләй җирсез калучылар да аз булмый. Андыйлар, үз өлешиманаларын сатып ашап бетергәннән соң, чит-ят җирләргә китеп, шунда сыену эзли башлый. Кайсыбер сабырсызраклары, мохтаҗлыкка чыдый алмыйча, иманасын гына түгел, иманын сату хәленә җитешә. Чукынып, күрше авылларда сыену эзли башлый. Иске Төгәлбуга тарихында да андый мисаллар бар. Ата-анасы вафат булгач, күрше чуаш авылына китеп, анда яшәп калган унҗиде яшьлек Әхсән язмышы шундый фаҗигаләрнең бер үрнәге. Хуҗасы кызына өйләнеп, үз диненнән ваз кичүчеләргә өстәп бирелә торган җир өлеше алып, Карга Куак авылында ул Аксеновлар нәселен нигезләде, дип сөйли авыл картлары.

Кәбир абзый гаиләсе дә ул ачлык елларын бик авыр кичерә. Гаилә ишле, җир аз. Шул аз җирне эшкәртү, чәчү дә катлаулыга әверелә. Чәчүлек җитми, арандагы ике ат та чак басып тора, өшәнгәннәр. Карчыгы үлгәннән соң, кече кызы белән генә калган Мокыч баба беркөнне бәхет эзләп чуаш авылына күчеп яшәргә ният кыла. Күрше Иске Салаван авылына барып, көтүчелеккә яллана. Бераздан Кәбир абзый да үз гаиләсе белән аларга барып кушыла. Берсе анда сыер-сарык көтүен йөртсә, икенчесе өлешенә чучка көтүе кала. Кәбир абзый чучка көтмәсә дә, авылга кайткан араларда Фәйзүкне «чучка көтә» дип үртәр өчен сәбәп табыла. Шул рәвешле, Фәйзүккә тугыз-ун яшьләреннән рәхимсез мыскыллау сүзләрен ишетеп үсү дә насыйп була. Дөресе, ярлы, мохтаҗ йортта туган һәр авыл малаеның өлешенә нинди авырлык төшә торган булса, Фәйзүк тә андый кыенлыкларны үз башыннан кичерә. Юклык, мохтаҗлыклар белән янәшә үртәлү, кимсенү кичерешләре дә яши — алар котылгысыз. Шул ук вакытта бала чакка гына хас булган барлык сөенеч һәм юанычлар да Фәйзүкне читләтеп үтмәгән. Бердән, ул — ата-анасының өлкән, сөекле улы. Ике кыз туганы булу өстенә, тиздән бер-бер артлы ике энесенең тууы да аңа сөенеч, шатлык кына өстәгәндер. Ышанычлы дусларың булу да зур бәхет. Читкә киткәч тә онытмаган, үз иткән дуслары була аның. Кыш айларында мәдрәсәдә укуын дәвам иткәндә берәү дә аңардан читсенми.

Әмма Иске Салаванда булганда аңа үкенү, кимсенү хисләрен ешрак кичерергә туры килгән. Баштарак ул үз авылына, дуслары янына еш кайткан. Әмма кайткан саен күңеле сүрелә барган. Чөнки Иске Төгәлбуга бала-чагасы, аны күрүгә: «Чәч үстереп килгән монда Фәйзүк атлы чукынган», — дип такмаклап үчекли торган була. Иске Салаван халкы да аларны үз итәргә, үз арасына кертергә ашыкмый, «килмешәк тутарлар» дип чагарга гына тора. Үз

яшенә күрә эрерәк буй-сынлы булган, яшьләр уенына керәсе килгән Фәйзүкне дә, кыз туганнарын да чуаш егет-кызларының өнәп бетермәве үзен еш сиздергән.

Шулай, төрле яктан каргала-тиргәлә, алар бу авылда икеме-өчме җәй яшиләр. Кимсетү, кыерсытулардан тәмам гаҗиз булган Кәбир абзый гаиләсе, Мокыч бабаны җир куенына салу белән үк, бу авылдан китәргә була. Иске Салаванда атасы өлешенә тигән җирне, кирәкмәсрәк йорт-кура әйберләрен калдырып, ялгыз ат җигүле арбага төялеп, Мәләкәс каласына карап алар юлга чыгалар. Кәбир абзый, инде анда барып, кайларга борын төртәсен алдан ук чамалаган була. Чөнки көтүдән арынып торган араларда ул тик ятмаган, озын кыш айларында якындагы базар тирәсендә олаучы хезмәтен үтәп, байтак кына кеше белән танышкан, аралашкан була.

**Бәхет кошын очрату**

Кайчандыр Иске Салаваннан аерылып чыккан, урман эченәрәк кереп, Чирмешән янәшәсенә үк сыенган Зур Салаван элек шаушулы базары белән данлы иде. Кыш айларында Кәбир абзый әнә шул базар кешеләренә үз аты белән хезмәт итеп йөрүчеләрнең берсе булып китә. Дөрес инде, күпчелек очракта андыйларны үз кул көче белән эшләгән вак-төякне сатучы ялламый. Базарда кибет тотучы алыпсатар сәүдәгәрләр өчен кирәгрәк була олаучылар. Кәбир абзый да күбрәк вакытта шундый кешеләр белән эш йөртә.

Халык телендә ул сату-алу җирен «урыс атнасы базары» яки «Салаван базары» дип кенә йөртәләр иде. Ул дәвердә, бәлки, берәр җирдә саф мөселман базары — җомга көн эшләүче базар да булгандыр. «Урыс атнасы базары» таң беленү белән башлана да төштән соңгарак таралып бетә. Аңа якын-тирә авыл халкы гына түгел, егерме биш-утыз чакрымнардагы Әбдери, Лабит, Төплистан, Пәрау кешеләре дә, гаилә-гаилә булып, ат-арбаларга төялеп киләләр иде. Чөнки монда ашлык белән эре мал-туардан кала барлык кирәк-яракны да сатарга һәм сатып алырга була. Хатын-кыз биредә кемнәрдер бәйләгән әйберләрне, кемнәндер артып калган кием-салымны да, кулдан эшләнгән йөзек, беләзекише бизәнү әйберен дә таба алган. Хак инде, авылча тормыш-көнкүреш өчен ни-нәрсә кирәксә, барысын да диярлек алып та, сатып та булган. Иләк, чиләк, гөбе, юкәдән үрелгән, агачтан юнып, чокып ясалган, кызыл яки сары балчыктан әмәлләп киптерелгән төрле-төрле савыт-саба — барысы белән дә сату итәләр монда. Бер почмактарак әнә, үзе ясаган кашык, кәнди, коштабакларын шакылдаткалап, агач әйберләр остасы утыра. Аның күршесендә тимер кыршаулы күәс-камыр тәпәннәрен, төрле зурлыктагы гөбе, кисмәк

ишеләрне ясаучы кисмәкче басып тора. Аның «арзанга сатам» дигән сүзләрен тагын да көррәк аваз белән кабатлаучы җәптәше дә якында гына. Монысының алдында ялтыравык ак калай белән бизәлгән эреле-ваклы сандыклар өеме тора. Бала учы чамасындагы кечкенәдән алып беләк буедай зур чабаталар бәйләмен ике иңенә аскан сакаллы һәм сакалсыз, картузлы вә түбәтәйле юкә «каешы» осталары да халык арасында туктаусыз йөренәләр. Аратирә алар да: «Хан кызлары киярдәй матур чабаталар... патша уллары киярдәйләр...» — дип, үз хезмәт үрнәкләрен мактыйлар. Әйе, монда берәүләр үз һөнәр җимешен күккә чөеп мактый-мактый сата. Хуҗалык кирәк-ярагын канәгатьләндерердәй әйберне эзләп тапкан кеше ала. Ата-бабаларыбыз әйтмешли, монда инде кемнәрдер алдый, кемнәрдер алдана. Һәр сатучының үз бәясен югарырак күтәрәсе килә, алучы исә арзанрак хаклысын очратмаммы дип эзләнә. Базар мөнәсәбәтләре шуңа корылган. Кемдер үзе сатасы әйберне ипләп-җайлап кына чамасыз мактый белә икән — аның сыйфатсызрак әйбере дә үтемле булып чыгачак, тизрәк сатылып бетәчәк. Сату-алу эшендә шомарган кеше андый гына хәйләне белә, әлбәттә. Мыжлап торган халык арасында чын жуликлар да буталып йөри, билгеле. Аларның төп кәсебе — икәүөчәү берләшеп, затлырак әйбер чәлдерү яисә берәр ачыгавызын төпсез кесәле итеп калдыру.

Карурман эченә кереп, мул сулы һәм балыкка бай Олы Чирмешән ягасына ук килеп утырган Зур Салаван халкы да урман һәм елга нигъмәтләре белән сату итәргә тәмам остарып беткән. Базарның бер кырыенда фәкать алар гына сәүдә итә торган икеөч озын киштә-ләүкәләр бар. Авылның уңганнары буйдан-буйга сузылган ул ләүкәләрне һәр якшәмбедә яңа тотылган балык, яңа өзелгән җиләк, бөрлегән, карлыган, шомырт кебек ризыклар белән тутырып куярлар иде. Киштәләргә аркылы сузып салынган аршын буе җәен, беләк буе симез чуртан һәм башка төр балыклар, бармак төртүеңә сискәнеп сикергәләп, яңарак тотылганлыкларын сиздерәләр. Шул ук ләүкәләр янәшәсендә суйган тавык, өем-өем йомырка, йомарлам май, кызыл эремчек, сөт-катык ише көндәлек кирәк-яракны сатып торучы төрле милләт хатын-кызлары да кайнаша. Алар арасында башына алсу-көрән яулык бәйләгән, чуар алъяпкыч япкан, чулпы таккан Иске Төгәлбуга, Иске вә Урта Исәнтимер, Иске Җүрәй кебек якынрак авыл киленнәрен дә очратып булган.

Әйе, заманында бик данлыклы була Зур Салаван авылы базары. Аңа Самара ягы авылларыннан да, хәзер Татарстанның көньяк чик буенда урнашканнарыннан да, Мәләкәс, Ставрополь (хәзер Тольятти) кебек шәһәрчекләрдән килеп сәүдә итүчеләр дә күп булган. Очраклы хәлдерме- юктырмы, ул төбәктәге патша дәвере

зур базарлары никтер урыс, мукшы, чуаш авылларында урнашканнар. Әйтик, безнең тирә-як кешеләре Салаван базарында булмаган эре мал-туар һәм арба-чана ише кирәк-яракны кырык-илле чакрымдагы икенче чуаш авылы Юхмачыдан кайтарганнар. Пәрау төбәге халкы исә Салаваннан тыш Кузнечиха тарафы базарына да йөргән.

Авыл картлары сөйләвенчә, Салаванда Мәләкәстән килеп сату итүче кешеләр дә була. Алар, башлыча, базарны каймалап алган ларекларда эш йөрткәннәр. Кәбир абзый кебек олаучылар нәкъ шундыйларга хезмәт иткән. Киләсе базарда сатыласы товарны алар атна арасында ук ташып куя торган булганнар. Тумышы белән безнең тирәдәге авылларның берсеннән чыккан Алексей Федоров дигән кеше белән Фәйзүкнең атасы аеруча якынлашып китәләр. Ә ул Федоровның Мәләкәстә зур кунак йорты да бар икән. Атлы-арбалы бер-ике дистә кунакны кабул итәрдәй Постоялый двор тоткан ул. Шул кеше Кәбир абзый гаиләсен үзенә сыендыра, эш бирә. Яңа урында аларның төп бурычы: ишегалдын тәртиптә тоту, мич-учакны утыннан өзмәү, кирәк-ярак товарны үз вакытында җиренә җиткереп кую, алып кайту була.

Монда күчкән вакытта Фәйзүккә унике-унөч яшь тирәләре булган. Балалыктан чыгып, яшүсмерләр дөньясына аяк басу еллары. Һәр шәхес язмышында үзенчәлекле бер дәвер: дөньяга, тирә-як мохиткә, чынбарлыкка караш көннән-көн үзгәрә, үсә барган бик тә кызыклы бер чор. Һәм нәкъ шундый үсеш, яңарыш дәверендә барлык өмет-хыялларың белән бөтенләй бер үзгә мохиткә — шәһәр мохитенә килеп кер әле син! Билгеле, Фәйзүкнең сөенеченә һич кенә дә тиңнәр булмагандыр ул көннәрдә. Аның сөенеч, куанычлары чиктән аша. Бәлки әле, хыялда гына булса да киләчәк бәхетле язмышы да күз алдына килгәндер.

Мәләкәс каласы ул вакытта Самара губернасының өяз үзәге санала. Аңа хәзерге Татарстанның көньяк биләмәләре дә керә. Унтугызынчы йөз ахырында Мәләкәс кырык көнлек ашлык ярминкәсе һәм өч зур тегермәне белән данлы санала. Агачтан һәм талчыбыктан өй җиһазы җитештерүче остаханәләр дә эшли. Машина куәте белән хәрәкәткә китерелә торган өч тегермәннең берсе татар бае Әбдүш варисларыныкы була. Мулла кушкан исем Габдулладан Абдюшев фамилиясен тудырган бу нәсел шәһәрдә 1917 елгы үзгәрешләр башланганчы үз дәрәҗәсен саклый. Каланың татарлар яшәгән өлешендә мәчет, мәдрәсә эшли. Совет хакимияте вакытында мәдрәсә җирлегендә педтехникум ачыла. (Мәләкәс татар педучилищесы Хрущев фәрманы чыккач ябылды.) Бу мәдрәсәдә узган гасыр башында күренекле тел галимебез Латыйф Җәләй дә белем алган. Шуннан соң ул берничә ел Иске Тогәлбуга янәшәсендәге Иске Җүрәйдә балалар укыта. 1919 ел-

лар тирәсендә кабат Мәләкәскә кайтып, әлеге укытучылар әзерләүче уку йортын нигезләүдә катнаша. Бу калада ул елларда татарча газета да берничә ел чыгып ала...

Атналарга сузылган ярминкә көннәрендә Постоялый дворларда ишек-капкалар һич тә ябылып тормый, билгеле. Кемнәрдер килә, урнаша. Кемдер, гаиләсен арбасына төяп, саубуллашып китеп бара. Үз яшенә караганда буйчанрак, калкурак күренгән Фәйзүк тә эшсез тормый. Ишегалдына чыгып атасына да булыша, кирәккәндә кунакларның йомышын үтәргә дә өлгерә. Йөгереп йөргән күндәм авыл малае, таш каланың ак күмәченә авыз тидереп тамак туйдыргач та, дәртләнеп, кушкан йомышларны карусыз үти. Самавыр да куя, кунак бүлмәләренә аш-суын да, башка кирәк-яракны да ташып кына тора. Җитез, зирәк һәм күндәм бу кәләпүшле малайны, мөгаен, бик күпләр үз иткән, яраткандыр. Килеп урнашкан беренче кышында ук инде ул тирә-күршедәге малайлар белән дә, кунаклар белән дә дуслашып өлгерә, аралаша башлый.

Ә ул кунаклар арасында ярминкәне бизәп, җанландырып җибәрү өчен Россиянең төрле тарафыннан җыелган һәвәскәр сәхнә әһелләре һәм цирк артистлары да була. Халык күп җыелган җирдә кәмит күрсәтүчеләрсез буламы соң! Алар дөньяны ямьләндереп, күңелләргә рухи азык бирүчеләр ич. Ачлык афәтеннән арынып, тук тормышка йөз тоткан бервакытта аларның кирәклеге бермәбер арта. Һәркемнең күңеле кәмит катыш җырлы-биюле уеннарга, карусельләргә тартыла.

Фәйзүк тә бөтен күңеле белән шул карусель уенын оештыручыларга, кәмитчеләргә якынрак торырга тырыша. Алар да йомышчы малайны үз итеп өлгерәләр. Чаршау корулы балаганнарына чакырып алгалыйлар, ара-тирә күмәк уенга да катнаштырып җибәргәлиләр. Монда цирк белән эстрада уеннары бергә, алмаштилмәшләп башкарыла торган була. Шунда ук җыр, бию, мәзәк сөйләү, акробатик күренешләр бер-бер артлы алышынып торалар. Өздереп гармунда уйнаучылар да шул ук балаган артистлары рәтендә йөри.

Фәйзүк баштарак, гади тамашачыга күренмичә, берничә яшүсмер белән бергә эчтән карусель чыгырын әйләндерү хезмәтен башкара. Өстә, мәйданчыкта, бәйрәмчә киенгән бала-чага чырчу килә, җил куып әйләнә, уйный. Фәйзүкләр, көч түгеп, аларга андый рәхәтне тудыралар. Узган җәйдә генә көтү көтеп көн үткәргән авыл баласының, шулай итеп, күк капусы көннән-көн ачыла бара. Тиздән аңа ачык сәхнәдә күренеп китәрдәй җиңелчәрәк рольләрне дә тапшыра башлыйлар. Шул рәвешле бер-ике сезон үтеп тә китә. Хәзер инде Фәйзүк кунакханәләрнең тар бүлмәләрендә атналап, айлап яшәүче, төрле һөнәргә ия булган

балаган артистларының самавырчысы гына түгел, арага кереп китәрдәй һөнәрдәшләренә әйләнә бара. Ярминкә көннәрендәге бәйрәмчә уен карарга килүчеләр аны гадирәк акробатик номер башкаручы сыйфатында да, ярыйсы ук оста итеп такмаклап русча һәм татарча биюче буларак та күрергә күнегәләр. Аның биографиясе белән таныш кешеләр: «Фәйзүкнең беренче артистлык амплуасы — баш очына самавырлы поднос куеп, русча бию була», — дип язалар.

Билгеле, артист халкы Постоялый двор бүлмәләренә хәл җыярга кайткач та тик кенә ятмый. Берише биюнең яңа алымнарын үзләштерә, икенчеләре җырлый, мәзәк сөйли, уен коралларында уйнаучылар яңа көй өйрәнә яки элекке көен камилләштерергә тырыша. Шул исәптән гармунчылар да үз уеннарын камилләштерү белән шөгыльләнәләр. Биючегә дә, җырчыга да, фокус күрсәтүчегә дә гармунчының булышып, уен тембрын үзгәртә-үзгәртә уйнап тору кирәк ләбаса. Ял вакытларында алар да берберсе белән тәңгәл килеп, бербөтен образ тудыру өстендә эшлиләр. Шул сәбәпле ярминкә көннәрендә Постоялый дворда һәрчак гармун чыңлавы яки моңлы бер көй уйналуы тынып тормый диярлек. Хәер, гармунны фәкать эч пошудан шыңгырдатып утыру очраклары да булгалый.

Гармунчыларның уйнауларына кызыгып карап торган әлеге кәләпүшле малайга да ара-тирә шул гармун сәдәпләренә баскалап алгаларга рөхсәт иткәләүчеләр була, әлбәттә. Тора-бара бик теләп үз һөнәрләренә өйрәтергә теләүчеләре дә табыла. Бу тормышта бит башкаларга карата хәерхаһ, ярдәмгә килергә әзер торучылар да еш очрый. Шулай булмаса кешелек дөньясы яши дә алмас иде.

Фәйзүк зирәк шәкерт булып чыга. Көй-моңнарны да, аларны күңелгә ятышлы итеп уйнау рәвешләрен дә тиз отып ала. Озакламыйча инде ул, өйрәтүчеләренә ияреп, иш-җәптәш булып уйнардай дәрәҗәгә җитешә. Өстәвенә әле аның җирле халык күңелен җилкендереп татарча һәм чуашча көйли алу сәләте дә ачыла.

— Ну, Фәйзүк, сиңа балаганнан һич аерыласы түгел, — дип, аны балаган хуҗалары башка шәһәрләргә үзләре белән гастрольләргә китәргә димли башлыйлар.

Оста гармунчы даны әнә шулай бөреләнергә керешә. Иске Төгәлбуга авылының ярлы Мокыч баба ызбасында туып үскән яшүсмер Фәйзүкне, шулай итеп, Мәләкәс Постоялый дворында үзләштерә башлаган һөнәр-кәсебе олы дөньяга алып кереп китә. Очраклы бер хәл — Кәбир абзыйның мохтаҗлыктан качып шул заман кунакханәсенә эшкә килеп урнашуы — улының киләчәк бәхетле язмышының тәүге терәге, этәргече була. Шул очраклы вакыйга Фәйзүкне тиздән олы сәнгать дөньясына алып чыга. Икен-

че бер очраклылык — Россия күләмендә танылган виртоуз гармунчы Уткинның нәкъ шул елларда Мәләкәскә килеп чыгуыдыр. Соңыннан Фәйзулла ага Туишев гомере буена шул остага рәхмәтле булуын белдерәчәк. Әйе, юклык, ачлык нәтиҗәсендә тук тормыш эзләп Мәләкәс каласына килеп эләккән татар гаиләсе гомердә көтелмәгән бәхетле язмышка дучар була.

Хак инде, армый-талмый эшләргә, хезмәт итәргә гадәтләнгән авыл баласы, ташны ярып чыккан язгы үлән кебек, әнә шулай һаман да яктыга һәм яхшыга омтыла бара. Җае туры килеп куйса, зур ихтирамга һәм дәрәҗәгә дә ирешә. Ә инде җае чыкмаса... әрнисыкрый үз йөген тарта. Балалары бәхетле булсынга дип булса да тырыша.

Фәйзулла аганы язмыш туган авылыннан кумыйча, шул Иске Төгәлбугасында калдырган булса, ул кем булыр иде икән? Әтисе Кәбир абзый кебек бер олы җанлы гаилә башлыгы, имана җирен үз вакытында чәчеп-урып, төпле генә тормыш алып баручымы? Тырышлыгы, зирәклеге һәм яшьлегендә күргән-татыган мохтаҗлыклар аны авылдашлары арасында тырыш хуҗа буларак танытмый калмас иде, әлбәттә.

Атасының зирәк акылын, гайрәт-куәтен, эзләнүчәнлеген исәпкә алганда, Фәйзүк тә, һичшиксез, үз мохитендә танылганрак авыл кешесе — мәчет куштаны, җыен активисты яки үз фикере белән абруй казанганрак кеше булыр иде, мөгаен.

Дөрес, заманасына, чорына күрә Кәбир абзый да коеп куйган мәчет карты да, фәрештә дә түгел. Аның да холкының кырысрак чаклары да еш булгалап торгандыр. Үз даирәсе таләп иткәнчә, динен дә тоткандыр. Балаларының бозык юлга басуыннан куркудан аларга карата кайчак кырысрак та кылангандыр, Фәйзүген дә баштарак төрле ят уеннардан һәм ят уен коралында уйнаудан тыярга тырышкандыр. Ф.Хөсни «Гармунчы» документаль повестенда аны шулайрак итеп күрсәтә. Фәйзүкнең үз хезмәтенә алган беренче гармунын да атасы таптап изә, диелә ул әсәрдә. Ләкин авылдашлары башкачарак фикердә. Унбиш яшьләрдәге Фәйзүкнең гармунга чын-чынлап мөкиббән булуын аңлаганнан соң, улының ул уен коралында уйный алуына ышангач, Кәбир абзый беренче гармунны аңа үзе сатып ала, дип сөйли безнең авыл кешеләре.

Әсәрдәге Кәбир абзый образы белән килешмәвемне мин кайчандыр повесть авторына да белгерткән идем.

— Син дә миңа бәйләнмә әле, анкета түгел лә ул, әсәр... «Гармунчы»га бәйләнүче, ризасызлык белдерүчеләр болай да җитәрлек булды, — дип җавап бирде ул вакытта Фатих ага.

Әйе, Фатих Хөснинең повестенда атаны артык диндар, томана итеп күрсәтергә тырышуын замана чире дип карарга кирәктер.

Әсәр бит утызынчы елларда, динне каһәрләгән чорда иҗат ителгән. Әсәрдәге Кәбир абзый образы чынбарлыкка туры килми. Чөнки андый диндар кеше гаиләсен ачлыктан йолып калу өчен булса да башка диндәге күрше авыл халкына барып баш иягргә курыккан булыр иде. Кәбир абзый исә шуның киресен эшли. Атасы, Мокыч карт сүзенә буйсынып, чуаш авылына барып көтүчелеккә яллана. Шул рәвешле, ишле гаиләсе белән авыр ачлык елларын уздырып җибәрә ала. Иске Салаванда да, Мәләкәс каласында да ул гади батрак кына түгел, үз кул көче белән көн күрергә омтылучы хуҗа буларак күзаллана. Көтү көтүдән бушаган айларда ул үз аты белән олаучы хезмәтен дә башкара. Мәләкәстә дә ул тик кенә, Постоялый двордан килгән ризыкны ашап кына ятмый. Базар-ярминкәләр булмыйчарак торган мәлләрдә Әбдүш тегерменәнә йөк ташый. Шул рәвешле, ике-өч йөкне тарта-тарта, ул озакламыйча үзе дә бер кешенең Постоялый дворын сатып ала, үз эшен башлап җибәрә. Мөселманнар өчен үз кунакханәсен ача.

**Сәяхәтләр, юллар...**

Кәбир абзый үз кунак өенә хуҗа булу көннәренә ирешкәндә, аның зур улы, беренче ярдәмчесе Мәләкәстән еракта була инде. Фәйзүк баштарак, уналты-унҗиде яшьләрендә, биюче һәм төрле мәзәк кыланышлар башкаручы сыйфатында Казаннан килгән төркем белән үзләрендәге уеннарда катнаша. Балаган җитәкчесе Анна Казаграндега аның чыгышлары ошый, һәм ярминкә ябылгач та, ул хатын аны үзләре белән алып китә. Казанда бастырылган яңа, матур афишаларда аның исеме дә «виртуоз артист Фәйзүк Туишев» буларак беренче мәртәбә теркәлә. Шушы көннән соң «Туишев» аның псевдонимы булып китә, соңрак фамилиягә әверелә.

Алар төркеме Казанда бер кыш дәвамында эшли. Фәйзүк сәхнәгә күбрәк вакытта рус яшьләре кыяфәтендә чыгып бии, гармунда рус көйләрен уйный. Баш очына самавыр беркетеп биюдә аеруча осталык күрсәтә. Шул сәбәпле бервакыт аны татар яшьләре урамда тукмап та китәләр. Яз башында бу төркем кабат Мәләкәс каласына юл тота. Шул ук вакытта монда Сембер каласыннан килгән цирк артистлары төркеме дә эшли. Ярминкә сезоны беткәч, Фәйзүк икенче гастрольгә шушы цирк төркеме белән чыгып китә. Алар биеп-җырлап, цирк тамашалары күрсәтеп, Идел буе шәһәрләрен йөреп чыгалар.

Шушы гастроль вакытында булса кирәк, Сембердә торып эшләгән бер вакытта, алар төркеме арендалаган цирк бинасы һәм күпчелек җиһазлары янып көл була. Күпмедер вакыт тулы хезмәт хакы алмыйча эшләгән артистлар акчасыз калалар. Төркем җитәк-

челәре шәһәрдән чыгып кача. Иң авыр хәлдә калучылар арасында яшь артист Фәйзулла Туишев та була. Ачы язмышка дучар ителгән артистны фәкать кулында калган гармуны гына коткара. Шушы вакыйгадан соң инде ул кечерәк кенә үз төркемен оештыра, ил күләмендә дан, шөһрәт биеклегенә илтүче туры сукмагына төшә.

Егерме ике яшендә, Сембердә цирк труппасы белән булган вакыйганың көзендә, Фәйзулла Туишев хәрби хезмәткә каралыр өчен дип туган авылына кайта. Иске Төгәлбугадан чыгып китүенә сигез-тугыз еллап вакыт үткән була. Ул заманда кабул ителгән тәртип таләп иткәнчә, хәрби комиссиядә каралырга тиешле һәркем туган җиренә кайткан. Чордашлары хәтерләвенчә, Фәйзүк авылга 1906 елның көзендә кайта. Өстендә затлы көзге пальто, аягында ялтырап торган күн итекләр була. «Авыл писарьлары кебек киенгән иде, иңендә зур гармун иде», — дип истә калдырганнар авылдашлары.

Ул вакытта безнең төбәк авыллары никрутларын Иске Төгәлбугадан егерме биш чакрым көньяктарак урнашкан Зирекле Куак авылында комиссия аша үткәрә торган булалар. (Бу татар авылы рәсми документларда Елховый Куст аталып йөргәнлектән, артистның биографияләрендә дә шулай теркәлгән.) Өяз каласы Самарадан килгән рус офицерлары Фәйзулла Туишевны үзләре белән алып китә, һәм, күпмедер вакыт үткәч кенә, «хәрби хезмәткә яраксыз» дип иреккә җибәрәләр. Ә Мөхәммәтша, Шәфигуллалар, солдат шинеле киеп, хезмәт итәргә калалар. Алар Фәйзүк кордашлары белән кабат фәкать ике зур сугыш һәм 1921 елгы ачлык вакыйгаларын кичергәч кенә кавыша алалар. Бу еллар аралыгында Фәйзулла Туишев үзе туплаган артистлар төркеме белән Россиянең барлык төбәкләрендә гастрольләрдә йөри. Халык мәхәббәтен яулый.

Театр артисты Локман Аитов «Артист язмалары» китабында Фәйзулла Туишев белән Түбән Новгород шәһәрендә очрашуын тасвирлый. 1909 елның җәе, ярминкә көннәре. «Шул көннәрдә Фәйзулла Туишев концертлары да барды. Аның белән дә таныштым. Безнең халыктан да шундый гармунчы чыгар икән дип тәмам хәйран калдым. Чөнки мин бу көнгә кадәр Пермьдә гастрольгә килгән рус уенчыларыннан мәшһүр Петр Невскийны гына күргәнем бар иде. Фәйзулла Туишевның рус көйләреннән башка татар халык көйләрен дә кечкенә гармуннарда зур осталык белән уйнавы, шуның өстенә тагы үзе уйнап, үзе биеп җибәрүләре соклангыч булды», — дип язды Локман ага.

Фәйзулла аганың замандашы, күренекле әдип Гомәр Бәширов та 1992 елда язылган бер мәкаләсендә авылдашымның «халыкчан иҗатын» югары бәяли. Милли саф көйләр башкаручылар-

ның берсе, ди. Муса Җәлилнең якташыма махсус багышланган күләмле генә шигыре дә бар. Менә аның башлангыч юллары:

Мәңге көләр үткен күзләреңне
Текәдең дә безгә, елмайдың.
Синең белән бергә
Көлгән төсле
Гармуның да ярсып чыңлады...

Республикабызның Милли музеенда Фәйзулла Туишев архивының бер өлеше һәм гармуннары саклана. Анда төрле елларга караган афишалар, концерт программалары да бар. Менә 1914 елның 17 апреленә караган бер программа. Ул рус һәм татар телләрендә аерым-аерым басылган. Анда Казан сәүдәгәрләре бинасының залында Фәйзулла Туишев катнашында концерт һәм спектакль буласы бәян ителә. Кичәнең администраторы Ш.Әбдиев, диелгән. Бер пәрдәлек спектакльдә катнашучы Вәлишин, Исмәгыйлев, Ибраһимов, Саттаровлар янәшәсендә дә Әбдиев фамилиясе күрсәтелгән.

Озакламыйча башланган Беренче бөтендөнья сугышы көннәрендә Ф.Туишевның Оренбургта, Мәскәүдә, Петербургта гастрольләрдә булуы мәгълүм. Бу көннәрдә «Ил» газетасында аңа багышлап мәкалә басылуы хакында да хәбәрләр бар.

Гражданнар сугышы тәмамланганнан соң, артист Казанга кайтып төпләнә. Татарстанның халык артисты Хәким ага Сәлимҗанов гармунчының Совет Татарстанында оештырылган беренче концертын яхшы хәтерли. Бу концерт Фәйзулла Туишевның Себер белән Ерак Көнчыгыш гастрольләреннән соң Татарстанга 1923 елда бөтенләйгә кайтуыннан соң уздырыла. «Кабатланмас якты талант, чын мәгънәсендә профессиональ музыкант иде Фәйзулла ага Туишев. Аның репертуары гаять бай иде. Менә ул, берара чит җирләрдә йөреп, ниһаять, сөекле, моңлы Казанына кайтты, — дип башлый ул аңа багышланган истәлеген. — Татар көйләреннән бигрәк тә «Ончы Фәхри» белән «Әллүки»не тирән эчке бер хис белән башкарды. Тамаша залы гөр килде».

Гармунда гаҗәп оста уйнаучы гармунчының бөтен хәрәкәтхаләтен бик төгәл тасвир иткән ул истәлеккә инде ни дә булса өстәп тә, шуннан арттырып сөйләп тә булмастыр. Хәким ага Сәлимҗанов татар тамашачысының һәм, гомумән, татар халкының гармунчыга карата булган ихтирамын һәм мәхәббәтен бик тулы чагылдыра, минемчә. Фәйзулла Туишев концертлары, кайларда гына оештырылмасыннар, тамашачының ялкынланып кул чабулары белән ачылып китеп, аягүрә басып, артистны озаклап алкышлаулар белән тәмамланганнар. Сөйгән халкы аны һәркайда яратып кабул иткән. «Туишев, афәрин!», «Туишевка озын гомер!» дип кычкыра торган булган. Халыкның дәррәү хуплавын күреп торган

кайбер шикләнүчәнрәк түрәләр дә сабырлык күрсәтергә, мәшһүр артистның элекке сәяси хаталарына күз йомарга булалар (егерменче еллар башында Харбинда ак офицерлар төркемендә йөрүенә).

Казанга кайткач, артист үзедәй оста гармунчылар әзерләргә кирәклеген дә онытмый. Милли музей архивында аның яшь музыкантлар белән дәрес уздыру вакытын чагылдырган бер фоторәсем дә сакланган.

Ерак Владивосток, Харбин якларында озаклап йөргәннән соң, артист туган җирен, туган төбәген дә бик сагынып кайта. 1923–1939 елларда ул Иске Төгәлбугада гадәттәгедән ешрак була. Артист буларак тәүге тапкыр туган авылына концерт куярга кайткан елны чордашлары төгәл хәтерләми хәзер. «Ачлыктан соңгы ел иде», — дип искә алалар. Әле Иске Төгәлбугада клуб булмый. Шәкертләрдән бушаган бер иркенрәк бинада — уку йортында концерт куела. Аның ул вакыттагы мөдире — «избачы» Нәкытдин бабай Миңлебаев җитмешенче елларда исән иде әле. Үзе дә авылның бер дигән җырчысы булган, Сандугач Нәкый кушаматын йөрткән карт гармунчының ул вакытта авылга кайту күренешен болайрак тасвир иткән иде: «Фәйзүк абыйның уйнавын карарга, тыңларга дип килгән кеше мәчет янәшәсендәге ул ызбага сыешып бетмәде. «Иртәгә дә килеп уйна», — дип күндердек үзен. Ике-өч көн шунда ялыкмыйча уйнады».

Берничә көннән соң авылдашларын озатырга дип Курай урамына килгән халык:

— Адә, тагын кайт, Фәйзүк, шулай уйнап безне тагын сөендер! — дип, матур теләкләр теләп калалар.

Шуннан соң ул авылга тагын берничә мәртәбә кайта. Ул вакытта әле Бәнат җиңгәсе дә, аның улы Шәмси дә исән-сау булалар. Артист һәр кайтуында үзе туып үскән өенә төшә, Бәнат тәчиендә кунак була. Бары тик 1939 елда гына авыл түрәләре Ләлә ханым белән икесен зурлабрак каршы алырга ниятлиләр. Авылның күренекле кешесе — «ЦИКа Гаян» өенә урнаштыралар. Аның өе пөхтә, зур була. Гаян апа Сәгъдиева егерменче еллар ахырларыннан авылның иң дәрәҗәле кешеләреннән санала иде. Самара өлкәсеннән Бөтенсоюз Үзәк Башкарма комитетына сайланган, мәшһүр Калинин баба белән бер өстәл артына утырып, ил язмышын хәл итешүдә дә катнашкан хатын ул. Ләлә ханым белән уртак сүз таба алыр дип тә уйлагандыр колхоз рәисе Имам Мостаев. Гаян апа өенә клуб та, авыл идарәсе йортлары да бик якын, күршедә генә диярлек. Димәк, кунакларга авыл буйлап йөрисе дә түгел.

Фәйзулла Туишев бу кайтуында элекке мәчет бинасында ике көн рәттән төрле гармуннарда төрле көйләр уйнады, авылдашларының күңелен күрде. Әйе, ул вакытта инде иң зур мәчет клубка

әвереләндерелгән иде. Фәкать түр башының урамнан беркадәр эчкә кереп, кыйблага йөз тотуыннан гына аның элекке мәчет икәнлеген чамалап була иде. Тамашачылар партер эскәмияләрендә генә түгел, залның өчтән бер өлешенә чыгып торган киң балконына да шыплап тулган иде. «Иде» дим, чөнки авызны ачып шул балкон киртәсеннән сәхнәдәге тамашаны йотлыгып күзәтүчеләр арасында үзем дә бар идем. Әйе, байтак кеше клубка балаларын да алып килгән. Ил күләмендә танылган артистны, авылдашын күреп калсын, авылдан кем чыкканын белеп торсын дигәннәрдер. Көндезге һәм кичке концертларга олау-олау төялеп күрше авыл кешеләре дә килгән иде. Бала-чаганы кызыктырып, мәчет каршында яңарак бер полуторка машинасы да тора. Димәк, кайдандыр ерактан аңа да төялеп килгәннәр. Тамашачылар арасында элекке мәчетнең бер почмагында бөрмә билле аксыл тунлы чуаш хатын-кызлары һәм ир-егетләре дә күренә. Димәк, Иске Салаван кешеләре дә көтүче Фәйзүкнең концертын күрергә һәм тыңларга дип килгән. Алар да, мөгаен, Фәйзулла абыйның уенын йотылып тыңлаган хәлдә: «Кайчандыр арабызга кертмәскә тырышып йөргән Фәйзүк шушымы соң? Әйе, шулдыр. Югыйсә безнең чуаш көйләрен бу кадәр оста уйный алмас иде», — дип сокланып торалар иде шикелле.

Шушы кайту Фәйзулла абыйның туган-үскән авылына соңгы мәртәбә аяк басуы булган икән. Шул елның көзендә үк финнар белән сугыш башланып китүе, аңа ялганып ук диярлек Бөек Ватан сугышының башлануы аны туган иленнән ерагайта. Ә сугыш белән бергә төрле авырулар һәм картлык көннәре килә. Авыр сугыш елларында артистның Бәнат җиңгәсе вафат була. Ике энесе — Сәхаб белән Шәмсетдин — ерак яу кырында ятып калалар.

Соңгы елларында иленә кайта алмаса да, Иске Төгәлбуга халкы бер дә онытмый үз улын, үз авылының мактанычы саналган бөек артист Фәйзулла ага Туишевны. Татарстан халкы да Татарстанның халык артисты Фәйзулла Туишевны һич онытмый. Дистә елга якын инде Казан каласында Фәйзулла Туишев исемендәге мактаулы дәрәҗәгә ирешү өчен төрле төбәкләрдән килгән гармунчылар арасында ярышлар уздырыла. Шундый дәрәҗәле исемгә лаек булучылар арасында мәшһүр артистның якташы Рөстәм Вәлиев тә бар. Күптәннән инде Татарстанның халык артисты исемен алган икенче бер виртуоз гармунчыбыз. Әйе, гәрчә ул Казанга Самара аша урап килсә дә, төп чыгышы буенча Иске Төгәлбуга даирәсенә кергән авылларның берсе саналган Төплистаннан була. Рөстәмнең ата-анасы шул авылдан. Үзенең дә бала чагы шул җирлектә, әби-баба карамагында уза. Рөстәм татар моңын күңеленә Фәйзулла агасын тудырган туфрактан ала.

Фәйзулла Кәбир улы Туишев оста музыкант-башкаручы гына түгел, көйләр тудыручы да. Аның яшьлек елларында иҗат иткән

төрле сюита, экспромтлары нотага салынмаган, ил буйлап гастрольләрдә йөргәндә таралып, югалып беткәннәр. Ә инде Казанда төпләнеп яшәү елларында иҗат иткән утызлап җыры һәм башка төр музыкаль әсәрләре аны композитор буларак та таныта. Аның тарафыннан музыкальләштерелгән җырлардан байтагын халкыбыз яратып кабул иткән. Әйтик, Әхмәт Ерикәй сүзләренә язылган «Халкыма», Сәхаб Урайский шигыренә нигезләнеп иҗат ителгән «Төзелештә», Мәхмүт Хөсәен сүзләренә язылган «Дустыма» җырлары элегрәк елларда радиодан да бик еш тапшырыла иде.

Халык сүзләренә таянып музыкальләштерелгән «Кукмара» җыры да һаман онытылмый. Болардан тыш Фәйзулла Туишев Гадел Кутуй истәлегенә багышлап марш һәм кыллы квартет өчен «Пионерлар сюитасы»н (М.Юдин белән бергә) иҗат итә.

1930 елларда Фәйзулла Туишев Казанда гармун фабрикасын ачуда башлап йөрүчеләрдән була. Һәм 1933 елдан фабриканың техник советында баштарак баш белгеч, соңрак консультант вазифаларын башкара.

1944 елның февралендә Фәйзулла Туишевка «Татарстанның халык артисты» дигән мактаулы исем бирелә. Моннан тыш аның башка бүләкләре һәм орденнары да бар, әлбәттә. Әмма иң зур бүләк — халкы күңелендә сакланган олы ихтирам, билгеле. Бердәнбер үкенеч — соңгы елларда мәшһүр гармунчының уены радиотапшыруларда бик сирәк яңгырый. Бәлкем инде, концертлардан язып алынган язмалар да юкка чыккандыр. Соңгы дистә елда безнең радиотапшырулар оешмасында андый югалтулар да булгалады бит. Әле күптән түгел матбугатта бер сөенечле хәбәр дә урнаштырылган иде. Ленинград шәһәрендә яшәп вафат булган күренекле рәссам Фәйзерахман Әминев гаиләсе Казан музеена Фәйзулла Туишев язмаларыннан унбер пластинка тапшыра. Димәк, Туишевның үзенчәлекле итеп уйнау үрнәкләре әле кая да булса сакланган булырга мөмкин дигән өмет тә бар. Ә Габдулла Тукай музеенда (Казан, Г.Тукай урамы) мәшһүр артистның төрле тавышлы, төрле рәвешле егерме концерт гармуны һәм концерт киемнәре күргәзмәгә куелган. Алар белән һәркем таныша, гармунда моң чыгара белүче тотып карый ала. Белгән кешеләр, артист кулында иллеләп шундый гармун булган, дип язалар. Аларның бер өлеше Милли музей архивында сакланадыр, мөгаен. Шунда ук бер куплет шигырь дә бар:

Туишевның кулларында гармуннары сайрый,
Сандугачка тиңдәш булып.
Ул канатсыз, оча алмый.
Тик шулай да
Җирдә яши былбылларга көндәш булып.

*«Казан утлары», 2007, № 8*

# ЕРАКТАГЫ АК ҖИЛКӘННӘР

*(Тарихи очерк)*

## 1

Үзенчәлекле шагыйребез, күренекле җәмәгать эшлеклесе Закир Рәмиев-Дәрдемәндкә багышланган зур фотоальбомга материал туплау нияте белән 1994 елның җәендә без Оренбург якларына барган идек. Юлдашым— күренекле фотограф, күптән түгел генә «Габдулла Тукай» альбомын нәшер итүдә төп вазифаны үтәгән Зөфәр Гомәр улы Бәширов. Билгеле инде, Оренбург төбәгендә атаклы шагыйрьнең бала чагы эзләрен саклаган Җиргән, Юлык авылларын да читләтеп үтмәдек. Бераз соңрак шагыйрь яшәгән Орск, Баймак шәһәрләренә, Чиләбе өлкәсендәге Балкан авылына да бардык.

Оренбург шәһәре янәшәсендәге бай тарихлы Татар Каргалысында да булдык. Бертуган Рәмиевләр монда бик еш килеп-китеп йөргән. Шакир Рәмиев хатыны Гәүһәр абыстай Оренбург кызы дип исәпләнсә дә, ата-аналарының тамыры шушы авылга бәйле булса кирәк. Дәрдемәнд «зәүҗаны» Мәһүбҗамал да бу «зыялы каланы» үз иткән — узган гасыр башларында монда Кызлар мәктәбе оештырып йөргән.

Язма әдәбиятта ул авылның «Оренбург Каргалысы» дигән исеме дә мәгълүм. Монда миңа элегрәк тә булгаларга туры килгән иде. Мәсәлән, 1984 елда язмыш миңа шагыйрь Һибәтулла Салихов варислары белән очрашырга, алардан истәлекләр язып алырга насыйп итте. Каргалы авылы элегрәк заманнарда мин үскән төбәкнең рухи-дини бер башкаласы булып торган. Безнең Бозаулык суы буе татар авыллары ул дәвердә рәсми рәвештә Самара губернасына буйсынсалар да, мулла-мөәзиннәренең күпчелеге шушы Каргалы мәдрәсәләрендә укыганнар. Совет хакимияте дәверендә дә Каргалыдан чыккан укытучылар ишле иде. Сугыштан соңгы елларда Бозаулык суы башланып киткән Иске Белогорда безне дә шул авылның бер кешесе укытты. Үз исеме Мөхәммәдне балалар теленә кертмәскә тырышып, ул үзенә «Салихов абый» дип эндәшүне генә хуп күрер иде.

Бу авылның халык телендә «Сакмар буе Каргалысы» дигән исеме дә бар. Чөнки ул Сакмар буенда, Сакмарсу тамагына якын гына җирдә урнашкан. Хәзерге рәсми язмаларда ул Татар Каргалысы дип атала. Күренә ки, татар дөньясына мәгълүм өч зур Каргалының берсе булган бу авылга карата халык телендә берничә төрле исем саклана. Еникиев, Терегулов морзаларның төп йорты саналган «Бәләбәй Каргалысы» (элек ул Бәләбәй өязенә кергән)

белән Татарстанның Чистай шәһәре янәшәсендәге Каргалыдан аермалы буларак, Оренбург янәшәсендәгесенең тагын бер рәсми атамасы булуын да әйтеп үтик. Унсигезенче-унтугызынчы йөзләргә караган язма документларда ул «Сәгыйд бистәсе» («Сеитов посад») исеме белән дә йөргән. Татар дөньясында бу авылга багышлап иҗат ителгән аерым хезмәтләр дә бар. Мәсәлән, Чулпанай Мирхәйдәр дигән берәү 1890 елда Оренбургта «Сәед бистәсе» исемле китабын бастырып чыгара. Мәшһүр галимебез Риза хәзрәт Фәхретдиневнең дә Уфада яшәгәндә үк бу авылга багышлап «Сәгыйд» исемле китап (1898) нәшер иткәнлеге һәм Оренбургта «Әхмәт бай» китабын (1911) язганда аерым бүлек багышлаганлыгы мәгълүм.

* * *

Каргалы элек Оренбург—Казан юлы өстендә утырган иң зур авылларның берсе булган. Хәзер дә әле ул Сакмар елгасы буйлап өч-дүрт чакрымга җәелеп утыра. Зур урамнары Сакмар ярыннан күтәрелә башлаган сөзәк үр буйлап сузылган. Аркылы урамнар үр сыртындагы борынгы кабер ташларына таба бара. Табигый таштан корылган зират коймасы белән авыл арасыннан киң асфальт юл уза. Мәңгелеккә дип эшләнгән ул зират коймасының кайчан корылганлыгын белүче юк. Ул койма, шундый ук таштан төзелгән элекке кибет, келәтләр авыл белән бер үк вакытта корыла башлаган булса кирәк. Басу ягы табигате үрле-калкулы ялан кырдан гыйбарәт. Сакмарсуның аргы ягын тоташ урман — өянке, усак, каен урманы хасил итә. (Урманның зур өлеше элек бер алпавыт карамагында булган. Хәзер ул шәһәр яны урманчылыгына керә.)

«Әхмәт бай» китабының «Каргалы шәһәре» бүлегендә Риза Фәхретдинев егерменче йөз башы авылын болайрак тасвир кыла: «Оренбургтан егерме чакрымнарда Сакмар елгасының уң яры буйлап сузылган бер шәһәр булыр. Халык телендә ул Каргалы дип кенә йөртелә. (Бу исем аңа шәһәр уртасыннан Сакмарга агып төшүче Каргалы елгасына нисбәтле рәвештә бирелгән.) Аның «Сәгыйд бистәсе» дигән атамасы да бар. Анда мөселманнар гына яши. Бу бистәне сәүдәгәр Сәгыйд Хәялин нигезләгән, шунлыктан шәһәр аның исеме белән дә йөри. Җаек һәм Идел елгалары буйларында башка андый саф мөселман шәһәрләре юктыр. Шушы көндә Каргалыда ун сан мәсчет булып, күбесендә икешәр указлы мулла бар... Каргалының барлык әһлиясе (халкы) чама белән унөч меңдер. Укымышлысы, хәлфә вә суфыйларны кертмичә, йөз ярым чамасы булачактыр. Каргалы шәһәрендә һәр гасырда үзенә күрә шөһрәтле галимнәр, аз булса да шагыйрь вә әдипләр яшәгән. Сәгыйд бистәсен Елизавета императрица 1745 елда төзергә рөхсәт бирә... Шушы көнге Каргалыда әлегә почта вә телеграф юк, хас-

таханә дә юк. Моңа шәһәр исеме бирелүе башкалардан аеру ниятеннән эшләнгәндер. Оренбургта исә бу көндә йөз мең чамасы кеше яши, шуның дүрттән бер өлеше әһле ислам кешеседер».

Боларга өстәп шуны әйтик, патшабикә әмере чыкканчы ук Казан төбәгеннән бу авылга берничә гаиләнең күчеп килгәнлеге мәгълүм. Алар 1743 елда Оренбург губернаторы И.И.Неплюев рөхсәте белән монда килеп төпләнәләр. Димәк, Каргалы авылы хәзерге Оренбург шәһәре белән бер үк вакытта төзелә башлый. Ә кайбер галимнәр фикеренчә, ул җирдә элек-электән үк ерак бабаларыбыз яшәгән булырга тиеш. Чөнки ул — безгә кардәш халыклы Урта Азия мәмләкәтләре белән Уфа, Казан төбәкләрен тоташтыручы сәүдә юлы өстендә утрак тормыш алып бару өчен иң җайлы урыннарның берседер. Шушы төбәк авыллары мазаратын хәтерләткән зират күренеше дә шул ук фикерне раслый сыман. Казан арты авылларыннан күченеп килгән мөселманнар монда каберлеккә агач утыртмый башлаганнар. Димәк ки, биредә алар элек-электән яшәүчеләр йоласын үтәргә мәҗбүр булганнар.

Оренбург тарихчысы Сергей Попов хәбәр итүенчә, 1747 елда Каргалыда йөз җитмеш өч йорт-каралты булган, анда яшәүче ир-ат саны меңгә җиткән. Бу авылга зур сәүдәгә керешерлек бай мөлкәтле һәм азмы-күпме сәүдә тәҗрибәсе туплаган кешеләрне генә алырга тырышканнар. Беренче күченеп утырган ике йөзләп сәүдәгәр башлыча Казан, Вятка, Сембер губерналарыннан китерелгән. Әлбәттә, алар арасында дин әһелләре дә ишле генә санала. Мәсәлән, Каргалының икенче ахуны, соңыннан илле ел чамасы Рәсәйнең Европа һәм Себер өлеше мөселманнары мөфтие вазифаларын үтәгән Мөхәммәтҗан бине әл-Хөсәен әл-Борындыкый нәселе монда Зөя елгасы буе Борындык авылыннан килгән була. Һәр сәүдәгәр, һәр мулла йорт-кура һәм мал-туар тоту өчен үзе белән берничә хезмәткәрне алып килә алган. Аерым һөнәр осталарын чакырып китерү дә рөхсәт ителгән. Мондый мәсьәләләрне хәл итү авылның беренче старостасы Сәгыйд Хәялингә йөкләтелә, билгеле.

Патша хөкүмәте Каргалы бистәсенең оешу көннәрендә үк Урта Азия ханлыклары белән сәүдә арадашлыгын башлап җибәрү бурычын куя. Ташкент тарафына беренче зур сәүдә кәрваны 1741 елда, Оренбург һәм Каргалы төзелә башлаганчы ук, Орск кальгасыннан җибәрелә. Аны оештыруда Сәгыйд Хәялин дә катнашкан дигән фикер бар. Шубай Арсланов белән Мансур Йосыпов җитәкләгән ул кәрван үз бурычын уңышлы үтәп чыга. Казакъ, Үзбәк ханлыклары җирләреннән үтеп, сәүдәгәрләр Ташкент каласына барып җитәләр һәм бер елдан соң зур табыш белән үз илләренә әйләнеп кайталар. Сәгыйд бистәсе тарихына багышланган соңгы китап авторлары — аталы-уллы Искәндәревләр раславынча («Сеитов посад». Казань, 2005), шул ук тарафка икенче зур

рәсми кәрван берничә елдан соң Каргалы авылыннан чыгып китә. Кәрван башы итеп Сәгыйд Хәялиннең бертуганы сәүдәгәр Габдулла Хәялин билгеләнә. Бу кәрван да, үз бурычын уңышлы үтәп, 1749 елда Оренбургка әйләнеп кайта. Әлеге китапта китерелгән архив материалларына караганда, кәрван ефәк, парча, чәйише товардан тыш җиде пот көмеш тә алып кайта. 1750 елда шул ук Габдулла Хәялин, Надир Сафаров һ.б. катнашында тагын бер кәрван Хива ханлыгы башкаласына юнәлә. Аны шул ханлык илчесе Ширбәт озата бара. Ә бер елдан соң зур бер кәрван тагын да ераграк юлга чыгып китә. Исмәгыйль Бикмөхәммәтев җитәкләгән ул кәрванга Һиндстанга барып җитү бурычы куелган була. Бу сәүдәгәрләр бик җитди бурычның бер өлешен генә үтиләр — Һиндстанга барып җитәләр, ләкин илләренә әйләнеп кайту күпләргә насыйп булмый. Чирек гасырдан артыграк вакыт үткәч кенә кәрван башы Оренбургка кайтып егыла, юлда күргәннәренең бер өлешен язып калдыра. «Исмәгыйль ага сәяхәте» язмасын Ризаэтдин Фәхретдинев, 1903 елда Оренбургта нәшер итеп, киң җәмәгатьчелеккә җиткерә.

Әлбәттә, әлеге кәрваннарны оештырып җибәрүдә төбәк түрәләреннән тыш рус сәүдәгәрләренең дә өлеше зур була. Мөселманнар яшәгән җирләргә рус кешесенең аяк басуы тыелган булганлыктан, алар анда үзләре бара алмаган, билгеле. Дөя өркәчләренә өелгән мал-мөлкәтләре генә ул якларда «сәүдә кылып йөргән». Каргалы кешеләре аша эш йөртүче рус сәүдәгәрләре исемлегендә Мәскәү төбәгеннән рус В.Журавлев, грек И.Мавродин, соңрак Казанда сәүдә өлкәсендә дан казанган Кекиннардан берәү, Урал-тау казылма байлыкларын аяусыз үзләштерүче сәнәгатьче Твердышевлар һ.б. бар.

Билгеле инде, патша түрәләре ул сәүдә кәрваннары белән әлеге ханлыкларга үз шымчыларын да даими рәвештә җибәреп торганнар. Шундый шымчыларның иң танылганы, әлбәттә, Ян Виткевич була. Ул Ташкент, Сәмәркандлар аша үтеп, Кабулга ук барып җиткән. Берләштерелгән Һиндстан империясен нигезләгән «мәшһүр татар» Заһретдин Бабур шаһның Кабулдагы затлы сарай һәм бакчаларында йөргәндә, бу разведчик рус патшаларын шул бай мәмләкәтне яулап алу мөмкинлекләре бар дип тә ымсындыра. Аның шуңа тартым хәбәрләре һәм күргән-белгәннәре турындагы язмалары безнең сәүдәгәрләр аша Оренбург якларына даими рәвештә җибәрелеп торган. Аңа багышланган кайбер хезмәтләрдә «Виткевич Коръән сүрәләрен мөселманнардан яхшырак белгән, намаз гамәлләрен алардан остарак башкарган» дип арттырыбрак та язалар. Дөреслектә кем булган соң ул? Польшада, туган-үскән илендә, Россиягә каршы фетнәдә катнашкан бер ир-егет. Мөгаен, тумыштан ук мөселман өммәте кешесе булган-

дыр. Сөргенгә Казакъ ханлыгы чигендә урнашкан Орск каласына җибәрелгән. Шунда, имеш, мөселманча гамәл кылырга һәм сөйләшергә өйрәнә. Аннары бер сәүдә кәрваны белән Урта Азия тарафына озатыла, тизрәк иленә кайтасың килсә, безгә хезмәт ит дип. Билгеле инде, чит-ят җирләрдә булганда ул татар исемен йөрткән, разведка мәгълүматларын Орск, Оренбург, Каргалы татарлары аша хәбәр итеп торган...

Кайбер Каргалы кешеләренең мондый төр хезмәтләре, мөселман илләрендә йөргәндә сәүдә эшеннән тыш башка хезмәтләр дә башкаруы турында әлегә мәгълүматлар тупланмаган.

* * *

Унсигезенче йөзнең сиксәненче еллары башында Каргалыда өч мәчет эшләгән. Аннары һәр ун-унбиш ел саен диярлек берәр мәчет салынган. Сакмар буендагы бишенче мәчет 1760 елда төзелә. Бер янгында ул янып бетә. Соңрак анда яңа мәчетне Хөсәеневләрнең бабасы Хөсәен бай салдырган, дип хәбәр итә Ризаэтдин хәзрәт. Унсигезенче-унтугызынчы йөзләрдә төзелгән кайбер таш мәчет биналары хәзер дә исән әле. Зәки мулла тырышлыгы белән төзелгән беренче таш мәчет 1775 елда ачылган. Элекке агач мәчет урынына яхшы кирпечтән өч катлы итеп 1883 елда төзелгән базар мәчете унтугызынчы йөзнең соңгы мәчете була. 1912 елгы зур янгыннан соң авылда тагын бер мәчет торгызыла.

Хәзерге көндә анда ике мәчет эшли. 1930 еллар ахырына авылның унөч мәчете дә үз вазифасын үтәүдән мәхрүм ителә. Күбесенең манаралары сүтелә. Мәсәлән, унтугызынчы йөз башларында таштан салынган «Кушманаралы мәчет»нең язмышы шундый. Аның манаралары 1941 елның көзендә, мәчет бинасында кавалерия полкы ашханәсе ачылганда сүтеп ташлана. Авылның нәкъ уртасында, Муса Җәлил тыкрыгы белән Габдулла Тукай урамы кисешкән урында урнашкан ул мәчет, халык таләбе белән, 1963 елда кабат ачыла. 1966 елда аңа яңа манара куела. Каргалы елгачыгыннан башланып авылның буеннан-буена сузылган Тукай урамында тагын берничә борынгы таш корылма саклана әле. Соңгы елларда аларның кайберләрен төзекләндерүгә керештеләр. Сакмар очындагы борынгы бер таш мәчетне дә матурлап яңадан эшли башлаганнар. Авыл уртасында Каргалыга нигез салган Сәгыйд Ает улы Хәялиннең табигый яссы таштан төзелгән йортының һәм коймасының бер өлеше дә саклана әле. Элек ул туптан атып та җимерә алмаслык нык корылма булган. Йортның бу өлешен зур кибет һәм товар сакларлык бүлмә, келәтләр биләп торган. Хуҗалар исә икенче катта, бүрәнә өйдә яшәгәннәр. Башка эре сәүдәгәрләрнең һәм һөнәрчеләрнең йорт-хуҗалыклары да элек шул рәвешлерәк итеп

эшләнгән була. Аста эре таштан төзелгән, челтәрле тимер ишек-тәрәзәле «пулатлар»да кибет яки остаханәләр урнаша, өстәге бүрәнә өйләрдә хуҗалар яши.

Авылның ярлырак өлешендә, Дунай бистәсендә, агач мәчетләр булган. Шулардан Әюб бине Ибраһим әл-Бөгелмәви имамлык иткән 9 нчы мәхәллә мәчете унтугызынчы йөз ахырында җәдидчелек хәрәкәтенә үз өлешен кертүе белән билгеле. Гани бай Хөсәенев тәкъдиме белән 1899 елдан мәчет карамагындагы мәдрәсәдә җәдидчә укытырга теләк белдергән хәлфәләр өчен махсус курслар эшли. Ул курсларның барлык чыгымын, шул исәптән курска килүчеләрне тәэмин итү чыгымнарын Гани бай үз өстенә ала. Каргалыга төрле тарафтан бик күп хәлфәләр белем күтәрергә килә. Ул курсларда татарның күренекле шәхесләреннән Һади Атласи, Гаяз Исхакый, Габдерахман Сәгъди һ.б. бик күпләр укый. Ул курсларның мөдире Төркиядә укып кайткан язучы, булачак «Вакыт» газетасы мөхәррире Фатих Кәрими була.

## 2

Олуг галимебез Риза Фәхретдинев «Әхмәт бай» китабының Каргалыга багышланган бүлегендә «Бу шәһәр киләчәктә үз трамвае, телефон станциясе, хастаханәсе булган тагын да зуррак шәһәргә әверелер әле» дип язса да, ул өметләр өлешчә генә акланды. Без яшәгән гасырның утызынчы-кырыгынчы елларында биредә йортларга электр уты, радио кертелә башлый, телефон линиясе сузыла. Ә медицина пункты (амбулатория) белән аптека — унынчы елларда, унбиш авыруны дәвалауга исәпләнгән төбәк хастаханәсе исә 1961 елда ачыла. Мәгәр Совет хакимияте дәверендә элекке «шәһәр» үсми, киресенчә, йортлар саны бермә-бер, халык саны исә өчләтә-дүртләтә кими. (Хәзер авылда дүрт мең чамасы кеше яши.) Мондый кимүләрнең сәбәпләре һәркемгә аңлашыладыр, шәт. Ике-өч йорт хуҗасының берсе байлар исәбендә йөргән ич ул вакытта. Дин әһелләре дә бик ишле булган.

«Һәр мәчет хозурында ибтидаи (башлангыч) вә бәгъзеләрендә рөшди (җиде сыйныфлы) мәктәпләр ачыла» дип хәбәр итә Р.Фәхретдинев. Әйе, авылда төзелеш барган елларда ук мәктәп-мәдрәсәләргә дә нигез салына. Тәүге мәдрәсә мөдәррисләре Каргалыга күченеп килгәнче үк дини уку йортларына җитәкчелек иткән абруйлы шәхесләр булалар. Шундый шәхесләр арасында Габдессәлам бине Уразмөхәммәд мулла беренче булып тора. 1746 елда Каргалыга күченеп килгәнче ул Казан артындагы Ташкичү авылы мәдрәсәсендә балалар укыткан. Каргалыга күчкәндә аңа кырык алтынчы яшь була. Белеме, тәҗрибәсе дә җитү булган бу мулланы авыл сәүдәгәрләре махсус чакырып китергәннәрдер,

мөгаен. Килгәч тә ул монда беренче мәдрәсәне ачып җибәрә. Үзе белән кайбер шәкертләрен дә ияртеп алып килгәнлектән, хәлфә-мөгаллимнәргә кытлык кичерми. Тарихтан мәгълүм ки, патша хөкүмәте җәберләвенә түзә алмыйча баш күтәргән татар-башкортлар фетнәсен оештырган Батырша да шушы Габдессәлам ахун шәкерте була.

Оста янына — оста, зыялы янына зыялы җыелыр, дип әйтә бит халык. Шигъри җанлы мулла Габдессәлам артыннан ук диярлек Каргалыга Буа тарафыннан Вәлид мулла да килә. Вәлид бине Мөхәммәд әл-Әминне икенче мәхәллә каршындагы мәдрәсәгә баш итеп билгелиләр. Вәлид ишан хәзрәтләре белән Уразмөхәммәд ахунның (тәхәллүсе — Габдессәлам Урай) шигырь үрнәкләре безнең көннәргәчә сакланган. Аларның кайберләре «Татар поэзиясе антологиясе»ндә дә урын алган. Габдессәлам шигырьләрен замандашы Г.Державин русчага тәрҗемә иткән. Боларның мәдрәсәсенә әдәби һәм гыйльми иҗат белән шөгыльләнүгә дәртле шәкертләр төрле тарафтан килә башлый. Оренбург губернасы Бөгелмә өязе Тимәш авылыннан килгән Габдеррәхим дә Каргалыда Вәлид ишан мәдрәсәсен үз итә. (Бөгелмә өязе 1851 елдан яңа оешкан Самара губернасына кергән.) Укуын тәмамлагач, ул, үз мәдрәсәсендә үк калып, берничә ел балаларга белем бирә. Шушы җирлектә ул шагыйрь Габдеррәхим Утыз Имәни әл-Болгари буларак таныла, тәүге гыйльми эзләнүләрен шушында башлап җибәрә. Утыз Имәни белән бер үк чорда Каргалыда аның яшьтәше, каһарман язмышлы Салават Юлаев та белем ала. Билгеле, ул да олуг шагыйрьләр арасында үзенең шагыйрьлек көчен сынап карагандыр. Бу ике яшьтәшнең шәхес буларак җитешүләре һәм иҗатларының чәчәк ату чоры, шөбһәсез, шушы Каргалы дәверенә туры киләдер. Габдеррәхим Утыз Имәнинең Каргалы кызына өйләнүе, 1774 елда аларның монда Бәдыйгөлҗамалы туганлыгы да мәгълүм.

Күпмедер вакыт Харәземдә һәм Казан артындагы Казаклар, Кышкар мәдрәсәләрендә шәкертләргә белем биреп, байтак тәҗрибә туплаган шагыйрь һәм фикер иясе Ишнияз бине Ширнияз бине Ярмөхәммәд әл-Харәзми дә 1776 елда Каргалыга килеп төпләнә. Монда аны да мәдрәсә мөдәррисе итеп куялар. Ишнияз мулланың әдәби һәм гыйльми мирасы өлешчә Казан мирасханәләрендә саклана. Каргалы авылы зиратында тулы исем-атамасы язылган гадирәк кенә кабер ташы да бар әле. Аның төрки дөньяда мәшһүр булган «Ләйлә илә Мәҗнүн» поэмасы җирлегендә, шул исем белән аталган җыйнак эчтәлекле матур бер әсәр иҗат иткәнлеге, Каргалыда яшәү дәверендә, 1780 елда, «Болгарда дини ышанулар» («Гакаиде Булгария») дигән фәлсәфи хезмәтен язганлыгы мәгълүм. Бу мәгърифәтче мулланың дини эчтәлекле дәреслек кулъязмаларының булуы да билгеле.

Бер авылда бергә яшәгән Ишнияз бине Ширнияз остаз белән Утыз Имәнинең үзара аралашмаулары һич тә мөмкин түгел. Ләкин ул хакта әлегә тулы мәгълүмат юк. Бөек Ватан сугышыннан соңгы елларда Ишнияз мулланың күпчелек мирасын якташлары Үргәнеч каласына алып китәләр. Андагы мирас белән безнең галимнәр таныш түгел дияргә була. Утыз Имәнинең 1788 елда ишле гаиләсен алып Бохарага чыгып китүендә дә, бәлки, Ишнияз остазның йогынтысы булгандыр. Ләкин әлегә ул хакта мәгълүмат юк шикелле. Ишнияз бине Ширнияз 1791 елда Каргалыда вафат була. Гаиләсе шунда торып кала. Варислары бүгенгә мәгълүм түгел. Каргалының беренче шагыйрьләреннән булган Габдессәлам Уразмөхәммәд (Урай), Утыз Имәни Каргалыга килгәнче үк, 1762 елда вафат булган. Вәлид мулла 1800 елда хаҗ сәфәренә китә һәм 1803 елда шунда гүр иясе була. Ләкин авылда аларның күпсанлы варислары, иҗатташ шәкертләре кала.

* * *

Мулладан — мулла, җир сукалаучыдан сукачы чыгар, дип әйтелә. Каргалы халкының зыялы катлавыннан чыккан, татар дөньясында күренекле эз калдырган шәхесләр дә шактый. Шуларның берничәсенә генә тукталып үтик.

Каргалы төбәгенә беркетелгән авыл муллаларына баш, ягъни ахун хәзрәтләре вазифасын да үтәгән Габдессәлам бине Уразмөхәммәднең оныгы Әбелмәних Әбелфәез улы Габдессәламов әдәбият сөючеләребезгә бик таныш кеше. Ата-бабасы кебек мулла вазифасын үтәүдән бигрәк ул безгә классик шагыйрь Әбелмәних Каргалый буларак билгеле. Аның икенче тәхәллүсе исә Сәгыйд бистәсенә нисбәтле була: Хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви әл-Сәгыйди. Бабасы вафатыннан соң дөньяга килгән бу бала бик тынгысыз холыклы булгандыр, күрәсең. Үз авылында мәдрәсә белемен үзләштергәннән соң, ул берникадәр вакыт Бохара, Истанбул кебек төрки дөньяның ул дәвердәге мәшһүр үзәкләрендә дә укып йөргән. Шул үзәкләрдә иҗат иткән әдипләр белән аралашкан. Алар белән ярышып шигырь вә поэмаларын язган. Танылган әдәбият галиме Мөхәммәт ага Гайнуллин аны унтугызынчы йөз татар әдәбиятының иң күренекле вәкилләреннән берсе дип атый. Ризаэтдин хәзрәт Фәхретдинев тә аның иҗатын бик югары бәяләгән: «Язылган шигырьләре һичбер җирдә вә гасырда йөз кызартачак түгел», — дип әйткән.

Шагыйрь 1830 еллар урталарында, илле биш яшьләр чамасында, икенче мәртәбә хаҗга барган җирендә изге туфракта ятып кала.

Әбелмәних Каргалыйдан ундүрт-унбиш елга соңрак, 1794 елда туган Һибәтулла Сәетбаттал улы Салихов Сәед бистәсе данын

татар дөньясына тараткан өченче күренекле шагыйрь санала. Аның атасы Каргалыныкы, бабасы исә бу авылга Чистай өязе Такталы карьясеннән килгән кеше. (Хәзер ул авыл Аксубай районына керә.) Һибәтулла туганда аның атасы Каргалыдан ерак булмаган Түбәнге Чебенке авылында мулла вазифасын үтәгән. (Авыл исемен шул төбәк халкы атаганча язуны хуплыйм. Бала чагымда укыткан Хөснә апам да шул авылныкы иде. Үрге һәм Түбәнге Чебенкеләр арасында элек, Оренбург каласын төзегәндә, вак таш — щебенка чыгару базы булган. «Матур туганда» романында Ш.Камал да ул баз-чокырларны тасвирлап үтә. Бу авыллар атамасы нигезендә шул «щебенка» сүзе ятадыр кебек. Безнең әдәби язмаларда кабул ителгәнчә, чебенгә бәйле сүз — «Чебенле» түгелдер.)

Һибәтулла шулай ук Каргалы мәдрәсәсен тәмамлый. Мәдрәсәдә аның остазы шагыйрь Вәлиәтдин Багдадый була. Һибәтулла Салиховның мулла, мәдрәсә башлыгы һәм шагыйрь буларак дан казанган төп йорты — Каргалыдыр. Бу авылның Сакмар очы зиратында ишан хәзрәтләренең җыйнак кына кабер ташы сакланган. Ул 1867 елда вафат була. Кабер ташының арткы өлешенә «Дүртенче, сөйгән хатыны Бибимәхтүмәнең дә кабере» дигән сүзләр дә язылган. Димәк, бу кабер ташы астында аркага арка терәп ике җан ята. Каргалыда шагыйрь нәселе вәкилләре исән әле. Аларның кайберләре — Салихов, берише Сәетбатталов фамилиясен йөртә. Күпчелеге укытучы һөнәрен сайлаган. Каргалыдан йөз утыз чакрымнар көнбатыштарак урнашкан Иске Белогор авылында Мөхәммәт Салиховның балалар укытканлыгы алда әйтелде. «Сугышмаган, әсир ителгән» дип, аны ул елларда бераз кыерсыттылар да шикелле. Әдәбият фәненнән укытмаса да, «Салихов абый» безгә кайчак, онытылып, дәреслектә булмаган шигырьләр сөйләве белән истә калган.

Һибәтулла Салиховның дүрт хатынының берсе (борынгы бабаларыбыз әйткәнчә, беренче — «алтын хатын»ы) атаклы татар морзалары Айдаровлар нәселеннән. Элек Оренбург, Уфа төбәкләрендә бу нәселдән чыккан зыялылар бик ишле булган. «Хөсәения» мәдрәсәсендә дә бу токымнан берничә кеше укыта. Татар матбугатында еш тиргәлгән Казан арты «Түнтәр авылы ишаны»ның кияве дә шул морзалар нәселеннән. Совет чоры татар язучысы Әсгать Айдар да шул токымнан иде.

* * *

1984 елда Каргалыда Һибәтулла Салихов мирасына ия булган олы яшьтәге ике апа исән иде әле. Хәзрәтнең кызының кызы туксан бер яшьлек Кәримә Габделлатыйпова ул җәйдә инде урын өстендә ята, авыр сөйләшә иде. «Минем әбием морза Айдаровлар

нәселеннән була. Кызым Зәйнәп белән хәзер без шушы абруйлы ике токымның соңгылары», — дип әйткән иде ул. Кәримәнең атасы Җәмил хәлфә ишан хәзрәтләренең яраткан шәкерте була. Әлбәттә, Һибәтулла хәзрәт һәм аның мирасы турындагы әңгәмәнең дәвамы пенсия яшенә җитеп килүче Зәйнәп апа белән дәвам ителде. Ул Каргалы мәктәбендә татар теле һәм әдәбиятын укыта иде. Илленче еллар башында Оренбург педагогия институтының татар бүлеген тәмамлаган. «Яраткан укытучым Үлмәс апа Беляева иде. Ул Каргалыга еш килеп йөрде. Иске язмаларны, китапларны укый, алып та киткәли иде. Үзем дә ул сораган иске китапларны аңа илткәләдем. Килгәндә күбрәк бездә торды... Әйе, Зөһрә әбиләрдә дә була иде...»

Зөһрә әбинең дә Һибәтулла хәзрәт нәселеннән икәнлеген белә идем. Каргалы урта мәктәбе башлыгы, авылдашым Илдус Зәбиров белән сиксән дүрт яшьлек Зөһрә Сәетбатталова өендә дә булдык. Авылның Дунай бистәсе очында. Зөһрә әби җитез хәрәкәтле, зиһенле татар апа-әбиләренең берсе буларак хәтердә калган. Ләкин инде ул без килгәндә сукырайган иде. «Күзем күрми башлаганга бишенче ел була. Шул сәбәпле әле өченче ел гына биатамнан (каенатамнан. — *Л.Х.)* калган биш-алты калын дәфтәрне Җизактан килгән бер зыялыга биреп җибәрдем. Бик озаклап дога кылып алды. Зур итеп сәдака бирде. Сукырайгач, үзем укый алмыйм. Балалар да кызыксынмый...» — дип сөйләгән иде ул.

Әйе, Утыз Имәнидән, Әбелмәних Каргалыйдан, Һибәтулла Салиховтан һ.б. Каргалы зыялыларыннан калган язма мирас белән кызыксынучылар күп була. Сугышка чаклы Оренбург педагогия институтында укыткан Җамал Вәзиева да, илленче еллар урталарында монда берничә көн булып киткән Нәкый ага Исәнбәт тә борынгы язма истәлекләр белән кызыксынганнар. Соңрак Каргалыда әдәбият галимнәребездән Мөхәммәт Гайнуллин, Миркасыйм Госманов һәм тагын кемнәрдер була. Җитмешенче-сиксәненче елларда Уфадан Зәйтүнә Шәрипова Каргалыга берничә мәртәбә килә. «Зәйтүнә монда ялгызы да, студентлар белән дә күп тапкырлар булды инде»,— дип искә алалар каргалылар. Туксанынчы еллар башында монда Казаннан Миркасыйм Госманов шәкертләре Җәүдәт Миңнуллин, Раиф Мәрданов, Ирек Һадиевләр җитәкләгән археологик экспедиция дә булып китә. Урта Азия гыйлем үзәкләре дә Каргалының язма мирасы һәм тарихы белән элегрәк елларда бик кызыксынганнар. Тик үткәндәге ул олы мирасның әлегәчә тулы килеш бүгенге укучы кулына ирештерелмәве генә беркадәр борчу тудыра. Әйтик, Үлмәс Беляеваның үз заманында, илленче-алтмышынчы елларда Оренбург төбәгендә туплаган язмаларының бик аз өлешен генә матбугатка чыгара алганлыгы көн кебек ачык. Ул дәвердә мулла чапаны кигән галимнәр

һәм шагыйрьләр турында иркенләп язып булмый, тупланган мирасны күрсәтеп бетерергә мөмкин түгел иде. Саклanган булса, бүген ул байлыктан иркенләп куллан да бит... Сакландымы икән соң ул кульязмалар — бөртек-бөртек хәреф белән чуарланган ул иске дәфтәрләр?

Зөһрә әби Сәетбатталова белән әңгәмәдән тагын шуны ачыклаган идем: күренекле радио һәм телевидение журналисты Фәрит Сәйфелмөлековның бабасы да Һибәтулла хәзрәткә кардәш тиешле икән. Ә ни рәвешле кардәш — Зөһрә әби безгә аңлатып бирә алмады. Чөнки ул кеше революциягә чаклы ук Каргалыдан киткән. «Мин әле ул чакта кияүгә чыкмаган ием. Уналтым тулгач, мине ишан хәзрәт оныгына ярәштеләр. Биатам Әхмәт хәлфә төп йортта яши иде...»

## 3

Әлеге олуг хәзрәтләрнең һәм шагыйрьләрнең чордашлары һәм авылдашлары булган беренче мөфтиләребезне дә искә алып китү зарурдыр. Болар — Россия мөселманнары арасында иң мәртәбәле вазифаны биләүче иң тәүге мөфтиләр Мөхәммәтҗан Хөсәенев, Габдессәлам бине Габдеррәхим һәм Сәлимгәрәй Тәфкилевләр. Мөхәммәтҗан Каргалы төбәгенең беренче ахуны Мөхәммәд бине Гали әл-Дагыстаниның шәкерте була. Остазы вафатыннан соң байтак вакыт үзе дә ахун вазифасын үти. Аның атасы Хөсәен баштарак Эстәрлебаш авылы мулласы була. Мөхәммәтҗан Каргалыда укый. Ахун булгач, аңа Урта Азия мөселман вәкилләре белән арадашлык итү бурычлары да йөкләнә. Мәсәлән, Оренбург генерал-губернаторы барон О.А.Игельстромның Каргалы ахунын берничә мәртәбә Кече Жүз казакъ түрәләре янына дипломатик сөйләшүләр алып бару өчен җибәргәнлеге мәгълүм. (Мөхәммәтҗан мөфтинең яшьлектә яшерен рәвештә Бохарага барганлыгы һәм шуннан соңгы еллардагы эшчәнлеге турында 1939 елда СССР Фәннәр академиясе нәшер иткән «Исторический архив» журналында кызыклы фактлар китерелә. Борынгы документларда мөфти фамилиясенең «Гусейнов» рәвешендәге язылышы да очрый.)

Екатерина II идарә иткән дәвердә Оренбург губернасының бик зур мәйданны биләвен һәм, Уралның аръягындагы казакъ ханлыкларыннан тыш, Кавказ төбәгендәге мәмләкәтчекләр белән дә чиктәш булуын билгеләп үтәргә кирәктер. Ул вакытта губернаның чикләре Иделдән Уралгача һәм Нократ елгасыннан алып Каспий диңгезенәчә җәелгән була. Пугачев фетнәсе бастырылгач та, ул чордагы Россиянең өчтән бер өлешен биләп торган әлеге губерна җитәкчесе итеп Әби патша швед О.А.Игельстромны билгеләде. Һәм ул катлаулы, күпмилләтле биләмә белән ничегрәк идарә

итәргә кирәклеге турында ике арада хатлар йөри башлый. (Хатларның бер өлеше 1886 елгы «Русский архив» журналының «Граф Игельстром архивы» өлешендә китерелә.)

Патшабикә хат-фәрманнарыннан бер-ике өзеккә күз төшерик: «Подданствобызда торган һәм сез идарә иткән төбәктә яшәгән яки шунда күчеп килгән халыкка карата бик сак мөгамәләдә булыгыз. Аларга карата җәбер кылмагыз, басым ясамагыз. Җәбер кылган тәкъдирдә, канун кушканча аларга дөреслекне табарга рөхсәт ителсен». Икенче хатта: «Шул халыклар арасында диндәшләре яисә башка берәр начар ниятле кешеләр тарафыннан безнең өчен зарарлы үгетләр таратылмасын. Зарарлы үгетләрне... мөмкин кадәр йомшаграк чаралар белән туктатыгыз», — диелгән.

Екатерина II белән язышкан хатларыннан күренгәнчә, Игельстром үзе дә, әйтик, татар-башкортларга карата йомшаграк мөгамәләдә булуны яклый. Дини карашка бәйле эзәрлекләүләргә каршы була. Урыннарда мәчетләр ачу кирәклеген хуплый. Әби патша да мөселманнар яшәгән төбәкләрдә мәчетләр төзергә рөхсәт бирү нияте барлыгын иң әүвәл Игельстромга хәбәр итә шикелле.

Яңа губернаторның мөселманнарга карата булган карашы, аларга беркадәр дини ирек бирергә кирәклеге турындагы фикере, мөгаен, Мөхәммәтҗан ахун белән якыннан аралашу нәтиҗәседер. Бу барон идарә итә башлагач та, Мөхәммәтҗан Хөсәеневне киң вәкаләтле Чик буе комиссиясенең ахуны итеп билгели. Ягъни әлеге ахун өлкә чигеннән көнчыгыштарак урнашкан Урта Җүз һәм Бүкәй казакъ ханлыклары белән тыгыз элемтә тотучы түрәләрнең берсенә әверелә. Шул рәвешле, булачак беренче мөфтигә багышлы рәсми язмалар СССР чорында нәшер ителгән казакъларга бәйле тарихи документларның 4 нче томында да урын ала («Собрание документов по истории колониальной политики царизма в Казахстане», 1939).

Мөселман татар-башкортлар 1773–1774 елларда Емельян Пугачев күтәрелешендә актив катнашалар. Шул ук чорда башланган Россия белән Төркия сугышы 1774 елда тәмамлана. Дунай елгасы буендагы Кече Кайнарҗа авылында төзелгән солых килешүендә Төркия хөкүмәте мөселманнарның Россиядәге язмышына карата җитди тәкъдимнәр кертә. Шушы җитди вакыйгалардан соң патшабикә Екатерина илдәге милли сәясәтне беркадәр үзгәртергә ниятли һәм патша хөкүмәте карары белән «Мөхәммәд дине җәмгыяте идарәсе»н оештыра. Шиһабетдин Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар...» китабының ул идарәгә багышлы өлешендә: «1192 (1778) елның 22 сентябрендә Оренбург кальгасында бер мөфти һәм өч казыйдан торган «Мөхәммәд дине җәмгыяте идарәсе» ачыла... Казыйлар һәр өч елда чиратлашып алышыналар... Бу идарәнең ачылуы, Коръән басылуга рөхсәт бирелү һәм мөселман-

нарны башкаларның җәберләвеннән тыю — Кечек Кайнарҗа килешүе шартларының берседер», — дип язылган.

Хәзрәт кулланган дата һәм идарә атамасына карата булган соравымны бер очрашканда мөфтият хезмәткәре, дин галиме Равил Үтәбай-Кәримигә дә биргән идем. Ул: «Мөфтият архивында шул дәвер документлары сакланмаган. Хәзер кабул ителгән датаны ачыклаучы күренми... Мәрҗани фикеренә каршы килеп булмый»,— дип әйткән иде. Мөфтиятнең Кече Кайнарҗа килешүенә бәйле рәвештә ачылуын Надир Дәүләт тә «Россия төркиләренең милли көрәш тарихы» хезмәтендә билгеләп китә. Ул дәвердәге Төркия башлыкларының Россия мөселманнары язмышы белән кызыксынулары элегрәк телгә алынмады.

Яңа идарәнең беренче рәисе итеп тәҗрибәле ахун Мөхәммәтҗан бине әл-Хөсәен бине Мансур әл-Җәбәли әл-Борындыкый билгеләнә. Ш.Мәрҗани «Мөстәфадел-әхбар...» китабында: «Тәрҗемәи хәле сөйләнә торган зат, озын гомер сөреп, якынча илле ел мөфти булып, Уфа янәшәсендәге үз милкендәге авылда 1823 елда вафат... Мәрхүм атабыз мелла Баһаветдин... һәм башкалар һәммәсе аның фазыл вә камил булуын, зур белемгә ия икәнлеген бердәм рәвештә таныйлар. Халык телендә дә бик галим буларак танылган», — дип яза. (Алда күрсәткән датасын Мәрҗани монда да кабатлый. Мөфтият 1788 елда оешкан булса, Мөхәммәтҗан ул вазифаны кырык ел чамасы гына үтәгән булыр иде.) Бу идарә 1788 елда Уфага күчерелә, исеме-аталышы да берникадәр үзгәртелә шикелле.

Россия империясендә мөфтиләрнең дәрәҗәсе вә вәкаләте зур була. Алар үзләре теләгән вакытларда патша җәнаблары белән турыдан-туры элемтәгә керү хокукына ия булганнар. Петербургтагы һәм Кырымдагы патша сарайларының ишекләре алар өчен һәрчак ачык торган. Мөхәммәтҗан үз вазифасын үтәгәндә, империя белән өч шәхес җитәкчелек итә: Екатерина II, аның улы Павел I һәм аның улы Александр I. Шиксез ки, Әби патша идарә иткәндә Мөхәммәтҗан Хөсәенев аның белән танышуга чакырылмыйча калмагандыр. Павел белән Александрның тәхеткә тәгаенләнү тантаналарында катнашкан булуы да һич тә шик тудырмый. Дәүләт карамагындагы бер сәяси идарә башлыгы буларак (мөфтият Эчке эшләр министрлыгының бер идарәсе саналган), барлык мөфтиләр дә патшаларны коронацияләү тантаналарыннан калдырылмаганнар. Андый олуг мәҗлесләргә мөселман өммәтендәге иң абруйлы дип күзалланган шәхесләр дә чакырулы булган. Мәсәлән, алтын приискалары хуҗалары, аталы-уллы Рәмиевләрнең шундый ике зур җыенда катнашканлыклары мәгълүм. Мөхәммәтсадыйк Рәмиев 1881 елда Александр III кә таҗ кидерү тантанасына чакырулы була. Кайбер хәбәрләргә караганда, ул яшь

императорга бик кыйммәтле һәм үзенчәлекле бүләк тапшыра. Мөхәммәтшакир Рәмиев 1894 елда император Николай II не коронацияләүдә катнаша. Ул тантанага Мөхәммәдъяр мөфтидән тыш тагын берничә мөселманның, шул исәптән Кырым морзасы Исмәгыйль Гаспринскийның чакырылганлыгы билгеле. Беренче мөфтиләргә шулай ук Урта Азия яисә Кавказ ханлыкларыннан килүче дәрәҗәле кунакларны Оренбургта яки Саратовта каршы алып, пайтәхеткә кадәр озата бару, ул кунакларның Россия түрәләре белән сөйләшүләрендә катнашу бурычы да йөкләнгән була.

Мөхәммәтҗан мөфти 1823 елның декабрендә вафат булгач, аның вазифасын вакытлыча үтәү бурычы Әмин казыйга йөкләнә. Әмин Дәмин улы әл-Җәбәли әт-Танавый да Зөя буенда, хәзерге Апас районына кергән Танай авылында туган. Дини идарәгә ул казыйлыкка сайлангач килә. Бер ел чамасы вакыт мөфти булып тора. Император тарафыннан яңа мөфти билгеләнгәч, тагын бер нәүбәт (өч ел) казый вазифасын үти. Шуннан соң туган ягына кайта, берникадәр вакыт Зөя өязендә ахун булып тора. 1830 елда Әмин Дәминевнең Казан университетына татар теле укытучысы итеп билгеләнүе мәгълүм. Мөфти урынына калган вакытта аңа шактый четерекле вакыйгаларда катнашырга туры килә. Мәсәлән, 1824 елның сентябрендә Александр I Оренбургта дүрт көн булып китә. Император җәнабларын каршылау зур шау-шу тудыра.

* * *

Ш.Мәрҗани беренче мөфтинең «тәртипсез вә тәүфыйксыз Мирзаҗан (Мирзакай) исемле углы» булуын гына яза, кызларын искә алмый. Мөфтинең ничә хатынга өйләнүен дә хәбәр итми. Башка чыганакларга караганда, Мөхәммәтҗанның ике кызы казакъ ханнары варисларына кияүгә бирелә. Кече кызы Фатыймага багышлы берникадәр мәгълүматны Карл Фукс китабында да очратып була. Казан университеты профессоры, танылган табиб Фукс Фатыйма һәм аның ире Җиһангир хан белән 1826 елның көзендә Казанда очрашкан.

1886 елда Петербургта нәшер ителгән «История родов русского дворянства» китабының икенче томында (55–56 б.) Кече Җүз ханнары исемлеге китерелә. Һәм шунда Бүкәй хан улы Җиһангирның «Оренбург мөфтие кызына өйләнгәнлеге һәм аларның дүрт улы һәм ике кызы» булганлыгы бәян ителә. «Кызлары Зөләйха полковник Тәфкилевтә кияүдә» дип тә өстәлгән. Бу полковникның бабасының бабасы генерал Котлымөхәммәт Тәфкилевнең 1731 елда Кече Җүз казакъ ханы Әбелхәерне Россиягә табыну

килешүен төзергә күндергәнлеге мәгълүм. Шул көннән башлап казакъ халкының көнбатыш өлеше Россиягә ярым буйсыну хәлендә яши. Әбелхәердән соң идарә иткән Нургали, Ишим, Бүкәйләрне ханлыкка тәгаенләү «ак патша» киңәшенә вә әмеренә таянып эшләнә башлый. 1800 елда хан тәхетенә Нургалинең уртанчы улы Бүкәй утыра. Император Александр I вакытында, Бүкәй хан вафат булгач, 1812 елда ханлык ике өлешкә бүленә. (Моңа кадәр инде Александр Россиягә Грузия, Финляндия, Молдавия кебек мөстәкыйль илләрне кушып өлгергән була. Соңрак Азәрбайҗан белән Польшаның көнчыгыш өлешен дә «руснякы» итәргә җитешә.) Җаек (Урал) белән Эмба елгалары аралыгындагы кече ханлыкка Бүкәйнең өлкән улы Җиһангиргәрәй билгеләнә. Ләкин аңа 20 яшь тулмау сәбәпле, вакытлыча идарә итү бурычы Бүкәйнең энесе Шиһабигә йөкләнә.

Җиһангир 1823 елда хан тәхетен били. Төркичә «бине-бине»ләп китерелгән шәҗәрәне русчалаштыргач, патша фәрманында ул Җиһангир Нургали улы Бүкәев рәвешендә языла. Бу хан 1826 елда Николай Іне тәхеткә тәгаенләү тантанасында катнаша. Шуннан үз иленә кайтышлый Казанда дүрт көнгә туктала. Аны озата йөрүче хан-солтаннар арасында үз мулласы, «нугай» Ает Мөхәммәт тә бар. «Ханга 24 яшь. Европалыга тартым аксыл йөзле... Чибәр кыяфәтле. Рус телендә... һәр сүзне дөрес, чиста итеп әйтә белә. Безнеңчә язуы әйбәт... Татар теленнән кала фарсы, гарәп телләрен белә...» дип яза К.Фукс. Галимнең шушы сүзләренә таянып, без казакъ ханнарының элек-электән үк татар бәк-морзалары белән якыннан аралашып яшәгәнлекләрен чамалый алабыз. Яшь ханның рус телен яхшы ук үзләштерүенә килгәндә, башта казакъ кардәшләрнең 1957 елда чыгарган китабына күз төшерик («Присоединение Казахстана к России», Москва). Анда «Җиһангир берникадәр вакыт Әстерхан губернаторы Андриевский өендә тәрбияләнә» дип язылган. Ә фарсыча, гарәпчә белемне кайда һәм кайчан үзләштерүе турында хәбәр юк. Андый хәбәрне укучыга җиткерер өчен татар мәдрәсәсен искә алырга кирәк булыр иде шул. Ә Совет хакимияте чорында «иске мәдрәсәне» искә алу килешеп бетми... Бигрәк тә «татар мәдрәсәсен» телгә алу килешми.

Ә аның тарихы болайрак. Оренбург каласы төзелгәч, казакъ халкы түрәләрен Россиягә тагын да якынайта төшү ниятеннән чыгып, анда бер алдынгы уку йортын ачу нияте барлыкка килә. Аның өчен башта мәчет салырга кирәк була. Шәһәрдә затлы таш мәчет төзетү өчен патша казнасыннан акча бүлеп бирелә. Мәчетне төзү, аның карамагында мәдрәсә ачу бурычы мөфти Мөхәммәтҗанга йөкләнә. Мөфти бу эшкә авылдашын, булачак икенче мөфти Габдессәламне тарта. 1799 елда ул аны Оренбург ахуны һәм шәһәрнең

Беренче мәхәлләсе имам-хатибы итеп билгели. Шәһәр үзәгендә, Урал елгасыннан ерак булмаган бер калкулыкта, тиздән кызыл кирпечтән матур итеп төзелгән мәчет бинасы пәйда була. 1805 елда аның карамагында махсус мәдрәсә ачыла. Хәзергечә итеп әйтсәк, ул ябык типтагы уку йорты була. Аңа күрше дәүләтләрнең хан-солтан балалары гына укырга алына. Җиһангир солтан һәм аның кардәшләре дә шушы мәдрәсәдә белем үзләштергән булырга тиеш. Бер хезмәттә «Кыргыз-кайсак хан-солтан балалары өчен ачылган мәдрәсә» дигән сүзләр күзгә чалынган иде. Ул мәчет карамагында соңрак, хан-солтанлыклар бетерелгәч, гади мулла балалары өчен мәдрәсә эшли. Шул ук гасыр ахырында анда күренекле әдибебез Галимҗан Ибраһимов белем үзләштерәчәк. Хатыны Гөлсем апа Мөхәммәдева сөйләвенчә, «Коръән Алладанмы, түгелме?» язмасына этәргеч биргән ниндидер бер кулъязма да Галимҗан кулына шул вакытта килеп керә.

Мөхәммәтҗан мөфтинең кызлары... Өлкәннәренең язмышы әлегә ачыкланмаган. Казанга ханбикә булып килгән Фатыймага унҗиде яшь. Ул үзләре тукталган сәүдәгәр Муса өендә профессор Фукс хатыны, шагыйрә Александраны кунакка ала. Чәйдән соң алар, диванга утырышып, бик иркенләп гәпләшәләр. «Фатыйманың теле русча җырлап тора, бер дә рус кешесеннән аерырлык түгел» икән. Йөз-кыяфәте дә ягымлы, күркәм; нәфис киенгән: атлас күлмәктән, аның өстеннән затлы камзул кигән. Муенында зиннәтле муенса, калфагы җем-җем килеп торучы энҗе бөртекләре белән бизәлгән. Җиһангир Фатыймага өч ел элек, ханга тәгаенләнү фәрманын алган елда өйләнгән. Шул елның көзендә Фатыйманың әтисе вафат була. Әнисенә, Кәримә бикәгә патша әмере белән зур гына пенсия билгеләнә. Фатыйма ханның яшь хатыны икән. Казанга сәяхәттә катнашмаган хатыныннан ханның ике улы — җиде һәм биш яшьләрдәге Искәндәр белән Зөлкарнәй бар, дип хәбәр итә К.Фукс.

Фатыйма кемнән һәм кайчан рус шагыйрәсе белән тиңләшерлек итеп русча сөйләшергә өйрәнгән соң? Профессор Фукс ул хакта берни дә язмый. Фатыйма туганда мөфтият инде Уфага күчерелгән була. Димәк, аның бала чагының бер өлеше шушы калада узган. Җәй айларын алар, билгеле, Мөхәммәтҗан «алпутның» ул вакыттагы «үз авылы»нда, Уфадан алтмыш чакрымдагы Атҗиттедә үткәргәннәрдер. Хөкүмәт карамагындагы идарә башлыгы буларак, мөфти хәзрәтләренең үз балаларын Петербугның иң дәрәҗәле уку йортларында укытырга мөмкинлеге була. Фатыйма да шундый уку йортларының берсендә белем алгандыр, мөгаен. Казакъ халык шагыйре Олҗас Сөләйманов та 2007 елның көзендә Казанда шундыйрак фикер әйткән иде. Карл Фукс язмалары шул фикерне раслый.

Җиһангиргәрәй Бүкәй хан Саратов губернасындагы үз утарында 1845 елда вафат була. Ул вакытта инде ул хан булудан бигрәк Россиянең рәсми рәвештә расланган кенәзе санала. Генерал дәрәҗәсендә була. Кенәз статусын алгач, ул һәм аның балалары, Чыңгыз хан варислары икәнлекләрен яшермичә, Җиһангир Чыңгыз, Гәрәй Чыңгыз рәвешендә йөриләр. Патша Россиясендә кенәз дәрәҗәсе бик сирәк шәхесләргә бирелгән. Димәк, ул шәхес һәм аның варислары патша нәсел-нәсәбе белән тиңләшә дигән сүз. Унсигезенче-унтугызынчы йөзләрдә Россиядә рус милләтеннән булмыйча кенәз дәрәҗәсен алучылар күп түгел. Кайчандыр үз ил-мәмләкәтенә хуҗа булган, төрле яклап кысканнан соң, «үз теләге белән» Россиягә кушылырга мәҗбүр ителгән грузин патшалары нәселе шундыйлардан. Нугай урдасы идарәчеләреннән Ырыс бәк (Урус бәк, кенәз Урусовлар) белән Йосыф морза (кенәз Юсуповлар) варислары да шул бик кыска исемлеккә керә.

Җиһангир Чыңгыз бу дөньядан китү белән үк, Кече Җүз һәм Бүкәй ханлыклары да гамәлдән чыгарыла. Бу вакытта инде казакъ иленең Арал диңгезенең көньягындагы өлкәләре генә яулап алынмаган килеш кала. Алары 1880 елларда яулап алыначак...

Соңгы чор казакъ ханнары, бигрәк тә Бүкәй урдасы вәкилләре — кардәш-ыру төрки халыклар мәдәниятен үстерүгә билгеле бер күләмдә өлеш керткән шәхесләр. Аларның Саратов губернасындагы утарына галимнәр һәм татарның зыялы кешеләре дә килгәләп йөргән. Шул исәптән Казан галимнәреннән Карл Фукс, Николай Катанов һ.б.ның алар белән аралашкан булуы бәян ителә. Бу традиция Җиһангир хан вафатыннан соң да дәвам иттерелгән. Фатыйма ханбикәнең озак гомер кичергәнлеге мәгълүм. Аның уллары Россия дәүләтенә хезмәт иткән Сәхиб, Ибраһим, Әхмәт һәм Гобәйдулла Чыңгызыйлар булалар. «История родов...» китабында алар да теркәлгәннәр. Кызлары Ходжаның (Хәдичәнең?) язмышы билгесез. Зөләйха, алда әйтелгәнчә, татар морзалары Тәфкилевләр килене. Аларның язмышы Оренбург белән Каргалыга да берникадәр бәйле. Элек-электән Тәфкилевләрнең зур җир биләмәләре шул тирәләрдә була. Совет хакимияте дәверендә Тәфкилевләрнең Каргалы янәшәсендәге төп утарында Ленин исемендәге совхозның үзәге урнашкан иде.

## 4

Икенче мөфти Габдессәлам бине Габдеррәхим әл-Бөгелмәви унөч ел дәвамында ул вазифаны үти (1825–1838). Аның Бөгелмә өязе Габдерахман авылында туганлыгы, яшьли Каргалыга килеп укыганлыгы мәгълүм. Мәдрәсәдән соң шунда ук мулла булып кала. Хива һәм Бохара ханлыклары илчелеге Россиягә килер алдыннан,

1799 елда беренче мөфти аны Оренбургка ахун итеп күчерә. Анда таш мәчет төзетү бурычын йөкли. Бу мулла шактый ук өлгер, үткен һәм үз чорына күрә белемле кеше булган. Рус телен дә яхшы ук үзләштергән. Бохарадан һәм Хивадан килгән илчеләрне кабул иткәндә, ул аларның патшага тапшырыласы гозер-үтенечләрен язып та биргәли. Губернатор җәнаблары алдында да абруй казанып өлгерә. Ә инде император Александр I Оренбургка килгән 1824 елда Габдессәлам ахун мөфти кәнәфиен биләрлек дәрәҗәдә тырышлык, өлгерлек күрсәтә. Һәм патша әмере белән 1825 елда мөфти итеп билгеләнә. Император Оренбургта дүрт көн була. Патша җәнабларын каршыларга дип ул шәһәргә күрше мәмләкәтләрнең хан-солтаннары да чакырыла. Элекке шәкерте, яңарак кына хан тәхетен биләгән Җиһангиргәрәй һәм аның өч бәк-солтаны белән бергә Габдессәлам дә император тарафыннан кабул ителә. Каргалы шагыйре Гомәр бине Мөхәммәтнең аңа багышланган ике зур шигъри әсәре сакланган. Бохара, Үргәнеч кунакларын кабул итү вакыйгалары «Тәзкирәи Габдессәлам мөфти» (1832) поэмасында бәян ителсә, булачак Александр II патшаны кабул итү күренешләре «Сәфәрнамәи шаһзадә Александр» (1837) дигән әсәрдә чагылыш тапкан. Шаһзадә Александр Оренбургка 1837 елның июнендә килә. Мөфти буларак, Габдессәлам аны берничә көн дәвамында озатып йөри. Казакъ ханлыгы чигенә якын торган Тозтүбә каласына да шаһзадә белән бергә бара. Казакъ хан-солтаннары һәм татар байлары белән бергә оештырылган милли бәйге-бәйрәмнең әйдәүчесе була. Тәхет варисы уздырган, санаулы сандагы мөселман өммәте вәкилләре катнашкан зур мәҗлес тә, әлбәттә, мөфти Габдессәламнән башка узмый.

Бу сәяхәт вакытында булачак императорны укытучы-тәрбиячесе, күренекле шагыйрь Василий Жуковский озата йөри. Мәгълүм ки, шагыйрьнең анасы Салиха татар нәселеннән. (Соңрак үземе яки биографиясен әвәләүчеләрме аның анасын «ключница турчанка» дип язалар. Ягъни элекке Касыйм ханлыгы биләмәсендәге Биләү шәһәрчегендә туган «төрек кызы» дип. Икенче бер рус шагыйре — Константин Бальмонт та Урал төбәгендә туган анасын татар нәселеннән дип атаудан тартынып, «шигъри җанлы турчанка иде» дип яза. Шигърияткә яшьли күңел бирүем дә анам тәэсире, ди 1914 елда «Нива» журналында чыккан автобиографик мәкаләсендә.) Жуковскийның анасы бер алпавытта хезмәт итә, уйнаштан тапкан улын баштарак үзе генә тәрбия кыла. Димәк, Василий азмы-күпме генә булса да үз ана телен дә белгәндер, шәт. Бу очрак та шаһзадәне озатып йөрүче Габдессәлам мөфти белән җирле шагыйрь Гомәр Мөхәммәтев файдасына була, билгеле. Гомәрнең Петербург архивында сакланган поэмаларын укый алган очракта, без ул вакыйгаларны тагын да тулырак итеп күзалла-

ган булыр идек. Жуковскийның да шаһзадәне озатып йөрүгә бәйле көндәлек язмалары 1902 елда «Русская старина» журналында нәшер ителгәннәр. Ләкин безнең Милли китапханәдә журналның нәкъ шул 1837 елга караган көндәлек язмалары кергән саннары юкка чыккан икән. Шул сәбәпле шагыйрьнең Оренбург төбәгенә бәйле язмалары белән әлегә танышып булмады...

1910 еллар башында Гомәр Дәүләтьяров хәлфә Каргалыдагы бер мәчет чормасыннан Габдессәлам мөфтинең үз көндәлек кульъязмаларын табып ала. Аларны Риза хәзрәт Фәхретдиневкә илтеп тапшыра. Ул язмалар 1913 елгы «Шура» журналының алты санында басылып чыгалар.

Шиһабетдин Мәрҗани Габдессәлам мөфти эшчәнлегенә ни өчендер бик аз туктала. Аның кылган эшләрен бик саран тасвирлый. Гаилә әгъзалары да хәзрәтнең китабында телгә алынмыйлар. Бәлки, Каргалы шагыйре Гомәр Мөхәммәт улының бу мөфтигә багышлап иҗат ителгән күләмле ике поэмасы барлыгын белгәнлектән шулай эшләгәндер ул. Мөфтинең балаларыннан улы Гыйният алда тасвир ителгән поэмаларның беренчесендә телгә алына, дип яза әдәбият галиме Мәсгуд Гайнетдин.

Гомәр Мөхәммәт улының бу ике поэмасы С.-Петербург архивларында һәм берсе Ташкенттагы Көнчыгышны өйрәнү институтының Кульъязмалар бүлегендә саклана икән. «Тәзкирәи Габдессәлам мөфти» поэмасы — татар әдәбиятына үзенчәлекле яңалыклар алып килгән, татар тормышындагы кайбер үзгәрешләрне чагылдырган әсәр... Бу әсәрнең тагын бер мөһим яңалыгы — реаль вакыйгаларның гадәттән тыш географик киңлеге. Сөйләм Оренбург, Петербург, Таганрог, Уфа вакыйгаларына күчеп тора...» дип бәяли аларны М. Гайнетдин. Әйе, шушы ике поэма эчтәлеге белән таныш кеше Габдессәлам мөфти эшчәнлеген дә тулырак бәяли алачак.

**5**

Шундый ук дәрәҗәдәге тагын бер шәхесне — гаскәри хезмәттән мөфтилеккә тәгаенләнгән Сәлимгәрәй Шаһингәрәй улы Тәфкилевне дә өлешчә Каргалыга мөнәсәбәте булган кеше дип санарга хаклыбыз. Ул 1865–1884 елларда мөфти кәнәфиен били. Шиһабетдин хәзрәт китабында Тәфкилев бәк-морзаларының Чыңгыз ханга барып тоташкан озын шәҗәрәсе китерелә. Сәлимгәрәйнең 1852 елда Истанбулда һәм хаҗда булганлыгы күрсәтелә. «Россия хөкемендәге мөселманнардан әлегәчә болар кадәр бай һәм дәүләт иясе булган кеше мәгълүм түгел» дип яза Ш.Мәрҗани. Әлбәттә, бу очракта «мөселман» төшенчәсен «татар» сүзе белән алмаштыру кирәктер. Чөнки алдарак берничә мөселман өммәте вәкиленең Россиянең патша йорты вәкилләре генә йөрткән

кенәз дәрәҗәсенә лаек булулары турында да сүз барган иде. Сәлимгәрәй — Уфада мөфтият бина-утарын төзеп бетерүе белән шөһрәт казанган шәхес. «Сәяхәт кылырга ярата. Кешеләргә дус һәм яхшы күренергә тырыша... Теле белән әсир итә торган зат... Ләкин, карашында тотрыклылык булмаганлыктан, күп эшләре тәмамланмыйча, ярты юлда кала иде. Еш кына үз әмерен үзе бозар иде... Сиксән ике яшендә вафат булды, Уфа шәһәренең таш мәчет күршесендә җирләнде. Балалары булмады» диелә «Мөстәфадел-әхбар...» китабында.

Алда билгеләп үтелгәнчә, Тәфкилевләрнең иң тәүге зур җир биләмәләре Каргалы тирәлегендә булып, төп утарлары да аның янәшәсендә урнаша. Ә ерак бабасы исемен йөртүче соңгы морза, Котлымөхәммәт Батыргәрәй улы Тәфкилев, патша чорындагы дүрт чакырылыш Дәүләт Думасы депутаты, ул җир биләмәләренең ике мең дисәтинәсен Мәхмүт бай Хөсәеневкә сата. Сатканда исә түбәндәге шартны куя: әлеге җирдән алынган керемнең бер өлеше, элеккечә үк, Каргалы мәчет-мәдрәсәләре файдасына бүлеп бирелергә тиеш, ди. Әлбәттә, андый кешеләрне Каргалы мәхәлләсеннән аерырга мөмкин түгелдер. Каргалы зиратында Тәфкилевләргә нисбәтле ике кабернең саклануын да әйтеп үтү кирәктер. Урта зиратның иң алгы өлешендәге ул каберләр, борынгы төрбәләр рәвешенә китерелеп, биек таш койма белән уратып алынган. Төбәк тарихчысы Мәдинә апа Рәхимкулова ачыклавынча, беренче кабердә шушы төбәктә зур эшләр башкарган генерал Котлымөхәммәт Мәмәш улы Тәфкилевнең хатыны ята. Заманында ул Тәфкилев Уралсу буендагы Орск, Оренбург шәһәрләрен нигезләүдә катнашкан олуг бер шәхестер. Каргалы «каласы»н нигезләшүдә дә өлеше булгандыр, мөгаен. Тәфкилевләргә нисбәтле ике кабер ташы да сакланган. Ләкин икесе дә йөзтүбән капланып, яртылаш җиргә сеңгән булу сәбәпле, андагы язуларны уку мөмкин түгел иде. Фәкать Тәфкилевнең Тимәш морзага ярәшелгән кызыныкы дип уйланган таш сыртына «1215 сәнә» дип чокып язылган язуны гына укып була иде. (Бу сан хәзерге исәп белән 1800–1801 елларга туры килә шикелле.) Хәзер инде ул ташларның берсе күтәртеп куелган. Таштагы язу өлешчә укыла: кабер иясе Хәдичә бикә икән, ул илле биш яшендә — 1751 елда шушы соңгы йортына иңдерелгән. Фараз ителүенчә, ул Котлымөхәммәт морзаның беренче хатыны булган.

## 6

Оренбург төбәгенең яңа чор морза-дворяннары нәселеннән чыккан Шаһимәрдән Ибраһимов мәрхүм Сәлимгәрәй мөфти урынын биләргә лаеклы кешеләр исемлегенә кертелгән була. Башта-

рак ул шул кәнәфине белергә иң лаек шәхес саналган. Ләкин аңа каршы русның югары дәрәҗәле дин әһелләре һәм карагруһчы зыялылары күтәрелүе мәгълүм. Миссионер, берара Казан университетының төрек-татар кафедрасы мөдире дә булып торган Ильминскийның шул хакта Синодның өлкән прокуроры К.Победоносцевка язган хатлары мәгълүм. Хатларында ул Ш.Ибраһимовны «цивилизованный, энергичный», акыллы, тирән белемле, русча бик иркен сөйләшә алучы, Урта Азия һәм башка Шәрекъ дөньясының билгеле кешеләре белән якыннан аралашкан зат дип мактый да нәкъ шул сыйфатлары безне куркытырга тиеш дигән нәтиҗә чыгара. Уңай сыйфатлары белән ул мәрхүм Тәфкилевтән күпкә өстен тора. Шул өстенлеге белән ул безнең дин әһелләрен һәм чиновникларны мөшкел хәлдә калдырачак, ди («может обаять и ослепить наших господь и чинов высшего управления»). Мөфти урынына безгә русча белеме чамалырак булган, түбән дәрәҗәле түрә алдында да калтырабрак торучы кеше кирәк. Мин ул урынга Солтановны кулайрак күрәм, дип яза Н.Ильминский 1885 елның 29 апрелендә җибәргән хатында. Һәм тиздән башкалада «башкорт төркеменнән булган» Мөхәммәдъяр Солтановны мөфтилеккә тәгаенләү турында фәрман бәян ителә.

**7**

Каргалы авылы һәм анда гомер кичергән олуг шәхесләр мине балачактан кызыктырып килделәр. Мәктәптә укыган елларда Каргалыны күреп белмәсәм дә, безнең Бозаулык суы буе татар авыллары белән ныклы элемтәсе барлыгын ишетергә һәм укырга туры килгән иде. Мин үскән Искавыл (Иске Белогор), аның янәшәсендәге Яңавыл (Яңа Белогор, ике уртадагы биек Актауга нисбәтле исемнәр), Аюлы, Имангол, Кондызлы картлары белән сүз чыкканда, әледән-әле шул сихри Каргалы мәдрәсәләре, Каргалы мәчетләре, Каргалы муллалары телгә алынырлар иде. Фәлән мулла Каргалыда укыган, икенчесе Каргалыдан килгән, имеш. Яңавылдан чыккан язучы һәм галим Габделбари Баттал да атасы мәктәбендә башлангыч белем үзләштергәннең соңында укуын Каргалыда дәвам иттергән.

Каргалы һәм анда яшәүчеләр белән кызыксыну ни өчен соң әле яштән үк күңелдә кузгалган? Бу кызыксынуның сәбәпләрен беркадәр аңлатып китү кирәктер. Әйе, башлангыч классларда укыткан укытучым Хөснә апа да Каргалыны бик еш телгә алып сөйләр иде. Түбәнге Чебенке авылында туган булса да, ул Каргалыны, аның кешеләрен дә бик сагына иде. Берничә ел шунда укыган да булса кирәк. Оренбург төбәгенең элеккеге барлык зыялысы да Каргалыдан чыккан дип, мисалга Айдаровлар гаиләсен

китерер иде. Әнә бит, Кәраметдин Айдаров хәзер Сәмәрканд университеты профессоры, аның туганы Галим Айдаров Оренбург педагогия институтында укыта икән. Бозаулык буе татар авылларының соңгы ахуны Харис хәзрәт тә шул нәселдән булган.

— Аның улы Әсгать Айдар күренекле язучы. Сез аны яхшы белергә тиешсез. Кечкенә Әсгать сезнең кебек вакытта шушы Искавыл урамнарыннан йөргән. Авыл читендә, Иртәк инеше буенда аларның җимеш бакчаларын барыгыз да беләсез... Киләсе дәрестән без аның «Ташбай» исемле әсәрен укый башларбыз. Ул малай узган сугышта батыр булган, кызылармеецларга акларны җиңәргә булышлык иткән, — дип сөйләгән иде Хөснә апа дүртенче класс балаларына.

Унөч яшьлек Ташбай маҗаралары, чик сакчыларының дошман көчләр белән көрәше барыбызга да ошады, әлбәттә. Әсгать Айдар исеме дә мәңгегә күңелгә сеңеп калды. Каргалы белән безнең авылны берләштерүче кешеләрнең берсе буларак та, язучы буларак та. Байтак еллар үткәч кенә Мөхәммәтхарис Айдаров ахунның шушы Иске Белогор авылында сабан туйлары оештырганлыгын, аңа Каргалы, Оренбург, Бозаулык, Самара тарафларыннан күпсанлы кунаклар җыелганлыгын укып белдем. Мондый вакыйгага багышланган хәбәрләр 1910–1914 еллар аралыгында «Вакыт» газетасында даими рәвештә басыла килгән икән. Менә 1910 елның 29 май санындагы хәбәрдән бер өзек: «Бозаулык өязе Иске Белогор карьясе янында, Айдаров хәзрәт утарында зур бәйге булды. Мөселман вә урыстан ике меңләп кеше җыелган иде. Авыллардан иллеләп имам килде. Ат чабыштыру, көрәш кеби кызыклар белән сабан туе ясалды. Берничә гәүдәт үгез суелып, халык хозурына аш бирелде...». Хәзер дә әле «хәзрәт бакчасы» исемен йөрткән ул урында кыргыйлашкан алмагач кәүсәләре саклана. Шул сәхрәдә узган сабан туйларында, бәлкем, минем бабам да катнашкан, ахун хәзрәтләре догасы белән чын мөселманча суелган ул яшь үгез итен татып карагандыр...

Алда әйтелгәнчә, Каргалы безнең төбәкнең Бозаулык, Иртәк, Иләк, Ток, Самар елгалары буе авыллары өчен үзенә күрә кечерәк бер Мәккә булган. Күрше-тирә авылларның муллалары башлыча шул Каргалы мәктәп-мәдрәсәләрендә укыганнар. Бабамның олы кызының кияве Хәбибулла да Каргалыда мәдрәсә тәмамлап кайткан була. Ләкин ул рәсми рәвештә мәхәллә имамы булып сайланырга өлгерми кала. Илдә зур үзгәрешләр башлана. 1919 елның җәендә Урта Азия тарафына ыргылган Кызыл Армия аны да үзе белән ияртеп алып китә. Яу-сугышлар беткәч тә ул шунда кала, Миһербан апабызны да үзе янына алдыра. Илленче елларда аларда кунакта булганда җизнә бабай туган авылы белән бердәй итеп Каргалыны да бик сагынуын искә алган иде.

— Шунда үзләштергән белемемне дә һич онытканым юк. Казакъ, үзбәк авылларында укытканда да көндез хәлфә, кичләрен мулдакә идем. Хәзер дә шулай, — дип мактанып та алган иде Хәбибулла бабай.

Унтугызынчы йөз башы Иске Белогор авылы мулласы Әхсәнне дә Каргалы кешесе дип искә алалар. Авыл зиратындагы кабер ташында «Биләгур имамы Әхсән»нең 69 яшендә 1824 елда вафат булуы, «24 сәнә» мулла булып торуы бәян ителә. Кабер ташы язулары бик таушалган — алда китерелгән сүзләрне һәм үлгән елын гына бераз чамалап була. Каргалыда туганмы ул яки шунда укыган гынамы — анысы билгесез. Әмма шунысы хак, ул Каргалы кешесе саналган. Оренбург ягыннан көнбатыш тарафка юл тотучы укымышлы кешеләр һәрвакыт аларда туктала торган була. (Оренбург белән Самараны тоташтыручы «чуен юлы» фәкать унтугызынчы йөзнең соңгы чирегендә генә төзелә. Аңа чаклы Самара тарафына баручы мөселманнар Бозаулык буе татар авыллары аша йөри торган булганнар.) Берничә мәртәбә хаҗга барган Каргалы кешесе Рафик бабаның зур сәфәрдән соңгы кайтышында Әхсән мулла өендә вафат булганлыгы мәгълүм. Хаҗины бик зурлап безнең авыл зиратына җирлиләр. Кабере өстенә зур табигый таш куела. Соңрак изге кеше кабере өстенә куелган ул «изге таш» төбендә кунып чыккан кеше савыга икән дигән бер ырым тарала. Сугыштан соңгы елларда да әле ул таш төбендә кунып, савыгып китәргә ниятләүчеләр еш очрый иде. Күпчелеге — якын-тирәдәге татар, башкорт авыллары карт-корылары. Култык таягына таянып килүче хәрби киемлеләр дә күренгәләр иде. Мосафирларны зират янәшәсендәрәк яшәүче Җомабикә әби каршы алыр һәм авыл башындагы күпергә җиткәнче озатып та куйгалар иде. «Файдасы булдымы соң?» — дип сораучы карт-карчыкка мосафирлар еш кына: «Әлегә рухым савыкты, шөт, тәнем дә савыгыр», — дип җавап биргән. Хаҗга йөреп изге исеме алган Рафик бабаның варислары Каргалыда бүген дә бар. Ерак бабалары каберенә «хаҗ кылучылары» гына хәзер юк инде. Дөнья үзгәрешләренә чаклы алар безнең авылга килгәләп йөргәннәр. Ә изгеләр каберендәге ул «изге таш» әле дә үз урынында, гарәп язулы дистәләгән борынгы каберташлар уртасында калкып утыра. Без аны 2006 елда гына фотога төшереп кайттык.

Иске Белогор авылының соңгы рәсми мулласы Габдулла Габидуллин бу вазифаны кырык алты ел чамасы башкара. 1926 елда вафат була. Язулы кабер ташы авыл зиратында саклана. Аның нәселе дә Каргалы белән даими рәвештә элемтәдә торган. Үзенең тумыш җире — Бозаулык буеның Сөңрән авылы. (Безнең тирә авыллары телендә — Түбән буй Сөңрәне; Бозаулык суы Иске Белогор янәшәсендәге Актау битләвеннән башланып китә.)

Сугыш һәм аннан соңгы чорда шагыйрь буларак таныла башлаган Гыйззел Габид тә шул авыл һәм шул токым кешесе. Иске Белогордагы кебек җиде-сигез сыйныфлы (рөшди) мәдрәсәсе булган Сөңрәндә мәгълүм китап рәссамы Байназар Әлмәнев тә беркадәр яшәп ала. Очрашкан, гәпләшкән мәлләрдә без аның белән якташлык тойгыларын да белгертешми калмый идек.

Габдулла мулла үз авылларыннан соң Каргалының гали өлешле (югары белем бирүче) мәдрәсәсендә дә укыган булырга тиеш. Балалары, шул исәптән кызы Мәрьям дә, Каргалыда укыйлар. Мәрьям әбинең оныгы, күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Роберт Шәмгунов гаиләсендә «Рәмия мәктәбе» укучыларының күмәк фотосы да бар иде. (Каргалынаң «Рәмия мәктәбе»н кайвакыт «Рәмия мөслимия» дип тә язалар.) Белгәнебезчә, ул Кызлар мәктәбен оештыруда Закир Рәмиев-Дәрдемәнднең хатыны Мәхүбҗамал да актив катнаша, аның тәүге җитәкчесе һәм иганәчесе була.

Бер Ходам, үзең ярлыка...

* * *

1994 елда безне, алдан сөйләшеп куелганча, Каргалы сәфәрендә Мәдинә апа Рәхимкулова озата йөрде. Иң элек юл өстендәге зиратларны карап, йөреп чыктык. Һибәтулла Салихов каберенә куелган кыскача язулы таш, элеккечә төп-төз булып, үз урынында басып тора иде. Ә менә Урта зираттагы Ишнияз бине Ширнияз кабереның эзенә төшә алмадык. Мәдинә апа: «Шушы тирәдә генә иде бит», — дип берничә мәртәбә кабатласа да, шул тирәне икеөч мәртәбә урап йөреп чыксак та, ул таш күренмәде. Кылган үләне шулхәтле биек һәм куе булып үскән, Мәдинә апа буйлап күрсәткән кечкенә ташны түгел, зурракларын да табарлык түгел иде. Ә менә очлы, өлгергән кылган орлыклары, арпа кылчыклары кебек, кадалмаган җирне калдырмадылар.

Зират тарафыннан авыл күренешен һәм кайбер истәлеклерәк, үзенчәлеклерәк кабер ташларын Зөфәр Бәширов фотога төшереп алды. Шуннан соң авыл эченә таба юнәлдек. Сәгыйд Хәялин йортының калдык нигезен дә, «Кушманаралы мәчет», Тукай, Җәлил урамы күренешләрен дә фотода истәлеккә калдырасы килә иде. Әле төп хуҗалары — имамнар карамагына тапшырылмаган берничә иске мәчет күренешен дә, авылның борынгы сәүдә үзәге кибет-келәтләрен дә рәсемгә алдык. Боларның барысы да бит мәшһүр җәмәгать эшлеклесе һәм шагыйрь Закир Рәмиев-Дәрдемәнд заманында гөрләп үз вазифаларын үтәп торган җанлы корылмалар булганнар.

Егерменче гасыр башында Каргалыда үзләре сайлаган өлкәдә мәшһүрлеккә ирешкән яки шуңа ирешү юлына баскан затлар да

ишле генә булган. Яңалыкка омтылуы белән шөһрәт казанган Әюб хәзрәт һәм аның Дунай мәхәлләсендәге мәчете һәм мәдрәсәсе алдарак бераз искә алып үтелде инде. Икенче бер мәчет карамагындагы мәдрәсә укытучысы Гомәр Дәүләтьяров исеме исә хәзер сирәк кешегә мәгълүм. Ә бит ул заманында Оренбург төбәгенең атаклы шәхесе булган. Гомәр Габдерахман улы Дәүләтьяров балаларга хисап дәресләрен укыту белән генә чикләнми, 1898 елда аның «Мөкәммәл хисаб» («Төгәл хисап») исемле дәреслеге дә басылып таратыла. Мәгәр аны илгә таныткан төп шөгыле астрономия өлкәсенә карый. Үз төбәгендә ул мөнәҗҗим буларак таныла. Мәшһүр галим Циолковский үрнәгендә Гомәр хәлфә дә үз өй түбәсендә кечерәк астрономик үзәк оештыра: күк җисемнәрен ерактан күзәтү пунктын ясый. Аның янына йолдызлар күзәтергә төрле тарафтан кешеләр килеп йөри торган була. 1914 елның язында аның Каргалыдагы обсерваториясе белән танышу өчен Казаннан Садри Максуди, Оренбургтан Закир Рәмиев, Фатих Кәрими һ.б. киләләр. Күк гөмбәзен күзәтү урынына менүче баскычта Гомәр мөнәҗҗимне уртага алып төшкән фоторәсемнәре сакланган. Г.Г.Дәүләтьяров 1930 елда кулга алына һәм «халык дошманы» буларак юк ителә. М.Рәхимкулова Гомәр хәлфәнең төп гаебе — Совет хакимияте урнашкач, мулла чапанын киюдә дип белә. Зур үзгәрешләр чорында мәхәллә халкы аны мулла итеп сайлап куйган була.

Каргалы данын еракларга тараткан, Дәрдемәнд һәм аның чордашларына замандаш булган драматург Габдерәүф Хәкимбай улы Ниязбаевны хәзер фәкать театр тарихы галимнәре генә беләдер, мөгаен. Ул 1881 елда Каргалыда туа, 1920 елда Эстәрлетамак шәһәрендә вафат була. Соңгы эш вазифасы — Башкортстан мәгариф комиссариаты инспекторы. Г.Ниязбаев, Каргалы мәдрәсәсенең рөшди өлешен тәмамлаганнан соң, Казанда Укытучылар мәктәбендә белем ала. Узган гасыр башында шул мәктәптә укыганда беренче мәртәбә сәхнәгә аяк баса. Шәриктәшләре Гаяз Исхакый, Ильясбәк Кудашев, Гафур Коләхмәтев, Шакир Мөхәммәдъяров, Шәриф Сүнчәләйләр белән бергә татарча беренче спектакльләрне куюда катнаша. Рус классик драма әсәрләрен тәрҗемә итүдә көч сынап карый. Аның 1906 елның мартында кайбер пьесаларны татар сәхнәсендә куярга рөхсәт сорап Казан губернаторы исеменә язган ике хаты мәгълүм. Шул хатларында ул Н.Гогольнең «Өйләнү», «Ревизор» комедияләрен, татар драматургларының «Кызганыч бала», «Өч хатын берлән тормыш», «Оят, яки Күз яше» һ.б. пьесаларын сәхнәләштерергә рөхсәт бирелүен үтенә. Һәм берничә пьесаны, шул исәптән «Өйләнү»не куярга рөхсәт ала. Ул заманда мондый адым ясарга сирәк кеше җөрьәт итә алган. Соңрак ул үз туган төбәгендә һәм Урта Азия уку йорт-

ларында балалар укыта. Театр белгечләре аның биш драма әсәре язганлыгын әйтәләр. Шулардан ике әсәре «Сәйяр» труппасы тарафыннан, берсе Оренбург татар драма театры тарафыннан сәхнәләштерелгән. «Сәйяр»дә Габдулла Кариев җитәкчелегендә куелган пьесалары — «Беренче таң» белән «Борадарән Галимевләр». (Автор кушкан исеме «Көчлеләр һәм көчсезләр».) Оренбургта уйналган пьесасы «Кара көннәр» дип аталган. Бу соңгы пьесаның Башкорт театры тарафыннан сәхнәләштерелгән булуы да ихтимал.

Закир Рәмиев-Дәрдемәндкә чордаш иң яшь каләм иясе Зәйнәп Сәгыйдә дә Каргалыда 1897 елда туган. Хәлиулла хәзрәт кызы Зәйнәп Каргалыда Кызлар мәктәбен тәмамлый. Мәктәптә уку дәверендә үк халык авыз иҗаты үрнәкләрен туплау белән кызыксына. Берничә дәфтәргә халык җырларын, бәет-мөнәҗәтләрне язып ала. 1914 елдан Зәйнәп Оренбургта яши, педагогик курсларда укый, татар матбугатына мәкаләләр, шигырьләр язып тора. Шагыйрәнең берничә шигыре һәм поэмасы Рәмиев байлар исәбенә чыгып килүче «Вакыт» газетасы белән «Шура» журналында басылалар. Зәйнәп Сәгыйдәнең 1915 елда «Шура»да басылган «Бикчәнтәй бабай дастаны» (икенче атамасы «Пугачевка багышлы Каргалы дастаны») исемле поэмасы күпләрдә кызыксыну уята. Зәйнәп Сәгыйдә әсәрләре белән шагыйрь һәм нашир Дәрдемәнд тә таныш булгандыр, аларны үз иткәндер дип өметләнәсе килә. Дәрдемәнднең үз карамагындагы газета белән журналда басылган күпчелек шигъри әсәрләрне нәшер ителгәнче үк күздән кичергәнлеге турында берничә истәлектә телгә алына. Зәйнәп Сәгыйдә иҗатына да ул игътибар иткән булса кирәк. Бердән, күңеленә якын Каргалы кызы бит... Икенчедән, шигъри иҗатны үз иткән яшь-яшь хатын-кыз буларак кызыксындыру уятмый калмагандыр. Әйе, Зәйнәпнең, һичьюгы, үзенчәлекле поэмасын Закир Рәмиев-Дәрдемәнднең үз итеп укыганлыгына чын күңелдән ышанасы килә...

* * *

Җәйге кояшның соңгы нурлары Сакмар елгасы белән Урал бергә кушылган тарафтан кыйгачлап, җир ягалап сузыла башлаганда, без, борынгы Каргалы шәһәре белән хушлашып, кайтыр юлга чыктык. Оренбург архивларында еш булучы, төрле тараф-тан тупланган иске китап, борынгы кулъязмалар белән эш итүче Мәдинә апа Рәхимкулова киләчәктә Закир Рәмиев-Дәрдемәнднең яшь шагыйрә Зәйнәп Сәгыйдәгә карата булган мөнәсәбәтен ачыкларга тырышачагын белдерде.

— Габдерәүф Ниязбайны да онытмагыз, — дидем мин.

*1994–2006*

# «ТАТАР УЯНСЫН ДИСӘҢ...»

Хәзер без еш кына «Мәгълүматка ия булу — дәүләткә ия булу» дигән әйтемне еш ишетәбез. Элек тә ул шулай булган. Халык арасында мәгълүмат тарату өчен вакытлы матбугат чаралары уйлап чыгарылган. Матбугат исә халыкның үзаңын күтәрүгә ярдәм иткән.

«Татар уянсын дисәң, аның үз матбугатын булдыру кирәк» дигән фикер безнең милләт зыялылары арасында унтугызынчы йөз башларында ук барлыкка килә. Әмма патша түрәләренең колониаль сәясәте татарга үз матбугатын ачарга ирек бирми. Йөз еллык көрәш фәкать егерменче гасыр башында гына уңай хәл ителә.

Шундый көрәш агымында торучылар арасында элекке морзалар нәселеннән чыккан Рәмиев байлар да бар. Бертуган Шакир белән Закир Рәмиевләр унтугызынчы гасырның сиксәненче елларында ук матбага ачарга теләкләре барлыгын сиздерәләр. Закир Рәмиев Төркиядә белем эстәп йөргән вакытта ук шул хакта үзара хәбәрләшүләре мәгълүм. Шакирның энесенә язган хатларында китап басу эше белән кызыксынырга кирәклеге дә әйтелә. Закир исә абыйсына Төркиядә чыккан газеталарны җибәргәләп тора. Мәсәлән, Исмәгыйль Рәми искә алган, 1881 елга караган бер хатында Шакир энесенә түбәндәге сүзләрне яза: «Тәрҗемане хакыйкать» гәҗите күптән килә башлады, укып бик рәхәтләнәм. Туктамый җибәреп тор. Мөмкин булса, атналык берәр журнал җибәрсәң дә яхшы булыр иде. Алган китапларыңны да җибәрә алмассыңмы? Цензура мәшәкате зур булмаса... Гәҗитләрне цензурада карап, бәгъзе җирләрен кара буяу белән буяп җибәрәләр...»

Төркиядән кайтышлый Закир, Бакчасарайга кереп, «Кырым бәге» Исмәгыйль Гаспринский белән дә очрашкан булса кирәк. Татарча газета чыгару уенда булган Исмәгыйль морза белән киләсе көздә үк Казанда бергә туры килүләре очраклы түгелдер. Газета чыгара башлауны хуплаучыларны ачыклар һәм хәлдән килгәнчә матди ярдәм итүчеләрне барлар өчен дип, 1882 елның көзендә Гаспринский морза Казанга килә. Монда аны бертуган Рәмиевләр каршы ала. Кырым морзасын халык белән очраштыру өчен дип алар зур гына бинаны үз исәпләренә арендага алалар. Ләкин чакырылган вакытка очрашырга килүче булмый. Казан татарларын ни өчендер Кырым морзасының эш-гамәлләре кызыксындырмый. Буш залда алар дүртәү — Исмәгыйль бәй, Шакир белән Закир Рәмиевләр һәм очраклы рәвештә Казанга килеп чыккан бер кавказлы мөселман гына кич дәвамында гәпләшеп утыралар. Шул рәвешле, киләсе елдан элекке Кырым ханнары башкаласы Бакчасарайда чыга башлаячак «Тәрҗеман»ның тәүге иганәче һәм

әбүнәчеләре исемлегендә фәкать Рәмиевләр фамилиясе генә теркәлә.

Соңрак алар да үз газеталарын чыгарырга талпынып карыйлар. Ләкин патша түрәләре Идел-Урал төбәге татарларына андый мөмкинлек бирүдән тыела. Галимҗан Ибраһимов «Революция тарихына материаллар» исемле хезмәтендә (1922), шундый фактларга тукталып, түбәндәге сүзләрне китерә: «Безнең Идел-Урал буенда газета чыгару өмиде ул заманда байтак кешеләрнең башларында булган. Рәшид казый (Ибраһимов), Һади Максуди, мәрхүм Шакир вә Закир Рәмиевләр, тагын әллә кемнәр ул караңгы вакытларда төрлечә исемнәр белән бер газета булдыру турында кузгалганнар. Ләкин хөкүмәт рөхсәт бирмәгән».

Гадәттәгечә, Россия хөкүмәтенең шул ук дәвердә кайбер башка милләтләргә карата башкачарак мөнәсәбәттә торганлыгы да мәгълүм. Әйе, колониаль сәясәтне алга сөргән шул ук хөкүмәтнең, империядәге төп халыкларның берсе саналган татарларга карата кырыслык күрсәтеп тә, безгә кардәш кайбер милләтләрне төрлечә юмаларга теләгәнлегенә дә мисаллар бар. Рус мәкалендә тасвирланганча, «берәүләр өстенә камчы күтәргәндә, икенче берәүләргә прәннек сузу» сәясәте үрнәге инде ул. Үзәк Россиядә яшәгән, башка төрки халыклар арасында мәдәни үсеше ягыннан күпкә югары булган татарларның үз телләрендә газета чыгарырга тырышулары кат-кат кире кагылган бер заманда Россия кочагына яңарак алынган Урта Азия, Кавказ һәм Кырым «мөселманнарына» карата мәрхәмәтлелек күрсәтелә. Янәсе, Россия аларны «тиң күреп» яулап алган, аерылып чыгарга дип талпына күрмәсеннәр. Шул рәвешле, 1865 елда гына Россия кочагына алынган Ташкентта иң әүвәл үзбәк һәм казакъ телләрендә беренче төрки газетаны нәшер итәргә рөхсәт бирелә. Әйе, 1870 елдан анда ике телдә чиратлашып атналык «Төркестан вилаяте» газетасы чыга башлый. Ул 1917 елгы үзгәрешләргә чаклы даими рәвештә нәшер ителә. Аның беренче мөхәррире милләттәшебез, Төркестан генерал-губернаторының җирле халыклар арасында эш алып баручы ярдәмчесе Ибраһимов Шаһимәрдән була. 1881 елда Шәркый Төркестандагы Җәркәнт шәһәренә Россия дипломаты вазифасын үтәргә җибәрелгәнче ул газетаны чыгару эшен дә башкарып килә. Кавказда «азәрбайҗан телендә» беренче газеталар да шул чордарак чыга башлыйлар. Дөресрәге, алар Кавказ төбәгендә яшәүче барлык халыклар өчен бердәм аралашу теле буларак кабул ителгән «уртак төрки телдә» нәшер ителгәннәр. (Революциягә кадәрге рус әдәбиятында алар «татар телендә» чыгучы газеталар буларак теркәлгәннәр.) Әдип һәм тарихчы Габделбари Баттал Кавказда чыгучы беренче төрки газета дип 1875 елдан Бакуда нәшер ителгән «Игенче» газетасын атый. Хәсән бәк Зәрбаби тарафыннан чыга-

рылган бу газетаны хөкүмәт тиз арада яптыра, дип хәбәр итә тарихи «Казан төрекләре» китабында Г.Баттал. Өч елдан соң «Зыяи Кафказия» газетасы Тифлис шәһәрендә чыга башлый. Ул да кыска гомерле була. Озынрак гомерлесе, 1905 елга чаклы яшәгәне «Шәркый рус» дип аталган. Ул газетада Казан татарларының язмалары да еш басылган. Мәсәлән, язучы Шакир Мөхәммәдевнең Оренбургтан җибәргәләп торган аерым хикәя һәм мәкаләләренең «Шәркый рус»та унтугызынчы гасыр ахырларыннан ук чыга башлавы мәгълүм.

1905 елгы халык күтәрелешеннән соң илдәге вазгыять бераз үзгәрә. Россиядәге төп халыкларның берсе булган татарларга да үз телләрендә газета-журналлар нәшер итү мөмкинлеге тудырыла. Шушы форсаттан иң әүвәл империянең башкаласында яшәүче, патша җәнабларына сакчы хезмәтен үтәүче мөселман гаскәриләренең дин башлыгы булып торган хәрби ахун Гатаулла Баязитов файдалана. 1905 елның 22 сентябрендә аның «Нур» газетасының тәүге саны басылып чыга. (Мәгълүм «Патша манифесты» игълан ителүдән бер ай чамасы алдарак. Милли телләрдә газета-журналлар нәшер итүгә рөхсәт бирүче рәсми фәрманга шул елның 24 ноябрендә кул куела.) Әйтергә кирәк, Гатаулла хәзрәт тә 1880 еллар башында ук «Хәфтә» («Атна») исемендә бер газета чыгарырга омтылып караган күренекле шәхесләребезнең берсе. Ләкин аңа да ул вакытта рөхсәт бирелми. 1905 елның көзендә икенче татарча газета — «Фикер» — ерак Җаек каласында борын төртә.

1906 елның 16 февралендә Рәмиевләрнең «Вакыт» газетасын Оренбургта нәшер итәргә дә рөхсәт бирелә. (Оренбург генерал-губернаторы канцеляриясендә теркәлгән документ номеры 367.) Бу документта «газетаның нашире Мөхәммәтзакир Мөхәммәтсадыйк улы Рәмиев. Мөхәррире Мөхәммәтфатыйх Гыйльман улы Кәримев» дип язылган. Ягъни, кайбер матбугат чараларында бәян ителгәнчә, Шакир Рәмиев бу очракта183 наширлар исемлегендә күрсәтелмәгән. Ә инде «Шура» журналын чыгаруга рөхсәт биргән документта ике бертуган да нашир дип белдерелгән.

Мөхәррирлеккә ни өчен Фатих Кәрими сайланган? Беренчедән, ул инде танылып килүче язучы, ике-өч китап авторы. Икенчедән, ул дәвердә губернадагы бердәнбер татар басмаханәсенең хуҗаларыннан берсе. Дөрес, Бөгелмә өязе ахуны Гыйльман Кәримев 1890 еллар ахырында типография ачарга ниятләгәндә, аңа беренче булып матди ярдәм итүчеләр, «хәлгә керүчеләр» дә бертуган Рәмиевләр белән Хөсәенев байлар булган. Шулай итеп, Кәримевләр белән Рәмиевләр арасындагы иҗади дуслык дистә еллар элек үк башланган дигән сүз. 1899 елда Шакир Европа илләре буйлап сәяхәт кыла. Парижда уздырылган Бөтендөнья сәнәгать күргәзмәсендә дә катнаша. Тәрҗемәче һәм юлдаш

сыйфатында аны Фатих Кәрими озата йөри. (Аның күләмле «Аурупа сәяхәтнамәсе» китабы 1902 елда С.-Петербургта басылып чыгачак.) «Вакыт» газетасы һәм соңрак нәшер ителә башлаган «Шура» журналы башлангыч чорда мәрхүм Гыйльман хәзрәтнең уллары Фатих белән Камил һәм кияве Тимерша Соловьев карамагында калган «Кәримевләр басмаханәсе»ндә басылалар.

Газетаның беренче саны типографиядән 21 февральдә чыга. Исмәгыйль Рәмиевнең «Вакытлы татар матбугаты. 1905–1925» исемле энциклопедик хезмәтендә: «Вакыт» — милли-либерал газета. Оренбургта чыга. Барысы 2309 сан чыкканнан соң, 1918 елның 26 гыйнварында туктатыла... (Оренбургны большевиклар яулап алгач, ике-өч көн үтүгә, «буржуаз газета-журналлар», шул исәптән «Вакыт» белән «Шура» да чыгудан туктатыла.) Сәяси мәсьәләдә сак, дини һәм милли мәсьәләләрдә үз артыннан ияргән милли матбугатка юнәлеш биреп барды. Уку-укыту эше, тел һәм әдәбият, мәдәният мәсьәләләренә киң урын бирә, милли театр, музыка сәнгатен җәелдерүгә теләктәшлек күрсәтә, дәүләт мәктәпләренә кереп укуны эзлекле яклый иде», — диелә.

1917 елның октябрь, 1918 елның гыйнвар айлары аралыгында «Вакыт»ның мөхәррире язучы, Дәрдемәнднең кияве Ярулла Вәлиев була. Ярулла элегрәк Бозаулык шәһәрендә сәүдә эше белән шөгыльләнә. Берничә хикәя бастырып, телгә керә башлаган яшь каләм әһеле санала. «Бай кияве булганчы», ягъни 1906 елда ук Ф.Кәрими аны газетада эшләргә дип чакырып китерә. 1908 елдан, Рәмиевләрнең үз типографиясе сафка бастырылгач, Я.Вәли аның мөдире вазифасын да үтәгән.

Рәмиевләр 1907 елның декабрендә «Шура» журналын чыгаруга да рөхсәт алалар. Ул айга ике мәртәбә, елына 24 сан булып чыга. Беренче саны 1908 елның гыйнвар башында дөнья күрә. «Наширлары Мөхәммәтшакир һәм Мөхәммәтзакир Рәмиевләр». Шул ук документта мөхәррире дип Ризаэтдин Фәхретдинев күрсәтелгән. Риза казый 1906 елның җәй ахырларында ук Уфадан Оренбург каласына чакырып китерелгән һәм октябрь аеннан «Вакыт» газетасының мөхәррир урынбасары итеп билгеләнгән була. Аны гаиләсе белән бу шәһәргә чакырып китерүчеләр яшьтәшләре Шакир белән Закир булгандырмы яисә апасының улы Фатихмы, әлегә ачыкланмаган. Мөгаен, бу мәсьәләне алар бергә киңәшеп хәл иткәннәрдер. Киләчәктә әдәби-иҗтимагый бер журнал нәшер ителәсе дә истә тотылгандыр, мөгаен.

И.Рәмиев китабында «Шура» журналының 1918 елның башына чаклы нәшер ителүе, барлыгы 240 саны чыкканлыгы әйтелә. Һәр саны зур форматта 36 битле булып, вакыт-вакыт рәсемнәр белән баетылып басылган. «Әдәби, гыйльми, тарихи журнал. Татар журналлары арасында иң күренеклесе. Дәвамлы, тәртипле

чыгып торуы белән дә абруй казанды, күп таралды, күп укылды... Техник эшләнеше ягыннан да үз заманында һичшиксез беренче урынны тотты», — дип яза Исмәгыйль ага. Журнал беренче елында шулай ук «Кәримев, Хөсәенев вә шөрәкясе» басмаханәсендә басыла.

Бу газета һәм журнал редакцияләрендә шул чорның танылган журналист вә әдипләре Борһан Шәрәф, Габделбари Баттал, Шәриф Камал, Җамал Вәлиди, Кәбир Бәкер, Ярулла Вәли һ.б. эшлиләр. Читтән торып алар эшендә Галимҗан Ибраһимов, Йосыф Акчура, Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Нәҗип Думави, Ярулла Биги, Зәки Вәлиди, Һади Атласи, Чыгътай һ.б. язучылар, шагыйрьләр, «җәмәгать хадимнәре һәммәсе диярлек үзләренең каләмнәре белән катнашалар». Бу басмаларда Тукайның йөздән артык каләм хезмәте дөнья күрә. «Вакыт» белән «Шура»ны татар, башкортлар гына түгел, башка кардәш халыклар, мәсәлән, үзбәк, казакълар да үз итеп укыйлар.

Газета һәм журнал битләрендә әдәби, гыйльми, дини эчтәлекле әсәр һәм хезмәтләр байтак урын алган, алар арасында үзара ярышлар уздырылган. Ярышларда җиңеп чыккан әсәрләр, газета һәм журнал кушымталары рәвешендә, Рәмиевләр тарафыннан аерым китап итеп тә бастырылганнар. Редакцияләргә килеп тә, төрле сәбәпләр белән аларда урын ала алмаган шигырь, хикәяләр дә еш кына аерым җыентыкларга тупланып чыгарыла торган булган.

«Закир Рәмиев редакция эшчеләренең тормыш ягыннан яхшы тәэмин ителүләре... яшәүләре ягына нык күз сала, аларга, ул чорларда һичбер җирдә күрелмәгән рәвештә зур жалованье — «Вакыт» газетасы редакторы Фатих Кәримев белән «Шура» журналы редакторы Риза казыйга аена 130 сум бирә иде. Моны күпләр «министрлар жалованьесе» дип йөртә торганнар иде» дип яза 1908–1909 елларда Оренбургта «Чүкеч», «Шура» журналларында эшләп алган әдип Зариф Бәшири («Замандашларым белән очрашулар», 1968). Ә 1917 ел башында «Закир әфәнде әмере белән расланган» бер исемлектән күренгәнчә, Фатих Кәриминең эш хакы 325, Риза Фәхретдиневнеке — 275, Ярулла Вәлинеке — 250, корректор Шәриф Камалныкы 180 сум булган. (Ул чорда гади редакторлар «корректор» дип йөртелгән.)

«Рәмиевләр, бигрәк тә Закиры, матбугат һәм әдәбиятка зур мәхәббәт белән караганлыктан, бу эшкә сәүдә-табыш ягыннан килмәделәр... Үткән елларда «Вакыт» һәм «Шура»дан алтын хисабы белән ун мең сумлап зарар күрделәр», — дип яза З.Бәшири.

«Вакыт» газетасын чыгара башлау белән бер үк вакытта Рәмиевләр, редакция хезмәткәрләре өчен дип, Шакирның йорт-утары янәшәсендә бер катлы, өч секцияле йорт булдыралар. Аның бер

секциясендә төрле елларда төрле гаиләләр яшәсә (мәсәлән, Кәбир Бәкер гаиләсе), калган өлешендә Ризаэтдин хәзрәтнең ишле гаиләсе урнаша. Шунда ук аның эш кабинеты да була. Ул өй урынында хәзер биш катлы торак бина, сиксәненче елларда аның диварына «1906–1918 елларда... бу урында Ризаэтдин Фәхретдинев яшәде» диелгән истәлек тактасы куелды.

Шул ук китабында З.Бәшири билгеләп үткәнчә, Кәримевләрнең басмаханәсе ярыйсы ук таушалган була, хәрефләр еш алышынмый, арзанлы кәгазь һәм начар буяулар кулланыла. (Зариф ага ул типографияне үз кулында тоткан Тимерша Соловьевтан еш зарлана, аның саранлыгы турында байтак дәлилләр китерә.) Рәмиевләр аның эшеннән бик үк канәгать булмыйлар һәм үз типо-литографияләрен ачу хәстәренә керешәләр. Дәрдемәнд йорт-утарының иркен ишегалды почмагында, арттагы Водяная урамында бина сатып алына, заманча типография җиһазлары урнаштырыла, мөхәррир һәм корректорлар өчен эш бүлмәләре булдырыла. «Вакыт» белән «Шура» 1909 елның 1 гыйнварыннан шунда ярыйсы ук сыйфатландырылган рәвештә чыга башлыйлар. «Вакыт» басмаханәсе мөһере сугылган әдәби, мәдәни, тарихи эчтәлекле китапларны һәм дәреслекләрне нәшер итүгә дә керешелә. Басмаханә 1918 елның гыйнвар ахырларына кадәр Рәмиевләр карамагында була.

1910 елларда Оренбургта нәшер ителгән кайбер рус һәм казакъ вакытлы матбугаты да шул басмаханәдә чыккан. «Казакъ» газетасы (Оренбург, 1913–1918), казакъ телендә сигез исемдә китап та (шулар арасында казакъча беренче повесть — «Көргенде бала») «Вакыт» типографиясендә басыла.

Ул дәвердә Оренбургта русча алты-җиде журнал, шул чамада ук газеталар чыга, ә бердәнбер хосусый Бреслин типографиясе 1915 елда ябыла. Губерна идарәсе басмаханәсе исә күбрәк рәсми материаллар бастыруга йөз тота. Совет хакимияте дәверендә Рәмиевләр эшчәнлеген барлау бик хупланмаганга күрә, «Вакыт» басмаханәсенә кагылышлы төпле фәнни тикшеренүләр булмады. Анда басылып чыккан китаплар саны да, хәтта бер үк авторның хезмәтләрендә дә төрлечә күрсәтелә. (Әбрар ага Кәримуллин хезмәтләре күздә тотыла.) Оренбург хәйрия җәмгыятенең «Белек» китапханәсе, Орскидагы «Шәрекъ көтебханәсе», Троицк, Чиләбе, Кустанай һ.б. якын шәһәрләрдәге китап-газета сәүдәсе ширкәт һәм җәмгыятьләре ул заманда нашир вазифасын да үтәгәннәр, кирәк дип санаган китапларын бастырып чыгару өчен Казан һәм Оренбург басмаханәләренә даими рәвештә заказлар җибәреп торганнар. Андый заказларны «Вакыт» типографиясе дә үтәгән.

«Вакыт» басмаханәсендә кайсы әдип вә галимнәребезнең китаплары нәшер ителгән соң? Кемнәр Рәмиевләр матбагасына якын

торган? Беренче урында, әлбәттә, Рәмиевләр тарафыннан бик ихтирам ителгән, Дәрдемәндкә яшьтәш булган Риза хәзрәт Фәхретдинев хезмәтләре. Аның дини, әхлакый-тәрбияви һәм тарихи эчтәлекле 35 китабы «Вакыт»та дөнья күргән. (Ә.Кәримуллин хезмәтләрендә алар саны шактый ким күрсәтелә.) Икенче, өченче урында Шәриф Камал белән Галимҗан Ибраһимов китаплары тора. Ш.Камалның революциягә чаклы дөнья күргән барлык әсәрләре дә диярлек башта «Шура» белән «Вакыт» битләрендә урын алган, аннары аерым китап итеп басылганнар. 1910 елда «Козгыннар оясында» исемендә озын хикәясе, 1914 елда — унбиш әсәрен берләштергән «Хикәяләр төркеме», 1915 елда «Акчарлаклар» повесте, «Вакыт» басмаханәсе тарафыннан китап рәвешенә китерелеп, укучыга тәкъдим ителгән. Г.Ибраһимовның да беренче иҗат дәвере хикәяләренең күпчелеге әүвәл «Вакыт» белән «Шура» битләрендә, аннары аерым китап буларак басылган. «Диңгездә» (1911), «Йөз ел элек» (1911), «Уты сүнгән җәһәннәм» (1912), «Карт ялчы» (1912) хикәяләре һәм күләмле «Татар шагыйрьләре» (1913) очеркы шулай нәшер ителгәннәр. Үз басмаханәсе булган Ф.Кәриминең дә кайбер хезмәтләре «Вакыт» типографиясендә чыга. Мәсәлән, «Истанбул мәктүпләре» исемле калын (450 б.) китабы һәм «Дөнья халыклары» исемендәге берничә китапчыгының язмышы шундый. Иҗтимагый, мәдәни, әдәби хәләхвәлне күзалларга ярдәм иткән Г.Сәгъдинең «Әдәбият кануннары», Г.Батталның «Габделвәли Яушев» китаплары, «Шәех Зәйнулла хәзрәтнең тәрҗемәи хәле» күмәк җыентыгы, Җ.Вәлидинең «Татар әдәбияты хакында», «таңчылар» төркеменең актив әгъзасы Шакир Мөхәммәдъяровның «Алпавытлар заманы», казакъ әдәбияты классигы Абайның икенче китабы саналган «Абай тирмәсе», Н.И.Ашмаринның унтугызынчы йөз ахыры татар әдәбиятына багышланган очеркының татарчага тәрҗемәсе һ.б. хезмәтләр дә — «Вакыт» җимеше. Тәрҗемә китапларыннан тагын Төркиянең күренекле әдибе Әхмәт Мидхәт, инглиз язучысы Конан Дойль, рус әдипләре Александр Пушкин, Николай Гоголь, Леонид Андреев һ.б. әсәрләрен өстәргә кирәк. «Вакыт» басмаханәсендә дөнья күргән дәреслекләр саны да ишле генә. Казакъ халкының милли азатлыгы өчен көрәшүчеләр даирәсенә кергән Миржакыйп Дулатовның беренче шигырь китабы «Уян, казакъ» (1909) белән казакъ телендәге беренче роман саналган «Бәхетсез Җамал» (1910) Казанда басылган булсалар, шуннан соңгы ике шигырь китабы — «Азамат» (1913) белән «Тирмә» (1915) Оренбург шәһәрендә яшәгән дәверендә Рәмиевләр басмаханәсендә дөнья күргән булса кирәк.

Шул рәвешле, ул басмаханә һәм бертуган Рәмиевләр нәшер иткән журнал белән газета татарга һәм аңа карындаш булган халыкларга уңышлы гына хезмәт иткән, оештыручыларының изге

ниятен үтәгән. Рәмиевләрнең матбугат эшчәнлеге өстәмә керем-табыш алу нияте белән башкарылмаганлыгын байтак замандашлары билгеләп үтә. Аларның бу эшкә керешкәндәге төп максаты милләт мәнфәгатен кайгыртуга, татар халкының үзаңын үстерүгә юнәлтелгән була. Һәм алар үз максатларына ирешәләр дә: «Вакыт» белән «Шура» татар халкы арасында гына түгел, безгә кардәш казакъ, каракалпак, үзбәк һәм Кавказ төбәге төрки милләтләре арасында да абруйлы матбага үрнәкләренең алгы сафында була.

*2001–2007*

## ДӘРДЕМӘНДНЕҢ ОРСКИДАГЫ ТОРМЫШЫ

### Орск каласы. Өстәмә борчулар. Балалар фаҗигасе

Закир Рәмиев-Дәрдемәнд тормышының соңгы фаҗигале еллары. Шагыйрьнең Орск шәһәрендә узган өч ел ярым гомеренең аерым сәхифәләре. Аны күреп белүчеләр, язма истәлекләр бу хакта ни сөйли?..

Закир белән Мәхүбҗамал 1918 елның февраль ахырларында Орскига чыгып китәргә җыеналар. Әлбәттә инде, элеккечә затлы тройкалар җигеп, кирәк-ярак җиһаз һәм затлы кием-салымны төяп түгел, җиңелчә, буш кул белән дип әйтерлек. Чөнки ике урталыктагы Сара авылы тирәсендә атаман Дутов гаскәрләре белән кызыллар арасында каты сугышлар барганлыктан, әйләнеч юлны сайларга мәҗбүр булалар. Ташкент поезды белән Актүбәгә кадәр барачаклар. Аннан соң йөз кырык чакрым араны Мәхүбҗамалның энесе җибәргән чанада үтәрләр.

Оренбург белән Орск арасында тимер юл яңарак кына төзелә башлаганлыктан, ат-арбада йөрү Рәмиевләр өчен гадәти күренеш була. Губерна үзәге белән өяз башкаласы арасындагы өч йөз чакрым чамасы юлны алар кышын-җәен берничәшәр мәртәбә йөреп күнеккән инде. Дөрес, башка елларда Мәхүбә ханым бала-чага белән олы юлга фәкать җәй айларында гына җыенып чыга торган иде. Ә быел менә кыш уртасында ук зур юлга икәүдән-икәү генә җыендылар. Аның сәбәбе, әлбәттә, Оренбургны кызыллар алуда гына түгел иде. Рәмиевләрнең ике кече улы — Җәгъфәр белән Морад та каядыр шунда Орск төбәгендә сугышып йөриләр. Кызыллар шәһәрне алганчы Оренбургка алардан хәбәрләр килгәләп тора иде. Хәзер исә ара тәмам өзелде. Ата-ана аеруча иң кечеләре — Морадлары өчен борчыла. Ул, яшьләрчә гайрәтләнеп, дутовчыларның офицерлар полкына эләккән иде. Килеп торган хәбәрләргә караганда, ул полкка иң катлаулы бурычларны үтәү йөкләнә, шунлыктан алар арасында югалтулар да күп икән.

Җәгъфәр исә ышанычлырак кулда. Ул Беренче башкорт кавалерия полкында сугыша. Аның командиры, пәһлеван кыяфәтле Муса Мортазин белән Закир Рәмиев берникадәр таныш. Мортазин — Зәки Вәлидинең иң ышанычлы һәм тәҗрибәле командиры. (1929 елда барлык Рәмиевләр кулга алынып Чиләбе төрмәсенә ябылгач, комдив Мортазин Җәгъфәрне аклауны үтенеп хат язачак. Ул хат-юлламаның күчермәсе минем архивта саклана.) Зәки хан үзе дә Рәмиевләрне чит-ят күрмәскә тиеш. Казанга укырга киткәндә, Закир агасы аңа хәер-фатиха теләп, шәкерт кешегә берничә айга җитәрлек итеп акча биреп җибәрде түгелме соң?! Ул вакыйгага да әле күп булса җиде-сигез ел үткәндер. Онытмагандыр, шәт. Зиһенле кеше андый ярдәмне онытмас... Мортазин полкы урнашкан төбәктә әлегә кызылларның басымы да бик үк гайрәтле түгел шикелле. Техник белеме булган Җәгъфәр дә ул полкта алгы сафта сугышмый. Мортазин аны корал белән тәэмин итү бүлегенә билгеләп куйган. Шуңа күрә ата-ананың Җәгъфәр өчен күңелләре бераз тыныч сыман. Егет үзе дә атылып утка керү яшеннән узып, олыгаеп бара.

Балалар язмышыннан кала приисклардагы хәл-әхвәлләр дә борчый Закир Рәмиевне. Бу буталчык заманда анда ни хәлләр икән? Прииск җиһазларын ватып, җимереп бетермәгәннәрме? Алтын бөртекләре сакланган таш келәтләр ышанычлы кулллардамы? Алтын чыганаклары урнашкан җир-биләмәләрнең бер өлеше әлегә мөстәкыйль Башкорт автономиясе карамагында, алары башкорт хәрби көчләре күзәтчелегендә. Ә ул мохтарияттән читтә урнашкан Балкан, Кумак, Шәйханнарда ни хәл икән? Үз биләмәмдәге байлыкка үзем хуҗа дип белдерүче яңа ханнар, атаманнар көннән-көн арта барса да, ул биләмәләрдәге приисклар өчен дә җаваплылык барыбер бит әле Рәмиев, Дашков, Тимашев кебек элекке хуҗалары өстендә. Анда эшләүчеләр алдында әлегә алар җаваплы. «Вакыт» басмаханәсен Совет хакимиятенә гауга-тавышсыз гына тапшырган кебек, приискларны да бит кичекмәстән кемгә дә булса тапшырырга кирәк булачак, ахрысы. Дөнья шул якка таба үзгәрә. Большевиклар әнә һөҗүм итә-итә Уралны узып баралар. Тиздән Орск тарафына да килеп җитәчәкләр. Сәяси отыш алар кулында. Җир дә, җирдәге байлык та шул байлыкны тудыручы эшчеләр, игенчеләр кулында булырга тиеш, дип белдерәләр. Күпчелекне тәшкил иткән ул эшче һәм игенчеләрнең үз өлешләре өчен теш-тырнаклары белән көрәшәчәкләре билгеле. Мөгаен, җиңеп тә чыгарлар. Әлегә ул байлыкка хуҗа булган азчылык катлау, Рәмиев, Романов, Дашковлар катлавы, тез чүкмичә булдыра алмастыр, әлбәттә.

Исә җилләр, күчә комнар, бетә эз...  
Дәрийгъ, мәхзүн күңел, без дә бетәбез...

* * *

Орскига китешли шушы уйлар да борчыгандыр Дәрдемәндне. Шуңа күрә дә инде, гадәттәгечә юл төшүен көтмичә, Орскига кышын китәргә булганнардыр. Орск — приисклардагы хуҗалыкларны берләштереп торучы үзәк. Җай чыкса, аннан приискларга да барып килергә мөмкин булачак. Бәлки, шул тирәдә сугышып йөргән балаларның да хәлен белеп булыр. Рәмиевләр эш йөрткән Орск банклары ни хәлдә икән?

Оренбургта, әлегә бик алай ят күренмәгән яңа идарәчеләр карамагында да аның зур хуҗалыгы кала. Шәһәр үзәгендәге Неплюев белән Введенская урамнары чатындагы төп йортта аның көндәлек эш кәгазьләре, яраткан китапханәсе тизрәк әйләнеп кайтуын көтеп торачак. Олы улы Искәндәр, йөкле килене, сөйгән кызкияүләре үз бала-чагалары белән әлегә Оренбургта төп утар-йортта торып калалар. Әйе, чит-ят җирдә адашып калган Гариф улыннан башка барлык балалары, оныклары яңа хакимият карамагында кала. Аларга карата бер-бер хәл булмасмы? Европа илләре белән Россия арасында башланган зур сугыш аркасында Гариф, туганнан туган агасы Әхмәт Рәмиев белән бергә Бельгиядә бүленеп калган иде. Закир аларны Льеждагы техник югары уку йортына үзе урнаштырып кайтты. Үкенечкә булган икән. Алар исән-саумы хәзер? Морад белән Җәгъфәрне мобилизацияләгән кебек, аларны да берәр армиягә алмадылармы икән? Алар да, бәлки, чарасыздан кемнәргәдер каршы сугышып йөриләрдер. Әнә бит, Германия армиясе Польша, Украина җирләрен басып алган. Басып алулар кан коюсыз башкарылмый. Яу кырында ике якның да солдатлары юк ителә. Шулар арасында Гариф белән Шакир агасының улы Әхмәт юктыр дип кем әйтә ала? Мылтык тотардай яшьләрне көчләп гаскәргә алу гадәте, мөгаен, Германиядә дә бардыр. Бик күп кешене юк итеп алып барыла торган сугыш заманы бит хәзер.

Җәй башында Орскига Искәндәр дә килер, шәт. Шәрифзадә киленнәре баладан исән-имин котыла алса. Аңа чаклы Гариф уллары турында да ышанычлы бер хәбәр алынса, күңел борчулары кими төшәр иде... (Гариф Рәмиевкә туган-үскән җиренә әйләнеп кайту насыйп булмый шул. Ул Беренче бөтендөнья сугышыннан соң Финляндиядә яши, балалар укыта. 1971 елда туганнан туганы Камилә Максуди белән күрешергә дип Римга баргач авырып китә, вафат була. Гариф Закир улы Рәмиев Римның мөселман зиратында җирләнгән. Әхмәт Рәмиевнең Бельгиядә яшәп калуы яисә туганы Камилә тирәсенә, Төркиягә барып елышуы да ихтимал. Бөек Ватан сугышыннан соң Америкага киткән икән, диючеләр дә бар.)

* * *

Актүбә белән Орск арасындагы озын юлны кичкәндә шагыйрь күңелендә шундыйрак уйлар бөтерелгәндер, мөгаен. Бу аралыкта казакъ кышлаулары белән яңарак күчереп утыртылган урыс авыллары ярыйсы ук шыксыз, күңелсез. Авыл аралары да шактый ук ерак. Ә хут аенының бураннары исә туктаусыз тынычсызлап тора: арттан куып җиткәне бетмәстән, алдагысы сагалаган була. Тун өстеннән бөркәнгән толып та коткармый. Авылдан авылга җиткәнче Мәхүбҗамал абыстай тәмам бөрешеп каткан була. Орск янәшәсендәге Әлимбәтевкәгә кайтып җиттек дигәндә генә, кояш мәрхәмәтлек күрсәтеп елмаеп ала. («Әлимбәтевкәгә җиткәч кенә, кояш күренде, эчкә җылы керде» гыйбарәсен Борнаевлар нәселенә бәйләнеше булган Шакира апа Мостафинадан язып алдым.)

Ялга туктаган авыл кешеләре хәбәр итүенчә, бу юлда да беркемгә дә буйсынмаган кораллы төркемнәр күренгәләп ала икән. Шуларны истә тотып, Мөхәммәтҗан Борнаев аларны алырга ике олау җибәргән була. Рәмиевләрне юл буе арткы чанадагы кораллы егетләр озата кайткан.

Закир белән Мәхүбә, элек-электән гадәтләнгәнчә, Борнаевларның төп йортына кайтып төшәләр. Әлеге бик зур йортның аскы катында бертуган Борнаевларныкы белән бергә Гали хаҗи Далатказин байның кибетләре дә урнашкан була. Йортның икенче катында хуҗалар үзләре яши. Монда Мостафа карт Борнаев заманыннан бирле кыз белән кияүгә дип билгеләнгән бүлмәләр була. Алар бит Орскига һаман саен килеп-китеп йөриләр. Мостафа карт вафатыннан соң төп йортта кече уллары Мәхмүтҗан белән киленнәре Мәхмүзә кала. Габдуллаҗанга исә күрше урамда ике катлы махсус торак өй җитештерелә. (Асты табигый таштан, өсте бүрәнәдән булган ул йорт хәзер дә исән. Хәзерге Энгельс һәм Пионер урамнары чатында урнашкан. Туксанынчы елларда анда балалар бакчасы иде. Шагыйрь эзләрен саклаган ике катлы зур сәүдә йорты 1984 елда «Орский рабочий» газетасының яңа типографиясен төзү өчен сүтелде.) 1918 елның май урталарында яңа туган уллары Бәшир белән Искәндәр гаиләсе кайткач, алар Габдуллаҗан абыйларында тора башлыйлар.

1918 елда Рәмиевләр Орскига күчеп килгәндә Мәхмүтнең Рәшит белән Шамил исемле ике улы була. Рәшит — 1910, Шамил 1913 елда туган. 1966 елда мин ул Рәшит ага белән очраштым, истәлекләрен язып алдым. «Шагыйрь баба» күчеп килгәндә аңа сигез яшь тирәсе була. Дәрдеменд аны үзе белән балыкка алып баргалый. «Бабай артта, кучер абый белән без кузлада утырып Ущельегә дә, Гөберлә елгасы буйларына да йөри идек», — дип сөйләгән иде. Урал елгасы Орск шәһәренә чаклы Уралтау тар-

макларының көнчыгыш сырты буйлап ага да капылт кына көнбатышка таба борыла. Уралсуның Уралтау сыртын кисеп үткән тарлавыгы шәһәр халкы телендә «Ущелье» дип атала. Тарлавык алдында елга берничә күл хасил итә. Дәрдемәнднең 1918–1919 елларда хәзерге Иске шәһәрдән ун-унбиш чакрымнардагы шул төнбоеклы, балыкка бай күлләр тирәсенә баргалавын Рәшит Борнаевтан гына түгел, башкалардан да ишеткәләргә туры килде.

Рәшит агадан Дәрдемәндкә багышлы тагын бер җөмлә язып алганмын: «Шагыйрь баба эче пошып ишегалдында йөргәндә французча сөйләшә торган була». Әлбәттә, бу җөмлә бала күңеленә зурлар сөйләменнән күчкән булса кирәк. Чынлыкта шагыйрь француз телен белгәнме соң? Хәзергә төгәл генә итеп әйтүе мөмкин түгел. Франция мәдәнияте йогынтысында булган Төркиядә уку дәверендә Закир, бәлки, француз теле белән дә беркадәр кызыксынгандыр. Соңрак та аның башка телләр белән кызыксынган булуы мәгълүм. Мәсәлән, оныгы Бәшир Рәмиевтә шагыйрь имзасы салынган төрекчә-немецча сүзлек саклана. Фатих Кәрими хәбәр итүенчә, ул гарәп телен китап укырлык, шул телдә сөйләшүчегә әңгәмәдәш булырлык дәрәҗәдә белгән. 1914 елда Закир Рәмиевнең Европа илләренә сәяхәт кылганлыгы да билгеле. Ул француз теле өстенлек иткән Бельгиядән соң Франция һәм Италия илләрендә була. Димәк, Рәшит Борнаев әйткән сүзләрдә дөреслек бардыр сыман. Шул ук вакытта төп-төгәл итеп, французча да белгән, дип әйтеп тә булмый. Европа буйлап сәяхәт кылганда бит аны кызы Зәйнәп, абыйсының кызы Камилә озата киләләр. Алар рус гимназияләрендә белем алганнар, мөгаен, чит телләрне дә үзләштергәннәрдер. Ә Камиләнең ире Садри Максуди исә Парижда Сорбонна университетын тәмамлаган. Ул да бит алар белән бергә сәяхәт кыла.

Шул ук вакытта фикердәше Фатих Кәримигә шагыйрь үзе сөйләгән бер вакыйга да истән чыкмый. Төркиядә яшәгән дәвердә Дәрдемәнд бер француз язучысының романын тәрҗемә итә. Соңрак, тәрҗемәне кабат укып чыгып күңеле кайткач, кулъязманы «ертып ташлаган» дип хәбәр итә Ф.Кәрими. Мәгәр ул романның кайсы телдән (турыдан-туры французчаданмы яки төрекчәгә күчермәсеннәнме) тәрҗемә ителүен язмый.

Алтмышынчы елларда Орск шәһәрендә миңа Борнаевлар нәселеннән Рәшит агадан башка кеше очрамады. Ә шул ук фамилияне йөртүче күпсанлы шәһәр телефоны абонентлары исә: «Без ул нәселдән түгел», — дип җавап бирделәр. Элекке заманда Борнаевларда төрле хезмәттә булган кайберәүләрнең балалары исән иде әле. Шулар арасыннан Шакирә Мостафина һәм Абдулла Исәнбаев шагыйрьнең Орскидагы тормышы турында байтак мәгълүмат бирделәр...

1918 елның җәй башында Орскига Искәндәр белән Шәрифзадә дә күчеп кайта. Биләүсәдәге бер айлык Бәширне күтәреп. (Бәшир аганың анкеталарында үги анасы Миңсафа гына күрсәтелгән. Соңгы автобиографик язмасында гына ул үз анасының Шәрифзадә Дашкова булуын белдерә. Шул сәбәпле туган урынын да «Орскида» дип яза. Дөреслектә ул Оренбургта туган. Анкета язмаларындагы үзгәлешләрне теркәргә аңа әтисе тәкъдим иткән була. Чөнки Рәмиевләр йортындагы элекке «самавыр куючы кыз Миңсафа» Чистай төбәгендәге гади крәстиян катлавыннан чыккан. Рәмиевләрнең башка онык-онычкалары да ул чорда үз парларын гади халык арасыннан сайларга тырышалар. Өммегөлсемнең өч ятимәсенең дә язмышы шундыйрак. Мәсәлән, аның икенче кызы Суфия, яшьлегендә шигырьләрне, әдәби парчаларны шагыйрь бабасы үрнәгендә оста итеп яза белгән бик чибәрдилбәр кыз, Мәскәүдә үзе сайлап бер эшчегә кияүгә чыга. Кардәше Әсмага, «үз фәлсәфәсен» аңлатып: «Рабочийга чыгарга кирәк, бездән туган балалар хөкүмәткә үги булмасын. Рәхәтләнеп вузга кереп укый алсыннар», — ди. Утызынчы елларда заманга яраклашырга тырышу күренеше бу нәсел варисларына гына хас күренеш түгел, әлбәттә.) Рәмиевләр ул җәйне, гадәттәгечә ике-өч гаилә берләшеп, Балкан авылы төбәгендә уздыралар. Шул хакта Әсма Рәхмәтуллина истәлекләрендә тәфсилләп бәян ителә. Әсма исә Маһруй кызы. Ә Маһруй, алдарак хәбәр итүебезчә, Мәхүбҗамалның бертуган сеңлесе. Әсма Әхмәтҗан кызы Рәхмәтуллина 1905 елда туган. Атасы, халык телендә Кара Әхмәтҗан дип йөртелгән мулла, тумышы белән Казан артындагы Әтнәдән була. Орскида ул мәгълүм бер мәдрәсәнең мөдәррисе. Дәрдемәнднең үз күргән баҗасы. Шәһәр халкы аны мәдрәсәдә генә чалмадан йөргән, өендә музыка уйнап, заманча яшәргә яраткан дип искә ала. Үз дәвере әдәбиятын күздән кичереп барган, мандолинада оста уйнаган. Өч кызын да заманча зәвыклы итеп тәрбияләргә тырышкан. Олырак кызлары Сара белән Хәдичә пианинода уйнарга өйрәнәләр, өчесе дә мәктәп сәхнәсеннән шигырь сөйли торган булалар.

Ул дәвердә шәһәрдә мөселман балалары өчен ике мәктәп, өч мәдрәсә эшләп килгән. Әхмәтҗанның хатыны Маһруй абыстай Кызлар мәктәбе тоткан. Әхмәтҗан мулланың Орскиның икенче бер байлары — Нигъмәтуллиннар белән дә кардәшлек бәйләнеше барлыгы мәгълүм. Орск кешеләре сөйләвенчә, революция алды елларында «Шәрекъ йорты» рәисе дә булган Сары Әхмәтҗан белән дә Дәрдемәнд еш аралашкан. Ә ул Әхмәтҗан исә күренекле артисткабыз Галия Нигъмәтуллинаның туганы була.

Төбәк тарихчысы Мәдинә Рәхимкулова үтенече белән башкарылган истәлегендә Әсма апа түбәндәгеләрне яза: «Җизниләр... җәй булгач бөтен семьялары белән Искәндәревский прииска

китәләр иде. Оренбурдагы йортлары бер катлы булган кебек, прискадагы өйләре дә бер катлы иде. Йорт җиһазлары гади. Шкафларда, этажеркаларда Уралда табылган ташлар һәм китаплар иде. Һәр ташның исеме язылган... Җизни озын буйлы, зәңгәр күзле, чәче дә дөм кара түгел, коңгырт төстә. Ә Мәхүбҗамал апа ак йөзле, правильный борынлы, коңгырт озын чәчле иде. Туганым абыстайны җизни уналты яшендә ала. Бик тату яшиләр. Без 1918 елның җәендә аларга кунакка бардык (шул прииска). Җизни белән Искәндәр абый еш кына эш белән китәләр иде. Көн дә сәгать сигездә иртәнге чәй була. Көн дә бер вакытта көндезге аш, кичке чәй бирелә. Йокы алдыннан катык ашыйдыр идек. Кичләрен Искәндәр абый Германиядә укыткан профессорының тормышын сөйләр иде. Профессорның кызлары күп, көн дә бер кызы өйне җыештыра икән. Искәндәр абый: «Прислугаларыгыз юкмыни?» — дип сорый. Профессор исә: «Кызларым тормыш алып барырга өйрәнсеннәр», — дип җавап бирә икән...»

Әле китерелгән өзектә, минемчә, бер генә төгәлсезлек бар: башка мәгълүматларга караганда, кияүгә чыкканда «туганым абыстай»га егерме яшь тирәсе була. Ул 1861 елда туган. Өйләнешүләре 1882 елның кышына туры килә.

Балканда уздырылган кайбер кичләрдә күмәкләп карта уйныйлар, «алтмыш алтылы» дигән уенны. «Минем апам Сара, җизнинең внучкасы Рабига (Өммегөлсем кызы), җизни һәм Фоад». Димәк, Фоад әле 1918 елда исән була. Дәрдемәнднең үз оныклары аны балачакта үлгән дип әйткәннәр иде. Җәгъфәр кызы Зөбәрҗәт тә аны «тугач та озак тормыйча үлгән» дип язды. Укытучы Зөбәрҗәт җибәргән исемлектә ул 1903 елда туган дип күрсәтелә. Сөләйман улы булмыйча, шул Фоад турында сүз бара, мөгаен.

Шушы истәлеккә нигезләнеп әйтә алабыз: Закир Рәмиев-Дәрдемәнд хәвефле 1918 елгы җәйнең байтак өлешен «Искәндәрский прииск»та үткәргән икән. Ә ул прииск хәзерге Чиләбе өлкәсенә кергән Балкан авылы тирәсендәге биш алтын чыганагының берсе саналган. Ул шахталар уртасында бертуган Рәмиевләрнең төп утары булган. Бу беркатлы купшы йорт-утарны Төркиянең күренекле җәмәгать эшлеклесе һәм галиме Гадилә Айда атасына багышланган «Садри Максуди-Арсал» китабында бик тәфсилле тасвирлый. Шакир Рәмиев кызы Камиләне Садри Максуди шушы йортка килеп ярәшә. Берничә бүлмәле, ике манаралы бу йортта 1918 елның җәендә Шакир Рәмиев гаиләсе дә яшәгән булырга тиеш. 1912 елда Шакир вафат булгач, аның өлешенә караган приисклар белән өлкән улы Сөләйман идарә итә. Германиядә Тау казылма байлыклары академиясен 1914 елда тәмамлап кайткан Искәндәр белән алар барлык хуҗалык эшләрен бергә-бергә башкара торган булалар. Әмма Әсма Рәхмәтул-

лина истәлекләрендә Шакир нәселе нишләптер телгә алынмый. Бәлки, алар ул җәйне башка бер прииск утарында уздырганнардыр.

Тарихтан мәгълүм булганча, 1918 елның җәендә әле Балкан авылы тирәләренә большевиклар килеп җитмәгән була. (Балкан хәзерге Магнитогорск шәһәреннән алтмыш чакрымнар көнчыгыштарак урнашкан.)

Балкан һәм Требия (Мәҗит Гафури повестенда — «Восьмой авыл») тирәсе приисклары егерменче йөз башында иң бай алтын чыганаклары саналган. Бу приискларга 1895 елда нигез салына. Мәҗит Гафуриның «Шагыйрьнең алтын приискасында» дип исемләнгән повестенда бәян ителгән «ат башы хәтле алтын» да шушы авыллар янәшәсеннән табыла. Дөресрәге, Шакир улы Әхмәт Рәмиев исемен йөртүче шахтаны ачкан вакытта казып чыгарыла.

* * *

Әсма Рәхмәтуллина җизнәсе белән Искәндәр абыйсының бу җәйдә ни-нәрсәләр эшләвен тәгаен белми, әлбәттә. Аңа әле унөч кенә яшь була. Шулай да ата-ананың шушы төбәктә сугышып йөргән уллары Морад белән Җәгъфәрдән хәбәр алгалап торуын сиздерә. Дөрес, вакытыннан алда ул Җәгъфәрне кызыллар ягында сугыша дип тә яза. Дөреслектә Муса Мортазин полкы әле тагын бер ел чамасы үткәч, 1919 елның март ахырларында гына большевиклар ягына чыгачак. Зәки Вәлиди «үз Башкорт автономиясе һәм армиясе» белән кызыллар тарафына күчкәч. Соңрак Җәгъфәр дивизия статусын алган бу полк белән полякларга каршы сугышта да катнашачак. 1920 елның көзендә, Киев шәһәре янәшәсендә барган бер бәрелештә каты яраланып, сыңар кул белән ата-ана йортына әйләнеп кайтачак.

1918 елның җәй ахырларында исә ата-анага Морадның каты авырып китүе, госпитальдә ятуы турында хәбәр килә. Шул хакта Әсма апа түбәндәгеләрне яза: «Без Орскига өйгә кайтырга җыйналдык. Шул көн бик хәсрәтле көн булды. Морад абыйның ерак түгел больницада тиф белән авырып ятуы турында элегрәк хәбәр килгән иде. Аның хәлен белергә аш-сулар белән кемнедер җибәрделәр дә. Ул кеше без китәсе көнне әйләнеп кайтты. Морад абый тифтан үлгән. Бик-бик рәнҗеп үлгән икән... Морад абыйның үлем хәсрәте безнең йөрәкләрне тетрәтте... Бу хәбәрне ишеткәч, җизни дә, туганым абыстай да бер күз яше күрсәтмәделәр. Бик кайгылы төс белән, алларына гына карап, иртәнге чәйне эчтеләр... Морад абый арада туган җанлы иде, балаларны бик ярата, безнең белән уйный иде. (Морад, мөгаен, Балканнан илле-алтмыш чакрымдагы Верхнеуральск госпиталендә яисә бераз ерактарак урнашкан

Троицк шәһәрендә үлеп калгандыр. Ул җәйдә атаман Дутовның аерым полклары шул тирәләрдә яу торкан.) Без Орскига кайтып озак тормадык, җизниләр дә бөтен семьялары белән безгә килеп төштеләр. Аннары Борнаевларга күчтеләр... Орскига кызыллар керә башлады...» (1918 елның җәй айларында Орск кызыллар кулында, камалышта була. Шәһәрдәге төп хәрби көчләр: 28 нче Урал укчы полкы, Б.Нуриманов, Ш.Гимадетдинов, С.Җантуаров кебекләр оештырган отрядлар. Шул елның 28 сентябрендә алар Актүбә тарафына таба чигенәләр. Дутовчылар, Уралны кичеп, шәһәрне алалар. Кызыл Армиянең 1 февральдә оештырган һөҗүме уңышсыз тәмамлана. Әйе, 1919 елда кызыллар Орскины яулап алырга өч мәртәбә талпыналар. Андый вакытларда Дәрдемәнднең гаиләсе шәһәрдән киткәләп тә тора. Мәсәлән, Орскидан кырык чакрымнардагы Җүнәй авылында Дәрдемәнднең яшәп китүе Мирхәйдәр Фәйзи көндәлегендә дә теркәлгән. Шәһәр өчен барган соңгы атышлар 1919 елның 29 август төненә туры килә.) Байтак гомер үткәч язылган Әсма Рәхмәтуллина истәлегендә кайбер вакыйгалар аша сикереп үтүләр дә сизелә. Әсма апа Орскиның кызыллар тарафыннан алыну вакыйгаларын да берләштергән булса кирәк. 1918 елның көзеннән ул киләсе елның август көннәренә күчә дә: «Оренбурдан (качып) килгән байлар һәм Орск байлары чыр-чу килеп качарга тотынгач, Искәндәр абый әйтә: «Кызылларның юллары дөрес, беркая да качмыйбыз, Орскида калабыз, ди», — дип әйткән сүзләрне яза. Рәмиев байларның ул вакытта Себергә дә, чит илгә дә китәргә теләкләре булмавын бәян итә. Хәер, ул көннәрдә Рәмиевләрнең төрле тарафка таралышкан гаиләсен тиз генә бергә туплап, илдән чыгып китүе мөмкин дә булмагандыр. Закир белән Мәхүбҗамалның сигез баласы гына да сигез тарафта ич ул вакытта: Өммегөлсем белән Зәйнәп Оренбургта, Рауза Чиләбе якларында, Гариф белән Җәгъфәр көнбатыш тарафта, билгесезлектә. Аларны ничек ташлап китәсең? Шакир агаларының дүрт хатыннан туган ишле бала-чагасының язмышы да шундый ук хәлдә... «Илдә чыпчык үлмәс... Язмыштан узмыш юк лабаса...»

## Яңа кешеләр. Яңа тормыш

1918 елгы хафалы вакыйгалардан соң Дәрдемәнд гаиләсенең тормыш-яшәешенә өстәмә ачыклык кертүче мәгълүмат бик аз. Шагыйрьнең 1919 елның җәендә каты сугышлар барган Балкан приисклары төбәгенә сәяхәт кылган булуы икеле. Шул ук вакытта аның Балкан, Шәйханнардан ике йөз чакрым чамасы көнбатыштарак урнашкан Юлык авылы төбәге алтын чыганакларында булу ихтималы зур. Чөнки монда да Рәмиев байларның егермеләп

шахтасы урнашкан була. Аларны Совет хакимияте вәкилләренә кемдер тапшырырга тиешле бит инде. Ул вазифаны Сөләйман белән Искәндәр генә башкарып чыкканмы яки анда Закир бай үзе дә катнашырга тиеш булгандырмы — болары әлегә ачыкланмаган. Шунысы хак: 1919 елның март башларында Юлык, Солтан шахта идарәләре урнашкан төбәктә Совет хакимияте дилбегәне үз кулына ала. Ул төбәк приискларыннан чыккан алтын Кызыл Армияне корал, кием һәм ризык белән тәэмин итү хаҗәтенә тотыла башлый.

Шәһәрне кызыллар алганнан соң күпмедер вакыт үткәч, Искәндәр Рәмиевнең үз белгечлеге буенча Совет оешмаларында эшли башлаганлыгы мәгълүм. 1925 елның ахырларында аны «Башкирзолото» трестына эшкә билгелиләр. Баймакта урнашкан бакыр һәм алтын кыю заводына ул баш «технорук», ягъни, бүгенгечә итеп әйтсәк, баш инженер итеп җибәрелә. Киләсе елның февраль башында гаиләсен һәм әнисен дә шунда алып китә. Орскидан ике олауга төялеп чыгып китәләр.

* * *

1919 елның ахырларында Орск төбәгендә яшәүче татар, башкорт һәм аз сандагы казакълар арасында эшләү өчен комиссар итеп Габдулла Дәүләтшин билгеләнә. Ул — тумышы белән Орскидан өч чакрымда урнашкан «казачий Ильяс утары» кешесе, Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыган һәм түнтәрелеш башланыр алдыннан ел ярым чамасы шунда укыткан бер хәлфә, татар-башкорт атлы казакларыннан большевиклар ягында торып сугышучы «кызыл атлы полк» оештыручыларның берсе. Большевикларга каршы көрәшкән Зәки Вәлиди хөкүмәтен дә 1918 елның гыйнвар ахырларында нәкъ шушы полк вәкилләре Оренбургта кулга ала. Ике-өч ай гына яшәп алган «мөстәкыйль Башкорт мохтарияте» урынына Габдулла Дәүләтшин җитәкчелегендә Совет Башкортстаны автономиясе оештырыла. Ләкин ул автономия дә өч ай гына яшәп кала. Дутовчылар ярдәмендә Оренбург төрмәсеннән качкан Зәки Вәлиди һәм аның җәптәшләре хакимиятне үз кулларына алып, мохтарият башкаласын аклар карамагындагы төбәккә күчереп куялар.

«Хөсәения» мәдрәсәсенең абруйлы тышкы идарәчеләреннән берсе булган Закир Рәмиев-Дәрдемәнд Габдулла хәлфәне танып белгәндерме, әйтүе читен. Ә Орск вакыйгалары аларны якыннан аралаштыра. Г.Дәүләтшин Орскига килеп төпләнгәч тә татар телендә «Ирек йолдызы» газетасын чыгара башлый. Атналык бу газетаның беренче битендә Хөкүмәт карарлары, икенче битендә сәяси темага багышланган чыгышлар урнаштырыла. Дүртенче

бите әдәбият-мәдәнияткә бирелә. (Орск шәһәре музеенда ул газетаның 1921 елның июлендә басылган бер саны саклана. Шул санның әдәбиятка багышлы битендә, мәсәлән, Төхфәт Ченәкәйнең бер шигыре һәм мәзәкләр урын алган.) Дәүләтшинның комиссариаты да, газета редакциясе дә элекке «Шәрекъ йорты» бинасында урнаша. 1920–1921 елларда Дәрдемәнд бу йортка килгәләп йөри. Үзәк матбугат хәбәрләре белән танышу, дөнья хәлләрен сорашып белү өчен килгәндер инде.

Габдулла Дәүләтшинның хатыны, драматург Мирхәйдәр Фәйзинең сеңлесе Хәлимә апа ул елларны болайрак искә ала: «Габдулланың эш урыны татарларның элек-электән мәдәният үзәге саналган йортта иде. Шунда ук яшьләр гөж килә, бандаларга каршы көрәшүче кызылармеецлар да килеп-китеп йөри. Шул ук йортта мөселманнар өчен лекцияләр укыла, концертлар да куела. Мәскәүдән яисә Оренбургтан килгән газеталар да шунда була. «Ирек йолдызы»н да шунда ук туплыйбыз. Мин дә шунда Габдуллага булышып йөрим. 1920 елның җәеннән ул йортка шагыйрь Дәрдемәнд тә килгәли башлады. Дөнья хәлен беләсе килеп йөргәндер инде. Еш кына алар Габдулла белән сөйләшеп китәләр иде. Күп вакытта мин, аларга комачауламас өчен, бүлмәдән чыгып тора идем».

Хәлимә Дәүләтшина белән мондый сөйләшүләр, ул чор вакыйгаларын искә алулар 1971–1972 елларда Мәскәү каласында булды. Шагыйрь белән очрашулардан соң илле еллап вакыт үткән, олы кешенең хәтере тоныклана төшкән иде. Сөйләм арасында Хәлимә апа Дәрдемәндкә катнашы булмаган, ләкин үз гаиләсенә, туганнарына кагылган истәлекләргә кереп киткәли. Әледән-әле мин аны үземне кызыксындырган мәсьәләләргә юнәлтергә тырышкалыйм.

— Дәрдемәнднең берәр шигыре «Ирек йолдызы»нда басылмадымы икән? — дип сорыйм бүлдереп.

Хәлимә апа:

— Хәтерләмим, аңа күп вакыт үтте ич инде, — дип җавап бирә. — Казакъ автономиясе башкаласы соңыннан Кызыл Урдага күчерелде. Ул чорда чыккан газеталар, документлар барысы да хәзер Казакъстандадыр, мөгаен.

Әйе, шулай булуы бик ихтимал. Оренбург 1920–1925 елларда Кыргыз-кайсак (казакъ) Совет автономиясенең башкаласы булып торган бит. Ул дәвердә бу төбәктә элекке зыялыларга яки башка төрле фикер йөртүчеләргә карата катгый чаралар да күрелмәгән диярлек. «Хөсәения» мәдрәсәсе хәлфәләре шул ук бинада, шул ук шәкертләрен укытуларын дәвам иттергәннәр. Фәкать мәдрәсә урынына ул уку йортының исеме генә Халык мәгарифе институты дип үзгәртелгән була. Закир, Шакир Рәмиевләрнең гаилә әгъза-

лары да 1926 елга чаклы үз йорт-утарларында яшиләр. (Оренбург шәһәренең үзәк өлешендә икесенең дә кирпечтән салынган затлы өйләре исән. Фәкать ишегалды каралты-куралары һәм Шакир өе артындагы бакча гына юк ителгән.) Кабат губерна идарәсе урнаштырылгач кына аларны эзәрлекләүләр башлана. Закир Рәмиев балалары да төрле якка таралырга мәҗбүр ителә. Яшәгән йортлары тартып алына. Кызы Зәйнәп белән кияве Ярулла Вәли Уфага китеп, Ризаэтдин Фәхретдинев канаты астына барып сыеналар. Рауза Искәндәр абыйсы белән җиңгәсе яшәгән Баймакка китә. Бәшир ага әйтүенчә, озакламыйча ул шунда гүр иясе була...

1921 елның август ахырларында Дәүләтшиннар гаиләсе Орск белән саубуллаша. Аларның икесен дә Мәскәүгә, Коммунистик университетның шәрекъ халыклары бүлегенә укырга җибәрәләр.

— Анда да кызыклы кешеләр күп иде. Шагыйрь Ярлы Кәрим дә безнең белән укыды. Балабыз елаганда, скрипкада уйнап, ул аны тынычландыра торган иде, — дип сөйләде Хәлимә апа.

1920 елның башында Закир Рәмиев гаиләсе Мәхүбҗамалның әнисе Хөснәнең бертуганы Закир Хәкимовлар йортына күченә. Мөгаен, Мәхмүтҗан Борнаев гаиләсе яшәгән ике катлы сәүдә йортын Совет хакимияте үзенә алган булгандыр. Ә шул ук елның җәй ахырларында шагыйрь гаиләсе өченче йортка күченеп яши башлый. Туган тиешле булса да, кеше өстендә яшәү ялыктыргандыр, күрәсең. Ә монда үзләренә бер өй, иркен ишегалды. Бу йортның хуҗасы Билал Мусин бер авылда кибет ача һәм гаиләсе белән шунда китеп бара. (1960–1970 елларда аның улы Рөстәмнең Казанда яшәгәнлеген дә хәбәр иткәннәр иде.) Бушаган өйләрен Рәмиевләргә биреп калдыралар. Бер катлы зур гына агач өй әле дә үз урынында — Поль Лафарг тыкрыгында биш тәрәзәсен урамга балкытып утыра. Белгән кешеләр, аның фәкать такта түбәсе искерде дип, шиферга төренгән өй кыегына күрсәтәләр. Бу өйдән бер йорт аша Уралсу буе «әрәмәлеге» — йөзьяшәр тирәкләр урманчыгы башланып китә. Шагыйрь гаиләсенә ат карарга ялланган Сабир Галиәкбәрев тә шушы өй янәшәсендә генә яшәгән — күрше урам кешесе булган. Сабирлар Рәмиевләрнең ишегалдына уртак койма капкасыннан гына кереп-чыгып йөргәннәр. Утын яру, кар көрәү кебек йорт эшләрен дә Сабир башкарган. Алтмышынчы-җитмешенче елларда әле Сабирның хатыны, кызы исән иде. Ул кыз, инде миңа апа тиешле олы хатын, кергән саен конфет, прәннек ишеләрне тоттырып чыгаручы «бай абыстай»ны бик җылы итеп искә алды. «Бай абзый»ны гына ул хатын хәтерләми диярлек, мин аны бик сирәк күрә идем, диде. Аңа шунысы сәер тоелган: җәмиг мәчете ике-өч тыкрык аша гына булса да, «бай абзый» анда һәрчак ат җиктереп барган. Үзе ише байлардан калышасы килмәгәндер, күрәсең.

Шагыйрьне соңгы елларда күрүчеләрдән Орскида Мәрьям Шәриф кызы Бикбова да исән иде әле. (Ул 1906 елда туган, 1994 елда вафат була.) Җитмешенче елларда без аның белән берничә мәртәбә очрашып сөйләштек. Аңарда гасыр башы кешеләренә караган калын фотоальбом да саклана иде. Мәдрәсә тотучы мулла Әхмәтҗан белән аның хатыны, яшь Маһруй абыстайның фотосы да ул альбомда бар иде. Мәрьям апа ике кыш «Маһруй абыстай мәктәбе»ндә укый. Аннары аны шәһәр гимназиясенә бирәләр. Ул да Хәлимә Фәйзуллина укыган гимназиядә белем ала. Мәрьям Бикбованың ата-анасы да сәүдәгәрләр токымыннан. «Ата-бабаларым, Мортазиннар, тире-яры белән эш иткән. Үзем балалар да тәрбияләдем, башка эшләр дә башкардым. Дәрдемәнднең оныч-касы Рабига белән бергә уйнаган чакларым да булды. Муса Җәлил белән дә таныш идем. Сәхнәдә мин җырлаганда, ул мандолинада уйнар иде».

— Дәрдемәндне ничегрәк хәтерлисез? Аны еш күрә идегезме? — дим.

— Урамда йөргәндә еш күрә идем. Бик ыспай киенеп йөрер иде. Тарантаста барганда да бик төз утыра, як-якка бер дә каранмас иде...

Шагыйрь вафат булгач, алар, гимназиядә укучы берничә кыз, аның белән саубуллашырга дип өенә дә баралар. Дәрдемәнд җеназасын Урал күперен чыкканчы озатып калалар.

## Соңгы көннәр

Орскида Совет хакимияте бөтенләйгә урнашкач, тормыш җайга салына башлаган кебек була. Ләкин ул тәртип ныгып өлгерми, элекке губерна күләмендә ачлык афәте башланып китә. Ваба, тиф авырулары көчәя. Бу афәтләр шагыйрь гаиләсен дә читләтеп узмый.

Әсма апа истәлегеннән: «Көз көне иде. Шәрифзадә җиңги карбызлар, кәбестәләр тозлап йөрде. Шулчак каты авырып китә, баласын тапканда тифтан үлә. Бәшир ятим кала. Бәширнең җылауларын күреп, туганым абыстайның күзеннән дә мөлдерәп аккан күз яшьләре онытырлык булмады». (Соңгы очрашу вакытында Бәшир ага да анасының икенче баласын тапканда, 1920 елның көзендә вафат булуын әйткән иде.) Истәлек язмасын дәвам итик. «Алар Закир абый Хәкимовлар йортына күчтеләр... Җизни еш кына яхшы чәйләрен күтәреп безгә кунакка килә. «Маһруй, ал, сездә үлән чәй генә», — ди. Без карбыз кабыкларын турап киптереп, чәй итеп эчә идек. Менә Орскида тиф, ваба авырулары башлана. Кайнамаган су эчмибез. Әниебез сарымсактан бөтиләр ясап, барыбызга да кидерә. Тик авыру безне дә читләтеп үтмәде. Ара-

быздан иң матуры, пианинода бик оста уйнаучы Сара апам унсигез яшендә үлеп китте. Аны күмәргә җизни әниемә акча бирде, өч куй (сарык) китертте. Үлем хәсрәтеннән айный алмый торганда (шул көздә), тагын зур хәсрәт килде. Җизни олы кызы Гөлсемнең хәлен белергә, азыклар илтергә дип Оренбургка бара. Аннан кайткан вакытта, поездлар ягылмаган булганга, җизни бик өшеп кайта, терелә алмыйча үлеп китә. Врач, аның йөрәге бик начар, дигән. Орскины ап-ак кар баскан иртә иде. Өйдәгеләр миңа: «Әниең туганым абыстайларга китте, җизни үлгән дип хәбәр иттеләр», — диде. Мин дә чаптым шунда».

* * *

1921 елның октябрендә Закир Рәмиев-Дәрдемәндне нәкъ әнә шул гади, биш тәрәзәсе урамга карап торган бүрәнә өйдән соңгы юлга озаталар. Монда аның соңгы кигән киемнәре, соңгы кулъязмалары кала. Искәндәр улы Бәшир Рәмиев сөйләвенчә, Мәхүбә абыстай бу йортта берникадәр вакыт «самавыр куючы кыз» Миңсафа белән икәү генә яшәп тора. Аннары Искәндәр дә өч яшьлек улы белән әнисе янына күченә. Ләкин 1922 елның апрель урталарында алар яшәгән йортны су баса. Иң кадерле әйберләрен генә алып, кабат Мәхүбҗамалның туганнары йортына күченәләр.

Орск шәһәренең үр башындагы өлешеннән астарак булган барлык йорт-урамнарны һәр егерме-егерме дүрт ел саен язгы ташу басып китүчән. Уралсу да, Ор елгасы да берьюлы кузгалган язларда ике елга бозы шәһәрне көньяк тарафтан каплап торган Гөберлә тау тезмәсе тарлавыгына килеп тыгыла, су кинәт ярларны бәреп чыга, бер төн эчендә урамнарны басып ала торган була. Мондый хәлләр элекке гасырларда да кабатланып торган. 1942 һәм 1957 елларда һәм аннан соң да кабатланды. Нәкъ менә Уралның шундый холкына бәйле рәвештә, Орск шәһәренең хәллерәк кешеләрен елганың аръягындагы калкулыкта урнашкан Ильяс авылы зиратына илтеп җирләгәннәр. Замана авыр булуга карамастан, Дәрдемәндне дә Уралсудан өч чакрымдагы шул татар атлы казаклары авылына илтеп җирлиләр. Кабере өстенә истәлек ташы да куелган була. Алтмышынчы-җитмешенче елларда мәетне шул авылга чаклы озата баручылар да, сугыштан соңгы чорда анда кабер ташын күрүчеләр дә әле исән иде. Мирхәйдәр Фәйзи оештырган спектакльләрдә катнашкан Мәгъсүм ага Шәмсетдинев ул каберлекне күрсәтеп тә йөрде. Ләкин ул вакытта инде элекке «Ильяс утары» Яңа шәһәр читендәрәк калган, каберстан җире бер хәрби завод биләмәсенә кергән иде. Ул завод биләмәсе исә биек таш койма белән коршаулап алынган иде. Әйе, 1930 елларда башланган Яңа шәһәр төзелеше «зыялылар каберлеге»н дә үз эченә ала.

1941 елның көзендә көнбатыштан күчерелгән хәрби заводка шул каберлек биләмәсе бүлеп бирелә. Кабер ташлары төзелеш кирәк-ярагына тотыла. Дәрдемәнд кабере өстенә куелган истәлек ташы да, мөгаен, нindidер бер яңа бина нигезендә ята булыр.

Дәрдемәнднең үлеме көтелмәгәнчә фаҗигале бер үлем була. Олы кызлары Өммегөлсемнең кинәт авырып китүе турында хәбәр алгач та, ул Оренбургка барырга дип юлга чыга. Бу вакытта Оренбург губернасының көнбатыш өлешендә ачлыктан үлүчеләр саны көннән-көн арта бара. Бәшир Рәмиев әйтүенчә, бабасы Оренбургка барганда Сара станциясеннән товар поездына утырып китә. Ул вакытта әле Оренбург—Орск тимер юлы шул Сара станциясенә генә килеп җиткән була. Ә Орскидан Сарага чаклы атта сиксән чакрым барасы. Атасы Оренбургка барып җиткәндә, Өммегөлсем авыр хәлдә була. Дәрдемәнд аның белән соңгы саубуллашу өлешенә генә өлгерә. (Дөрес, Әсма Рәхмәтуллина истәлек язмасында аны, соңрак вафат булды, дип яза. Ә Өммегөлсем кызы Кафия исә анасының шул көздә үлгәнлеген әйткән иде.) Өммегөлсемнең ике кече кызын үзе белән Орскига алып китә. Иң олысы — Рабига — ул вакытта инде Ташкентта кияүдә була. Соңрак, атасы Гариф Камалов та үлгәч, аның янына Суфия да китә.

Оренбургтан кайтканда Дәрдемәнд пассажир поезды белән Актүбә шәһәренә килә, аннан ат яллап кайталар. Алар кайтканда көн бик җилле, бик суык була. Дәрдемәнд юл өстендә үк үзен начар сизә башлый. Орскига кайтып берничә көн авырып ятканнан соң вафат була. Оныклары аны тифтан үлгән дип беләләр. Саклык белән генә җирләргә кушкан булалар. Өммегөлсемнең Галия һәм Кафия исемле кызлары Мәхүбҗамал әбиләре белән Искәндәр агалары карамагында буй җитәләр. «Искәндәр абый юк вакытта Миңсафа җиңги мине яшем җитмәстән элгәре кияүгә бирде», — дип зарланган иде Кафия апа 1993 елның декабрендә сөйләшкәндә. Аңа чаклы инде Галия, җиңгәсе белән сүзгә килеп, Урта Азия якларына чыгып киткән була. 1948 елгы җир тетрәү вакытында үзе дә, улы Рөстәм дә Ашхабадта һәлак булалар.

Шагыйрьнең фаҗигале язмышы турында соңгы елларда төрле уйдырма сүзләр дә язгаладылар. Бер ветеран укытучы, аны кайсыдыр бер авылның ташландык өендә ялгыз үлеп калган икән, дип тә язган иде. Икенче берәүләр исә ачлыктан үлгән икән дигән хәбәрләр дә тараттылар. Онык һәм онычкалары белән аралашкан кеше буларак, бу хәбәрләрнең дөрес түгеллеген кабатлап әйтергә мәҗбүрмен. Хәер, шагыйрьнең Уфада яшәгән кызы Зәйнәп белән очрашып сөйләшкән, Башкортстан белән Чиләбе өлкәләре чигендәге бер колхозда хисапчы вазифасын үтәгән улы Җәгъфәр (икесе дә җитмешенче елларда гүр иясе булдылар) белән хатлар алышкан Мөхәммәт ага Гайнуллин Дәрдемәнднең тифтан вафат бул-

ганлыгын 1959 елда ук бер мәртәбә язып чыккан иде инде. Шагыйрь үлем түшәгендә ятканда, аның тирәсендә сөйгән хатыны Мәхүбҗамал, аның сеңлесе Маһруй, өлкән улы Искәндәр, аның булачак хатыны Миңсафа (әлеге самавырчы кыз), уртанчы улы Җәгъфәр, Мәхүбҗамалның бертуганнары гаиләләре белән шунда булалар. Димәк, бер шагыйрьне карарлык һәм туйдырырлык кына мөмкинлекләре булган. Әсма апа да бит истәлегендә: «Җизни Гөлсемгә ризык илтә китте», — дип яза. Өйдәге соңгы ризыкны алып китүе булмагандыр, шәт. Бу чорда Рәмиевләрдә потлы алтын кантарлары сакланмаган очракта да, кулда йөртерлек алтын-көмешләренең җитәрлек дәрәҗәдә булуына дәлилләр дә байтак. Әле утызынчы елларда гына да Рәмиевләр нәселенә караган барлык хатын-кызлар алтын-көмеш тәңкәләр белән тулышкан зур-зур күкрәкчәләр йөрткәннәр. Ул заманда андый тәңкәләрне атна саен берәмтекләп дәүләт оешмаларына тапшыра барсаң да, җитәрлек күләмдә ризык табу мөмкинлеге булгандыр, шәт. Сугышка чаклы диярлек алтын бөртекләре, алтын, көмеш тәңкәләр исәбенә азык-төлек биреп торучы, Торгсин дип аталучы махсус оешма яшәп килгәнлеген бүген күпләребез белми, әлбәттә... Ул елларда Орск, Оренбург шәһәрләре тормышына бәйле хәбәрләрне даими биреп килүче, Эстәрлетамак каласында нәшер ителүче «Башкортстан хәбәрләре» газетасы да 1921 елның 30 ноябрендә чыккан санында шагыйрь Дәрдемәнднең Орск шәһәрендә тифтан вафат булуын хәбәр итә.

* * *

Соңгы сүземне шагыйрь белән чирек гасырдан артык вакыт бергә яшәп, якыннан аралашкан бер зыялыга биреп төгәллисем килә. Үзе дә әдәбият күгендә якты эз калдырган, мәдәниятебез мәйданында беренче рәшә, беренче елдырымнардан булган күренекле әдип Фатих Кәрими шагыйрь турында түбәндәге сүзләрне яза: «Дәрдемәнднең кешелек ягы бик югары булып, ул гади татар байларына бер дә охшамый иде. Ул алдау, хәйлә, риялану, икейөзлелек шикелле нәрсәләргә дошман иде. Аның үзендә андый сыйфатлар юк. Һәрнәрсәне туры әйтергә ярата. Сүзендә, мөгамәләсендә соң дәрәҗәдә туры. Аның әйткән сүз, биргән вәгъдәсе документлардан, вексельләрдән нык иде». Ф.Кәрими бу сүзләрне 1927 елда, байларны төрлечә хурлау гадәте яшәгән көннәрдә язган.

Димәк, кешелек сыйфатлары белән Закир Рәмиев-Дәрдемәнд барыбызга да үрнәк булырлык. Шул сыйфатлары һәм халкы өчен кылган изге гамәлләре белән ул һәрвакыт милләтебезнең күңел түрендә булырга хаклы.

Әйе, Дәрдемәнд-Рәмиев шәхес буларак билгеле бер чорда калыпланган, шул дәвердә ул бай сәнәгатьче дә, киң колачлы җәмәгать

эшлеклесе дә, үзенчәлекле бер шагыйрь дә булган. Аны үз чорыннан, үз иш-фикердәшләре арасыннан һич кенә дә аерырга ярамый сыман. Шул ук вакытта ул чордашларыннан бик күпкә аерылып та тора. Шигырьләрендә урын алган уй-фикерләре белән ул безгә дә, бездән соң килүчеләргә дә якын һәм бик кирәкле шәхес. Аның мирасы безнең милләт җирлегендә мәңгелек. Без аны хәзер кылган күркәм эшләренә, олы мирасына карап бәялибез. Ихтирам итәбез. Офыгыбыз күгендә ул һаман-һаман да балкып торыр!

*«Идел», 2007, № 11*

## ЕСЕНИН ТУКАЙНЫ КАЯН БЕЛГӘН?

Галимнәребез бәян итүенчә, узган гасыр башында җирле рус зыялылары арасында татар әдәбияты белән кызыксыну арта. Казанда керәшен мәктәбендә татар теле дәресләрен укыткан Николай Ашмарин 1901 елда «Очерки литературной деятельности татар-мухамедан в 1880–1895гг.» дигән китабын бастырып чыгара. (1913 елда Рәмиевләрнең Оренбургтагы «Вакыт» басмаханәсендә ул хезмәт татар телендә дә нәшер ителә.) 1908 елда «Волжско-Камская речь» газетасының ике санында Сәгыйть Рәмиевнең русчага тәрҗемәдә берничә шигыре дөнья күрә һәм хуплап кабул ителә. Бу газетада шулай ук Габдулла Тукай иҗаты белән рус җәмәгатьчелеген таныштыру талпынышы да булып ала. Ә 1914 елда шул ук Н.Ашмарин аның «Шүрәле» поэмасын башкалада чыгучы бер журналга тәкъдим итә. 1914 елда шагыйрьнең «Пар ат» шигыре Лондонда нәшер ителүче «Рашен ревью» журналында инглизчә дә басыла.

Бөек шагыйребезнең рус телендә беренче юкарак китабы 1920 елда Ташкентта нәшер ителә (Габдулла Тукаев. «Избранные стихи». Ул китапка кагылышлы мәкаләм 1986 елда «Азат хатын» журналында басылган иде). Аны туплап чыгаручы һәм күләмле кереш сүз авторы Ибнеәмин Янбаев була. Касыйм шәһәрендә туган, 1917 елгы түнтәреш алдыннан гына Мәскәү коммерция институтын тәмамлаган кеше. Октябрь революциясе кузгаткан дулкын белән ул Урта Азиягә барып чыккандыр, мөгаен. 1919 елдан башлап аның Ташкентта университет каршындагы рабфакта укытуы мәгълүм. Шул ук вакытта И.Янбаев Төркестан Автономияле Совет Республикасының билгеле бер түрәсе — әлеге китапны бастыруга әзерләгәндә Мәгариф комиссариатының коллегия әгъзасы була. Китапчыкның «Биографик очерк» өлешендә И.Янбаев әдәбият сөючеләрне шагыйрьнең биографиясе һәм иҗаты белән бик тәфсилләп таныштыра. Г.Тукай шигырьләренең ни өчен үз халкы тарафыннан яратып кабул ителүен аңлатырга омтыла.

Шагыйрь иҗатын югары бәяли; шигырьләренең гади, халыкчан телдә язылуын, эчтәлекләре белән гомумхалык күңеленә якын булуын билгеләп үтә. «Тукай гади халыкта шигърияткә мәхәббәт уятып кына калмады, шигъриятнең үзен дә бер баскыч югары күтәрде», — дип яза И.Янбаев. Бу «Биографик очерк», мөгаен, Г.Тукай иҗатына карата рус телендә язылган иң беренче төпле анализ, төпле фикер әйтү булгандыр. Тик шунысы үкенечле: ул сүзләр Тукаебыз яшәгән төбәктән бик еракта бәян ителгән, Тукайның үз мохите даирәсеннән читтәрәк әйтелгән булган. Шул сәбәпле андый китапның нәшер ителүен Тукайның иҗатын якын иткән гади укучы гына түгел, ул иҗатны барлаучы күпчелек галимнәребез дә белми иде. Башкаласы Ташкентта урнашкан Төркестан Совет Республикасына ул чорда хәзерге Үзбәкстанның бер өлкәсе һәм Казакъстанның көньяк өлкәләре кергән. Димәк ки, ул китапның таралу даирәсе дә зур булган.

Русча «Сайланма әсәрләр» исеме белән чыккан ул нәни китапчыкка шагыйрьнең алты шигыре кергән. Аларның барысын да рус теленә шагыйрь Валентин Вольпин тәрҗемә итә. Вольпинның иҗади биографиясен ачыклап бетерә алмадым. Ул 1894 елда туган. Ташкентта яшәгән дәвердә аның «Обманный путь» (1917), «Ярмо и воля» (1920) исемендә үз шигырь җыентыклары басыла. 1919 елда ул революция темасына багышлы шигырьләр тупламасын — «Антология революционной поэзии» китабын барлап нәшер итә. Аның Сергей Есенин даирәсенә якын торганлыгы да мәгълүм. 1921 елның җәендә бу олуг рус шагыйре Ташкентка килә, Валентин Вольпинның хәзер Хәдичә Сөләйманова исемен йөрткән урамдагы фатирында яши. Мөгаен, шул вакытта С.Есенин татар шагыйренең иҗаты һәм аянычлы язмышы хакында В.Вольпин белән И.Янбаевлардан күп нәрсәләр ишетеп белгән булгандыр. Соңыннан аның Тукайны зурлап искә алуының тарихы шушы русча китапчыктан башланадыр.

Ике тугандаш халык арасындагы әдәби-мәдәни багланышларны тикшерүче үзбәк галиме Шерали Турдыев миңа ул китапчыкның ксерокопиясен дә җибәргән иде. Хәзерге заман техникасына һәм затлы кәгазьгә кытлык чорында эшләп җибәрелгән ул күчермәнең сыйфаты бик үк яхшы булмаса да, Г.Тукай музее ачылганда аны миннән Дания ханым Баһаветдинова сорап алган иде. Музейның беренче директоры Госман Хәбибуллин ул күчермәне шагыйрьнең тәрҗемә китаплары күргәзмәсенә куярга ниятләвен дә әйткән иде. Туксанынчы елларда мин Милли музейга шундый күргәзмәләргә кую өчен дип тагын берничә китап тапшырдым. Алар арасында Г.Тукайның казакъча, М.Җәлилнең үзбәкчә басылган җыентыклары да бар иде. Ләкин нишләптер безнең музейларда олуг шагыйрь һәм әдипләребезнең башка бик күп телләрдә

басылган китапларын даими рәвештә күргәзмәдә тоту тәртибе кертелмәгән шикелле. Шул сәбәпле Г.Тукайның рус телендә 1921 елда Казанда нәшер ителгән «Разбитая надежда» («Өзелгән өмид») китабын күреп белүчеләр дә бик сирәктер, мөгаен. (Аны Казанда яшәгән рәссам һәм шагыйрь Павел Радимов тәрҗемә итеп чыгарган.)

Шушы уңайдан чит төбәкләрдә, чит телләрдә басылган татар язучылары китапларын барлауга кагылышлы борчылуларымны да әйтеп китәсем килә. Совет хакимияте урнаштырган катгый тәртип яшәгән елларда да аларны барлау тиешле дәрәҗәгә җитешә алмады. Әйтик, Китап палатасы туплаган мәгълүматлар җирлегендә дөнья күргән еллык исемлекләрдә дә ара-тирә җитешсезлекләр очраштыргалый иде. Хәзер исә республикабызда эшләүче бихисап нәшриятларның ни-нәрсәләр чыгаруын исәпкә алу да кыенлашты кебек. Ә чит-ят телдә кемнең нәрсә чыгаруын бөтенләй дә белеп булмый башлады. Совет хакимияте дәверендә, мәсәлән, Казакъстанда һәм Үзбәкстанда һәр биш-ун ел саен Г.Тукай, М.Җәлил китаплары даими рәвештә нәшер ителде. Г.Ибраһимов әсәрләре дә алтмышынчы-сиксәненче еллар аралыгында күп тапкырлар басылды. Үзбәкстанда татар әдәбиятын кардәш үзбәк телендә чыгаруда шул республикада иҗат итүче милләттәшләребез Әсгать Мохтар, Габдулла Уразаев актив эшләделәр. Казакъстанда Жакан Сыздыков, Жобан Молдагалиев, милләттәшебез Барый Мәҗитов, Г.Тукай, М.Җәлил, Г.Ибраһимов, Г.Бәширов әсәрләрен үз итеп, яратып тәрҗемә иттеләр. Союздаш республикаларда ике әдәбият арасында арадашлык өлкәсендә мактаулы эш башкаручыларга карата хуплау чаралары күрелсә, бездә еш кына иң бөек дип танылган язучыларыбызның әсәрләрен чит республикада актив пропагандалаучыларга карата рәхмәт сүзләре юллау очраклары да сирәк күренеш булгандыр.

Г.Тукаебыз шигырь-поэмаларының рус телендә тулырак җыентыкларын чыгаруга сугыштан соңгы елларда ешрак мөрәҗәгать ителде. Илленче-сиксәненче еллар дәверендә бөек шагыйребезнең калын-калын сайланма әсәрләре Казанда һәм Мәскәүдә һәр ун ел саен диярлек чыга тордылар. Ләкин ул «Сайланма әсәрләр»гә кергән күпчелек шигырьләрнең тәрҗемәләре ике телне белгән укучыны канәгатьләндерерлек түгел иде. Аның ул елларда подстрочникларга (сүзгә-сүз тәрҗемәләргә) нигезләнеп эшләнгән күп кенә шигырьләренең эчтәлекләре шактый ук ярлыландырылган иде. Шагыйрьнең укучысына әйтер сүзе, җиткерәсе фикере нык гадиләштерелгән булды. Рус әдәбияты дөньясында зур талант иясе саналган шагыйрьләрнең дә, ике телнең үзенчәлекләрен, икенче шагыйрь яшәгән мохитне белмәүләре сәбәпле, тәрҗемә шигырьләре уңышсыз чыга. Шуңа күрә дә Г.Тукай әсәрләренең русча һәр

яңа басмасына яңадан-яңа тәрҗемәләр өстәргә кирәк була иде. Элегрәк елларда эшләнгән күпчелек тәрҗемәләр ашык-пошык әвәләнгән подстрочниклар ярдәмендә башкарылган булса, торабара ике телне дә камил белгән яшьрәк буын тәрҗемәчеләргә дә үз көчләрен сынап карау мөмкинлекләре тудырыла башлады. Шул рәвешле, Тукай шигырьләрен тәрҗемә итүчеләр сафына сагаеп кына Вил Ганиев, Шамил Мәхмүдев-Анак, Равил Бохараев кебек үз кешеләребез килеп керде. Соңгы елларда бу өлкәдә милләттәшебез Венера ханым Вәлиева бик актив һәм нәтиҗәле эшли.

Әйе, шигъри сүз-җөмләне башка телгә, бигрәк тә рус теленә зур төгәллек белән тәрҗемә итү бик тә катлаулы, авыр хезмәт. Шуңа күрә әле бүген дә милли горурлыгыбыз саналган Г.Тукай, Һ.Такташ, Дәрдемәнд кебек үзенчәлекле шагыйрьләребезнең әсәрләрен рус телендә канәгатьләнерлек рәвештә күрә алганыбыз юк. Классик әдипләребезнең әсәрләрен рус телле укучыга җиткерү эше белән турыдан-туры шөгыльләнүче Татарстан Язучылар берлеге идарәсе бу өлкәдә күп хезмәт куйды. Төрки-татар шигырь үрнәкләрен тәрҗемә итүдә уңышка ирешкән шагыйрьләрдән Семен Липкин, Михаил Львов, Рувим Моран, Сергей Иванов белән аерым килешүләр төзелә, алар өчен дип кат-кат эшкәртелгән подстрочниклар әзерләнә иде. Татар мохитен яхшырак үзләштерсеннәр дигән өмет белән алар еш кына Казанга кунакка чакырылдылар. Семен Липкинның «Шүрәле» поэмасын һәм кайбер шигырьләрне уңышлы тәрҗемә иткәнлеген хуп күреп, аңа республикабызның иң югары бүләге тапшырылды. Ул Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды. Ләкин төрки телле шигырьләрне оста тәрҗемә итүе белән танылган шагыйрь Арсений Тарковский гына нишләптер татар шигъриятен зур дөньяга чыгаруда активлык күрсәтә алмады. Тумышы белән татар теленең бер тармагы саналырдай кумык-нугай тел мохитеннән чыккан Тарковскийны үзебезгә җәлеп итәргә тырышуларны яхшы хәтерлим. (Тарковскийлар Дагыстан төбәгенең хан-солтаннары нәселеннән. Шәҗәрәләре Алтын Урда чоры Ширин бәкләргә барып тоташа.) Җитмешенче елларда, Г.Тукайның олуг юбилеен билгеләп үтәргә җыенган вакытта, аны Казанга китерергә тырышып караулар булды. Ләкин Сталин заманы төрмә-лагерьларын кичкәннән соң, сәламәтлегенең нык какшаган булуы сәбәпле, ул монда килә алмады. Мәскәү янәшәсендәге Иҗат йортында аның Г.Тукайның берничә шигырен тәрҗемә итә башлаганы хәтеремдә калган. Бу эштә аның төп булышчысы һәм консультанты мәрхүм Шамил Анак булды.

Нәкъ менә шул вакыйгалар барышында Язучылар берлегенең ул вакыттагы рәис урынбасары шагыйрь Равил Фәйзуллин һәм Шамил Анак тәкъдиме белән Г.Тукайның сайланма шигырь-поэмаларының фәнни нигездә эшләнгән сүзгә-сүз (подстрочный)

тәрҗемәләрен булдыру килешүе дә төзелде. Ул тәкъдимне республика җитәкчеләре, шул исәптән Министрлар Советы рәисе урынбасары, әдәбият галиме Мансур Хәсәнев тә хуплады. Берничә елдан соң Ш.Анак ул фәнни хезмәтне башкарып, Язучылар берлегенә китереп тә тапшырды. Г.Тукайның һәр шигыренең тәрҗемә үрнәкләре берничәшәр вариантта башкарылган иде: сүзгә-сүз тәрҗемәсе, сүзләрнең мәгънәви бәйләнеше, шагыйрьнең әйтергә теләгән фикере сөземтәсе һ.б. Бу хезмәте өчен Ш.Анакка зур суммада акча да түләнде. Бераз соңрак Башкортстанның халык шагыйре Мостай Кәрим «Волга» журналында (1982, 5 нче сан) шул хакта түбәндәге сүзләрне язып чыккан иде (автор фикеренә хилафлык килмәсен өчен, аның язганнарын рус телендә китерәм): «Поэт Ш.Анак завершил научно-филологические переводы поэтических произведений классика татарской литературы Габдуллы Тукая. В них впервые наиболее полно и точно зазвучало на русском языке все поэтическое наследие поэта. Научно-филологический перевод — понятие новое, он сочетает в себе максимальную точность... образного мышления поэта». Ялгышмасам, ул хезмәт машинкада алты данәдә басылган иде. Аның ике данәсе авторга акча түләгән Язучылар берлеге белән Милли музей бухгалтерияләренә, бер-ике данәсе кырык-илле данә итеп бастырып чыгару өчен шулай ук Язучылар берлеге идарәсенә тапшырылды. Бу хезмәтне эшләүнең төп максаты аны күпләп бастырып тәрҗемәчеләргә таратудан гыйбарәт иде. Ләкин ул хезмәт ни сәбәпледер типографиягә вакытында бирелмәде, тиражланмады. Хәер, Г.Тукай шигырьләренең камилрәк эшләнгән яңа тәрҗемәләрен, яңа басмаларын чыгару да бер заман тоткарланыбрак торды. Чөнки тиздән илдә буталчык заман башланды, классик әдипләрнең әсәрләрен кабат бастырып чыгару эшләре чигерелде. Хәзер андый эшкә җиң сызганып кабат тотынырга ниятлибез шикелле. Әлбәттә, иң беренче бурыч итеп Габдулла Тукайның «Сайланма әсәрләре»нең яңа тәрҗемәләрен эшләп чыгаруны алга куярга тиешбездер. Шул уңайдан телче галим, үзенчәлекле шагыйрь Шамил Мәхмүдев-Анакның дистә еллар дәвамында читкә тибәрелебрәк яткан ул фәнни-филологик хезмәтен искә төшерү дә файдалы булачак. Классик әдипләребезнең әсәрләрен башка телләргә тәрҗемә итеп чыгаруны бездән башка берәү дә эшләмәс. Ул безгә, безнең халыкка кирәк. Безнең балаларыбыз да олуг шәхесләребезнең уңышын күреп горурланырга, яшәү көчен шулардан алырга хаклылар.

*«Мәдәни җомга», 2006, 21 апрель*

# МИЛЛИ МИРАСЫБЫЗ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

## 1

Казанда губернатор рөхсәте белән беренче рәсми милли спектакль куелуга — 100 ел, күренекле татар драматургы Мирхәйдәр Фәйзинең тууына 2006 елда 115 ел тулды. Хәер, 1906 ел беренче милли театр оешуы белән генә истәлекле түгел. Татар халкы, татар җәмәгатьчелеге өчен гомумән дә бик истә калырдай, тарихи вакыйгаларга бай ел булган ул. Нәкъ шул елда татар халкы бергә тупланып яшәгән байтак төбәкләрдә — Казан, Уральск, Оренбург, Әстерхан калаларында үз милли телебездәге күпчелек газеталар, журналлар басыла башлый. Шул ук елның язында эшли башлаган беренче чакырылыш Дәүләт Думасына бер дистә милләт вәкиле сайлана. Патша Россиясе хакимлек иткән дәвердә алар тарихта беренче мәртәбә, дәүләт мөнбәренә басып, татар халкын борчыган мәсьәләләр хакында ачыктан-ачык сүз әйтү хокукын алалар. Шушы җитди вакыйгаларның бер гасырлык юбилее уңаеннан мөхтәрәм Президентыбыз Минтимер Шәймиев указы белән 2006 елның «Әдәбият һәм сәнгать елы» дип игълан ителүен барыбыз да хуплады.

Унтугызынчы-егерменче гасырлар чигенә кергән еллар татар милләтенең кабат уяну, мәдәни вә рухи күтәрелеш дәвере булarak күзаллана. Бу чорда иҗтимагый-тарихи һәм дини-рухи әдәбият белән беррәттән матур әдәбият өлкәсендә дә зур уңышларга ирешелә. Рус һәм Көнбатыш әдәбияты үрнәгендә беренче драма әсәрләре языла. Татар телендә спектакльләр куярга омтылыш туа. Мондый хәл татар дөньясының башкаласы булган Казаннан тыш Әстерхан, Оренбург, Уфа, Уральск, Касыйм, Орск, Троицк, Чистай кебек шәһәрләрдә дә күзгә ташлана. Санкт-Петербургтагы татар җәмгыяте белән касыймлылар элек-электән тыгыз элемтәдә торган, татарлар арасында алар беренче булып рәсми Хәйрия оешмасын төзегәннәр. Театрлар тарихы белгече Һәнүз Мәхмүдев хәбәр итүенчә, «Касыймда... 1899–1901 елларда татар телендә беренче ачык спектакльләр булып үтә». Казанда «шундый кичәләрнең беренчесе Казан Җәмгыяте хәйриясе файдасына 1901 елның 27 гыйнварында шәһәр театрында оештырыла. Аңа дүрт йөзләп татар тамашачысы килә». Дөрес, бу спектакль әле татарлар өчен рус артистлары тарафыннан рус телендә уйнала. Әлеге Хәйрия җәмгыяте рәистәшләренең берсе, Кавказ халыклары ирегe өчен көрәшкән мәгълүм шәех Шамил оныгы Заһид Шамилнең бу спектакльне яртылаш булса да татарча куярга тырышуы хөкүмәт түрәләре һәм үзебезнең «халык вәкилләре» тарафыннан кире кагыла.

Казанда татарча спектакль куярга омтылыш иң элек «урыс хәлфәләре» әзерләүче Татар укытучылар мәктәбе яшьләре арасында туа. 1898 елда ук алар шундый үтенеч белән түрәләргә мөрәҗәгать итәләр. Ләкин аларга башкаладан «Театр уеннарын рус телендә уйнарга» дигән рөхсәт кенә бирелә. Шул рөхсәтнең дә киләчәк өчен файдасы зур була. Рус телендәге спектакльләрдә уйнау тәҗрибәсен алган яшьләр татар театрларын нигезләүче төп көчләргә әвереләләр. Шундыйларның беренчеләре арасында без Гаяз Исхакый, Гафур Коләхмәтев, Хөсәен Ямашев, Шакир Мөхәммәдьяров, Ильясбәк Кудашев-Ашказарский, Габдерахман Мостафин, Габдерәүф Ниязбаев (булачак драматург), Шәриф Сүнчәләй һ.б. күрәбез. Боларның күпчелеге Казаннан еракта урнашкан мәдрәсәләрдә башлангыч белем алган, киләчәктә үз мәдрәсәсенә кайтып, рус телен укытырга тиешле яшьләр була. Аларның бер өлеше Казанда «Шимбәчеләр» түгәрәген оештыруда да катнаша.

XIX йөзнең соңгы елларыннан башлап Оренбургның «Хөсәения» мәдрәсәсеннән дә бу уку йортына дүрт-биш шәкерт җибәрелеп тора. Монда җибәрелгән икенче-өченче төркем шәкертләр исемлегендә Зәки Ишаев, Мирсәяф Туктамышев, Ильясбәк Кудашев һ.б. исемнәрен очратабыз. Казанда уку дәверендә һәвәскәр артист буларак сәхнәгә тәүге тапкыр аяк баскан шәкертләрдән И.Кудашев, Ш.Мөхәммәдьяров, Г.Ниязбаев соңыннан Оренбург төбәгендә татар театрын булдыру эшенә үз өлешләрен кертәләр. Гармунда, скрипкада һәм пианинода ярыйсы ук оста уйнаучы, үз ана һәм рус телләрендә иркен сөйләшә белүче Ильясбәк Кудашев та, 1904 елда укуын тәмамлап «Хөсәения»гә кайткач, җиң сызганып театр оештыру әмәленә керешә. Үз тирәсенә Вәли Мортазин, Исхак Әлмәшев, Әхмәт Ишморатов, Габдерахман Мангушев, Нури Сакаев һ.б. сәләтле шәкертләрне туплап репетицияләр үткәрә башлый. Шул рәвешле, бер-ике елдан соң ул татарлар арасында профессиональ Беренче театр труппасын оештыручы буларак танылa. 1907 елның март-апрель айларында ул оештырган театр төркеме артистлары якташлары Ярулла Вәлинең «Оят, яки Күз яше», Александр Островскийның Ильясбәк тәрҗемә иткән «Галимлек вә наданлык» пьесаларын Оренбург тамашачысына уйнап күрсәтәләр. Һәм май аенда тәвәккәлләп Бозаулык, Самара, Сембер, Казан, Чистай якларына гастрольләргә чыгып китәләр. Оренбургта беренче театр уеннарын оештыруда җирле Хәйрия җәмгыяте һәм аның рәисе Газиз Мәхмүт улы Хөсәеневнең дә өлеше зур була.

Казанда аларга беренче хатын-кыз артистка Сәхипҗамал Гыйззәтуллина (сәхнә псевдонимы Волжская), ә Мәкәрҗә ярминкәсендә исә Габдулла Кариев килеп кушылалар. Ашказарский җи-

тәкчелегендәге милли театр труппасы ирешкән иң зур уңыш Мәкәрҗә ярминкәсе көннәренә туры килә. Спектакльләрдән кергән керем көтелгәннән дә ишлерәк була. Өстәвенә алар куйган бер спектакльне Түбән Новгород губернасы губернаторы да карый һәм хуплый. Шул ук җәйдә бу төркем артистлары сәяхәттә йөрүче «Сәйяр» театры исеме белән танылалар.

Татар театрының 100 еллык юбилеен үткәрүгә сәбәп булган, рәсми рөхсәт алып беренче мәртәбә Казанда уйналган ачык спектакль артистлары да, нигездә, шушы Татар укытучылар мәктәбе шәкертләре, ике-өч студент һәм гимназиядә укучы кызлар була. 1906 елның 22 декабрендә куелган ул тамашаның беренче бүлегендә уйналган «Кызганыч бала» драмасында төп рольләрне «Шимбәчеләр» түгәрәгендә катнашкан өч гимназистка белән бергә Шакир Мөхәммәдъяров һәм Шәриф Сүнчәләй башкара. Икенче бүлектә уйналган «Гыйшык бәласе» комедиясендә шул ук кызлар һәм өч университет студенты катнаша...

Ильясбәк Кудашев-Ашказарский исә бу вакыйгага кадәр төгәл бер ел элегрәк, 1905 елның 3 декабрендә, Оренбургта татарча беренче спектакль куярга талпынып карый. Рус драма театры бинасы арендага алына, шунда репетицияләр уздырыла. Әмма «Оренбургская газета»ның 27 ноябрь санында ике телдә игълан басылгач һәм типографиядән кайтарылган афишалар таратыла башлагач, мөселманнар арасында шау-шу куба. Губернатор галиҗәнаплары хозурына, «рөхсәт итмәскә» дип ялварып, «чалмалы вә дәү корсаклы» вәкилләр килеп җитә. Спектакль башланырга ике-өч көн калгач, губернаторның әлеге тамашаны тыю турындагы әмере чыга. Оренбургта яшәгән төбәк тарихчысы мәрхүмә Мәдинә апа Рәхимкулова 1980–1990 елларда шушы вакыйгага кагылышлы күп кенә материалны туплаган, берничә мәкалә язып бастырган иде. 1905 елның 3 декабренә билгеләнгән спектакль афишасы, газета белдерүләре, анда катнашырга тиеш булган яшьләрнең исем-фамилияләре һәм киләчәк язмышлары да аның тарафыннан барланган иде. 2006 елда Оренбургка барганда мин аның шул төбәк театры тарихына караган архивының хәзер кемдә булуын ачыклый алмадым. Мәдинә апада шулай ук И.Кудашев-Ашказарский тарафыннан 1907 елның башында оештырылган профессиональ «Сәйяр» театры, соңрак Оренбургта эшләгән «Нур», 1915 елда барлыкка килгән «Ширкәт» һ.б. театрлар турында да бай мәгълүмат, шул исәптән ул чор артистлары фоторәсемнәре тупланган ике зур альбом да бар иде. Альбомнарның берсе бүген өлкә татар китапханәсе фондында саклана. Икенчесенең, егерменче еллардан башлап алтмышынчы еллар ахырынача Оренбург татар театрында эшләгән һәм үз дәвере артистлары йөзләрен, исем-фамилияләрен саклаган Хәдичә Таһирова-Ханская

альбомының язмышы әлегә билгесез. Шуны да әйтеп китү кирәктер, Оренбургта 1919 елның башында Совет хакимияте урнаштырыла. «Ширкәт» драма артистлары төркеме җирлегендә озакламыйча рәсми рәвештә теркәлгән Оренбург татар театры барлыкка килә. Аны рәсмиләштерү эшен шул вакытта Губерна башкарма комитетының мәгариф бүлегендә сәнгать тармагын җитәкләгән Исхак Мөхәммәтҗан улы Әлмәшев башкарып чыга шикелле. Аңа хәтле Исхак «Хөсәения» мәдрәсәсе шәкерте, 1912 елда Уфада оешкан «Нур» төркеменең режиссеры була, Беренче герман сугышында катнаша. Самарада оешкан махсус театр курсларын тәмамлап чыккан артистларның күпчелегенең нәкъ шушы театрга җибәрелүе дә монда ныклы җирлек булганлыгы турында сөйли. 1920 елның декабрендә ул курстан Оренбургта эшләү өчен җибәрелгән зур төркем арасында Таҗи Гыйззәт, Рифкать Фәйзи, Хөсәен Уразиков, Әсгать Мәҗитов кебек булачак күренекле шәхесләр дә бар. 1930 еллар уртасыннан Оренбург театры күчмә рәвештә көн күрә башлый, 1949 елдан дәүләт карамагындагы филармониягә беркетелә. 1989 елдан кабат мөстәкыйль иҗат оешмасы статусын алды, үз бинасы булдырылды. Хәзер ул театр Мирхәйдәр Фәйзи исемен йөртә. Репертуарында татар һәм башкорт драматурглары әсәрләреннән тыш рус һәм көнбатыш авторлары әсәрләре дә бар. «Ширкәт»не һәм Оренбург татар театрын оештыруда актив катнашкан, аларның җитәкчесе, баш режиссеры булган Вәли Мортазин-Иманский 1921 елда Башкорт автономиясенең башкаласы Эстәрлетамакка чакырып алына. Аңа анда Башкорт драма театрын нигезләү бурычы йөкләнә.

Күренә ки, Оренбургның милләтчел рухлы зыялылары тырышлыгы белән ул шәһәрдәге драма театры да, 1906 елда ачылган милли китапханә дә йөз ел дәвамында өзлексез рәвештә эшләп киләләр. Бу ике оешма шул төбәктә татар телен, рухын саклауда бик зур вазифа башкара. 1980 еллар ахырында кабат оешкан барлык рәсми милли җәмгыятьләргә ныклы нигез булдылар алар. Оешкан дәвердә «Белек», 1914–1925 елларда Исмәгыйль Гаспринский, 1925 елдан соң Хөсәен Ямашев исемен йөртүче бу өлкә китапханәсе дә 2006 елның октябрендә 100 еллык юбилеен билгеләп үтте.

## 2

«Хөсәения» мәдрәсәсенең хәлфә һәм шәкертләреннән бер төркем татарча театр уеннарын оештыру хыялы белән йөргән бер вакытта, 1906 елның көзендә, бу уку йортына сәнгатькә тартым җанлы Мирхәйдәр Фәйзи килеп керә. Ул Казан, Оренбург һәм башка төбәкләрдә чыга башлаган татарча газеталарны, әдәби әсәрләрне даими укып баручы, ил-дөнья тормышы белән кызык-

сынып торучы яшьләрнең берсе була. Өстәвенә Орск шәһәре мәдрәсәсендә укыган дүрт кышта үзлегеннән каләм тоткаларга да өйрәнеп килә. Аерым шигъри юллар, бәетләрдән тыш ул әле яңарак кына «Татар туе» исемле бер күренешле сәхнә әсәрен дә язган була. Шул пьесасын күпсанлы җиңгә һәм кодачалары алдында укып, аларны хәйран калдыра. Әлбәттә инде, мәдрәсәгә яңа гына килеп керүенә карамастан, Ильяс хәлфә тирәсенә тартылган шәкертләргә якынрак булырга тырыша.

Мирхәйдәр, гаиләдә унберенче бала буларак, 1891 елның 1 ноябрендә дөньяга килә. Иң кече бала булу сәбәпле бик иркә үсә. Алар яшәгән Күкшел авылы элекке өяз үзәге Орск шәһәреннән илле чакрымнар төньяк-көнбатыштарак, Уралтауның бер тармагы булган Гөберлә тау-калкулыклары арасында, Гөберлә суы буенда урнашкан. Утызлап йортлы Күкшел утарын булачак драматургның атасы Мостафа карт 1870 еллар ахырында нигезләгән була. Мостафа мәхдүм Чистай өязе Шахмай авылында туган (хәзер Татарстанның Яңа Чишмә районына керә). Унтугыз яшендә, 1854 елда ул, Орск каласына килеп, бер сәүдәгәргә кулдаш булып урнаша. Бервакыт Хөсәенев байлар казакъ иленнән кайтарылган көтү-көтү мал-туарны симертер өчен иркен җир-сулыклар сатып алалар. Шуны кулда тотардай идарәче кирәк булгач та, аларга «мулла баласы мишәр Мостафа»ны тәкъдим итәләр. Бертуган Хөсәеневләрнең җир биләмәләре управляющие вазифасын ул 1905 елга кадәр, чирек гасырдан артыграк вакыт үти. Мостафа ярыйсы ук укымышлы кеше була — берничә кыш Чистайда Закир ишан, бер кыш Казанда Шиһабетдин Мәрҗани мәдрәсәләрендә укый. «Тәрҗеман» газетасы чыга башлаган көннән аны алдыра. Оренбург янәшәсендәге Каргалы авылында туган хатыны Зәйнәп тә укый-яза белүче хатын-кызлардан була. (Мостафа Фәйзуллинның үзе кичергән вакыйгаларны, Казан ханлыгы чоры бәк-морзаларына бәйле булган шәҗәрәләрен теркәгән калын куен дәфтәрен Казан университеты мирасханәсенә кайтаруда үземнең дә катнашуымны әйтеп үтим.)

Күренә ки, Мирхәйдәр Фәйзи заманы өчен шактый ук укымышлы гаиләдә туган. Ул төпле тәрбия алган, зәвык күргән яшүсмер булып буй җитә. Төскә-биткә бик чибәр, чандыр гәүдәле була. «Һәрвакыт җыйнак, пөхтә итеп киенгән булыр иде. Сабыр холыклы, тыйнак кеше иде», — дип искә алалар аны якыннан белүчеләр. Ул балачактан ук бик күп җирләрдә була, төрле катлаудан чыккан зыялы затлар белән аралашу бәхетен татый. Аның олы апасы Фатыйманы Малмыжның укымышлы кешесенә — Камал Мозаффаровка кияүгә бирәләр. Абыйсы Сәетгәрәй дә Малмыж өязенә караган Түнтәр авылында Ишми ишан мәдрәсәсендә белем ала. 1901 елда ул ишан кызы Фатыймага өйләнә. Язучы Рәфыйк

Шәрәфиев Балтач төбәге музейларына багышланган бер күләмле язмасында М.Фәйзинең бертуган апасы белән абыйсының Орск шәһәреннән мең ярым чакрымдагы Малмыж, Балтач, Түнтәр тирәләренә ни сәбәпле килеп чыгуларын шул төбәктә яшәүче туганнарының белмәгәнлеген бәян итә. Сәетгәрәй мулланың ике улы — Сәгыйть белән Икрам Фәйзуллиннар Татарстанда мәгълүм журналистлар иде. (Малмыж, Балтач якларында Фатыйма белән Камал Мозаффаров нәселе вәкилләре дә яшәгәндер, мөгаен.) Сәетгәрәй «Нилектән бу дини мәдрәсәгә килгән? Ни өчен нәкъ менә Түнтәргә?» дип сорау бирә автор («Казан утлары», 1997, № 4). Бу сорауларга җавапны шул балалар атасы Мостафа Фәйзуллинның Чистай белән Казан мәдрәсәләрендә кемнәр белән бергә укуын, кемнәргә дус булганлыгын ачыклагач кына җавап биреп булыр, мөгаен. Һәрхәлдә, аның Малмыж кешеләре һәм шул төбәкнең иң абруйлы дин әһеле Ишмөхәммәт Динмөхәммәдев белән тыгыз элемтәдә торганлыгын алда сурәтләнгән вакыйгаларга бәйләп беркадәр аңлатып була, минемчә. Икенче бер элемтә җебе XIX йөз ахырларында Оренбургта мәгълүм мәдрәсә тоткан Шаһимәрдән хәзрәт Үтәгәневкә бәйле булырга мөмкин. Түнтәр авылыннан чыккан бу кеше 1880 елларда Оренбург төбәгендә абруй казанган «Дамелла Шаһимәрдән хәзрәт мәдрәсәсе»нең мөдәррисе була. 1889 елда үз уку йортын «Хөсәения» мәдрәсәсенә кушкач, байтак еллар шунда укыту бүлеге мөдире вазифасын башкара. Өченче бәйләнеш Түнтәрдән килеп Оренбургта сәүдә иткән Хәкимев Шакир аша оештырылган булуы да ихтимал. Шул авылның Рәфгать Зарипов дигән кешесе әйтүенчә, Мөхәммәткамал Мозаффаров белән әлеге «бай Хәкимев» кардәш-ыру тиешле дә булганнар.

* * *

Сәетгәрәй абыйсы туена дип әти-әнисе белән бергә Мирхәйдәр дә зур юлга җыенып чыгып китә. Күкшелдән өч йөз чакрымдагы Оренбургка башта алар ат-арбада киләләр. Аннан Самарага поезд белән китәләр. Самарадан Казан тарафына таба әүвәл зур Идел пароходында, аннан соң Нократ елгасына керүче кечерәк пароходта баралар. Ун яшьлек хисчән, зирәк бала күңелендә бу сәяхәт мизгелләренең мәңгегә уелып калуы бик табигый. Ул туйга Оренбургтан Мәхмүт бай Хөсәенев, аның конторасында эшләүче абыйсы Мәхмүтгәрәй хатыны белән, Казаннан сәүдәгәр һәм фабрикант Габдерахман Ишморатов ике хатыны белән киләләр. Ишан хәзрәтләрен олылаган, аңа дус, фикердәш булган абруйлы төрле төбәк муллалары да ул туйда катнаша.

Туйдан кайтышлый Фәйзуллиннар Чистайда тукталыш ясыйлар, шуннан Шахмай авылына сәяхәт кылалар. Соңрак Мирхәйдәр

Шахмай табигатенең матурлыгы, Әхмәтҗан бабасының авыл уртасындагы ике катлы өенең нык булуы турында көндәлегенә язып куя. Алар Мостафаның бертуганы Гобәйдә абыстай өенә төшәләр. Чистайдан соң Казанга киләләр. Әхмәт бай Хөсәеневнең Кабан күле буендагы өендә берничә көн кунак булалар. Шәһәрнең мәчетләрен, базарларын карап, тамаша кылып йөриләр. Мәгәр ул вакытта әле Мирхәйдәр шәһәрнең өске өлешенә, университет, гимназияләр тирәсенә бармаган булса кирәк. Мөгаен, Мостафа карт ул вакытта «чукынган урыс ягына» чыгып йөрүне өнәп бетермәгәндер.

1906 елның җәендә дә Фәйзуллиннар кабат Казанда, Малмыжда һәм Сәетгәрәй муллалыкка тәгаенләнгән Шода авылында булып кайталар. Яңарак кына Оренбург белән Ташкент арасында тимер юл төзелгәнлектән (ул 1905 елның ахырыннан эшли башлый), Мирхәйдәрләрнең сәяхәтенә бераз үзгәреш кертелә. Алар башта Орскидан йөз кырык чакрымдагы Актүбә каласына ат-арбада юл тоталар. Юлда казакъ халкы яшәешенә хас күренешләр белән дә танышалар. Шуннан поезд белән Оренбургка киләләр. (Искәртеп китим, киләчәктә иҗат ителәчәк «Асылъяр» драмасы җирлеге дә шушы Орск—Актүбә юлына бәйле рәвештә барлыкка килгән.)

Мондый сәяхәтләр, төрле дәрәҗәдәге төрле холык-гадәтле кешеләр белән якыннан аралашу яшүсмер Мирхәйдәрнең зиһен офыкларын киңәйтә, билгеле. Язучының киләчәк әсәрләрендәге төрле холыктагы персонажларны оста тасвирлый алу сәләтен үстерә.

Оренбургта укыганда ул Мәхмүтгәрәй агасы белән Фәрихә җиңгәсе карамагында, алар өендә яши. Дәрестән кайткач та күп укый, яза. Шигырь-бәетләрен, мәкалә-хәбәрләрен газета-журналларга да тәкъдим иткәли. Аларның кайберләре Тимерша Соловьев нәшер иткән «Чүкеч» журналында, Казанда чыгучы «Әлислах» һ.б. газеталарда басылалар. Шул көннәрдә ул көндәлегенә: «Хәлфәләр зобани төсле түгел... Бу яңа хәят мине бик тиз җәлеп итте. Башта яңа уйлар, яңа хыяллар хөкем сөрә. Шагыйрь булу, артист булу, музыкант булу кебек уйлар белән җенләнәм», — дип язып куя.

## 3

Ләкин Мирхәйдәргә «Хөсәения» мәдрәсәсендә озак уку насыйп булмый. Күп уку, кичләр буе баш иеп язып утырулар аның сәламәтлеген какшата. 1907 елның язында врач аңа тумыштан йөрәк авырулы булганлыгын белдерә. Йөрәк өянәгеннән сакланып, физик көч сарыф итмичә авыл шартларында яшәргә киңәш

бирә. Ильяс хәлфә шәһәр күләмендә беренче ачык спектаклен куярга җыенган бер вакытта, март ае ахырларында, Мирхәйдәргә Оренбургны калдырып китәргә туры килә. Ул Орск шәһәреннән егерме биш чакрымнардагы Җүнәй авылында яшәүче абыйларына кайта. Бу вакытта инде аның ата-анасы авылдан киткән, Орскиның үзәк урамнарының берсендә төзелгән ике катлы үз йортларына күчкән була. Мирхәйдәр берникадәр вакыт үз яшьтәшләре белән аралашмый диярлек. Хәятын биләп алган хасталык болыты кышын шәһәргә кайткач та тиз генә таралмый. Чөнки барча таныш-белеше диярлек: «Порок сердцалы кеше озак яшәми», — дип тәкрарлап тора. Шушы сүзләр аны гомере буе сагалап йөриячәк, буйдак булып яшәргә хөкем итәчәк.

Ә бу вакытта Орск яшьләре шау-гөр килеп театр куярга дип янып йөриләр. Бу эшкә тотынырга аларны Казан каласыннан кунакка кайткан якташлары Шакир Мөхәммәдъяров күндерә: «Әйдәгез, егетләр, шәһәрдә татар театры ачабыз»,— ди. Ләкин аның тирәсенә тупланган беренче төркем аулак өйләрдә сөйләшеп утырулардан узмый әле. Шакир да калага тиз генә кабат кайта алмый. Гаяз Исхакый җитәкләгән «таңчылар» фиркасенең актив әгъзасы буларак, шул ук көздә аңа Казанны калдырып китәргә туры килә. Университетта уку хыялын тормышка ашыру нияте белән ул Орскидан бик еракта урнашкан Санкт-Петербургка барып төпләнә. Үз шәһәрендә исә театр уены уйнарга хирысланып өлгергән яшьләр — Габдулла Мангутов, Әхмәтгали Багданов, Мәгъсүм Шәмсетдинов, өч бертуган Гобәйдуллин кебек теләктәшләре генә кала. Мирхәйдәр шәһәргә кайткач кына бу төркем җанлана, активлаша башлый.

1907 елда Орскиның зыялырак һәм баерак катлавы Хәйрия җәмгыятенә берләшә, «Шәрекъ көтепханәсе» исемендә китап кибете ачуга ирешә. Аның уку залына татарча, русча һәм төрекчә басылган газета-журналлар кайтарыла. Һәркем аларны анда барып укый ала. «Шәрекъ көтепханәсе» үзе дә Оренбург, Казан басмаханәләренә заказлар биреп, берничә заманча китап чыгаруга ирешә. (Мәсәлән, китап белгечләре Г.Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романы шушы ширкәт заказы белән 1913 елның башында Казанда нәшер ителгән дип белдерәләр.) Мирхәйдәрнең бер шигырь китабы да шул ширкәт исәбенә басыла. Форштат бистәсе тарафындарак урнашкан ул «кыйраәтханә»гә тиздән Мирхәйдәр дә бик теләп йөри башлый. 1911 елда Хәйрия җәмгыяте мөстәкыйль китапханә ачу өчен шәһәр уртасында иркен бер бинаны сатып ала. (Фәйзуллиннар яшәгән урам чатында урнашкан ул милли китапханә 1962 елга чаклы шәһәр халкына хезмәт итте. Совет хакимияте дәверендә Мулланур Вахитов исемен

йөртте.) Себер белән иркен казакъ иле чикләрендәге өяз башкаласы Орскига ара-тирә рус театр төркемнәре килеп чыккалый. Гимназия укытучылары белән шәһәр яшьләре үзләре дә спектакльләр куйгалыйлар. (Аларда тәүге артистлык чиркануын икенче бер якташыбыз, СССР чорының күренекле язучысы Лидия Сәйфуллина да ала. Атасы Әхмәт ягыннан ул да Чистай өязенә бәйле.) Андый спектакльләрне карарга Мирхәйдәр дә иптәшләре белән баргалый. Һәм 1909 елның кышында шундый бер тамашадан соң ул «Ике Хәсән» исемле пьесасын яза. Пьеса яшьтәшләре тарафыннан хуплап кабул ителә. Театр уены уйнарга хыялланучы яшьләрнең тәмам тупланып җитүенә ул пьеса бер этәргеч була. Шул яшьләрнең беренчеләре сафына кергән Мәгъсүм ага Шәмсетдиневнең соңыннан сөйләвенчә, «Ике Хәсән»не аулак өй утырышларында берничә мәртәбә уйнап, үз ишләренә күрсәткәннәр, әмма халык алдына чыгарга аларга мөмкинчелек бирмәгәннәр.

1908–1911 еллар аралыгында М.Фәйзи байтак кына шигырь иҗат итә. Үрнәк, өлге итеп, нигездә, Габдулла Тукай шигъриятен сайлый. Мирхәйдәрнең шигырьләрен бу елларда Казан, Әстерхан, Троицкида нәшер ителүче газета-журналлар бик теләп бастыралар. 1912 елда ул шигырьләр Казанда китап буларак укучы хөкеменә тапшырыла. Шушы ук чорда ул Клавдия Лукашевичның «Чәчәкләр арасында» исемле пьесасын тәрҗемә итә, һәм тәрҗемәне Казандагы «Сабах» китап ширкәте бастырып та чыгара. Бу пьеса Мирхәйдәрне театр сөючеләр арасында таныткан беренче әсәр була. «Чәчәкләр арасында»ны ул елларда байтак кына үзешчән театрлар сәхнәләштерә. Әлеге әсәр сәхнәләштерелгән шәһәр һәм шәһәрчекләрнең исемнәре әдип көндәлегендә теркәлгән.

1911 ел Мирхәйдәр Фәйзинең күпкырлы иҗатының тәмам ачылып китү елы санала. Шул елның җәендә Орскига «Сәйяр» төркеме килә. Әзерлерәк яшьләрне үз уеннарына җәлеп итәләр. Алар күрсәткән өч спектакльнең икесендә Мирхәйдәр дә катнаша. «Орск тарихында татарча театрны башлап уйнаучы «Сәйяр» булса да, сәхнәдән иң беренче сүзне әйтү миңа насыйб булды. «Оят, яки Күз яше» драмасындагы Маһи булып сәхнәгә иң тәү мин кердем», — дип яза ул шул хакта. Көндәлекнең алдагырак битләрендә: «Кыштан ук театр кую уе белән репетициягә тотындык. Беркөн беребезнең, беркөн икенчебезнең өенә барып репетиция ясыйбыз», — дип тә теркәп куелган. Ләкин ни сәбәпледер ул кышта алар зур сәхнәгә чыга алмыйлар. Спектакль куярга губернатор рөхсәте соңлабрак килгәндер, мөгаен. Ә менә «Сәйяр» төркеме китеп өлгермәстән, ике-өч ай дәвамында өч зур театраль кичә уздырыла. 1911 елның 9 августында зур сәхнәдә «Югалган хатын» белән «Түләшү» пьесалары куела, 11 сентябрьдә — «Бүләк өчен», «Кияү эзләү», «Кызлар

шулай кызык итәләр», ә 10 декабрьдә «Яшь хатын» әсәрләре уйнала. Боларны сәхнәләштерүдә унөч ир-егет (бертуган Гобәйдуллиннар, Габдулла Хәсәнев, Гариф Галиәкбәрев һ.б.) катнаша. Мирхәйдәр ул пьесаларның һәрберсендә хатын-кыз рольләрен башкара. («Сәйяр» афишасыннан башлап аның сәхнә псевдонимы М.Мирфанская буларак кабул ителә.) Шушы вакыйгалардан соң Орск яшьләре һәр елда татарча дүртәр-бишәр спектакль куярга керешәләр. Спектакль куюдан җыелган акчаның күбрәк өлешен Хәйрия җәмгыятенә тапшыралар. Тәүге «артистлар» төркеменә тиздән булачак халык артисты Хәким Сәлимҗановның ике абыйсы һәм татар театры дөньясында беренчеләрдән булып Хезмәт Батыры исемен алачак артист Мифтах Әпсәләмев тә килеп кушыла. 1918 елда шәһәрдә беренче мәртәбә Совет хакимияте урнаштырылгач, бу төркем шактый киңәйтелеп, яңа вазифалар йөкләнеп, «Төрек-татар яшьләре оешмасы» исеме белән йөртелә башлый. «Төрек-татар яшьләре»нең тәүге зур эше «Галиябану» пьесасын кабат сәхнәләштерү була.

1911 елда Мирхәйдәр Фәйзи тиз арада популярлашып киткән, байтак театр коллективлары тарафыннан сәхнәләштерелгән «Яшьләр алдатмыйлар» һәм төркемдәше, фикердәше Габдулла Әмирев белән бергә «Бизәнү» комедияләрен язып төгәлли. «Яшьләр алдатмыйлар»ның тиздән китап булып басылып чыгуы һәм «Сәйяр» тарафыннан сәхнәләштерелүе Мирхәйдәргә иҗади дәрт өсти.

1913 елда аның икенче шигырь китабы — «Яшь күңел» — Казанда басылып чыга. Шул кышта ул Орскида «Кызганыч» (1914 елда аерым китап булып басыла), «Тәкъдирнең шаяруы» драмаларын, җәй айларында Җүнәйдә бер пәрдәлек «Авыл бәйрәме» исемле шаян пьесасын язып төгәлли. Бу өч әсәр дә төрле-төрле тарафларда уйнала башлый. «Авыл бәйрәме»н 1921 елда автор ике пәрдәле итеп үзгәртә һәм иң элек Юлык авылы яшьләре белән бергә үзе сәхнәләштерә. (Бу пьеса 1924 елда Казанда нәшер ителә.) Мирхәйдәрнең ул елларда иҗат иткән барлык пьесалары да төрле-төрле шәһәрләрдә, төрле театраль коллективлар тарафыннан бер-бер артлы сәхнәләштерелә тора.

Әмма ки, Мирхәйдәр Фәйзи иҗат иткән, татар халкының иң олуг мирасына әверелгән әсәр — «Галиябану» музыкаль драмасы. Ул драманы башка кардәш халыклар театрлары да бик яратып куйды. Шушы әсәр дистә еллар дәвамында татар сәхнәсенең сүнмәс бер җәүһәре булып калды. Аны заманында барлык авыл һәвәскәрләре дә бик теләп һәм яратып сәхнәләштерә иде. Хәер, элекке СССР биләмәсендәге төрки телдә эшләүче театрлар арасында да «Галиябану»ны сәхнәләштермәгәне бик сирәктер. Әсәр бүгенге көнгәчә сәхнәдән төшмичә уйналып килә.

## 4

Мирхәйдәр Фәйзи җәйге айларда авылда яшәүне хуп күрә. Авыл яшьләрен ул самимирәк, үзара аралашуда үзе кебек үк гади холыклы дип исәпли. Аның көндәлекләрендә бу фикерне раслаучы язмалар бик күп. Шәһәргә күчеп яши башлаганнан бирле ул җәй айларын Җүнәй авылында уздыра. Җүнәй аның туган авылы Күкшел кебек үк текә маңгайлы, җәлпәгрәк түбәле Гөберлә таучыклары куенына сыенып утырган. Тау белән тау култыклашкан иңкүлекләрдә бер буй булып усак, каен агачлары үскән «урман колаксалары» да очрап тора. Авыл зур түгел. Монда Мирхәйдәрнең бертуган абыйлары Әхмәтгәрәй, Мөхәммәтгәрәй, Шакирҗан игенчелек хезмәте белән көн күрә. Алар белән бергә Мостафа картның үги анадан туган энеләре дә монда яши. (Әхмәтҗан баба исеменнән алынган Әхмәтҗанов фамилиясен йөртүчеләр. Егерменче еллар ахырында алар, кулак буларак, Магнитогорск төзелешенә барып әләгәчәкләр.) Җүнәйнең калган халкы шул ук Гөберлә елгасының аргы ярында зур гына мәйдан биләп торган Дүрткүлдән була. Тау тирәләрендә монда зур-зур табигый ташлар аунап ята. Авыл каршындагы шундый бер яссы ташка утырып Мирхәйдәрнең китап укыган, ни-нәрсәләрдер язган очраклары да еш кабатланган. Тау башыннан күрше ике авыл тормышы уч төбендәгедәй күренеп торган. Тау өстендәге ташта утырганда яисә тау итәгендәге печәнлектә эшләгәндә, Мирхәйдәрнең күңеле күтәрелеп киткән яисә моңсуланган чаклары да булган. «Аның үзенчә бик матур итеп җырлавы вакыт-вакыт ике авыл өстендә яңгырап торыр иде»,— дип искә алган иде Дүрткүлдә яшәүче Зәкия апа Фәйзуллина. Мандолинада да ул халык көйләрен моңлы, сагышлы итеп, бик бирелеп уйный торган була. Үзе уйнаган көйләрнең саны илледән артык булуын һәм ул көйләрнең исемлеген Мирхәйдәр соңрак куен дәфтәренә дә язып куя.

Менә 1913 елның декабрендә Җүнәйдә узган туй күренеше язмалары. Әдип анда Гариф Галиәкбәревнең туенда кияү егете сыйфатында катнаша. «Кыз (өе) янында Җүнәй һәм Дүрткүл егетләре җыелган. Кунакларны араларыннан гармунда уйнап, җырлап үткәрделәр. Сыйлар мул: каз итләре табаклап. Уен, җыр, бию. Үтә матур тавыш белән яшь кенә егетләр җырлыйлар. Берсе артыннан берсе төшеп шундый өздереп бииләр. Йә Раббым, бөтен матурлыкны авыл өстенә генә түккәнсең икән... Дүрткүлдән Хәсән Зөфәрев исемле унсигез яшьлек егетнең җырлары шундый үзәгемә үтте, шундый көчле тәэсир бирде ки. Шундый саф, матур тавышлы егетләре бар халык та бәхетле булмаса...»

Көндәлектән мондый озын өзекнең китерелү сәбәбен укучы озакламый аңлар. Мирхәйдәр Фәйзинең иң югары бәяләнгән,

бүген дә сәхнә түреннән төшмәгән иҗат җимеше — «Галиябану» музыкаль драмасының автор күңелендә бөреләнә башлаган көннәргә якынлашабыз. 1913–1916 еллар аралыгында Мирхәйдәр Җүнәй белән Дүрткүл яшьләре уеннарында еш катнаша. Кичке уеннарда яшьләрнең үзләрен тиң, тигез тотуларын билгеләп үтә. Бу яшьләрнең һич кыстатмыйча җырлый алуларына, җитез итеп тыпырдап биеп китүләренә сокланууларын көндәлекләренә даими теркәп бара. Шәһәр яшьләре андый түгел, үзләрен авылныкылар кебек иркен тота белмиләр, дип зарлана. Авылга кайтканда үзенең мандолинасын һич тә калдырмавын белдерә.

Менә 1914 елның 12 июленә караган язма. «Мәмәшевләр яшьләр өчен зур гына мәҗлес ясады. Дүрткүлдән дә байтак егетләр, шул җөмләдән Хәсән дә килде. Гатиятулла, Хәким — оста гармунчылар, Хәсән, Шаһидулла, Хәким — шәп җырчылар, Хәмкәй, Локман, Фәтхулла — матур биючеләр... Сиптерәбез!» Ләкин андый күңелле кичәләр озакка бармый. Шул елның августында башланган Беренче бөтендөнья сугышы бу яшьләрнең күбесен юк итәчәк яки гарипләндереп кайтарачак. Озакламыйча җырчы Хәсән дә иптәшләре белән шунда китеп югалачак. Мирхәйдәр сугышка китүче Хәсәнне үз атына утыртып озата барган, аның моң-хәсрәтле соңгы җырлавын озак вакыт оныта алмаган. Хәсәннең госпитальдә үлү хәбәрен ишеткәч тә ул бик өзгәләнә. Менә 1916 елның 28 октябренә караган көндәлек язуы: «Күңелемә бик якын тоелган Хәсәннең лазаретта үлгәнлеген ишетеп иңрәдем. Моңлы җаның мәңге ямьнәрдә йөзсен, дус!.. Иленне күралмый тилмереп үлдеңме, яшь җан? Синең үлемең мине рухан газаплый... Синең матур хәрәкәтләрең, мәгъсүм кыяфәтең, саф тавышың күңелемдә кадерләп тирбәтелер, туган! Синең белән ике ел таныш булып, егерме тапкыр күрештем. Ямьле йөрешләр, күңелле утырышлар бар иде. Алар үтте, син үлдең, хуш!» Әдипнең «Җырчы Хәсәнгә» дип исемләнгән шигыре дә бар. Аның бер өлеше шушы икеюллык белән тәмамлана:

> Мин сөямен халкымны, син халыкның алтыны,
> Моңнар белән сызылып чыга яшь күңлеңнең ялкыны.

1914–1915 елларда Мирхәйдәрнең аерым шигырьләре матбугатта басыла, К.Лукашевичның тагын бер пьесасының тәрҗемәсе «Корым тазартучы» исеме белән «Ак юл» журналында дөнья күрә. Бу ике елда Орск яшьләре җиде мәртәбә спектакль куялар. Мирхәйдәрне иң сөендергәне — ниһаять, сәхнәдә яшь артистканың пәйда булуы. 1915 елда: «Өч мәртәбә театр уйнадык. Камилә туташ Гомәрова Орск сәхнәсе тарихында кызлардан беренче каһарман булды», — дип яза ул көндәлегенә. Ә аннан алдарак исә шул җәйдә Җүнәй авылында оста гармунчы Вафа Әдһәмов белән оч-

рашу-танышуы тасвир ителә. «Августның 2 се. Калага үтеп барган Юлык никрутлары белән күрешү. Вафа исемлесенең гармунны ифрат матур һәм сөйкемле кыланып уйнавы белән күңелемнең самими дуслыгын казануы... Бер елга калып, Орскидан кайтып барышында Вафа белән кабат утырыш: матур көйләр уйнавы, күңелемдә матур типлар, матур уйлар тудыруы», — дигән сүзләр теркәлгән ул очрашу турында.

Сугыш елларында аның күңелен тетрәткән тагын бер вакыйганы искә алыйк. Дүрткүл авылында кич утырганда, солдаттан гарипләнеп кайткан берәү йөрәк өзгеч иттереп бәет сыман бер җыр җырлый. Фаҗигале, тигезсез мәхәббәткә багышланган «Сәгадәтбану» җырын. Аның җырын тыңлагач та, Мирхәйдәрнең күңеле тетрәнә. Шул җырны отып алып, күңеле моңланган мизгелләрдә җырлый торган булып китә. 1916 елның җәендә Малмыж шәһәре бакчасында да «Җәмилә», «Сәгадәтбану» көйләрен моңланып җырлап утыруын көндәлегенә язып куйган. Бу җырга бәйле хатирәләр Мирхәйдәрнең энесе, Сәетгәрәй улы Сәгыйть ага истәлекләрендә дә телгә алына.

Европа мәмләкәтләренә тиң җир-биләмәгә ия Орск өязенең бер читендәрәк урнашкан Юлык авылы һәм җырчы, оста гармунчы Вафа дусты белән Мирхәйдәр Фәйзи тагын дүрт ел чамасы вакыт үткәч якыннанрак танышачак. Рәмиев байларның Юлык мәчете янәшәсендәге китапханәне саклап калу өчен, 1919 елның февралендә аны шунда эшкә җибәрәләр. Шул китүдән башлап аның төп эш урыны китапханә булачак. Юлык, Баймак һәм Темәс кебек алтын чыгару, алтын эшкәртү төбәгендәге эшче китапханәләрендә ул сигез ел чамасы эшләп ала. Арадан бер суык кышны — 1924 елның кышын — Казанда, Үзәк Шәрыкъ китапханәсенең балалар әдәбияты бүлегендә өши-туңа уздыра. (Мөгаен, нәкъ шул кышта аның күңелендә Г.Тукайның «Шүрәле» поэмасы нигезендә яңа бер әсәр язу уе да тугандыр әле. Шул фикерне дәлилләүче фактларга алдарак тукталырбыз.)

Кайбер җитди генә хезмәтләрдә Мирхәйдәр Фәйзинең унынчы елларда ук Башкортстан ягы авылларына йөреп, әйтик, Орскидан бик еракта урнашкан Бөре, Балтач тирәләренә барып, халык иҗаты үрнәкләрен барлаганлыгы бәян ителә. Икенче берәүләр аны вакытыннан алда, унынчы еллардан ук, китапханәче хезмәтен башкаручы дип күрсәтмәкчеләр. Кабатлап әйтергә кирәк, авторның көндәлекләрендә мондый сәяхәтләр һәм ул елларда китапханәче вазифасын башкару очраклары теркәлмәгән. Беренче мисалда авторлар әдипнең хәзерге Киров өлкәсе белән чиктәш булган Балтач, Шодаларга сәяхәт кылуларын үз төбәкләре белән бәйләргә тырышкан булса кирәк. Ә китапханәче хезмәтен үтәүгә Мирхәйдәр, алда әйтелгәнчә, 1919 елның февралендә генә керешә.

Анда да аның ул эшкә тотынуы очраклы рәвештә килеп чыга. Гражданнар сугышының Уралтау белән Җаек елгалары тирәсендәге озакка сузылган һәм иң авыр чоры 1918 елның урталары белән 1919 ел башларына туры килә. Шул дәвамлы сугыш-кырылышлардан соң ул төбәктә ваба (холера), тиф кебек зәхмәтләр кузгала. Ул авырулар, нигездә, кеше һәм хайван мәетләренең вакытында җиргә күмелмәгәнлегеннән барлыкка килә. Бу чирләр, ярлы яки бай булуга карамастан, һәркемне сагалап тора. 1918 елның кара көзендә Мирхәйдәр дә бер ай чамасы сырхаулап ала. Шәһәрдә иң бай нәсел, икенче гильдия сәүдәгәр Борнаевлар нәселеннән дә бер кыз ул фаҗигадән котылып кала алмый. Мирхәйдәр белән хат, фотолар алышып, сөешеп-күрешеп йөргән Гөлсирә Борнаева ноябрь башларында вабадан вафат була. Шул хәлләрдән соң туган-ыру арасында Мирхәйдәрне яман чирләр баскан шәһәрдән ераккарак озатып тору теләге туа. Һәм ул Орскидан йөз илле чакрымдагы берничә өркәчле биек Ирендек таулары артындагы Юлык авылына юллама ала.

1916 елның җәендә Орскига «Нур» театры артистлары килә. Театр җитәкчесе Сәхипҗамал Гыйззәтуллина белән Мирхәйдәр Фәйзи «Сәйяр» труппасының шәһәргә беренче сәфәр кылган көннәреннән таныш була. Бу юлы да ул сәхнәдә алар белән бергә берничә роль башкара.

Шул ук көннәрдә ерак Малмыж шәһәреннән борчулы хәбәр алына: Фатыйма апасының хәле начар икән. Мәшәкатьле озын сәфәргә чыгып китәсе була. Сәетгәрәй агасының Орскига кунакка килгән улы, унбиш яшьлек Сәгыйть белән алар 7 июль иртәсендә юлга кузгалалар. (Сәгыйть Гәрәй улы Фәйзуллин озак еллар Татарстан китап нәшриятында мөхәррир, тәрҗемәче булып эшләде. М.Фәйзинең 1957 елда нәшер ителгән ике томлыгын төзеп чыгаручы һәм әдипнең төп язма мирасын Казан университеты мирасханәсенә тапшыручы да ул булды.) Мирхәйдәр, Малмыжда берәр атна торганнан соң, мулла Сәетгәрәй агасы яшәгән Шодага юл тота. (Бу авыл хәзер Татарстанның Балтач районына керә.) Әдипнең көндәлегендә Шода авылы тирәлеге күренешләрен, анда яшәүчеләрнең гореф-гадәтләрен тасвирлауга багышланган битләр байтак. Аларны көндәлек сәхифәләре итеп түгел, саф әдәби әсәр битләре кебек мавыгып укыйсың. «Кешеләрнең киенү рәвеше дә бездәгенең тәмам киресе дип әйтерлек. Хатын-кызларда да аякта чабата, тула оек. Күбесенең өстендә кызыл күлмәк. Кызларның билендә матур алъяпкыч. Кырдан кайтканда кызлар бик киенешеп кайталар... Ялтырап торган уракларын кулларына тотып, ваграк атлап, нык басып китүләрен авылның иң матур күренешләреннән санарга ярый». Шушы сүзләр янәшәсендә мондый юллар да бар: «Иген уру машиналары татар авылларында таралмаган әле,

кул белән уралар. Җир өсте кызыл яулыклы абыстайлар белән тулган була».

Әмма бу авылда Мирхәйдәр күңеленә иң хуш килгәне яшьләрнең саф сулы чишмә буенда очрашу-аралашулары, шул тирәдәге болында яшьләр оештырган уеннар була. Үзенең алардан өлкәнрәк икәнлегенә карамастан, җырларга, мандолинада уйнарга һәвәс булган яшь күңелле Мирхәйдәр дә алар уенына кушылып китә. Үзеннән күпкә яшьрәк кызлар белән дус, сердәш булу дәрәҗәсенә ирешә... Шода авылына Мирхәйдәрнең 1923 елда килүе аеруча истәлекле. Унҗиде-унсигез яшьләрдәге бик чибәр күрше кызы Гыйлембану белән ул аеруча якын мөнәсәбәткә керә: аның сердәшенә әверелә. Яше утыздан ашканын онытып, ул шушы кызга тәмам гашыйк була. «Шодада көннәр бик күңелле уза. Бигрәк тә матур су буе манзарасы мине тәмам сихерләде... Гыйлембану Шодадагы көннәремнең таҗы булды. Аның белән бер күрешеп сөйләшү мең рәхәттән рәхәтрәк тоела...» Кызның күңелендә йөрткән егете барлыгын белгәч тә, теге егеткә карата бераз үч тә саклап йөри Мирхәйдәр. «Гыйлембану исеме исемә төшкәндә — сөенеп, Ибрай исемә төшкәндә көенеп китәм», — дип язып куя көндәлегенә. Үз-үзен белештермичә гыйшык утында яна башлавын аңлагач кына, ул авылдан тизрәк китәргә була. «Үзем китәм, күңелем кала... Хуш, Шода, хуш...» — дип уфтанып та куя. Ләкин бу авылдан киткәч тә, аның йөрәге тиз генә тынычланмый. Гыйлембану, аңа гыйшык тотып йөрүче тегермәнче егет тиз генә онытылмыйлар. Шушы яшь кызга булган хисләренең бер чеметемен ул Шодадан киткәч язган «Сәрвиназ» хикәясендә, «Ибрай яры янында» шигырендә чагылдырган:

Тау башында Сабир, Габдулла, мин,
Тау астында кызлар су ала;
Ал чиләген асып, вак-вак басып
Гыйлембану килгәч, бу бала
Алларына бәхте баскан кебек,
Күккә ашкан кебек куана, —

дип яза ул үзе турында.

Кызга гыйшык тотып, аңа өйләнергә йөргән Ибрайның шигырь авторына дус булганлыгына ишарә дә бар бу шигырьнең соңгы строфасында:

Ал кулыңны, көнләштермә егетен,
Яшь Ибрайның җанын кыйнама!
Ирексездән дуслык җимерелмәсен,
Су буеның ямен буяма!

«Сәрвиназ» хикәясендә исә шушы ук мәхәббәт өчпочмагы чак кына башкачарак тасвир ителә.

Мирхәйдәр Фәйзинең туганнары, дусларының көндәлек һәм

альбомнарына, аларга юллаган хат һәм фотосурәтләргә теркәлгән шигырь куплетлары да байтак. Җитмешенче елларда аларның бер өлешен — мин, бер өлешен Орск шәһәре музее хезмәткәре Татьяна Черкас, күпмесендер «Орский рабочий» газетасы мөхәррире Михаил Секрет тупларга тырышып караган идек. М.Секрет Мирхәйдәргә багышлап рус телендә документаль повесть язарга да хыялланды. Әсәренең өзекләрен үзе редакцияләгән газета битләрендә бастырып та чыгарган иде. Мирхәйдәрнең шигырь рәвешендәге ул истәлек язмаларында да Шода вакыйгасына бәйле берике куплет сакланган. Мәсәлән, абыйсының улы, булачак инженер Искәндәр альбомына ул түбәндәге сүзләрне яза:

«Икәү генә уйнадык,
Соңга калып.
Суын алып,
Биреп китте кулъяулык.
Көянтәсен җилкәләгәч,
Егетеннән иркәләнгәч,
Китте теләп саулыкны;
Җырлап калдым,
Болгап калдым
Җаныем чиккән яулыкны!

Бу (очрашу) 1924 ел, июнь 13 тә, җомга көн Шода авылында булган һәм язылган. Вакыйгасы, җыры, көе бергә бәйләнеп барды. Асылында «авыл кызы» урынында Гыйлембану тора. Үзем өчен бик сөйкемле хатирәмне синең альбомыңа теркәдем. Абыең М-Хәйдәр Фәйзи. 1924, 2 сентябрь, Җүнәй».

Шода авылында, элекке Сәетгәрәй мулла йортында, хәзер Мирхәйдәр Фәйзи тормышына һәм иҗатына багышланган музей эшли. Ул Татарстан хөкүмәте һәм Балтач районы җитәкчелеге тырышлыгы белән әдипнең тууына 100 ел тулган көннәрдә, 1991 елның көзендә ачылды. Мирхәйдәрнең өзелеп сөйгән, соңгы мәхәббәте булган, ай кебек аксыл йөзле, кара толымлы Гыйлембануга да, олыгаеп килүче әдипне ике ут арасында янарга мәҗбүр итүче Ибрайга да анда урын бирелгән.

## 5

Малмыж-Шода якларында йөреп кайтканнан соң, Мирхәйдәр Фәйзи яңа әсәр язарга керешәчәген белдерә. Менә аның 1916 елның 8 октябрендәге көндәлек язмасы: «Казан ягы авылларында йөреп кайттым. Бу яктагы авылларда күргән матур күренешләрдән файдаланып, «Сәгадәтбану» исемле пьеса язу уе туды. Көннәрем шул хакта мәшгуль булып уза башлады». Шушы юллардан соң берничә бит кенә арырак, 28 октябрьдә әдип җырчы Хәсәннең «лазаретта үлеп калуы» турындагы хәбәргә бәйле кайгы-хәсрәт сүзләрен

теркәгән. Бу көндәлек язмаларыннан күренә ки, булачак пьеса каһарманнары Хәлил, Исмәгыйль, Галиябану образларын тудырган дәвердә авторның күз алдында Шода авылы яшьләренең тормышяшәеше генә түгел, шулай ук Җүнәй белән Дүрткүл яшьләренең үзара бәйләнышлары да торган. Кайбер хезмәтләрнең авторлары язганча, Хәлил образына төп оеткыны салучы оста гармунчы һәм җырчы Вафа Әдһәмев кенә булмаган. Сәхнәдә атып үтереләчәк Хәлил артында, аңа сөялеп, фаҗигале язмышлы җырчы Хәсән дә тора, Шода авылы егете Ибраһим да шул тирәдә шәйләнә. Галиябану образы да ниндидер мифик бер Сәгадәтбану копиясе генә түгел. Ул образ артында Шода, Җүнәй, Дүрткүл кызлары шәүләсен дә, Орск сәхнәсендә бер кыш балкып алган «мөкаммәл кыяфәтле» Камилә туташ Гомәрова язмышы чагылышын да күреп була. (Камиләне нәкъ шул вакыттарак үзе теләмәгән, өлкәнрәк яшьтәге кешегә кияүгә бирәләр.) Әсәрнең тәүге исеменә карата да кайберәүләр белән бәхәскә керәсе килә. Сәгадәтбану исем-атамасын хәзерге татарчага күчерсәң, Бәхетлебану була. Бәхетлеме соң пьесада сурәтләнгән кыз? Юк, әлбәттә. Күз алдында сөйгән яры атып үтерелгән кыз берничек тә бәхетле була алмый. Миңа калса, Мирхәйдәр Фәйзи бу әсәрен язарга керешер алдыннан бәхетле кыз образын тудырмакчы булган. Әмма язып бетерү дәверендә инде ул аның язмышын үзгәрткән. Ә баштарак, пьеса исемен сайлаганда, аның күптәнге кумиры Галимҗан Ибраһимовның «Сөю — сәгадәт» әсәре йогынтысында булуы да бик ихтимал. Мирхәйдәр дә авыл яшьләренең үзара мөнәсәбәтләре, сөю-сөешүләре йогынтысында шушы әсәрен язарга утыра. (Г.Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романын укыганнан соң әсәрләнгән Мирхәйдәрнең тиз арада мәкалә язып, аны «Идел» газетасында бастыруын да истән чыгармыйк.)

Соңгы елларда татар һәм башкорт матбугатында (бигрәк тә Башкортстандагы күршеләрдә) «Галиябану» әсәренең язылу вакыты һәм анда тасвирланган вакыйгаларның җирлеге мәсьәләсендә байтак кына ялгыш фикерләр әйтелде һәм язылды. Имеш, ул пьеса Юлык вакыйгаларына бәйләп, Юлык авылында язылган. (Алда әйткәнемчә, Мирхәйдәр Юлыкка эшкә 1919 елның башында җибәрелә. 1921 елда ул Юлыкта «Кызыл йолдыз» драмасын яза.) Әле 2006 елда гына да Башкортстанда яшәүче бер татар журналисты Казанда басылган мәкаләсендә «Галиябану» Баймак төбәге вакыйгаларын чагылдыра, әсәр шунда язылган дигәнрәк фикер белән чыкты. Шундыйрак эчтәлекле «гыйльми язма»ларны укыгач, бер сорау туа: Мирхәйдәр көндәлекләрен алып укыганмы соң бу каләм әһелләре? Мирхәйдәр эзләреннән йөргәннәрме? Ул көндәлекләрдә акка кара белән язылган ич: «Галиябану» пьесасы 1916 елның октябрь урталарында языла башлый һәм өч айдан соң Орск шәһәрендә тәмамлана. 1917 елның башында ул Оренбургка, «Ширкәт» труп-

пасы режиссеры Вәли Мортазин-Иманскийга җибәрелә. Вәли, үз тәкъдимнәрен язып, пьесаны кире кайтара. Мирхәйдәр кульязмага үзе кирәкле тапкан өстәмәләрне кертә һәм аны тиз арада кабат Оренбургка озата. «Ширкәт» артистларына әсәр ошый, бик хуп күреп, алар аны тиз арада сәхнәгә чыгаралар. «Галиябану» Оренбург шәһәр театры бинасында шул елның 19 март кичендә халыкка тәкъдим ителә. Галиябану ролен татар халкының булачак күренекле артисты, мөлаем тембрлы тавышлы Сара Байкина, Хәлил ролен режиссер Вәли Мортазин үзе, Исмәгыйль ролен Госман Садыйков бик оста башкарып чыгалар. Алар уенын халык дәррәү кубып хуплый. Шул ук елның 15 декабрендә пьеса Оренбургта кабат уйнала. 1918 елның кышында исә ул Казан сәхнәсендә куела. Ә 1922 елда, Г.Ибраһимовның мактаулы кереш сүзе белән, Казанда аерым китап буларак басылып чыга.

«Галиябану»ның беренче мәртәбә сәхнәгә куелуын бозып күрсәткән тагын бер үкенечле фактны билгеләп үтмичә мөмкин түгел. Милләтебез абруен, данын дистә еллар дәвамында сакларга, акларга һәм пропагандаларга тиешле «Татар энциклопедиясе» китабының икенче томында, шушы әсәргә багышланган мәкаләсендә, театр белгече И.Илялова «беренче тапкыр Оренбургта аны «Нур» труппасы куйды» дип яза. Ә бу труппага багышланган махсус язмаларда исә «Нур» 1916 елның язында Оренбургтан китә, шул елның көзендә эшчәнлеген Уфада дәвам иттерә» дип белдерелгән. Бу очрак та кайберләребезнең Мирхәйдәр Фәйзи иҗатына һәм мирасына карата саксыз булганлыгын күрсәтә, минемчә. «Галиябану» пьесасына нигезләнеп эшләнгән бер кино әсәре авторының никадәр саксыз эш итүе турында безнең матбугатта бер-ике кәлимә сүз булган иде инде. Мирхәйдәрнең «Галиябану» пьесасында түгел, башка бер генә әсәрендә дә хатын-кызга карата мыскыллап карау, хатын-кыз образын пычратып тасвирлауны очрату мөмкин түгел. Үзе дә гомер бакый саф намуслы, чын зыялы, тәрбияле шәхес булган. Әсәрләреннән дә пакьлек, сафлык нуры бөркелеп тора.

Орск шәһәре артистлары да «Галиябану» әсәрен 1917 елның 29 декабрендә автор катнашында сәхнәләштерәләр. Монда Галиябану ролен икенче бер күренекле шәхес — Башкортстанның булачак халык артисты Майбәдәр (Маһибәдәр) Юсупова башкара. Галиябану — Бәдәрнең Орск сәхнәсендә уйнаган икенче роле. 1917 елда инде ул Идрис Багдановның «Югалган хатын» пьесасын куюда Люси псевдонимы белән катнашкан була. Соңрак та ул Орск сәхнәсендә берничә пьесада җырлы-биюле рольләрне башкара. Шул исәптән «Асылъяр»ны беренче мәртәбә сәхнәләштергәндә Бәдәр-Люси баш рольне башкара. Орскида укытучылар курсын тәмамлагач, ул төрле татар һәм башкорт мәктәпләрендә берничә ел укыта.

Һәвәскәр артистка Майбәдәрне 1926 елда Башкорт дәүләт театрына кабул итәләр. Тиз арада ул шул театрның йөзек кашына әверелә. (Дүрткүл халкы, Майбәдәрнең балачагы бездә үтте, ата-анасы безнең авылныкы, дип мактанып сөйлиләр.)

Орск сәхнәсендә уйнаучы артистлар, рәсми рәвештә театр труппасы оештырылмау һәм махсус театр ачылмау сәбәпле, Совет хакимияте дәверендә дә үзешчән булып калалар. Шул ук вакытта Мирхәйдәр Фәйзиләр чорыннан алып 1960 елларга кадәр шәһәр халкына даими рәвештә театр уеннарын уйнап киләләр. Үз рәсми театрларын ачарга омтылган очраклары да булгалый. Большевикларга каршы көрәшкән милләт вәкилләре белән бергә колчакчыларга ияреп Себергә киткән Габдулла Кариев, акылга килеп, 1919 елның башында аклар кулындагы Орск шәһәрендә туктала. (Адмирал Колчакның руслардан башка халыкларга якты йөз күрсәтергә теләмәвен, «кече» милләт вәкилләрен тиздән кәкре каен башына утыртасын бөек артист әйтерсең лә алдан сизенгән.) Орскига элегрәк елларда килгәләгән, аның зыялы байларын һәм М.Фәйзи тирәсенә берләшкән иптәшләрен яхшы белгән кеше буларак, бераз хәл алгач та ул монда труппа туплау эшенә керешә. Ул төбәктә сугыш афәте әле тәмам бетмәгән бер вакытта репетицияләрне башлап та җибәрә. Шул елларда бу вакыйгаларны яхшы белгән күренекле артист Хәким ага Сәлимҗанов ул көннәрне болайрак тасвирлый: «Габдулла Кариев килеп төште. Килү белән труппаны оештырып җибәрде. Бәхетемә, абыйларым да аның кул астында уйный башладылар. Кариев килгәч, халыкның театр белән кызыксынуы арта төште. Ул вакытта спектакльләр кую, театрга йөрү чын мәгънәсендә модага кереп китте». Ләкин шул ел урталарында ук Кариевны Казанга чакырып алалар. Аның урынына калган Мифтах Әпсәләмевне дә тиздән «Казан тартып ала». Бу вакытта Мирхәйдәр Фәйзи исә Баймак төбәгендә халыкны мәдәниятле итү, агарту эшләре белән шөгыльләнә. Юлыкта да, Баймакта да бер-бер артлы спектакльләр куя. Җир куеныннан алтын, бакыр ише байлыкларны чыгаручы эшчеләр арасында матбугат тарату, театр уеннары оештыру эшләре белән мәшгуль була. Шул рәвешле, Орскида милли театр үз вакытында ачылмыйча кала. Ә Орскидан байтакка кечерәк Баймакта соңлабрак булса да ул ачыла! Бу очракта да Мирхәйдәрнең тырышлыгы җилгә очмый, нәтиҗәсен бирә.

1920 елның май аенда Самара шәһәрендә З.Солтанов белән К.Тинчурин җитәкчелегендә ачылган драма артистлары студиясенә укырга Орск шәһәре һәвәскәрләреннән унлап кеше җибәрелә. Туган шәһәрләрендә рәсми театр ачылмау сәбәпле, Маһинур Казакова, Маһинур Хәсәнева, Рифгать Фәйзи, Зиннур Садыйков кебекләр үзләренә башка сәхнәләрне сайларга мәҗбүр булалар. Әйтик, Мирхәйдәргә эне тиешле Рифгать Шакирҗан улы Фәйзи соңрак

Башкорт драма театры сәхнәсендә артист һәм режиссер буларак таныла, «Башкортстанның халык артисты» дигән мактаулы исемгә лаек була. Егерменче еллардан башлап Орск шәһәрендә «Беренче май» исемен йөртүче татар клубы эшли, аның штатына драма артистлары эшчәнлеген оештыручы ике кеше билгеләнә. Соңгы шундый җитәкчеләрнең берсе мәшһүр шахматист Гата Камскийның бабасы, элегрәк төрле театрларда уйнаган профессиональ артист Г.Сабиров-Камский була. Ул клуб карамагындагы драма түгәрәгендә дистә еллар дәвамында сәхнәдән төшмичә уйнаган, шәһәр халкы күңелен яулаган чын артистлар бар иде. Мәсәлән, җырлы-биюле рольләрне дә, җитдирәкләрен дә бертигез камил башкаручы, унҗиде яшеннән клуб сәхнәсен икенче эш урыны итеп санаучы Зәйнәп Зарипованы шәһәр халкы бүген дә сагынып искә ала. Спектакльләрдә төрле типтагы рольләрне оста башкарудан тыш кичә, концертларны алып баручы да, Г.Тукай, Һ.Такташ, М.Җәлил әсәрләрен рәвешенә китереп, артистланып сәхнәдән укучы да Хөрмәт Хасиятуллин булды. Ул Орскида илленче еллар сәхнәсенең күрке иде. Ләкин 1960 елда, Н.Хрущевның милли мәсьәләгә караган тискәре әмерләре чыккач, ул клуб ябылды. Шул рәвешле, илле еллык тарихы булган Орск шәһәре милли театры да таркалды.

**6**

Чирек гасырлык иҗат гомерендә Мирхәйдәр Фәйзи җәмгысе 16 оригинал һәм 7 тәрҗемә пьеса авторы буларак таныла (кульъязмада сакланган әсәрләрен исәпкә алмаганда). Ике шигырь китабы, үзе җыеп туплаган «Халык җырлары» җыентыгы, кечерәк бер китаплык хикәяләр һәм җитмештән артыграк дәфтәрне берләштергән көндәлекләр дә — аның шома каләме белән язылган иҗат җимешләре. Аның драма әсәрләреннән «Авыл бәйрәме» (1913, Җүнәй — 1921, Юлык), «Урал суы буенда» (1918, Орск), «Асылъяр» (1919, Орск), «Кызыл йолдыз» (1921, Юлык), «Ак калфак» (1922, Темәс авылы), «Адашкан күңел» (Темәстә языла башлый, 1923 елда Уфада төгәлләнә) татар һәм башкорт театрлары тарафыннан һәммәсе дә кат-кат сәхнәләштерелгәннәр. «Кызыл йолдыз» белән «Адашкан күңел» пьесалары Татарстан Республикасы күләмендә оештырылган конкурсларда алдынгы урыннарны яулап алган әсәрләр. Бу төркемдәге пьесалар һәм «Галиябану» берничәшәр тапкыр Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә дә куела. Мондый бәхеткә сирәк драматурглар ирешә алган. Андый бәхетләләр исемлеге зур түгел. «Галиябану» музыкаль драмасы шундый жанрдагы беренче татарча пьеса рәвешендә дә, эшләнеше ягыннан камил, төгәл, җитлеккән әсәр буларак та милли җәүһәрләребезнең тәүгеләреннәндер. Ул әсәр татар сәхнәсенең сүнмәс бер йолдызы.

Элекке СССР мәмләкәтенә кергән төрки телдә эшләүче театрлар арасында «Галиябану»ны сәхнәләштермәгәне калмагандыр. Башка бер милләт җимеше булса, андый әсәр күптән инде рус теленә һәм башка телләргә тәрҗемә ителгән булыр иде.

Казан университеты китапханәсенең Кульъязмалар бүлегенә тапшырылган әдип мирасы арасында тагын берничә әсәрнең саклануы билгеле. Байтак еллар шул китапханәдә эшләгән, Мирхәйдәр Фәйзи тормышына һәм иҗатына багышлап рус телендә юка бер китапны нәшер итүдә катнашкан Диләрә ханым Абдуллина шул хакта менә ниләр яза: «Архивта әлегә кадәр беркайда да басылмаган, хәтта исемнәре дә тиешенчә билгеле булмаган пьесаларның кульъязмалары бар — «Китап», өч картинада, «Чүмеч баш», бер пәрдәле көлке әсәр, «Әмәти улы Мәмәти», бер пәрдәле көлке әсәр, «Ватык көзге янында», бер пәрдәле тәрҗемә пьеса... Язучы иҗат иткән башка жанрдагы әсәрләр дә байтак». Әйтергә кирәк, М.Фәйзинең кульъязмалары бу мирасханәдән тыш Гыйльми институт һәм Милли музей архивларында да саклана бит әле. Анда ниләр бар икән?

Узган гасыр башында Орскида туган һәм гомерен шул шәһәрдә уздырган инженер һәм фотожурналист Абдулла абый Исәнбаев Мирхәйдәрнең тагын бер пьесасы булуын сөйләгән иде. Габдулла Тукайның «Шүрәле»се җирлегендә ул егерменче елларда балалар өчен шул пьесаны язган була. 1924 елның җәендә балалар белән аны сәхнәләштерергә дә талпынып карый. Ләкин байларга каршы көрәш барган бер заманда онык-онычкаларын гимназиядә укыткан «Мостафа бай баласы»ның укучылар белән эшләвен хупламаучылар табыла. Мирхәйдәр үз шәһәреннән китәргә мәҗбүр була. А.Исәнбаев әйтүенчә, ул пьесаның кульъязмасы аңарда булырга тиеш икән. «Китап шкафларын актарганда килеп чыкса, мин сиңа хәбәр итәрмен», — дип вәгъдә бирде ул миңа 1971 елда. Ләкин озакламый Абдулла абый үлеп китте. Ә менә берничә хаты һәм Мостафа Фәйзуллин йортының ул төшергән фотосурәте миндә саклана. Шул йортка истәлек тактасы куелгач төшергән бер фото да бар иде, ләкин ул кайсыдыр редакциядән кире кайтмады, шул газетада чыккан шәүләсе генә калды.

Алда сурәтләнгән фактлардан күрәбез ки — татар театрының 100 еллык олуг юбилеена драматург Мирхәйдәр Фәйзинең керткән өлеше зур икән. Аны без икеләнмичә татар милли театрына нигез салучыларның берсе дип әйтергә хаклыбыз. Драматург буларак аның күпчелек пьесалары да үз вакытында сәхнәләштерелә, сәхнәдә уңыш казана. Димәк ки, аның әсәрләре артистларның, күпсанлы дәүләт театрлары һәм үзешчән төркем-труппаларның яшәешенә, үсешенә булышлык иткән. Икенчедән, Шакир Мөхәммәдъяров башлаган эшне дәвам иттерүче, бер шәһәр театр сөючеләренең һәм үзешчәннәренең әйдәүчесе буларак та аның хезмәте хөрмәтләүгә лаек. Әйе, ул Орск

шәһәре мөселманнары арасында иң беренче шәһәр күләмендә спектакльләр куеп йөрүче дә бит. Димәк, аны икеләнмичә Орск шәһәрендә беренче театрга нигез салучы дип әйтергә тулы хакыбыз бар.

Димәк, татар театрының 100 еллык юбилей тантанасында Мирхәйдәр Фәйзинең исеме дә зурлап телгә алынырга, искә төшерелергә бик тә хаклыдыр.

Соңгы сүз итеп аның иҗатын һәм исемен киләчәк буыннарга саклау кирәклеге турындагы фикерләремне дә белгертеп үтим.

1. Орск шәһәрендә ул яшәгән йорт диварына 1972 елда истәлек тактасы беркетелгән иде. (Язучылар берлеге исеменнән ул эшне башкаруда мин турыдан-туры катнаштым, ике мәртәбә барып, ул шәһәр җитәкчеләре белән сөйләштем. Хат-юллама копияләре әле дә миндә саклана.) Кызганыч ки, 1994 елда ул шәһәргә барганда без, Зөфәр Бәширов белән икебез, андый истәлек тактасын күрмәдек. Кемдер аны йолкып ташлаган. Аны алдыру турында рәсми карар булмады, дип аңлаттылар. Ул истәлек тактасын урынына кайтару чарасын күрәсе иде.

2. Мирхәйдәр Фәйзи 1928 елда хәзерге Баймак шәһәрендә вафат була һәм бик хөрмәтләп шәһәр уртасындагы революция каһарманнары каберлегендә җирләнә. Кабер өстенә гади генә таш та куела. 1980 елларда ул һәйкәлташ яңартылды. Миндә ул аксыл мәрмәр ташның фотосы да бар иде. Шул ук 1994 елда без ул кабер ташын очратмадык. Аның урынында тимер казык кына тырпаеп тора иде.

Шушы язмама тотыныр алдыннан, шәһәр үзәгендәге бер-ике китапханәгә кереп, Мирхәйдәр Фәйзинең 1957 елда чыккан икетомлыгын эзләгән идем. Китапханәләрдә юк андый китаплар. Милли китапханә фондында алар саклана. Ләкин ул икетомлыклар да, меңләгән куллар аша үтеп, тузып-таушалып беткәннәр инде. Мирхәйдәр Фәйзи кебек олуг шәхеснең китапларының илле ел дәвамында бер тапкыр да кабат басылмавы аяныч хәл, билгеле. Аның иң популяр әсәрләрен туплаган бер томлыгын һәм аерым китап итеп үзенең һәм атасының көндәлекләрен бастырырга күптән вакыт җиткәндер инде.

*«Казан утлары», 2007, № 2*

## МУСА ҖӘЛИЛ: ТУГАН ТӨБӘГЕ ҺӘМ МИРАСЫ

Халкыбызның батыр улы, күренекле шагыйрь һәм мәгълүм сәнгать эшлеклесе Муса Җәлилнең олуг юбилее — 100 еллыгы тиздән ил күләмендә зурлап билгеләп үтеләчәк. Дөресрәге, матбугатта бәян ителүенчә, ул олуг юбилей тантанасына багышлы вакыйгалар Россия Федерациясе биләмәсе белән генә чикләнмичә, Германия, Казакъстан, Төркия кебек ил-дәүләтләрдә дә билгелә-

нәсе икән. Муса Җәлил шәхесе шундый тантаналар үткәрүгә бик тә лаек. Андыйрак бәйрәмне ешрак кабатласаң да зыян итмәс иде әле. Ник дисәң, татар милләтен бөтендөнья халкы алдында данлаган сирәк шәхесләребезнең берсе бит ул. Чит җирләрдә дә зурлап искә алырга җыенганда, бөек шәхесебезне туган-үскән төбәгендә көтәләрме икән? Шагыйрьнең яшьлек эзләреннән әйләнеп кайтыйк әле.

## Орск

Бөек шагыйребез туган якларда үскән һәм күпмедер дәрәҗәдә аның яшьлек юлларыннан үткән кеше буларак, Муса Җәлил иҗаты һәм тормышы миңа да бик якын. Илленче еллар урталарында, мин Орск шәһәрендә эшли башлаган вакытта, «комсомол Мусаны» күреп белүчеләр, аның белән аралашкан кешеләр әле исән-сау иде. Әйтик, сәүдәгәр кызы, шагыйрьнең яшьтәше, чая, сөйкемле Мәрьям Бикбова шундыйлардан иде. Илле яшендә дә моңлы итеп борынгы озын көйләребезне җырлаучы Мәрьям апа «Шәрекъ клубы»нда Муса белән «сәхнәдәш» була. Ул җырлаганда шагыйрь һәрчак, мандолинада уйнап, аңа булышлык итә. «Кызлар, егетләр бергә сахрага да чыккалый идек. Бервакыт Мусалар тау арасыннан бер кочак тюльпан җыеп кайттылар», — дип искә ала иде ул. Икенче чордашы, Габдулла Мостафин, 1926 елда комсомол өяз комитетында Муса белән бергә эшли, аңардан инструктор эшләрен кабул итеп ала. Габдулла ага Мостафин илленче елларда Иске шәһәрдә партия райкомы секретаре иде, яшьләр белән очрашканда Муса белән авылларга, төрле оешмаларга бергә бару вакыйгаларын сөйләр иде. Муса Җәлил ул җәйдә күпмедер вакыт Габдуллаларда яши — аларның өйләре өяз комитетыннан ерак түгел, хәзерге Совет урамы башындагы түгәрәк күл артында гына була.

Бу шәһәргә сугыштан соң килеп төпләнгән Ситдыйка апа Чудина да яшь Мусаны яхшы хәтерли иде. Габдрахман Әпсәләмовның якташы булган бу апа үсмер чорында Мәскәүдә укыган, авылдашына ияреп Муса Җәлил оештырган әдәби түгәрәккә йөргән икән. Мусаны уртага алып, күмәкләп төшкән фоторәсеме дә бар иде. (Сиксәненче елларда ул фото шәһәр музеена тапшырыла.) Шәһәрдә нәшер ителгән «Орский рабочий», Оренбургта чыккан «Чкаловская правда», «Комсомольская племя» газеталарында ул елларда Муса Җәлилгә багышланган күпсанлы истәлекләр дә басылды. Шагыйрьнең өлкән сеңлесе Зәйнәп апаның берничә зур мәкаләсенең өлкә газеталарында урын алганлыгы хәтеремдә. Шәһәр музеенда шагыйрь тормышына бәйле ике стенд та бар. Берсендә аның өяз комитетында инструктор булган чоры беркадәр чагылдырыла, бергә эшләгән иптәшләре белән төшкән фоторәсем дә

шунда куелган. (Ул фото «Муса Җәлил» альбомнарында бар.) Зуррак икенче стенд музейның Бөек Ватан сугышына багышланган урта бер залында. Анда М.Җәлилгә сугышчан батырлыгы өчен Советлар Союзы Герое һәм иҗат батырлыгы өчен Ленин исемендәге Дәүләт бүләге бирелгәнлеге бәян ителә, шул бүләкләр бирелү турындагы Хөкүмәт карарларының күчермәләре һәм «Моабит дәфтәре» циклыннан бер шигыренең русчага тәрҗемәсе урнаштырылган иде. Иске шәһәрнең Пионер урамындагы элекке өяз комсомол комитеты урнашкан бинага Советлар Союзы Герое «...Муса Җәлил монда эшләде» дип, Карл Маркс урамындагы бер йортка (кайчандыр Мирхәйдәр Фәйзинең туганнары яшәгән ике катлы йорт) «1924–1925 елларда монда... Муса Җәлил яшәде» дип русча язылган истәлек такталары куелган иде. Соңрак, алтмышынчы еллар ахырында, шәһәр үзәгеннән ерактарак төзелгән «Биофабрика бистәсе»ндә Муса Җәлил исемендәге урам да барлыкка килә. (Кызганыч ки, узган ел Орскида булып кайткан Г.Камал исемендәге театр кешеләре әлеге истәлек такталарының кемнәр тарафыннандыр алынган булуын хәбәр иттеләр. Мирхәйдәр Фәйзи яшәгән йортка 1972 елда куелган истәлек тактасының да язмышы шундыйрак.)

Ачыклык кертеп китим: Муса яшәгәндә әле монда Урал елгасы борылышына сыенып утырган Иске шәһәр генә була. Уралсуның аръягындагы, Гөберлә тау итәгендәге Яңа шәһәр утызынчы елларда төзелә башлый.

Орск шәһәренә бәйләнешле тагын бер фактка тукталып үтәсем килә. Шагыйрьнең баҗасы язучы Мәхмүд Максуд истәлекләрендә Мусаның 1930 еллар башында Мәскәүдә Дәүләтшин фатирында яшәгәнлеге әйтеп кителә. Фатир хуҗасының исеме аталмый. Бу кеше Орск янәшәсендәге авылда туган, «Хөсәения» мәдрәсәсендә Муса белән бер чордарак укыган һәм революция башланыр елда гына шунда укыта да башлаган Габдулла Дәүләтшин булырга тиеш. Г.Дәүләтшин 1920–1921 елларда Орск төбәгендә зур «түрә» — милли комиссар була, шул ук елларда анда «Ирек йолдызы» газетасын да чыгара. Газетаның шәһәр музеенда сакланып калган бердәнбер санында, мәсәлән, Мусаның остазы Төхфәт Ченәкәйнең бер шигыре дә басылган. Шул вакытта Габдулла Дәүләтшин Мирхәйдәр Фәйзинең сеңлесе гимназистка Хәлимәгә өйләнә. 1921 елның августында алар Мәскәүгә — Коммунистик университетта укырга җибәреләләр. Утызынчы еллар ахырынача Мәскәүдә яшиләр. Шигем юк, Муса бер җәй нәкъ менә шушы элекке комиссар, «Хөсәения» буенча шәриктәше Габдулла фатирында торгандыр...

Муса Җәлилнең тууына 80 ел тулыр алдыннан, 1985 елның март башында, Татарстан Язучылар берлегенең ул вакыттагы рәисе Туфан Миңнуллин мине Оренбург төбәгенә командировкага җибәрде:

— Бар әле, туган, атна-ун көнләп ул якларда йөреп кайт. Орск, Оренбург шәһәрләрендә бөек якташларының олуг юбилеен ничек каршыларга җыеналар икән, шуларны төгәлрәк ачыкларга тырыш, — диде.

Сәяхәтемне яшьлек хатирәләренә бәйле Орскидан башлаган идем. Шәһәр үсә, киңәя төшкән. Анда яшәүчеләр саны 300 меңгә якынлашкан. Элеккечә үк халкының дүрттән бер өлеше чамасын татар, башкортлар тәшкил итә. (Мәсәлән, 1897 елда халык санын исәпкә алганда алар 22% чамасы булган.) Казакълар да очраштыргалый — шәһәр Казакъстанга чиктәш җирдә урнашкан. Ләкин калада милли мәдәният тармагы бик нык ярлыланган иде. СССР империясенең өченче җитәкчесе булган Никита Хрущевның «милли республикалардан читтә урнашкан милли мәктәп язмышын ата-аналар хәл итә» дигәнрәк эчтәлекле карары игълан ителгәннән соң (1957 елда шикелле), бик хәтәр хәлләр башлана. 1960 елларда Оренбург һәм Орск педагогия институтларының татар-башкорт бүлекләре бетерелә, өлкәнең ике төбәгендә эшләп килүче милли педагогия училищелары ябыла. Хәер, уку йортларына гына түгел, мәдәният учакларына да кагылган бу хәтәр карар. Орскида егерменче гасыр башыннан бирле эшләп килүче татар клубы (1930 еллардан «Беренче май» клубы) һәм кайчандыр шәһәр байлары сатып алган аерым бинада урнашкан, Совет чорында комиссар Мулланур Вахитов исемен йөрткән милли китапханә дә ябылган икән. (Ул китапханә элек милли рухны саклап тотучы бер җәмгыять булса, аның мөдире Лина Әбләисова шул җәмгыятьнең рәисе кебек иде.) Элекке «Шәрекъ клубы»нда һәм китапханә бинасында Дәрдемәнд, Мирхәйдәр Фәйзи, Муса Җәлил, шушы шәһәрдә туып үскән композитор Заһид Хәбибуллин, танылган сәхнә осталарыбыз Мифтах Әпсәләмев (артистлардан беренче Хезмәт Батыры), Галия Нигъмәтуллина, Хәким Сәлимҗанов, Г.Исхакый белән бергә «таңчылар» төркемен җитәкләгән, патша чорында Петербург университетын тәмамлаган, 1918 елда Г.Тукайга багышлап китап чыгарган Шакир Мөхәммәдъяров эзләре дә сакланырга тиеш иде. Шәһәр халкының милли җанлы кавеме хәтереннән алар мәңгегә сызып ташланган, юк ителгәннәр дияргә була. Дөрес, Яңа шәһәрдәге төбәк музеенда аларның кайберләре искә алына сыман. М.Фәйзинең балачак кәләпүше, З.Хәбибуллинның музейга кайчандыр мин бүләк иткән китабының тышлыгы, ирле-хатынлы Сәлимҗановлар катнашкан бер спектакльнең афишасы ишек төбендәге кечерәк бер бүлмәгә урнаштырылганнар. Боларга өстәп мин әле шушы шәһәрнең нигезен салуда катнашкан Петр I чоры полковнигы Котлымөхәммәт Тәфкилев исемен дә атый алам. Иске шәһәр үзәгендәге яшмалы тау түбәсендә биек бер каланча калкып тора иде. Шәһәр халкы телендә илленче-алтмышынчы елларда

әле алар «Полкауник тавы», «Полкауник каланчасы» дип йөртелделәр. Урал суы буенда яңа кальга төзелешенә җитәкчелек иткәндә ул «полкауник» хәтәр тупларын шул каланча мәйданчыгына менгереп куя торган була. (1994 елда ул каланчаның да рус руханилары тарафыннан «часовня» итеп үзгәртеп төзелүен күргән идек.)

1985 елда Орск шәһәр партия комитетының идеология буенча секретаре һәм башкарма комитетның мәдәният бүлеге мөдире герой-шагыйрьнең юбилеена ныклап тотыначакларын вәгъдә иткәннәр, эшләнәсе эшләрнең кайберләрен санап киткәннәр иде. Шәһәр музее киңәйтеләчәк, аңа өстәмә бина биреләчәк, шунда М.Җәлилгә тулы бер бүлек булдыру күздә тотылачак икән. Татар милләтеннән булган, язмышлары шәһәр белән бәйле башка шәхесләргә багышланган экспонатлар да шул яңа музейда урын алачак икән. Иске шәһәрдәге бер мәктәпкә шагыйрь исеме бирелүе дә ихтимал. «Шәһәр театры күптәннән бирле Мирхәйдәр Фәйзинең бер спектаклен кую турында хыяллана. Русчага тәрҗемә ителгән яхшы пьесасын җибәрүләрен үтенеп Казанга берничә тапкыр мөрәҗәгать иттек, уңай җавап килмәде. Казан театрлары үзләре дә безгә гастрольгә килмиләр», — дип зарланып та алган иде ул вакыттагы шәһәр мәдәният бүлеге мөдире Абдулла Ильясов. Аннары ике җитәкче бердәм рәвештә: «Татарстан хөкүмәте ярдәм иткән очракта боларның барысын да эшләп була. Әнә Украина һәр биш ел саен бездә Шевченко көннәрен уздыра. Тарас Шевченко һәйкәлен куюда да, аңа аерым музей булдыруда да алар булышты»,— диделәр. (Милли азатлык тарафдары Т.Шевченко Орск каласында сөргендә була, кайбер җитди әсәрләрен шул вакытта иҗат итә. М.Җәлилнең 1939 елда Киевка Т.Шевченко юбилеена баруы да Орск чоры хатирәләре белән бәйле булса кирәк.)

Шагыйрьнең 80 еллык юбилее алдыннан алып барылган ул сөйләшүләр нәтиҗәсез калды. Гадәттәгечә, Оренбург өлкәсендә буласы юбилей тантаналары өлкә шәһәре һәм М.Җәлилнең туган авылында уздырылган бәйрәм, очрашулар белән генә чикләнде. 1994 елда, Дәрдемәнд эзләре буйлап кабат Орскига килгәндә, ун ел чамасы элек үк эшләнергә тиешле эшләрнең үтәлмәгәнлегенә шаһит булдык. Элекке танышыбыз Абдулла Ильясов яңарак кына төбәк музее директоры итеп билгеләнгән иде. «Бернәрсә дә эшләнмәүнең төп сәбәбе — музейга дип тәгаенләнгән бинаның безгә бирелмәве... Ә элекке экспонатлар, стендлар барысы да үз урынында калды»,— диде ул.

Әлегә менә шундый мөнәсәбәт яши Орск төбәгендә Муса Җәлилгә һәм башка зыялыларыбызга карата. Бөек шәхесебезнең олуг юбилее — 100 еллыгы алдыннан үзебезгә дә милләттәшләребез яшәгән Орскины һәм шул тирәләрдәге татар авылларын да бер искә төшерәсе, туганлык җепләрен ныгыту өчен шул тарафка зур

тантананың бер десантын җибәрәсе иде. Милли каһарман һәм милли йолдызларыбызны шул төбәктә яшәүче халкыбыз күңеленнән бөтенләй юкка чыгармасын дисәк — мондый талпыныш бик тә заруридыр. Хәер, монда авыллар гына түгел, татарлар күпләп яшәгән тагын берничә шәһәр булуын да әйтеп китү кирәктер: Орскидан 10–15 чакрымда, Гөберлә тау сырты аша йөз мең кешеле Новотроицк — Орск-Хәлил металлургия комбинатының төп «йорты», 45 чакрымда илле-алтмыш мең кешеле бакыр мәгъдәне чыгаручы шахтерлар каласы Гай, 70–80 чакрымда шулай ук бакыр белән эш итүчеләр калалары Куандык, Медногорск. (Хәзерге Новотроицкиның кайчандыр Муса килеп-китеп йөргән Хабарное авылы булуын да белеп тору зыян итмәстер.) Казакъстанның бер өлкә башкаласы, татар бистәсе сакланган Актүбә шәһәренә дә Орскидан 140 кына чакрым. Шунда Заһид Хәбибуллин скрипкада уйный башлаган, уналты яшьтән Шамил Усманов кардәш-ыру тиешле Акчуриннар тегермәнендә эшләгән. Классик әдибебез Кави Нәҗминең яшүсмер чоры, дошманга каршы көрәшүче җәлилчеләр төркеменең хәзер җитәкчесе дип танылган Гайнан Курмашның сугыш алды еллары язмышы шушы Актүбәгә бәйле. Шәһәрнең «ком буранлы» урамнарыннан давыллы 1919 елның көзендә күпләребезнең бабалары — Беренче Татбригада сугышчылары үткәннәр...

Шуны да онытмасак икән — быел көз Орскида яшәгән һәм иң үтемле әсәрләрен шунда иҗат иткән икенче бер олуг шәхесебезнең дә юбилее булачак бит. Халкыбыз яшәгәндә сәхнә түреннән мәңге төшмәс «Галиябану»ларны тудырган Мирхәйдәр Фәйзинең тууына да быелның 1 ноябрендә 115 ел тулачак.

## Оренбург

Билгеле инде, бу шәһәрдә Муса Җәлилне белүчеләр, аны сагынып яшәүчеләр, мирасына табынучылар бермә-бер күп иде. 1985 елда әле сеңлесе Хәдичә апа да исән иде. Мәгариф, мәдәният өлкәсендә эшләүче кайберәүләр белән хат аша хәбәрләшеп яши идем. Шушы төбәк тарихы, биредә якты эз калдырган зыялылар язмышы белән кызыксынучылардан Мәдинә апа Рәхимкулова, Сабит ага Якупов, Мидхәт Пономарев, элекке татар мәктәбе директоры Якуб ага Шабакаев, 1906 елдан эшләп килүче милли китапханәнең мөдире Нажия Мөхсинова, алтмышынчы еллардан бирле милли-мәдәни хәрәкәткә җитәкчелек итүчеләрдән Фатих ага Солтанов, Зиннур Шакиров кебек асыл затлар яши иде анда. Дәрдемәнд, Риза Фәхретдинев, Г.Тукай, Ш.Камал, Һ.Такташ, М.Җәлил, С.Сәйдәшев һ.б. күренекле шәхесләрнең юбилейларына багышлап шәһәр күләмендә тантаналы җыелыш һәм кичәләрне уздыручылар да шушы кешеләр. Аларга бу эштә 1915 елда оешкан «Ширкәт» театры

традицияләрен авыр сугыш вакытында да өзмичә, таркатмыйча дәвам иттерүче «татар театр бригадасы» (элек өлкә филармониясе карамагында эшләде, хәзер аның җирлегендә М.Фәйзи исемендәге театр) артистлары булышты. М.Җәлилгә багышлап мәкаләләр язган, махсус китап чыгарган («Юность Мусы Джалиля», 1969) журналист Владимир Григорьевич Альтов та шунда яши. 1981 елда ул Чиләбе нәшриятында шагыйрьнең русча өчтомлыгын туплап чыгарды. Өлкә газетасы «Южный Урал»да 1984 елның 25 августында басылган аның күләмле «Подвиг Джалиля» мәкаләсен миңа Орскида ук укытканнар иде.

Шәһәргә килгәч тә иң әүвәл шулар белән очрашып сөйләштем. Сырхаулабрак торучы Хәдичә апа фатирына барып, аның киңәштәкъдимнәрен язып алдым. Абыйсына багышланган истәлек китабын үзем белән алган, юлда кабат укып чыккан идем...

Булачак шагыйрь бу шәһәргә беренче мәртәбә җиде яшендә аяк баса. Ишле гаиләле Мостафаны бирегә яшь баҗасы Хаммат Сәйфетдинев чакырып китерә. «Өч имана җирең белән сигез җанны туйдыру авырдыр. Сату-алу кәсебен беләсең, бәлки, калада уңарсың», — дигәндер ул, мөгаен. Үзе дә Мостафа авылыннан килеп, тормышын гади балта остасы булып башлаган кеше. Инде менә ул зур бер мәдрәсә утарын төзегән «Оста Хаммат»... «Хөсәения»нең өч катлы төп бинасын, мәчетен, имам өен, хезмәткәрләр өчен дип салынган ике катлы йортын торгызуда әйдәп йөрүчеләрдән булганы өчен Хөсәенев байлар Хамматны үз иткәннәрдер, күрәсең. Баҗасын шәһәргә китерәсе булгач та, аңа мәдрәсә хезмәткәрләре өеннән аерым торак бүлеп бирәләр. «Оренбургта без башта «Хөсәения»нең... ишегалдында яшәдек», — дип яза шагыйрьнең абыйсы. Шул рәвешле, Муса, кулына китап тотып бу мәдрәсәдә укый башлаганчы ук, аның хәлфәләре белән аралаша башлый. Соңыннанрак җизнәләре Мусаларга тагын бер мәртәбә игелекле кулын суза. 1926–1927 елларда, әнисе Рәхимә белән сеңлесе Хәдичәне Муса үз янына алдыргач, бер елдан артыграк алар Хамматның Урал аръягындагы утарының кече өендә торалар. Мусаның «Роща»да (русча «Зауральная роща»дан алынган) яшәү чоры байтак истәлекләрдә телгә алына. Өяз комсомол комитетының милли азчылык бүлеге мөдире Фатих Исхаков та берникадәр вакыт Мусаларда яшәвен яза. Зиннәт Әбдерәшитев тә, бергә «Роща»га йөрдек, минем кардәшләр анықыннан арырак яши иде, дип хәбәр итә. Мусаның шул елларда Оренбург педагогия техникумында укыган бер энесе Таһир Корбанов та «вакыт-вакыт мин дә «Роща»га барып куна идем» дип искә ала. Дөрес, анда кемнәрдә кунуын төгәл әйтми. Мөгаен, ул да әнисенең бертуганы булган Рәкия апаларында урын тапкандыр. Хаммат белән Рәкиянең кызлары Мәрьям дә Мусаның Оренбург чорына мөнәсәбәтле хатирәләрдә еш телгә алына. Ә улларын, «Хөсәени-

я»нең яшь хәлфәсе, гарәп теле укытучысы Әмирҗан Сәйфетдинев хаҗины ул дәвер комсомоллары нишләптер искә алырга «оныталар». Шәрекъ иленә барып белем эстәгән, шуннан хаҗи булып кайткан кешене искә алу чорында язылмаган шул ул хатирәләр. Гази ага Кашшаф кына аны бер тапкыр «җанлы энциклопедия» дип атый.

### Шагыйрь мирасы эзләре

Муса Җәлилнең олуг юбилеена багышланган бу язмамда элекке елларда ярым кинаяләп, читләтеп кенә искә алынган бер нәсел тармагына киңрәк тукталуымның төп сәбәбе — шагыйрь белән якыннан аралашкан кешеләр даирәсен берникадәр иңли төшүдер. Шул ук Мәрьям, Әмирҗаннар гаиләләрендә бүген дә әле Муса Җәлилгә бәйле истәлекләрнең яки хатларның сакланган булуы бик ихтимал бит. Бу кешеләр, шулай ук озак еллар Казан педагогия институтында укыткан Таһир Корбанов шагыйрьнең әнисе ягыннан туганнан туганнар була. Ә атасы ягыннан кем дә булса бармы соң? Иң беренче, әлбәттә, СССРның халык артисты Хәлил Әбҗәлилевне атарга кирәк. Т.Корбанов «Кызыл чәчәкләр» китабында (Казан, 1990), күренекле артистның авылга кайтып, Муса белән балалар театрын оештырып йөрү вакыйгаларын тасвир иткән урында: «Муса... башта Хәлил абыйсы ярдәменә таянды. Аларның аталары бер токымнан — Әбҗәлил баба токымыннан бит», — дип яза. Муса Җәлил дә бер автобиографиясендә «Габделҗәлил баба» нәселеннән икәнлеген теркәп калдырган. Хәер, мәшһүр артист та 1928 елга кадәр Җәлилев фамилиясен йөрткән. Хәлил ага ун яшькә кече энесен берәр урында искә аладырмы, миңа мәгълүм түгел. Мусалар Мәскәүдән кайтып Ершов урамындагы 4 нче йортта (ял паркы каршындагы) яшәгән вакытта аларны бергә шунда очратуын Таһир ага Корбанов искә төшергән иде. Хәлил агага эне тиешле Габдерахман Әбҗәлилев исә утызынчы елларда Оренбург татар педагогия техникумының директоры була...

Алда әйтелгәнчә, 1985 елның мартында Оренбургта булганда миңа шагыйрь белән якыннан аралашкан кайбер кешеләр белән очрашырга, хатирәләрен кәгазьгә төшергәләп алырга туры килгән иде. Берничә табышым да булды. 1920 елларда Оренбург губерна башкарма комитеты каршында РСФСР башкарма комитетының милләтләр эшләре буенча вәкиле булып торган Фатих Солтановның улы Надир ага бер зур фото бүләк итте. 1927 елның апрелендә алынган ул күмәк фотода Муса белән Фатих янәшә басып торалар. Алгы рәттә утыручылар арасында Мусаның дуслары Фатих Исхаков, Фатыйма Габина, Заһид Шәркый-Йосыповлар бар. Надир аганың Казандагы Муса Җәлил музеена тапшырырга дип биргән икенче бүләге дә кызыклы иде. Бик кечкенә форматлы

«В.И.Ленин» фотоальбомын Муса, Надирга бер яшь тулган көнне котлау сүзләре язып, 1927 елда Фатих дустына биргән була. (Ул бүләкне мин кайткач ук музейга тапшырдым. Шул еллардагы музей мөдире И.Миңһаҗева ул хакта матбугатта язып та чыкты.)

Муса Җәлилне күреп белүче олы яшьтәге ике ханым белән дә очраштык. Яшьлегендә Ченәкәй, Бабич, Җәлилләр белән якыннан аралашкан укытучы Гөлсем Хәсәневаның истәлек язмалары Мусага багышланган хатирә китапларына кергән. Дөрес, үзе әйтүенчә, алар бик тә кыскартылып басылганнар икән. Ә Мусаның «Хөсәения» буенча өлкәнрәк шәриктәше Заһид Шәркый-Йосыповка кардәш булган Майшәкәр апаның андый истәлек-хатирәләре басылмаган шикелле. Һәрхәлдә, очрашканда аларны искә алмады. Ул бераз яшьрәк буын вәкиле. Шулай да яшь Мусаны бик яхшы хәтерлим, Заһид белән еш аралашалар иде, Заһид эшләгән газета редакцияләренә килеп йөрүләре әле дә истә, дип сөйләде.

Кем соң ул Заһид Шәркый-Йосыпов? Мусаның чордашларының истәлек язмаларында аның исеме бөтенләй дә телгә алынмый. Чыгышы белән Урал суы буендагы Зубачи авылыннан. Г.Тукай, Ф.Әмирханнар белән якыннан аралашкан, мәгълүм театр тәнкыйтьчесе, 1914–1917 елларда «Шура» журналының икенче мөхәррире булган Кәбир Бәкергә авылдаш, димәк. Заһид 1914–1915 еллардан башлап, «Хөсәения»дә уку белән берүк вакытта, Рәмиевләрнең «Вакыт» басмаханәсендә хәреф җыю, корректорлык һөнәрләрен үзләштерә. Бәлки, кечерәк күләмле газета хәбәрләре дә язгалагандыр әле. Аны Шәриф Камал шәкерте дип тә атыйлар. Мөгаен, шулай булгандыр. Ш.Камалның да бит «Вакыт» басмаханәсендә корректор булып эшләве инкарь ителми. Тәүфыйк ага Сабитов, ул төбәкнең икенче «җанлы энциклопедиясе», Ш.Камалны Рәмиевләр монда махсус чакырып китерде, дип әйткән иде. Заһид Йосыпов белән бер үк чорда «Вакыт» типографиясендә Мусаның абыйсы Ибраһим да эшли. Димәк, алар элек мәдрәсәдә генә түгел, шул басмаханәдә дә очрашкалый торган булганнардыр. (Мусаның Ш.Камалга карата булган олы ихтирамы да шул елларда бөреләнгәндер, мөгаен. Дәрдемәндкә карата да олы ихтирам саклый. М.Максуд билгеләп үткәнчә, беренче дәвер шигырьләре дә Дәрдемәнд йогынтысында иҗат ителгәннәр.)

1918 елның гыйнвар ахырларында Оренбургта Совет хакимияте урнаштырыла. Замандашлары һәм туганнары истәлегенә караганда, Заһид «Вакыт» басмаханәсен хуҗаларыннан Совет хакимияте вәкиле буларак кабул итүдә катнаша. Һәм шул вакыттан бирле ул газета мөхәррире буларак таныла. 1970 елларда Оренбург дәүләт архивында гарәп язулы газета-журналларны барлау һәм тасвирлау эшен башкарган Сабит ага Якупов раславынча, Заһид Йосыпов 1918 елның февраль–июнь айларында «Оренбург

мөхбире» газетасы мөхәррире була. (Июль башында шәһәрне Дутов гаскәрләре яулап ала. Ш.Усмановның «Легион юлы» әсәрендә шул вакыйгалар тасвир ителгән. Анда без шәһәрдән чигенер алдыннан «үз газетасын тотып Заһид килеп керде» дигән җөмлә дә бар. «Татар энциклопедия сүзлеге»ндә мондый факт теркәлмәгән.) 1919 елның гыйнварында шәһәрне янә большевиклар ала, Совет хакимияте яклы газеталар яңадан чыга башлый. Шәһәрне азат итү бәрелешләренең берсендә авыр контузия алган Заһид, терелгәннән соң, кабат үз эшенә керешә. Баштарак аңа татар-башкорт телләрендә нәшер ителгән «Башкортстан хәбәрләре» газетасын чыгару вазифасы йөкләнә. Шул көздә үк бу газета Эстәрлетамакка күчерелгәч, ул 1920 елның маенда дөньяга килгән «Юксыллар сүзе»ндә эшли башлый. Газетаның мөхәррире Афзал Таһиров Оренбургтан киткәч, аның урынына кала. (Шул ук елларда анда Һ.Такташ сәркатиб була.) Оренбург губерна башкарма комитетына караган «Юксыллар...» ябылуга, РКП(б)ның Казакъстан өлкә комитеты Заһидка «Юл», аннары «Сабан» газеталарын нәшер итүне тапшыра. Казакъ (ул чорда Кыргыз-Кайсак) Автономияле Республикасы башкаласы 1925 ел урталарында Кызыл Урдага күчерелгәч тә Заһид Шәркый-Йосыпов Оренбургта 1926–1927 елларда «Очкын» газетасын редакцияли. Шуннан соң ул Мәскәүгә укырга җибәрелә. Укуын тәмамлагач, Донбасска — татарча чыгучы «Пролетар» газетасын редакцияләргә билгеләнә. Бер сөйләшкәндә Нәби ага Дәүли: «Ул мине шул газетага эшкә алды, кеше итте», — дигән иде. Яңадан Мәскәүгә кайткач, 1933 елның башында Заһид татарча чыгучы «Коммунист» газетасының мөхәррир урынбасары итеп билгеләнә. С.Якупов, М.Йосыпова һәм мөхәррирнең кызы Азат (Долгопрудное шәһәрендә яши иде) фикеренчә, Заһид Шәркый-Йосыпов гомер буе Мусага карата хәерхаһ булган, үзе эшләгән матбугатта аның әсәрләренә урын биргән, кирәге чыкканда үзен эшкә дә алган. Әйе, Мусаның 1924 елның җәендә «Юл» газетасында эшләвен дәлилләүче документ сакланган. «Коммунист» газетасына да аны эшкә якташы димләгән дигән фикердә дә хаклык бардыр, шәт. «Коммунист» ябылганнан соң, Заһид ике ел Кызыл профессура институтында укый, аны 1937 елда тәмамлагач, «Литературная газета»ның милли әдәбиятлар бүлегенә эшкә билгеләнә. 1941 елның сентябрендә Заһид Йосыповны Башкортстанның бер ерак районына партия эшенә җибәрәләр. 1961 елның язында ул Уфада вафат була.

Бу шәхеснең биографиясенә ярыйсы ук озаклап тукталуымны укучы гафу итәр. Аның хезмәт юлының Мусаның сугышка чаклы булган язмышы, биографиясе белән тыгыз үрелеп барганлыгы һәркемгә аңлашылгандыр, мөгаен. Ләкин алар хезмәттәшлегенең ни дәрәҗәдә, ничек үзара үрелгәнлеген ачыклап, тәгаенләп бете-

рәсе бар әле. Шушы көнгә кадәр әле берәүнең дә Оренбург төбәгендә 1917–1928 еллар аралыгында нәшер ителгән газета һәм журналларны җентекләп барлап чыкканы юк, минемчә. Ул эшне әлегә җиңел генә эшләп тә булмыйдыр. Ул елларда чыккан газета-журналларның сирәк саннары гына Оренбургта тупланган. Аларның күпләп сакланган өлеше хәзерге вакытта Кызыл Урда шәһәре дәүләт архивында булырга тиеш. Совет хакимияте дәверендә меңләгән битле язма мирасыбыз сакланган ул архивка барып барлардай кеше никтер табылмады. Ә бит Оренбургтан 1925 елдан соң алып кителгән ул архив турында матбугатта хәбәрләр күренгәләде.

Оренбургта соңрак та, 1935–1940 елларда, татарча «Коммунист» газетасы нәшер ителә. Анда соңгы елларда бүлек мөдире булган Ф.Кыргызбаев «Коммунист»ның В.И.Ленинга багышланган бер санында шагыйрьләрдән М.Җәлил белән Ф.Кәрим дә катнашты» дип хәбәр итә. КПССның өлкә комитеты архивында сакланган «Коммунист» саннары белән Ш.Хамматовның барып, танышып йөрүен беләм. «Табышлар бар анда», — дигән иде мәрхүм. Ләкин ул хакта матбугатта хәбәр итәргә өлгермәде шикелле.

Автобиографиясендә Муса Җәлил, мин 1916 елдан шигырь яза башладым, ди. Димәк ки, аның яшүсмер чор язмаларының басылмаган килеш кайсыбер редакция архивына эләгү мөмкинлеге дә бар. Мусаның Оренбург чоры чордашларыннан башкорт әдибе Сәгыйть Агиш һәм соңыннан Казанда яшәгән партия ветераны Гомәр Баязитов истәлек язмаларында: «Аның шигырьләре «Юксыллар сүзе» газетасында басылды», — дип белдерәләр. Ә шул елларда Оренбург төбәгендә яшәгән һәм иҗат иткән кешеләрдән Дәрдемәнд, Фатих Кәрими, Шәриф Камал, Мәхмүт Галәү, Һади Такташ, Шәехзадә Бабич, Афзал Таһиров әсәрләре яисә аларның башка төр язмалары ул газеталарда юк дип кем әйтә ала? Шамил Усманов 1919 елда Оренбургта ике пьеса язганлыгын хәбәр итә. Шәркый-Йосыповның да ул елларда өч-дүрт пьесасы Оренбург «Шәрекъ театры» тарафыннан сәхнәләштерелә. Мусаның да Казанда, Оренбургта һәм Уфада сәхнәләштерелгән пьесаларының исемнәре мәгълүм кебек. Муса Җәлил тормышын һәм иҗатын барлауга Шәмси ага Хамматов бик зур өлеш кертте, бай мәгълүматлы берничә китап бастырып чыгарды. Мусаның драма әсәрләренә, кайберләренең сәхнәләштерелү тарихына караган бер зур мәкаләсе дә басылган иде. Аның архивында җитди генә документларның, кызыклы хатирәләрнең саклануы да ихтимал. Анда шулай ук Мусаның Татрабфакта укыганда язган «Кала малае» пьесасы кульязмасы да бар иде. (Таһир Корбановның Мусага багышланган китабын редакцияләгәндә шул кульязмадан берничә битен кулланганыбыз хәтеремдә.)

Элекке елларда мыскылламыйча гына исемен атарга да ярама-

ган Габдерахман Шәфи Алмаз архивы белән танышырга да вакыт җиткәндер, мөгаен. Оренбург якларында туган, Казан сәүдәгәре Габделхәмид Казаков кияве булган, НЭП чорында башкалада яшәгән кеше. (Казан зинданыннан качкан Г.Баттал 1921 елда аның белән Мәскәүдә очрашуын, бу илдән качарга кирәклеге турында аның фикерен дә хуплавын искә ала.) Сугыштан соң гаиләсе белән Төркиягә китә, 1954 елда вафат була. Хатыны Әминә белән өч кызы шунда яшәп калалар. Алар шагыйрьне дә хәтерлиләрдер әле.

1920 еллар әсәрләре, бүгенге караштан чыгып бәяләгәндә, бәлки, җитлекмәгәнрәктер, эшләнеп тә бетмәгәннәрдер. Ләкин алар шул катлаулы дәвернең, иҗтимагый тормышыбызның йөз градуска кискен борылыш ясаган чорының көзгесе буларак кыйммәтле. (Араларында бик җитлеккән, ләкин Совет хакимияте хакимлек иткән утызынчы-алтмышынчы елларга эчтәлекләре белән ярашмаган әсәрләрнең булуы да бик мөмкин. Бу очракта, әлбәттә, М.Җәлил мирасы гына күз алдында тотылмый.) Ул хезмәтләр, халкыбызның мирасы буларак бергә тупланып, фәнни оешмаларыбызның мирасханәсендә сакланырга тиешләр. Шуңа күрә аларны эзләү, табу бик тә мөһим бурыч. Шул ук егерменче елларда Оренбургта нәшер ителгән һәм Кызыл Урда архивына бервакытта илтеп салынган казакъ матбугатына күз төшереп чыгу да зыян итмәс иде. Мусаның казакъ телен камил белүе турында күп яздык ич. Үз чорының казакъ әдипләре белән аның дустанә мөнәсәбәттә булуына да дәлилләр җитәрлек. Әйтик, булачак Социалистик Хезмәт Батыры Габит Мөсрепов белән Муса Мәскәү шәһәренең бер бистә кызларына өйләнәләр. Габитның каенатасы Гимад Тимербаев Мусаның үзе исән чактагы беренче бюстын ясый. Муса белән бер үк вакытта Оренбургта шагыйрьләр Сәкен Сәйфуллин, Галимҗан Ибраһимов шәкерте Бәембәт Майлин, Мохтар Әүэзов (соңрак прозаик буларак таныла) эшлиләр. «Хөсәения» мәдрәсәсе җирлегендә оешкан рабфакта Сабит Моканов, Габидин Мостафин, Габит Мөсреповлар укый. Башка аксакалларыбыз да ул елларда казакъ каләмдәшләре белән бик якыннан аралашканнар. Шул чор казакъ матбугатында аларның үз әсәрләре урын алмаган очракта да, алар хакында кызыклы язмаларның урнаштырылган булуы бик тә ихтимал. 1920–1925 еллар аралыгында Оренбургта казакъча түбәндәге көндәлек һәм айлык матбугат нәшер ителә: «Кызыл Казакъстан» (әдәби-сәяси журнал), «Енбекше казакъ» («Эшчән казакъ»), «Жас казакъ», «Ортак» («Иптәш»).

Оренбургта нәшер ителгән татар һәм казакъ матбугаты, шул елларда анда чыккан татарча һәм казакъча китаплар барысы да диярлек Рәмиевләрнең «Вакыт» басмаханәсе җирлегендә дөнья күрәләр. 1925–1926 еллардагы күченеш чорында шул басмаханәнең бай архивы да Кызыл Урдага барып чыккандыр. (Китап тари-

хын барлаучы Әбрар ага Кәримуллин «1920 елда «Вакыт» басмаханәсе бетерелә» дип хата яза. Минемчә, бетерелми ул, фәкать хуҗасын алыштыра.)

Муса Җәлилнең 100 еллык юбилеен бөтен халкыбыз түземсезләнеп, онытылмаслык очрашулар булуына зур өметләр баглап көтеп кала. Җәлил язмышына һәм иҗатына караган яңа ачышлар, яңа табышлар булырына да өметләрне өзәсе килми. Үзебезнең республика җитәкчелеге аңа әзерлек турында да күптән кайгыртып куйды — ике ел элек үк махсус карар кабул итте, зур суммада акча билгеләде. Россия хөкүмәте дә читтә калмаска ниятли — тантананы уздыручы дәүләт комиссиясен билгели, күпмедер акча да бүлеп бирә. Инде ул юбилей көннәрен, атналарга, айларга сузып, тиешле дәрәҗәдә үткәреп җибәрәсе генә кала. Юбилей, тантана көннәре безнең бөтен ил, бөтендөнья буйлап таралган милләтебезне тагын да берләштерү, бер-беребезгә якынайту кебек зур максатыбызга якын китерелеп үткәрелсен иде. Кайларгадыр ашыкпошык барып, биеп-җырлап кына олуг юбилейларны уздырган вакытларыбыз күп булды инде. Барган җирдә көтеп торучы милләттәшләр белән җитди рәвештә аралашу, фикер туплашу заманнары да җитте шикелле. Амин, шулай була күрсен!

Шушыларга өстәп кино сәнгатенә кагылышлы үз фикеремне һәм тәкъдимемне дә белдерәсем килә. Муса Җәлилнең тормыш юлын чагылдырган, иҗатын зурлаган бер төпле, җитди документаль фильм төшерелүен күпләребез көтә. Ул эшләнәме, юкмы — әйтә алмыйм. Сиксән еллыгы алдыннан шул мәсьәлә үзебездә кузгатылгач, акча юк, пленка юк, аны эшләрдәй кеше юк дигәнрәк җавап бирелгән иде. Шул «юклар»га сылтау итеп бүгенге көнгәчә Казаннан читтә яшәп иҗат иткән олуг шәхесләребез Дәрдемәнд, Риза Фәхретдинев, Мирхәйдәр Фәйзиләргә багышлы бер җитди телевизион тапшыру да оештыра алганыбыз юк әлегә. Дөрес, 1980 елларда Мәскәүдә яшәүче кинорежиссер Йолдыз Карамышева 4 серияле телевизион фильм эшләү хыялы белән йөрде. Нишләптер аның ул хезмәтен миңа күрергә насыйп булмады. Андый хезмәт тәгәлләнеп бетмәгән очракта да җәмәгатьчелеккә кат-кат тәкъдим ителергә тиештер, мөгаен. Минем карашымча, Муса Җәлилгә багышлы документаль фильм өч мөстәкыйль өлештән торырга, әдәби жанр таләбенчә, трилогия рәвешендә булырга тиеш. Беренче өлешкә Мусаның яшьлек чоры, аның Мостафа авылына, Орск каласына, Оренбургка бәйле язмышы сыярга, икенчесенә Мәскәүдә һәм Казанда эшләү еллары керергә, өченчесендә гомеренең соңгы, фаҗигале айлары чагылдырылырга тиеш. Эпилог өлешендә олуг шәхесләрнең аңа һәм иҗатына карата булган фикерләрен бирергә кирәк.

*«Мәдәни җомга», 2006, 27 гыйнв.–3 февр.*

# Ал бакча җимешләре

# КАЗАН — ТАТАРНЫҢ МӘККӘСЕ

Бөтендөнья буйлап сибелгән татар халкы өчен Казан шәһәре Мәккә булса, Матбугат йорты — аның Кәгъбәседер. Серле китап дөньясына мөкиббән булган һәркем өчен Бауман урамындагы унтугызынчы йорт изге йорт санала. Ул адресны һәркем яттан беләдер, мөгаен. Монда урнашкан мәһабәт бинада безнең телдә төрле-төрле эчтәлекле китаплар басыла. Ул китапларда зур тормыш чагылышлары, өлкән буын зыялыларының укучыга җиткерәсе килгән уй-фикерләре, фатихасы урын алган.

Биш катлы Матбугат йорты шәһәрнең матур, җыйнак бер урамының кыл урталыгында урнашкан. Аның беренче катында бинаның буеннан-буена сузылган китап кибете генә иде элек. Дүртенче катында исә китап чыгаручы мөхәррирләр — бу йортның баш әүлиялары эшләп утыра. Башка бихисап бүлмәләрдә элегрәк елларда көндәлек һәм айлык татар матбугатына «җан өрелде». Әйе, җир йөзенең барлык кыйтгаларында үз укучысы булган «Азат хатын», «Казан утлары», «Чаян», «Ялкын» журналлары, «Кызыл Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан»), «Яшь ленинчы», «Татарстан яшьләре» газеталары да кырык ел дәвамында шушы бинада «төпләнеп» чыгарылды. Хәзер газета-журнал редакцияләреннән бушаган мәйданның бер өлешендә «Мәгариф» нәшрияты эшли. «Мәдәни җомга» газетасы редакциясе дә шунда урнашты. Монда татарның иң зыялы, иң танылган әдип вә журналистлары эшләгән. Татарстан язучыларының төп штабы-идарәсе дә, аның карамагындагы Тукай клубы да шушында урнашкан иде. Атна саен ул клубта кызыклы очрашулар үткәрелеп килде. Ике йөз урындыклы клуб залында еш кына басып торучылар да күп була иде. Әдипләр сүзен тыңларга, фатиха алырга дип шәһәрнең төрле почмагыннан олысы-кечесе килер иде. Ул клуб мөнбәреннән күренекле язучыларыбыз Мирсәй Әмир, Гомәр Бәширов, Кави Нәҗми, Ибраһим Гази, Афзал Шамов, Сибгат Хәким, Мостай Кәрим, Нажар Нәҗми, Сәйфи Кудаш, Гариф Ахунов, Равил Фәйзуллиннар гына түгел, Мәскәүдә яшәп иҗат итүчеләрдән Александр Фадеев, Сергей Михалков, Людмила Татьяничева, Николай Доризо, Евгений Евтушенко, аның беренче җәмәгате Белла Ахмадуллиналар, безгә кардәш әдәбият вәкилләреннән Гафур Голәм, Кайсын Кулиев, Чыңгыз Айтматов, Олҗас Сөләйманов һ.б бик күп олуг фикер һәм сүз ияләре китап сөючеләребезгә фатиха бирделәр, нотык сөйләделәр.

Бу йорт адресы безгә бала чактан, мәктәптә уку елларыннан бирле мәгълүм. Уралтау сыртларының бер почмагында — Казаннан мең чакрым ераклыкта урнашкан Искавыл мәктәбе һәм авыл советы китапханәләренә шушы бинада нәшер ителгән дәрес-

лекләр, газета-журналлар, матур әдәбият үрнәкләре авыр сугыш елларында да бер тоткарлыксыз диярлек килеп торды. Авылның карты-яше даими рәвештә татар матбугатын шуннан алып укый ала иде. Яшүсмерләр арасында кич утырып, күмәкләп китап уку гадәте бар иде. Бервакыт без, сугыш чоры балалары, Габдрахман Әпсәләмовның сугыш вакыйгаларын тасвирлаган «Зәңгәр кыя» китабын бик кызыксынып укып чыктык та, үз уй-тойгыларыбызны белдереп, Казанга — Матбугат йорты адресына хат юлладык. Ерак Оренбург төбәгеннән җибәрелгән ул хатны, бәлкем, авторның үзенә үк тапшырганнардыр. Меңләгән рәхмәт хатларының берсе буларак, ул да авторга укучылар күңелендә мәңге сакланачак яңадан-яңа әсәрләрен иҗат итәргә ярдәм иткәндер...

Изге Кәгъбә дәрәҗәсендә күңелгә якын булган Матбугат йортының затлы мәрмәр баскычларына тәүге тапкыр 1961 елның гыйнвар аенда аяк бастым. Казанга килеп урнашкан гына идем әле. «Совет әдәбияты», «Азат хатын», «Татарстан яшьләре» редакцияләре хадимнәре белән якыннанрак танышасым, аралашасым килә иде. Иң әүвәл нишләптер «Азат хатын»да эшләүчеләр белән якынаеп киттем. Аларның эш бүлмәләре дә иң якында: икенче катка күтәрелүгә үк уң һәм сул тарафтагы ишекләргә «Азат хатын» дип язып куелган. Ул вакытта анда Рашат ага Гайнанов җаваплы сәркатиб, Хәсән Сарьян, Розалина ханым Нуруллина бүлек мөдирләре иде. Килгән, күрешкән саен сөйләшерлек сүз табыла — Рашат ага да, Сарьян да Башкортстаннан — Урал ягы кешеләре булып чыкты. Сарьян әле Уфадан яңарак килгән, монда эшли генә башлаган икән. Татар Мәккәсенә күченеп килер алдыннан гына мин дә Уралтауның башкаласы саналган Уфада берничә ай яшәп киткән идем. Андагы яшьрәк буын язучылар, матбугат әһелләре белән дә беркадәр танышлыгым бар. Якташым яшь шагыйрь Шәрәф Әхмәмәтев «Кызыл таң» газетасы оештырган «әдәби укулар»га мине дә ияртеп баргалады. Очрашулар еш кына газетаның әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире, шагыйрь Рафаэль Сафинның кояш нурына балкыган иркен эш бүлмәсендә яисә якындагы университет бинасында оештырыла иде. Шунда шигырь язу, әдәби әсәргә тема сайлау кебек нәрсәләр турында иплән кенә гәпләшәләр, шигырь сөйлиләр. Анда Шәрәф дустым, Рәшит Фазлыев, Фәнил Арсаев, Бари Ногманов ише яшь иҗатчылар гына түгел, шул чорда ук дан казана башлаган яисә казанган шәхесләрдән Әхмәт Гайсин, Әнгам Атнабаев, Нажар Нәҗми, Язучылар оешмасының яшь көчләре белән эш алып баручы вәкиле Муса Гали дә булалар иде...

Казанда «Азат хатын» редакциясенә, оста әңгәмәдәш Сарьянның кысан эш бүлмәсенә дә язучылар күп йөри иде. Уңга китүче коридорның аргы башындарак урнашкан «Чаян» редакциясеннән Аяз Гыйләҗев, Мәдинә Маликова, күршедәге «Ялкын» бүлмәлә-

рендә утырып эшләүче Габделхәй Сабитов, Илдар Юзеев, алардан арырак урнашкан «Совет әдәбияты» тарафыннан Вакыйф Нуруллин, Малик Хәмитев, Рәшит Гәрәйләр килә. Кайберсе килә-килешкә Сарьян өстәлендә яткан «Алтынчәч» кабына үрелеп папирос ала, «Алтынчәч»нең хуш исен бүлмәңә таратып җибәрик» дигән була. Шушы бүлмәдә һәм соңрак Сарьян фатирында миңа үзем бик хөрмәт иткән Нәкый Исәнбәт, Әмирхан Еники, Фатих Хөсни кебек зыялылар белән якыннанрак танышу да насыйп булды. Ул елларда әле Әмирхан аганың «Йөрәк сере» повесте телдән төшми, матбугатта да, телдән дә мактала, шуңа күрә әдипнең күңеле бик көр, йөзе балкыр иде.

«Совет әдәбияты» журналы редакциясе элегрәк елларда — Гомәр Разин (Бәширов), Кави Нәҗми, Гази Кашшафлар аңа җитәкчелек иткәндә — бинаның иң өске катында, Тукай клубының кечерәк арткы бүлмәсендә урнашкан була. Соңрак ул редакциягә дә икенче катның сул коридоры башында өч бүлмә бүлеп бирелә. Шунда ук Язучылар берлегенә билгеләнгән өч-дүрт бүлмә һәм язучылар китапханәсе урнашкан иде. Коридорның ул очында да һәрдаим җанлылык сизелә. «Ялкын» редакциясе белән язучылар оешмалары урнашкан ике арада кечерәк кенә фойе бар — төштән соң шул «көфер почмагы»на үзара гәп корырга, әдәбият түрәләрен күреп, ни-нәрсәләрдер хәл итәргә дип язучылар җыела башлый. Фойеның бер тарафында язучыларның дивар газетасы — колач ярым киңлегендәге «Тынгысыз каләм» эленеп тора. Анда язучыларның көлкеле шаржларын күреп, бер-берсенә карата язылган төртмәле шигырьләрен укып, рәхәтләнеп, шаркылдашып көлеп торырга була. Мәсәлән, бервакыт анда Гамил Афзалның Гомәр Бәширов иҗатына карата язылган усал гына төртмә сүзләре эленеп торды. Гомәр аганың ике зур романы («Туган ягым — яшел бишек», «Җидегән чишмә») язылып бетмәгән бер дәвердә ел аралаш «Сиваш» белән «Намус» китапларының нәшер ителүенә кинаяләп, шагыйрь 7–8 юллык шигырен: «Бир Нәфисәң кияүгә», — дип тәмамлый. Ә Нәби Дәүлинең Тел, әдәбият һәм тарих институтында (Фәннәр академиясе филиалында) эшләүче галимнәрнең гыйлем өлкәсендә сүлпән кыймылдауларына кинаяләп язган төртмә шигырен «Филләр ял иткән оешма» дип исемләгәне хәтеремдә. Соңрак «Тынгысыз каләм» битләрендә «Тмин» имзасы белән язылган кызыклы мәзәкләр, мәрхүм Фаил Шәфигуллин һ.б. «тел бистәләре»нең дә төртмәле юллары еш күренә башлаган иде. (Кызганыч ки, ул язмалар хәзер югалган. Язучылар берлеге сиксәненче еллар башында яңа бинага күчәр алдыннан эленеп торган берничә «газета» гына Ләбиб Лерон сандыгында саклана.)

Бу «почмак»ка гәп корырга язучылар һәм өстәге катларда урнашкан төрле редакцияләрдә эшләүчеләр генә түгел, олы һәм урта

буын артистлар да килә. Еш кына монда күренекле шахматист Рәшит Нәҗметдиновны да күрергә була иде. Ул, гадәттә, тиз-тиз атлап, «Казан утлары» исеме белән чыга башлаган әдәби журналның шахматчылар җыела торган арткы бүлмәсенә үтеп китә. Анда аны «шахмат жене кагылган» язучылар, журналның бүлек мөдирләре Яхъя Халитов, Вакыйф Нуруллин, «Татарстан коммунисты» журналы хезмәткәре Сәгыйть Хафизов, клуб мөдире Маннур Сатаров көтеп ала. Эш сәгате тәмамланыр алдыннан гына иң маһир шахматист — күренекле әдип Шәйхи Маннур да килеп җитәр иде. Ул елларда: «Матбугат йортын иң соңгы ябып чыгучылар ике Маннур булыр», — дип тә шаярткаладылар.

1967 елның яз башыннан мин дә, шушы «язучылар почмагы»ның кечерәк бер «кетәге»нә кереп утырып, Әдәби фонд оешмасында эшли башладым. Фойеның бер читендәге эш бүлмәм бик тар булса да, кеше күп килә, ишек бер дә ябылып тормый иде. Чөнки язучыларның тормышына, көнкүрешенә кагылышлы байтак мәсьәлә минем шул «кетәк» бүлмәмдә хәл ителә диярлек. Авырып китүчеләрнең авырган көннәренә түләү, ял һәм иҗат йортларына путевкалар юллау, җитди авыручыларны хастаханәләргә урнаштыру һ.б. мәшәкатьләр көн дә туып кына тора. Мин эшли башлаганда, Мәскәү тарафыннан рәсми танылган йөз унбиш язучы, шул чамага якын вафат булган язучы гаиләсе һәм алтмышлап башлап язучы исемлектә теркәлгән иде. Язучылар берлеге рәисе Мирсәй ага Әмир мине эшкә алганда, ярым шаярып:

— Скрипка көйли беләсеңме? — дип сорады.

— Юк, — дидем.

— Бездә бит кешеләр бик үзенчәлекле холыклы... Үз өстәле янында утырганда язучы үзе түрә дә, баш та. Сафка бастырсаң да бит алар барысы да «мин первый» дип кенә җавап бирәселәр...

Әңгәмәгә Зәки Нури кушыла:

— Элекке урынында өч мең кеше белән эшләгән. Безнең скрипканы көйләргә дә тиз өйрәнер. Үзе дә каләм тоткалый, язучыларның күбесе белән таныш, — диде.

Шул рәвешле миңа уналты-унҗиде ел язучылар «скрипка»сын көйләргә-җайларга туры килде. Рәисләр, рәис урынбасарлары бер-бер артлы алышынып беттеләр. Оешма җитәкчелегенә Мирсәй агадан соң Ибраһим Гази, аннары Зәки Нури, Гариф Ахунов килде. Аларның беренче урынбасарлары Гариф Ахунов, Ренат Харис, Равил Фәйзуллин, Фәрваз Миңнуллин, Мөсәгыйт Хәбибуллин кебек танылган шагыйрьләр, прозаиклар булдылар. Бергәбергә эшләү дәверендә байтак кына уң эшләр башкарылды, күп кенә язучылар яңа фатирларга күчте. Затлы шифаханәләрдә ял итеп, көч-куәт җыйганнан соң, илнең төрле почмагындагы иҗат йортларына йөреп иҗат иттеләр. Аларның иҗат җимешләрен

Матбугат йортының дүртенче катында эшләгән мәгълүматлы мөхәррирләр китап рәвешенә китереп нәшер итә тордылар. Китап сөючеләр дә Матбугат йортында басылып чыккан ул китапларны көтеп ала, тиз арада үзара бүлешеп бетерә иделәр. Көндәлек матбугат битләрендә яисә язучылар белән очрашу вакытларында: «Китап җитми!», «Урыннарга китап әз килә!» — дип оран салырлар иде. Ул елларда иң аз тиражлы чәчмә әсәрле китап ун-унбиш мең данәдә нәшер ителер, балалар өчен чыгарылганнарының тиражы йөз меңгә җитәр иде. Үтте бугай андый заманалар.

Шулай да изге Кәгъбәбезгә тиң Матбугат йортыбыз мәңге яши бирсен. Һәм шулай яшәр дә әле ул! Китап сүзенә игътибарлы булу, китапка баш ия белүне мин өлкәннәр фатихасын тоеп, аны кабул итеп яшәү дип аңлыйм. Ә өлкәннәр фатихасы һәрберебезгә бик кирәк ул.

*«Мәдәни җомга», 2006, 23 июнь*

## ӘДӘБИ ФОНД СӘХИФӘЛӘРЕ

Мәгълүм ки, СССР Әдәби фондын оештыру турындагы карар СССРда яшәүче язучыларның Беренче съездында, 1934 елның августында кабул ителә һәм шунда ук аның дәүләт оешмалары тарафыннан хупланган Уставы да раслана. Әдәби фондның (сөйләм телендә — Литфонд) төп максаты — язучыларга уңайлы иҗат шартларын тудырудан гыйбарәт. Ул фондка (бабаларыбызчарак итеп әйтсәк — вакыфка) язучының тормыш-көнкүреш шартларын яхшырту, сәламәтлеген саклау, иҗат итү мөмкинлекләрен булдыру һәм иҗтимагый-сәяси белемен үстерүгә булышу бурычлары йөкләнә. Фондка тупланасы акчаны исә язучының «иҗат җимеше»н товарга әйләндерүче оешмалар — китап-журнал нәшриятлары, театрлар, концерт заллары хөкүмәт карары белән расланган бер күләмдә (хезмәте өчен автор алган «каләм» хакының ничәдер процентына тиң рәвештә) күчерергә тиеш була. Фонд шул керемнәр исәбенә яши.

Уставта бәян ителгәнчә, Әдәби фонд кереме исәбенә СССР Язучылар берлеге идарәсе аппаратын, Мәскәүдәге Үзәк язучылар йортын (ЦДЛ), М.Горький исемендәге Әдәбият институтын һәм аның карамагында эшләүче икееллык югары әдәбият курсларын тоту каралган иде. Айлап-еллап уздырылган махсус курс-семинарлар (сценарий язучыларның еллык курслары, сугыш турында, авыл хуҗалыгы турында һ.б. төр семинар-курслар) эшчәнлеге дә Әдәби фонд кереме исәбенә оештырыла иде. Җитмешенче елларда шушы оешмаларны һәм курсларны «ашатуга» елына уртача 2,5 млн. сум акча тотыла килде. Чит илләр белән эшләү комиссиясенең генә дә

еллык чыгымы СССР Әдәби фонды карамагындагы күпсанлы иҗат йортлары чыгымыннан ким булмады. Бу чыгымнарның бер өлешен «Литературная газета» һәм «Советский писатель» нәшриятының өстәмә кереме исәбенә каплауны үтенеп партия Үзәк Комитетына берничә мөрәҗәгать кабул ителде. (Совет хакимияте дәверендә барлык матбугат органнарының кереме Үзәк Комитет карамагына күчерелде. Мәсәлән, «Казан утлары» журналы гына да шул хисапка һәр елны 450–500 мең чамасы керем акчасын күчереп барды. Журнал редакциясе тарафыннан уздырылган әдәби конкурсларда җиңүчеләргә дә бүләкне керем исәбенә түли алмыйча, Әдәби фонд өлешеннән бүлеп бирәләр иде.) 1979 елның декабрендә, ниһаять, иң югары дәрәҗәдә кабул ителгән карар нигезендә СССР Язучылар берлеге идарәсе аппаратын тотуга каралган ярты миллионлык чыгымны каплауны «Литературная газета»га йөкләделәр. Шушы саннардан күренә ки, Әдәби фондка аерым бер язучының тормыш-көнкүрешен уңай якка үзгәртергә омтылудан тыш башка төр зур бурычлар да йөкләнгән була.

Россиядә Хәйрия җәмгыяте рәвешендәге беренче рәсми «язучылар фонды» унтугызынчы йөзнең алтмышынчы елларында ук та барлыкка килә. Аны И.Тургенев, И.Гончаров һ.б. күренекле рус әдипләре (барлыгы җиде кеше) оештыралар. Ләкин фондның кулланыш даирәсе тар, кереме дә санаулы гына була. Чөнки фондка ярдәм итәргә теләгән язучылар, башка төр меценатлар акчаны үз кесәләреннән түлиләр (спонсорлар булалар), ягъни ул даими рәвештә тулыландырылып тормый. Ул фондка тупланган акча матди яктан авырлык кичергән сәләтле язучыга яисә билгеле бер оста каләм иясенең фәкыйрьлектә калган гаиләсенә ярдәм итү өчен тотыла. Революциягә чаклы татар дөньясында шуңа охшаш берәр төрле хәйрия оешмасының оешуы мәгълүм түгел.

Совет хакимияте урнашкач, НЭП чорында, мондый үзара ярдәмләшү тәртибе җанланып ала. Ваграк берничә шундый Хәйрия җәмгыяте тергезелә. Аннары, 1920 еллар ахырында, ул традицияне рәсми рәвештә оешкан язучылар төркемнәре (эшчеләргә мөнәсәбәтле РАПП, ТАПП яки иректә караштa торучы сул фронт һ.б.) дәвам иттерәләр, үз фондларын оештыралар. Шул елларда беренче иҗат йортлары барлыкка килә: Кырымның көнчыгышында, Куктүбә авылы янәшәсендәге рәссам һәм шагыйрь Максимилиан Волошинның һәм Мәскәү өлкәсенең көнбатышында, Руза елгасы янәшәсендәге әдип Александр Серафимовичның дачасы шул максат өчен сатып алына. (Мәскәүдән 60–70 чакрымдагы «А.Серафимович исемендәге Малеевка иҗат йорты»нда 1931 елның көзендә Хәсән Туфан белән берничә язучының иҗат итеп ятулары турында истәлекләр бар. Аларның шунда бергә төшкән фоторәсемнәре дә матбугатта басылды.)



*Казакъстанның күренекле галиме, дипломат Морад Әүэзов (мәшһүр әдип Мохтар Әүэзов белән милләттәшебез Фатима Габитованың улы) белән бергә Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Разил Вәлиев, «Фән» нәшриятының баш мөхәррире Булат Хәмидуллин. 2004*

*Арчада Гариф Ахунов һәйкәле янәшәсендә. 2004, 18 сентябрь*





*Татарстан китап нәшриятында Җиңү көнен билгеләп үтү. Сулдан уңга: Республиканың сугыш һәм хәрби хезмәт ветераннары советы рәисе Әхәт Юлашев, нәшрият директоры Дамир Шакиров, нәшрият ветераннары советы рәисе урынбасары Лирон Хәмидуллин. 2005, 5 май*

*Оренбург Каргалысында очрашу. Сулдан уңга: «Сәет бистәсе» китабы авторы, табиб һәм эшмәкәр Әнвәр Искәндәрев, Россия күләмендә танылган документаль фильмнар авторларының берсе, авылга нигез салучы Сәгыйд Хәялин токымыннан булган Рафаэль Хәялин, Лирон Хәмидуллин. 2006*





*Казакъстан язучылары һәм галимнәре белән Казанда очрашу. Янәшәдә — шагыйрь һәм галим Олжас Сөләйманов. 2004*

*Милли әдәбиятлар вәкилләре — галим һәм әдипләрдән бер төркем Ленино-Кокушкинода*





*Татар энциклопедиясе институтында Татарстан Фәннәр академиясенең Мактау грамотасын тапшыру көне. 2007*

*СССР Дәүләт бүләге иясе Давыт Көгелтинов белән әңгәмә.*
*Сулдан уңга: Давыт Көгелтинов, Шамил Маннапов, Мөдәррис Мусин, Гәрәй Рәхим, Лирон Хәмидуллин. 1981*



СССР Әдәби фондының Татарстан бүлеге 1934 елда ук оештырыла. Аны барлыкка китерүдә Язучылар берлеге идарәсе рәисе Кави Нәҗми актив катнаша. СССР Әдәби фондының урындагы вәкиле (уполномоченные) вазифасын үтәү К.Нәҗминең якын танышы, элекке хәрби Закир Самитовка тапшырыла. (Җитмешенче елларда Самат Шакирның Гражданнар сугышында милли батальон комиссары булган З.Самитовка багышлы әдәби очерклары басылды.) Хәрби тәртипкә күнеккән З.Самитов йөкләнгән бурычны бик тырышып үти: нәшрияттан, театрлардан кергән акча исәбенә барлык язучы гаиләләренә утын, күмер китертә. (Гомәр ага Бәширов сөйләвенчә, ташкүмер тутырылган капчыкларны арбадан үз җилкәсенә салып та ташый торган була.) Югары Ослан авылында шәхси йортларда «бүлмәләр арендалап», «Язучылар дачасы»н оештыра. Әдәби әсәр язудан арыгач язучылар иркенләп ял да итсен дип, берничә көймә һәм кечерәк бер катер сатып ала. (Югары Ослан дачаларында язучыларның ничек эшләүләре һәм ял итүләре турында истәлекләр булгалады. Шул исәптән Муса Җәлил белән бергәләп Шота Руставилиның «Юлбарыс тиресен ябынган батыр» дастанын Идел өстендә «Литфонд көймәсендә» йөзгәндә күмәкләп тәрҗемә итүләре турында да хәбәрләр булды.)

Әмма ләкин Закир Самитовның язмышы фаҗигале тәмамлана. 1937 елда аны Кави Нәҗми белән бер вакытта кулга алалар. Хатыны, мәрхүмә Зәйнәп апаның һәм кызы Розаның (Казанда, Татарстан урамындагы йортларның берсендә яши) сөйләүләренчә, З.Самитовның төп гаебе Кави Нәҗмигә якынлык һәм Ялтада дәваланып ятучы авыру Галимҗан Ибраһимовка ярдәм итеп тору, аның белән хат алышуларга мөнәсәбәтле була. Мин Әдәби фондта эшләгән дәвердә 1937–1940 елларга караган «Карарлар кенәгәсе» саклана иде. (Ләкин туксанынчы еллар урталарында, Язучылар берлеге яңа бинага күчкәннән соң кабат эзләсәм дә, аны таба алмадым. Анда ул чор язучылар язмышына, шул исәптән Хәсән ага Туфанга кагылышлы язмалар да бар иде.) Шунда Мәскәүдән килгән вәкил катнашында 1938 елның башында уздырылган бер утырыш протоколы да теркәлгән иде. Ул утырышта З.Самитовның кемнәргәдер буйсынып күп акча тотуы, арендага йортлар, катерлар алуы бәян ителә, шулар өчен ул гаепле дип белдерелә. Билгеле, гаепләнүче үзе утырышта катнашмый. Аның инде ул вакытта атып үтерелгән булуы да ихтимал. Бу документның фәкать гаепнең исәннәр өстенә дә төшмәвен тәэмин итү өчен генә оештырылуы чамалана иде.

Закир Самитов башлаган эшне тиздән шагыйрь Әхмәт Исхак дәвам иттерә һәм ул вазифаны сугышка киткәнче башкара (1938–1942). Әдәби фонд бүлекчәсенең баш хисапчысы хезмәтен бу ва-

кытта яшь шагыйрь, 1925–1928 елларда «Ислам баласы» кулъязма журналын чыгаруда катнашкан Исхак Закиров үти. Соңрак ул сугышта вафат була.

З.Самитов 1938 елның гыйнвар урталарында Пелөтән төрмәсендә атып үтерелгән. Зәйнәп Самитова Иске бистә кешеләре аркылы иренең хәлен белгәләп, ашамлык җибәргәләп торган. Һәлак булу көнен һәм төрмәдән чыгарып җирлисе төнне дә аңа хәбәр иткәннәр. Тоткыннарны, гадәттә, атнага бер генә чыгарып күмә торган булганнар. Казанның Архангель зиратында ул иренең үле гәүдәсен үзе каршылый, тоткыннарның «күмәк кабере» булган чокырдан ике-өч метрга читкәрәк илтеп җирли. Зәйнәп апа раславынча, шул ук атнада төрмә хастаханәсендә вафат булган Галимҗан Ибраһимовның гәүдәсен дә ире белән бер чанада алып чыгалар. Илленче еллар урталарында Г.Ибраһимовның аклануы турында хәбәр алынгач, аның кайда җирләнүен ачыклау өчен җитди комиссия оештырыла. «Әдипнең кайда җирләнүен ачыклау акты»на сугыш алды елларында төрмәдә эшләгән кешеләр, шул исәптән бер татар табибәсе сөйләгәннәр белән бергә Зәйнәп апа хатирәләре дә теркәлә. Шул документ нигезендә шаһитлар күрсәткән «күмәк чокыр» өстенә классик әдибебез Галимҗан Ибраһимов истәлегенә затлы кабер ташы урнаштырыла. Шуннан өч-дүрт адымда гына Закир Самитов каберенә куелган гадирәк язулы таш та бар. Ул һәйкәл-ташларны кую чыгымнарын Әдәби фондның Татарстан бүлеге күтәрде.

Сугыш алды елларында Әдәби фонд бүлеге карамагында клуб ачыла. Китапханә оештыру турында карар кабул ителә. Алар өчен Бауман урамындагы Матбугат йортының бишенче катында махсус бүлмәләр арендага алына. Татар әдәбиятында, татар матбугатында еш телгә алынган, 1950–1990 еллар аралыгында әдәбият сөючеләрнең яратып йөргән урынына әверелгән Г.Тукай исемендәге язучылар клубы иде ул. Әдәби фонд акчасына җан асрады. Илленче еллардан башлап клуб мөдире вазифасын шагыйрьләр Маннур Саттаров, Гөлшат Зәйнашева, аннары Котдус Дәүләтшин, Лариса Сәйфуллина (1965–1980), Әхмәт Рәшитов (1980–1993) башкардылар.

Әдәби фонд штатында булган Язучылар китапханәсе рәсми рәвештә 1946 елда ачыла. Китапханәнең беренче мөдире Сорур Еникиева-Сүнчәләева була. Аңардан соң эшләгән ханымның исем-фамилиясе хәзер истән чыккан, илленче еллар ахырында аның педагогия институты китапханәсенә күчүе генә мәгълүм. Аннары шактый вакыт анда Нәсимә Гобәйдуллина-Вәлиуллина (1960–1969), Шәһидә Максудова-Ахунова (1969–1983), Римма Миңнуллина (1983–2004) эшләделәр. (Туксанынчы еллар урталарыннан мөдиргә эш хакын Язучылар берлеге идарәсе түли башлады.)

1968 елдан китапханәгә башкорт телендәге «Агыйдел»дән кала тугандаш төрки телдә чыгучы тагын берничә журнал алдырылды (казакъча «Жулдыз», үзбәкчә «Шәрык юлдузы», кыргызча «Алатау»). Ләкин язучылар алар белән кызыксынмадылар диярлек (Н.Арслан, Ә.Исхак, Н.Исәнбәттән тыш). Шул сәбәпле аларны алдыру туктатылды.

Бөек Ватан сугышы башлангач, Татарстанга Мәскәү, Ленинград һ.б. зур шәһәрләрдән завод-фабрикалар һәм анда эшләүче йөз меңнәрчә кеше күчеп килә. СССР Фәннәр академиясе һәм аның кайбер институтлары ике-өч ел дәвамында Казанда эшлиләр. СССР Язучылар берлегенең оешмалары, шул исәптән СССР Әдәби фонды идарәсе эшчәнлекләрен Казанда һәм Чистайда дәвам итterәләр. Язучылар берлегенә караган «Советский писатель» нәшрияты, «Знамя», «Иностранная литература» һ.б. журнал редакцияләре монда эвакуацияләнә. Бауман урамындагы Матбугат йорты бүлмәләре, шул исәптән Тукай клубы бинасы илкүләм танылган язучы, журналистларның һәм аларның гаиләләренең торак йортына әверелә. Шул дәвердә Язучылар берлегендә һәм Әдәби фонд бүлекчәсендә эшләгән Гази Кашшаф белән Әхмәт Исхак агалар хәтерләвенчә, аларга үз вазифаларын үтәүдән тыш (яу кырындагы сугышчылар белән элемтә тоту, «Совет әдәбияты» журналын вакытында чыгару һәм язучы гаиләләренә ярдәм итәргә тырышу) эвакуацияләнгән язучыларны урнаштыру һәм көндәлек кирәк-ярак белән тәэмин итү бурычы да йөкләнгән була.

Шушы уңайдан бер фаҗигале язмышка тукталып үтмичә һич мөмкин түгел. Чөнки аның язмышында Әдәби фонд оешмасының да катнашы бар. Сүз күренекле рус шагыйрәсе Марина Цветаеваның үлеменә бәйле вакыйгалар һәм шул тирәдә «куерган» мәсьәләләр турында бара. Мәгълүм ки, гомеренең соңгы ике-өч атнасын ул Татарстан җирендә уздырган. Хәзер аның ул көннәренә һәм үлеменә карата төрле хәбәрләр таратыла. Шулар арасында уйдырмалары да бихисап. Элегрәк елларда хәтта татар халкына карата әйтелгән гайбәт сүзләрен дә ишеткәләргә туры килгәләде. Кайбер Мәскәү кешеләре: «Татары убили ее»,— дип әйткәләүдән дә тартынмадылар. Янәсе, Алабугада татарлар аны эшкә урнаштырмаганнар. Әйе, М.Цветаева да сугыш афәтеннән качып килеп Татарстанга сыенган йөз меңләгән качакның берсе була. Татарстан җиренә ул Мәскәү Язучылар оешмасы вәкилләре белән бергә эвакуацияләнеп килә. Ләкин аны «үз» каләмдәшләре бөтенләй дә үз итеп бетермиләр. Чөнки ул да бит элегрәк Совет хакимиятен үз итеп бетермәгән, чит илгә киткән була. Утызынчы еллар ахырында гына Мәскәүгә әйләнеп кайта. 1941 елның җәендә Мәскәүне бер корабта ташлап киткән язучыларның күпчелеге (язучылар саны гына алтмыштан ашкан, һәрберсенең гаиләсе, ә кайберләре-

нең әле «домработница»сы да бар) һәм СССР Әдәби фонды җитәкчелеге Чистай каласында төпләнә, кечерәк дәрәҗәле ваграк төркемнәрне Алабуга, Бөрсет тирәләренә озаталар. М.И.Цветаева уналты яшьлек улы белән Алабугага эләгә. Әмма Чистай каласына, андагы каләмдәшләре янына баргалап йөри. Чистайда эшли башлаган СССР Язучылар берлеге оешмаларына эш сорап мөрәҗәгать итә. Андагы бер түрә әдиптән «һичьюгы, Литфонд столовыенда савыт-саба юарга булса да алуын» үтенә. Ләкин аны беркая да эшкә алмыйлар. Шуннан кайткач та шагыйрә асылынып үлә. Аны шәһәр зиратының бер почмагына җирлиләр. (Динйолалар үзенә кул салучыны зиратка кертмәү ягында бит.)

Алтмышынчы еллар урталарында, М.И.Цветаева иҗатына әһәмият бирелә башлаган бер вакытта, аның каберен табу һәм истәлек ташы кую мәсьәләсе кузгатыла. Бу хакта СССР Язучылар берлеге идарәсенең махсус карары чыга. Шул карар нигезендә комиссия төзелә. Аның эшендә Алабуга шәһәре җитәкчелеге дә катнаша. М.Цветаеваны күмешеп йөргән, аның белән аралашкан кешеләр барлана. Шулар сөйләгәнгә нигезләнеп, кабер урыны билгеләнә, шул хакта «ачыклау акты» төзелә.

1967 елның декабрь башында Казанга Мәскәү вәкиле килде. (Исем-фамилиясен оныткanмын инде, Язучылар берлегенең шул замандагы кечерәк бер түрәсе иде.) Татарстан Язучылар берлеге идарәсе җаваплы секретаре Зәки Нури, әлеге вәкил һәм мин шәһәрнең Коммуналь хуҗалык җитәкчелеге карамагына бардык, фаҗигале үлем белән үлгән күренекле рус шагыйрәсе каберенә куярга лаек булырдай затлы кабер ташы табып бирүен үтендек. Ул елларда затлы кабер ташын табуы бик тә читен иде. Икенче көнне безгә андый ташны күрсәттеләр — алсурак төстәге матур гранит иде ул. Мәскәү вәкиленә таш ошады. Аңа нинди сүзләр язасын күрсәтеп, билгеләнгән акчаның тиз арада Казанга күчереләсен белдереп, вәкил китеп тә барды. 1968 елның җәендә ул ташны Алабуга зиратына илтеп урнаштырдык. Машинада аны ул вакыттагы яшь шагыйрь Зөлфәт озата барды. Ташны урынына кую эшләрен Алабуга шәһәре идарәсе башкарды. Шулай итеп, элек Татарстанга бәйләнеше булмаган, хәтта ки шигырьләрендә татар халкына карата берничә мыскыллау сүзе кулланудан да тайчанмаган күренекле рус шагыйрәсе безнең изге җиребездә җирләнде. Аны олылап без кабере өстенә затлы истәлек ташы куйдык. Урыны җәннәттә булсын!

Сугыштан соң СССР Әдәби фондының Татарстандагы вәкиле итеп язучы Халикъ Садри билгеләнә (1945–1954). Олы яшьтә булуына карамастан, ул сугышта катнаша, полк комиссары була. Яралана. Кызыл Йолдыз һәм Икенче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары белән бүләкләнә. Сугышка кадәр ун ел чамасы «Спар-

так» аяк киемнәре фабрикасы директоры була. Димәк, абруйлы, тәҗрибәле җитәкче. Әдәби фонд эшчәнлеген дә тиз җайга сала. Бигрәк тә Язучылар берлеге идарәсе башлыгы Гомәр ага Бәширов белән бик килешеп эшлиләр. Язучыларның иҗади активлыгына куәт өстәү максатыннан чыгып, кечерәк бер Иҗат йортын төзү кирәклеген Мәскәү белән үзебезнең республика җитәкчелеге алдында дәлилләп чыгуга ирешәләр. Ул елларда барлык Союздаш республикаларда да шундый йортлар ачыла (Азәрбайҗанда — «Шәүлән», Әрмәнстанда — «Севан», Үзбәкстанда — «Дүрмән», Киев янәшәсендә — «Ирпень» һ.б.). Сугышка чаклы Татарстанда, Тәтеш шәһәре янында, алпавыт Молоствовларның элекке утарында да шундый бер иҗат йорты эшләп килгән. Турыдан-туры Мәскәүгә буйсынган булса да, татар язучылары да анда барып иркенләп эшләп һәм, режимлы ашау-эчү оештырылганлыктан беркадәр савыгып, ял итеп кайта торган булганнар. Сугыш башлану белән, анда яралыларны савыктыру пункты ачыла һәм инде кабат СССР Әдәби фонды карамагына кайтарылмый. Тәтеш янәшәсендәге иҗат йортында җәмгысе унбишләп эш бүлмәсе була. 1954 елда шул чамада ук эш бүлмәсе булдыруга исәп тотылган Иҗат йортын ачуга рөхсәт алына. Республика җитәкчелеге ярдәме белән аны 1955 елда төзеп тә бетерәләр. Анда өчәр бүлмәле һәм верандалы дүрт җыелма фин йорты, алты бүлмәле һәм иркен ике верандалы зур бүрәнә йорт һәм алтыпочмаклы бүрәнә ашханә бинасы төзелә. Шул рәвешле, Казан үзәгеннән унсигез чакрымда, Аккош күленнән ике чакрым чамасы төньяктарак булган бер урында язучыларның «Аккош күле иҗат йорты»на нигез салына. (Хәзер анда язучыларның күмәк бакчачылык ширкәте.) Аларны Халикъ Садри төзетә башлый, ләкин ачу тантанасында катнаша алмый, алтмыш бишенче яшендә вафат була. Төзелеш барышында анда каравылчы һәм комендант вазифаларын шагыйрь Нәби Дәүли башкара. Сугышның беренче көннәрендә үк дошман тарафыннан әсир ителгән, шул сәбәпле рәсми хакимият вәкилләреннән генә түгел, кайбер каләмдәшләреннән дә битәрләү сүзләре ишеткәләп яшәгән Нәби абыйга бу эш ошап куя. Кыш дәвамында урман аланында ялгыз яткан озын төн-көннәрендә ул тынычлап иҗат итә, булачак шигырь китапларыннан тыш «Яшәү белән үлем арасында» повестеның караламасын язуга да керешә. Атналык ризыкны аңа Казаннан Язучылар берлеге шоферы Майшакәр белән Литфонд җитәкчелеге китереп торалар. Х.Садридан соң бүлек җитәкчесе булган Сөнгать ага Сафиуллин (1955–1964) хәтерләвенчә, ул елларда Аккош күле тирәсендә бушлык булган, юл бик начар чистартылган. Майшакәргә еш кына кар көртләрен ерып барырга туры килгән. «Сугыш юлларында да машина йөрткән чая хатын, өстәвенә Нәби дигәндә утка керергә дә әзер

иде. Шул рәвешле, без Нәбине кыш буе бәрәңге белән икмәктән өзми яшәттек», — дип сөйләр иде Сөнгатулла абый.

Нәби Дәүли төзелеш беткән көннән башлап вафатына чаклы (1989 елның май урталары) җәй айларында шунда яшәде, иҗат итте. Ашау-эчүле һәм көнкүреш хезмәте күрсәтүле тулы мәгънәле Иҗат йорты буларак төзелсә дә, ни сәбәпледер аны язучыларга арендага бирешле дачалар рәвешендә калдыралар. Ашханә өчен дип төзелгән аерым йорт идарә рәисе Г.Бәширов гаиләсенә бирелә. (Бер үк вакытта Гомәр ага утыз биш ел чамасы дача коллективының рәисе дә булды.) «Аккош күле» иҗат дачасының тәүге чор арендаторлары арасында күренекле язучылар Нәкый Исәнбәт, Гомәр Бәширов, Афзал Шамов, Әхмәт Фәйзи, Фатих Хөсни, Хәсән Туфан, Абдулла Әхмәт, Салих Баттал, Гали Хуҗи, Галимҗан Латыйп, Зәки Нури, Сафа Сабиров, Мария Николаевна Елизарова булалар. Шәүкәт Галиев, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Алексей Талвир, Надежда Бабенко, Нил Юзиев, Ренат Харис кебек яшьрәк буын вәкилләре дә соңрак анда җәйләрен җиләк-җимеш үстереп һәм иҗат итеп яшиләр. Җитмешенче елларда бу төркемгә Мәҗит Рафиков, Ренат Мөхәммәдиев, Роберт Миңнуллин, Мансур Вәлиевләр өстәлә. Җәен-кышын шунда торучылар да булгалый. Башлангыч чорда — Габделхәй Сабитов гаиләсе, җитмешенче елларда исә булачак Г.Тукай бүләге лауреаты, шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов гаиләсе кыш айларында да анда яшәделәр. Илленче еллар ахырында Литфонд йортларыннан бер почмактарак Ибраһим Гази белән Сибгат Хәкимнәрнең хосусый йортлары төзелә. Җитмешенче еллар ахырында аларга өчәр бүлмәле тагын ике Литфонд йорты өстәлде. Дөресрәге, җыелма каркаслы шундый өч йорт төзүгә идарә рәисе булган елларда Зәки Нури акча һәм рөхсәт алган иде. Соңрак ул йортларның берсе язучыларның Васильево бистәсе янәшәсендә алынган яңа бакчачылык ширкәтенә күчереп төзелде. Төзелеп беткәч тә, анда яңарак кына Тольятти шәһәреннән күченеп килгән шагыйрә Флера Гыйззәтуллина гаиләсе ике-өч ел яшәде.

Төзелештән соңгы елларда «Аккош күле» иҗат дачасында комендант һәм өч-дүрт хезмәткәр эшли. Комендант вазифасын берничә ел дәвамында отставкадагы подполковник башкара. 1960 еллар урталарыннан анда комендант-охранник штаты гына калдырыла. Дачаларны тотуга СССР Әдәби фонды тарафыннан акча бирелми башлый диярлек. Ибраһим ага Гази Язучылар берлеге идарәсе рәисе итеп сайлангач, 1968 елның августында шушы мәсьәләгә дә ачыклык кертү, акча сорау өчен үзенең урынбасары Гариф Ахунов белән мине (1967, апрель — 1983, апрель аралыгында бүлекчә директоры булдым) Мәскәүгә — СССР Әдәби фонды идарәсенә җибәрде. Безне идарә рәисе, язучы Варткес

Тевекелян кабул итте. «Язучыларның Переделкинодагы дачаларын беләсезме? — дип сорады башта. Уңай җавап алгач: — Анда кемнәр яши, беләсезме? СССРның иң күренекле язучылары, — дип, кайберләренең исемен, дәрәҗәсен санап чыкты. — Секретариатның карары белән хәзер ул дачаны тотуны да чиклибез. Йортларны хосусый милек итеп үзләренә сатып бирәбез. Сезгә дә шулай эшләргә кирәк», — диде. Әйе, шактый кырыс сөйләште безнең белән СССР Язучылар берлеге идарәсе секретаре, Әдәби фонд рәисе. «Секретариат карарын үтәү йөзеннән дачаларны бетерү эшенә кагылышлы документлар әзерләнә. Тиздән сез дә аларны алырсыз», — дип ул сүзен тәмам итте.

Ләкин... «Аккош күле» дачалары бетерелми калды. Күпмедер вакыттан соң Тевекелян вафат булды. Җитмешенче еллар башында аның вазифасын үтәү күренекле кабардин шагыйре Алим ага Кешоковка йөкләнде. (Шуны да әйтеп үтим, Мәскәүгә барган саен ул Сибгат Хәким, Гомәр Бәширов агаларга сәлам әйтеп җибәрер, аларның хәл-әхвәлен сорашыр иде. Беренче танышу вакытында бугай мин аңа Муса Җәлил белән Габдулла Тукайның русча чыккан китапларын бүләк иттем. Тукай китабын актаргалап карады да әйтә бу: «Тышлыгына «Тукай» дип язылган, шагыйрь үзе менә монда «Тукаев» дип язган». Шулай дип ул шагыйрьнең гарәп хәрефләре белән куелган имзасын күрсәтте. Аннары Кавказ таулары арасындагы бер мәдрәсәдә укыганда ук «Тукаев» шигырьләре белән таныш булуын сөйләде.)

1964 елның 1 гыйнварыннан бүлекнең статусы, ягъни мөстәкыйльлек дәрәҗәсе бераз күтәрелә, һәм вәкил урынына директор вазифасы кертелә. Язучылар берлеге идарәсе карары белән директор итеп Хәсән Сарьян билгеләнә. Ул 1965 елның декабренә кадәр эшли. Күләмле «Нокталы өтер» повестен яза башлавы сәбәпле, эштән китә. Декабрьдә аны икенче бер прозаик — Мәсгут Шәрифуллин алыштыра. Ләкин ул да озак эшли алмый — замандыбыз зәхмәте — ашказаны рагы аның гомерен өзә. Шуннан соң ул вазифаны үтәүгә мин алындым. Дөрес, идарә рәисе Мирсәяф ага Әмирев чакырып, эшкә алынырга күндергәч тә әле тиз генә аңа тотына алмадым. Ярты ел дәвамында мине элекке эшемнән җибәрмичә интектерделәр — ике-өч мең чамасы кеше эшләгән коллективта партком секретаре идем. Литфонд бүлекчәсе белән иң озак җитәкчелек итүче саналам. Шул дәвердә башкарылган кайбер эшләр турында алдарак сүз булыр. Миннән соң идарә иткән язучыларны да санап китәм: Әхмәт Гадел (1983–1984), Ренат Вахитов (1984–1986), Ләбиб Лерон (1986–1988), Шаһинур Мостафин (1988–1992), Рафис Корбан (1992–1994), Мансур Шиһапов (1994–1996), Данил Салихов (1996 елдан башлап).

СССР һәм 1959 елдан оеша башлаган РСФСР фондларының

үз идарәләре булды. Автономияле республикалардан беренче булarak бездә дә Литфонд идарәсе 1963 елдан бирле эшли. Аның җитәкчесе итеп Язучылар берлеге идарәсе әгъзасы, азмы-күпме хуҗалык, җитәкчелек эше белән таныш булган абруйлырак бер язучы сайлана иде. Хезмәт хакы алмыйча, җәмәгать тәртибендә эшләгән шундый рәисләрнең исемлеге: Афзал Шамов (1963–1979), Азат Әхмәдуллин (1979–1992), Әхсән Баян (1992–1999). 1999 елдан Әдәби фонд бүлекчәсе рәисе итеп Язучылар берлеге идарәсенең элекке рәис урынбасары Гәрәй Рәхим сайланды. Төрле елларда РСФСР Әдәби фонды идарәсе әгъзасы булып торучылар: А.Шамов, Л.Хәмидуллин, М.Хәбибуллин. СССР Әдәби фонды таркалгач (туксанынчы еллар башы), аның вазифасын Халыкара Әдәби фонд башкарырга алынды. Аның 1992 елгы оештыру пленумында элекке СССР Әдәби фонды бүлекчәләреннән Азәрбайҗан, Казакъстан, Ленинград, Кыргызстан, Әрмәнстан, Грузия һ.б белән бергә Татарстан вәкилләре дә катнашты. Халыкара Әдәби фонд идарәсендә бүгенге көндә Гәрәй Рәхим әгъза булып тора.

Татарстанда яшәүче язучыларның иҗатына булышлык итү, тормыш шартларын яхшыртуга юнәлтелгән нindирәк эшләр башкарылды соң? Алда Халикъ ага Садри эшчәнлегенә бәйле рәвештә «Аккош күле» иҗат дачасына кагылышлы вакыйгалар беркадәр бәян ителде. Казанда өйләрне мич ягып җылыту заманнарына караган бер эпизод та телгә алынган иде. Язучы гаиләләрен ягулык белән тәэмин итү бурычы Әдәби фонд җитәкчелеге тарафыннан җитмешенче еллар башына чаклы үтәлеп килде. Күп утын таләп ителгән «убырлы мичле» өйләрдә иң соңгы яшәүчеләр Әмирхан ага Еники белән Хәсән Сарьян булдылар. Әмирхан аганы Достоевский урамындагы шактый иркен үз өеннән 1968 елның көзендә күчердек. Ул баштарак «казна» йортына күчүгә бик каршы булды. Хәтерлим әле, Язучылар оешмасында профсоюз эшен башкаручы Сарьян белән миңа ул мондыйрак тәкъдим дә әйтеп карады: шәһәр хуҗалыгына минем йорт урыны кирәк икән, миңа алар якын-тирәдән шундый ук урын сайлатырга һәм өй салып бирергә тиешләр. Шуңа ничек ирешергә? Ул елларда Казанда шәхси йортлар төзү тыелган иде. «Ә Нурихан төзеде бит әнә», — ди аксакал әдип. Нурихан Фәттахның шәхси йорт төзергә рөхсәт алып йөрүләре Сарьян Әдәби фонд директоры булган чорга туры килә иде. Шуңа ирешү өчен Нурихнның элекке сабакташы булган республика җитәкчесенә ялынып йөрү вакыйгаларын сөйләп биргәч кенә, Әмирхан ага үзенә аерым утар-йорт төзетү фикереннән кайтты шикелле. Шмидт урамындагы «казна» фатирына да без аны Сарьян мәрхүм белән бергә күчерешкән идек. Шул ярдәмем өчен ул миңа илленче елларда кулдан ясалган бик зур бер китап шкафы бүләк иткән иде. Ләкин, өйдә аны сыйдырып булмаганга күрә,

байтак еллар мин аны «Аккош күле» дачасы сараенда тоттым. Шуннан соң гына үз бакчама алып китеп, ике өлешкә бүлеп, астын верстак итеп куллана башладым. Әмирхан ага бервакыт миңа Достоевский урамындагы йорт күршесенең «Рәшә» повестендагы баш каһарман чалымнарына ия булуын да сөйләгән иде. Ул инженер шул елларда бер зур заводның абруйлы директоры булып эшләде.

Өйләр, йортлар турында сүз чыккач, Әдәби фонд тарафыннан язучыларның торак мәсьәләсен хәл итү эшчәнлегенә тулырак тукталыйк. Сугыштан соңгы дәвердә СССР Әдәби фонды бүлекчәләргә акчаны рәсми теркәлгән язучылар санына нисбәтләп бүлеп бирә иде. Шуңа урындагы Язучылар берлеге төзегән исемлеккә карап (ә ул әгъза булып торучы язучылар саныннан артмаска тиеш) яшь иҗат көчләре белән эшләү өчен беркадәр өстәлә (Хрущев заманында кабул ителгән акча белән ул кеше башына 15–20 сумнан артмый иде). Вафат булган язучы гаиләсенә ярдәм итү өчен дә шул ук нисбәттә акча бирелә иде. Смета төзегәндә ел саен ул исемлекләр Мәскәүгә җибәрелеп торды. Әгәр шәһәр һәм республика җитәкчеләре яңа төзелә торган йортлардан түләүле фатир алуга рөхсәт кәгазьләре бирсә (ундүрт имзалы, унлап битле «документ»), һәм шуны вакытында Мәскәүгә илтеп тапшырсаң — СССР Әдәби фондының фатирлар булдыру өчен өстәмә акча бирүе дә ихтимал иде. Мондый мөмкинлектән бигрәк тә Зәки Нури белән Гариф Ахунов Язучылар берлегендә җитәкче булганда еш файдаландык.

СССР Әдәби фонды исәбенә иң беренче булып мул итеп фатир алу бәхетенә безнең язучылар илленче еллар ахырында ирешә — Гомәр ага Бәширов Язучылар берлеге идарәсе рәисе, СССР Язучылар берлеге идарәсе секретаре һәм СССР Югары Советы депутаты булган вакытта. Тимерьюлчылар Маяковский урамында төзегән биш катлы кирпеч йортта берьюлы сигез гаиләзур өй туе уздыра. Анда Г.Бәширов, М.Әмир, А.Шамов, Х.Туфан, Ф.Хөсни, Ә.Исхак, Г.Әпсәләмов, Т.Журавлев гаиләләре күченә. Алтмышынчы-җитмешенче елларда Мәскәүдән алынган акча исәбенә язучыларга ким дигәндә өч-дүрт фатир бирелә килде. Шул максат өчен СССР Әдәби фондыннан соңгы акча 1983 елда алынган иде. Ул вакытта инде республикада торак мәсьәләсе җиңелрәк хәл ителә башлады шикелле, «горплан», «госплан», «Татстрой», шәһәр идарәсе оешмаларына йөреп, имза-документлар җыеп мәшәкатьләнәсе калмады, ахрысы.

Дистәләгән татар язучысы ел саен төрле өлкә һәм Союздаш республикаларга булачак әсәрләренең геройлары белән очрашуга яисә материал тупларга дип командировкага бара иделәр. Шул ук максат белән ун-унбиш көнгә үз районына яисә авылына Әдәби

фонд исәбенә кайтып килүчеләр саны тагын да күбрәк иде. Сирәгрәк булса да, чит илләргә дә фонд исәбенә йөргәләүчеләр булды. Аның өчен нинди максат белән баруыңны дәлилләп Язучылар берлегенә гариза язу һәм Берлек идарәсенең рөхсәтен алу гына кирәк иде. «Муса» романын язар алдыннан Шәйхи ага Маннур — Германия Демократик Республикасына, В.И.Ленинның Польшадагы тормышын чагылдыручы очеркларын әзерләгәндә Зәки Нури — Польшага, «Сызгыра торган уклар» романын язарга керешкәч, Нурихан Фәттах Монголиягә барып кайттылар. Рафаэль Мостафин, Сибгат Хәким, Әминә Җәлил һ.б. М.Җәлилгә һәм җәлилчеләргә бәйле истәлек-хатирәләрне барлау, яңа материаллар туплау өчен ике-өч мәртәбә шулай ук Берлинга барып кайттылар. Рөстәм Кутуй, Габдрахман Минский, Алимә апа Кутуева Гадел Кутуй каберенә зиярәт кылу ниятеннән шулай ук Польшага бардылар. Төрле делегацияләр белән чит илләргә йөрүче язучылар да Әдәби фонд акчасына баралар иде. Хәтта чит илләргә Язучылар берлеге юлламасы белән турист рәвешендә баручыларның да юл чыгымының зур өлешен Әдәби фонд каплый иде. Безнең язучылардан андый сәяхәтләрдә Җәвад Тәрҗеманов, Хәй Вахит, Саҗидә Сөләйманова, Аяз Гыйләҗев, Равил Фәйзуллин, Гәрәй Рәхим, Мөхәммәт Мәһдиев, Мәдинә Маликова, Рәшит Әхмәт һ.б. бик күпләр булып кайтты. Алар Һиндстанда, Төркиядә, Япониядә, Гарәп илләрендә һәм Европаның барлык җирләрендә булып, киләчәк әсәрләре өчен мая, фикер тупладылар.

СССР Әдәби фонды тарафыннан финансланган М.Горький исемендәге Әдәбият институтында укып чыгучылар исемлеген Габдрахман Әпсәләмовтан башларга тиешбез. Сугыш алды елларында ул шунда белем ала, бер җәйдә Казанга килеп, икенчесендә Урта Азиягә Әдәби фонд исәбенә барып практика үтә. Сугыштан соң Әдәбият институтында Әдип Маликов, Рәшит Гәрәй, Габделхәй Сабитов, Разил Вәлиев, Вахит Монасыйпов, Булат Сөләйманов, Әхмәт Гадел, Роза Кожевникова, Солтан Шәмси һ.б. укыды. Икееллык Югары әдәбият курсларында белем алучыларның саны илледән ашса кирәк: Зәки Нури, Аяз Гыйләҗев, Мәсгут Шәрифуллин, Шәүкәт Галиев, Рабит Батулла, Туфан Миңнуллин, Рәфкат Кәрами, Рөстәм Мингалим, Ризван Хәмид һ.б.

Әдәбият фонды язучының авырган көннәре өчен акча түли, курорт-шифаханәләргә ярым түләүле юлламалар белән дәваланырга җибәрә иде. Язучылар шулай ук СССР Әдәби фонды карамагында иҗат йортлары мөмкинлекләреннән дә шактый иркен файдаландылар. Күпчелеге анда гаиләсе, бала-чагасы белән бара, иҗат та, ял да итеп кайта иде. Татар әдәбиятын баетырдай байтак кына әсәрләр шунда язылды дияргә була. Мәсәлән, Г.Ахунов «Хәзинә» романының башлангыч җитмеш битен Гагра иҗат йор-

тында язып кайттым» дип еш кына искә ала иде. А.Гыйләҗевнең матбугатта дөнья күргән хатларында да иҗат йортларында нинәрсәләр өстендә эшләве бәян ителә. Ул һәр елда кышын һәм җәен шунда иҗат итеп кайтыр иде.

Бөтенсоюз күләмендә танылган иҗат йортларыннан берничәсе санаторий-шифаханә рәвешендә эшләде, язучыларны беркадәр дәвалап та кайтара иде. Мәскәү өлкәсендәге Малеевка, Фин култыгы буендагы (Латвия) Дубулты шундыйлардан булып, аларга башлыча олырак яшьтәгеләр ешрак йөрделәр. Кайбер бик актив иҗат итүче язучылар, мәсәлән, Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Хәй Вахит, Аяз Гыйләҗев кыш айларында Мәскәү янәшәсендәге Переделкино, Малеевкада айлап, икешәр айлап эшләсәләр, җәен көньяктагы диңгез буендагы иҗат йортларын да үги итмәсләр иде. Җәй айларында инде, әлбәттә, гаилә белән барып, күмәкләшеп ял итү үзенә күрә бер гадәткә кергән иде. Кызганыч ки, буржуаз җәмгыятькә кергәч, андый мөмкинлекләр иҗат кешеләре өчен тудырылмый башлады.

Соңгы сүз итеп шуны әйтергә кирәктер: СССР Әдәби фонды җитәкчелеге безнең оешмага карата нигездә уңай фикердә булды. Безнең үтенечләрне үтәргә тырыша иде. Алтмышынчы-җитмешенче елларда Әдәби фондның Татарстан бүлеге берничә мәртәбә Мактау грамотасы белән бүләкләнде. Шәхсән үземә бирелгән шундый ике мактау кәгазе архивымда саклана.

*«Казан утлары», 2004, № 10*

## ӘСТЕРХАН КЫЗЫ

Мәшһүр әдибебез Галимҗан Ибраһимовның тууына йөз егерме ел тулды. Аның беренче әдәби хезмәте «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» язылуга да төгәл йөз ел үтте. Шуннан соң бер-бер артлы дистәләп хикәя һәм «Яшь йөрәкләр» романын иҗат итеп, 1917 елгы Октябрь революциясенә кадәр үк ул классик әдип дәрәҗәсенә күтәрелгән шәхесләрнең берсе булды. 1917 елгы вакыйгалардан соң инде ул иң алгы сафларда баручы татар җәмәгать эшлеклеләре арасына килеп керә. Мулланур Вахитов белән бергә Мәскәүдә милли комиссариат оештыруда, бердәм Башкорт-татар милли автономиясен төзүгә кагылышлы документларны барлауда катнаша. (Дөрес, төрле сәбәпләр аркасында андый мохтарият ул вакытта төзелми кала.) 1919 елда Казанга кайткач, әдәби эшчәнлеген дәвам иткән хәлдә, татар вакытлы матбугатын торгызу эшендә әйдәп йөрүчеләрдән була. «Безнең юл», «Мәгариф» журналлары турыдан-туры аның катнашында нәшер ителә башлыйлар. Әмма Г.Ибраһимовның татар иҗтимагый фикерен үстерүгә

керткән иң зур эшчәнлеге Гыйльми үзәкне җитәкләгән елларга туры килә. Әдәби һәм гыйльми-җәмгыяви эшчәнлеген истә тотып, 1928 елда ул СССР Сәнгать академиясенең хакыйкый әгъзасы итеп сайлана. Ә 1932 елда Г.Ибраһимовка «Хезмәт Батыры» дигән мактаулы исем бирелә.

Киеренке иҗтимагый һәм әдәби эшчәнлеген үтәгән көннәрендә аңа кемнәр ярдәмче булган? Өй, оя җылысын аңа кем тудырган? Дәвалауга бирешмәүчән авыру белән авырый башлаган әдипнең иң якын таянычы кем булган? Шул хакта әле без бик аз беләбез шикелле. Бу язма Г.Ибраһимовның сөекле хатыны «Гөлсем балакай»га багышлана. Яшь аермасын истә тотып, әдип аңа һәрчак шулай, исеменә «балакай» сүзен өстәп эндәшә торган була.

Егерменче гасырның беренче яртысында Әстерхан төбәгеннән чыккан татар зыялылары байтак булган. Күренекле артистлар төркеменнән Байкиннар династиясе, Зәйни ага Солтанов, язучылардан Газиз Иделле, Габдрахман Минский, Бари Рәхмәт — Әстерхан төбәгеннән күтәрелеп чыккан шәхесләр. Җитмешенче еллар башында татар эстрадасы сәхнәсенә уктай атылып килеп кергән бик үзенчәлекле җырчыбыз Зиннур Нурмөхәммәтев тә шул яклардан иде. Бу ике буын вәкилләре арасында әстерханлы Абдулла Дубин да мәдәниятебез күгендә бик мактаулы эшләр башкарды — Татарстанда телевизион тапшыруларга нигез салучылардан булды, татарларга бәйле тарихи фотоматериалларны барлаучы һәм нәшер итүче кеше буларак танылды.

Казанга килеп дан алган, олуг исем йөрткән шәхесләребез даирәсендә ешрак телгә алынырга лаеклы тагын бер кеше бар — татар халкының бик тә мәшһүр улының сөеклесе булган язучы һәм галим Гөлсем апабыз ул.

Әстерхан шәһәренең урта хәлле бер татар гаиләсендә тәрбияләнеп буй җиткән Өммегөлсем апа Мөхәммәдеваның язмышы үтә дә гыйбрәтле һәм кызыклы. Аның атасы Давыт абзый Каспий диңгезендә балык тоту кәсәбәчелеге белән шөгыльләнүчеләрнең көймә-корабларын төзекләндерүче кечерәк бер остаханә тоткан. Әстерхандагы милләттәшләребез арасында аның абруе зур булган. Ул анда Хәйрия җәмгыятен ачуда, төрле-төрле әдәби-музыкаль кичәләр оештыруда башлап йөрүчеләрнең берсе санала. Балаларын да бик яшьли шул «әдәби-мәдәни ахшамнар»га алып йөри. Шуңа күрә алар бик иртә ул чорның иң күренекле шәхесләре белән күрешү, аралашу бәхетенә ирешәләр. Өммегөлсем апа сөйләвенә караганда, Казан яки Кавказ (Баку, Тифлис) якларыннан шәһәргә килеп чыгучы барлык артистлар да диярлек аларның җитешле өйләренә ашка алына, кунак ителә торган була. Татар хатын-кызларыннан беренчеләр исәбендә Петербург консервато-

риясендә җыр сәнгате нечкәлекләрен өйрәнә башлаган Мәрьям Искәндәрева да, 1911 елда Идел буе шәһәрләрендә җыр кичәләре оештырып йөргәндә, берничә көн алар өендә булып китә. Күренекле шагыйребез Сәгыйть Рәмиев 1910 елның җәендә Әстерханга «Идел» газетасына эшкә чакырып алына. Давыт Мөхәммәдев һәм аның зыялы гаиләсе белән шагыйрь бик тиз аралаша башлый. Беркөнне Давыт абзый аңа: «Ашау-эчүең дә, торуың да бездә булыр», — дип, аерым бүлмә күрсәтә. «Кымыз эчеп, бераз дәваланып китәрсең», — дип, бер елдан соң Сәгыйть Габдулла Тукайны да Әстерханга чакырып китерә. Бөек шагыйребезгә багышланган истәлекләр китабында (1976 елгы басма) түбәндәге юлларны укыйбыз: «Сәгыйть Рәмиев... Давыт Мөхәммәдевләрдә тора иде. ...Тукай килү хәбәрен ишетү белән, ул (аны) үз өйләренә алырга тәкъдим итә. Соңыннан ул (Давыт) бөтен буш вакытын кунагы Тукайның Әстерханда булуын оештыруга багышлады» (Вәлит Алиев истәлеге, 120 б.).

Шушы зыялы, ишле гаиләдә тәрбия алган Өммегөлсем апа Казанны барып күрү турында яшьтән үк хыяллана. Өй шартларында мөселманча-татарча, шәһәр гимназиясендә русча белем үзләштергәннән соң, 1922 елның җәй ахырларында ул Казанга килә, университетның медицина факультетында укый башлый. Бик авыр еллар булуга карамастан, ял вакытларында студентлар төрле-төрле кичәләр, галимнәр, язучылар белән очрашулар оештыралар. Шундый кичәләрнең берсендә ул булачак ире — татарның мәшһүр язучысы Галимҗан Ибраһимов белән таныша. Ә 1923 елның җәй урталарында алар өйләнешәләр. (Бу вакыйгалар Г.Мөхәммәдеваның соңгы китабы «Олы юл»да ярыйсы ук тәфсилле тасвир ителә.) Хәсән ага Туфан, икенче бер мәшһүр шәхесебез Һади Такташның Казанга беренче аяк баскан айларын искә алып, мондый вакыйганы да сөйли иде. Яшь шагыйрь яңа дуслары белән хәзерге Кремль урамыннан үтеп бара икән. Бер фотоателье янында ул бик сөйкемле ике кыз фоторәсемен күреп туктап кала. Сокланып бик озак карап тора да, шуларның берсенә таба ишарәләп: «Бу кызны эзләп табачакмын», — дип әйтә икән. Ул кыз исә яңарак кына кияүгә чыккан Гөлсем Мөхәммәдева булган, имеш. «Шылай да Такташ ул кызга карата булган җылы мөнәсәбәтен һичкайчан онытмады», — дип сөйли иде мәрхүм олуг шагыйребез.

Яшь гаиләнең башлап яши башлаган «өе» — Кремльгә илтүче урамдагы Икенче совет йортындагы 33 нче бүлмә була. «Морҗа кебек тар, озын, шыксыз бүлмә. Ишек төбендә үк, уң кулда тимер карават. Аның өстенә коңгырт соры одеял капланган. Аннары ... эче кием-салымнан бигрәк китап белән тутырылган гардероб. Түргә табарак зур язу өстәле». Яшь килен ялгызак ирнең шушы рәвештәге бүлмәсен тиз арада үзгәртергә керешә, әлбәттә.

Галимҗанның абыйсы һәм энесе килгән вакытларга инде Гөлсем ул бүлмәне гөл кебек итеп җыештырып куйган була. Озак та үтмәстән Татарстан хөкүмәте бу гаиләгә Комлев урамында дүртбиш бүлмәле иркен фатир бирә. «1924 елда яңа өйгә күчеп килдек. Кулда акча бар чак иде, өй җиһазлары, савыт-саба алдык», — дип язачак соңыннан Гөлсем Мөхәммәдева. Бу өй аларга тагын бик зур сөенеч китерә — 1926 елның 5 ноябрендә уллары Рөстәм туа. «Галимҗанның улын бик көтеп алганлыгы тоела иде. Кайвакыт баланың бишегә кырыена терсәкләре белән таянып, бик озак карап торыр да: «Син аның күзләренә кара, нәрсәдер аңларга тырышкандай булып, төбәп багып тора бит! Акыллы егет булып үсәр төсле күренә. Башының формасы минеке, борыны да минекенә охшый бугай. Ә күзләре... синең күзләреңнән дә зәңгәррәк!»

Ләкин милләтебезнең иң күренекле шәхесләреннән берсе булган кеше белән бәхетле башланган гаилә тормышы тиздән бик фаҗигале рәвеш ала. Бергә яши башлауларына дүрт ел тулмастан Галимҗан бик каты авырып китә. Ул елларда дәвалауга бөтенләй дә бирешмәгән үпкә чире белән катлаулы көрәш башлана. (Шул хакта тулырак мәгълүматны Ө.Мөхәммәдеваның «Зур тормыш» дигән истәлек китабыннан укып белергә була.) Тиздән бу фаҗигагә икенчесе өстәлә — биш яше тулмастан бердәнбер балалары, Рөстәмнәре, кинәт авырып, үлеп китә. 1926 елда Рөстәм тугач чиксез сөенгән Галимҗан Ибраһимов белән Өммегөлсемнең нинди тетрәнү кичерүләрен күз алдына китерүе дә кыен. Үпкә чирен чигендерү чарасы итеп үткәрелгән катлаулы операцияләрдән соң беркадәр тернәкләнә башлаган, «Безнең көннәр» романының икенче өлешен язарга керешкән Галимҗан янә урын өстенә ава. Яшь йөрәген берьюлы ике кайгы телгәләгән Өммегөлсем өчен дә тормышның яме бетә. Аңа ул вакытта егерме сигезенче яшь була. Бу вакыйгаларны тулырак язуымның сәбәбе шул — соңрак кайберәүләр аны «авыру ирен ташлап китте» дип гаепләргә тырышкалады. Мондый авыр кичерешләрдән соң алар гаиләсе чынлап та таркала. Ләкин әле ул көннәргә чаклы тагын ике ел чамасы вакыт үтә. Кырымның мәрхәмәтле табигате, яхшы табиблары һәм табибәлеккә укыган хатынының тырышлыгы нәтиҗәсендә Г.Ибраһимов яңадан аякка баса, тоткарланган иҗат эшен дәвам иттерә ала.

Өммегөлсем Мөхәммәдеваны 1934 елның башында Кырым АССРның мәркәзе булган Симферопольгә чакырып алалар. Ул анда «Кызыл Кырым» газетасында тәрҗемәче булып та, башка оешмаларда да эшли. Сугыш башлангач, эшләгән оешмасы белән бергә Үзбәкстанга эвакуацияләнә; 1941 елның көзеннән яңа гаиләсе белән Сәмәрканд шәһәрендә яши. Баштарак ул анда хастаханәдә табибә була, соңрак бер гыйльми институтта эшли.

1956 елда диссертация яклап, биология фәне кандидаты дәрәҗәсен алуга ирешә.

Өммегөлсем (Гөлсем) Давыт кызы Мөхәммәдева язучылык эшенә кайчан керешкән соң? «Олы юл» китабында ул үзенең Галимҗанга кияүгә чыкканчы ук тарихчы Газиз Гобәйдуллинның энесе кул астында кайбер рәсми брошюраларны русчадан татарчага, татарчадан русчага тәрҗемә иткәнлеген яза. Ул хезмәтләрен тел белгече Мөхетдин Корбангалиев тә хуплый. Галимҗан белән бергә яшәгән елларында ул әдәби әсәрләр дә тәрҗемә итә, үзе дә каләм сынап карый. 1925 елда иренең «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре» хезмәтен, соңрак «Кызыл чәчәкләр» исемле озын хикәясен русчага тәрҗемә итеп бастыра. Ялтада яшәгән елларында Галимҗанның хәлсез кул белән сырлап чыккан кулъязмаларын матурлабрак күчереп язу хезмәтен дә Гөлсем башкара. Симферопольгә күчеп эшли башлаганчы ук Кырым татарлары язучыларының кечерәк берничә әсәрен тәрҗемә итә. Утызынчы елларның икенче яртысында инде ул тәҗрибәле тәрҗемәче буларак таныла, үзенең дә кечерәк күләмле язмалары кырым-татар матбугатында күренә башлый. 1940 елда Гөлсем Мөхәммәдеваны СССР Язучылар берлегенә кабул итәләр. (Сугыштан соңгы СССР язучылары исемлекләрендә ул «прозаик, переводчик» буларак теркәлгән.) Җитмешенче елларда Казанга әйләнеп кайта. Хәзерге заман татар дөньясына ул, нигездә, Галимҗан Ибраһимовка багышлы кызыклы истәлек язмалары, өч зур повесте белән мәгълүм.

Аның күләмле «Зур тормыш» истәлек-очеркы әүвәл Афзал ага Шамов 1966 елда төзеп чыгарган «Г.Ибраһимов турында истәлекләр» китабында урын ала, аннары, беркадәр тулыландырылып, йөз битле китап рәвешендә русча басыла («Большая жизнь», 1968). Әдипнең балачак һәм яшүсмер чорына багышланган шактый кызыклы «Яшьлек көннәре» документаль повесте башта «Казан утлары» журналында, аннары аерым китап буларак басылып чыкты (1975). Галимҗанның яшьлек елларын тулы күзалларлык бу әсәрен (һәм калган ике документаль повестен) язганчы Өммегөлсем апа әдипне якыннан белгән бик күп кеше белән аралаша, хат алыша. Язучы Афзал Шамов белән әдәбият галиме Мансур Хәсәневкә дә даими ярдәмләшеп торулары өчен бик рәхмәтле иде ул. Г.Ибраһимовның аклану хәбәре алынгач та, Афзал ага иң беренчеләрдән булып әдип турында истәлек язмаларын тупларга керешә. Өммегөлсем апаны да эзләп таба, «Зур тормыш», «Яшьлек көннәре» әсәрләрен язарга керешер алдыннан аңа үзендә булган мәгълүмат белән танышу мөмкинлеген тудыра. Ө.Мөхәммәдева үзе дә бик күп архив материалы һәм истәлек язмалары туплаган иде. 1986 елда, «Яшьлек көннәре»нең дәвамы булган «Эзләнүләр» по-

весте да кергән кулъязмасын редакцияләү дәверендә, миңа аның белән бик еш аралашырга туры килде. Өстәлендә Г.Ибраһимовның Киев төрмәсендә утыру вакыйгаларына багышлы бик күп документ копияләре белән тулы бер папка һәм байтак кына кызыклы фотолар ята иде. Аерым бер юкарак папкада төрле кешеләрдән алынган хатлар тупланган иде. Шул исәптән анда Галимҗанның Киевта яшәү чорында күңеле төшеп йөргән Уфа кызы Гөлсем Әхтәмева һәм әдипнең беренче хатыны исәпләнгән Мәчтүрә ханым Фәйзуллина белән язышкан хатлар да бар иде. (Студентка Әхтәмева соңрак курсташы Ордубатскийга кияүгә чыга, калган гомерен Азәрбайҗанның Нахичевань шәһәрендә үткәрә.)

«Эзләнүләр» китабы басылып чыккан көннәрдә, беренче нөсхәләрен күрсәтергә барганда Өммегөлсем апа миңа: «Галимҗанның Совет хакимияте дәверендәге эшчәнлегенә багышланган повестемны да язып төгәлләп киләм. Хәзер кулъязмамны Афзал Шамов укый... Ул китабыма да сез мөхәррир булсагыз икән», — дигән иде. Ләкин «Олы юл» документаль повестен безгә аның белән бергә китап рәвешенә китерү насыйп булмаган икән. «Эзләнүләр» басылып чыгып өч-дүрт айлар үтүгә, 1988 елның мартында, Өммегөлсем апа Мөхәммәдева сиксән бишенче яшендә арабыздан китеп барды. Автор тарафыннан тәмам эшкәртелеп бетмәгән кулъязма, төрле киштәләрдә байтак вакыт аунап йөргәннән соң (туксанынчы елларда түнтәреш-башбаштаклык чоры килде бит), мөхәррир кулына соңлап килеп керде. Язучының соңгы әсәре «Олы юл», минем тарафтан берникадәр әдәбиләштерелеп, 1994 елда гына китап рәвешен алды. (Кулъязмада бу әсәргә «Талант һәм аның фаҗигасе» дигән исем дә куелган иде. Повестьны әдәбиләштерү барышында «Уфа үрләре» дигән исемдә яңа башлам бүлеге өстәлде, башка бүлекләргә дә әз-мәз үзгәрешләр кертелде.)

Бүген без, әдәбият-мәдәният өлкәсендә эшләүчеләр һәм әдәбият сөючеләр, олуг әдибебез Галимҗан Ибраһимовның иң якын кешеләреннән берсе булган һәм аның тормыш-яшәешенә багышлап зур эшләр башкарган язучы Өммегөлсем Давыт кызы Мөхәммәдеваны бик хөрмәтләп искә алырга тиешлебез. Ул аңа бик тә лаек. Аның олуг әдибебезгә багышлап иҗат иткән «Зур тормыш», «Яшьлек көннәре», «Эзләнүләр», «Олы юл» әсәрләре һәр әдәбият сөюченең китап киштәсендә Г.Ибраһимов томнары белән янәшә торырга тиештер, мөгаен. Өммегөлсем апа язучы буларак кына түгел, бөек каләм әһеле Галимҗан Ибраһимовның якын, сөйгән заты буларак та онытылмаска, зурланырга хаклы. Мәшһүр әдип, танылган җәмәгать вә дәүләт эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның олуг юбилей көннәрен билгеләгәндә, аның белән авыр елларда гомер иткән Гөлсем апаны да искә алып үтик.

*«Сөембикә», 2007, № 3*

# КҮЗӘТҮЧӘН, ЭЗЛӘНҮЧӘН ӘДИП

Исмәгыйль ага Рәмиев белән якыннан танышуым алтмышынчы еллар урталарына туры килә. «Совет әдәбияты» журналында аның патша Россиясе заманында югары белем алуга ирешкән татар яшьләре турында күләмле бер хезмәте басылып чыккан иде. Унтугызынчы йөздә генә дә Казан университетын тәмамлаган милләттәшләребез саны егермедән ашкан икән. Ә бит әле Россиядә башка югары уку йортлары да булган. Бәлки, татар яшьләре аларда да белем үзләштергәндер. Шушы хезмәт басылганчы, безнең вакытлы матбугат битләрендә дистә еллар дәвамында бер уйдырма фикер кабатлана килде. Имеш, элекке заманнарда Россиядә югары уку йортларында укучы татар яшьләре булмаган. Алар, иске мәдрәсәләрдә укып, белемсез калганнар. Революциягә кадәр Казан университетын да бары тик ике-өч бай баласы гына тәмамлый алган, имеш. Бердән, мәдрәсәләрне яманлау, хурлау күңелдә ризасызлык тудыра иде. Язучыларның гомуми бер җыелышында шул хакта Нәкый ага Исәнбәтнең ачынып чыгыш ясаганлыгы да хәтердә. К.Насыйри, Г.Тукай, Г.Ибраһимовларыбыз, Г.Камал, Ф.Бурнаш һәм К.Тинчуриннарыбыз да шул яманланган иске мәдрәсәләрдә укыган зыялыларыбыз ич. Димәк, мәдрәсәләрнең дә төрлесе булган. Анда күңел биреп укыган шәкертләр арасыннан да белемле кешеләр чыккан лабаса.

Исмәгыйль аганың әлеге зур очеркы күңелләрдә йөргән шушы ризасызлыкларны да беркадәр баса төште. Шуннан соңгы беренче очрашу-танышу вакытында ук ул мәдрәсәләр тәмамлаган татар яшьләренең чит мөселман илләренең югары уку йортларына барып уку очракларын да сөйләде. Шулар турында да бер язып чыгачагын әйткән иде.

Шушы сөйләшүдән соң бераз вакыт үткәч, 1965 елның җәендә, Бауман урамындагы китап кибетенә килеп керсәм — шул ук авторның «Истәлекләр. Татарча басма сүз» дип исемләнгән китабы сатылуын күрдем. Актарып карыйм — кечерәк кенә форматлы бу юка китапка биниһая күп мәгълүмат тупланган. Габдулла Тукай, Сәгыйть Рәмиев, Габдулла Кариевка багышланган истәлекләр дә, татарча беренче басмаханәләр тарихы да урын алган анда. Китапны кулга алуга йотлыгып укый да башладым. «Шагыйрьнең «апартаменты» бүлеге күңелне шундук үзенә җәлеп итте. Габдулла Тукайга багышланган гаҗәеп кызыклы истәлекләр. Бөек шагыйребезне күп тапкырлар күреп белгән, аның белән аралашкан кешенең истәлекләре. Автор ике-өч җөмләдә Тукайның холкын, кыяфәтен тасвир итеп бирә белә.

«Шагыйрьне күреп белүем 1911–1913 елларга туры килә, — дип башлый ул истәлекләрен. — Тукай... бер караганда, уйчан,

гамьле. Бер караганда, күзендә саркастик чаткы уйнаган Тукай иде. Тирән уйга талган чагында, аның акыл сирпеп торган күз карашы вакыт-вакыт бер ноктага текәлеп туктап кала. Шундый минутларда ул онытыламы, әллә иҗат итә идеме, билгеләве читен. Табигать аңа бөек рәссам Рафаэльме, әллә юкса Микель Анджело рәсемнәреннәнме күчереп алынган төсле матур профильле антик борын һәм киң маңгай бүләк иткән. Киң маңгай ул — акыл билгесе, диләр. Көчле характер, авыр сабырлылык акыл ияләренә хас сыйфатлар. Шагыйрьне төрле чолганышта очратырга туры килде. Әмма мин аның үтә кабынып китеп иләмсез чыгыш ясаганын йә булмаса каушап калган чагын очратмадым... Аз сүзле иде ул».

Бер-ике биттә шагыйрьнең соңгы апартаменты — «Амур» кунакханәсендәге тормышы сурәтләнә. Хәзерге Мәскәү урамындагы 70 нче йортка — «Амур» кунакханәсенә шагыйрь 1912 елның җәй ахырында, Троицк тирәсендә кымызда булып кайтканнан соң урнаша. Элегрәк дусты Фатих Әмирхан да мондагы күрше бүлмәгә килеп урнашкан була. Тукайның бүлмәсе «буйга — җиде, иңе биш адым булыр». Ятак урыны фанер ширма белән бүлеп куелган. Шунда Тукай «явым-чәчемле көннәрдә авырсынып ята. Ятакта килеш укый, яза» торган була. «Мосафирханә тынгач, төнге тынлыктан файдаланып эшли. Төннең икенче яртысында да бүлмәсендә ут сүнми», — дип яза Исмәгыйль абый. Әйе, тасвирбәяләмәләре нинди төгәл, ышандыргыч. Олуг шагыйрь бөтен барлыгы белән укучы күз алдына килеп баса. Кесәгә сыешлы кечкенә форматлы китапчыкның биш-алты гына битле бер бүлегендә икенче бер сөекле шагыйребез — «Сәгыйть Рәмиев» образы тудырылган. Эстәрлетамак өязе ахуны Сәлим Рәмиевнең дүртенче буын варислары Сәгыйть белән Исмәгыйль тәүге тапкыр 1913 елның җәендә Әстерхан каласында очрашалар. Сәгыйть Рәмиев бу вакытта Әстерханда «Идел» газетасын нәшер итә. Исмәгыйль Рәмиев, «Сәйяр» труппасы суфлеры буларак, шәһәргә гастрольгә килгән. Соңрак, шагыйрь Уфага әйләнеп кайткач, бу ике кардәш ешрак аралашканнар, билгеле. Шушы аралашулардан соң әдип күңелендә туган шагыйрь образына без дә күз салыйк. Менә алдыбызда Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә белем алган бер шәхес: «Мавыктыргыч җанлы әңгәмәче ул. Рус, гарәп, фарсы әдәбияты белән таныш булганга, әңгәмәсе әдәби мисалларга, әйтемнәргә бай. Иптәшләренең кәефен кырмаслык үлчәүле чамада шаян табигатьлек, юмор да бар үзендә. Ыспайлап, җөпләп сөйли белгәне кебек, башкалар сөйләгәнне тыңлый белә торган чибәр гадәте дә бар. Кешенең сүзен бүлеп үзе сүзгә керешми. Һәркемгә — олысы вә кечесенә карата ачык йөзле, җылы һәм йомшак сүзле... Пөхтә һәм килешле киенә. Булганын — искесен, тотылганын да сылап-сыйпап, пөхтәләп кия белә иде. Сәхнәгә

чыгып, әсәрләрен оста укучының берсе, нәфис сүз остасы булып танылганы Сәгыйть Рәмиев иде. Ягымлы тавыш белән, сүзне-иҗекләрне ачык иттереп, ашыкмыйча һәм каушамыйча тәмләп сөйли иде... Шуннан соңгы буын шагыйрьләребездән әсәрләрен матур укуда Һади Такташка җиткән берәү дә булмады. Такташның үзен тотышында, тавышында һәм нәфис сөйләвендә Сәгыйть белән ниндидер уртаклык бар иде».

Югарыда санап кителгән яхшы, күркәм сыйфатларның әлеге истәлек китабы авторына да хас булуын мин Исмәгыйль ага белән ешрак аралаша башлагач аңладым. Без хәзерге Милли китапханәнең уку залында яисә язучыларның Тукай клубында уздырылган әдәби кичәләрдә ара-тирә очрашкалый идек. Иң элек Оренбург, Башкорстан төбәкләренә бәйле вакыйгалар, ул вакыйгаларда катнашучыларның язмышлары безне фикердәш итте. Соңгы өч-дүрт ел гомерендә ул кыскача бер тарихи-биографик белешмә («кече энциклопедия») төзү уе белән яшәде. Шул эш белән мавыкты. «Совет әдәбияты» журналында әлеге зур очеркы дөнья күргәч, «өлкән әдипләрдән бер төркем дуслары — Нәкый Исәнбәт, Афзал Шамов, Әмирхан Еникиләр — аңа, үзендә булган материаллардан һәм башка чыганаклардан файдаланып, Октябрьгә кадәрге татар әдәбияты һәм мәдәни хәрәкәте буенча бер белешмәлек төзергә киңәш итәләр» дип язды соңыннан Рәис Даутов И.Рәмиевкә багышланган күләмле хезмәтендә. Әйе, шушы сөйләшү-киңәшләрдән соң булса кирәк, Исмәгыйль ага, олы яшьтә һәм авыру булуына карамастан, көн саен диярлек Ленин урамындагы В.И.Ленин исемен йөртүче китапханәгә, аннан ерак булмаган архив бинасына килеп, эшләп йөрде. Кулындагы букчасында һәрвакыт төрле китаплар, тигез, вак хәрефләр белән сырланган кәгазь битләре булыр иде. (Әйе, аның язмалары бик пөхтә, беркадәр түгәрәкли төшеп язган бертигез хәрефләре ачык, җиңел укыла торган иде. Шуңа күрәдер инде, Беренче бөтендөнья сугышы чорында хәрби хезмәттә вакытта да, Бөек Ватан сугышы елларында трудармиягә алынгач та, аны писарь вазифасын үтәргә билгеләгәннәр.) Вафатына берничә ай калганда, тупланган материалын ул кульязма энциклопедия рәвешендә машинкада бастырып та алган иде. Ләкин аңа ул кульязманың китап рәвешендә чыгуын күрергә насыйп булмады. 1969 елның декабрь урталарында аны буым ютәле арабыздан алып китте. Нәкъ бер ел элек без аны, Афзал ага Шамов тәкъдиме белән, СССР Әдәбият фонды әгъзалыгына кабул иткән идек. Ул эш белән миңа Мәскәү түрәләре алдына тез чүгеп берничә тапкыр барырга туры килде: алда телгә алынган юп-юка китабыннан тыш башка әдәби мирасы сакланмаган. Яңа китабы әле басылмаган иде. «Репрессияләр чорында әдәбияттан читләштерелгән зат. Хәзер, авыру сәбәпле, әкренрәк эшли.

Безнең арага кире кайтырга хакы бар», — дип дәлилли торгач кабул ителгән иде. Ләкин Әдәби фонд биргән мөмкинлекләрдән файдаланырга өлгермичә үк ул арабыздан китеп тә барды.

Исмәгыйль Рәмиев төзегән әлеге хезмәт фәкать 2001 елда гына басылып чыкты. Бик күптән көтелгән, татар әдәбиятын һәм мәдәниятен һәрьяклап колачларга омтылган ул җитди хезмәтне басмага әзерләп чыгаручы язучы, әдәбият белгече Рәис Нәүширван улы Даутов булды. «Әдәби сүзлек» исеме белән чыккан ул китап тышына хаклы рәвештә ике авторның исеме куелган: Исмәгыйль Рәми һәм Рәис Даутов. Китапны тулырак итеп чыгару максатын истә тотып, Р.Даутов аңа Исмәгыйль аганың башка төр язмаларын да беркадәр редакцияләп-эшкәртеп өстәгән. Мәсәлән, И.Рәмиевнең 1926 елда Казанда нәшер ителгән тагын бер зур энциклопедик хезмәте — «Вакытлы татар матбугаты. 1905–1925 еллар» альбом-белешмәлеге бар иде. Үзебезнең илдәге генә түгел, чит илләрдәге галимнәр дә кызыксынган бу хезмәт Совет хакимияте дәверендә башка беркайчан да кабат басылмады. (1960 елларда ул энциклопедик белешмәлеккә багышлап Англиядә бер гыйльми хезмәтнең нәшер ителүе турында Исмәгыйль ага үзе бер сөйләгән иде. Аңа ул хәбәрне Мәскәү өлкәсендә яшәүче, «Техника молодежи» журналында сирәк-мирәк кенә мәкаләләре басылгалаучы инженер кияве җиткергән булган.) 2001 елда басылып чыккан «Әдәби сүзлек»кә шул белешмәлектән дә байтак мәкалә урнаштырылган. Һәм ул китапка кергән барлык мәкаләләр дә диярлек Р.Даутовның астөшермә өстәмәләре белән баетылган. Бу астөшермә өстәмәләре соңгы утыз-кырык елда ачыкланган яңа мәгълүматны эченә ала, шул рәвешле Исмәгыйль ага хезмәтен тагын да баета төшә. Мәсәлән, алтмышынчы елларда кайбер шәхесләребезнең репрессияләнүләре яки беришенең чит илдә яшәп иҗат иткәнлеге турында язып чыгу һич тә мөмкин түгел иде. Р.Даутов өстәмәләрендә андый очракларга да ачыклык кертелгән. Менә, мәсәлән, язучы, җәмәгать эшлеклесе Фәхрелислам Агиевка багышланган мәкаләнең Рәис өстәгән астөшермәсе «Ф.Агиев 1928 елның ахырында ОГПУ органнары тарафыннан фальсификация юлы белән оештырылып, «Солтангаливнең контрреволюцион оешмасы» дип исемләнгән мәгълүм «эш» буенча кулга алына» дип башланган, язучының соңгы чор язмышын тулы яктырткан өч зур җөмләдән торган мәгълүмат урнаштырылган. Андый мисаллар бу китапта байтак.

«Әдәби сүзлек» китабында урын алган күп кенә әдип вә шагыйрьләрнең 1969–2001 еллар аралыгында, ягъни сүзлек авторы вафат булганнан соң, шактый гына хезмәтләре кабат басылып чыкты. Р.Даутов ул китапларның да барысын барлап, астөшермә искәрмәләрендә теркәп куйган. И.Рәмиев кулъязмаларында кайбер

шәхесләрнең туу, вафат булу даталары да тәгаенләнеп бетмәгән була. Китапның автордашы аларны да ачыклап чыккан, кайбер очракларда хаталану сәбәпләренә аңлатмалар да биргәләгән.

«Әдәби сүзлек»тә, нигездә, XIX йөз белән XX йөз башларында татар халкы, аның аерым шәхесләре тудырган рухи-мәдәни хәзинә үрнәкләре, шул чорда иҗат иткән иҗатчыларның кыскача биографиясе теркәлгән. Борынгы заманнарда иҗат ителеп тә, халык күңелендә сакланган, мәдрәсәләрдә укытылган кайбер бик «иске» әдәбият ядкәрләре турындагы мәгълүмат та анда урын алган.

Бу китапның соңгы өлешендә Рәис Даутовның олы замандашы Исмәгыйль Рәмиевкә багышланган тәфсилле биографик очеркы да бар. «Мәдәниятебез фидакяре» дип исемләнгән ул хезмәттән без Исмәгыйль аганың соңгы елларындагы иҗади омтылышларын да, татар халкы мәдәниятенең үткәненә карата битараф булган кайбер түрә һәм иҗатташларының аңа бу өлкәдә ничек «ярдәм» иткәнлекләрен дә белә алабыз. Татар әдәбияты һәм мәдәнияте үсеше өчен әһәмияте зур булган, ләкин утыз елга соңлап дөнья күргән бу җитди китап язмышын хәл итүчеләр исемлеген тулыландыру максатыннан чыгып, тагын бер фидакяр кешене атап үтү кирәктер, мөгаен. Исмәгыйль аганың якын кардәше (аналары бертуган), музыка белгече Фатыйма апа Вәлиева, олы агасының үксез кулъязмасын кочаклап, байтак вакыт ишектән ишеккә йөрде. Бу хезмәтнең татар халкына бик кирәкле икәнлеген расларга тырышты. Шулай оешмадан оешмага йөри-йөри, үзе дә гүр иясе булды. Аның ялгызак кеше фатирында сакланган ул кулъязмалар (шул исәптән үзенең революциягә кадәр иҗат иткән милләт музыкантларына һәм башкаручыларына багышланган язмалары) тәмам юкка чыкты шикелле. Һәрхәлдә, алар саклана дип искә алучыларны мин очратмадым.

Исмәгыйль Рәмиевнең соңгы хезмәтенә автор үзе исән чакта ук тискәре бәя бирүче дә үз кешебез, мәгълүм бер галимебез булды. (Бәлки әле, аның шул тискәре фикерле «кәгазь кисәге» үк Исмәгыйль аганың «бума ютәле» көчәеп китүенә бер сәбәп булгандыр.) Ул галим биргән бәяләмәнең копиясе Ф.Вәлиева кулында да бар иде. Хәтерем ялгышмаса, бәяләмәдәге төп фикер бу хезмәтне «признанный» галим кеше язмаган, кулъязмада тупланган материал әдәбият-мәдәният дөньясын тулы барламый рәвешендәрәк иде. Ә хәзер зур коллективлар, күренекле галимнәр туплап чыгарган энциклопедияләрне тулы дип әйтә алабызмы соң? Әлбәттә, юк. Совет чорында нәшер ителгән энциклопедияләрне дә, хәзергеләрен дә «йөз процентка тулы» дип бирәү дә тасвир итә алмастыр. Ә инде бер кеше тарафыннан тупланган белешмәлеккә карата бу сүзне куллану да килешми сыман. Ләкин бит ул хезмәтләрнең кыйммәте аңа карап кына бер дә кимеми. Утыз ел

дәвамында дөньяга чыга алмыйча яткан әлеге кулъязма, үз вакытында басылган булса, күпме кешегә, күпме галимгә ярдәмгә килә алган булыр иде. Бүген дә ул, «Татар энциклопедиясе» томнарын әзерләгәндә дә кулдан төшми кулланыла. Бу сүзләрне мин, шул институтта сигез ел эшләгән кеше буларак, раслап әйтәм.

Шушы җәһәттән караганда да, Рәис Даутовның бу кирәкле хезмәтне соңлап булса да нәшер итәргә алынуы мактауга лаек. «Әдәби сүзлек» китабын тудыручы ике шәхес, ике әдип тә татар мәдәнияте өлкәсендә үз иҗади байлыклары белән билгеле зыялылар. Әмма ләкин Исмәгыйль Рәмиевнең узган гасырның егерменче елларындагы иҗаты белән генә бүгенге заман әдәбият сөючеләре таныш түгел. Ә шул дәвердә дә ул эзләнүчән һәм күзәтүчән әдип булган бит. Вакытлы татар матбугатын барлаган әлеге альбом моңа дәлил. Шаян, көлке хикәяләр авторы буларак та ул дан казанган. Туксан еллык юбилеен билгеләргә якынлашып килүче, халык арасында киң таралышлы «Чаян» журналын нигезләүчеләр төркемендә дә «И.Рәми» тамгасы бар.

*«Татар иле», 2004, № 4*

## ҖЫРЛАРДА ИЛ ГАМЕ

Әдәбият сөючеләребезгә Татарстан халык шагыйре Равил Фәйзуллин исеме күптән таныш инде. Аның беренче шигырьләре матбугатта басыла башлауга ярты гасыр тулып килә. Шушы дәвер эчендә Равилнең күпсанлы шигырь җыентыклары татар һәм рус телләрендә Казанда һәм Мәскәүдә басылып чыктылар. Аның иҗатын зурлап Татарстанның Муса Җәлил һәм Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре бирелүенә дә байтак еллар узды.

Равил әле «коеп куйган шагыйрь» генә түгел. Ул — актив җәмәгать эшлеклесе, дистә еллар дәвамында Татарстан Язучылар оешмасы җитәкчеләренең берсе, зур стажлы идарә әгъзасы булган кеше. Өченче дистә ел инде әдәбиятыбызның тутыкмас көзгесе саналган «Казан утлары» журналының баш мөхәррире вазифасын үтәп килә. Бүгенге әдәби хәрәкәттә бик эшлекле катнаша. Әдәбиятыбызның киләчәген кайгыртып, борчылып язган мәкаләләрен дә, зур җыелышларда ясаган җитди чыгышларын да күпләребез яхшы хәтерли. Әдәби хәрәкәткә кагылган бер генә сөйләшү дә Равил Фәйзуллин катнашыннан башка узмый диярлек. Һәм һәрчак аның чыгышлары күпчелек тарафыннан яклау таба. Чөнки ул трибунадан милли әдәбият һәм милли сәнгатебезнең гомуми үсешен кайгыртып сүз әйтү ягын карый. Сүзен үтемле итеп, башка милли мәдәниятләр үсеше белән чагыштырып сөйли белә.

Равил Фәйзуллинның менә бу күркәм сыйфатлары Татарстан китап нәшрияты элегрәк елларда чыгарган «Җырларда — ил гаме» җыентыгында да ачык чагыла. Ул китапта шагыйрьнең татар әдәбиятына һәм аерым татар әдипләренә багышлап язылган мәкаләләре, чит-ят җирләрдә йөргәндә туган уй-хисләрен белдергән юлъязма һәм очерклары урын алганнар.

Бу китап ике бүлектән тора. Җыентыкның турыдан-туры татар әдәбиятына багышланган беренче яртысы — «Әдип исеме — олы исем» бүлеге хакында икенче бер танылган әдибебез Гариф ага Ахунов элегрәк газетада язып та чыккан иде. Ничаклы гына тырышсам да, мин бу китаптан алган тәэсирләремне Гариф абый кебек үк канатлы итеп сөйләп бирә алмамдыр, мөгаен. Шуңа күрә Равил Фәйзуллин иҗатын үз итүчеләр ул тәфсилле мәкаләне табып укырлар дигән ышанычта калам. Бу очракта Гариф Ахуновны куәтләп шуны гына өстисем килә: китап бик аз санда чыккан, күбрәк кирәк иде. Мондый төр әдәбиятның, олы иҗат тәҗрибәсенә таянып язылган әсәрләрнең китап киштәләрендә аунап ятмавын беләбез ич. Элгәрерәк елларда дөнья күргән Кави Нәҗми, Фатих Хөсни, Әмирхан Еники, ниһаять, мәрхүм Хәсән Сарьян язып калдырган әдәби портретлар китабын хәзер әнә китапханәләрдә дә сирәк очратасың.

Мин исә бүген Равил Фәйзуллин китабының икенче бүлегенә — «Юлларда туган уйлар» өлешенә бераз тукталмакчы булам. Чөнки әлеге бүлеккә тупланган күләмле алты очерк һәм юлъязма минем күңелгә дә бик якын темага — әдәбиятлар дуслыгы һәм әдәби арадашлык темасына багышланганнар. Шунысын да әйтеп китим: бүгенге татар язучылары арасында Равил Фәйзуллин үзебездә һәм чит илләрдә яшәүче бик күп күренекле әдипләр, сәнгать әһелләре белән иң актив аралашкан, алар белән дустанә мөнәсәбәт булдырган кеше дисәм дә ялгышмамдыр, шәт. Шулай ук ул, Гариф Ахунов тасвирлап үткәнчә, «Сахалиннан алып Ак диңгезгә чаклы арада» бик күп җирләрдә булган, игенче һәм инженерлар белән дә, галим һәм эшчеләр белән дә якыннан танышкан, аралашкан шагыйрь. Шул сәбәпле аның җырларында, шигырьләрендә ил гаме, кешеләр язмышы калку сурәтләнә. Бик күпне күрәсе, беләсе килгән тынгысыз җан, аерым кешеләр һәм илләр, халыклар язмышы белән тирәнтен кызыксынучан, иренмәс сәяхәтче дә, ялкынлы шагыйрь дә һәм чак кына галим дә бит әле ул. Чак кына галим дә дип кимсетеп әйтүем түгел, фәкать әле бу юнәлештәге хезмәтләренең, уй-фикерләренең аз басылганлыгына бер ишарә генә.

«Җырларда — ил гаме» китабының юлъязмалар, сәяхәтнамәләр өлешенә нәрсәләр кергән соң? Әйткәнемчә, монда барлыгы алты әсәр. Аларда тасвирланган географик өлкәләргә, илләргә Равил-

нең ун-унбер мәртәбә барып кайтканлыгы беленә. Димәк, Владивосток, Уссури тайгалары һәм Испания иленнән тыш һәр җирдә ул икешәр, өчәр мәртәбә булган. Мәсәлән, хәзер тәмам таркалып беткән Югославиядә — ике, Әстерханда өч мәртәбә булуын әйтә автор. Шуннан соң гына анда күргән-белгәннәре хакында татар укучысы белән фикер уртаклашу нияте туган икән. Без аның шулай ук Кавказ, Урта Азия республикалары белән дә, молдаван һәм украин халыклары яшәгән төбәкләр белән дә якыннан таныш булуын беләбез. Элеккеге Ленинградта һәм Урал, Себер өлкәләрендә дә йөреп кайта Равил. Анда яшәгән аерым күренекле шәхесләр, ул илләр халкы белән татар халкы арасындагы элемтәләр хакында да без, бәлкем, киләчәктә укырбыз. Ләкин бу китапта әле алар юк. «Юлларда туган уйлар» бүлеге «Кояш чыгышында» дигән зур гына очерк белән башланып китә. Очерк язылуга беренче төп сәбәп — шагыйрь Равил Фәйзуллинның ун мең чакрым юл үтеп Владивостокка, мактаулы Уссури краена барып чыгуы. Шагыйрь анда үзе генә түгел, элекке илебезнең иң танылган ике-өч дистә язучысы белән бергә бара. Анда алар элекке СССР Язучылар берлеге җитәкчесе, танылган романчы Александр Фадеевка багышланган әдәбият көннәрендә катнашырга җибәреләләр. Равил Фәйзуллин шул олуг мәҗлестә Татарстан вәкиле булып күпмедер дәрәҗәдә татар әдәбиятын пропагандалаучы буларак катнаша.

Шушы уңайдан Равилнең әлеге китапта китерелгән бер җөмләсе миңа аеруча тәэсир итте: кайсы гына илгә барма, бүгенге көндә татар кешесе өчен төп пароль, беренче танышу чарасы булып Муса Җәлил исеме тора дигән фикерне әйтә ул. Әлбәттә, бу исемне чит илләрдә йөргәндә ешрак кулланыргадыр. Чөнки әдәбиятыбызны тәгаен белеп бетермәгән бик ерак өлкәләрдә дә татар халкын белмиләр дип зарлана алмыйбыз. Әнә бит Равил дә туган яклардан ун мең чакрым юл китеп, җир читендәге, ерак Япон диңгезе яр буендагы шәһәрдә дә якташларын очрата.

Кая барма — якташларым күрәм,
Кая чыкма — татар очратам, —

дип яза ул.

«Владивостокның үзәгендәге Почет тактасында... унике кеше арасында Сафина Т.А. фамилиясе дә бар. Унынчы төзү идарәсенең малярлар бригадиры икән ул», — дип соклана шагыйрь. Һәм андый очрашулар аны бер Ерак Көнчыгышта гына түгел, элекке илебезнең барлык төбәкләрендә, шул исәптән күп гасырлар буе бик үк аралашмаган Прибалтика республикаларында да сагалап кына тора диярсең.

Әмма бу һәм башка очерк, юлъязмаларның максаты чит җирләрдә якташларны очратуга гына кайтып калмый, алар сүз

уңаенда «бер горурлык хисе белән» телгә алынып киткән детальләр генә. Төп максаты, минемчә, бүгенге татар әдәбиятының күпмилләтле әдәбиятлар арасында урынын ачыклау, ул әдәбиятлар белән бәйләнешен белергә тырышудан гыйбарәт. Һәм хәлдән килгәнчә шул юнәлештә киләчәктә нәрсәләр эшләргә кирәклеген барларга омтылуын тоям мин. Бу хәл Александр Фадеевның татар әдәбияты һәм татар әдипләре белән бәйләнешен сурәтләгәндә дә ачык сизелә. Муса Җәлил, Сибгат Хәкимнәрнең Фадеевка мөнәсәбәте, Фадеев әсәрләренең язылу белән үк диярлек татарча басылып чыгулары («Тар-мар» романын утызынчы елларда Афзал Шамов, «Яшь гвардия»не сугыштан соң ук Габдрахман Әпсәләмовлар тәрҗемә иткән) — моңа бер дәлил. Һәм шундый дәлил, хатирәләр аша, Әстерхан өлкәсендәге зур татар авылында туып үскән русның икенче бер олы шагыйре Михаил Луконинннар иҗаты аша без рус һәм татар әдәбиятларының һәм халыкларының бергә-бергә дус, тату яшәү серләренә төшенә башлыйбыз. Халыклар дуслыгын бозарга теләп, кемнәр һәмниләр генә уйлап чыгармасыннар, бер җирдә туып, бер суны эчеп үскән ике халык гомергә дус, кардәш булып калырга хаклы. Моның өчен фәкать үзара татулык, аралашып яшәү генә шарт диясе килә.

Латвия Республикасында латвия язучылары белән аралашкан чакта да, тугандаш каракалпаклар яшәгән чүл сахрасы буйларында йөргәндә дә шагыйрь Равил Фәйзуллин байтак кына кешеләр белән танышкан, аларның һәркайсысы, элек нинди диндә, нинди мәзһәбтә тәрбияләнгән булуларына карамастан, аның күңелендә туганлык, дуслык хисе уятканнар. Күңел җылылары белән уртаклашканнар. Кая гына барса да, үзен дә олы бер халыкның абруйлы вәкиле итеп кабул иткәннәр, чын ихластан дуслык бәйләнешләре урнаштырып йөрүче илчесе итеп таныганнар. Латвиялеләрнең классик шагыйре Ян Райниска, балкар әдәбиятының күренекле вәкиле Кайсын Кулиевка, каракалпакларның үлмәс Бердахы, Хаҗиниязларына булган олы мөнәсәбәте аша без Равил Фәйзуллинның шушы шәхесләрне тудырган халыкларга булган тугандашлык хисләрен дә тоябыз. Һәм бу шагыйрьнең тикмәгә генә бер очеркын «Дуслык — агачыдыр, көрәшмәк — җимешедер» дип башлавының серен яхшы аңлыйбыз.

Инде соңгы сүз итеп әнә шундый дуслык агачларын багып үстерүчеләребез дә, ул агачларның җимешләре дә киләчәктә тагын да ишлерәк булсын иде дип телисе генә кала. Шагыйрь Равил Фәйзуллин ишеләр ярган юллар, үстергән җимешләр яңа сәяхәтләр, яңадан-яңа дуслык бәйләнешләренә китерсен. Илнең, дөньяның иминлеге — дуслык, туганлык хисләренең нык, өзелмәстәй булуына бик бәйле бит. Күренекле әдибебез, Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллинның китап киштәмдә

торган, элегрәк елларда басылып чыккан «Җырларда — ил гаме» китабын кабат күздән кичергәннән соң, миндә шундый хисләр туды.

*«Татар иле», 2005, № 31 (авг.)*

## БЕРЕНЧЕ БУРАЗНА ЯРУЧЫ

Татар милләтен тарихи үткәненнән, дан-шөһрәтле борынгы чор-дәверләреннән аерырга тырышкан бер заманда, узган гасырның алтмышынчы елларында, Нурихан Фәттах тарихи әсәрләр язарга кереште. Байтак еллар эшкәртелмичә яткан киң дала уртасыннан беренче буразна салган тәүге батыр кебек булды. Нуриханның хәзерге заман вакыйгаларын чагылдырган «Мөдир Саҗидә», «Бала күңеле далада» кебек романнарыннан соң дөнья күргән «Әтил суы ака торур» әсәре татар зыялылары һәм әдәбият сөючеләре тарафыннан хуплап кабул ителде. Бу вакыйга чүлдә сусап интеккән җан иясенә бер кушуч су биреп, аны терелтеп җибәрүгә тиң иде.

«Әтил суы ака торур» романы «Казан утлары» журналында дөнья күргәч тә, язучыларның гомуми бер җыелышында ул әсәр турында җитди бер сөйләшү булган иде. Җыелышта катнашкан күпчелек язучы һәм галимнәр әсәрдә тарихи вакыйгаларның дөрес чагылдырылуын, укучы күңелен җәлеп итәрдәй сюжетка корылган булуын билгеләп үттеләр. Ә шагыйрь һәм шәркый телләр белгече Мостафа ага Ногман: «Бу роман саф төрки-татар телендә иҗат ителгән, анда хәзерге күпчелек язучылар кулланган алынма сүзләргә урын бирелмәгән», — дип чыгып сөйләгән иде. Соңрак шул ук фикерен ул берәр фәнни хезмәтендә бәян иткәндерме, әйтә алмыйм.

Татарның тарихын, элек-элек заманнарда аның кем булганлыгын оныттырырга тырышу омтылышлары элгәреге чорларда да булгалап торган. Фәкать егерменче гасыр башларында гына аның борынгы шанлы-данлы тарих катламын ачарга тырышу күренеше бер булып алган иде инде. Гайнетдин Әхмәрев, Ризаэтдин Фәхретдинев, Рәмзи Морад, Газиз Гобәйдуллин, Зәки Вәлиди, Габделбари Баттал кебек фидакяр затларның саф тарихи һәм тарихи-әдәби китаплары басылып чыкты ул заманда. Яңа хезмәтләр белән беррәттән урта гасырларда тупланган, киң җәмәгатьчелеккә мәгълүм булмаган китапларны халыкчан телгә күчереп язу үрнәкләре дә күзәтелде. Бу җәһәттән бигрәк тә Ризаэтдин хәзрәт Фәхретдинев редакцияләгән «Шура» журналы күп эш башкарды. Шул ук елларда Габделгаллəм Фәезхановның төрки халыклар тарихын җентекләп барлаган Әбелгазый Баһадур хан китапларын

тәрҗемә итеп кабат чыгаруы да татар халкының үзаңын күтәрүгә юнәлтелгән зур хезмәт булганлыгы шиксез.

Ләкин... Совет хакимияте дәверендә буй җиткән бик күпләребезгә бу хезмәтләр мәгълүм түгел иде. Алар тыелган яки юк ителгәннәр иде. Юк ителмәгәннәре дә махсус яшерен киштәләргә бикләп куелган булды. Андый әдәбият белән бик сирәк кешеләр генә кача-поса таныша алды. Нурихан Фәттах шундый бәхетлеләрнең берсе булды. Элекке Император университеты китапханәсенең сургучлы мөһер сугулы караңгы бүлмәсендәге киштәләргә үтеп керә алмаган очракларда да ул кирәкле китапларны табу юлын белә иде. Андый хәзинәне патша заманыннан бирле яшереп саклаучы укымышлы карт-корылар исән иде әле. Шундый зыялыларны эзләп табар иде ул. Алтмышынчы еллар урталарында миннән дә бер аксакалны белешүемне үтенгәне булды. «Оренбургта язучы Шакир Мөхәммәдевнең кияве яши икән. Борынгы китаплары күп икән. Шул картның адресын белмисеңме?» — дигән иде. Тәүфыйк исемле ул кешенең адресын табышып биргән идем шикелле. Элемтәгә керә алу-алмауларын белмим.

Милли мирасны барлау эшенә Нурихан Фәттах университетта укыган елларында ук керешә. Шул максатка ирешү өчен ул университет галимнәре оештырган археографик экспедицияләрдә бик теләп катнаша. Татарстанның көнчыгыш, Башкортстанның көнбатыш төбәкләре авылларын йөреп чыкканлыгы мәгълүм. Алтын Урда дәүләте башкаласы урнашкан урыннарда — Волгоград, Әстерхан өлкәләрендә тикшерү эшләре алып баручы археологлар белән дә берничә сезон эшли. Чит ил галимнәренең Шәрекъ халыклары тарихына багышланган хезмәтләрен дә үзенә тупларга тырыша. Хәтеремдә әле, үзара аралаша башлаган бер мәлдә, алтмышынчы елларда, мин дә аңа профессор С.Толстовның Харәзем дәүләте тарихын чагылдырган бер-ике китабын укырга дип биреп торган идем. (С.Толстов Харәзем чоры архитектурасын Шумер дәүләте архитектурасының дәвамчысы дип билгели. Харәзем иле дәүләтчелеген борынгы шумерлар дәүләтчелеге белән бәйли. Ләкин нишләптер «шумер» атамасын «сумер» дип язып, Совет дәвере укучысының юлын яздыра.) Ә гарәп зыялысы Усама ибне Мункызның тәре яулары чорын тасвирлаган «Книга назидания» китабын бөтенләйгә дип сорап алган иде. (Ул китапта Шәрекъ илләренә яу белән килгән европалыларның наданлыгы һәм рәхимсезлеге белән беррәттән, Шәрекъ дөньясының ни дәрәҗәдә аңлы, укымышлы булганлыгы бәян ителә. Ул вакыйгаларда төркиләр дә актив катнаша.)

Хәер, ул елларда татарның үткән язмышы, чын тарихи мирасы белән кызыксыну үзенә күрә бер мәртәбә санала иде шул. Бу хәл бигрәк тә яшьрәк буын язучылар арасында, университетның

татар студентлары арасында киң тарала башлаган бер күренеш иде. Андый яшьләрнең алгы сафында булачак олуг галимнәр Миркасыйм Госманов, Сәлам Алишев, Әзһәр Мөхәммәдиев, Марат Мөлеков һ.б.лар торды. Нуриханның ул елларда булачак тарих фәне докторы Сәлам Алишев белән аеруча дустанә мөнәсәбәттә булганлыгын беләм. Сәлам ага белән бер фәнни институтта эшләгән, борынгы скифларның бер өлешенең төрки булулары турында хезмәт язарга җыенган галим Җәвад Алмаз да Нуриханга якын фикердәш булгандыр, мөгаен. Чөнки ул да бит скифлар атамасының төрки җирлекле булуы турында яза «Ерак гасырлар авазы» хезмәтендә. Үкенеч ки, Җ.Алмазның «Царские скифы тюрки» («Патша скифлары төркиләр») дип исемләнгән, җитди гыйльми эзләнүләр нәтиҗәсе булган хезмәте әле дә дөнья күрә алмый. Милли музей архивында тузан җыеп ята. Башка милләт мирасында андый хезмәт булса, аны инде күптән «тарихи бер версия» дип тамгалап чыгарган булырлар иде.

Сарьян Хәсәневнең шәһәр уртасындагы иркен фатирында «тарихка мөкиббән булган» чордашларның җыелышкалауларын, бәхәсләшүләрен дә хәтерлим. Ул чорда анда Нурихан да еш була иде. Шундый бер утырыштан соң, бер кочак тарихи китапларын күтәрешеп, Киров районының бер почмагындагы өенә озатып куйганым да булды. Башлыча кытай һәм рус тарихчылары язган ул калын-калын томнарны Нурихан икенче зур тарихи романын — «Сызгыра торган уклар»ны язганда кирәк тапты. Тарихи җирлекне тәгаен белмичә торып, укучыны ышандырырлык әсәр язып булмый, билгеле. Сарьян белән Нуриханның ул еллардагы дустанә мөнәсәбәтләрен белгерткән тагын бер-ике мисалны билгеләп үтим. Ул замандагы рәсми һәм рәсми булмаган олы бәйрәмнәрне дә алар гаиләләре белән бергә уздырырлар иде. Ниндидер бер мәҗлестән соң Нурихан белән Руфинәне озата барып, аларда кунып калганым да хәтеремдә. Ә Нурихан Чыңгыз бистәсе тирәсендә яңа йорт төзергә дип йөргән бер мәлдә, аңа иң беренче ярдәм күрсәтүче кеше дә шул балта остасы Сарьян булды. Бер сәүдәгәрдән калган таза бүрәнә йортны да алар икәү сайлап алдылар. «Бүрәнәләре корыч кебек чыңлап тора. Чәере белән бергә каткан карагай бүрәнәләр», — дип мактый-мактый, Чехов урамы тирәсендәге ул йортны аннары өчәү дә карап йөргән идек әле. Чыңлап торган коры бүрәнәләрдән салынган ул йорт аннары Чыңгыз белән Нагорный бистәләре арасына барып утырды. Белүемчә, бүген дә әле ул өй Фәттаховлар гаиләсенә хезмәт итә.

Нуриханның бик гаилә җанлы кеше булганлыгын да әйтү кирәктер, мөгаен. Әдәби фонд оешмасының җирле идарәсе җитәкчесе булып эшләгән елларда мин аңа иҗат йортларына путевка-юлламалар булуын хәбәр иткәли идем. «Күп эшлисең, бераз ял

итеп кайт. Сихри диңгез буйларында йөреп кайту файдага гына булыр», — дип «кодалый» идем. Чөнки ул, кайберәүләр кебек: «Фәлән айда мине фәлән җиргә җибәр», — дип дәгъвалап йөрүчеләрдән түгел иде. Ләкин ул еш кына: «Руфинә эштән китә алмый. Аңардан һәм балалардан башка мин беркая да йөрмим», — дип җавап бирер иде.

Язучы Нурихан Фәттахны мин икеләнмичә чын тарихчы буларак кына түгел, телче сыйфатында да иң алдынгы телче галимнәребез белән янәшә куям. Аның халкыбызның ерак тарихын күзалларга ярдәм иткән «Әтил суы ака торур», «Сызгыра торган уклар» (трилогия) романнары, «Кол Гали», «Сармат кызы Сәринә» трагедияләре мәңге яшәгән кебек, бер үк вакытларда язылган «Ерак гасырлар авазы», «Шәҗәрә» кебек фәнни хезмәтләре дә милләтебезнең югалмас мирасы булып калыр. Дөрес, «Шәҗәрә» белән «Ерак гасырлар авазы» әлегә тиешле бәяләрен алмадылар шикелле. Киләчәк буын галимнәре ул хезмәтләрне кайта-кайта барларлар, бәяләрләр дигән ышанычта калам.

Нурихан Фәттах иҗаты белән кардәш казакъ әдәбияты вәкилләре дә кызыксыналар иде. «Әтил суы ака торур» романы басылып чыкканнан соң, 1974 елның көзендә миңа Алма-Ата шәһәрендә булырга туры килде. Ике кардәш әдәбият үрнәкләрен уртаклашу, иң күренекле дип саналган әсәрләрне алмашып, тәрҗемә итешүне җайга салу өчен мине анда Татарстан Язучылар берлеге җитәкчелеге җибәргән иде. Казакъстан Язучылар берлегенең ул вакыттагы икенче секретаре Ильяс ага Есенберлин, уртак мәсьәләгә күчкәнче үк, «Әтил суы ака торур» романы белән таныш булуын, аның авторы белән элемтә урнаштырырга теләге барлыгын белгертте. Үзе дә ул соңгы вакытта борынгы төркиләр тормышын чагылдырган әсәрләр язуга өстенлек бирә икән. Аның тарихи эчтәлекле «Бәрелеш», «Хан көне», «Булат кылыч» кебек әсәрләре казакъ әдәбият сөючеләре тарафыннан хуплап, яратып кабул ителгән. Шул хезмәтләре өчен аңа 1968 елда Абай исемендәге Дәүләт бүләге дә бирелгән. Инде ул «Күчмәләр» дип исемләнгән роман-трилогияне язып төгәлләгән, шуны хәзер «Кочевники» исеме белән Мәскәүдә рус телендә бастыру мәшәкате белән мәшгуль икән. «Нурихан Фәттах үз романын бездә чыгарырга килешсә, тиз арада ике данә китабын безнең Язучылар идарәсенә, минем исемгә җибәрсен»,— дип калды Ильяс ага. Казанга кайткач та мин бу сөенечле сөйләшүне Нуриханга җиткердем. Әдип ул тәкъдимне кабул итте һәм күпмедер вакыттан соң ике данә «Әтил суы ака торур» китабын Алма-Атага җибәргәнлеген дә әйтте. Ләкин үз вакытында роман казакъ телендә басылып чыкмый калды шикелле. Бердән, нәкъ шул елларда күп кенә татар роман һәм повестьларын казакъчага тәрҗемә иткән милләттәшебез Барый ага Мәҗитов вафат булды. Ильяс Есен-

берлин да аннан соң озак яшәмәде. 1978 елда кабат Алма-Атага барганда мин инде аның белән күрешә алмадым. «Китте шул инде ул, соңгы йортына китте», — дип әйттеләр. Эш урынында аны татар милләтен тагын да якынрак күргән, казакъ илендә татар җырларын оста җырлавы белән дан казанган Шерхан Мортазаев алыштырган иде. Нурихан Фәттахның тарихи романын казакъчалаштыру турында Ильяс ага белән сүз булган иде, дидем мин аңа. «Хәзер татар телен яхшы үзләштергән тәрҗемәчеләребез бик аз калды шул. Романның русча вариантын да җибәрә алмассызмы»? — диде Шерхан. Кайткач та мин аның үтенечен үтәгәнмен. Архивымда «Әтил суы ака торур»ның русчага тәрҗемәсен җибәрүем турындагы хат копиясе сакланган.

Нуриханның тарихи романнарын татар халкы һич тә онытмастыр дип уйлыйм. Ул әсәрләр кабат һәм кабат басылыр, киләчәк буыннар да аларны укудан мәхрүм ителмәс. Шул ук вакытта ул романнарны һәм тарихыбызның төрле катлаулы чорларына багышланган фәнни хезмәтләрне башка телләргә күчереп язу бурычы да киләсе буын карамагына тапшырыла. Уңыш юлдаш булсын аларга.

*«Мәдәни җомга», 2007, 13 июль*

## ОСТАЛАРНЫҢ ОСТАЗЫ

Татар әдәбиятын, татар китабын үз иткән, яраткан һәркемгә язучы Рәис Даутов исеме якын булырга тиеш. Ул — кырык ел гомерен язма мирасыбызны барлау һәм дөньяга чыгаруга багышлаган олуг шәхесләребезнең берсе. Татарстан китап нәшриятында эшләү дәверендә елына унике китапка «җан өреп», нәшер итүгә әзерләгәндер дип уйласак та, аның каләме аша татар укучысы кулына биш йөзләп рухи хәзинә барып ирешкән була. Ә аның әле гадәти мөхәррир генә түгеллеген, әдәбият фәне өлкәсендә галим-текстолог икәнлеген дә истә тотарга тиешбез.

Борынгы әдәби ядкәрләрдән Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ын, Утыз Имәни, Габделҗаббар Кандалый, Заһир Бигиев, Акмулла, Дәрдемәнд әсәрләре җыелмаларын, Габдулла Тукай, Галиәсгар Камал, Галимҗан Ибраһимовларның сайланма томлыкларын Рәис Нәүширван улы Даутов редакцияләп чыгарды. Төрле чор, төрле гасырларда иҗат иткән шәхесләребезнең мирасын бүгенге көн таләпләренә туры килердәй итеп бастырып чыгару зур осталык таләп итә. Андый китапларның кульязмасын әзерләгәндә нәшрият мөхәррире әдәбият галиме дә булырга тиеш. Егерменче гасырның икенче яртысында Татарстан китап нәшриятында Рәис Даутов шундый осталыкка ирешкән иң дәрәҗәле мөхәррир иде.

Хәзерге көндә аңа тиң әзерлекле мөхәррирләргә барлык нәшриятлар да зур мохтаҗлык кичерә.

Мамадыш районының Шәмәк авылында туган Рәис Казан педагогия институтында белем ала. 1953 елның февралендә Татарстан китап нәшриятына эшкә билгеләнә. Шәхес культына бәйле булган сәяси торгынлыкның чигенә башлаган чоры. Татарның бөек әдипләреннән Фатих Әмирхан, Дәрдемәнд, Галимҗан Ибраһимов, Кәрим Тинчурин, Шакир Мөхәммәдев, Шамил Усманов кебек башка күренекле шәхесләр иҗатының кабат халкына кайтарыла башлаган чоры була ул.

Соңгы алтмыш-җитмеш еллык дәвердә татар халкының милли йөзен, телен саклап калуда Татарстан китап нәшриятының тоткан урыны бәяләп бетермәслек дәрәҗәдә зур булды. Чөнки ул татарның бердәнбер үз нәшрияты иде. Анда әлифбадан башлап барлык төр милли дәреслекләр, борынгы һәм бүгенге әдәби җәүһәрләр, аратирә генә булса да иҗтимагый-сәяси яки тарихи эчтәлекле китаплар нәшер ителде. Ул елларда китапларның тиражлары да унарйөзәр мең данә исәпләнер иде. (Хәзерге көндә иң үтемле дип саналган китапның да тиражы өч-дүрт мең данәдән артмый.) Халыкның рухи тормышын тулаем канәгатьләндереп бетермәсә дә (дини эчтәлекле хезмәтләрне басарга рөхсәт ителмәгән заман иде), зур күләмдә басылулары сәбәпле, ул китаплар һәр йортка барып җитәр, туган телебезне оныттырмауга бер сәбәп булып торыр иде. Рәис Даутов та шул беренче карлыгачларны чыгаруга җиң сызганып керешә. Хәтта берара, редакция мөдире буларак, дистә еллар дәвамында онытылыбрак торган олуг мирасны кабат халкына кайтару эшендә башлап йөрү бурычы да аңа йөкләнгән була.

Шул ук елларда аның тәүге үз хезмәтләре — әдәби тәрҗемәләре күренә башлый. Дөнья һәм рус классик әдипләре әсәрләреннән М.Твен, Ф.Купер, Ф.Достоевский һ.б. романнары, Э.Хемингуэй, О.Генри, А.Куприн һ.б. хикәя, повестьлары татар укучысына аның тәрҗемәсендә барып ирешәләр. Шәхес культы чоры корбаны булган Мәхмүт Галәү-Мәрҗанинең «Мөһаҗирләр» романына яңа сулыш өрүче дә Рәис Даутов булды. Патша Россиясе хакимиятенең сәяси кысу-эзәрлекләүләренә түзмичә чит илгә чыгып китәргә мәҗбүр ителгән татар гаиләләре язмышын тасвирлаучы бу җитди әсәрнең татарча варианты да авторы белән бергә «кулга алынган», юкка чыккан иде. Аның сакланып калган русча нөсхәсеннән Рәис яңа роман язарга тиеш була. Шул хезмәткә тотыныр алдыннан аңа М.Галәүнең барлык иҗатын барларга, үз күңеле аша уздырырга туры килә.

Тәрҗемә өлкәсендә дә Рәис Даутов бик күп каләмдәшләренә үрнәк һәм остаз була алды. Татар теле һәм әдәбияты тарихын тирәнтен белү, яшьли татарның зыялы катлавы белән якыннан ара-

лашу аның оста тәрҗемәче булып танылуының төп нигезләредер. Форсаттан файдаланып кына булса да әйтеп үтик, ул — мәшһүр драматург һәм танылган артистлар династиясе саналган Камаллар гаиләсе даирәсенә кергән бәхетле затларның берсе. Шул татар зыялыларының ишле гаилә вәкиле булган драматург Әнәс Галиәсгар улы Камалның кияве иде. Хәер, Рәиснең үз нәселен дә зыясызлардан дип булмый. Атасы Нәүширванның гарәп язуындагы әдәбиятны яхшы үзләштергән булуын хәтерләүчеләр бар.

Әйе, Рәис Даутовның тәрҗемә өлкәсендәге эшчәнлеге дә үрнәк булырлык. Әдәби тәнкыйтьтә аның хезмәтләре уңай бәяләнде. Аның тәрҗемәсендә дөнья күргән китаплардан аеруча Достоевскийның «Җинаять һәм җәза», Купринның «Атышу», «Гранат кашлы беләзек», Куперның «Соңгы могикан»ы турында Афзал ага Шамов, Кыям Миңлебаев, Таһир Нурмөхәммәтев, Равил Фәйзуллин, Наис Гамбәров һ.б. тарафыннан байтак җылы сүзләр язылды.

Рәис каләмдәшнең тагын бер эшчәнлеген аерым билгеләп үтү кирәктер. Татар әдәбиятын пропагандалауга ул мөһим бурыч дип карый. Көндәлек татар матбугатында, еллык календарьлар битләрендә төрки-татар әдипләренә, аларның аерым әсәрләренә багышланган күпсанлы мәкаләләре басыла. 1986 елда аның Совет чоры татар язучыларының тормыш-көнкүрешенә һәм иҗатларын барлауга багышланган зур күләмле хезмәте дөнья күргән иде. Былтыр гына «Мәгариф» нәшрияты Р.Даутовның «Балачак әдипләре» исемле җыентыгын бастырып чыгарды. Китап эчтәлеге, сурәтләү теле җәһәтеннән дә, техник эшләнеше ягыннан да бик зәвыклы, затлы итеп эшләнгән. Җыентыкка бүгенге көндә актив иҗат итүче утызлап күренекле язучыга караган биобиблиографик белешмә кергән. Һәр язучының анда үзе язган истәлек-хатирәсе урнаштырылган. (Китапның 4 нче томы 2007 елда чыкты.)

Рәиснең иҗади эзләнүләренең тагын бер юнәлеше — төркитатар дөньясына караган борынгы язмаларны һәм белешмәлекләрне туплау, өйрәнү. Тикмәгә генә аны шәкертләре «рәсми дәрәҗә алмаган академигыбыз» дип атап йөртмиләрдер. Татар шигъриятe антологиясен төзүгә керешелгән илленче еллардан бирле ул элекке гасырларда иҗат иткән шагыйрь, әдипләребез мирасын туплауга җитди игътибар бирә. Антологияләргә кермәгән яисә ул тупламаларда иҗатлары тулаем чагылыш тапмаган (антология булгач, анда сайланма әсәрләр генә урын ала ич) күп кенә авторларның мирас хәзинәсе Рәис Даутовның китап киштәләрендә нәшер ителү чиратын көтәләр. Аның тарафыннан кат-кат эшкәртелеп, нәшер ителгән хәзинәләр исәбенә мәшһүр әдип Заһир Бигиевның «Зур гөнаһлар» исеме белән чыккан җыентыгын атарга кирәктер. Ул китапка ике роман һәм бер юлъязманың бүгенге укучыга авыр аңлаешлы төп нөсхәләре дә, авторына багышлы

күләмле биографик очерк һәм төзүче-тәрҗемәченең бай мәгълүматлы искәрмәләре дә урнаштырылган. Мәгълүм ки, Заһир Бигиев — татар дөньясында беренче романнар иҗат иткән шәхес. «Мавәраэннәһердә сәяхәт» исемле күләмле юлъязмасы да бай, тирән эчтәлекле җитди әсәр. Аңа Фатих Әмирхан да «хәзергә кадәр татар әдәбиятында тиңе булмаган әсәр» дип бәя бирә. Китапка кергән әсәрләрнең барысы да унтугызынчы гасырның икенче яртысында иҗат ителгәннәр. Безнең дәвер укучысы кулына ул әсәрләр беренче мәртәбә диярлек Рәис Даутов тырышлыгы нәтиҗәсендә килеп керде, кайтарылды.

Язучы, журналист һәм матбугат тарихы белгече Исмәгыйль Рәмиев мәдәният өлкәсендә зур эз калдырган вакыйгаларга һәм шәхесләргә багышлап кайчандыр кулъязма сүзлек төзегән иде. Рәис Даутов «Мәдәниятебез фидакяре» дип исемләнгән күләмле очеркында бу хакта түбәндәге сүзләрне яза: «1961 елда И.Рәми (сөргеннән)... Казанга күчеп кайта. Нәкъ шул вакытларда өлкән әдипләрдән бер төркем дуслары (Н.Исәнбәт, А.Шамов, Ә.Еники һ.б.) аңа... Октябрьгә кадәрге татар әдәбияты буенча кыскача белешмәлек төзергә киңәш итәләр. Әдип илһамланып эшкә тотына һәм алтмышынчы еллар ахырларына «Әдәби сүзлек» дип аталган хезмәтен төгәлли». Шул ук елларда И.Рәми аны китап итеп бастыру хәстәренә дә керешә, ләкин уңышка ирешә алмыйча үлеп китә. Ул кулъязма хезмәт җирлегендә 2001 елда ике автор исеменнән (И.Рәми, Р.Даутов) «Әдәби сүзлек» китабы басылып чыкты. Рәис Даутов энциклопедик әһәмияткә ия ул китапны Исмәгыйль аганың башка төр кулъязмалары һәм үзенең авторлык өстәмәләре исәбенә шактый тулыландырган. Бүгенге көндә ул сүзлек-китап татар әдәбияты вә мәдәнияте тарихы белән кызыксынучы һәркемнең эш өстәлен бизәрлек бер зур хезмәт буларак кабул ителә.

Рәис Нәүширван улының тагын бер җитди хезмәтен күрсәтеп китәсе килә. 1992 елда Татар энциклопедия институты оештырыла. Галимҗан Ибраһимовның сигез томлык иҗат мирасын нәшер итүгә әзерләгәндә бергә эшләүләрен истә тотып, институт директоры академик М.Хәсәнев Рәис Даутовның энциклопедик белеме һәм тәҗрибәсеннән файдалану ниятеннән чыгып, аны үзенә чакырып ала. Булачак зур күләмле энциклопедия томының беренчел нигезен тәшкил итәсе лөгатьлекне төзү бурычын йөкли. Шул рәвешле, саф татар телендә төзелгән беренче энциклопедик белешмәлек 1996 елда басылып чыга (нәшер-хисап күләме 35 табак). Әлбәттә, аңа кергән мәгълүматны туплашуда, элек татар телендә кулланышта булмаган йөзләгән термин-атамаларга үз телебездә тәңгәл килердәй исемнәр барлашуда байтак кына галимнәр җәлеп ителә. Мәгәр ул эшне оештырып, тәртипкә салып һәм туплап чыгаручы — шул эшкә тәгаенләнгән өлкән фәнни

хезмәткәр һәм әдип-мөхәррир Рәис Даутов булуы безнең өчен мәртәбә, билгеле.

Рәис Даутовның язучылык хезмәтенә бәйле өлкәдә дә, мөхәррир буларак та шәкертләре бик ишле. Аны бүген зур-зур дәрәҗәле исемнәр алган, иҗатлары бөтен халыкка билгеле булган абруйлы сүз осталары да, матбугат өлкәсендә эшләп килүче байтак кына мөхәррирләр дә остазлары дип таныйлар. Икеләнмичә әйтә алабыз — бүгенге заман татар әдәбиятының күренекле осталарының бик тә абруйлы остазы ул. Шигырь һәм хикәя осталарына тукталмастан, татар мәдәниятендә күптән үз уңышлары булган кайбер мөхәррирләрне генә атап үтәсем килә. Шул бүгенге осталарның остазы булган Рәис Даутов янәшәсендә эшләп, аннан күп нәрсәгә өйрәнгән шәхесләр. Татарстан китап нәшрияты җитәкчелеге, аеруча Гарәф Низаметдин улы Шәрәфетдинов эшләгән дәвердә алмаш әзерләүгә аеруча зур әһәмият бирелде. Шул елларда Рәис ярдәмендә оста мөхәррир булып җитешкән, яхшы тәҗрибә туплап, үз сукмагына баскан кешеләрдән мәрхүм Фәез Зөлкарнәевне (соңыннан ул «Татар әдәбияты тарихы» томнарын редакцияләде), Харрас Әюповны (хәзер Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире), Наис Гамбәровны (соңгы елларында «Казан утлары» журналында бүлек мөдире булды), Рафыйк Юнысовны («Идел», аннары «Казан утлары» журналларының баш мөхәррир урынбасары), Равил Рахманины (Татарстан китап нәшриятында «Мирас» редакциясе мөдире буларак байтак саваплы эш башкарды) атап була. Равил Рахмани, остазы эшчәнлеген дәвам итеп, соңгы дистә елда китап нәшриятында борынгы әдәби ядкәрләрне, егерменче гасыр башында дан казанган кайбер зыялыларыбызның сайланма хезмәтләрен барлап нәшер итте. Бүгенге көндә ул, мәрхүм остазы үтенечен үтәп, аның соңгы елларда эшләгән эшләрен барлап, шул кульязмаларны нәшриятка әзерләү белән мәшгуль.

Рәис Даутов белән беренче танышуым алтмышынчы елларга туры килә. Ул дәвердә яшь язучылар иҗатына багышлап ел саен бер җыентык әзерләнә иде. Шундый китапларның берсенә минем «Дәгъва» исемле озын хикәям дә тәкъдим ителде. Ул тупламаның проза өлешен Рәис редакцияләде («Кайнар хисләр» китабы, 1966). Якыннан танышу-аралашуларыбыз шул көннәрдән башланып китте. Хәзергәчә иҗади дустанә мөнәсәбәттә яшәдек. Берничә ел дәвамында бергә Татарстан китап нәшриятында эшләдек. Соңрак бергә-бергә Татар энциклопедик институтында «бер арба»ны тарттык: татар дөньясында беренче мәртәбә үз телебездә җирле-милли энциклопедик сүзлекне нәшер иттек. Ул «арба»ны төпкә җигелеп тартучы, төп юнәлеш бирүчебез Рәис Даутов булса, тәртә ягаларыннан ярдәмләшеп баручылар — аның күптәнге каләмдәшләре һәм хезмәттәшләредер. Зур күләмле (йөз утыз җиде

табаклы), бай мәгълүматлы татарча энциклопедия сүзлеген туплау 2002 елның декабрендә тәмамланды һәм редакцион советта расланды. Рәис Даутовның җитмеш биш яше тулган көннәрдә шундый зур күмәк хезмәтне басмаханәгә тапшыру үзенә күрә бер юбилей бүләге булып кабул ителде.

*«Казан утлары», 2003, № 3*

## «ГЫЙБРӘТЛӘР АЛЫРЛЫК ҮТКӘН ЮЛ»

Узган елда «Казан утлары» журналының 8 нче һәм 9 нчы саннарында Равил Фәйзуллинның шушы исем астында зур бер хезмәте әдәбият сөючеләр хөкеменә тапшырылды. Ул Татарстан Язучылар берлеге төзелүнең 70 еллыгын билгеләп үткән көннәргә атап язылган. Фактик материалга бик бай, тирән мәгънәви эчтәлекле бу хезмәт озакламыйча зәвыклы бер китап рәвешендә дә дөнья күрде («Гыйбрәтләр алырлык үткән юл», 2004). Китапка яңа мәгълүмат та, фотосурәтләр дә өстәлгән. Ул соңгы елларда «Идел-Пресс» матбугат базасы ирешкән югарылыкта, җыйнак, матур итеп туплап чыгарылган.

Татарстанның халык шагыйре, күренекле җәмәгать эшлеклесе Равил Фәйзуллинның бу хезмәтне язарга алынуына, каһарманлыгына сокланмыйча, аның эзләнүләре һәм табышлары алдында баш имичә мөмкин түгел. Китапка кергән мәгълүматны төрле чыганаклардан алып туплау, тәртипкә салу һәм тәфсилләп язып чыгу өчен бик күп эзләнергә, уйланырга кирәк булгандыр, мөгаен. Язучылар берлегендә байтак еллар эшләгән кеше буларак беләмен ки — архив материалларын саклау эше анда таләп ителгән тәртипкә салынмаган иде диярлек. Дөрес, Язучылар берлегенең VII съезды якынлашкан көннәрдә, Берлекнең җаваплы секретаре Зәки Нури Дәүләт архив идарәсе вәкилләрен чакырып китереп, 1934–1968 еллар арасында тупланган документларның бер өлешен аларга тапшырып киткән иде. Ләкин Дәүләт архивы ул вакытта күп кенә документны, шул исәптән язучылардан, төрле оешмалардан килгән хатларны, яшь язучылар җибәргән әсәр үрнәкләрен алмады шикелле. Архивка кирәкмәс кәгазьләр арасында, мәсәлән, Казаннан читтә яшәүче яшь һәм башлап язучылардан кергән шигырьләр, хикәяләр бар иде. Архив вәкилләре калдырып киткән ул кәгазьләр өеме берәр ай чамасы Язучылар берлеге биләгән бина коридорында аунап яттылар әле. Теләгән кеше, актарынып, аннан үзе кирәк санаган документны алып та китә ала иде. Мәсәлән, үзем мин Муса Җәлилнең култамгасы сакланган бер-ике язманы (берсе — Шәриф Камалга орден бирер алдыннан тутырылган характеристиканың икенче экземпляры), Газиз Укмасиның Язучылар берлегенә кабул ителү

уңаеннан тутырылган «дело»сын (күптән түгел иске кәгазьләрне актарганда ул папка кабат күземә чалынды да, бер читкәрәк алып куйдым әле, анда язучының үз кулы белән язган автобиографиясе дә бар) һәм Әдәби фонд идарәсенең 1938–1940 елларга караган протоколлар журналын алган идем. Кызганыч, бик гыйбрәтле язмалар тупланган ул журнални мин, киләчәк өчен кирәк булуы ихтимал дигән уй белән, 1983 елда эштән киткәндә СССР Литфонды уставы һәм башка җитдирәк документлар белән бергә сейфта калдырган идем. Соңыннан әлеге устав та, каһәрле елларның күз яшьле һәм фаҗигале вакыйгаларын теркәп барган протоколлар да юкка чыккан булды. Язучылар берлеге хәзерге Мөштәри урамындагы яңа бинага күчкәндә калдырылган кәгазь өемнәре арасында алар юкка чыкканнардыр, мөгаен.

Р.Фәйзуллинның «Гыйбрәтләр алырлык үткән юл» китабын зур бер гыйльми хезмәт, фәнни эзләнү нәтиҗәсе буларак кабул иттем мин. Әдәбият, мәдәният өлкәсендә эшләүче галимнәребез дә, әдәбият сөючеләребез дә аны шулай кабул итәрләр, шәт. Чынчынлап рәсмиләштерә калсаң, мөгаен, «Гыйбрәтләр алырлык үткән юл» язмасы фән докторы дәрәҗәсенә лаек бер хезмәттер. (Шушыңа охшаш тагын бер очрак хәтергә килде әле. Берничә ел элек шул ук «Казан утлары» журналында мәрхүм каләмдәшебез Тәүфикъ Әйдинең төрек әдәбиятына һәм төрек әдәбияты белән татар әдәбияты арадашлыгына багышланган бик тәфсилле, тирән эчтәлекле хезмәте басылып чыккан иде. Бер очрашу вакытында мин Тәүфикъка: «Бу хезмәтең белән син кимендә фән кандидаты була аласыңдыр. Шуңа тырышмыйсыңмы?» — дип әйткән идем. «Галимнәребездән андый тәкъдим булмады әле. Хәер, алардан әлегә, язмаңны укыдым, уңышлы эш башкаргансың, дигән хуплау сүзләрен дә ишеткәнем юк», — дип җавап биргән иде әдип.)

Равил Фәйзуллин, нәкъ әдәбият гыйлеме таләп иткәнчә, хезмәтен чорларга бүлеп тасвирлый — дүрт дәвергә бүлеп бәян итә. (Хәер, безнең галимнәрдә ул чор-дәверләрнең чикләре башкачарак билгеләнә бугай. Равил аңа, шул иҗат берлегендә кырык елдан артыграк эш йөрткән, «ат уйнаткан» шәхес буларак, үзгәрәк чикләр билгели.) Әдәбиятыбыз тормышындагы һәр чорга кереш өлешендә автор кыскача гына илдә барган сәяси вазгыятьне дә тасвирлап үтә. Китапның һәр дәвер-чорда актив иҗат иткән шәхесләрнең фоторәсемнәре белән тулыландырылган булуы да бик уңай күренеш. Шулай ук китапның соңгы битләрендә татар әдәбияты һәм мәдәниятенең төп үсеш чорларын, үзгәлекләрен теркәп баручы әдәби журналыбызның («Казан утлары»ның) кыскача «биографиясе» дә баш мөхәррирләренең фотосурәтләре белән бергә урын алган (1908–1918 елларда нәшер ителгән «Шура», 1912–1918 елларда чыккан «Аң» журналларының да тышлык сурәтләре бирелгән).

Хезмәтенең төп максатын Р.Фәйзуллин түбәндәге юлларда бәян итә: «Язучылар оешмасының бу юбилей датасы уйлану-фикерләшү өчен бер сәбәп кенә. Төп мәсьәлә — безнең рухи киләчәгебез. Киләчәк турында төпле фикер йөртер өчен үткәннәрне белеп гыйбрәт алу, бүгенгене хәл кадәри анализлау фарыз. Алда әйтелгәнчә, соңгы чор әдәбиятыбыз тарихы (ягъни егерменче гасыр әдәбиятының зур бер өлеше) Язучылар оешмасы белән тыгыз бәйләнгән. Язма авторы буларак искәртеп узыйм, минем дә бу оешма белән гомерем тоташкан, аның өчтән ике өлеше турыдан-туры аңа бәйле, 40 елга якын Язучылар берлегендә әгъза булып торып, шуның 37 ел дәвамында тоташтан шушы оешманың идарә әгъзасымын. Уйлап баксаң — үзе бер гомер. Шуңа күрә Язучылар оешмасы, аның эшчәнлеге турында уйланып фикер әйтергә хакым бар шикелле». Бу сүзләрне шәрехләп тору артык булыр. Өстәп шуны гына әйтим, Язучылар берлеге оешкан заманнан башлап хәзерге көнгәчә язучылар «колхозы»ның идарәсендә шулай озаклап җитәкчелек итүчеләр дүрт-биш кенә кешедер, мөгаен. Идарәчелектә йөрүче олпат шәхесләрдән беренчелекне, еллар исәбе белән санаганда, Гариф Ахунов тота. Аның «стажы» 41 ел: 1958 елда IV съездда идарә әгъзалыгына сайлана һәм вафатына бер ел кала, 1999 елда аннан китә. Өстәвенә 10 ел дәвамында идарә рәисе булып та эшли. Икенче урында Равил Фәйзуллин. Ул да берничә ел язучыларның Әлмәт оешмасына җитәкчелек итте, Берлек рәисенең беренче урынбасары булды. Унбиш еллап инде ил күләмендә танылган «Казан утлары»ның баш мөхәррире — шушындый катлаулы елларда журналның дәрәҗәсен күтәрүгә, тиражын үстерүгә зур көч куйды. Равилдән соң идарәдә күп еллар дәвамында әгъза булып торучылар исемлегендә Сибгат ага Хәким: 1954 елда беренче тапкыр идарәгә кертелә һәм 32 ел чамасы шунда эшли. Чирек гасырга якын абруйлы әгъза булучылар исемлегендә шулай ук Берлекнең элеккеге рәисләре Мирсәй Әмир, Гомәр Бәширов, Афзал Шамов та бар.

«Гыйбрәтләр алырлык үткән юл» китабында китерелгән мәгълүматларның кайберләренә ни-нәрсәдер өстисе, кайбер нәрсәләрне ачыклый төшәсе дә бар шикелле. Аларны ачыкларга тырышуларым Равил Фәйзуллин хезмәтеннән хата эзләү дип кабул ителмәстер, шәт. Минем максат — ул җитди хезмәтне фәкать тулыландырырга бер омтылыш ясау. Әдәбият сөючеләр дә аны шулай фаразлар дип уйлыйм. Әйтик, идарә җитәкчеләрен сайлау тәртибе китапта берничә урында әйтеп кителсә дә, тулы ачыклык кертелми әле, минемчә. Язучылар берлеге оешкан көннән, I съезддан башлап (1934) 1989 елдагы X съезд аралыгында узган гомуми җыелышларда (съездларда) идарә генә сайланды. Илдәге үзгәртеп корулар вакытына туры килгән XI съезддан башлап кына идарә

рәисләрен яшерен тавыш бирү юлы белән күмәкләп сайлау тәртибе кертелде. Шуңа күрә безнең матбугатта һәм тикшереләсе китапта еш кабатланган «фәлән съездда фәлән кеше рәислеккә сайланды» дигән сүз тезмәсендәге хәбәр дөрес үк түгел. Рәисне идарә әгъзалары үз араларыннан беренче утырышта сайлыйлар иде. Съезд беткәч тә таралышкан күпчелек еш кына аның кем булуын ул кичтә белми кала иде. Мәсәлән, 1968 елда узган съезд барышында «обкомда сөйләшкәндә рәислеккә Сибгат Хәкимне күндергәннәр икән» дигән сүз йөрде. Съездан соңгы беренче идарә утырышында исә Ибраһим Гази сайланды, Сибгат ага ул вазифадан баш тартты. Съезд араларында рәисне алыштыру очраклары да шактый еш кабатлана иде. Сугыштан соңгы дәвердә генә дә Ә.Ерикәй, Г.Гобәй, А.Шамов вакытыннан алда «үз теләкләре» белән ул эштән киттеләр. И.Гази вафатыннан соң (1971) идарә утырышында рәислек вазифасын үтәү Зәки Нурига тапшырылды. Сугыштан алдагы елларда, илдә барган репрессия вакыйгаларына мөнәсәбәтле рәвештә, идарә рәисләрен алыштыру, идарәгә өстәмә вәкилләр билгеләп кую гамәлләре елга берничә мәртәбә булып тора. Мәсәлән, 1937 елда Язучылар берлегендә дүрт рәис алышына, шулардан икесе, шул исәптән Мирсәй Әмир әле I съездда идарәгә дә сайланмаган була (Кави Нәҗми, Ләбиб Гыйльми — идарә әгъзалары). 1938 елда Берлек җитәкчелегенә билгеләнгән Нур Баян, 1939 елда сайланган Муса Җәлил дә идарәгә соңрак кертелгәннәрдер, күрәсең. Китапта сугыш елларында идарә җитәкчесе булып алган (1944–1945) Гази ага Кашшаф та аерып күрсәтелми — архив материаллары сакланмагандыр, мөгаен. Ул елларда Г.Кашшаф оештыру эшләрендә актив катнаша. Бөек Ватан сугышы башланган айларда Казанга һәм Татарстанның башка төбәкләренә эвакуацияләнеп килүче рус һәм чит ил язучыларын урнаштыру эшләрендә аеруча таныла.

Кайбер язучыларның әгъзалыкка алыну елларына бәйле исемлекләргә карата булган шик-шөбһәләрем. I съездда әгъзалыкка һәм әгъзалыкка кандидат булып кабул ителүчеләр исемлегендә (22 б.) кайберәүләр әгъза буларак теркәлгән. Берничә биттән соң шул ук кешеләр «әгъзалыкка кандидатлар» төркеменә дә кергән. Шундый ук хәл И.Газигә, А.Шамовка карата да күзәтелә. Бу очракта төп гаеп «замана»га бәйле булса кирәк. Мәсәлән, 1938 елга караган бер язмада «хәзер Язучылар берлегендә 8 генә әгъза калды» дигән хәбәр бар. Димәк, кулга алынмаган язучылардан да кемнәрдер әгъзалыктан төшерелгән булган. Кайбер хатирәләргә караганда, Язучылар оешмасыннан 1937 елның август ахырларында Мөхәммәт Гали, Афзал Шамов (тагын кемнәрдер) чыгарылалар. А.Шамовның төп гаебе «халык дошманнары»на булышлык итү була. Ул китап нәшриятында бергә эшләгән каләмдәше Фа-

тих Кәримне яклап сүз әйткәне һәм Кәрим Тинчуринның хикәяләр җыентыгын, тагын кемнәрнеңдер «шикле» китапларын чыгаргандагы «талымсызлыгы» өчен гаепләнә. Бер елдан соң гына яңадан кандидат итеп алына, ә 1939 елда Муса Җәлилнең рәсми урынбасары итеп сайлана. Язучыларны әгъзалыкка кандидат итеп кабул итү тәртибе 1934–1959 еллар аралыгында гамәлдә була. Кандидатлыкка кабул ителгән язучыны шул елда ук Әдәби фондка әгъзалыкка алу һәм Литфонд уставында күрсәтелгән мөмкинлекләрдән файдалану тәртибе каралган була. Татарстан оешмасында яңа карар чыкканчы алынган иң соңгы кандидатлар Мәхмүт Хөсәен, Сафа Сабиров, Рәисә Ишморатова иде. 1958 елдан башлап алар Литфондта тулы хокуклы әгъза булып тордылар, ә менә Язучылар берлегенә бик соңлап кабул ителделәр.

Мәскәүдә уздырылган барлык СССР һәм РСФСР съездларына һәр оешма рәсми делегатлардан кала сайлау хокукы булмаган кунакларны да алып бара иде. Кайсы оешмадан ничә кунак килергә тиешлеге съездны оештыручылар тарафыннан билгеләнә иде. Гадәттә аларның саны рәсми делегатларның яртысы чамасын тәшкил итә, исемлеге идарә тарафыннан билгеләнә иде. Идарә утырышлары барышын теркәүче документларда (протоколларда) алар сакланырга тиеш. Әгәр дә ул протоколлар табылырлык урында сакланган булса...

Журналда басылган вариантта һәм әлеге китапта күзгә чалынган ике-өч төгәлсезлек яки күләмне арттырмаска тырышу нәтиҗәсендә кайбер фактларга тулырак тукталмау зур бәла түгел, билгеле. Төгәлсезлеккә тартым фактларның да әле каһәр суккан утызынчы-кырыгынчы елларга туры килүен танырга кирәктер. «Гыйбрәтләр алырлык үткән юл» — тулаем алганда, бик уңышлы эшләнгән хезмәт. Язучылар оешмасы эшчәнлеге дә, аерым, башлыча әйдәп баручы язучыларның иҗат һәм тормыш юлы да анда гыйбрәт алырдай итеп тасвирланган. Бу китап Г.Тукай исемендәге бүләк иясе, күренекле шагыйрь һәм абруйлы җәмәгать эшлеклесе Равил Фәйзуллинның татар мәдәниятенә багышланган зур казанышы буларак кабул ителергә хаклы.

*«Мәдәни җомга», 2005, 13 май*

## ОРЕНБУРГНЫҢ ФИДАКЯР ЗАТЫ

Татар әдәбияты һәм мәдәнияте өлкәсендә тирән эз калдырган күренекле шәхесләргә багышланган эзләнүләре һәм табышлары белән танылды Мәдинә Рәхимкулова. «Татар энциклопедия сүзлеге»ндә аның хакында «үз төбәге тарихчысы һәм педагог» дигән билгеләмә теркәлгән. Оренбург өлкәсе татарлары җәмгыяте эш-

чәнлегендә иң актив катнашучыларның да берсе иде ул. Аның арабыздан китүенә дә берничә ел тулды инде. Соңгы айларын ул туган-үскән төбәгеннән бик еракта — Санкт-Петербург шәһәрендә, уртанчы баласы Диләрәсе карамагында үткәрде һәм шунда вафат булды.

Мәдинә Фәтхи кызы Рәхимкулова 1916 елда элекке Оренбург губернасының «башкорт ягы» авылларының берсендә (ул авыл хәзер Башкортстанның Кыргыз Миякә районына керә) мулла гаиләсендә туа. Атасы Фәтхи, 1924 елда муллалык вазифасын калдырып, мәктәптә укыта башлый. Аның үрнәгендә балалары да укытучы булырга хыялланып үсәләр. Мәдинә апа, Урта Азиядәге Сәмәрканд шәһәрендә рабфак тәмамлаганнан соң, 1938–1941 елларда Казан университетының физика-математика факультетында югары белем ала. 1941–1953 елларда Оренбург өлкәсенең Мостай районы үзәгендәге урта мәктәптә балалар укыта. 1953 елда аны Оренбург авыл хуҗалыгы институтының физика кафедрасына эшкә алалар. Ул анда 1971 елгача студентларга белем бирә. Бер үк вакытта педагогия фәннәре кандидаты дәрәҗәсе алу өчен әзерлек эшләренә керешә. Оренбург, Уфа архивларында булып һәм революциягә кадәр нәшер ителгән газета-журнал битләрен тикшереп, шул хезмәте өчен бик күп материал туплый.

1971 елга аның «Революциягә кадәрге Россиядә татар мәктәп-мәдрәсәләрендә фәнни дисциплиналарны укыту» дип исемләнгән зур хезмәте тупланып, фикер әйтү өчен галимнәргә тапшырыла. Бу җитди хезмәттә патша чоры татар уку йортларында кулланылган хисап, алгебра, физика, астрономия, география, зоология һәм химия дисциплиналары дәреслекләре, аларның авторлары турында СССР күләмендә беренче мәртәбә әтрафлы материал туплап бирелә. (Ул хезмәтнең бер нөсхәсен автор сиксәненче елларда Казан дәүләт университеты китапханәсенең кулъязмалар бүлегенә тапшырды.)

Шушы зур хезмәтен туплаганда Мәдинә Рәхимкуловага архив киштәләрендә хәрәкәтсез яткан бик күп документлар, кызыклы язмалар белән танышу насыйп була. Шуларга нигезләнеп, ул Казан, Уфа, Оренбург шәһәрләрендә нәшер ителүче газета-журналларга күпсанлы мәкаләләр, очерклар язып тапшыра. Аның Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсенә багышлап язылган бер мәкаләсенә нигезләнеп минем тарафтан күләмле (52 битле) очерк әзерләнде, һәм ул хезмәт икебез исеменнән «Казан утлары» журналында, «Мәдрәсәләрдә китап киштәсе» (Казан, 1992) дип исемләнгән җыентыкта басылып чыкты. Мәдинә Рәхимкулова Оренбургта яшәп иҗат иткән олуг шәхесләребезнең тормышын һәм иҗатын барлауга да күп көч куйды, аларның эшчәнлеген күпсанлы мәкалә һәм аерым хезмәтләрендә яктыртты. Аның аеру-

ча яратып һәм олылап искә алган шәхесләреннән Ризаэтдин хәзрәт Фәхретдинев белән Дәрдемәнд (Закир Рәмиев) икәнлеген билгеләп үтү кирәктер. «Риза бине Фахрутдин» исемле русча беренче хезмәте 1975 елда Уфада басылган иде. Аерым мәкаләләре төрле елларда татар һәм рус матбугатында дөнья күрделәр. Риза казыйның үз хезмәтләреннән дә берничәсен Мәдинә Рәхимкулова гарәп шрифтыннан кириллицага күчереп, Казан белән Уфа нәшриятларына тәкъдим итте. Зур күләмле «Җәвамигулькәлим шәрхе» дин белгече Равил Үтәбаев-Кәрими төзәтмә-шәрехләүләре белән Казанда 1990 еллар урталарында басылып чыкты. (Равил фикердәше яңадан басылган, эшкәртелгән ул кульязмаларны тотып Казанга килгән чакларда озаклап сөйләшеп утырган вакытлар булды. Мин дә ул елларда Татарстан китап нәшриятында эшли идем.) Иң әүвәл Мәдинә апа кулы аша узган «Тәрбияле хатын» китабы да соңрак Казанда «Иман» нәшриятында нәшер ителде (1996). Олуг галимнең «Әхмәд бай» китабы әүвәл татар, аннары рус телләрендә Оренбургта чыгучы «Яңа вакыт» газетасы ярдәме белән дөнья күрде (1978, 1998). Оренбургта Ризаэтдин хәзрәт яшәгән (1906–1918) элекке йорт урынындагы бинага истәлек тактасы куйдыру эшләрендә әйдәп йөрүчеләрнең берсе Мәдинә Фәтхи кызы Рәхимкулова булды. (Татарстаннан читтәге бер шәһәрдә түгел, Казаныбызның үзендә татар кешесенә андый эшне башкарып чыгуның ничаклы мәшәкатьле икәнлеген күпләребез ишетеп яки укып беләдер, мөгаен.) Дәрдемәнд гаиләсе Оренбургта 1885–1925 елларда яшәгән йорт диварына да туксанынчы еллар башында истәлек тактасы куелды. Аны куюда Оренбург «Туган тел» җәмгыятенең актив әгъзасы Мәдинә Рәхимкулова шулай ук башлап йөрүчеләрдән булды. Бу тантанага Уфадан шагыйрьнең оныгы Равил һәм кайбер язучылар, галимнәр дә чакырылган иде.

Мәдинә Рәхимкулова белән ире, байтак еллар Оренбургта татар мәктәбе директоры булып торган укытучы Якуб ага Шабакаев, татар фольклорын, бигрәк тә борынгы җырларны туплауга да зур әһәмият бирделәр. Алар Оренбург һәм Ульяновск өлкәләре авылларында яшәгән картлардан хәзер кулланыштан чыккан яисә бик сирәк кенә җырланган алтмышлап борынгы җырны магнитофон тасмасына язып алалар. Соңрак текст һәм ноталары белән кассетага алынган ул язмаларны Татарстан Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының фольклорчы галимнәре Г.Макаров белән Р.Ягъфәревкә, консерваториядә укытучы музыка белгече Й.Исәнбәткә тапшыралар. Шундый ук кассеталарны һәм татар әдәбиятының күренекле вәкилләре иҗатын барлауга багышланган башка язмаларны Мәдинә апа Осло университеты (Норвегия) галимнәренә дә бүләк итә. (Сиксәненче-туксанынчы елларда аларның өлкән кызлары Динә белән норвегияле кияүләре Норвегия һәм

Швеция университетларында укыттылар. Кызлары Динә һәм Диләрә Ленинград дәүләт университетын тәмамлыйлар, уллары Рәшит Оренбург политехника институтында белем ала.)

Оренбургта 1960 еллардан бирле татар зыялылары җәмгыяте актив эшләп килә. Ул җәмгыятьне оештыручылар Гражданнар сугышы чоры каһарманы Фатих Солтанов, үз төбәгендә энциклопедик белеме һәм борынгы китапларны тупларга яратуы белән танылган Тәүфыйк Сабитов, элекке Оренбург прокуроры Солтанов (исемен онытканмын), бер хәрби завод инженеры Зиннур Шакиров, пенсиядәге укытучы Сабит Якупов һәм Мәдинә апалар булды. Шушы кешеләр ел әйләнәсенә шәһәр күләмендә татар әдәбияты һәм мәдәнияте шәхесләренә багышлап зур-зур кичәләр оештырдылар. Ул кичәләрдә катнашырга Казаннан һәм Уфадан Язучылар берлеге вәкилләрен чакырып алалар иде. Андый кичәләр, гадәттә, шәһәрнең «Родина» исемен йөртүче мәдәният сараенда уздырыла иде. (Бу мәдәният сарае зур бер хәрби завод карамагында булып, ул заводның байтак еллар эшләгән директоры да милләттәшебез Надир Фатих улы Солтанов иде шул. Шәһәрдә сугыштан соңгы татар җәмгыятен оештыручылар, шул исәптән Надир ага да, күптән арабыздан киттеләр инде.)

Оренбург шәһәрендә татарча һәм башкортча (аз санда булса да, анда башкорт кардәшләребез дә яши) әдәби кичәләр яисә шәһәргә килеп чыккан берәр зыялы белән фикер алышу җыелышларын үткәрүдә милли китапханә хезмәткәрләре дә җиң сызганып катнашалар. Еш кына зур җыеннарда төп докладны әзерләүчеләр һәм сөйләүчеләр дә шушы Хөсәен Ямашев исемен йөртүче китапханә хезмәткәрләре булыр иде. 1980 еллар ахырында шәһәр һәм өлкә күләмнәрендә эш алып баручы, өлкә хакимияте тарафыннан рәсми танылган «Туган тел» җәмгыяте эшли башлады. Аның шәһәр бүлегенә байтак еллар Зиннур Шакиров җитәкчелек итте. (Шушы өлкәдәге эшчәнлеге өчен аңа яңа гасыр башында «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән исем бирелде.) «Туган тел» җәмгыяте эшчәнлегендә иң актив катнашучыларның беренче сафында Мәдинә Рәхимкулова белән ире Якуб ага Шабакаев булдылар. Шул җәмгыять тырышлыгы белән Оренбург өлкәсендә туксанынчы еллар башыннан татар телендә радио һәм телевизион тапшырулар оештырылды. 1957 елгы Хрущев чоры карары чыкканнан соң ябылган татар-башкорт педагогия училищесы эшли башлады. Оренбург педагогия институтында шул ук карар нәтиҗәсендә ябылган татар-башкорт бүлеген, беркадәр соңлабрак булса да, ачтыруга ирештеләр. 1991 елдан «Яңа вакыт» газетасы чыга башлады. Шушы нәтиҗәләргә ирешү юлында Мәдинә апа Рәхимкулова да күп көч куйды. Төрле-төрле оешмаларның бусагасын таптау, фәлән эштә аяк чалалар дип җирле

матбугат битләрендә язып чыгуда ул әйдәп йөрүчеләрнең берсе иде. Оренбург педагогия училищесы ачылгач, ул анда балалар укытырга алынды. Авылдан килгән әзерлексезрәк балалар белән әзерлек сәгатьләре үткәрде. Берничә ел дәвамында «яхшы» билгеләренә укыган дүрт-биш укучыга үз стипендияләрен билгеләде. Шушы фидакярлекләре өчен Оренбург төбәге халкы мәңге аны онытмаска тиештер, мөгаен.

Шушы зур йөкләмәләрне үтәгән дәвердә дә ул архивларда эзләнүләрдән, табышлары турында төрле матбугат оешмаларына мәкалә, очеркларын җибәреп торудан туктамады. Аның ул хезмәт үрнәкләре «Сөембикә», «Казан утлары», «Аргамак», «Татарстан» журналларында, «Ватаным Татарстан», «Татарстан хәбәрләре», «Татарстан яшьләре» газеталары битләрендә басылып чыгалар иде. Мәдинә Рәхимкулованың алда атап үтелгән иҗтимагыймәдәни эшчәнлеге Татарстан Республикасы җитәкчелеге тарафыннан да югары бәяләнде — аңа Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре исеме бирелде. Оренбург өлкә хакимияте дә аңа Россия Федерациясе география җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы мактаулы исемен алуга ярдәм итте.

Мәдинә Рәхимкулованың шигъриятне сөйгәнлеген әйтми китү гөнаһ булыр. Дистә еллар дәвамында ул шагыйрь Төхфәт Ченәкәй-Сәмәвинең төрле җирдә, шул исәптән Урта Азия шәһәрләрендә таралып йөргән шигырьләрен туплау белән шөгыльләнде. Аларны калын бер дәфтәргә күчереп язып, башка төр язмалар да тупланган бер папкада Казан дәүләт университеты китапханәсенең кульъязмалар бүлегенә тапшырды. Туксанынчы еллар ахырында ул папканың анда теркәлү-теркәлмәвен ачыклауны миннән дә үтенгәне хәтеремдә. Аңарда шулай ук Дәрдемәнд улы Җәгъфәр Рәмиевнең егерменче елларда язган шигырь үрнәкләре дәфтәре дә саклана иде. Дәрдемәндкә нисбәте булган фотоларны төрле тарафтан барлап, кечерәк бер үзешчән альбом да чыгарды. Мәдинә апа туплаган фотоларның бер өлеше 2003 елда нәшер ителгән зур Дәрдемәнд альбомына да керде. Мәдинә апа үзе дә шигырьләр язгалый иде. Аның кайбер үрнәкләре «Яңа вакыт» газетасы битләрендә дә басылгалады. Кечерәк бер дәфтәргә күчергән шигырьләрен миңа да җибәргән иде. Мин аларны кадерле бүләк итеп саклыйм.

Мәдинә Фәтхи кызы Рәхимкулова кебек зыялы, фидакяр шәхесләр кимемәсен, даирәбезгә даими рәвештә өстәлә торсын иде дигән теләктә калам.

*«Казан утлары», 2006, № 2*

# КҮПКЫРЛЫ ИҖАТ ИЯСЕ

Мансур Әхмәт улы Шиһапов алтмышынчы еллар башында җәмәгатьчелеккә зур киләчәге өмет ителгән сәләтле артист буларак күренеп алды. Иҗатташы Рабит Батулла бер мәкаләсендә аның шул дәвердәге эшчәнлеген болай бәян итә: «Качалов исемендәге театр каршында оешкан театр мәктәбен тәмамлап, байтак вакыт Күчмә театрда, аннан соң филармониядә артист булып эшләде. Сәхнәдә ул иҗат иткән образлар байтак булды. Әйтик, Н.Хикмәтнең «Сәер кеше»сендә Ф.Кастро, Г.Мдиванининың «Терезаның туган көне»ндә — Антонио, Ә.Мирзаһитовның «Әниемнең чал чәчләре»ндә — стиляга Гошка, Г.Минскийның «Тапшырылмаган хатлар»ында — Искәндәр, Хәй Вахитның «Беренче мәхәббәт»ендә Госман Әкбәревич рольләре аның актерлык уңышы санала».

Әйе, Балык Бистәсе районының Олы Солтан авылы урта мәктәбен тәмамлаганнан соң Мансур Казанга килә, 1957–1961 елларда В.И.Качалов исемендәге Зур театр каршында оешкан театр студиясендә белем ала. Курс җитәкчеләре Празат Исәнбәт була. Театр дөньясында зур абруйга ирешкән Наилә Гәрәева, Ирек Баһманов, Вадим Кешнер — аның партадашлары.

Шушы уңайдан байтак татар яшьләренә олы иҗат юлын сайларга юнәлеш биргән, шул рухта тәрбияләгән Олы Солтан мәктәбен һәм аның укытучыларын да олылап искә алып китәсе килә. Анда Татарстанның халык артистлары Равил Шәрәфиев, Хәлим Җәләлев, күренекле шагыйрь Кадыйр Сибгатуллин Мансур Шиһапов белән бер үк елларда укыйлар. Аларга хәтле һәм алардан соңгы елларда шул мәктәптә белем алучы танылган иҗат әһелләре исемлегендә язучылардан Роберт Әхмәтҗанов, Вакыйф Нуруллин, Мидхәт Миншин, Әхәт Сафиуллин, Госман Гомәрев һәм өч бертуган Гаффаровлар бар. Татарстанда шушындый ук уңышка ирешкән тагын бер авылны мин белмим. Гомумән, Балык Бистәсе районы халык күңеленең йөзек кашы булырдай шәхесләр тәрбияләүдә үрнәк бер төбәктер, минемчә. Татарстанның халык артисткасы Рауза апа Хәйретдинова, халык шагыйре Равил Фәйзуллин, күренекле драматург Сәет Шәкүров, шагыйрь Әхмәт Гаделләр дә — шул тарихи, болгар бабаларыбыз яшәгән дәвердә үк оешкан Чаллы әмирлеге җирлегеннән.

Мансур Шиһапов шушы районның Яншык авылында 1940 елның 1 маенда туа. Район күләмендә кечерәк бер вазифа үтәгән, авылдашлары арасында абруй казанган Әхмәт Шиһаповның инде дүрт улы була. Бишенчегә Мансур туа. Әхмәт абый дүрт ел сугышта йөреп, 1нче группа инвалид булып кайтканда инде ул әнисенең төп йомышчысына әверелә. Сугыштан соң туган сеңлесе белән энесенең беренче тәрбиячесе дә ул була. Әхмәт белән

Нәфисә Шиһаповлар гаиләсенең булсынга дип тырышып яшәүләренең тагын бер мисалы — җиде балаларының да югары белемле булуы. Әхмәт Шиһапов, сугыш яраларыннан тернәкләнеп китә алмыйча, илленче еллар башында вафат булгач, кече энесеңелләрне аякка бастырышуда агалары булышлык итә. Үз авылларында утыз еллап укыткан һәм мәктәп директоры булган Хуҗиәхмәт агасы Мансурга да студиядә алган белем белән генә чикләнмәскә киңәш итә. Мансур, эш арасында укып, Казан дәүләт университетының журналистика факультетын тәмамлый.

Аңа чаклы ук инде Мансурның тагын бер мактауга лаек сыйфаты — оештыручы, берәр эшне әйдәп баручы сәләте ачылган була. Атасы Әхмәткә, абыйларына хас бер сәләт. Җитмешенче еллар башында ул Язучылар берлегендә матур әдәбиятны пропагандалау өлкәсендә танылып ала, 1974–1976 елларда Г.Камал исемендәге театрның баш администраторы, аннары Курчак театры һәм Күчмә театрның директоры булып эшли. Күчмә театрның статус-дәрәҗәсен күтәрүгә, аны Драма һәм комедия театры дип үзгәртүгә ирешә. Туксанынчы еллар башыннан ул Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары булып эшләде. Хәзерге көндә — 1996 елдан башлап Республиканың Дәүләт зур концерт залы директоры. 1980 елдан Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, 1996 елдан Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының Мактау грамотасы иясе (2000).

Мансур Олы Солтан мәктәбендә укыган елларында шигырь яза башлый. Дусты Кадыйр белән авылларыннан егерме чакрымдагы шул мәктәпкә барганда-кайтканда алар ярышып шигырь әйтешәләр. Мансурның берме-икеме шигыре район газетасында басылып та чыга. Мәктәптә ул, драма түгәрәге «артисты» булудан тыш, татар шагыйрьләренең шигырьләрен оста сөйләүче буларак та танылa. Казанда, театр студиясендә укып йөргәндә, берме-икеме шигыре көйгә дә салына — ләкин әле ул җырчы шагыйрь буларак соңрак танылачак. Беренче шигырь китабы «Әйләнеп кайтыгыз» бик соңлап, 1991 елда гына дөнья күрә. Аңа сүз башын — «Шомыртлар ак шәлен ябынса»ны Мөхәммәд Мәһдиев түбәндәге юллар белән тәмамлый: «Кулъязманы укып чыккач уйга калдым: тәрәзәдән яз исе бәреп кергән сыман булды, туган авылымның җәйрәп яткан иген басуларын күргән кебек, туган нигеземдәге бакча башында ак шәлен ябынган шомыртны күргән кебек булдым». Соңрак шагыйрь Кадыйр Сибгатуллин «Исәннәр әйләнеп кайталар» мәкаләсендә (1993) Мансур шигырьләренә төпле анализ ясап, аларга бик уңай бәһа бирә. Ул китапның мөхәррире буларак, бу бәяләр мине дә сөендерде, әлбәттә.

Шагыйрьнең икенче китабы фәкать җырлардан тора. Аңа авторның иң популяр җырларының берсе булган «Туй күлмәге»

исеме бирелгән (1997). Китапка «Әйләнеп кайтыгыз», «Яшьлегем эзләре», «Өлешемә тигән, әй, көмешем», «Кыр казларын бергә каршылыйк» кебек, җыр, сәнгать сөючеләргә таныш, якын булган кырык-иллеләп җыр кергән. Язучы Альберт Хәсәнев «Игелекле яуган яңгыр төсле» бәяләмәсендә М. Шиһаповның җыр иҗаты турында болай дип яза: «Танылган җырчыларыбыз Мансурның «Сагыну», «Васыять», «Бүләк ит син», «Унҗиде яшем», «Язгы җыр» һ.б. җырларын аеруча яратып башкара, аларны һәрчак концерт программаларына кертәләр. Талантлы шагыйрьнең сүзләренә көйләрне дә бит Сара Садыйкова, Рим Хәсәнев, Рамил Курамшин, Рәис Нәгыймов, Сафьян Ибраһимов кебек танылган, дан алган композиторлар язганнар. Теләмәсәләр, җан тартмаса, шигырьне укып илһамланмаса, син алардан көйләрне өсләренә күсәк белән янап та яздыра алмассың». Өстәп шуны да әйтергә кирәктер, китап рәвешенә кергәнче әле бу җырлар башта җыр сөючеләргә ике дискетага теркәлеп барып ирешәләр. «Яшьлегем эзләре» җыры (С.Садыйкова көе) — Нәфисә Васыйлова, «Әйләнеп кайтыгыз» (Р.Хәсәнев көе) — Асаф Вәлиев, «Өлешемә тигән көмешем» (Азат Хөсәенев көе) Зәйнәп Фәрхетдинова һ.б. абруйлы артистларыбыз (Римма Ибраһимова, Хәйдәр Бигичев, Вафирә Гыйззәтуллина, Зөфәр Хәйретдинов) башкаруында бирелә.

Шунысын да әйтергә кирәк: бу китаплары дөнья күргәнче, вакытлы матбугатта Мансур Шиһаповның күпсанлы мәкаләләре һәм Курчак театры тарихын чагылдырган, анда эшләүче артистлар, башка иҗат әһелләре белән таныштырган «Казан дәүләт курчак театры» китабы басылып чыккан иде. Драматург буларак та ул көч сынап карый. Гадел Кутуйның «Рөстәм маҗаралары» повестена нигезләнеп, «Абага чәчәге» инсценировкасын яза. Ул пьеса 1978 елда Курчак театрында куела, һәм күренекле әдип Нәби Дәүли, аны уңай бәяләп, матбугатта язып чыга. Гариф Ахуновның «Хәзинә» романына нигезләнеп эшләнгән «Кошның да үз оясы бар» инсценировкасы да театр сәхнәсендә уйнала. Драма һәм комедия театрының Ташкенттагы сәфәре вакытында уйналган төп әсәрләрнең берсе буларак шулай ук уңай бәяләнә. Ташкентта яшәүче милләттәш әдибебез, драматург Зиннәт Фәтхуллин аңа багышлап зур мәкалә бастыра.

Бер гаиләдән ике-өч иҗат кешесенең чыгуы бик сирәк күренеш. Бу җәһәттән дә Әхмәт абый белән Нәфисә апа уңганнар исәбендә торалар. Урыннары җәннәттә булсын! Мансурдан ике генә яшькә олы абыйсы Рәшит Шиһапов та биш шигырь китабы, берничә танылган җыр сүзләре авторы иде. Педагогия институтын тәмамлаганнан соң, байтак еллар Лениногорск шәһәрендә яшәде: балалар укытты, шәһәр халык театрын оештыручы һәм аның җитәкчесе булды. Хәзер җәсәде туган авылы каберлегендә. Абыйсы

вафат булганчы ук язылган, туган төбәгенә, якыннарына багышланган «Ак болытларга карап» мәкаләсендә шагыйрь Мансур Шиһаповның мондый юллары бар: «Туган авылым Яншыкка кайтсам, беренче чиратта зиратка ашыгам. Анда җиде буын бабамның, кардәшләремнең каберләре... Үзем дә мәңгелеккә шушы зират куенына күчәрмен — каберем шунда булыр. Ташына язарга инде шигырем дә әзер...»

Мансурның күпсанлы җырларыннан (ноталары белән), шигырьләреннән һәм очерк, мәкаләләреннән торган яңа китабы «Җырлыйсы җырларым бар әле» дә тиздән укучы кулына килеп керәчәк. Туплашуда үземнең дә катнашым булган ул китапның кульязмасы күптән түгел Татарстан китап нәшрияты тарафыннан басмаханәгә тапшырылды. Төкле аягы белән дөньяга киләсен генә көтеп калабыз.

Мансур Шиһаповның үзенчә моңсу шигырьләре, күңелгә «сеңеп» калучан җырлары, яңадан-яңа пьеса һәм инсценировкалары белән әледән-әле танышып яшәргә язсын. Еллар дәвамында тупланган иҗат җимешләрен укучыга ешрак җиткерсен, куен дәфтәрендә генә сакламасын дигән теләктә калам.

*«Казан утлары», 2005, № 5*

# Теләктәш тә, теләктәш тә идек без

# ИКЕ ХАЛЫКНЫҢ БЫЛБЫЛЫ

«Бөтендөнья тарихына бер караш» китабында Һиндстанның күренекле җәмәгать эшлеклесе, булачак ил башлыгы Җәваһарлал Неру татар милләте вәкилләре эшчәнлегенә дә зур бәя бирә. Алар элек бөтендөнья күләмендә мәгълүм мәмләкәт тотучылар иде, соңрак та күп кенә ил-мәмләкәтләрнең эшлекле вазифа башкаручылары буларак танылдылар, дип яза ул өч томлы тарихи хезмәтендә. Әлбәттә инде, бу очракта галим Неру хәзерге тар мәгънәдәге татар төшенчәсен күз уңында тотып язмый, борынгы төрки-татарлар оештырган зур дәүләтләр дәверен искә төшерә. Шулай да күңелнең бер кылына чиртеп ала — сөендереп куя. «Ул төркиләр арасында безнең — хәзерге заман татарларының бабалары булганлыгы да шиксез» дип уйлыйсың. Димәк, Җ.Неруның татарларга карата әйткән мактау сүзе өлешчә генә булса да безгә дә кагыла. Безнең күңелләрне дә җилкендерә.

Бүгенге көндә дә татарлар, кайда гына яшәсәләр дә, гыйлемгә, дәрәҗәле вазифалар башкаруга омтылган кеше буларак таныла. Әйе, үзе сайлаган хезмәт юлында дан казанган милләттәшләребез байтак. Мондый мактауга алар үзләре сайлаган эшне башкаруда талантлырак, остарак булулары нәтиҗәсендә ирешкәннәр. Әйтик, чордашларыбыздан Кытай кебек зур бер империядә югары дәрәҗәләргә ирешкән Буа ягы татары Борһан Шаһидине, бөтендөнья күләмендә мактаулы исемнәр яулаган галимнәрдән Роальд Сәгъдиевне, Һарун Таҗиевны, Рәшит Сүнәевне, бию осталары Рудольф Нуриев, Ирек Мөхәммәдевне алыйк. Яки Кытай җирендә башлангыч белем үзләштергән тарихчы академигыбыз Миркасыйм Госманов, Алма-Атага чиктәш бер бистәдән чыккан музыка сәнгате академигы Фоат Мансуров, Үзбәкстанда туган борадәрән Акчуриннар, шунда яшәп иҗат иткән архитектор Мидхәт Булатов, Ерак Көнчыгышта туып-үскән җырчы һәм композитор Гали Ильясов, Себер тарафыннан калкып чыккан оста шахматчы Гата Камский һ.б. бик күп замандашларыбызны хәтергә төшерик. Алар белән горурланмаслыкмы соң? Бары тик аларның барлыгын онытмаска, ара-тирә булса да искә алгалап торырга кирәктер.

* * *

Татар һәм казакъ дөньясында танылган күренекле композитор Латыйф Хәмиди дә шундый затларыбызның берсе. Җитмешенче елларда Алма-Атада миңа аның белән ике мәртәбә очрашып, озаклап сөйләшеп утырырга насыйп булды. Казакъстанның Актүбә шәһәрендә дүрт ел уку дәверендә исә аның җырларын,

симфоник әсәрләрен, опералардан арияләрен радиодан еш тапшыралар иде. Шуннан соң композитор белән Казанда да күрешкәләдек. Опера театрында узган ниндидер тантаналы кичәдән соң якташым Җәүдәт ага Фәйзинең, җитез хәрәкәтле, юкарак гәүдәле юлдашына күрсәтеп: «Латыйф Хәмиди агаң булыр», — дип, аның белән таныштыруы хәтеремдә. Шул вакытларда әле ул тугангүскән якларына еш кайтып йөрде. Якын күргән, Мәскәүдәге опера студиясендә бергә укыган дусларыннан Җәүдәт Фәйзи, Мансур Мозаффаров, Заһид Хәбибуллин һ.б. әле ул вакытта саусәламәт, киң колачлап иҗат итәләр. Музыкаль әсәрләре сәхнәдән төшми уйнала. Халык күңеленә якын булган җырлары һәр кичәдә диярлек башкарыла килде. Л.Хәмидинең берничә әсәрен дә Казанда оештырылган әдәби-музыкаль кичәләрдә бик еш кабатладылар. Тамашачылар аеруча аның татар һәм казакъ моң-аһәңен бергә кушып иҗат иткән «Былбыл» җырын яратып кабул итәр иде. Ул җырны бездә иң оста башкаручы Наҗия Теркулова, соңгы дәвер казакъ илендә Бибигөл Teләгәнева булды. (Бибигөлнең анасы безнең милләттән икәнен дә искәртеп үтик.) Муса Җәлил сүзләренә язылган «Уңыш җыры» («Беренче вальс») белән казакъ совет әдәбиятына нигез салучыларның берсе Сабит Муканов шигыре нигезендә иҗат ителгән «Казакъ вальсы» да заманында бик популяр иде.

Хәзер ул чор композиторлары әсәрләренә сәхнәдә урын әзрәк бирелә. Ә 1990 еллардан соң дөнья күргән җыр китапларында Л.Хәмиди исеме бөтенләй дә төшеп кала башлады. Җыр, көйләре тамашачы күңеленә ошамаганлыктан түгел, билгеле. Көй чыгаручыларыбыз ишәеп китеп, китап битләренең санаулы булганлыгыннандыр дип уйлыйм.

Ә бит Латыйф Хәмиди бик үзенчәлекле композитор. Балачак гомерен Урта Азиядә, татар, казакъ һәм үзбәк арасында үткәргән. Аның татарча яңгырашлы көй-моңнарына да безгә тугандаш казакъ һәм үзбәк кардәшләребез аһәңнәре дә кушылып, көйне баетып җибәрә. Шундый күренешнең үзенчәлекле чагылыш үрнәге буларак, әлеге шул мәшһүр «Былбыл» җырын, «Казакъ вальсы»н һәм «Беренче вальс»ларны атап үтәргә кирәктер.

* * *

Казакъстанның халык артисты Латыйф Хәмиди белән АлмаАтада очрашуыбыз көтелмәгәнчә килеп чыккан иде. Үзара арадашлык җепләрен ныгыту, татар язучыларының әсәрләрен — Казакъстанда, казакъларныкын Татарстанда бастырып чыгару мөмкинлекләрен ачыклый төшү максатыннан Татарстан Язучылар берлеге җитәкчелеге 1974 елның октябрь урталарында мине

Казакъстан Язучылар оешмасына эш белән җибәрде. Октябрь ае ул елларда матбугатка әбүнәчеләр туплау-барлау чоры да бит. «Казан утлары», «Азат хатын», «Чаян» журналларына, татар телендә чыгучы газеталарга андагы кардәшләребез ничек языла, ул республика күләмендә әбүнәчеләребез саны күпме? Шуларны да ачыклап кайтырга кушылган иде. Ул дәвердә казакъ кардәшләребез илендә дүрт йөз меңнән артыграк татар кешесе яшәде. Кардәш республика башкаласының Карл Маркс урамындагы матбугатка язуны оештыручы идарәгә бардым. Анда: «Сезнең якташлар газета-журналларга бик теләп язылалар. Елдан-ел планны арттырып үтәп киләбез. Безнең үзәк идарәдә дә, өлкәләрдәге идарәләрдә дә татар хатын-кызлары да байтак эшли, подписка чорында алар сезнең матбугатны таратуда бик актив катнашалар. Татар журналлары бездә казакъ телле журналлардан ким таралмый»,— дип, бик сөендереп җибәрделәр. Соңгы ике-өч елда дөнья күргән саннарны язып алдым. Казанга кайткач, аларны үзебездәге әбүнәчеләр саны белән чагыштырып карадык. «Казан утлары» белән «Азат хатын»га язылучылар санының, ягъни мең кешегә тиңләп исәпләү нәтиҗәләренең ике республикада да бер чамадарак булуы ачыкланган иде. Ул баруда «Казан утлары» журналы белән таныштыруга, киләсе елда анда ни-нәрсәләр басылачагын белдерүгә багышлап «Казакъ әдәбияты» газетасында кыскача язмам да бирелде. Республиканың комсомол яшьләр газетасы «Лениншыл жас»та белдерү урнаштырылды. Әйе, казакъ, үзбәк кардәшләр мәмләкәтләрендә гомер итүче милләттәшләребез ул дәвердә әле туган-үскән илләре белән тыгыз элемтәдә яши, газета-журналларны да ярыйсы ук арзан хакка алдыра ала иде. Әйтик, җитмешенче елларда «Казан утлары»на язылу хакы җир читендә урнашкан Владивостокта да, Казандагы кебек үк, алты сум гына тора иде. Хәзер исә почта хезмәтеннән файдалану бәясе гади әбүнәче бюджеты күтәрә алмас дәрәҗәгә җитте...

Әлбәттә, иң элек Язучылар берлеге йортына юнәлдем. Алма-Атага барып урнашканның икенче иртәсендә. Берлек идарәсе рәисе Әнүәр Әлимҗанов белән элегрәк Мәскәүдә бер очрашкан идек. Үзе белән танышканчы ук аның тарихи вакыйгаларга кагылышлы повестьлары барлыгын беләидем. Казакъстанда русча нәшер ителүче «Простор» журналында басылган «Отрар хатирәсе» повестен кайчандыр йотлыгып укып чыктым һәм, тәрҗемә ителсә, татар укучысы өчен дә гыйбрәтле бер әсәр булачак дигән фикергә килгән идем. Мәскәүдә узган бер җыелышта очрашканнан соң, шул хакта да сүз булды. Ул миңа шул шәлкемгә кергән повестьларының казакъ телендә чыккан вариантларын җибәрергә вәгъдә бирде. Шулар нигезендә мин аның ике повестен, тәрҗемә итеп, нәшриятка тапшырган идем.

Әнүәрнең киң, иркен эш бүлмәсендә сөйләшеп утырабыз. Иң элек ул хатыны Флюраның да безнең милләт вәкиле булуын, шуңа күрә татар мәдәнияте, татар әдәбияты белән аеруча нык кызыксынуын бәян итте. «Татарстан белән Башкортстаннан килгән бер генә артистның да чыгышын карамыйча калмыйбыз. Илһам Шакиров белән Ренат Ибраһимов җырлавын бигрәк тә үз итеп тыңлыйбыз. Мәскәүгә барган саен русча басылган берәр татар китабын алмыйча кайтмыйм», — диде. Кызганыч, чит-ят җирләрдә үскән яшьрәк буын кешеләре кебек, аның Флюрасы да татарча укый белми икән. Аның нәселе инде байтактан бирле иленнән аерылып яшәгән. Шулай да Флюра үзенең кайсы милләт вәкиле булуын онытып бетермәгән икән әле. (Соңрак, казакъ дуслар белән якыннанрак аралаша башлагач, Совет чоры зыялы катлавының байтагының теге яки бу рәвешле үз халкым вәкилләре белән кан-кардәшлек дәрәҗәсендә икәнлеген ачыкладым. Бер-беребезне дус күреп йөрешкән күренекле язучылардан Шерхан Мортазаев, Саин Моратбәков, Сатимҗан Санбаев, Морад Әүэзов, Әнәс Сараев шундый шәхесләрдән иде. Картрак буын зыялылары арасында андый кушма канлы гаиләләр тагын да күбрәк. Әйтик, Социалистик Хезмәт Батыры исеменә лаек булган язучы Габит Мөсреповның җәмәгатен дә Мәскәүдә үскән татар кызы дип әйтәләр иде. Саин һәм Морад каләмдәшләремнең аналары Сәхипҗамал белән Фатыйма да безнең милләттән — «нугай кызлары». Галимнәр, композиторлар, артистлар арасында да андый кушма канлы гаиләләр ишле иде ул елларда.)

Әлбәттә инде, Әнүәр белән язучылар оешмалары эше, китап, журнал нәшриятлары эшчәнлеге турында да сүз булды. Сөйләшәсөйләшә озаграк та утырганбыз, ахрысы.

Чәй касәләре тотып бүлмәгә кабат кергән секретарь ханым:

— Сезне анда Композиторлар берлеге рәисе көтеп утыра. Керсенме? — дип сорады.

Әнүәр:

— Керсен. Безнең яшерен сүзебез юк, — дигәч тә, бүлмәгә бик сөйкемле бер ханым килеп керде. Зифа буйлы, мөлаем кыяфәтле, уртача яшьләрдәге бу ханымны күргәч тә, күңелдә «чынлап та, бу чибәркәй композиторлар җитәкчесеме икән» дигән уй йөгереп үткән иде. Әнүәр минем кем булуымны әйтте: — Лирон Хәмидуллин. Казаннан...

— Газизә Җубанова, — диде ханым, күрешкәндә.

Әхмәт Җубанов дигән композиторны ишетеп белә идем. Ул Актүбәдән илле чакрымдагы Тимер станциясендә туган. Латыйф Хәмиди белән бергә берничә опера язган мәгълүм шәхес.

— Опералар иҗат итүче Әхмәт Җубановны ишетеп-укып белә идем. Ул бит Актүбә өлкәсеннән... Сез дә шул нәселдәнме? — дидем.

Ханым елмаеп торган арада, Әнүәр:

— Әйе, мәрхүм Әхмәт ага Газизәнең атасы була. Хәзер ул атасы вазифаларын башкара — Казакъстан композиторларының җитәкчесе һәм данлыклы консерваториябезнең ректоры.

Газизә дә сүзгә кушылды:

— Сез композитор Латыйф Хәмидине беләсезме? — диде.

— Беләм. Казанда бер күрешкән дә идек. Ул бит сезнең әтиегез белән бергә берничә опера язган...

Газизә минем ничә көнгә килүемне, кайда тукталуымны белеште.

— Ерактан килгән кунак бит. «Алма-Ата» кунакханәсенә урнаштырдык, — дип, минем өчен Әнүәр җавап бирде. Аннары, миңа табарак борылып: — Өр-яңа кунакханә әле ул. Урынны көнендә бирмиләр. Алдан телеграмма сугып дөрес иткәнсең.

— Ә-ә, безнең опера театры каршында ук икән. Бүлмә номерыгызны да әйтмәссезме?

Ни өчен сораганын ачыклап тормастан, мин ул ханымга бүлмә номерын әйтеп бирдем. Һәм, ике җитәкченең сөйләшер, киңәшер сүзләре бардыр дип, саубуллашып чыгып киттем. Ә кичен, тамак ялгап, бүлмәмә кереп утыруга, кемдер шалтырата:

— Лирон Хәмидуллин буласызмы сез? Хәзер мин килсәм, сөйләшеп утыра алабызмы? Латыйф Хәмиди агаң булам, — ди.

Димәк, Газизә Җубанова Латыйф агасының күңелен күрү өчен минем кунакханә номерын сораган булган икән. Фамилиямне дә кат-кат белеште: Хәмидуллин белән Хәмидинең үзара якынлыгы барлыгын да истә тотуы булгандыр, күрәсең.

Кулына төргәк-төргәк алма, йөзем тоткан Латыйф ага кунакханәгә бик тиз килеп җитте.

— Мин бит опера театрына янәшәдәге Түләбаев урамында гына торам. Моннан ерак түгел. СССР халык артисты мәрхүм Мукан Түләбаев белән дә иҗатташлар, дуслар идек. Казакъстан гимнын да бергә эшләдек. Өченче автордаш итеп соңрак Брусиловскийны беркеттеләр...

Соңрак ачыклавымча, композитор Түләбаев исемен йөртүче ул үзәк урамнарның берсендә казакъның күп кенә күренекле шәхесләре гомер иткән икән. Казакъ совет әдәбияты классиклары Мохтар Әүэзов, Сабит Мукановларның музей-квартиралары да шунда ук урнашкан иде. Ул елларда исән-имин эшләп ятучы каләм әһелләреннән Әнүәр Әлимҗанов, Шерхан Мортазаев, Тәхәви Ахтанов, Әким Тарази һ.б. опера театры янәшәсеннән башланган шул урамда Латыйф агага күрше булганнар. «Абай» исемен йөртүче, Латыйф Хәмидинең төп йорты саналырдай Казакъ опера һәм балет театры исә 1933 елда ачыла...

* * *

Латыйф ага Татарстанның хәзерге Кайбыч районына кергән авылда 1906 елда туган. Җиде яше тулмастан, үзбәк кардәшләребез илендәге Кәттә Курган шәһәрендә яшәгән. Шунда укыган елларында ул — мандолинада, 1917 елдан соң ачылган музыка мәктәбенә йөргәндә, фортепьянода уйнарга өйрәнә. Тиздән илдә зур үзгәрешләр башлана. 1918 елның апрелендә Ташкентта Хәмидуллиннар яшәгән төбәктәге милләтләр мәнфәгатен кайгыртырга тиешле яңа идарә оештырыла — Төркестан Совет Автономияле Республикасы. Дөрес, тиздән барлыкка киләсе СССР җирлегендә иң беренче булып оешкан ул автономияле республиканы Совет хакимияте соңрак никтер сирәк искә алды. Чөнки ул кирәгеннән артыграк үзбаш булды сыман. 1940 елда басылган «Страна социализма» исемле калын рәсми белешмәлектә ул да, 1920 елда оешкан Казакъ Автономияле Республикасы да бөтенләй дә телгә алынмыйлар. Моның сәбәбен, бәлки, Төркестан милли мохтариятен оештыручыларның, шул исәптән аның башлыгы — «милләтче» Турар Ырыскуловның 1937–1938 елларда юк ителүе белән бәйләргә кирәктер. 1925 елның урталарында Төркестан белән Казакъ республикалары берләштерелә. Яңа Казакъ автономиясенең башкаласы итеп Кызыл Урда билгеләнә. Ташкент исә мөстәкыйль бер шәһәр статусында кала. Фәкать 1929 елда гына үзбәк кардәшләр мохтарияте башкаласы Сәмәркандтан шушында күчерелә. Алдарак китереләсе хатирәләрдән күренгәнчә, егерменче еллардагы Ташкент шәһәрен үзенчәлекле бер татар мохтарияте үзәгенә тиңләрлегебез бар. Ләкин ул дәвер безнең әдәбият, мәдәният тарихында әлегә ныклап өйрәнелмәгән.

1919 елда Төркестан Республикасының Мәгариф Халык комиссариаты җитәкчесе итеп татар язучысы Шәһит Әхмәдиев билгеләнә. (Башка бик күп җитәкче оешмаларга да безнең милләттәшләр килә. Әйтик, «Хөсәения» мәдрәсәсендә укып җитлеккән Кәрим Хәкимев тиздән Төркестан АССР коммунистлары башлыгы булып китәчәк.) 1920 елда автономиянең башкаласы Ташкентта төрки милләтләрне берләштергән Белем йорты эшли башлый. Аның карамагында татар, үзбәк, казакъ бүлекләре булган Халык мәгарифе институты ачыла. Латыйф Хәмиди дә әлеге институтка укырга керә һәм аны 1926 елда тәмамлый.

Әлеге Белем йорты һәм Мәгариф институты белемгә сусаган татар яшьләрен әллә кайлардан үзенә тарта. Ә 1921 елның җәй башында, ачлыктан качып, монда Рәсәй өлкәләреннән дә бик күп татар зыялысы, татар байлары һәм яшьләре килеп тула. Ташкентта аерым-аерым татар мәхәлләләре барлыкка килгән кебек була. Бу елларда без ул шәһәр урамнарында шагыйрьләрдән Һади Так-

таш, Зариф Бәшири, татар театрының күренекле шәхесләреннән Кәрим Тинчурин, Таҗи Гыйззәт, Сәет Булатов, Әсгать Мәҗитов, әдәбият-тел галимнәреннән Габдрахман Сәгъди, Гыйбад Алпаров, композитор Салих Сәйдәшев, күренекле җырчылардан Газиз Әлмөхәммәдев, Фәттах Латыйпов һ.б. бик күпләрне күргән булыр идек. Заманында Тукай белән якыннан аралашкан Кәбир Бәкер дә монда татар һәм үзбәк телләрендә «Олуг Төркестан» газетасын нәшер итә. Мәгариф комиссариатының икенче бер түрәсе, касыймлы Ибнеәмин Янбаев тырышлыгы белән 1920 елда Ташкентта Тукаебызның русчага тәрҗемәдә беренче китабы дөнья күрә.

Әйе, 1920 елда Самарада театр студиясен тәмамлаган, бер кыш Оренбург татар театрында эшләгән зур бер төркем артистны да Төркестан Республикасы ул вакытта үзенә сыйдыра. Шәһәр үзәгендә урнашкан Белем йорты һәм аның янәшәсендәге Приказчиклар клубы күчмә татар театры үзәкләренә әвереледереләләр. Алар эшендә үзбәк театрына нигез салучылардан Хәмзә Хакимзадә Ниязи дә катнаша. Хәмзәнең анасы һәм җәмәгате безнең милләт вәкиле булуын да әйтеп үтү кирәктер. Аның кайбер әсәрләрен татар телендә язганлыгы турында да истәлекләр сакланган...

Әдипләребез, артистларыбыз иҗатында соңрак Ташкентта узган гомер эзләрен чамалап була. Әйтик, Такташ мирасында. Яки Т.Гыйззәттә. Ташкенттан кайткач, ул 1923 елда үзбәк тормышыннан алынган пьесасын — «Каһәрле мөһер»не яза. Әсәр Сембер, Казан театрларында уңыш белән бара.

Л.Хәмиди өчен бу еллар иҗади чыныгу, аякка басу еллары була. Русчалабрак әйтсәк, старт алу еллары. Шул дәвердә аның кайбер сәхнә әсәрләрен музыкаль бизәүдә катнашуы мәгълүм. Шунда аның беренче көйләре туа. Мәдәният-сәнгать кичәләрендә аларны ул сәхнәдә үзе дә мандолина һәм фортепьяноларда уйнап күрсәткәли. Монда таратылган җилем басма «Белем йорты» журналында үзбәк Гафур Голәм, казакъ Мохтар Әүэзов, Һади Такташ һ.б. шагыйрьләрнең шигырьләре белән янәшә Л.Хәмидинең язма иҗат үрнәкләре дә урын ала. Әдәбият укытучысы Габдрахман Сәгъди аның киләчәктә шагыйрь буларак таныла алуына шикләнми.

Әйе, шушы институтта укыган һәм шушы үзенчәлекле мохиттә яшәгән чорда Л.Хәмидинең тәүге җырлары җырлана башлый. Ул монда татарча «Беренче вальс» көен иҗат итә. (Соңрак ул көй Муса Җәлил сүзләре белән Мәскәүдә «Октябрь баласы» журналында «Уңыш җыры» исеме белән басылып чыгачак.) Муса Җәлил белән алар беренче тапкыр Казанда 1924 елның җәй башында очрашачаклар. Әйе, Латыйфның иҗади үсешен күзәтеп торган

милләттәшләре аңа Казанга барырга, яңа ачылган Шәрекъ музыка техникумына укырга кирәргә киңәш итәләр. Институт җитәкчесе, унынчы еллардагы «Шура» журналында байтак шигырьләре басылган иҗади фикерле Габдулла Мостакаев та ул тәкъдимне хуплый. «Бар, тәвәккәлләп кара»,— дип киңәш итә. 1924 елның язында Латыйф ерак юлга җыенып чыгып китә.

Ләкин Казанда аны гына көтеп тормаганнар икән. Алты-җиде яшеннән туган иленнән читтә яшәгән яшүсмернең өметләре акланмый. Балачактан күнегелгәнчә, «әкә-үкә», «мәйле» ише күп кенә үзбәк сүзләрен кушып, ашыгыбрак сөйләүче кечерәк буйлы бу унсигез яшьлек малайны руслар түгел, үз милләттәшләре дә баштарак кабул итеп бетерми, ят күрә. Шәрекъ музыка мәктәбе дип аталган уку йортында да ул вакытта әле үз милли кадрларыбыз булмый диярлек. «Композиторлыкка укырга телим» дигән егетне, «бездә андый бүлек юк» дип кире борып җибәрәләр. Ләкин аның «үз Тәшкәнтенә» тиз генә кайтып китәсе килми. Ул педагогия техникумына хор җитәкчесе буларак эшкә керә. Музыка техникумы карамагында эшләгән курска йөри. Нота язуын тирәнтенрәк өйрәнергә тырыша. Заһидулла Яруллин, Солтан Габәши, Салих Сәйдәшев белән таныша. Кешеләр белән тиз аралашучан егет монда да үз ишләрен таба: Гадел Кутуй, Кави Нәҗми, Әнәс Камал белән әдәби очрашуларда катнаша. Бигрәк тә Оренбургтан килгән рабфак укучысы Муса Җәлил белән омтылыш-теләкләренең уртак икәнлеге беленә. Өстәвенә икесе дә мандолинада оста чиртәләр, икесе дә шигырь сөяләр. Казан яшьләре аларны үз итә башлый. Ташкент дуслары да онытып бетермиләр — ике арада хатлар йөреп тора. Латыйфка: «Монда кайтып укуыңны тәмамла», — дип киңәш итүчеләр дә була... Беренче башлап музыкаль белемгә өйрәтүче укытучысы Гыймад Тимербулатов та аңа: «Әүвәл укуың тәмамла», — дип үгет бирә. Л.Хәмиди, башлаган укуын дәвам иттерергә карар кылып, 1925 елда Ташкентка кайтып китә.

* * *

Институтны тәмамлау таныклыгы алганнан соң, ул Мәскәү музыка техникумына керергә ният кыла. Бу вакытта инде аның Кәттә Курган музыка мәктәбендәге укытучысы, мандолинада оста уйнаучы остазы Гыймад Тимербулатов та үз Мәскәвенә кайтып төпләнгән була. Латыйфны ул Мәскәүдә якын күреп кабул итә. Мәгълүм Әсәдуллаев йортындагы үз фатирына урнаштыра. Бу хәл 1927 елның җәендә була. Беренче Мәскәү музыка техникумының композиторлар әзерләү бүлегенә кабул ителеп, тулай торакка күчкәч тә, Латыйф Гыймад агаларына бик еш килеп йөри. Көз

көнендә бер килүендә ул шушы йорт тирәсендә Муса Җәлил белән кабат очраша. Муса да Мәскәүгә укырга дип килгән, Әсәдуллаев йортында яшәүче элекке танышы Дәүләтшиннарга фатирга төшкән икән. Ике күренекле шәхеснең иҗади дуслыгы шушы көзгә бәйле рәвештә башланып китә. Һәм дистә еллап дәвам итә.

Алар шул чорда популяр булган, башлыча яшьләргә һәм укучы балаларга багышланган җыр-көйләрен бергә язалар. «Комсомол җыры», «Күз җитте», «Күңелле яшьләр», «Ленин турында җыр»ны аларның яшьтәшләре урамда да, уку йортларында да бик яратып җырлыйлар. «Кызыл очкыч җыры» марш буларак күпләр күңеленә хуш килсә, «Син дулкыннар тавышын тыңладыңмы?» романсы татар көенә яңалык алып килүе белән истә кала. Латыйф Мәскәүдә яшәүче Әхмәт Ерикәй шигырьләренә дә берничә көй иҗат итә. Аларның күбесе Муса Җәлил редакцияләгән журналларда басылып та чыга.

Л.Хәмиди 1931 елда техникумны тәмамлый. Әмма эшеннән һәм дусларыннан аерыласы килмичә, Мәскәүдә яшәп кала. Бу вакытта инде ул «Октябрь баласы» журналының музыка бүлеге мөдире була. (Журнал 1932 елның декабрендә ябыла.) Шул ук Әсәдуллаев йортында урнашкан татар мәктәбендә җыр дәресләре дә алып бара, милли телләрдә китаплар нәшер итүче «Центриздат» белән дә хезмәттәшлек итә. Казакъстанга эшкә билгеләнгәч кенә, аның Мәскәүдәге дуслары белән арасы бераз сүрелә төшә.

Беренче мәртәбә Казакъстанга эшкә билгеләнүенең сәбәпләрен Латыйф ага миңа болайрак аңлаткан иде. Бердән, ул элек Урта Азиядә яшәгән, андагы төрле милләт вәкилләре белән аралашкан. Шундагы халыкларның гореф-гадәтен, телләрен белә. Латыйф ага, шул сүзләрен раслагандай:

— Казакъ дуслар хәзер дә әле «Ташкентка барып төшү белән үк үзбәккә әвереләсең» дип шаярткалыйлар, — дип әйтеп куйган иде.

Икенчедән, ул дәвердә үзәк тарафыннан казакъ мәдәниятен торгызуга зур әһәмият бирелгән була. Утызынчы еллар башында Казакъстанның Алма-Ата, Кызыл Урда, Семипалатинск кебек эре шәһәрләрендә бер-бер артлы берничә милли театр оештырыла. Опера театрын нигезләү турында карар кабул ителә.

— Казакъ иле өчен мондый тизләтелгән чаралар нилектән килә? Белмисез шул сез... Мондагы утызынчы елгы ачлык афәтен дә, халык күтәрелешен дә Рәсәйдә белүчеләр юк. Бездә дә ул хакта берни дә язмыйлар. Аларны язарга да, сөйләргә дә ярамый. Боларны мин сиңа сер итеп кенә әйтәм. Синең сер тота белгәнеңне чамалап...

Әйе, казакъ, кыргыз халкының 1916 елда патша Россиясенә каршы баш күтәрүе турында әз-мәз хәбәрләр бар. Ләкин ул

хәбәрләр дә узган гасырның егерменче еллары чигеннән чыкмый диярлек. Соңгы дәверләрдә нәшер ителгән «Большая Советская энциклопедия» томнарында миңа андый мәгълүмат очрамады. Бәлки, ул кузгалышка багышлы мәкалә атамасын дөрес билгели алмаганмындыр. Әмма шунысы да хак: халык күңелен, бигрәк тә әз-мәз кыерсытылган милләт вәкилләре күңелен кузгатмас, учларын корал тотарга ымсындырып тормас өчен, җитәкче түрәләр безгә андый фактларны мөмкин кадәр җиткермәскә тырышканнар. 1980 еллар башында Лев Толстойның «Хаҗи Морад» романын кабат нәшер итәргә ниятләгәч тә, үзебезнең үк түрәләрнең «планга кертмәскә» дип әйтүләре хәтердә. Хәзер дә тыныч булмаган Кавказ төбәгендәге «тау халыклары»ның Советка каршы оештырылган, 1954 елга кадәр дәвам иткән кораллы көрәшен кем белә? Яки соңгы елларда гына «чечен бандаларының Дагыстанны яуларга омтылуы» нигезендә ни-нәрсә ятканын кем аңлатып бирә ала? Дагыстан вакыйгаларының нигездә Яңа Лак (Новолакский) районында барганын һәм шул хәлләрдән соң лак халкының чикле мөстәкыйльлеге (кече мохтарияте) өчен көрәшүче кайберәүләрнең юкка чыгуын истә тотканда — анда да ниндидер «сер» ята.

Казакъ халкының бер өлешенең 1930 елдагы баш күтәрүе хакында бездә, билгеле, бернинди дә мәгълүмат басылмаган. Читят җирләрдә бәян ителгәннәре дә онытылгандыр, мөгаен. Ул вакыйгалар әлегә аерым кешеләр күңелендә генә саклана. Актүбә каласында тимерьюлчы һөнәрен үзләштереп йөргән илленче елларда бер карт машинист миңа мондыйрак бер вакыйга сөйләгән иде. Сүз шәһәр үзәгендә Гражданнар сугышы каһарманы комиссар Амангелде Имановка куелган һәйкәл янында башланып китте. Амангелде (безнеңчәрәк язсаң, Аманкилде — «исән-имин туды» дигән мәгънәдә) — 1916 елгы кузгалыш җитәкчеләреннән берсе. Казакъ иленең көнбатыш өлешендә алар Әйҗәрүк батыр белән бергә баштарак патша җәза отрядларына, 1917 елгы түнтәрештән соң «ак гаскәриләргә» каршы сугышкан. Совет хакимиятен биредә урнаштыру өчен көрәшкән. Ә 1930 елда шул ук Әйҗәрүк батыр «казакъ халкына тулы мөстәкыйльлек бирмәгән, ачтан интектергән» Совет хакимиятенә каршы кылыч күтәрә. Шундый ук хәл Казакъстанның башка төбәкләрендә дә күзәтелә. Һәр өлкәнең үз батыры, үз каһарманы табыла. Мәсәлән, исеме һәм иҗаты 1990 елларда гына халкына кайтарыла башлаган бер күренекле шагыйрь биографиясенең соңгы җөмләсе «үз ишләре белән гаскәргә каршы торганда атып үтерелә» дигән юллар белән тәмамлана.

Гражданнар сугышы турында сөйләшеп торганда, әлеге карт машинист һәйкәлгә төртеп әйтә:

— Утызынчы елда исән булса, бусы да, мөгаен, Әйжәрүк дустыннан калышмас иде. Ярый әле ул вакытта ярдәмгә Оренбурдан, Самарадан гаскәри көчләр вакытында килеп өлгерде. Югыйсә безне монда атып, суеп бетерәчәкләр иде...

Әйе, нәкъ менә шушы вакыйгалардан соң казакъ халкы тормыш-көнкүрешенә караш төптән үзгәрә. Иксез-чиксез булып яткан казакъ илендә яңа сәнәгать корылмалары төзелеше тизләтелә. Илнең төрле тарафыннан монда тәҗрибәле белгечләр җибәрелә. Үз теләкләре белән ирекле килүчеләр белән бергә монда «сөрген срогын» үтәргә тиешле бихисап сандагы галим, профессорларга да урын табыла. Безнең техникумда гына да шундыйлардан берничә кеше укытты. Ленинград университеты профессорларыннан Семен Семенович Грузман — физика, Виктор Васильевич Некрасов математика фәненнән безгә ярыйсы ук тирән белем бирделәр. Математикадан бер дәреслекне кулга алганда, укытучыбыз, китап авторы фамилиясен кырыс кына атап:

— Студент чакта һәрвакыт миннән күчереп утырды, — дип әйтеп куйгалар иде.

* * *

1933 елда А.Затаевич дигән авторның «Казакъстан татарларының илле җыры» җыентыгы «Центриздат»та дөнья күрә. Аның мөхәррире якташыбыз Л.Хәмиди була. Китапны казакъ зыялылары да хуплап кабул итә. Алар Л.Хәмидине Алма-Атада эшли башлаган Казакъ драма театрының музыка бүлеген җитәкләргә чакыралар. Анда ул элекке танышлары белән дә кабат очраша. Ташкент институтында бер чорда укыган, бергә-бергә шигырьләр, мәкаләләр язышкан Мохтар Әүэзов әлеге театрны оештыручыларның берсе икән. Аның шул театрда сәхнәләштерелгән берничә пьесасын музыкальләштерү бурычы Латыйфка йөкләнә. Шул рәвешле ул монда беренче мәртәбә Абай тормышы һәм иҗаты белән якыннан таныша. М.Әүэзовның «Кобланды батыр» дастанына нигезләнгән пьесасыннан соң ул «Абай» драмасын музыкальләштерүдә дә катнаша. Бер үк вакытта аңа Казакъстан ССР радиокомитеты карамагында хор коллективын оештыру бурычы да йөкләнә. Шушы ике-өч еллык дәвердә аның казакъ халкы моңаһәңнәренә яраклаштырып иҗат иткән беренче казакъ җырлары да туа. Ильяс Җаңсыгуровның Кызыл Армиягә багышлы шигыре «Кызыл кыран»га («Кызыл бөркет», «Кызыл лачын») нигезләнгән җыр бик тә уңышлы килеп чыга. Аны һәр җирдә мактыйлар, җырлыйлар. Ләкин ул җыр бик кыска гомерле була. Шагыйрьнең тиздән кулга алынуы сәбәпле, «Кызыл кыран»ны телгә алу һәм җырлау тыела.

Бу елларда әле Латыйф Хәмиди Казан һәм Мәскәүдәге иҗатташлары белән бөтенләйгә аерылып өлгерми. Казакъ илендә вакытлыча гына эшләп, тәҗрибә туплармын да туган төбәгемә кайтырмын дип хыялланып яши. Мәскәүдә уку елларында аралашкан Муса Җәлил, Мансур Мозаффаров һ.б. белән хәбәрләшеп тора. Мәскәү консерваториясе каршында Татар опера студиясе оешканлыгын да белә. Аңа да ул студиягә кабул ителеп, югары музыкаль белем алу мөмкинлеге барлыгы турында хәбәр итәләр. Һәм 1936 елда ул янә Мәскәүгә килеп төшә. Монда элекке һәм яңа дуслар, иҗатташлар белән бергә күләмле музыкаль әсәрләр иҗат итү серләрен үзләштерә башлый. Бу чорда аның партадашлары Салих Сәйдәшев, Мансур Мозаффаров, Җәүдәт Фәйзи, Заһид Хәбибуллин, Фәрит Яруллин, Нәҗип Җиһановлар була. Нәкъ шушы елларда Латыйф ага татар халкының яраткан көйләреннән «Галиябану», «Каз канаты», «Ком бураны», «Су буйлап», «Сарман», «Шомыртым» һ.б.ларны, хор өчен эшкәртеп, нотага сала башлый. Соңрак та ул эш белән шөгыльләнүдән бизми һәм, тулы бер китаплык мая җыелгач, 1964 елда аларны Мәскәүдә бастырып та чыгара. Студияне тәмамлаганда, диплом эше итеп «Татар бию көйләренә сюита»ны нотага сала. Җитәкче укытучысы, профессор Г.Литинский ул симфоник сюитаны бик уңышлы әсәр дип кабул итә. Иҗатташ иптәшләреннән кемнәрдер балет, кемнәрдер опера яза. Мәсәлән, Н.Җиһанов «Качкын», М.Мозаффаров «Галиябану» операларын эшләргә шул чорда тотыналар. Җырлар язып кына чикләнүчеләр дә була.

1938 елның җәй башында укулар тәмамлана. Эшкә билгеләнү көннәре килеп җитә. Кемнәрдер алдан ук Казанда тиздән ачылачак опера театрына эшкә билгеләнгән була. С.Сәйдәшев элекке эшенә — Дәүләт драма театрының музыкаль бүлеген җитәкләргә дип кайтып китә. Л.Хәмидигә һәм тагын кемнәргәдер республиканың мәдәният идарәсеннән киләсе чакыру кәгазе һаман күренми. Нәкъ шул вакытта Ленинградтан кайтып килүче казакъ артистлары һәм М.Әүэзов Мәскәүдә пәйда булалар. Мохтар һәм әлеге таныш артистлар аны Алма-Атага кайтырга димлиләр. «Бездә Халык музыка уен кораллары оркестры эшли башлады, аңа дирижер кирәк. Син ул эшкә бар яктан да килешле зат», — ди М.Әүэзов. Шулай итеп, язмыш талантлы татар композиторын тагын үз иленнән читкә алып китә. Дөрес, Алама-Атада аны бик зурлап каршылыйлар. Гаилә белән яшәрдәй фатир бирәләр. (Бу вакытта Казанга кайткан студиячеләр гаиләләренең күпчелеге кунакханә бүлмәләренә урнаштырылган була.) Шул көздә үк ул әлеге оркестрның баш дирижеры һәм сәнгать җитәкчесе итеп тәгаенләнә. Хәзер дә уңышлы эшләп килгән, дөнья буйлап сәяхәт кылудан туктамаган, унтугызынчы йөз көй чыгаручысы һәм оста кубызчы-

скрипкачы Кормангазый исемен йөрткән ул Дәүләт оркестры белән якташыбыз биш ел җитәкчелек итә. (Соңгы тапкыр бу оркестр Казанга 2003 елда килде. Якташыбызның берничә әсәрен дә башкарды.) Шул чорда аның гомерлек дан китерердәй әсәрләреннән «Казакъ вальсы» (1940), чак кына соңрак «Былбыл» (1945, Н.Баймөхәммәдев сүзләре) җырлары туа. Якташыбызның казакъ илендә иҗат иткән җырларының саны өч йөзгә якынлаша. 1960 еллар башында Казакъстанда татар әдәбияты һәм мәдәнияте көннәре һәм тиздән шундый ук чара Казанда уздырылуы уңаеннан Латыйф ага татар шигыренә нигезләнеп тагын берничә көй яза. Шулардан иң танылганы, сәхнәдән еш кабатланганы, мөгаен, «Иртәләрен, кичләрен» җырыдыр (Хәсән Туфан сүзләре).

* * *

Казакъстанда яшәгән дәвердә Латыйф Хәмидинең өч опера, бер оперетта, берничә сюита һәм халык яратып кабул иткән дистәләгән казакъ җырын иҗат иткәнлеге мәгълүм. Унтугызынчы йөз казакъ көйчеләреннән Кормангазый, Дәүләтгәрәй, Биржан һ.б. әсәрләрен оркестр өчен эшкәртә. «Балалар өчен фортепьяно әсәрләре», «Балалар өчен җырлар», «Думбрада уйнау мәктәбе» һ.б. уку-өйрәнү әсбапларын төзи һәм бастыра.

Мохтар Әүэзов «Абай» драмасы җирлегендә тиздән опера либреттосын әзерли. Шуны чын опера рәвешенә китерүне яңарак оешкан композиторлар берлеге рәисе Әхмәт Җубанов белән опера студиясендә укып кайткан Латыйф Хәмидигә йөклиләр. Бу йөкләмә нәкъ авыр сугыш көннәренә туры килә. Халык уен кораллары оркестрында да эшне дәвам итәсе, сугыш батырларына багышлап җырлар да язасы, операга да җан өрәсе бар бит. 1942 елдан ул — музыка училищесында, 1944 елдан яңа ачылган консерваториядә укыта. Мактаулы доцент.

— Ул елларда көн-төн эшләдек. Ярты көнне миндә яки Әхмәтләрдә арияләр язып утырсак, икенче ярты көн училищеда дәрес биреп узар иде. Кичләрен опера театрында да эшләр чыгып тора... Өйгә кайтуга, ястык өстенә аварлык кына хәл кала. Авыр сугыш вакыты кешеләренең күңелен күтәрүгә өмет ителгән дистәләгән җыр язганмын. Совет иле каһарманы Маншук Маметовага, Панфилов дивизиясе батырларына, партизаннарга багышлы җырларым әле хәзер дә радиотапшыруларда кулланыла...

Бик күп тырышлык куелган, байтак сынаулар үткәннән соң, ниһаять, «Абай» операсы язылып бетә. Мәскәү, Киев, Ленинградлардан эвакуацияләнгән музыка, сәхнә белгечләре ярдәмендә сәхнәләштерелүгә керешелә. 1944 елда тамашачы операны дәррәү алкышлап кабул итә. «Абай» — җирле милли кадрлар тарафын-

нан иҗат ителгән беренче милли опера. Дөрес, аңа кадәр, 1934 елда ук, бер тәҗрибә булып ала. Опера сәхнәсендә «Кыз җибек» («Ефәктәй кыз») дастаны нигезендә эшләнгән музыкаль әсәр уйнала. Ләкин аның музыка авторы башка милләт вәкиле — Евгений Брусиловский була.

«Абай» операсы — казакъ опера сәхнәсенең иң уңышлы әсәре. Аның әлегәчә куелмый, уйналмый калган елы юк. Мәскәүдә уздырылган казакъ мәдәниятенә багышлы чараларда да «Абай» сәхнә түрендә йөри. Ул операда баш рольләрне башкаручы Күләш Байсәетова, Роза Җаманова, Бибигөл Телөгәнева, Ирмәк Серкебаев, бертуган милләттәшләребез Ришат һәм Мөслим Абдуллиннар дөнья күләмендә танылган артистлар дәрәҗәсенә ирештеләр.

Алда әйтелеп үткәнчә, 1945 елда өч композитор тарафыннан Казакъстан ССРның үз гимны иҗат ителә. Бер үк вакытта Л.Хәмиди акын Җамбулның йөз яшенә багышлап бер актлы «Җамбул белән Айкуныс» операсын да эшли (1946). Соңрак, 1949 елда, опера, тулыландырылып, «Җамбул» исеме белән 1952 елда сәхнәләштерелә. Сугыш барган көннәрдә үк башланган һәм төрле сәбәпләр белән бераз тоткарланган «Теләгән Туктаров» операсы да, ниһаять, 1947 елда төгәлләнә һәм сәхнәләштерелә. Сугыш батырына багышланган бу опера да Латыйф ага белән Әхмәт Җубановның уртак җимеше.

— Әхмәт белән без утызынчы еллар ахырында Кормангазый исемендәге оркестрда бергә эшли башлаган идек. 1939 да композиторлар оешмасын да бергә нигезләдек. Беренче көннән башлап анда идарә әгъзасы булып торам. Музыка сәнгатенә багышлап йөзләгән мәкалә, очерк язып бастырдым. Музыка фонды рәисе булуыма да дистә еллар инде. Төрле музыкаль чараларда жюри рәисе яки әгъзасы булган очраклар да еш кабатлана. Үпкәләр җаем юк. Читкә тибәрергә теләгәннәрен тоймыйм.

Хак әйтә Латыйф ага. Казакъ илендә әлегә аның абруе зур. 1942 елда аңа Казакъстан ССРның атказанган артисты, 1966 елда халык артисты дигән мактаулы исемнәр бирелә. 1978 елда ул Күләш Байсәетова исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була. Берничә орден, медаль белән бүләкләнә. Әдәбият, сәнгать өлкәсендә хезмәт итүчеләр өчен Казакъстан ССРның дәүләт бүләкләрен булдыру карары 1944 елда кабул ителә. Әдәбият өлкәсендә эшләүчеләр өчен ул хәзер — Абай, музыка, театр осталары өчен Күләш Байсәетова исемендә йөртелә. Күләш — казакъның танылган беренче опера җырчысы. Аңа 1936 елда ук (егерме дүрт яшендә) СССРның халык артисты исеме бирелә. Хәер, казакъ опера сәнгатендә һәм музыка өлкәсендә дәүләтнең андый иң югары исемен яшьли алучылар байтак. Роза Җаманова, Мукан Төләбаев, Ирмәк Серкебаев СССРның халык артисты исеменә 1959 елда, Бибигөл

Теләгәнева белән Ришат Абдуллин 1967 елда лаек дип табылалар. Роза белән Ирмәккә андый зур дәрәҗәле исем бирелгәндә, әле егерме дүрт яшь тә тулмаган була. Талантлы, сәләтле иҗат кешеләрен шулай иртә бәяли белүдән үрнәк алырга кирәктер, мөгаен.

Өстәп шуны да әйтик, Көләч Байсәетова Латыйф аганың «Казакъ вальсы» белән «Былбыл» җырын иң беренче һәм үзенчәлекле моң вә күтәренке рухлы итеп башкаручыларның берсе санала.

— Арабыздан иртә китмәсә, без тагын да бергә күп нәрсә иҗат иткән булыр идек әле, — ди композитор, аның белән иҗатташ булу елларын искә төшереп. Көләч 1957 елда вафат була. Кырык биш яшендә. Әмма аның җырлары, арияләре хәзер дә радио, телевидение репертуарыннан төшми җырланалар.

Латыйф Хәмиди 1948 елда Н.Баймөхәммәдев либреттосына «Балбулак» опереттасын иҗат итә. Бу әсәр аның шушы юнәлештәге соңгы хезмәте. Мирасында тагын берничә күләмле симфоник әсәре — сюиталары бар. Казакъстанда элегрәк даими башкарылган «Татар бию көйләренә сюита»дан тыш иҗатташлары һәм музыка сөючеләр тарафыннан югары бәяләнгән «Кобланды» һәм «Алма-Ата» сюиталарын атап үтәргә кирәктер.

Латыйф Габделхәй улы Хәмиди 1983 елда җитмеш җиде яшендә Алма-Атада вафат була. Ике-өч ел элгәре генә бергә гомер иткән карчыгы Сания дә гүр иясе була. Аңа чаклы әле без тагын бер мәртәбә шул ук «Алма-Ата» кунакханәсенең иркен бүлмәсендә иркенләп сөйләшеп утырган идек. 1980 елның июнь башларында, замандашы Сабит Мукановның сиксән еллык юбилее билгеләп үтелгән көннәрдә Латыйф ага миңа җитмеш яшенә атап чыгарылган буклетын (иҗат биографиясе язмасын) бүләк итте. (Аның җитмеш яшьлек юбилеен билгеләп үтү тантанасы 1976 елның 8 декабрендә Абай исемендәге Опера һәм балет театрында бик зурлап уздырыла.) Шул очрашуда Латыйф ага Әхмәт Җубанов белән икесенә багышлап повесть иҗат ителүен, ләкин хәзергә ул әсәрнең үзендә юклыгын белдергән иде. Блокнот битенә «Повесть авторы Лия Җаһанова» дип язып куйганмын. Музыка белгече А.Юсфин 1964 елда — Мәскәүдә, Б.Ерзакович 1978 елда Алма-Атада «Латыйф Хәмиди» исемле хезмәтләрен нәшер иткәннәр. «Казакъстан ССР энциклопедиясе»нең 4 нче томында да якташыбызга багышлы төпле мәгълүмат бар. Ә «Татар энциклопедия сүзлеге»нең 727 нче битендә кыскача таныштыру мәкаләсе урнаштырылган.

*2007*

# ЧЫҢГЫЗ ТАУЛАРЫНЫҢ БӨРКЕТЕ

*(Очерк)*

Оренбург каласының ап-ак йортлары тезелешеп утырган Урал суы башына — җәй көннәрендә үзенә бер үзәккә әверелгән өлешенә барып чыктым исә, нигәдер казакъның бериш олы язучылары күз алдыма килә: Сәкен Сәйфуллин, Мохтар Әүэзов, Сабит Моканов, Габит Мөсрепов... Габиден Мостафин... Алар — казакъ совет әдәбиятына нигез салучылар, казакъ мәдәнияте тарихында исемнәре алтын хәрефләр белән язып куелган шәхесләр — кайчандыр шушы «Ак кала» урамнарында йөргәннәр бит, шушы текә яр башыннан ашкын сулы Урал елгасына рухланып карап тора торган булганнар. Шушы урында алар күмәкләшеп казакъ халкының киләчәк язмышын кайгырткан — дала тормышын үзгәртеп корырга хыялланып яшәгәннәр, чөнки бу чорда бит әле алар язучылыктан бигрәк казакъ илендә Совет хакимиятен урнаштыру эше белән күбрәк шөгыльләнгәннәр. «Ак шәһәр»нең күрке булып, Урал суына йөз белән карап утырган өч катлы мәһабәт ак йорт — беренче казакъ Совет хөкүмәте йорты.

Кыргыз-казакъ Автономияле Совет Республикасы оешкач та, Оренбург шәһәре аның башкаласы итеп билгеләнә. Чөнки бу кала элек-электән, казакъ хан-солтаннары белән беренче элемтәләр барлыкка килә башлау белән үк, үзенә күрә бер идарә үзәгенә әверелгән була. Патша хөкүмәте моннан торып ике-өч гасыр дәвамында дала тормышы белән идарә итеп килә. (Дала ягы халыклары белән икенче идарә үзәге — Омск, казакъчалаштырып әйтсәк, Омбы — соңрак барлыкка килә.)

Урал яры өстендәге ул өч катлы йортта яшь Автономияле Республиканың Үзәк башкарма комитеты да урнаша. Башкарма комитетның беренче рәистәше һәм Мәгариф Халык комиссары шагыйрь һәм ялкынлы яшь революционер Сәкен Сәйфуллин була. Ә 1923 елда ул Казакъстан АССРның Халык Комиссарлары Советы рәисе итеп билгеләнә. Башкарма комитетның икенче бер эшлекле җитәкчеләреннән берсе — яшь язучы Мохтар Әүэзов. Соңрак алар янына тагын да яшьрәк буын каләмдәшләре килеп кушылачаклар...

Шушы яр башындагы йорттан торып алар үз «мөстәкыйль мәмләкәт»ләре белән идарә иткәннәр, үз халыкларының аң-белемен, абруен күтәрергә хыялланганнар... Шушы «Ак кала» урамнарында йөргәндә, мөгаен, язылачак әсәрләре хакында да уйланганнардыр.

Әйе, Урал буеның шушы тирәләренә юлыктым исә, күз алдыма алар килеп басалар: әнә алдарак атлаучысы — казакъ халкының баш бирмәс лачыны Сәкен Сәйфуллин... Аның янәшәсеннән

киң маңгайлы, текә карашлы бөркет, Чыңгызтау буйларында канат чыгарган Мохтар Әүэзов киләдер сыман...

Мохтар Әүэзов... Күпмилләтле совет әдәбияты күгендәге якты йолдызларның берсе. Төрки телдә язучы әдипләрдән беренче буларак аның иҗаты иң югары бүләккә — Ленин премиясенә лаек дип табылган иде. Ә аңа чаклы, «Абай» романының беренче китабы дөнья күргәч, 1949 елда Мохтар Әүэзовка СССР Дәүләт бүләге бирелде. Өстәвенә ул илкүләм танылган язучылык хезмәтеннән тыш казакъ әдәбиятының үткәнен барлауга күп көч куйган шәхес, бу юнәлештәге эшчәнлеге өчен 1946 елда ук Казакъстан ССР академиясенең академигы дәрәҗәсенә ирешкән галим дә иде. Бер үк вакытта Мохтар Әүэзов чорыбызның танылган җәмәгать эшлеклесе иде — СССРның Тынычлыкны яклау комитеты әгъзасы, СССР Ленин премияләре комитетының абруйлы бер вәкиле булды. Азия һәм Африка илләре прогрессив язучыларының дуслыгын, үзара бердәмлеген ныгытуны истә тотып оеша башлаган берләшмәнең беренче нигез ташын салучыларның берсе иде. Ул берничә тапкыр Казакъстан ССР Югары Советы депутаты итеп сайланды.

Мохтар Омархан улы Әүэзов 1897 елның 28 сентябрендә казакъ иленең иң көнчыгышында — Алтай таулары итәгендә урнашкан җирдә туа. Семипалат өлкәсе Чыңгыз өязе Чыңгызтау итәгендә күченеп йөргән кечерәк бер авылда. Бабасы Әүэз аңа биш-алты яшеннән токымдашы шагыйрь Абайдан калган кулъязма буенча хәреф танытырга керешә. Якын-тирәдә генә мәктәп-мәдрәсәләр булмый. Патша заманында яшәп килгән тәртип буенча, мәктәп-мәдрәсәләрне мәчет каршында гына ачу рөхсәт ителгән, ә күчмә тормыш белән яшәгән казакъ авылларында мәчетләр булмаган диярлек. Дөрес, Семипалат шәһәрендә укымышлы татар мулласы Әхмәт Риза ачкан данлы мәдрәсә эшләп килә. Атасы вакытсыз үлмәсә, Мохтарны да, мөгаен, шул ерактагы мәдрәсәгә илтеп бирерләр иде. (Бу мәдрәсәдә кайчандыр Абай да белем эстәгән бит, беренче шигырьләрен дә шунда яза башлаган.)

Әмма 1908 елда атасы үлгәч тә, Мохтар Касыймбәк абыйсы тәрбиясендә кала, агасы аны шул көздә үк биш класслы казна мәктәбенә илтеп тапшыра. Шулай итеп, Мохтар русча укуга күчә. Соңыннан әдип бу хакта: «Касыймбәк агам, остазы Камалетдин хәзрәт бәддогасы белән дә исәпләшеп тормастан, мәдрәсәне ташлап, рус мәктәбендә белем алган. Мине дә, Чыңгыз өязе стипендиясе хисабына, шунда урнаштырды. Бу биш класслы училище җирле халыктан патша хезмәтенә яраклы тылмач вә башка төрле вак чиновниклар әзерли иде. Әлеге уку йортын тоту өчен халыкка өстәмә салым салына. Тик халыкта ул мәктәпкә карата кырын караш яши, чукындыру нияте белән ачылган ул дип, балаларны

җибәрмәскә тырышалар. Шунлыктан анда укучыларны мәҗбүри рәвештә җыялар, кайвакытта хәтта бала атасына күпмедер «йолым» да түләнә иде... Табигый, безнең бабай улларына һәм оныкларына биредә укырга юл куйганы өчен ырудашларыннан шелтәне аз ишетмәде»,— дип язды.

Укуга сәләтле Мохтар монда алган белем белән генә дә чикләнми — Семипалаттагы укытучылар хәзерләүче семинарияне дә уңышлы тәмамлап чыга. Һәм шунда укыганда, казакъ халкының фольклор үрнәкләре белән дастан-поэмаларына нигезләнеп, беренче шигъри пьесасын яза.

Мохтар семинарияне тәмамлаган җәйдә дала тормышы бик катлаулы чор кичерә. 1919 елда «аклар-кызыллар» тартышы нәкъ шушы тирәләрдә куәт алган чак була. Текә борылышлар чоры. Урта Азиянең күпчелек өлешендә әлегә большевикларга сырты беләнрәк торучы Төркестан Автономияле Республикасы хакимлек итә. Аның йогынтысы Семипалат тирәләренә дә җитә, чөнки әле монда да аерым милли дәүләт төзергә хыялланган Алаш Урдачылар түрә булып утыралар. Ләкин инде аларның хакимлегенә атналар, айлар гына калган була. Озакламый губернада революцион көчләр җиңүгә ирешәләр, Семипалатта Совет хакимияте урнаша. Ак патша чоры тәртипләре юк ителә.

Шул дәвердән башлап Мохтар Әүэзовның җәмәгать эшчәнлегенә һәвәслеге ачылып китә — беренче Совет оешмаларында җиң сызганып эшкә керешә ул. Хәер, аның яшьтәшләре, казакъ халкының беренче яшь интеллигенция вәкилләре — Сәкен Сәйфуллин, Сабир Шәрипов, Баембәт Майлиннар ише яшьләр — һәркайсы үз төбәк-губерналарында яңа тормыш-яшәеш өчен барган көрәшнең алгы сафында булалар, революция давылы алып килгән үзгәрешләрне үз өяз-губерналарында урнаштыручылар сыйфатында танылып өлгерәләр.

Егерме ике яшь тулмаган Мохтарны да тиздән Семипалат губерна Советы башкарма комитетына җаваплы эшкә билгелиләр. Бик хәтәр вакытлар булуга карамастан, ул өяздән өязгә, авылдан авылга йөреп тора, анда яңа тормыш урнаштыруга булыша. Озакламый аңа шушындый вазифаны бөтен Казакъстан күләмендә дип әйтерлек башкару эше йөкләтелә: 1920 елда Кыргыз-казакъ Автономияле Совет Республикасы оешкач та, ул Үзәк башкарма комитет карамагына җибәрелә. Бу дәверне ул соңрак болай дип искә алды: «Шәһәрдә укып кайткач, дала тормышының иске гореф-гадәтләре, сыйнфый тигезсезлекләре, хатын-кызга карата җәберзолым күзгә тагын да ташлана төшә иде... Артта калган тормышның шушы караңгы яклары әле шулкадәр көчле булып, Казакъстанда Совет власте урнаштырылгач та, җәмәгатьчелеккә, кешенең хокукына карата борын-борын заманнардан ук килгән караш,

гадәт һәм шәригать кануннарына ябышып ятучы байлар, ыру башлыклары белән нык кына көрәшергә туры килде...»

Нәкъ шушы көннәрдә ул, халык арасында йөргәндә күргәннәренә нигезләп, Максим Горький, Шәриф Камалларның башлангыч иҗат чорларындагыча чын реалистик алым белән, җанны тетрәндерердәй беренче хикәяләрен — «Ятимә язмышы», «Искелек күләгәсендә», «Сүнеп яну», «Барымта», «Өйләнү», «Ятим» һ.б. яза.

Мохтар Әүэзов монда, Оренбургта торып эшләү дәверендә, шулай ук драма әсәрләре язуын да дәвам итә. Алда әйтеп үтелгәнчә, казакъ халык иҗатына нигезләнеп ул инде семинариядә уку чорында ук «Енлик-Көбәк» әсәрен язган була. Пьесаның төп каһарманнары Көбәк батыр белән Енлик, мәгълүм Кузы-Күрпәч белән Баянсылу, Айман белән Чулпаннар кебек, феодализмның традицион каршылыкларына, хатын-кызның хокуксызлыгына риза булып яшәмәүләрен белдерәләр һәм шул көрәш юлында озакламый һәлак булалар. Шулай итеп, пьеса, борынгы дастан алымнарын кулланып язылып та, Мохтар яшәгән көннәрнең көрәш рухын да үз эченә алган, үзендә чагылдырган бер әсәр рәвешендә кабул ителә.

М. Әүэзовның башлангыч иҗат чорын күз алдыннан кичергән байтак әдип һәм галимнәр, язучының кырыс хакыйкатькә таянып язылган беренче хикәяләрен һәм «Енлик-Көбәк» шикелле әсәрләрен истә тотып булса кирәк, аңа традицион Шәрекъ әдәби мирасының гына түгел, бәлки алдынгы рус әдәбиятының да йогынтысы барлыгын әйтәләр. Әйе, Мохтар Әүэзовның бу ике зур мирасны — урта гасырларда чәчәк аткан Шәрекъ мәдәнияте белән соңгы йөз еллыкларда көч алган Европа мәдәниятен бик яхшы өйрәнеп үзләштерүен, үз иҗатында бик белеп аларны үстерүен Вс.Иванов, А.Фадеев, Л.Соболев һәм Н.Тихонов кебек танылган шәхесләр дә билгеләп үтәләр.

Ләкин әле әдәбият белгечләре шушы ике мәдәният арасында торган татар эшлекләләре арадашлыгына әһәмият биреп бетермн, бу ике мәдәниятне берләштереп торучы чуклы-челтәрле ул күперне күрмичәрәк үтәләр шикелле. Шунлыктан мин бу хезмәтемдә шушы арадашлык өлкәсенә күбрәк басым ясамакчы, үзем белгәннәрне әйтеп калмакчы булам.

Мохтар Әүэзов шәхесенә килгәндә исә, татар мәдәниятенең үз заманында күренекле бер үзәге саналырдай Оренбург каласына килеп юлыкканчы ук инде ул татар дөньясы белән азмы-күпме таныш була. Семипалатта уку дәверендә үк алдынгы татар яшьләре белән якыннан аралаша.

Мәгълүм ки, Октябрь революциясе алды елларында Казакъстанның байтак төбәкләрендә алдынгы карашлы казакъ һәм та-

тар яшьләре — шәкертләр, мөгаллимнәр, приказчиклар — бергә берләшеп, әдәбият-сәнгать түгәрәкләре, «Яшьләр җәмгыятьләре» оештыралар. Бу ике халык вәкилләре кушылып, нык аралашып яшәгән шәһәрләрдә казакъның алдынгы карашлы беренче матбугаты борын төртә башлый: 1911 елда халкының күпчелеген татарлар тәшкил иткән Троицк шәһәрендә казакъ телендә беренче әдәби-сәяси «Айкап» журналы басыла. 1913 елның башында Оренбург шәһәрендә казакъ халкына ирек, хөррият даулаган бер төркем яшьләр милли үзаңны үстерүгә юнәлеш тоткан «Казакъ» газетасына нигез салалар. Шул дәвердә актив иҗат юлына баскан Галимҗан Ибраһимовның «Казакъ» газетасы редакторы Әхмәт Байторсынов белән якыннан аралашканлыгы, ул вакытта казакъ илендә Абайдан кала иң күренекле шагыйрь булган Мәгъҗан Җумабаев белән дустанә мөнәсәбәттә торганлыгы мәгълүм ич. Сталин хакимияте дәверендә исеме һәм иҗаты юкка чыгарылган Мәгъҗан Җумабаев мирасы яңадан халкына кайтарылган бу көннәрдә Г.Ибраһимовның «Казакъ кызы» романындагы эпиграф-шигырь астына кабат «Җумабаев» дип куеп, бу ике шәхес арасындагы мөнәсәбәтләрне барлап, яңартасы гына калды...

Киң дала, күрсәң гуй, ана җаткан,
Җебәктәй җәсел чүптә* битен җапкан,
Аскар тау, балдай татлы сулары бар,
Ана шул анам иде мине тапкан...

Әйе, егерменче гасыр башларында казакъ, татар яшьләренең бердәмлеге нәтиҗәсендә ике ара чатындарак урнашкан Троицк, Оренбург, Уральск, Кустанай, Петропавел (Кызыл Яр) ише шәһәрләрдә әдәбият-сәнгать түгәрәкләре, үзешчән театрлар барлыкка киләләр. Мохтар Әүэзовның яшьлек дусты Галиәкбәр Түрәбаев хәтерләвенчә, «Енлик-Көбәк» пьесасын беренче мәртәбә халык хөкеменә Семипалат шәһәренең әнә шундый яшьләрдән торган «Есаймак» драма түгәрәге чыгара.

Шул ук елларда казакъ яшьләре һәм калкып, күтәрелеп килүче әдип һәм шагыйрьләре арасында, мәсәлән, беренче казакъ романы авторы Әсфәндияр Кубиев, шагыйрь Солтан-Мәхмуд Торайгыров, шагыйрь Мәгъҗан Җумабаев, Сәкен Сәйфуллиннар биографияләрендә чагылыш тапканча, Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимовлар иҗаты белән кызыксыну да арткannan-арта бара. Яшүсмер дәверендә укуын гәрчә рус мәктәбендә дәвам иттерсә дә, Мохтар Әүэзов та татар әдәбияты белән танышудан читләшеп калмый. Күренекле тел га-

* Кардәш казакъ халкы «чүп» дип печәнне атый. Бу очракта «җәсел чүп» яшел үлән була.

лиме Г.Мусабаев белән бер әңгәмәсендә ул бу хакта ачык әйтә һәм хәтта: «Рус классик әдәбияты белән беренче танышуым да татар әдәбияты аша булды»,— дип белдерә.

Инде кабат Оренбург көннәренә әйләнеп кайтыйк. Сәкен Сәйфуллин, Мохтар Әүэзовлар яшь автономияле республиканың җитәкчеләре сыйфатында бу шәһәргә килеп тупланган көннәрдә әле монда татар халкының олуг шәхесләре Дәрдеменд, Фатих Кәрими, Риза Фәхретдинев эзләре һич кенә дә суынмаган була. Театр сәхнәләрендә тәҗрибәле драматург Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану», «Асылъяр»лары белән янәшә Шамил Усмановның «Канлы көннәрдә»се, Фатих Сәйфи-Казанлы, Кәрим Тинчурин, Фәтхи Бурнаш пьесалары уйналалар. «Юксыллар сүзе» газетасында тиктормас ялкынлы шагыйрь Һади Такташ эшләп тора. Шәһәр күләмендәге җәмәгать эшләрендә катнашып, инде татар әдәбиятының аксакаллары рәтенә баскан әдип һәм драматург Шәриф Камал йөри. Аның да бу уяну дәверендә «Хаҗи әфәнде өйләнә» комедиясе сәхнәдән төшми карала, «Акчарлаклар» повесте кулдан-кулга йөреп укыла торган чак. Шул «картлар» арасында әле баласымак кыяфәтле яшь шагыйрь Муса Җәлил дә күренеп киткәли, әледән-әле булып торган җыелыш, митингларда ул, остазы Төхфәт Ченәкәй белән аралаша-аралаша, дәртләнеп шигырь сөйли.

Бу чорда монда әледән-әле әдәби-музыкаль кичәләр оештырылып тора, сәхнәдә сүз осталарын музыкантлар, җырчылар алыштыра. Оренбургта бу вакытта татарның өч булачак композиторы — Салих Сәйдәшев, Җәүдәт Фәйзи, Александр Ключарев яшьләр белән аралашып яшиләр, кичәнең музыка бүлеген даими җанландырып торалар. Танылган җырчылардан Газиз Әлмөхәммәтев тә әледән-әле монда күренгәләп ала. Ул бигрәк тә, Шаляпиндай куәтле тавышын яңгыратып, татар, башкортларның борынгы көйләрен башкарырга ярата. Ә ул көйләр, билгеле инде, киң кыр-далада үскән казакъ баласына да бик үз, бик якын бит!

Әйе, бу көннәрдә казакъ һәм татар мәдәниятен, мәгърифәтен үстерергә омтылган бу яшьләр уртак тел тапкандыр (татар һәм казакъ телләре үзара бик якын бит), бергә-бергә җыелышлар уздырган, кичәләр, кич утырышлар оештыргандыр, әлбәттә. Тик әлегә ул очрашуларны тасвир итеп калдырган истәлекләр генә бик алай ишле түгел. Чөнки заманында «менә без, татар һәм казакъ язучылары, яшьләре, бергә-бергә шундый-шундый урыннарда аралаштык, берләштек» дип язып торуның кирәге булмаган. Ә язылганның булган кадәресе исә, минем уемча, беркем тарафыннан да барланмаган, тикшерелмәгән.

Кыргыз-казакъ автономиясе оешканның беренче көннәрендә үк байтак кына татар интеллигенциясе Казакъстан җирлегендә уку-

укыту эшләрен җайга салуга тартыла. Әйтик, татар дөньясында беркадәр эз калдырган язучы Зариф Бәшири казакъ, уйгыр мәктәпләре өчен дәреслекләр төзүдә, уку-укыту эшен яңача кору юнәлешендә җиң сызганып эшли. Яңа ачылган күп кенә газета-журналлар да татар зыялылары ярдәмендә аякка бастырылалар. Мәсәлән, Муса Җәлилнең өлкән шәриктәше, элекке «Хөсәения» мәдрәсәсе шәкерте Заһид Шәркый-Йосыповка 1924 елның башында казакъ телендә «Юл» газетасын редакцияләү, газета чыгаруны юлга салу эше йөкләтелә. Бәлки, аңа бу вазифаны башкарма комитетта уку-укыту, мәдәният эшләре белән җитәкчелек итүче Мохтар Әүэзов үзе үк йөкләгәндер. Заһид Шәркый-Йосыпов моңарчы Шәриф Камал белән бер үк елларда «Вакыт» газетасы редакциясендә эшләгән. Соңра, Оренбургта Совет хакимияте урнашкач, татар телендәге «Мөхбир», «Юксыллар сүзе» газеталары редакторы булган тәҗрибәле журналист. Үзе дә әз-ким каләм тибрәткәләүче кеше. Егерменче елларда берничә пьесасы Оренбург театры сәхнәсендә уйналган, әдәби-тәнкыйть мәкаләләре, очерклары газета-журнал битләрендә даими рәвештә күренгәләп торган. Танылган комиссар Шамил Усмановның, әдип Шәриф Камалның якыны. Соңрак та ул танылган язучылар белән якыннан аралаша: Донбасста татарча «Пролетар» газетасын редакцияләгәндә Нәби Дәүлине каләм һөнәренә тарта, утызынчы елларда Мәскәүдә Муса белән бер газетада эшли, редактор урынбасары була. «Коммунист» газетасы 1934 елның декабрендә ябылгач та, СССР Язучылар идарәсе карамагындагы «Литературная газета»ның милли әдәбиятлар бүлеге мөдире була. Сугыш башлангач, бу газета чыгудан туктап тору сәбәпле генә, ул хезмәтеннән китә.

Әйе, Мохтар Әүэзов, Сәкен Сәйфуллин, Сабит Мокановлар безнең Мусаларны, Заһид, Такташларыбызны Оренбургта бергәбергә эшләгән вакытта гына түгел, соңрак та белгәннәр, алар белән даими рәвештә аралашып яшәгәннәр.

Мохтар Әүэзов үз гомерендә байтак кына әсәрләр иҗат итә. Драматург буларак та бик бәрәкәтле эшли. Мәсәлән, аның кулы белән язылган «Абай» драмасы һәм шуның нигезендә композитор якташыбыз Латыйф Хәмиди катнашында опера сәхнәсе өчен эшләнгән «Абай» опералары бүген дә сәхнәдән төшми уйналалар. Ә инде проза жанрындагы уңышларын әйтәсе дә түгел — бөтен дөньяга мәгълүм ич. Язма казакъ әдәбиятының нигезен салучыларның берсе, русның Пушкины яисә татарның Тукаедай шәхес булган шагыйрь Абай Конанбаевның тормыш һәм иҗат юлын яктыртуга багышланган «Абай» һәм «Абай юлы» романдилогиясе татар укучысына да бик таныш һәм якын. Киң эпик колачлы бу әсәр заманында казакъ халкының телен, гореф-гадәт-

ләрен бик яхшы белгән әдип Сәрвәр апа Әдһәмова тарафыннан тәрҗемә ителгән иде.

Билгеле инде, Мохтар Әүэзов кебек бер халыкта бер гасырга берәү-икәү генә туган мөхтәрәм шәхес вафатыннан соң да һич онытылмый. Мохтар ага бу дөньядан 1962 елның кышында киткән иде. Аның үлеменнән соң ук аңа дип махсус атап салынган ике катлы мәһабәт йорт-утар олы әдипнең музее итеп үзгәртелде. Алма-Ата шәһәренең үзәк урамындагы бу музей-йортның ишеге менә утыз елга якын инде һич ябылмыйча, төрле төбәкләрдән һәм төрле илләрдән килгән кунаклар өчен һәрвакыт ачык.

Шул музейда булган саен, мин һәрчак бер зур горурлык хисе кичерәм. Мохтар Әүэзовтай олы бер шәхес янәшәсендә, аның киңәшчеләре, дуслары, фикердәшләре сыйфатында байтак кына минем якташларым да булган икән дип сөенәм мин. Әнә музей киштәләрендә татар хәреф җыючылары җыеп туплаган казакъ китаплары. Казан, Оренбург, Уфа басмаханәләрендә дөнья күргәннәр алар. Алар янәшәсендә үк Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Муса Җәлил томнары. Мохтар ага аларны кат-кат кулына алган, укыган. Тагын бер киштәдә олуг чордашларына авторлар үз куллары белән тапшырган китаплар — Хатип ага Госман әнә «Татар әдәбияты» җыентыгын, Кави Нәҗми «Язгы җилләр», Ибраһим Гази «Гади кешеләр» романнарын бүләк иткәннәр. Ә музейның түреннән Мохтар Әүэзовның сөйкемле зур рәсеме елмаеп карап тора. Аны 1941 елда олуг рәссамыбыз Бакый ага Урманче эшләп бүләк иткән икән...

Нихәтле хатирәләр бу музейда! Ләкин аның залларында йөргәндә дә минем күз алдымда ерак Оренбург каласы, текә Урал яры өстендә калкып торган ак бер бина — Сәкен, Мохтар, Мусалар эзен саклаган бина пәйда була. 1925 елның июнь ахырында Казакъ мохтариятенең башкаласы Кызыл Урда шәһәренә күчерелә. Оренбург фәкать шул өлкәнең башкаласы булып кала. Уралсу буендагы ак бина өлкәнең комсомол комитеты карамагына бирелә.

Әйе, әйе, Мохтар Әүэзовлардан соң бу бинада Оренбург өлкәсенең комсомол штабы урнаша. Муса Җәлил анда инструктор булып эшли башлый...

*«Офыктагы рәшәләр», 1990*

## ЯКЫН КАРДӘШЛЕК ЭЗЛӘРЕ

Казакъ һәм татар әдәбиятлары багланышларын беркадәр күздән кичерәсе килә. Тел-лөгать һәм тарихи җирлек җәһәтеннән казакъ белән каракалпак халыклары безгә иң якын кардәшләр. Татарга алардан да якынрагы фәкать башкорт милләте була. Ун-

тугызынчы гасырның икенче яртысында яшәгән күренекле фикер иясе, шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Абай Конанбаевның казакъ халкы тарихын барлаган бер хезмәте бар («Бераз сүз казакъның төбе кайдан чыкканы туралы»). Анда ул казакъларның борынгы Монгол империясенә бәйле булуын билгеләп үтә дә түбәндәге җөмләләрне язып китә: «Иске мизгелдә (борынгы заманда) мангулдан бер татар аталган халык билгеле икән. Кытайлар «татан» дип яза. Асыл төбе казакъның шул татар. Шушы көндә дә казакъның түрә нәселләре үзләрен без татарбыз дип әйтәдер». Бөек акын язып калдырган бу сүзләр, минемчә, бүгенге фән күзлегеннән караганда да инкарь ителми. Бүген җир йөзендә яшәгән һәр халыкның тарихы катлы-катлы, милли йөзе катлам-катлам. Үзләрен «саф рус» дип атаучыларның да канында, рухында һәм кыяфәтендә татар-төркиләрдән тыш угыр-фин һ.б. халыклар чалымнарын микроскопсыз да шәйләп була. Тел байлыклары турында әйтеп тә торасы юк. Билгеле, татар милләтенең тарихи катлаулары арасында болгары да, кыпчагы да, йәмәк-кимәге дә бар. Исем-атамасыннан ук күренеп торганча, бик борынгы татар катлавы да анда сизелерлек калын булган. Казакъ этносының язмышы да шундый. Ул кардәш милләт нигезендә йәмәк-кимәк, кыпчак, найман һәм, Абай билгеләп үткәнчә, беркадәр борынгы татар эзе дә бар.

Революциягә кадәр берән-сәрән генә профессиональ язучылары булган казакъ әдәбияты һәм мәдәнияте хәзерге вакытта мактаулы исемнәргә бик тә бай. Киң колачлы проза әсәрләре иҗат итүчеләрдән генә дә бүген күпчелек әдәбият сөючеләргә мәгълүм дистәләгән исемне телгә алып узарга мөмкин булыр иде. Әйе, казакъ әдәбияты, бигрәк тә проза тармагындагы уңышлар бүген бөтендөнья укучысына да яхшы таныш дияргә буладыр. Миржакып Дулатов, Сәетваккас Сәйфуллин, Мохтар Әүэзов, Сабит Моканов, Габиден Мостафин, Габит Мөсрепов, Әнүәр Әлимҗанов, Ильяс Есенбирлин, Әбдеҗәмил Нурпеисов, Олҗас Сөләйманов, Әбиш Кекилбаев, Мохтар Мәгауин, Шерхан Мортазаев, Саин Моратбәков, Әнәс Сараев һ.б. бик күпләрнең иҗатлары бүген байтак кына чит ил телләренә тәрҗемә ителгәннәр. Аларның күпчелегенең әсәрләре белән бүген Көнбатыш Европа укучысы да, Азия илләре әдәбият сөючеләре дә таныш. (Соңгы чорларда казакъларның, мәсәлән, Кытай, Япония белән элемтәләре тотрыклы.) Совет чоры хакимияте тарафыннан утызынчы еллардан бирле казакъ әдәбиятын вә мәдәниятен үстерүгә аеруча әһәмият бирелде, аларны киң мәйданга чыгару юнәлешендә байтак эшләр эшләнде. Җитмешенче елларда, хакимият җитәкчелегенә Казакъстан вәкиле буларак килгән Леонид Брежнев заманында, казакъ мәдәнияте тагын бер югарылыкка күтәрелде. Мисалга Алма-Ата

киностудиясе төшергән кинофильмнарның ил күләмендә киң таралганлыгын китерү дә җитәдер. Казакъ әдәбиятын чит илләрдә тарату һәм пропагандалау көчәйде. Безгә, безнең мәдәнияткә караш икенчел дәрәҗәгә тиң санала башлады. Автономияле республикалардагы язучылар оешмаларына Союздаш республикалардагы каләмдәшләре белән турыдан-туры элемтә тоту, аралашу өчен дә Мәскәүдән махсус рөхсәт алу сорала башлаган иде.

Ә бит безнең күпчелек борынгы әдәбият үрнәкләре уртак булган. Борынгы дастан-поэмаларны күпчелек төрки халыклар уртак мирас дип санаганнар. Утрак тормыш алып баруга шактый иртә күчүебез сәбәпле, бездә язма әдәбият үрнәкләре дә иртәрәк туган. «Кардәш казакъ әдәбиятына без һәрвакыт үрнәк булганбыз» дип тә язгалый идек элгәреге елларда. Бүген инде без алай дип әйтә алмыйбыздыр, мөгаен. Бүген безнең дөнья күләмендә танылган әсәрләребез дә, мәдәният күгендә ялтырап алган шәхесләребез дә бик аз. Дөрес, алар безнең үзебездә бар. Заманча тирән фәлсәфи яңгырашлы шигырьләребез бер генә милләт шигъриятеннән дә калышлы түгел. Әмирхан Еники, Фатих Хөсни, Нурихан Фәттах, Миргазыян Юныс кебек прозаикларыбызның үрнәк әсәрләре дә башкалардан ким түгел шикелле. Ләкин аларны үзебездән башка кеше белми диярлек. Соңгы дистә елларда андый әсәрләребез хәтта Россия мәйданына да чыга алмыйча, үз Казаныбыз даирәсендә генә мәгълүм булып кала бирә. Уйлавымча, драматургиябез дә киң мәйданга чыгарга хаклы. Ләкин иң уңышлы дип саналган драма әсәрләрен дә үзебездәге рус драма театрлары да ни сәбәпледер кабул итәргә ашыкмый. «Кече милләтләр» мәдәниятенә һәм әдәбиятына кимсетеп караулар хөкем сөргән рус патшалары хакимияте дәверенә кире борылыш ясыйбыз сыман...

Казакъ халкы әдәбиятының үсеш нигезләре нидә соң? Иң әүвәл, әлбәттә, халыкның милли традицияләре төп нигез, төп чыганак була. Гасырлар буе халык теленнән төшмичә, онытылмыйча сакланган күпсанлы борынгы дастан һәм кыйссалар, сөйләкләрдән көч-куәт алып күтәрелгән ул әдәбият. Аның тамыры хәзерге татар һәм казакъ халыкларының уртак нигезенә — кыпчак, болгар бабаларыбыз җирлегенә барып тоташа. «Идегәй», «Кобланды», «Кузы Көрпеш», «Кыз җибек» («Ефәктәй кыз») кебек башлыча ике халык телендә дә сакланып калган бу дастаннарның тарихи җирлеге бер, каһарманнар язмышы уртак булган. Казакълар бу дастан-кыйссаларны телдән телгә сөйли-сөйли язма әдәбият чорынача килеп җиткән. Алар башлыча иҗади күңелле, шигъри фикерле халык. Инде язма әдәбият дәвере әдипләрен хаклы рәвештә шул матур традицияләрне дәвам иттерүчеләр дияргә була.

Элгәрерәк елларда СССР дигән илнең байтак кына әдәбият галимнәре, шул исәптән кайбер үз галимнәребез дә «казакъта язма

әдәбият чоры бик соң башлана» дип билгеләп үтәргә яраталар иде. Үз арабыздан да: «Казакъта язма әдәбият Октябрь революциясеннән соң гына туган», — дип расларга тырышучылар, хәтта ки шулай дип язып чыгучылар да булгалады. Әлбәттә, язма әдәбият барлыкка килсен өчен аерым шартлар һәм ихтыяҗ булуы кирәк. Иң беренче шарт, билгеле, киң таралыш алган мәктәп-мәдрәсәләрнең даими эшләп торуы. Нигездә күчмә тормыш белән яшәгән казакъ илендә бу шарт тулаем үтәлмәгән диярлек. Даими эшләүче мәдрәсәләр Акмола, Кызылъяр, Семипалат кебек сирәк калаларда гына барлыкка килә. (Хәзер Астана исемен йөртүче шәһәр кайчандыр ак ташлы каберлек урынында барлыкка килгән. Шуңа күрә аның элекке исеме тамырында «мола» — «каберлек» сүзе ята. Ул шәһәрне «Акмулла» дип дин әһеле атамасына бәйләп язу дөрес түгел. Еш кына без шул хакта онытып җибәргәлибез.) Аларның да күпчелегендә югары — галия класслары булмый. Икенче шарт — китап басмаханәләре һәм вакытлы матбугатның булуы зарурлыгы. Чыннан да, казакълар яшәгән төбәкләрдә китап басу эше бик соң — егерменче йөзнең егерменче елларында гына, Казакъ Совет автономиясе оештырылгач кына барлыкка килә башлый. Патша хөкүмәтенең һәртөрле эзәрлекләүләре нәтиҗәсендә андый остаханәләр күпчелек төрки халыкларда шактый соң туалар. Әйтик, төрки халыклар арасында унтугызынчы йөз урталарына китап басу эше фәкать Казан белән Бакуда гына беркадәр җайга салынган була. Шул ук вакытта газета-журналлар нәшер итү эшенә исә казанлылар иң соңлап керешәләр. 1905 елгы халык кузгалышына кадәр татарларга вакытлы матбугат тудыру рөхсәт ителми. Бу җәһәттән казакъ кардәшләр Идел-Урал буе төркиләреннән генә түгел, хәтта ки ул чорда бу өлкәдә иң алга киткән азәрбайҗаннардан да өлгеррәк булып чыгалар. Тарихи казакъ җирләре тәмамән яуланып бетмәстән элгәре үк, 1870 елдан казакъ һәм үзбәк телләрендә атнага бер мәртәбә «Төркестан вилаяте гәҗите» басыла башлый. Дөрес, аны оештыручы һәм беренче мөхәррире безнең якташыбыз, Оренбург төбәгеннән чыккан морза Шаһимәрдән Ибраһимов була. Бу газета егерменче гасыр башындагы түнтәрешләргә кадәр яши. (Совет хакимияте чорында казакъларны ике-өч йөз еллар элек үк инде Россиягә үз теләкләре белән кушылганнар дип санарга күнеккән, ике йөз илле еллык бәйрәм датасын да күптән билгеләп үткән идек. Бу дата Кече Җүз ханы Әбелхәернең, безнең Тәфкилев морза киңәшен тотып, 1731 елда төзегән солых килешүенә нигезләнеп үткәрелә килде. Гәрчә ул килешү Урта һәм Олы Җүз ханлыклары белән төзелмәгән булса да. Урта Җүзнең Арал диңгезе тирәләрендәге җирләре исә Россия тарафыннан фәкать 1880 елларда гына яулап алына. Уралдан алып Каспий диңгезенәчә булган мәйданны биләгән Бүкәй ханлыгы 1876 елда бетерелә.)

Казакъ телендәге икенче газета 1888 елдан Акмола шәһәрендә чыга башлый. Дөрес, газеталарның икесе дә үз төбәкләрендә нәшер ителгән русча газеталарның атналык кушымталары гына булганнар. Ләкин аңа карап кына аларның әһәмияте югалмый: беренче саннарыннан башлап аларда казакъ халкының фольклор әсәрләре, элек сөйләм телендә генә яшәгән дастан үрнәкләре дә, шул дәвердә иҗат ителгән яңа әсәрләр дә урын алган. Мәсәлән, Акмола каласында чыккан «Дала вилаяте гәҗите»ндә Абай Конанбаев, аның замандашы Шөҗе һәм башка акыннарның шигырьләре даими рәвештә басылган. Оренбургтагы рус-казакъ мәктәбе укытучысы Ибраһим Алтынсаринның (әнисе безнең милләт кешесе) һәм яшьрәк буын хикәячеләренең хикәяләре дә башлап шул газета битләрендә урнаштырылалар. (Әдәбият гыйлемендә И.Алтынсаринның хикәяләре казакъ язма прозасының нигезе санала.) Ташкентта нәшер ителгән «Төркестан вилаяте гәҗите»ндә исә казакъ авторларыннан тыш үзбәк, каракалпак әдәбияты классиклары әсәрләренең унтугызынчы йөзнең җитмешенче елларында ук дөнья күргәнлеге мәгълүм. «Дала вилаяте гәҗите»ндә күренекле казакъ галиме һәм сәяхәтчесе Чокан Вәлихановның Урта Азия халыклары тарихы һәм көнкүрешенә багышланган хезмәтләре, анасы татар нәселеннән булган Г.Шоңаев дигән берәүнең татар әдәбиятына, татар халкы белән арадашлык мәсьәләләренә караган язмалары, Мөхәммәтзакир Ишмөхәммәтев дигән икенче берәүнең казакъ халкы фольклорыннан ике йөз иллеләп үрнәге нәшер ителгән. Шул ук газетада кемнәрнеңдер казакъчага якынайтып эшкәртүендә татар әдәбиятыннан да әсәрләр бастырыла.

Шушы мисаллардан күрәбез ки, язма казакъ әдәбиятына унтугызынчы йөзнең икенче яртыларында ук нигез салына. Шул ук еллардан казакъ телендә китаплар да басыла башлаган. Аларның беренчеләре Казан, С.-Петербург, Оренбург басмаханәләрендә дөнья күргәннәр. Китап тарихы белгечләре Казанда басылган казакъ телендәге беренче китап итеп «Кыйссаи хуҗа Гафан вә Сәдүваккас» әсәрен атыйлар. Ул 1870 еллар башында нәшер ителгән. Казакъның унтугызынчы йөздә иҗат иткән классик шагыйре һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе Абай Конанбаевның беренче шигырь җыентыгы 1909 елда С.-Петербургта Кырым татары Ильяс Бораганский басмаханәсендә басылып чыккан. Икенче китабы 1916 елда Оренбургта Рәмиевләрнең «Вакыт» басмаханәсендә «Абай тирмәсе» исеме белән нәшер ителә. Гарәп хәрефендә Абайның өченче китабы 1922 елда Казанда «Абай Кунанбай улының өлеңе» (шигырьләре) исеме белән басыла. Давыллы еллар каһарманы, казакъ халкының 1916 елгы баш күтәрүендә «яшь казакълар» хәрәкәте җитәкчеләреннән берсе һәм беренче Казакъ Совет автономиясе җитәкчесе булган шагыйрь һәм проза-

ик Сәдүваккас (Сәкен) Сәйфуллинның да тәүге шигырь җыентыгы 1914 елда Казанда басылып чыга. Егерменче гасыр башында Оренбург шәһәрендә Рәмиевләрнең «Вакыт» басмаханәсендә казакъ телендә басылып чыккан китаплар саны әлегә сигез санала. (Оренбург басмаханәләренең чын тарихы әле барланмаган диярлек, шунлыктан тулы мәгълүмат юк.) Шул исәптән бу басмаханәдә 1911 елда казакъча беренче повесть — М.Нурбаевның «Көргенде бала» («Тәрбияле бала») китабы дөнья күрә. Икенче бер басмаханәдә Әсфәндияр Кубеевның «Калым» китабы — казакъ телендәге тәүге романнарның берсе — 1913 елда басылып чыга. Казакъча беренче зур күләмле әсәр — Мирҗакыйп Дулатовның «Бәхетсез Җамал» романы да 1910 елда Казанда Кәримовлар басмаханәсендә дөнья күргән. Аңа чаклы, 1909 елда, Казанда бу авторның казакъ дөньясын дер селкеткән шигырь җыентыгы — «Уян, казакъ!» китабы басылып тарала. (Искә төшерик, татар телендәге беренче романнар унтугызынчы гасыр ахырларында нәшер ителгән. Галимҗан Ибраһимовның «саф татарча» язылган «Яшь йөрәкләр» романы, Орск шәһәрендәге «Шәрекъ китапханәсе» наширлеге ярдәмендә, 1912 елда укучы кулына килеп керә.)

Шул ук елларда татар телендә казакъ дөньясын һәм әдәбиятын тәфсилле өйрәнүгә багышланган байтак кына әһәмиятле хезмәтләр дә пәйда булган. Шулардан Казанда һәм Оренбургта дөнья күргән, әмма безнең көннәрдә бөтенләй диярлек телгә алынмый торган берничә тарихи әһәмиятле хезмәтләрне генә санап китик: «Казакъ әхвәленнән» (авторы ачыкланмаган, 1907), Ниязмөхәммәт Сөләймановның «Кызылъярдан Петербургка сәяхәт» китаплары, Нәүширван Яушевның «Шура» журналында басылган «Төркестан Чини» («Кытай Төркестаны»), Корбангали Халидинең «Тәварихе хәмсәи шәркыя» («Шәрекъның бишлек тарихы») һ.б.

Ике халык өчен дә файдалы булган әдәби-мәдәни арадашлык, үзара якыннан багланышлар, минемчә, 1930 еллардан соң кабат яңартыла. Алтмышынчы еллар башында ике тугандаш халык арасында киң рәвешле, колачлы әдәбият-сәнгать атналары уздырылу да үз нәтиҗәсен бирми калмагандыр. Бөек Ватан сугышына чаклы татарчадан казакъчага һәм казакъчадан татарчага тәрҗемә ителгән китаплар саны бер дистәгә дә тулмаган булса, сугыштан соң ул эш даими төс ала. Сугышка кадәр казакъчага тәрҗемә ителгән төп әсәр Галимҗан Ибраһимовның «Казакъ кызы» романы булса, казакъ әдәбиятыннан Казанда нәшер ителгән күләмле әсәр исәбенә Сәкен Сәйфуллинның «Тар жол, тайгак кичү» романын күрсәтергә ярыйдыр. Йөзьяшәр Җамбулның шигырь җыентыгы бездә 1939 елда нәшер ителә.

Бөек Ватан сугышыннан соң ике әдәбият арасындагы арадашлык, хезмәттәшлек тагын да җанланыбрак китә. Бигрәк тә Казакъ-

станда татар китабы күпләп тәрҗемә ителә башлый. Габдулла Тукай әсәрләрен даими рәвештә нәшер итү тәртибе урнаштырыла. Совет чоры әдипләренең аерым китаплары да басыла башлый. Казакъ әдәбияты үрнәкләрен татар теленә тәрҗемә итү эшенә дә әһәмият бирелә. Татар укучысы 1947 елда казакъ язма әдәбиятына нигез салучыларның берсе саналган шагыйрь Абай Конанбаевның «Шигырьләр һәм поэмалар» исеме белән чыккан сайланма әсәрләре белән таныша ала. Ул китапны туплап һәм тәрҗемә итеп чыгаручы шагыйрь Мәхмүд Максуд була. Абай әсәрләренең тагын да тулырак басмасы бездә 1981 елда дөнья күрде («Шигырьләр һәм поэмалар. Хикмәтле сүз»). Ул китапның төзүчесе һәм «Хикмәтле сүз» бүлеген тәрҗемә итүче мин идем. Шигырь һәм поэмалар тәрҗемәсенең күпчелеген казакъ телен камил белгән шагыйрьләр Нури Арслан, Әхмәт Исхак һәм Мәхмүт Хөсәен башкарып чыктылар. Марс Шабаев белән Әхмәт Рәшитов тәрҗемәләре дә бик уңышлы булды. Аңа чаклы, 1950 елларда, Абайның үзенә багышланган ике калын китап дөнья күрде. Иҗаты бөтендөнья күләмендә югары бәяләнгән Мохтар Әүэзовның киң танылган «Абай» һәм «Абай юлы» романнары язучы Сәрвәр Әдһәмова тарафыннан татарчага тәрҗемә ителде һәм ике китап булып басылып чыкты. Соңрак казакъ әдипләренең хикәя һәм повестьларын берләштергән күләмле «Дала җыры» (1964), «Ак дөя» (1979), «Дала гөлләре» (1991) һәм «Казакъстан шагыйрьләре» (1968) җыентыклары нәшер ителделәр.

Казакъ прозасы үрнәкләрен татарча сөйләмгә күчерү өлкәсендә үземнең тәҗрибәгә дә тукталып үтим. Мохтар Әүэзовның «Өйләнү» хикәясе, Абай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Сырбай Мәүләневнең «Җырлы Казан» очеркы үз вакытында «Казан утлары» журналында басылып чыктылар. Шундый ук югары дәүләт бүләгенә лаек булган күренекле прозаиклардан Әнүәр Әлимҗановның ике үзенчәлекле повестен берләштергән «Отрар хатирәсе» (1974), Саин Моратбәковның ике повесть һәм хикәяләрдән торган «Әрем исе» (1986) китаплары, Мохтар Мәгауин белән Уралхан Букиевның да кызыклы повестьлары кергән «Җәйләүдә» җыентыгы (1993) минем хезмәт җимешләре. Кайбер авторларның аерым әсәрләре минем тәрҗемәдә башка вакытлы матбугат битләрендә дә дөнья күрделәр.

Минем исәп буенча, 1950–1990 еллар арасында татар телендә утызга якын казакъчадан тәрҗемә китабы басылып чыкты. Шушы ук дәвердә казакъ телендә нәшер ителгән үз китапларыбызның исемлеге исә бермә-бер ишлерәк. Союздаш республика дәрәҗәсенә кергән, ярым мөстәкыйль булган казакъ илендә һәр елны кимендә бер-ике татар китабы чыга килде дисәк тә хата булмастыр. Бу елларда Г.Тукай белән М.Җәлилнең сайланма әсәрләре берничәшәр мәртәбә казакъ укучысына җиткерелде. Г.Ибраһимовның «Безнең

көннәр», «Казакъ кызы», Г.Бәшировның «Намус», К.Нәҗминең «Язгы җилләр», Ф.Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы», Ә.Фәйзинең «Тукай» романнары, Ш.Усмановның «Тургай далаларында» дилогиясе, И.Нуруллинның «Тукай» китабы, И.Салаховның «Күкчәтау даласында» җыентыгы, «Татар повестьлары» тупламасы, Г.Ахунов, Р.Хафизова, М.Насыйбуллин һ.б.ның повесть, хикәя тупламалары, Н.Арслан, М.Ногман, З.Нури, М.Хөсәен, С.Шакир һ.б. ларның шигырь җыентыклары казакъ телендә зур-зур тиражлар белән басылып чыктылар. Байтак кына шагыйрь һәм прозаикларыбызның аерым әсәрләре Казакъстанда нәшер ителгән гомуми җыентыкларда, әдәби журнал битләрендә урын алдылар. Уртак бер кино эшләү турында да сүз барды. Казакъ киностудиясе җитәкчеләреннән берсе булган язучы Абиш Кекильбаев, мәсәлән, җитмешенче елларда ук нефтьчеләр тормышын чагылдырган уртак кинофильм эшләргә мөмкин булуы турында сүз кузгаткан иде. «Әйдәгез, бергәләп сценарий языйк», — дип тәкъдим итте. (Ул елларда Казакъстанның Өстерт, Магышлак тирәләрендә Татарстан нефтьчеләре зур эшләр башкардылар. Якташыбыз Дамир Нуретдиновның исеме ил күләмендә танылган, рәсемнәре үзәк матбугат битләреннән төшмәгән чак иде.)

1970–1980 елларда Казакъстанның дәүләт театрлары Ш.Хөсәеневнең «Әни килде», Т.Миңнуллинның «Диләфрүзгә дүрт кияү» пьесаларын сәхнәләштерде. М.Фәйзинең «Галиябану» пьесасының элегрәк елларда казакъ телендә кат-кат уйналганлыгы турында да хәбәрләр бар. Бу җәһәттән безнең театрлар бераз калышты сыман. Миңа, мәсәлән, казакъ халкының үткәндәге тормышын чагылдырган бер әсәрнең Казанда уйналганлыгы гына мәгълүм. Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры күренекле прозаик һәм драматург Габит Мөсреповның «Кузы-Көрпеш һәм Баянсылу» драмасын 1957 елда сәхнәләштергән була. Әсәр татар тамашачысы тарафыннан бик яратып кабул ителә. Соңрак исә кыргыз әдәбияты вәкилләре әсәрләре бездә өстенгә чыкты. Чыңгыз Айтматов белән Мар Байҗиев драмалары безнең театрлар тарафыннан кат-кат сәхнәләштерелде.

Кызганыч ки, 1990 еллардан башлап мондый арадашлыкларга нишләптер чик куелды. СССР таркалганнан соңгы дәвердә үзара әдәби-мәдәни мөнәсәбәтләр җайга салынмаган килеш кала. Элек без бер-беребез белән теләктәш тә, терәктәш тә идек. Хәзер дә андый теләктәшлеккә зур киртәләр юк шикелле. Тулы мөстәкыйльлек алган Казакъ җөмһүрияте башлыгы Нурсолтан Назарбаев, 2004 елда Казанда булганда, «ике кардәш халыкның дуслыгы ныгырга тиеш» дигәнрәк сүзләр дә әйткән иде шикелле. Әмма әлегә ике яктан да аңа омтылыш сизелми. Шулай да күңелләрдә өмет сүнмәгән әле...

*«Мәдәни җомга», 2007, 10 август*

# КҮРЕНЕКЛЕ ЯКТАШЛАРЫБЫЗНЫҢ БЕРСЕ

Язучы, мәгълүм җәмәгать эшлеклесе Габдулла Гиматдин улы Уразаевның гомере туган-үскән җиреннән читтә — Үзбәкстан илендә уза. Тумышы белән ул элекке Самара губернасы Мәләкәс өязе Урта Кандалый авылыннан. Ягъни хәзерге Ульяновск өлкәсе Иске Майна районы Абдул авылы кешесе. Рәсми туган елы — 1904. Туган авылы хәзерге Татарстан чигеннән егермеләп чакрымга көньяктарак урнашкан. Ләкин Габдулла ул авылда озак яшәми — гаиләсе тиздән Мәләкәс шәһәренә күчеп китә. «Атам анда извозчик хезмәтен үтәгән», — дип сөйләгәне хәтеремдә. Мәләкәстә ул Гатаулла ахун хәзрәтләре тоткан «Исламия» мәдрәсәсендә җиде ел белем ала. «Исламия»дә булачак күренекле артист Әсгать Мәҗит белән бергә укыйлар. Соңрак та язмыш аларны бер тирәдәрәк йөртә. Дөрес, буй җиткәч, чит-ят җирләрдә йөргәндә рәсмиләштергән таныклыгына караганда, Габдулла Әсгатьтән дүрт яшькә кечерәк. Дөреслектә яшь аралары алай ук зур булмагандыр, мөгаен.

Язучы Тәүфикъ Әйдигә сөйләгән бер хатирәсендә Габдулла ага атасының өйгә «Вакыт» газетасын, «Шура» журналын алдыруын, аның шуларны һәм башка татар вакытлы матбугатын укып үскәнлеген әйтә. «Исламия»нең өлкән сыйныфларында укыганда, шәһәрдә чыга башлаган «Мәләкәс тавышы» белән элемтәгә керә, беркадәр вакыт ул газета типографиясендә хәреф җыю эшендә дә катнаша. «Ундүрт яшемнән хәреф җыю һөнәрен үзләштердем», — дип искә алган иде. Бу һөнәр аның киләчәк көннәрендә дә кирәк булачак әле.

1917 елгы вакыйгалардан соң, Сембер шәһәрендә Совет хакимияте укытучылар әзерләүче курслар ача. Әсгать Мәҗит дусты белән алар шунда барып керәләр. Анда алар Кави Нәҗми, булачак артист Сәет Булатов белән бергә укыйлар. Барый Тарханов оештырган «Кызыл йолдыз» драма түгәрәгенә бик теләп йөриләр. Драматург, «Көн» исемле газета мөхәррире Фәтхи Бурнаш, яшь татар комиссары Бәкер Белоусов белән якыннан аралашалар. 1919 елда Габдулланы кызылларның Бишенче армиясе нәшер иткән «Кызыл яу» газетасына хәреф җыючы итеп алалар. «Сугышып йөрергә буең кечкенә, дип, комиссар Гыйлемдар Баембәтев мине ул эшкә үзе билгеләде. Берүк вакытта армия карамагындагы татар театр труппасында суфлер булдым. Бөгелмә, Бәләбәй, Чишмә, Уфа шәһәрләре безнең тарафтан яулап алынды. Яулап алынган һәр авыл, һәр шәһәрдә спектакльләр куя идек. Ул труппада Камал I, Шакир Шамильский, Гыйлаҗ Казанский, җырчы артистлар Фәттах Латыйф, Әмин Зөбәеревләр уйнады», — дип сөйләгән иде Габдулла абый бер очрашу вакытында. Шул елларда Габдулла-

ның беренче каләм хезмәте — «Мәхәббәт чәчәкләре» пьесасы күңелендә бөреләнә.

Уфада авырып китеп, кабат үз шәһәренә кайткач, Г.Уразаевны 1920 елның августында Мәләкәс өяз комсомол комитеты җитәкчелегенә сайлыйлар. Аңа «милли азчылык» вәкилләре белән эшләү бурычы йөкләнә. Ул «Яшьләр бәйнәлмиләле» газетасын чыгаруда катнаша. Самара губернасы татар-башкортлары арасында эш йөртүче комиссар Халик Садрый аның белән бергә милли басмаханә һәм нәшрият эшен җанландырырга өмет иткән була. Ләкин...

Ләкин Идел буенда моңарчы күрелмәгән ачлык афәте башланган көннәрдә, 1921 елның җәендә, Үзәк комсомол комитеты Габдулланы Төркестан Совет Автономияле Республикасына эшкә җибәрә — Хаҗәнт каласындагы ЧКга бүлек башлыгы урынбасары итеп билгели. 1924 елда, Сәмәркандтагы партия мәктәбендә укып чыккач, аны партия эшенә билгелиләр.

Күңеле белән ул туган якларына тартыла. Сәмәркандтагы партия мәктәбенең укыту бүлеге мөдире шагыйрә Заһидә Бурнашева да аңа Казанга кайтырга киңәш иткән була. 1925 елның җәй ахырларында ул, яшь комиссарларга хас булганча, күн киемнәрдән Казанга килеп төшә. Университет карамагындагы рабфакка укырга керә. Элекке танышларыннан Кави Нәҗми, Әсгать Мәҗитне эзләп таба, Галимҗан Ибраһимов, Шамил Усманов, «самаралы» Гадел Кутуй һ.б. белән аралаша башлый. Үзе дә кабат кулына каләм ала. Нәсер, шигырь, мәкаләләрен мондагы матбугат бик теләп бастыра. Әсгать Мәҗит, Риза Ишморат һ.б. белән театр уеннары уйнауда катнаша. Өч пьесага «җан өрә». «Ике көрәш» белән «Еллар карынында» пьесалары укучы яшьләр кичәләрендә уйнала, «Серле шалаш» дип исемләнгәне 1927 елда Мәскәүдә «Центриздат» нәшриятында аерым китап буларак басылып чыга. Габдулла аганың узган гасырның егерменче еллары ахырында татар матбугатында дөнья күргән каләм хезмәтләрен барларга теләүче булса, аларны «Вил Уразай» яки «Абдулла Вилдан» тәхәллүсе белән эзләсен. Ул елларда һәм соңрак та Габдулла ага язмалары шул исемнәр белән басылганнар. Казанда яшәү дәверендә ул Г.Кутуйның «Сулф» әдәби төркеменә якынрак тора. «Губернадашлар» — якташлар бит. (Риза Ишморатның «Дусларым, остазларым» китабында якташыбыз да телгә алына.)

* * *

Үзбәкстан ССРның атказанган мәдәният хезмәткәре, шундагы иҗтимагый-әдәби эшчәнлек өлкәсендә танылган хезмәт ветераны Габдулла ага Уразаев белән мин 1976 елның октябрендә

Ташкент шәһәрендә танышкан идем. Аның белән мине Ташкенттагы хезмәттәшем, СССР Әдәби фондының Үзбәкстан бүлеге директоры Шамил ага Аләдин таныштырды. Элегрәк елларда бу Кырым татары белән инде без Мәскәүдә күрешкәләгән идек. Ул миңа Үзбәкстанда яшәүче язучы милләттәшләребездән Әсгать Мохтар, Габдулла Уразаев, Зиннәт Фәтхуллин, Җәүдәт Ильясовлар турында бераз мәгълүмат биргән иде. «Казан татарлары үзбәк әдәбиятының да алгы сафында атлыйлар, бил бирмиләр», — дип, аларның һәрберсенең иҗатын да беркадәр барлап чыкты. Шуннан соң мин Әсгать Мохтарның ул чорда бик макталган романын — «Чинар»ны тәрҗемә иттем. (Ә.Мохтарның ата-анасы Башкорстанның хәзерге Благовар районыннан чыккан кешеләр. Әмирхан Еники белән алар күрше авыллардан иделәр.) Соңрак, Габдулла ага белән очрашканнан соң, мин анда тагын берничә якташ язучыны «таптым»: Равил Мирхәйдәрев — Актүбә каласыннан, Рәүф Галимов — Чиләбе өлкәсеннән, Мәрвә Җәләлетдинова үзебезнең Шөгер төбәгендәге Куакбаш авылыннан икән. Рус фамилиясе йөртеп тә, татарча иркен сөйләшүче язучылардан Чирмешән егете Сергей Волгинның, Иске Майна районының Кече Кандалый авылыннан чыккан Константин Волковның Ташкент каласында яшәгәнлекләре дә мәгълүм булды.

Габдулла ага беренче очрашудан ук мине үз итте, кайбер серләрен дә ачып салды шикелле. Мәләкәс төбәгендәге авылдан чыкканлыгымны белгәч: «Без икеләтә якташлар — өлкәдәшләр дә икәнбез бит», — дип, үзенең дә Ульяновск өлкәсе Иске Майна районыннан булганлыгын хәбәр итте ул. Югыйсә Үзбәкстан Язучылар берлеге белешмәлегендә аны Татарстаннан дип язганнар иде. Мәләкәс шәһәрен искә төшерү икебез өчен дә кадерле булды.

«Рабфактан соң нишләп Казанда гына калмадыгыз соң?» — дип соравыма, ул болай дип җавап бирде: «Партия солдаты бит без. Урта Азиядә ул вакытта русча белемле кадрлар җитешми иде. Мине яңадан шунда җибәрделәр. Элек анда эшләвемне истә тотканнардыр. Зәрафшан өлкәсе партия комитетының матбугат бүлеге мөдире итеп билгеләделәр үземне. Шул чакта, 1929 елда матбугатка кагылышлы ике китапчык бастырдым, «Мөхбирләр юлдашы» журналын нигезләдем...»

Хәер, заманы өчен бик тә дәрәҗәле эшкә юллаганнар шул. Андый тәкъдимне теләсә кем биш куллап кабул иткән булыр иде. Институтка кереп уку теләген дә бөтенләй үк онытмый Габдулла. Рабфак биргән таныклыктан файдалану чиге якынлашкан бер дәвердә, ул Ташкент педагогия институтына укырга керә һәм аны уңышлы тәмамлый. Төп эшеннән, партия кушкан вазифаларны башкарудан аерылмаган рәвештә. Бу вакытта аны Ташкентка,

партия Үзәк Комитетында эшләргә дип чакырып алалар. Аңа В.И.Ленин хезмәтләрен үзбәк теленә тәрҗемә итү бурычы йөкләнә. Шул эшләрне башкару өчен Үзәк Комитетта партия тарихын барлаучы махсус бүлекчә оештырыла. Ул бүлекчә җитәкчеләренең берсе Г.Уразаев була. Бу эшне уңышлы башкарып чыккач, утызынчы еллар ахырында Г.Уразаевны «Совет Үзбәкстаны» газетасының баш мөхәррире итеп билгелиләр.

Ул арада Бөек Ватан сугышы да тәмамлана. Сугыш елларында таушалган, таркалган хуҗалык тармакларын аякка бастыру, яңарту чоры килеп җитә. Теләсә кайсы эшкә җиң сызганып тотына белгән, уңышлы башкарып чыга алган үҗәт мишәрне яңа көрәш мәйданына «ташлыйлар» — 1945 елда аны Үзбәкстан ССР Министрлар Советы карамагындагы радиокомитетка рәис итеп куялар. Габдулла Уразаев бу вазифаны үтәргә керешкәндә, радиодан үзбәк телендә көнгә фәкать дүрт сәгатьлек тапшыру оештырыла. Бинасы иске, кысан, җиһазлар таушалган. Габдуллага берничә студия эшли алырлык иркен бина булдыру, яңа җиһаз-аппаратуралар кайтарып урнаштыру эшләрен сугыштан соңгы авыр шартларда үтәргә туры килә. Илленче еллар башына ул эшләрне үҗәтлек белән җиренә җиткереп төгәлли Г.Уразаев. Дүрт студия берьюлы эшли алырлык зур бина булдыра, яңа аппаратуралар кайтарта. Үзбәк телендәге тапшырулар сәгатен уналтыга җиткерә. Республикада яшәүче уйгыр, таҗиклар өчен үз телләрендәге тапшыруларга да юл ачыла. Радиокомитет карамагында милли оркестр оештырыла. Әйтергә кирәк, нәкъ шул елларда Үзбәкстан радиосында татар телендәге тапшыруларга да бер сәгать вакыт бирелә һәм ул тәртип туксанынчы еллар башына кадәр саклана.

Алга куелган бурычларны башкарганнан соң, ул биләгән кәнәфигә төп милләт вәкилен утырталар да, Уразаевны яңа башлангычны үтәргә дип, яңа урынга күчерәләр. Берничә ел гомерен ул дәреслекләр чыгаручы «Укытучы» нәшрияты эшчәнлеген җайга салуга багышлый. Анда баш мөхәррир һәм директор була. Шуннан соң аны әдәбият һәм сәнгать әсәрләрен нәшер итүче зуррак нәшриятның директоры итеп куялар. Шул вазифаны башкарганда ул Үзбәкстан Язучылар берлеге идарәсенең секретаре итеп тә сайлана.

Якташымның соңгы эш урыны — СССР Әдәби фондының Үзбәкстан бүлеге директоры кәнәфие. Алтмышынчы еллар уртасында лаеклы ялга киткәндә ул үз вазифасын каләмдәше һәм милләттәше Шамил Аләдинга тапшыра.

Г.Уразаев утызынчы еллар урталарында ук СССР Язучылар берлеге сафына кабул ителгән. Аның төп иҗат юнәлеше Үзбәкстанда үзбәк телендә татар әдәбиятын тарату, пропагандалау була. Ташкент шәһәрендә яши башлаган беренче көннәреннән үк ул

Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Һади Такташ, Шамил Усманов һ.б. иҗатына багышланган күпсанлы очерк, мәкаләләр язып бастыра. Г.Ибраһимовның «Тирән тамырлар», «Казакъ кызы» романнарын (икешәр басма), Ш.Усмановның «Памирдан радио» дип аталган фантастик әсәрен үзбәкчәгә тәрҗемә итә. Соңрак дәвердә аның каләме аша үзбәк укучысы кулына Әхмәт Фәйзинең «Тукай», Кави Нәҗминең «Язгы җилләр» романнары, Фатих Хөснинең «Йөзек кашы» повесте һ.б. әсәрләр барып ирешә. Габдулла Тукайның 1976 елга кадәр үзбәк телендә дөнья күргән барлык «Сайланма әсәрләр»ен туплашуда Г.Уразаев катнаша, күпчелек очракта кереш сүз авторы да ул була.

1979 елда үзбәк телендә хәзерге заман татар хикәяләрен туплап бастыру турында карар кабул ителде. Ташкентта булганда мин шул хакта Габдулла агага хәбәр иттем. «Ул китапны эшләп чыгарырга алынмыйсызмы?» — дип сорадым. «Кулымда эшем бар әле, Әмирхан Еники әсәрләрен тәрҗемә итәргә ниятләдем», — дип җавап бирде ул. Җитмеш биш яше тулган кеше бит, аны кабат аптыратып тормадык. «Дуслык китапханәсе» сериясендә 1981 елда басылган «Еллар вә юллар» хикәяләр җыентыгы тәрҗемәсен үзбәк язучысы Хәйрулла Эргашев башкарып чыкты.

Кадерле якташым Габдулла ага белән без соңгы тапкыр 1981 елның июнь ае ахырларында Кырымда, язучыларның Кара диңгез буендагы «Күктүбә» иҗат йортында очраштык. Үзе кебек кечерәк буйлы, бик ачык йөзле, мөлаем кыяфәтле карчыгы белән икәү ял иткәннәр, инде китәрләренә ике көн генә калган иде.

— Ял гына иттегезме, әллә бераз эшләдегез дәме? — дидем.

Иң әүвәл бу соравыма җәмәгате Зәйнәп апа җавап бирде:

— Тик утырырга бер дә күнекмәгән инде ул. Эшсез бер дә тора алмый, — диде.

Сөйләмендә үзбәк аһәңе белән янәшә мишәр чалымнары да сиземләнгән кебек иде. Ләкин, сүзгә мавыгып, аның туып үскән төбәген сорарга онытканмын.

Габдулла абый исә бераздан өстәп куйды:

— «Казан утлары» журналында Гариф Ахунов әсәрләре еш басыла. Рабфак буенча шәриктәшем Гариф Миңнуллин да бер килгәндә аның иҗатын мактап телгә алган иде. Шуның бер повестена тотынып торам әле. Ни булып бетәр, — диде.

Г.Ахуновның «Чикләвек төше» повесте китабы аның тәрҗемәсендә Ташкентта 1985 елда басылып чыкты.

Шул очрашудан соң миңа Ташкентка барырга туры килмәде. (Ташкент аша Нукуска һәм Бишкәккә очу очракларын искә алмаганда.) Берникадәр вакыт үткәч, сиксәненче еллар урталарында Мәскәүдә очрашканда, шагыйрь, Үзбәкстан Язучылар берлеге идарәсе секретаре Нармодад Нарзуллаев күңелсез хәбәр җиткер-

де: «Обдулло әкә койтыш булды», — диде. Соңгы күрешкән вакытта Габдулла әкә безгә: «Туган якта күптән була алганым юк. Авылымны, Мәләкәсемне бик сагындым», — дип әйткән иде. Гомере читтә узган кешенең кабере дә читтә калучан шул. Туган төбәген ул кайтып күрә алмады шикелле. Кайткан булса, якташлары хәтерләр иде. Ульяновскида уңышлы гына нәшер ителеп килүче «Өмет» газетасы мөхәррире, якташы Исхак Хәлимов андый очракны хәтерләми.

Хәзер Ташкентта нәселеннән кем дә булса исән-саудырмы, әйтә алмыйм. 1981 елда «Күктүбә»дә аның улы да ял итте. Миннән өлкәнрәк ир уртасы кеше иде. Үзбәкчәдән русчага проза әсәрләре тәрҗемә итәм, дип сөйләде. Үз телебездә аралаштык. Ә исеме онытылган...

* * *

2007 елның 14 ноябрендә Иске Кызылсу авылында шагыйрь Сәхаб Урайский истәлегенә багышланган очрашулардан соң туды бу истәлек язмасы. Иске Кызылсу белән Абдул (Урта Кандалый) исә — күрше авыллар. Кызылсу мәктәбендә С.Урайскийга багышлап истәлек тактасы куелды. Ул тантанага, шагыйрь истәлеген олылап, Ульяновск өлкәсе хакимияте җитәкчеләре дә килгән иде. Шул ук авылда туган, Мәләкәснең «Исламия»сендә Г.Уразаев белән бер чордарак укыган күренекле галим, татар теле һәм әдәбияты белгече Латыйф Җәләлетдин улы Җәләлетдиневне дә ул очрашуларда искә алгаладылар. Шушы Иске Майна районына кергән авылдан чыккан классик шагыйребез Габделҗаббар Кандалый исеме дә монда еш яңгырады. Якташлары аның олуг юбилеен — тууына ике йөз дә ун ел тулу вакыйгасын Мәләкәс (хәзерге Димитровград) шәһәрендә зурлап билгеләп үтәчәкләрен белдерделәр. Иске Кызылсуның рәсми русча атамасы «Татарское Урайкино» дип йөртелә. Бөек шагыйребезнең бу авылны искә алып язган дүртьюллыгы да бар икән:

Ишан сагышын сагышлап,
Ишан рухына багышлап,
Ашап-эчеп, күңел хушлап
Гуляйт иттем Урайкинда!

Татарстаннан читтәге бер төбәктә уздырылган бу әдәби кичәдән соң туган уйларым, чит-ят җирләрдә гомер кичергән якташымны искә алулар, бәлки, кемнәргәдер кызыклы тоелыр. Безнең милләттән Габдулла Уразаев кебек кешеләр дә чыккан икән дигән горурлык хисен уятыр.

*«Мәдәни җомга», 2008, 25 июль*

# ӘДӘБИ ТӘРҖЕМӘ ДӘ БИК КИРӘК ЭШ

Һәрдаим күңелгә тынгылык бирмичә, җанны борчып торган мәсьәләләр була. Татар әдәбиятының башка телләргә тәрҗемә ителешенә караган уйлар да нәкъ шулай, әледән-әле күңелдә борчу тудыра. Әдәби мирасыбыз зур. Еш кына без «мең еллык язма әдәбиятыбыз бар» дип мактанып та куйгалыйбыз. Әмма ләкин ул байлыкны башкаларга таныту юнәлешендә генә бик әкрен кыймылдыйбыз шикелле. Тугандаш яки замандаш булган башка халыкларга да ул язма мирасыбызны җиткерәсе, ирешелгән уңышлар белән аларны да таныштырасы иде дә бит. Җитешә алмыйбыз, көндәлек ыгы-зыгы белән өстебездә шундый бурычлар торуын онытабыз.

Безгә якын дәвердә яшәп иҗат иткән классик әдип вә шагыйрьләребезнең мирасын һәм исемнәрен дөнья мәйданына чыгару эшебез әлегә ярыйсы ук сүлпән бара. Бүгенге көнгә хәтле бөек Тукаебызның күп кенә шигырь һәм поэмалары тиешле дәрәҗәдә рус теленә дә тәрҗемә ителмәгәннәр. Дөньяның киң таралышлы башка телләре турында инде әйтеп торасы да түгел. (Дөрес, соңгы елларда берничә китапның, шул исәптән Г.Тукайның «Шүрәле» поэмасының инглиз телендә чыгуы турында матбугатта хәбәрләр булды*. Аларны бастыруга әзерлек эшен Татар ПЕН-үзәге үз өстенә алган икән. Уңышлы башлангыч була күрсен.)

Утыз биш еллар элек Дәрдемәнднең шигъри мирасын рус телле укучыга җиткерү талпынышы да булып алган иде. 1970 елда нәшер ителгән «Стихи» китабын дөньяга чыгаручылар күренекле шагыйрьләребез Сибгат Хәким белән Ренат Харис булды. Татар җәмәгатьчелеге ул җыентыкны нигездә хуплады. Әмма ләкин, аңа кергән шигырьләрне чыгаруда тәҗрибәле тәрҗемәчеләрнең аз катнашуы сәбәпле, анда уңышсыз тәрҗемә ителгән, шагыйрь фикерен укучысына тулаем ирештерә алмаган тәрҗемәләр дә җитәрлек урын биләгән. (Ул китапка кергән уңышлырак тәрҗемәләрне Р.Харис соңыннан «Агарган кыл» китабына туплап та бастырды. Ул китапны әзерләшүдә З. Бәширов белән минем дә бераз катнашым булды.)

Шәхси батырлыгы һәм иҗаты белән исеме бөтен дөньяга танылган Муса Җәлилебез бу җәһәттән беркадәр бәхетлерәк. Аның шигырь һәм поэмалары рус теленнән тыш башка бик күп телләргә тәрҗемә ителде. М.Җәлил иҗатына багышланган бер мәкаләдә

---

* 2006 елда Татарстан китап нәшриятында Г.Тукайның «Шүрәле» поэмасы унбиш телдә дөнья күрде. — *Мөх.*

хәбәр ителүенчә, аның әсәрләре бүгенге көндә илле дүрт телдә басылып чыккан. Тәрҗемәләренең кат-кат эшләнүе, андый җаваплы эшкә илебезнең иң тәҗрибәле тәрҗемәчеләренең җәлеп ителүе нәтиҗәсендә аларның сыйфаты да канәгатьләнерлек. Мәсәлән, шагыйрьнең байтак әсәрләрен украин теленә тәрҗемә итүче шагыйрь һәм академик Павло Тычинаның төрки телләрне яхшы белүе дә ярдәм иткән. Украинада нәшер ителгән бер җыентыкта ул хакта «Павло Тычина знав тюркски мови» дигән сүзләр китерелә.

Элегрәк елларда сыйфатлырак дип саналган әдәби әсәрләрне татарчага тәрҗемә итеп чыгару өлкәсендә дә шактый уңышка ирешкән идек. СССР күләмендә югары бәяләнгән, дәүләт бүләкләре алган әсәрләрне тәрҗемә итү бервакыт рәсми төс алган, сәясәткә әверелгән чаклар да булды. 1940–1950 елларда югары бәяләнгән андый әсәрләрне тәрҗемә итү мәҗбүри санала иде. Ул мәҗбүрилекнең безнең өчен уңай нәтиҗәләре дә булгалады. Нәкъ шул дәвердә 3 нче дәрәҗә Сталин премиясенә лаек дип табылган үз әсәрләребездән Гомәр Бәшировның «Намус»ы белән Кави Нәҗминең «Язгы җилләр»е күпчелек Союздаш республика халыклары телләрендә басылып чыктылар. Болгар, венгр, кытай, немец, поляк һ.б. телләрдә сөйләшүче әдәбият сөючеләр дә нәкъ шул елларда Совет чоры татар әдәбияты үрнәкләре белән танышa алдылар. Күпләребез хаклы рәвештә өнәп бетермәгән «Сталин дәвере» узганнан соң, безнең әдәбият вәкилләренә андый мөмкинлекләр кабат тудырылмады инде.

* * *

Бу өлкәдә ирешелгән белән канәгать булмау хисе, бәлки, миңа гына хастыр. Миңа гына шулай тоеладыр. Югыйсә байтак кеше тәрҗемә әдәбиятка әһәмият бирми диярлек. Бу халәт, бәлки, кайчандыр үземнең дә әдәби тәрҗемә белән шөгыльләнгән кеше булуымнан киләдер. Андый эшне оештыру өлкәсендә дә беркадәр тәҗрибәм бар иде шикелле. Ун ел чамасы Язучылар берлеге каршында эшләүче тәрҗемәчеләр секциясе җитәкчесе булдым. Дөрес, ул секция, нигездә, башка телләрдән татарчага тәрҗемә итүчеләрне берләштерде. Аз санлы «рус телле» тәрҗемәчеләр русча иҗат итүче язучылар секциясенә беркетелгән иде. Узган гасырның алтмыш-сиксәненче елларында рус, белорус, казакъ, украин, үзбәк, азәрбайҗан, грузин һәм кайбер чит ил телләрендә нәшер ителгән иң күренекле әсәрләрне үз телебездә бастырып чыгарырга тырыштык. Әлбәттә инде, ул еллардагы бердәнбер нәшриятыбыз мөмкинлек биргән кысаларда. Матур әдәбият сөючеләр кулына ул заманнарда елына кимендә җиде-сигез тәрҗемә әдәби китап барып ирешер иде.

Күпмилләтле үз илебездә һәм бөтендөнья күләмендә танылган авторлардан Михаил Шолохов, Мохтар Әүэзов, Константин Симонов, Чыңгыз Айтматов, Виктор Астафьев, Василь Быков, Юрий Бондарев, Әнүәр Әлимҗанов, Роман Солнцев, Валентин Распутин, Нодар Думбадзе, Әсгать Мохтар, Гафур Голәм һ.б. әсәрләре бу чорда татар укучысы тарафыннан хуплап кабул ителделәр. Классик әдипләрдән Лев Толстой, Алексей Толстой, Абай, Иван Тургенев, Федор Достоевский, Александр Куприн әсәрләренең яңа буын тәрҗемәчеләре тарафыннан эшләнгән үрнәкләре дә уңышлы булды. Әйе, бу дәвердә Чыңгыз Айтматовның барлык повесть һәм романнары да әнисенең туган теленә тәрҗемә ителде. Утызар мең данә тиражлы китаплары тиз арада таралып бетә иде. Хәер, ул елларда үз авторларыбызның әсәрләре дә, тәрҗемә китаплар да укучы кулына тиз барып ирешә, кибет киштәләрендә озаклап ятмыйлар иде. Чөнки ул елларда китап сәүдәсенә дә җитди әһәмият бирелде. Хәтеремдә әле, казакъ язучысы Сайын Моратбәковның «Әрем исе» китабы бездә 1986 елда нәшер ителде. (Сүз уңаеннан әйтеп үтим, аның әнисе дә татар милләтеннән. Бер очрашу вакытында ул: «Анам Сәхипҗамал да, киленем Надия дә сезнең нәселдән», — дип әйткән иде.) Бер елдан соң автор безнең якларга килеп чыга, ләкин тугыз мең данәдә басылган үз китабын таба алмыйча китеп бара.

Ул елларда бездә рус, азәрбайҗан, казакъ, төрекмән һ.б. халыклар әдипләренең күмәк хикәя яки повесть, шигырь җыентыклары да даими рәвештә туплап басыла килде. Мәсәлән, каракалпак халкы әдәбияты антологиясе «Арал дулкыннары», Идел буе республикалары язучыларының күмәк җыентыклары, казакъ авторлары повестьлары тупламалары «Ак дөя», «Җәйләүдә», «Дала гөлләре», союздаш һәм автономияле республикалар әдипләренең сайланма хикәяләр җыентыгы «Дуслык аланы» һ.б. бездә зур тиражлар белән нәшер ителделәр. Кардәш әдәбият вәкилләре дә бурычлы булып калмады. Казакъстанда «Дуслык көтепханәсе» сериясендә күләмле «Татар повестери» китабы, Үзбәкстанда «Йиллар ва йуллар», Каракалпакстанда «Татар гүрриңлери» исемендә хикәя җыентыклары, Украинада «Свети меня, Чулпан-заря» дип исемләнгән шигырь тупламасы һ.б.лар дөнья күрделәр. Азәрбайҗан белән Кыргызстанда да шундый ук күләмле җыентыклар басылып чыкты. Әлбәттә, ул республикаларда андый күмәк җыентыклардан тыш та татар әдипләре әсәрләре тәрҗемә ителә иде. Шул җәһәттән аеруча казакъ кардәшләрне аерым билгеләп үтү урынлы булыр. Сугыштан соңгы чорда Казакъстанда һәр елны диярлек икешәр-өчәр татар китабы дөнья күрде. Г.Тукай, М.Җәлил җыентыклары да даими рәвештә басыла торды. Үзбәк уртаклар да алардан калышмаска тырышты. Үзбәкстанда татар

әдәбияты таралышына зур әһәмият бирүчеләрдән милләттәшләребез Габдулла Уразаев белән Әсгать Мохтарны аерым искә алу кирәктер.

Ул заманда СССР һәм чит дөнья халыклары әдәбияты үрнәкләрен татар телендә чыгаруда актив эшләүче язучылардан дистәләгән роман вә повестьлар тәрҗемә иткән Рәис Даутов, Яхъя Халитов, Кыям Миңлебаев, Таһир Нурмөхәммәтов, Әнәс Хәсәнев, Шәһидә Максудова, Фәния Гайнанова, Наилә Вәлитова, Люция Нәҗмиеваны билгеләп үтәсе килә. Ул чорда шагыйрьләребезнең дә байтагы үз күңеленә хуш килгән үрнәк әсәрләрне ана телебезгә күчереп бастыруны мәртәбәгә санады. Тәрҗемәләре даими рәвештә татар вакытлы матбугатында дөнья күргән шагыйрьләрдән Нури Арслан, Зәки Нури, Рәдиф Гаташ, Гәрәй Рәхим, Әхмәт Рәшит, Шамил Маннап, Әхмәт Гадел, Госман Садә исемнәре һәрберебезгә мәгълүм. Ул чорда Абай (күмәк тәрҗемә), Гомәр Хәйям (Н.Арслан), Давыт Көгелтинев (Г.Рәхим), Американың унтугызынча йөз әдәбияты классигы Уолт Уитмен (М.Шабай) һ.б.ның шигырь җыентыклары, Евгений Евтушенконың «Казан университеты» поэмасы (М.Шабай) татар телендә басылып чыкты. Кардәш төрки телләрдән тәрҗемә итүче осталар рәтендә Сәрвәр Әдһәмова, Нури Арслан, Әхмәт Исхак, Мостафа Ногман, Мәхмүт Хөсәен һәм Тәүфикъ Әйди дә ул дәвердә бик актив эшләделәр. Мин дә шул өлкәдә көч сынап карадым. Казакъ, каракалпак, үзбәк телләреннән чәчмә әсәрләр тәрҗемә иттем. Тәкъдим булган очракларда рус телле авторлар әсәрләренә дә җитешкәләдем. Шул рәвешле, Юрий Бондарев (тумышы белән Орск шәһәреннән), Павел Бажов һ.б. хикәяләре, Василь Быковның СССР Дәүләт бүләгенә лаек дип табылган ике повестен берләштергән «Һәйкәл» китабы минем хикәяләүдә үз телебездә дөнья күрделәр.

Җитмешенче-туксанынчы еллар аралыгында Язучылар берлеге идарәсе тырышлыгы белән классик әдипләребезнең һәм әйдәп баручы шул чор авторларының байтак китабы рус теленә тәрҗемә ителде, басылып чыкты. Ул китапларның күпчелеге Мәскәүнең «Детгиз», «Советский писатель», «Современник» нәшриятларында, бик сирәкләре «Художественная литература», «Молодая гвардия» кебек үзенчәлеклерәк басма йортлары имзалары белән дөнья күрделәр. Ләкин шунысы аянычлы, ул вакытлардагы тәрҗемәләрнең байтагының сыйфаты зыялы укучыны канәгатьләндерерлек түгел. Ул тәрҗемә авторларының күпчелеге татар мохитен начар белә, кемнәр тарафыннандыр эшләнгән сүзгә-сүз тәрҗемәләр (подстрочниклар) ярдәмендә генә эш итә. Ә арзан хак түләүле ул подстрочникларны исә үз кешеләребез ашык-пошык әзерләп бирә иде. Квалификацияле подстрочник эшләүче бер-ике кеше (мәсәлән, Ил Саттаров) үзләренә охшаган авторлар белән

генә эш йөртәләр, барысына да өлгерә алмыйлар. Ә ниндидер бер студентның ашык-пошык әвәләгән подстрочнигына нигезләнеп тәрҗемә ителгән китапның нинди сыйфатлы буласын күз алдына китерү кыен түгел, әлбәттә.

Дөрес, соңга табарак татарчадан русчага тәрҗемә итүче үз кешеләребез дә пәйда булды. Алар, ике телне дә камил белеп, әсәрнең эчтәлегенә зыян китермичә эшли башладылар. Ләкин, санаулы санда булулары сәбәпле, алар исән, дәрәҗәлерәк язучылар белән генә хезмәттәшлек итүне хуп күрделәр. Мәсәлән, Гомәр Бәшировның Мәскәүдә нәшер ителгән күпчелек әсәрләре Разия апа Фәизова хикәяләве аша рус телле укучыга барып иреште. Әмирхан Еники, Фатих Хөсни дә тәрҗемәче сайлауга бик таләпчәннәр иде. Архивымда Фатих аганың тәрҗемәчесенә таләпләр куеп язган бер хат нөсхәсе саклана. Нурихан Фәттахның «Әтил суы ака торур» романын булачак Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Марсель Зарипов тәрҗемә итте. Марсельнең шуннан соң кемнең дә булса әсәрен тәрҗемә итүен хәтерләмим. Элегрәк, Әлмәттә бергә яшәгән дәвердә, бу өлкәдә Гариф Ахунов белән хезмәттәшлек иткәнлеге генә мәгълүм.

Классик әдипләрдән Фатих Әмирхан хикәяләрен Мәскәүдә яшәүче әдәбият галиме Галия Хантимерова, Шәриф Камалның «Таң атканда» романын нәшрият мөхәррире Азалия Бадюгина, Шәйхи Маннурның «Агым суларга карап» романын язучы Светлана Гыйльметдинова, яшьрәк буын авторларының берничәсенең әсәрләрен язучы Җәмил Мостафин бик уңышлы тәрҗемә итеп чыгардылар. Тиздән болар төркеменә Мәскәүдәге әдәбият институтында тәрҗемәче һөнәрен үзләштерүгә биш ел гомерләрен сарыф иткән ун яшь тәрҗемәче килеп кушылырга тиеш иде. Ул вакыттагы Язучылар берлеге идарәсе рәисе Зәки Нури тырышлыгы белән М.Горький исемен йөртүче әдәбият институтында 1972 елда татарчадан русчага тәрҗемә итүчеләр курсы оештырылды. Өметләр тулаем акланмаса да, Солтан Шәмси, Роза Баубекова-Кожевникова, Фирдәүс Әһлия кебек каләм әһелләре тәрбияләнеп чыкты ул төркемнән. Укуын тәмамлагач ук, С.Шәмси классик әдибебез Галимҗан Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр» повестен һәм хикәяләрен тәрҗемә итеп бастырды. Мирсәй Әмир белән Ләбибә Ихсанованың аерым хикәяләрен вакытлы матбугатка эшләп бирде. Роза Баубекова да татар поэзия үрнәкләрен тәрҗемә итеп бастыру өлкәсендә зур абруй казанды. Фирдәүснең тәрҗемә өлкәсендәге уңышлары бик алай зурдан булмаса да, ул үзенчәлекле прозаик буларак күз алдына килә. Вакытлы матбугатта аның театр әһелләренә багышланган кызыклы язмалары, очерклары бик еш күренә.

* * *

Туксанынчы елларда төрле-төрле нәшриятлар барлыкка килүенә карамастан, татар китабының язмышы, аңа булган мөнәсәбәт кискен үзгәрде. Ә тәрҗемә әдәбият чыгудан туктады дип әйтерлек. Чөнки китап сәүдәсенә бөтенләй дә әһәмият бирелми башлады. Татар әдәбиятын үз итүчеләр, яратып укучылар башлыча авылда яши. Авыл халкына хезмәт итүче төп сәүдә оешмасы элгәре елларда Татпотребсоюз җәмгыяте иде. Базар мөнәсәбәтләрен үзләштерәбез дигән сылтау белән иң әүвәл ул оешманың китап сәүдәсе бүлекчәсе бетерелде. Авылда түгел, хәтта ки район үзәкләрендә дә китап кибетләрен яптылар. Янәсе, китап сәүдәсе аз керемле. Ә аракы сәүдәсенең кереме хәтсез-чиксез әнә. Шул хәтсез күп керемгә алданып, хәзер авылның үзен дә бетереп барабыз шикелле. Дөрес, авыл үзе бар барын. Тик анда элекке авыл җәмгыяте, авылча яшәү тәртибе генә тәмам таркалу хәлендә. Рухи халәт бик зәгыйфь. Һәм әлегә ул көннән-көн зәгыйфьләнә генә бара. Шундый хәлгә төшүебез зур табыш китерүче аракы, сыра кибетләренең һәм ресторанбарларның күпләп ачылуына да бәйле, билгеле.

* * *

Хәзерге нәшриятларда тәрҗемә әдәбиятка әһәмият бирелми, дидек. Нәтиҗәдә төрле телләрдә иҗат итүче әдипләрнең бер-берсе белән аралашуына да чик куелды. Бу хәл бигрәк тә үз мәмләкәтләрен булдырган элекке кардәш әдәбият вәкилләре белән араны өзүгә китерде. Болай дәвам итсә, тиздән без бөтенләй дә изоляциядә калачакбыз. (Әдәбиятка, телгә булган мөнәсәбәтләр үзгәрмәсә, мөгаен, безне резервациядә үк калу көтәдер.)

Шушы ук дәвердә татар әдәбиятын башка халыклар укучысына җиткерү, башка телләргә тәрҗемә итү эше дә нык аксый башлады. Бу эшнең бөтенләй туктап торган еллары да күз алдында. Соңгы вакытта гына бераз кыймылдарга керештек шикелле. Рус теленә тәрҗемәләр әз-мәз күренгәли башлады. Кардәш милләтләрдән казакъ, кыргыз, үзбәк, төрекмән һ.б. лар бүген татар язучысының китабын кулга тотып караудан бөтенләй мәхрүм ителгән. Татарстанда яшәүче рус телле «кардәшләребезнең» хәле бераз җиңелрәк. Хәзер алар өчен Казанда елына ике-өч китап тәрҗемә ителә. «Идель», «Казань» кебек рус телле журналларда да аерым тәрҗемәләр күренгәли. Бу җәһәттән «Идель» журналының активрак булуын билгеләп үтәргә кирәктер. Ә Мәскәү нәшриятлары һәм журналлары әлегә безне танымый, тиң күрми. Чынбарлыкта без Россия Федерациясенә керүче төп халыкларның берсе саналабыз югыйсә. Сан ягыннан икенче урында торабыз бит.

Яңа гасырга кергәч, чәчмә әдәбиятны русча тәрҗемәдә бастырып чыгаруны әлегә ике дәүләт нәшрияты — «Мәгариф» белән Татарстан китап нәшрияты җайга салырга омтылалар сыман. Матур әдәбиятны рус теленә тәрҗемә итүчеләр сафына сәләтле яңа көчләрнең килә башлавы да сөендерә. Мәсәлән, «Идель» журналы битләрендә Фаяз Фәизев, Гадел Хәеров, Гәүһәр Мәһдиева-Хәсәневаларның тәрҗемә хезмәтләре ешрак күренә башлады. Гәүһәрнең «Идель»дән тыш Мәскәүдә чыгучы «Современник» журналында күренгәләп китүе дә сөендерде. Соңгы вакытларда ул А.Гыйләҗев, М.Галиев, Р.Зәйдулла һ.б. лар хикәяләрен, Ф.Яруллинның «Йөртә безне язмышлар» повестен рус телле укучы хөкеменә тапшырды. Улым Булат Хәмидулинның тәрҗемәләре дә ешрак күренә башлады. 2001 елда ул Г.Ахуновның соңгы елларда иҗат иткән өч повестен берләштергән «Тимерханның күргән-кичергәннәре» китабын, 2005 елда В.Имамовның «Казан каласы» романын нәшер итте. «Дәрдемәнд» фотоальбомын чыгаруда да тәрҗемәче буларак катнашты. Ара-тирә аның хезмәтләре вакытлы матбугат битләрендә дә күренгәләп китә. Соңгы вакытта Язучылар берлеге каршында теркәлгән тәрҗемәчеләр секциясе эшендә актив катнашкан Наилә Краеваның да уңышлары күзгә ташланырлык. Рус телле әдәбият сөючеләр хөкеменә аның тәрҗемәсендә Фатих Хөсни, Гариф Галиев хикәяләренең кечерәк тупламалары тәкъдим ителде. Аның Айдар Хәлим белән җитди хезмәттәшлек итә башлавы турында да мәгълүмат бар. Ишетеп белүемчә, Айдарның бер китабы инде аның тәрҗемәсендә басылган да. Мәскәүдә яшәп иҗат итүче Венера ханым Вәлиеваны әле санап үтелгән яшьләр рәтенә кертеп булмый, билгеле. Әмма аның Г.Тукай шигырьләрен дистә еллар дәвамында эзлекле рәвештә тәрҗемә итәргә алынуын хупларга кирәктер.

* * *

Шигырь тәрҗемәсенә килгәндә, бик авыр, бик катлаулы эш ул. Шигъри сүз-җөмләне башка телгә зур төгәллек белән күчерү осталары бик сирәк очрый. Бигрәк тә ике телне камил белүчеләр бик сирәк. Габдулла Тукай, Дәрдемәнд, Муса Җәлил, Һади Такташ кебек олуг шагыйрьләребезнең иҗади мирасын рус дөньясына таныттырга җөрьәт иткән элекке шундый тәрҗемәче шагыйрьләрдән фәкать Вил Ганиев, Шамил Анак-Мәхмүдев, Равил Бохараев кына хәтергә төшә. Аллага шөкер, дип әйтик, бүген аларга алмашка ике телне дә яхшы белүче Роза Баубекова-Кожевникова, Рөстәм Сабиров, Лилия Газизовалар килде. Татар телле мохиттә яшәгән, шигъри әсәрләрне бик теләп, яратып тәрҗемә иткән рус шагыйре Сергей Малышевны да шушы төркемгә кертеп бу-

ладыр, мөгаен. (Кызганычка каршы, С.Малышев һәм Р.Баубекова-Кожевникова 2007 елда вафат булдылар.) Ул хәзерге татар шигъриятен иң күп һәм оста тәрҗемә итүчеләрнең берсе иде. Мәрхүм Марк Зарецкий да татар әдәбиятын, татар шигъриятен үз итеп, рухи якын күреп эшләүчеләрдән булды. Олуг шагыйрьләребездән Дәрдемәнд, Габдулла Тукай шигырьләре дә аның тәрҗемәсендә бик килешле итеп эшләнеп, рус телле укучыга тәкъдим ителде. Чөнки соңгы ике автор (Сергей белән Маркны истә тотуым), тумыштан рус телле булсалар да, Мәскәү тәрҗемәчеләре кебек кемдер язып биргән подстрочникка таянып кына эш итмиләр, шигырьнең татарча яңгырашын тоярга, сүз-җөмлә аралыгына салынган мәгънәви эчтәлекне тирәнрәк аңларга тырышып тәрҗемә итәргә омтылалар иде. Моның шулай икәнлеген М.Зарецкий белән китап нәшриятында бергә эшләү елларыннан яхшы беләм. Берәр әсәрне тәрҗемә итәргә керешсә, ул аның эчтәлеген, яңгырашын төгәл чагылдыру ниятеннән чыгып, бүлмәдәше Кыям Миңлебаев, күрше бүлмәдәге Рәис Даутов, шагыйрь Харрас Әюп һ.б. белән аралашып, киңәшеп чыгар. Тәрҗемә иткән вариантларын каләмдәшләренә кат-кат укып күрсәтер иде. Әлмәт каласында, татар мохитендә күпмедер вакыт яшәп алган Мария Аввакумова да, кайбер чордаш шагыйрьләренең әсәрләрен уңышлы тәрҗемә итеп, аларның ил күләмендә танылуына үз өлешен кертте.

Ике телне белмичә, фәкать сүзгә-сүз тәрҗемәләр белән эш итүче шагыйрьләр еш кына шигырь эчтәлеген ярлыландыралар. Алар формаль рәвештә шигырь юллары, сүз иҗекләре санын сакларга тырышкан була. Ягъни тышкы, формаль тәңгәллеккә омтыла. Андый тәрҗемәләрдә еш кына шагыйрьнең укучысына әйтәсе, җиткерәсе фикере нык гадиләштерелә. Тәрҗемә белән шөгыльләнүчегә, ике тел мохитен дә күпмедер дәрәҗәдә белү кирәклегенә мисал итеп, әдәбият галимнәре еш кына Самуил Маршакның бер тәрҗемә үрнәген китерәләр. У.Шекспирның сонетларын тәрҗемә иткәндә, ул, инглиз телен дә белүе сәбәпле, сонетларга хас ундүрт юллыклар белән генә чикләнмичә, юллар санын арттырып тәрҗемә итә. Шул рәвешле рус телендә сонетларның мәгънәви эчтәлеген тулырак бирүгә ирешә. «Аның тарафыннан иң уңышлы тәрҗемә ителгән сонет егерме дүрт юллы булып чыккан. Ләкин моның өчен берәү дә аны гаепли алмый — шул рәвешле ул шигырьнең тулы эчтәлеген укучысына җиткерә алган», — дип язалар әдәбият галимнәре. Ә үзебезнең милли телләрдән тәрҗемә итүче шагыйрьләрнең күпчелеге исә еш кына формаль тәңгәллеккә ирешү белән чикләнделәр. Һәм: «Һади Такташ, Хәсән Туфан кебек шагыйрьләрнең катлаулы эчтәлекле шигырьләрен рус телле укучы кабул итәрдәй дәрәҗәдә эшләү бик авыр», — дип зарланалар.

* * *

Тәрҗемә эшен оештыруга карата булган фикерләремне дә әйтеп үтим. Алда санап кителгән уңышлар һәм ул уңышка ирешкән тәрҗемәчеләр, нигездә, авторлар белән килешеп, алар белән еш аралашып эшләүчеләр булды. Соңгы ун-унбиш елда исә тәрҗемәгә карата мөнәсәбәт шактый сүрелде. Әйе, туксанынчы еллардан башлап андый эшне оештыруга җиң сызганып тотынучы батырлар никтер күренмәде. Шушы дәвердә сайланган Язучылар берлеге идарәләре дә мәшәкатьле һәм күпмедер күләмдә акча тоту таләп ителгән ул вазифаны үтәүдән читләшергә тырыштылар шикелле. Күпмедер чыгым чыгу кирәклеге турында әйткәндә, мин классик әдипләребез иҗатын пропагандалауны күздә тотып әйтәм. Алар инде үзләре рус, инглиз яки төрек телендә сүзгә-сүз тәрҗемә вариантларын эшләп бирә алмыйлар. Элек андый эшне оештыру бурычы Язучылар берлеге идарәсенә йөкләнгән иде. Шул йөкләмәне башкарып чыгу өчен дип, Татарстан хөкүмәте ел саен билгеле бер күләмдә акча да бүлеп бирә иде. Хәзер әсәрен башка телдә чыгару һәр авторның үз эше дигән караш өстенлек итә. Ә бит татар йөзен ачардай матур үрнәкләр биргән, әмма классик әдипкә тиешле дәрәҗәгә формаль рәвештә ирешә алмаган, бүгенгечә иттереп әйтсәк, Дәүләт бүләге иясе булмаган, халык язучысы яисә халык шагыйре исемен даулап йөри алмаган Шәйхи Маннур, Салих Баттал, Нәби Дәүли, Хәсән Сарьян кебекләрнең иҗатын пропагандалау белән кем шөгыльләнергә тиеш? Әлбәттә, Язучылар берлеге идарәсе. Дөрес, андый җаваплылыкны Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре карамагына калдыру ягында торучылар да бар. Кем хаклыдыр — киләчәк үзе күрсәтер. Совет хакимияте дәверендә андый эшләр белән башлыча Язучылар берлеге идарәсе шөгыльләнә иде. Ә фәнни институт әдәби мирасыбызны барлап-туплап, тәртипкә китереп, үз телебездә нәшер итү бурычын үтәде. Ике оешмага да акчаны, мыскаллап кына булса да, Татарстан хөкүмәте бүлеп бирә иде. Хәзер исә бу изге эшләрне башкаруга милли җанлы иганәчеләрне дә җәлеп итү мөмкинлеге туды шикелле. Әнә бит «Татнефть» акционерлык җәмгыяте карамагында оештырылган «Рухият» фонды соңгы унъеллыкта гына никадәр зур эшләр башкарып ташлады. Онытылып барган татар әдипләренең, татар галимнәре һәм җәмәгать эшлеклеләренең китапларын нәшер итеп, халыкка, китапханәләргә таратты. Андый мактаулы эшләрне оештыруда күренекле академигыбыз Миркасыйм Госмановның өлеше дә зур. «Рухият» һәм «Җыен» фондлары нәшер итеп чыгарган милли

әдәби-иҗтимагый мирасыбызның байтагы аның кайгыртуы һәм оештыруы нәтиҗәсендә дөнья күрде.

Бүгенге көндә, бәлки, татар әдәбиятының иң яхшы үрнәкләрен рус, инглиз, француз, гарәп һ.б. телләргә тәрҗемә итү эше белән шөгыльләнердәй махсус бер төркем булдыру кирәктер. Тәрҗемәчеләрне табу, яллау, кирәк чакта сүзгә-сүз тәрҗемәләр булдыру, нәшриятлар һәм сәүдә оешмалары белән килешү төзү — хәзерге заманда булдыклы бер башкаручы төркем оештыруны сорый, минемчә. Ул төркем Язучылар берлеге кул астында яисә әлеге фәнни институт карамагында булырга мөмкин. Ләкин аның алдына махсус бурыч куелган, эш планы бирелгән булырга тиеш. Чит телләргә әдәби мирасны тәрҗемә итүдә беркадәр тәҗрибәсе булган ПЕН-үзәк тә читтә калмаска тиештер, шәт. Әмма турыдан-туры Татарстан хөкүмәте белән гамәли-финанс бәйләнеше булмаган бу җәмгыять төп вазифаны үтәүче була алмыйдыр, мөгаен.

* * *

Төрек кардәшләр белән бәйләнешкә мөнәсәбәтле берничә сүз өстисе килә. Соңгы вакытта Төркия җөмһүрияте белән арадашлык мөнәсәбәтләре күзгә карап үсә, киңәя кебек. Аларның эшмәкәрләре, галимнәре безгә килгәләп йөри. Безнең галимнәр, җәмәгать эшлеклеләре дә аларда еш булалар. Ара-тирә әдәбият әһелләренә дә андый бәхет эләгеп куйгалый. Әмма арадашлыгыбыз әлегә, аеруча әдәбият өлкәсендә, еш кына коры сүзгә генә кайтып кала шикелле. Бу җәһәттән сәнгать әһелләребез бәхетлерәк —төрле фестивальләрдә катнашып, үз иҗатларын кардәш милләткә дә җиткерә алалар. Ә менә татар китапларының Төркиядә (төрекләрнекенең Татарстанда) басылып чыгуы хакында мәгълүмат бик аз. Җитәрлек күләмдә эшләнмәгән эшне эшләнде дип әйтеп тору да читендер шул. Ара-тирә анда яшерен-батырын кемнәрдер үз әсәрләрен бастыргалаган икән, үзбәк кардәшләр әйтмешли, бик хуп. Әмма безнең Габдеррәхим Утыз Имәни, Әбелмәних Каргалый, Габделҗаббар Кандалыйларыбыз, Дәрдемәндләребез иҗатын шул рәвешле генә чит-ят җирләрдә чыгарып булмастыр. Монда төпле, нигезле оештыру кирәклеге көн кебек ачык. Узган гасыр башларында ук Төркиянең әдәбият галиме Фуад Көпрелү тарафыннан иҗаты югары бәяләнгән Г.Тукайның әдәби мирасы анда соңгы тапкыр кайчан нәшер ителде икән? Төрек кардәшләр илендә укыган заманда каләм тибрәтергә керешкән Дәрдемәнд, Фатих Кәрими кебек шәхесләребезнең иҗаты белән анда кем дә булса танышмы икән?

Юл өстендә генә шуны да әйтеп китәсе килә — күренекле һәм классик әдипләребезнең чит төбәкләрдә, бигрәк тә милли республикаларда һәм чит илләрдә басылган китаплары еш кына Казанга килеп җитми. Мондый хәлгә хәтта оештыру эшләре шактый ук җайга салынган Совет хакимияте дәверендә дә очраштыргалар идек. Урта Азия республикаларында йөргәндә, андый басмаларны барлап, табылганнарын биштәремә төяп кайткалаган чакларым еш булды. Олуг язучыларның юбилейларын үткәргәндә, күргәзмәгә куярга дип, аларны миннән алып та торгаладылар. Үзем дә шундый берничә китапны Милли музейга да, «Казан» милли мәдәният үзәгенә дә бүләк итеп тапшыргаладым. Кайбер китаплар әле дә үземдә саклана. (Бу җәһәттән мәрхүм Тәүфикъ Әйди күпкә өлгеррәк булды, тугандаш төрки телләрдә басылган китаплар саны буенча аның китапханәсе күпкә бай иде.)

Ә үзебез бүген төрек әдәбиятын беләбезме? Аны үзебездә пропагандаларга әзерме без? Юктыр, мөгаен. Мәрхүм Тәүфикъ Әйдинең төрек-татар әдәбиятлары арадашлыгына багышланган җитди бер хезмәте «Казан утлары» журналында басылып чыккан иде. Аны һәм шуңа тартым хезмәтләрне китап киштәләренә куярлык, китапханәләргә таратырлык итеп, аерым бастырып чыгару да кирәктер, мөгаен.

Төрек кардәшләребез соңгы вакытта барлык кыйтгалардагы төрки кавемне бик сөендерде: төрек әдибе Орхан Памук Халыкара Нобель бүләге лауреатлары исемлегенә кертелде. Ә без ул әдипне беләбезме соң? Әсәрләре бездә басыламы? Юк бит. Безгә аларны турыдан-туры авторның ана теленнән күчереп нәшер итү зарур. Былтырларда рус йортташларыбыз русча бастырып чыгарган нөсхәләрдән түгел. Төрек телен яхшы үзләштергән осталарыбыз бар ич бүген. Мәсәлән, Асия Рәхимова инде шундый берничә китапны тәрҗемә итеп бастырып чыгарды. Дөрес, саф төрек әдәбияты үрнәкләрен түгел, үзебезнең анда барып сыенган милләттәшләребезнекен. Шул ук эшне оста башкарып чыгарга сәләтле язучыларыбыздан Азат Ахунов, Рөстәм Сүлти, Чулпан Зарипова кебек төрекчә белүчеләребез дә байтак хәзер. Ул эшне фәкать оештырып җибәрү генә сорала.

* * *

Галимнәребез бәян итүенчә, узган гасыр башында җирле рус зыялылары арасында татар әдәбияты белән кызыксыну арта. Казанда керәшен мәктәбендә татар теле дәресләрен укыткан Николай Ашмарин 1901 елда «Очерки литературной деятельности та-

тар-мухамедан в 1880–1895 гг.» дигән китабын бастырып чыгара. Ул китап соңрак 1913 елда Рәмиевләрнең «Вакыт» басмаханәсендә (Оренбург) үз телебездә дә кабат басыла. 1906, 1908 елларда «Волжско-Камская речь» газетасында Сәгыйть Рәмиев иҗатына багышлап ике мәкалә урнаштырыла, шигырьләре басылып чыга. Мәсәлән, С.Рәмиев иҗатын тирәнтен өйрәнгән галим Ш.Садретдинов, аның турында беренче мәкаләне татар авылында үскән поляк Альберт Пинкевич, икенчесен Г.Коләхмәтов яза, дип белдерә. Шул ук Пинкевич шагыйрьнең «Таң вакыты», «Мин», «Син», «Ул» шигырьләрен тәрҗемә итеп, рус дөньясына чыгарган икән («Татар әдәбияты тарихы», 3 том, 172–183 б.). Ул газетаның кайбер саннарында яңа басылып чыккан китаплар исемлеге дә китерелгән икән. Ш.Садретдинов 1908 елгы шундый бер исемлектә С.Рәмиевнең «Низамлы мәдрәсә» китабы чыкканлыгы турында мәгълүмат теркәлгәнлеген дә күрсәтә. Ул исемлекләрдә тагын кемнәрнең исемнәре аталган, кемнәрнең чыккан китаплары турында хәбәр ителгән икән соң?

Шул чорның рус газеталарында Габдулла Тукай иҗатына да мөрәҗәгать ителә, дигән сүзләр дә булгалады. Ләкин үзе исән вакытта басылып чыккан тәрҗемәләре һәм иҗатына бәя биргән язмалар турында әлегә язма мәгълүмат юк шикелле. Һәрхәлдә, миңа андыйлар очрамады. Ә шагыйрьнең вафатыннан соң шул ук тел белгече Николай Ашмаринның үзе укып чыккан институт бастырган бер җыентыкка «Шүрәле» поэмасын 1914 елда тәкъдим иткәнлеге турында хәбәрләр бар. Ашмарин укыган Лазарев исемендәге шәркый телләр институтын 1827 елда Мәскәүдә Еким Лазарян дигән бер әрмән морзасы ачкан була. Егерменче гасыр башына чаклы эшләгән ул институтны байтак кына мәгълүм шәркыять галимнәре тәмамлыйлар. Шул институтны тәмамлаган татарлар да бар. Әйтик, И.Рәми белән Р.Даутов төзеп чыгарган «Әдәби сүзлек»тә анда Габдулла Гыйсмәтинең укыганлыгы әйтелә. Г.Гыйсмәти 1913 елда С.-Петербургта оештырылган «Г.Тукай стипендиясе» фонды исәбенә анда белем ала. Шул институт нәшер иткән җыентык һәм журналларда татарларга багышлы хезмәтләргә дә урын бирелгән булса кирәк. Ләкин ул хезмәтләр әлегә безнең әдәбият галимнәре тарафыннан тәфсилләп тикшерелмәгән бугай.

Шул ук 1914 елда Г.Тукайның «Пар ат» шигыре, инглиз теленә тәрҗемә ителеп, Лондонда чыгучы «Рашен ревью» («Россия хәбәрләре») журналында дөнья күрә. Рус телендә берничә шигыре тупланган тәүге китабы 1920 елда Ташкент шәһәрендә басыла. Ул «Избранные стихи» («Сайланма шигырьләр») җыентыгына кергән шигырьләрне Сергей Есенинның якын дусты ша-

гыйрь Валентин Вольпин тәрҗемә иткән. Тирән эчтәлекле, күләмле кереш мәкаләне ул вакыттагы Төркестан Автономияле Республикасының Мәгариф комиссариаты хезмәткәре Ибнеәмин Янбаев язган. Ә 1921 елның октябрь аенда исә Казанда, рәссам һәм шагыйрь Павел Радимов тәрҗемәсендә, бөек шагыйребезнең икенче русча китабы «Разбитая надежда» («Өзелгән өмет») басылып чыга.

Шул традицияләрнең күпкә арттырылып һәм үстерелеп дәвам иттерелүен генә телисе кала.

Хәер, бу өлкәдә соңгы вакытта алга китеш үрнәкләре сөендерә, өметләндерә кебек. Татарстан китап нәшрияты Татарстан Язучылар берлеге белән берничә үрнәк тәрҗемә китапларын бастырып чыгаруга иреште. 2007 елда рус телендә күләмле татар хикәяләре җыентыгы, быел исә заманыбыз шигърияте тупланмасы дөнья күрделәр.

*2008*

# Ян бакча хәзинәләре

# «БӘР, МЫЛТЫГЫМ, БӘР, БӘР!»

*(Эссе)*

## Мохтариятсез төбәк

Туган авылым Иске Төгәлбуга Татарстан чигеннән егерме чакрым чамасы көньяктарак урнашкан. 1943 елга кадәр Куйбышев өлкәсе Кошка, Яңа Малыклы районнарына карый иде. Хәзер Ульяновск өлкәсе Яңа Малыклы районына керә. Олы Чирмешән буеның «карурманы» безнең авыл очында башлана да Әлки, Нурлат районнары чигенә кадәр дәвам итә. Ике арада элек урманчыларның Каракүл исемле кечерәк торак пункты гына бар иде. Нурлат районының Биккол, Фома авылларына бездән утыз биш-кырык чакрымнар. Авылдашларым элек Нурлаттан чак кына арырак булган Кизләү мәдрәсәсенә муллалыкка укырга йөргәннәр. Хупҗамал әбиемнең туганы Закирҗан да революция өермәләре башланган чорда шул мәдрәсәдә белем алган. Әмма аңа, башына чалма урап, авыл халкына вәгазь укулар насыйп булмый. Гомере фаҗигале рәвештә өзелә.

Китап тотып шәм тирәсендә озаграк утырган чакларымда әбием:

— Шәкертҗан агаң кебек укымышлы булырсың, ахрысы, — дип үсендереп куяр иде.

Бик дини карчык, авылның оста мөнәҗәтчесе иде, мәрхүмә. Алтмышынчы еллар башында Габделҗаббар Кандалый китабын укыгач та, әбием мөнәҗәтләрен очратып хәйран калган идем. (Ул тумышы белән элек шул шагыйрь яшәгән Пәрау авылыннан иде.)

Иске Төгәлбуга бик зур авыл. Совет дәвере урнашканчы, анда җиде йөз унбиш йорт исәпләнгән. Биш мәхәлләле булган. Без үскәндә дә әле берничә мәчет манарасы авыл манзарасын бизәп утыра, тик олы мәчет кенә клубка әверелдерелгән иде. 1939 елда мәшһүр авылдашыбыз Фәйзулла Туишев мәчет рәвеше сакланган шул бинада ике көн гармуннарда уйнап китте. Советча яшәргә иртәрәк җайлашкан күрше Урта Исәнтимер белән чагыштырганда, Иске Төгәлбуга элек-электән динлерәк саналган, район, өлкә җитәкчеләре карашынча «кадимче», «кара авыл»лар рәтендә йөртелгән. Мондый караш әле алтмышынчы елларда да үзен сиздерә иде.

Кошка һәм Яңа Малыклы районы чикләрендәге төбәкнең төп халкы татар, чуаш, мукшылар гына диярлек. Аерым рус авыллары юк дәрәҗәсендә. Алар элекке волость үзәкләрендә һәм тимер юлга мөнәсәбәтле урыннарда гына күмәкләп яшиләр. Гасыр башында төзелгән Сембер — Бөгелмә — Уфа тимер юлы Кошка, Яңа Малыклы (икесе дә зур мукшы авыллары) районнарын ике тарафка аерып үтә. Иске Төгәлбугадан биш чакрым көнбатышта-

рак Урта Исәнтимер, аннан арырак Әбдери, Зирекле Куак, Лабид, Төплистанише зур-зур татар авыллары. Район үзәгеннән чак кына арырак шундый ук зур Өчкаен һәм берничә кечерәк авыл. Көнчыгышта, район үзәкләре Кошка, Нурлатлар тарафында Иске вә Яңа Җүрәйләр (хәзер Иске һәм Яңа Фәйзулла), Карамалы һәм берике кечерәк авыл. Төньяк тарафта Иске Исәнтимер һәм бер мукшы, бер чуаш авылы аша бездән утыз чакрымдагы Пәрау булыр. Аннан Татарстан чигенә дүрт-биш чакрым чамасы.

Иске Төгәлбуга тирә-як авыллар арасында «сәнәкчеләр бунты» үзәге булуы белән дә истә калган. 1920 елның җәй башында яңа оешачак Татарстан Республикасының картасы басылып чыга. Безнең төбәк авылларының ул мохтарият чикләренә кертелмәве ачыклана. Гражданнар сугышыннан күкрәкләрендә Кызыл Байрак ордены балкытып кайткан берничә вәкилне авыл җыеннары Самарага юллый. Алар: «Безне Татарстаннан аермагыз! Безнең төбәктә күпчелекне татар, чуаш, мукшылар тәшкил итә»,— дип, милли җөмһүрияткә керергә хаклы булуларын расларга тиеш булалар. Ләкин халык таләбен үтәргә теләүчеләр табылмый. «Самара крае» түрәләре вәкилләр таләбенә «арестовать» дип җавап бирәләр. Уракка төшкән көннәр булуга карамастан, авылларда шау-шулар башлана. Сәнәк-чалгы күтәргән халык авыл мәйданнарына җыела. «Безне Татарстанга кушыгыз!» — дип даулыйлар. Әмма халык таләбе исәпкә алынмый. Безнең төбәк милли мохтарияттән читләштерелә.

Сембердән алып Бөгелмәгә кадәр Татарстан чиге буйлап сузылган татар авыллары мохтарият биләмәсенә кертелмиләр. Алар бүген дә Татарстан Җөмһүрияте канаты астына сыену хыялы белән яшиләр. Татарстан чигеннән көньяктарак урнашкан зур бер биләмә, татарлар күпләп яшәгән бер төбәк аерылып кала. Мондагы авыллардан татарның күренекле шәхесләреннән Габделҗаббар Кандалый, Төгәлбай Галәүтдин, Фәйзулла Туишев, Габдулла Шамуков, Латыйф Җәләй, Ибраһим Нуруллин, Демьян Фәтхи, Сәхаб Урайский, Зыя Ярмәки, Әнвәр Давыдов, Җәмил Гыйльманов, Рәшит Шамкай, Рөстәм Миңгалимнәр чыккан.

Татар дөньясына мәгълүм шәхесләрдән кемнәр дә булса Иске Төгәлбугада яшәгәнме соң? Дөресен әйтим, авыл тарихы тиешенчә барланмаган. Егерменче елларда туган-үскән җиреннән сөрелгән Хафиз Шәкүревтә ниндидер документларның булганлыгын сөйлиләр. Биләмәсе безнең ызаннан башланган бер рус алпавыты белән җиргә кагылышлы бәхәсләрдә шуларга таянганнар. Шул ук кешедә борынгы бер китаптан күчермә дә булган, имеш. Ике гасыр чамасы әүвәл немец фамилияле бер сәяхәтче авылда кунган һәм соңыннан истәлек язмасында шул хакта язып чыккан икән. Шуның күчермәсе дә әлеге Хафиз байда булган. Тарихчы галим

Җәмил ага Гыйльманов та андый фактны раслаган иде. Ул сәяхәтнамәне табарга дип тә вәгъдәләшкән идек. Ләкин Бөек Ватан сугышына багышланган «Без сугышта юлбарыстан көчлебез» китабын минем тәрҗемәдә чыгаруга ук, үзе арабыздан китеп барды.

Утызынчы еллар урталарында Нәкый ага Исәнбәт Татарстан чигеннән көньяктарак урнашкан татар авылларында халык иҗаты җәүһәрләрен туплап йөри. «Туган авыл хатирәләре» дәфтәремә аның сөйләгәннәрен язып куйганмын: «Авыл картларыннан күп нәрсә язып алган. Соңыннан архивта эшләгәндә дә аңа Гаделша, Гобәйдулла исемле Иске Төгәлбуга кешеләре күчереп язган кульязмалар очраган. Төгәлбай Галәүтдин исеме белән узган гасырда иҗат иткән шагыйрьнең дә безнең авыл кешесе булуы ихтимал».

Төгәлбай Галәүтдиннең «Мәгъшукнамә» исемле шигырь җыентыгы 1880 елларда Казанда ике мәртәбә басылган. Дөрес, аны тәгаен безнең авыл кешеседер дип расламыйм. Шул ук төбәктә Татар Төгәлбае авылы да бар. Элек алар икесе дә Самара губернасына караганнар. Унсигезенче йөзнең беренче яртысында нигезләнгән сиксән-туксан йортлы ул авыл хәзер Татарстанның Әлки районы Кошки авыл советына керә. Алтмышынчы елларда шундагы мәктәп мөдире белән очрашып сөйләшкәнем булды. Ул исә үз авылларының шул исемдәге көньяктарак урнашкан бер «карья»дән күчкән булуын бәян итте. «Тәгаен Иске Төгәлбәдән булу-булмавын картлар белергә тиеш», — диде. Нишләптер ул якларга барып чыгылмады.

Татарстанның халык артисты Фәйзулла Туишев тумышы белән безнең авылдан. Аңа унбер яшьләр тирәсендә Кәбир абый гаиләсе Олы Чирмешән буенча кырык чакрым түбәндәрәк урнашкан Мәләкәс шәһәренә күчеп китә. Гореф-гадәт кушканча, төп йортта энесе Туктаров Хөснетдин кала. Аның варисларыннан кайберәүләр әле исән. 1941 елда туган Туктаров Дамирның хәзер Арчада яшәвен әйттеләр. Күрше авылда Кәбир аганың кыз туганы варислары да бар иде әле.

Мәгълүм тарихчы Җәмил Гыйльманов та җиде яшьтән Иске Төгәлбугада тәрбияләнә. Аның әтисе, Төплистан авылы хәлфәләре нәселеннән чыккан Ибраһим абый, бездә бик абруйлы укытучы иде, чирек гасыр дәвамында мәктәпнең укыту бүлеге мөдире булды. Кайчандыр миңа исем сайлашуда Баян апа белән Ибраһим аганың да катнашуын әнием әйтер иде. Сугыш алды елларында ук мәктәп каршында балаларга һөнәри белем үзләштерү түгәрәген оештырган кеше. Без анда агачтан уенчык чана, арбалар, авыл очындагы кизләү ярыннан алынган йомшак балчыктан курчак, сыбызгылар әмәлләп маташкан була идек. Зуррак малайлар исә тәгәрмәчле тракторлар, җилгә каршы куйсаң, канатлары шыгырдап әйләнә торган тегермәннәр ясап, бездәй бала-чаганы үз тирәләренә тагын да җәлеп итә төшәрләр иде.

Ул яңа мәктәптә миңа ике кыш та ике ай гына укырга насыйп булды. Гомер буена андагы укытучыларны сагынып яшәдем. Ул мәктәпне бүген дә үрнәк итеп алырлык. Анда башлангыч классләр өчен аерым бина, аерым ишегалды. Өлкән класстагылар ишегалды белән ике арада тәбәнәк койма: тәнәфестәге уеннар аерым-аерым уздырыла. Кизү торучы укытучылар ул уеннарны оештырып җибәрәләр. Дөрес, әтиләр яшәгән Урта Исәнтимер авылы мәктәбе дә һәрчак мактаулы булды. Сугышка хәтле үк анда хәзерлек сәгатьләре кертелгән иде. Дәрестән соң, колхоз исәбенә җиңелчә тамак ялгап алгач, балалар шунда ук өйгә бирелгән эшләрне кизү торучы укытучы күзәтүендә башкаралар. Урамга чыгып, күмәкләп уйнап та алалар иде. Олы Чирмешән борылышындагы «карурманга» сыенып ук утырган Иске Исәнтимер балалары да Урта Исәнтимергә йөреп укыдылар. (Үзләрендә башлангыч класслар гына булгандыр, күрәсең.) Кичке якта аларны алып кайтырга дип берничә атлы килә. Алмачуар көр атлар җигелгән арба-чаналарда заманча рухлы җырлар җырлап үткән ул яшьләр артыннан сокланып карап калмыйча мөмкин булмагандыр. Үкенеч ки, сугыш афәте ул яшьләрнең күбесенең гомерен пыран-заран китереп ташлады. «Бәр, мылтыгым, бәр, бәр!» җырын яңгыратып алмачуар атларда җырлап үткән яшь-җилкенчәк тиздән чын мылтык тотып утка керде, шул ут өермәсе эчендә янып-үлеп, арабыздан китеп барды. Туган җирендә, туган авылында исән-сау калганнарының да тормышы, тормышка булган мөнәсәбәте нык үзгәрде. «Бу Рәсәйдә көр тормыш корып булмый. Алда безне җүнле язмыш көтми» дигәнрәк уй-фикерләр кеше күңеленә тирәнрәк сеңә бардылар. Җиңү байракларына ияреп кайткан аракыга табыну гадәте көннән-көн күбрәк корбаннарны җәлеп итте. Сугыш алды балалары күреп калган көр атлар, җитешлеккә ирешеп килүче колхозлар, таза-аек яшәешле, аек фикерле, киләчәккә өмет белән караучы ир-атлар саны авылда көннән-көн кими барды. Ул заманнарда һәр авыл карты иман сагында торыр, һәркемгә үрнәк булырга тырышыр, балаларга шул рухта йогынты ясауны изге бурыч итеп санар иде. Кем баласын очратса да: «Һәрвакыт шулай тәртипле бул, балам! Намусың сакла», — дип җылы сүз әйтеп, күңелен үсендереп китәр иде. Бик үк тәртипле дә, намуслы да булмаган бүгенге заман картларының күпчелеге хәзер үз баласына да җылы тәрбия сүзен әйтә алмый.

Авылымның мулла-мәзиннәре, байлары-кулаклары хакында да берничә сүз әйтеп үтим. Без үскәндә, инде алар кыерсытылган, юашландырылган яисә чит-ят җирләргә озатылган кавем иде. Урта хәлле крәстиян Хәмидулла бабамның ике туганы нәселе — Шәкүрев, Туктаров фамилияләрен йөртүче «зур кулаклар» да шундый язмышка дучар ителгәннәр. Иске Төгәлбуганың ике мәхәллә

имамы Пәраудагы ишан нәселеннән булган. Әнисеннән яшьли ятим калып, ишан йортында тәрбияләнгән Хупҗамал әбиемә чыбык очы кардәш тиешлеләр. Курай урамы мулласы Әхмәтҗанны әбием аеруча үз итә, якын күрә иде. Манарасы җитмешенче елларда гына киселгән шул мәчет мулласының язмышы да аяныч. Утыз тугызынчы елда сөргеннән кайткач, аның ишле гаиләсен авылга кертмиләр. Алар, өч землянка казып, авыл читендә яшәделәр. Шул җәйдә әбием авылдан читтәге Сыза кизләвенә суга йөрергә хәвәсләнеп китте. Чишмә сукмагы әлеге землянкалар янәшәсеннән үтә. Чиләк төпләренә сөт, катык, ипи, йомырка ише әйберләрен сала да, өсләрен әрекмән яфрагы белән томалап, чишмә суына дип бара. Мин дә аңа иярәм. (Җәй айларында авылда без икәү генә яшәдек.) Чиләктәге күчтәнәчләрне бушатып, ике-өч авыз сүз алышуга, без Сыза ярыннан төшеп тә китәбез. Сөргеннән кайтучылар белән озак аралашырга ярамый. Бервакыт мулла бабайның: «Бик еш йөрмә, улыңа зыяны булмасын», — дип, әбигә әйткәнен хәтерлим. Элекке муллалар өендә, мәктәп-мәдрәсә биналарында фельдшерлык пункты, китапханә, балалар бакчасы яки «бригада йортлары» урнашкан иде. Авыл очындагы кирпеч заводы кайсы кулакныкы булгандыр, сорашмаганмын. Аның иркен биләмәсе, Чирмешән буеннан китерелгән аксыл ком өемнәре, кирпеч киптерелә торган озын-озын ачык сарайлары, янәшәсендәге тирән күле бала-чаганың иң яратып уйный торган урыны булгандыр, мөгаен. Көн-төн ут бөркеп торучы дәү мич янына гына безне якын җибәрмәсләр иде. Сугыштан соң бер кайтуымда, ул тирәләрнең ташландык хәлгә килгәнлеген күреп, күңелем сыкраган иде. Кирпеч тә бит авыл кешесенә бик кирәк. Элек аны күрше авыллар халкы да бездән олау-олау ташып торыр иде.

## Әтиләр

Сугыш алды елларында еш җырлана торган бер җыр бар иде. Аның аеруча басым ясап кабатлана торган өч юлы гына хәтеремдә калган:

Бәр, мылтыгым, бәр, бәр,
Бәр, мылтыгым, бәр!
Явыз дошман йөрәгенә утыңны җибәр!..

1940–1941 елларның җәй айлары. Туган авылымда да, ара-тирә барып чыгылган Урта Исәнтимердә дә ир-ат еш кына авыл читендәге мәйданга җыела. Анда алар аркаларына капчык-биштәрләр асып йөгерешә, сикерешәләр. Аннары биштәрләрен казыкка элеп куялар да, йөгереп килеп, шуңа таяк-мылтыкларын кадаган булалар. «Раз, два... раз... када!..» Шундый әмерләр биреп торучылар — авыл түрәләре, укытучылар. Алар арасында Гаяз абый Зәйнуллов та бар. Әтигә туганнан туган тиешле, Нурыйҗан

бабам сеңлесенең улы. Гаскәриләрчә ыспай киенеп, шул язда гына хәрби хезмәттән кайткан кече командир. Авыл халкы шулай хәрби әзерлек курсларын үтә. Байтак вакытлардан соң Гаяз абый: «Ул елларда хәрби хәзерлек үтәргә дүртәр йөз сәгать билгеләнде», — дип әйткән иде. Икенче Герман сугышына әзерлеккә менә ни дәрәҗәдә әһәмият бирелгән булган икән. «Гаскәри» уеннар беткәч тә, ир-егетләр сафка тезелеп әлеге мәйдан тирәли бер-ике мәртәбә әйләнәләр. Яки «раз, два» әмеренә авазлаш атлап, бер урында таптанып торалар. Кемдер: «Җыр башла!» — дип боера. Йокыга талып баручы авыл өстендә «Бәр, мылтыгым, бәр, бәр!» яки шуңа тартым заманча бер рус җыры авазлары яңгырап калыр иде.

Ә кайбер көннәрдә иртән безне баш очындагы самолет гөрелтесе, аларның атышу тавышлары йокыдан уята. Дөрес, мотор гөрелтеләренә караганда, аларның ату авазлары бик тонык — суга таш аткандагы кебек палт-полт итеп кенә ишетелә, шуңа күрә олылар аңа игътибар да итмиләр шикелле. Ә безнең өчен ул бер зур тамаша: тавык кыткылдаган, абзарга бәйләнгән бозаулар мөгрәгән өй тирәләреннән ераккарак китәбез дә, чирәмгә чалкан ятып, һавада барган хәрби уеннарны күзәтергә керешәбез. Зәңгәр күк йөзендәге аксыл болыт кисәкләре арасында бөтерелгән «ераплан»нарның кызыл йолдыз сурәтләре ап-ачык күренеп тора. Гадәттә ул очкычларның берсенең «койрыгына» көмештәй ак түшле «вагон» тагылган була. Ак түшен кояш нурында йолк-йолк уйната-уйната ул «вагон» анда-монда талпынып очкан арада башка аэропланнар чиратлашып аны куып җитәләр дә палт-полт китереп шуңа ата башлыйлар. Кайбер көннәрдә андый атышлар кичкә кадәр кабатлана иде. Бер төркеме авыл өстеннән китеп өлгерми, күк йөзендә башка очкычлар пәйда була.

Дамир дустымның әтисе, укытучы Нур абый, авыл яшьләренең хәрби уеннарын оештыручыларның берсе:

— Очучылар Ворошиловча төз атарга өйрәнәләр. Алгы очкычка тагылган зур куык мишень була, — дип аңлатып бирер иде.

Безнең авыллар өстендә очып, сугыш күнегүләрен үзләштерүче ул өйрәнчек очучылар кай тарафтан булганнардыр; хәрби очучыларны Казанда да, Куйбышев һәм Ульяновск шәһәрләрендә дә укытканнар. Соңгы ике шәһәр безгә якынрак, икесенә дә төгәл йөз егерме чакрым, дип сөйлиләр иде олылар. Сугыш башланган елның кышында ике канатлы шундый бер очкыч, бала-чаганы сөендереп, авыл очындагы «төзәм»гә дә «егылып» төшкән иде. Ерактан ярдәм килеп өлгергәнче, авыл халкы кардан арындырган мәйданчыкта талпынгалаганнан соң, ул кабат күтәрелеп китә алды.

Бала чакта күрелгән «һава сугышлары» хатирәсен яңарткан бер вакыйгага 1984 елның август азакларында тап булдым. Татарстанның Нурлат районы «Игенчеләр» колхозында урып-җыю эшләре

белән танышып йөрибез. Колхоз рәисе Сәлим ага Гафуров, аның урынбасары һәм мин ерак кырдан кайтып килешли, зур буа күле буенда тукталдык. Фома авылыннан ерак түгел бер урында. (Исем-атамасы ятрак булып ишетелсә дә, мөселман динле татарлар яшәгән мәчетле авыл.) Тирә-юньдә тынлык. Көн буена тамак төбенә утырган тузан катламын «юып» төшерерлек йомшак һава. Аяз күктә бихисап йолдызлар җемелдәшә. Офык читендә генә ярымай күренә. Һавада яңарак урылган камыл исе... Һәм иң гаҗәбе — балачактан таныш әчкелтем-төчкелтем кычыткан исе аңкый. Әйе, бала чакны искә төшергән, күңелгә якын бер татлы ис борынны ярып керә. Коры һавалы дала якка тартым бу төбәк авыллары өчен уртак бер билге.

Шул рәхәткә чумып, онытылып күктәге йолдызларга карап торам. Күрәм, җете зәңгәр нур бөркеп балкыган ике йолдыз кинәт кенә бер-берсенә якыная башладылар. Шул мизгелдә үк каяндыр өченчесе дә килеп чыкты. Болар күктә бердәй тигез кырлы өчпочмак хасил иттеләр. Шул рәвешле бераз торгач, тагын да якыная төштеләр, Морзе әлифбасын хәтерләткән бер сызыкка тезелделәр. Аннан соң зур тизлектә өчесе өч якка атылдылар. Аңлашылды ки, болары инде Ходай Тәгалә кодрәте белән барлыкка китерелгән күк җисемнәре түгел, ниндидер тиз йөрешле яңа төр Совет очкычлары иде. Юлдашларым да алар очышын күзәткән икән.

— Төнге күктә алар шулай әледән-әле күренәләр... Сугыш уеннары уйныйлардыр инде, — дип куйды Сәлим ага. Аннары сугыш чорында үзе күргәннәрне сөйләп алды. Ул да «Бәр, мылтыгым, бәр, бәр!» җырын җырлап тәрбияләнгән буын кешесе. Унҗиде яшеннән иңенә чын мылтык аскан солдат...

Тып-тын тирәлек һәм... сугыш уеннары. Ерак басуда комбайннар иген ура, авыл халкы тыныч кына көнкүреш мәшәкатьләре белән шөгыльләнә. Ә кемнәрдер шул вакытта тыныч халык өстенә ничек бомба ташлау һәм аларны күпләп юк итү хәстәрен күрә...

Әйе, безнең ил, безнең ата-бабаларыбыз гомер кичергән дәүләти берләшмә гомер-гомергә тыныч яшәмәгән. Элек-электән Рәсәй түрәләренең иң яраткан шөгыле сугышка хәзерлек булган. Рәсәй патшалары һәрвакыт диярлек хәрби кием киенеп йөргән, Ходай Тәгалә бүләк иткән һәр көннең бер өлешен махсус плац-мәйданнарда хәрби уеннар уйнап уздырганнар. Соңгы зур сугыш алды Совет хакимияте вәкилләренең дә яратып кигән киемнәре хәрби френч, галифелар булды. Сугыштан соңгы җитәкчеләребезнең күпчелеге генераллар иде.

Туган авылымны кабат күз алдына китерәм. Бөек Ватан сугышына чаклы ук анда бер кулсыз, бер аяксыз кешеләр байтак иде. Яу кырында тән җәрәхәте алып та, җәрәхәтләре күзгә бәрелеп тормаучылар күпме булгандыр. Без «таяк атлар»га атланып, «таяк кылычлар»ыбызны болгап «Чапай» булып уйнаганда, олыларның,

капылт кына: « Эх, балалар, белмисез шул әле чын тормышны»,— дип әйтеп куюлары гына күңелгә сеңеп калган.

Безгә фамилия бүләк иткән Хәмидулла бабабызның өч улы, бер кызы үскән. (Хәер, үзе, аларның үсеп җитүен дә күрмичә, иртәрәк вафат булган.) Аның карчыгы Фәтхия әбине 1930 елның җәй башында гүр иясе булды дип сөйлиләр иде. Улларының өчесе дә сугыш афәтен кичергән кешеләр. Иң олысы Шакирҗан «действительный» хезмәтне тутырып кайтам дигәндә генә япон сугышы башлана. Яу кырына ук барып җитмәсә дә, төрле михнәтләр күреп, җиде елга якын иңендә солдат киемен йөртә. Шул михнәт чигүләр нәтиҗәседер инде, илле яшьтән чак кына ашып, 1934 елда үз өендә капылт кына вафат була. Кечеләре Әхмәтҗан Гражданнар сугышында катнаша. Кайларда һәм ничек сугышканын олылардан белешеп калмаганмын. Хәер, ул картны яхшы хәтерлим. Барлык төс-кыяфәте белән әбием аны Нурыйҗан бабама охшата иде. Уртача төз буйлы, аксыл йөзле, аксыл-сары чәчле. Бик каушамый гына эшли, җай-сабыр гына сөйләшә иде. Ул төп йортта калган, Искавыл очында, олы урамда яши, ә безнең өй янәшә зур урамда иде. Авылның калган урамнары безнекеләр кебек үк өчәр чакрымга сузылган булсалар да, йә өзек (Яңавыл белән ике арадагы иске зират бүлеп тора), яки тулы түгел, шунлыктан Сыңар канат дип йөртеләләр иде. Күрше урамдагы Әхмәтҗан бабайларга йомышка күп йөрдем: мал чаласы булса да, йорт эшен башкарырга ир-ат кулы кирәккәндә дә әби мине аларга йөгертә иде.

Арада Нурыйҗан бабам иң бәхетлесе дә, иң фаҗигале язмышлысы да. Шуңа ул бәхетле: дүрт бала белән ятим калган Фәтхия әби фәкать аңа гына авыл мәдрәсәсен тәмамларга мөмкинлек бирә. Үзе дә укуга, белемгә хирысрак кеше булгандыр, күрәсең. Үзлегеннән русча сөйләргә һәм беркадәр рус язуын танырга да өйрәнгән. Шунлыктан атасының хәллерәк ага-братлары кыш айларында аны үзләре белән базар-ярминкәләргә йөртә торган булганнар. Өйләнгәч, үз йортын торгызганчы, Туктар байның кече ызбасында әби белән берике кыш яшәгәнлекләре мәгълүм. Атлар яраткан. Бер сабан аты, бер юртагы булган. Урта хәлләләр исәбендә йөргән. Туган елын тәгаен белмим. Әтинең сеңлесе әйтүенчә, әбидән ике-өч яшькә олы булган. Ә Хупҗамал әбиемнең метрикасын 1943 елның августында әни белән икәү Пәраугa барып алган идек — ул 1879 елда туган.

Нурыйҗан бабам ике зур сугышта катнаша, икесеннән дә исән чыга. Беренче бөтендөнья сугышына 1915 елда алына, 1917 елның көзендә унбер иптәше белән авылга кайта. Мылтык, кылычлары белән кайттылар, дип сөйли иде әби. Шул кышта ук Гражданнар сугышына алына. 1920 елга чаклы кай тарафлардадыр сугышып йөри. Шуннан кайткач, үзен авыл түрәлегенә дә кыстыйлар — ризалык бирми. Әбием дә, туганнары да каршы булган шикелле.

Шуннан соң аны, авылдан билгеләнгән артельгә баш итеп, Сембер — Бөгелмә тимер юлын төзекләндерү эшенә билгелиләр. Атна саен аннан мунча керергә кайтып йөриләр. Гаиләгә әзме-күпме ризык кайтарып торалар. 1921 елның апрель башында шуннан кайтышлый вафат була. Ачлыкның һәм ваба чиренең көчәйгән вакыты. Иптәшләре әйтүенчә, биштәрендә ун кадак ярмасы һәм ипие булган. Әбигә аларын кайтарып бирмәгәннәр.

Әтием Хәйдәрҗан һәм аның сеңлесенең ире Шакирҗан иң аяныч язмыш ияләре. Аларның икесен дә бер чордарак, миңа ике яшь булганда, ике еллык хәрби хезмәткә алалар. Ул заманда армиягә егерме ике яшьтә алганнар. Өч ел читтә укып йөргән әти шактый соңлап, егерме алты яшьтә генә хезмәт итә башлый. Ләкин инде шуннан соң аны бер дә алай соңлатып йөртмиләр. Хәер, фин сугышына беркадәр соңлабрак алына әле. Алар эшелоны Ленинград янына җиткәндә, ул сугыш язмышы хәл ителгән була инде. Шулай да тиз генә кайтарып җибәрмиләр үзләрен. Ә Шакир Алиев (җизни) һәм аның яшьтәшләре бу сугышның башыннан ахырына кадәр катнашалар.

Барлык михнәтләрдән, шул исәптән әсирлектән котылып өенә кайта алган кордашы һәм авылдашы Миңлегали абый Әхмәтев үз башларыннан кичкән хәлләрне болайрак сөйләгән иде. Яу кырында алар ротасы ике мәртәбә бик хәтәр хәлдә калган. Соңгы мәртәбәсендә бер атна чамасы чолганышта сугышканнар, байтак кына иптәшләре шунда ятып калган. Шакир җизнинең дә беләге җиңелчә яраланган булган. Финнар белән килешү төзелгәч тә, никтер алар дивизиясен тиз генә кайтарып җибәрмәгәннәр. «Сугышны мартта тәмамладык, безне уракка төшәр алдыннан, июньдә азат иттеләр», — дигән иде әңгәмәдәшем.

Ульяновск шәһәренә дивизияләре белән кайталар. Бер ел үтмәстән, 1941 елның апрель ахырында авылдан унике кешене, шул исәптән җизнине «кырык көнлек хәрби хәзерлек җыенына» дип алып китәләр. Барысы да 1912–1914 елларда туганнар. Миңлегали абый хатирәләренең дәвамы: «Июньнең егермеләреннән соң алар кайтырга, үзебезнең 154 нче дивизиягә без барырга тиеш идек. Сборга барысы да әзер — сохари киптерелгән, башка кирәк нәстә биштәргә салып куелган. Чакыру көнен көтәбез. Атна башыннан да соңга калдырмаслар шикелле иде. Базар көнне яңа хәбәр килә: сугыш башланган! Егерме өчендә кичке якта без инде дивизиядә идек. Башкаларны элеккечә пехотага билгеләделәр. Берничә кешене бер майор, үгетләп, үзенә алып китте. «Кем ат ярата, алга чыгыгыз», — диде. Мин буйсындым. Шулай итеп, 77 нче тупчы полкка ездовой булып эләктем: иңемдә авыр мылтык урынына карабин, ерак юлга чыкканда, ат өстендә барасың. Барысы да әйбәт кебек, тик авылдашларның күбесеннән аерылу гына борчый иде. Июль урталарында Днепр аръягындагы Жлобин шәһәрен немец-

лардан азат итәргә боерык алдык. Безнең тупчы дивизионнарны укчы полкларга беркеттеләр, һөҗүмгә бергә бардык. Билгеләнгән Жлобин шәһәрен, берничә авылны азат иттек. Шуннан соң инде немец зур һөҗүм башлады. Чолганышта калгач та, берничә атна сугыштык. Соңрак барлык полкларны, берләштереп, бер иттеләр. Чынлыкта бер батальоннан кимрәк булганбыздыр. Командирыбыз татар, Батталов фамилияле. Фин сугышында да безнең белән бергә булган, батыр сугышкан, орден алган, дип сөйләделәр. Исән калган пехотачы авылдашлар белән тагын шул батальонда кавыштык. Шакир җизнәң дә анда иде, шуннан соң инде аның белән аерылышмадык. 13 октябрьдә безне әсир иттеләр. Лагерьда тагын бер авылдашны — Гомәр Вәлиуллинны очраттык. Ул да, мин дә җиңелчә яралы. Җизнәңнең аягы без очрашканчы ук яраланган иде. Лагерьдан лагерьга йөри-йөри, бөтенләй аякка баса алмас хәлдә калды. Без аны Бобруйскидан башлап култыклап йөрттек. Варшава янәшәсендәге лагерьга көч-хәл белән килеп җиттек. Шакир бөтенләй хәлсезләнде, ашаудан калды, паекларын безгә бирә башлады. «Исән-сау илгә кайтсагыз, балаларымны багышыгыз», — дип ялварды. Җизнәңне шул Варшава лагеренда җирләдек. Вәлиулла белән икебезгә авылга кайту насыйп булды. Затия апаңа, балаларына хәлдән килгәнчә булышуымны беләсең».

Татарстанда һәм аңа чиктәш Ульяновск өлкәсендә оешкан дивизияләрне берләштергән армиянең бу контрһөҗүменә зур әһәмият бирелүе, безнең якташларның яу кырында исәпсез-сансыз кырылуы исәбенә дошманның һөҗүм итүе күпме вакыткадыр тоткарлануы хакында соңыннан маршал Г.К.Жуков китабында язылган түбәндәге шушы сүзләр аша белдем. «Генерал Ф.И.Кузнецов командалык иткән 21 нче армия 13 июль таңында Днепр елгасын кичте, Рогачев һәм Жлобин шәһәрләрен яулап алды... Нәтиҗәдә немецларның сигез дивизиясе шул тирәдә тоткарланды. Ул вакытта безнең өчен аның әһәмияте бик тә зур иде», — диелгән анда.

Шул нәтиҗәгә ирешү өчен кан койган, башын салган дистә меңнәрчә сугышчы, аларның гаиләсе язмышы гына, гадәттәгечә, әһәмият үзәгеннән читтә кала килде. Сугышта алган ярасыннан 1943 елның башында Варшава янәшәсендәге әсирләр лагеренда вафат булган Шакир Алиев язмышы да моңа дәлил була ала. «Билгесез югалган» сугышчы мөһере сугылган Шакир Алиевнең ятим калган өч баласы, хатыны хакимият җитәкчеләренең шикле карашын тоеп яшәргә мәҗбүр ителде. Аларга хөкүмәттән бернинди дә ярдәм булмады диярлек. Билгесез югалучының әсирлектә үлеп калуын, туган авылында шуны раслардай шаһитлар барлыгын белдереп, 1972 елда ук Яңа Малыклы районы Хәрби комиссариатына хәбәр иткән идем. Сиксәненче елларда шундый ук хатны Затия апа да илтеп бирде. Үлеменә сәбәп булучы каты яраны яу

кырында алган сугышчыны соңгы көннәргә кадәр «эзсез югалучылар», ягъни «качкыннар» исәбендә йөрттеләр. «Хәтер» китабына да исемен, авылдаш һәм яудашларыннан аерып, өстәмә томга гына урнаштырганнар иде. Ә бит андый язмышка дучар булганнар бер Шакир Алиев һәм аның гаиләсе генә түгел.

Бөек Ватан сугышы һәм аңа бәйле вакыйгалар безнең буын кешеләре күңелендә мәңге саклаunion, онытылмаячак. Сугыш башланган көннән, ягъни сигез яшемнән, мин дә төрле михнәт һәм кимсенүләр кичердем. Чөнки ятим калган өч баланың иң өлкәне мин булдым. Кулыма әлифба китабы тотып, беренче сыйныфка укырга кергән көннәремдә инде әтием ябырылып килгән дошман явыннан Ленинград шәһәрен сакларга керешкән була. Аларның 885 нче тупчы полкы шәһәр оборонасының иң хәтәр бер урынында, атаклы Киров исемендәге заводка килү юнәлешендә дошманга каршы тора. Шул көзнең 17 сентябрендә язган хаты сакланып калган. Шакмаклы дәфтәр битенең ике ягына ашыгып язылган юллар: «Сездән әлегә бер хәбәр дә ала алганым юк, ничек яшисез» дип борчылган. «Игеннәр, бәрәңгеләр уңдымы, җыеп ала алдыгызмы?» дип сораган.

Сакланган икенче хаты 1942 елның 11 июлендә язылган. Яраланып, Ленинградтагы госпитальдә дәваланганнан соң, кабат хәрби частька билгеләнгәч җибәргән беренче хәбәре. «Хәзер миңа «п/п 699» адресы белән языгыз, 3 нче дивизиянең 14 нче гвардейский полкына эләктем, авылдашлардан аерылдым» дигән. «Җаным, синнән биш ай хат алганым юк, сезнең өчен бик тә борчылам» дип ике урында кабатлаган. Хәтеремдә әле, аның госпитальдә ятканда язган хатлары да бар иде. (Өч мәртәбә яраланды. Соңгысында, 1943 елның башында, озак кына Череповец шәһәре госпиталендә дәваланды. Аннан җибәргән соңгы фотосурәте минем кулда.) Ленинград госпиталеннән җибәрелгән хатының берсендә әни белән әбигә иң вак бәрәңгене дә исраф итмичә, кышка сакларга кушылган иде. Ул киңәшнең Ленинградтагы галәмәт ачлык чагылышы булганлыгын без бик соңлап аңладык, билгеле.

Әйе, Хәмидуллин Хәйдәрҗан Нурыйҗан улының яу кырыннан җибәргән хәбәрләренең байтагы безгә килеп ирешкән. Ә әнинең күз яшьләрен түгә-түгә язган хатларының күпчелеге исә 1941 елның 8 сентябреннән чолганышта булган Ленинград хәрабәләре арасындагы окопларга барып җитә алмаган икән. Хәрби җитәкчеләр ул авыр көннәрдә, бәлки, тонналап җыелган хатлар урынына чолганыштагыларга берничә тонна өстәмә ризык яки корал илтүгә өстенлек биргәннәрдер.

Әтине авылдан 7 август иртәсендә озатып калуыбызны яхшы хәтерлим. Егерме чакрымдагы район үзәгенә алар берничә олауга төялеп чыгып киттеләр. Әти белән әни утырган җиңел таран-

тас артына тотынып мин дә авыл очына җиткәнче бардым. Аннары әле башка озатучы малайлар белән бергәләп күрше авыл ызанына чаклы чабып баруыбыз да хәтеремдә саклана.

Мөбарәк энем шул көзнең иң хәтәр көннәрендә — Мәскәүгә дә чолганыш янаган бер вакытта — 1941 елның 5 ноябрендә дөньяга килде. Ул иртәдә мин мәктәпкә чыгып киткәндә, әнинең эшкә бармыйча ятып калуы бик гаҗәпләндергән иде. Сабыр гына кар сибәләп торган көн уртасында укудан кайтсам, «үә-үә» килгән аваз каршы алды үземне. Сабыйның аяк табаннарын, тырпайтып куелган кул чугын кәгазь битенә төшереп, әтигә җибәреләсе хатлар эченә сала идем. Янәшәдә утырган Хупҗамал әбием дә, сабый башын сыпыргалап, үз сүзен белдергәләп куяр иде: «Яз, килен, кече улымның чәче Нурыйҗан бабасыныкы кебек салам төсендә, диең. Көлгәндә дә бабасы чалымнары сизелә, дип яз». Менә шул хатларның күбесе әти кулына барып ирешмәгән, кайлардадыр аунап, югалып калган икән.

Әтинең хатлары күп иде. Зур бер өлешен без, бала-чага, югалтып, ерткалап бетергәнбездер, күрәсең. Әнинең туган якларына, Оренбург өлкәсенә кайткач, без ике гаилә бергә кушылып яшәдек. Әнинең җизнәсе дә сугышның беренче елында ук — каты сугышлар барган Смоленск тирәсендә билгесез югалган иде. Ике яшь ана, бер ояга биш баланы сыйдырып, унөч ел бергә яшәделәр. Һөнәри белем үзләштереп эшли башлагач кына, мин әни белән кече энемне үз карамагыма алдым. Биш бала арасыннан да иң олысы мин идем. Менә шуннан соң атамның ике-өч хатының сакланып калуы гаҗәп тоелырга мөмкин.

Цензура тикшерүен белгәнгәме, әллә башка сәбәптәнме — әтинең сугыш хәлләренә кагылышлы бер генә җөмлә дә язмаганлыгын хәтерлим. Элек зур бер колхозда баш хисапчының уң кулы булган әнигә яңа урында андый эш табылмады. Унике чакрымдагы рус авылыннан почта кайтару һәм өләшү эшенә алынды. Хат алучылар күп очракта аны укып бирүне дә үтенәләр иде. Кайбер хатларда кара тушь белән буялган өлешләр күп була. Әтием хатларында андый таплар бик сирәк иде. Сак кеше булгангадыр инде, сугыш хәлләрен бер дә иркенләп язмады, мәрхүм. Кайларда, кем булып сугышуын да хәбәр итмәде. Очраклы рәвештә алар сугышка Гаяз абый белән бер көндә алынганнар икән. Аерым хәрби берәмлекләргә бүленер алдыннан тупчы старшина Гаяз Зәйнуллов авылдашларына әйткән: «Үзегезне тупчы дип танытыгыз, бергә булырбыз»,— дип. Шул рәвешле әти тупчы булып киткән.

Гаяз абый 1941 елның декабрендә каты яралана, өч-дүрт ай госпитальдә ятканнан соң, аны ялга җибәрәләр. Ул килеп сөйләгәч кенә, без әтинең хәл-әхвәлен беркадәр күзаллаган идек. Бер вакыйга бик хәтергә сеңеп калган.

Бабай вафат булгач, 1921 елның җәй башында аның туганнары унөч яшьлек әтине бер немец хуторына көтүчелеккә яллыйлар. Шул рәвешле дүрт кешелек гаиләне ачлык афәтеннән коткаралар. Авылдан егерме чакрымдагы ул хуторда әти ике җәй бозау көтүе көтә. Шунда немец телен дә беркадәр үзләштергән була.

Гаяз абый сөйли: «Немецча әз-мәз белүчеләрне, җыеп, дошман тылына озата башладылар. Йөкләнгән бурычны үтәгәч, үзебезгә кайтырга тиеш булсалар да, берсе дә кире кайтмый диярлек. Шул вакыт абый миңа әйтә, дошман телен төшенгәнне берәүгә дә белгертмә, авылдашларга да әйтеп куй, ди. Абый батарея командиры карамагында элемтәче иде, җае чыккан саен безнең блиндажга килеп, хәл белеп киткәләр иде».

1943 елда Ленинград блокадасын өзү омтылышы ике мәртәбә кабатлана. Кышкы зур һөҗүм барышында әти яралана, бер ай чамасы Череповецта дәвалана. Ә июль аендагы Ленинград һәм Волхов фронтларының боҗраның эченнән һәм тышыннан алып барылган һөҗүмнәре барышында яу кырында ук ятып кала. Безгә җибәрелгән белешмәдә «1943 елның 27 июлендә батырларча сугышып һәлак булды. Синявино биеклеге, 6 нчы поселок янында җирләнде» дигән иде. Хәзер ул бистә Ленинград өлкәсенең Киров шәһәре биләмәсенә керә. Әтинең кыш уртасында тууын исәпкә алганда, аңа әле утыз биш тә тулмаган була. Ә Шакир җизнигә утыз яшь Варшава концлагеренда вакытта тула. Шул гомер аралыгында алар өчәр мәртәбә солдат булырга һәм икешәр мәртәбә яу-сугышларда катнашырга өлгерәләр. Алар язмышы илнең «Бәр, мылтыгым, бәр, бәр!» җыры рухында яшәү дәверенә туры килде. Хәмидулла бабам токымыннан ул сугышта катнашучылардан берәү дә иленә әйләнеп кайтмады. «Хәтер» китабының Иске Төгәлбуга авылына багышланган битләрендә соңгы зур сугышта һәлак булган өч Хәмидуллин теркәлгән. Ә Урта Азиядән сугышка алынган һәм башка меңнәрчә сугышчы кебек үк яу кырында эзсез югалган Хәмидуллин Әхмәтгәрәй Шакирҗан улы исә ул «Хәтер» китабына да кертелмәгән.

Мәрхүмнәрнең урыннары оҗмахта булсын! Алар башына төшкән авыр язмышны башка буыннарга күрергә насыйп булмасын дигән теләктә калам.

*«Казан утлары», 2002, № 11*

## БИОБИБЛИОГРАФИК БЕЛЕШМӘ

Лирон Хәйдәр(җан) улы Хәмидуллин 1932 елның 22 октябрендә (10 ноябрьдә теркәлә) Ульяновск өлкәсе (1943 елның мартына кадәр Куйбышев өлкәсе) Яңа Малыклы районы Иске Төгәлбуга авылында хезмәткәр гаиләсендә туа. Оренбург өлкәсендәге Иске Белогор авылында җидееллык мәктәпне тәмамлагач, укуын Актүбә шәһәрендәге (Казакъстан) тимерьюлчылар техникумында дәвам иттерә. 1951–1954 елларда хәрби хезмәттә була. 1956–1960 елларда Орск (Оренбург өлкәсе) шәһәрендә төп белгечлеге буенча эшли. Кичләрен Мәскәү политехника институтының Орск филиалында дүрт ел югары техник белем үзләштерә. Орск шәһәренең татар-башкорт яшь һәвәскәрләре белән бергә әдәби-музыкаль кичәләр оештыруда катнаша. 1960 елда Башкорт дәүләт университетына керү теләге белән Уфага килә. Шәһәрнең 3 нче һөнәр училищесында дүрт ай укыткач, татар мохитенә якынрак булу теләге белән, 1961 елда Казанга күчеп килә.

1961–1967 елларда шәһәр транспорты оешмасында тимер юл бүлеге инженеры, баш инженеры, идарәнең партком секретаре булып эшли. 1967–1983 елларда — СССР Әдәби фондының Татарстан бүлеге директоры.

1985–1994 елларда — Татарстан китап нәшриятында әдәбият редакциясе мөхәррире. Анда танылган әдипләр белән башлап язучыларның йөз иллегә якын китабын редакцияләп чыгара. Кайбер авторларның әсәрләрен редакцияләү белән генә чикләнмичә, төрле яклап аларга булышлык та иткәләргә туры килгәли.

1998–2005 елларда Татарстан энциклопедия институтының өлкән фәнни хезмәткәре; татарча энциклопедик сүзлекне нәшер итүдә (2002 елда ул басылып чыкты) һәм «Татар энциклопедия сүзлеге»нең татарча I томын чыгаруга әзерләшүдә катнаша. Сүзлеккә кергән егермеләп һәм томнарда урын алачак берничә мәкаләнең авторы да.

Әдәби эшчәнлеге 1960 елларда «Татарстан яшьләре» газетасында хәбәрләр, кыска очерклар бастырудан башлана. Яшь һәм башлап язучыларның күмәк җыентыкларында берничә өйрәнгеч хикәясе, 1968 елда «Юлда» исемле кечерәк күләмле хикәяләр җыентыгы нәшер ителә.

Әдәби тәрҗемә өлкәсендәге хезмәтләре дә байтак. Аеруча кардәш телле казакъ, үзбәк, каракалпак әдипләренең әсәрләрен яратып тәрҗемә итә. Абай Конанбаев, Мохтар Әүэзов, Әнүәр Әлимҗанов, Әсгать Мохтар, Сайын Моратбәков, Мохтар Магауин, Яныбай Хамматов, Теләпбиргән Каипбиргәневләрнең роман, повесть һәм хикәяләре «Абай», «Ак дөя», «Арал дулкыннары», «Дала гөлләре», «Дуслык аланы» кебек күмәк җыентыкларда һәм аерым китапларда басылып чыгалар. Җәмил Гыйльмановның Бөек Ватан сугышына багышланган очерк-мәкаләләр тупламасы — «Без сугышта юлбарыстан көчлебез», күренекле белорус әдибе Василь Быковның СССР

Дәүләт бүләгенә ия булган ике мәгълүм повестен берләштергән — «Һәйкәл», Александр Капустинның «Беренче җиңүләр» китаплары да татар укучысына аның хикәяләве аша барып ирешәләр.

Шулай ук татар әдәбияты үрнәкләрен тугандаш халыклар һәм рус телләрендә туплап чыгаруга да ул күп көч куя. Казакъча күләмле «Татар повестери» җыентыгы (8 повесть, «Дуслык китапханәсе» сериясе, 1979), үзбәкчә «Йиллар вә йуллар», каракалпакча «Татар гүрриңлери» (1981), русча «Пробуждение» (1978) исемендәге хикәя тупламалары — әдәбиятлар арадашлыгы өлкәсендә башкарылган хезмәт нәтиҗәләре. Язучылар берлеге идарәсе кушуы буенча, Венгриягә дә татар хикәяләрен туплап җибәрә. 1980 елларда РСФСРда яшәүче аерым милләт әдипләренең сайланма повесть җыентыкларын «Халыклар дуслыгы» сериясендә чыгару планлаштырыла. Совет чоры татар әдәбиятына ике том билгеләнә. Язучылар берлеге идарәсе ул томнарны барлауны да, тәрҗемәчеләр секциясе җитәкчесе буларак, Л.Хәмидуллинга йөкли. Егерме дүртәр табаклы ике китапка тупланган повестьлар вакытында Мәскәүдәге «Современник» нәшриятына тапшырыла. Беренче томының корректура варианты әзер булгач (1991), Советлар иле таркалуы сәбәпле, ул җыентыкларны чыгару туктатыла.

Л.Хәмидуллинның әдәби эшчәнлеген хуплап, матбугатта үз фикерләрен әйтүчеләрдән Гариф Ахунов, Хәсән Сарьян, Фәрваз Миңнуллин, Рәис Даутов, Таһир Нурмөхәммәтов, Миркасыйм Госманов, Равил Фәйзуллин, Шәһидә Максудова, Фоат Галимуллин исемнәрен атап китәргә була.

Орскида эшләү дәвереннән бирле (1956–1960) язмышлары шул шәһәр белән бәйле булган драматург Мирхәйдәр Фәйзи, мәшһүр шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Закир Рәмиев-Дәрдемәнд иҗатлары һәм биографияләре белән кызыксына һәм аларга кагылышлы мәгълүматны барлый. Ул шәхесләрнең Орск, Оренбург, Уфа һәм Мәскәү шәһәрләрендә, Оренбург белән Башкортстан төбәге авылларында яшәүче туганнары, якыннары һәм оныклары белән бәйләнешкә керә, шактый күләмдә кызыклы мәгълүмат туплый. Соңгы елларда дөнья күргән кайбер әдәби әсәрләрләр дә шушы олуг шәхесләр язмышына һәм иҗатына багышланган. «Рухият» нәшрияты 2002 елда чыгарган «Бертуган Рәмиевләр» җыентыгын туплашуда (төзүчеләрнең берсе һәм ике мәкалә авторы), Татарстан китап нәшрияты 2003 елда нәшер иткән «Дәрдемәнд» альбомын төзеп чыгаруда катнаша. Хәзер «Җыен» фонды нәшер итәргә ниятләгән «Миллионер Хөсәеневләр» китабына кирәсе хезмәтләрен барлый.

1977 елдан — СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

1982 елдан — ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре.

## ҮЗ КИТАПЛАРЫ

1968. Юлда: хикәяләр.
1971. Дала иртәсе: повесть.
1990. Офыктагы рәшәләр: повесть, хикәя, очерклар.
2002. Ак төннәр хәтере: очерк, эссе, хатирәләр.
2003. Дәрдемәнд: альбом (русча һәм татарча).
2007. Күңелдә калганнар: очерк, эссе, юлъязмалар.

## ТӘРҖЕМӘ КИТАПЛАР

1974. Ә л и м җ а н о в Ә. Отрар хатирәсе: ике повесть (казакъчадан).
1976. М о х т а р Ә. Чинар: роман (үзбәкчәдән).
1984. Б ы к о в В. Һәйкәл: ике повесть (русчадан).
1986. М о р а т б ә к о в С. Әрем исе: повестьлар, хикәяләр (казакъчадан).
1989. Г ы й л ь м а н о в Җ. Без сугышта юлбарыстан көчлебез (русчадан).
1993. Җәйләүдә: казакъ повестьлары.
1995. К а п у с т и н А. Беренче җиңүләр: повесть, хикәя (русчадан).
1996. Х а м м а т о в Я. Бөртекләп җыела алтын: роман (башкортчадан).

## ҖЫЕНТЫК ҺӘМ ЖУРНАЛЛАРДА ЧЫККАН ХИКӘЯ, ОЧЕРКЛАР

1964. «Яшьлек таңы» (кит.) — «Сәгыйтьнең сөю сүзе», «Бала күңеле».
1965. «Кайнар хисләр» (кит.) — «Дәгъва»: хикәя.
1969. «Рассказы 1968 г.» — «Незабываемым проселком»: хикәя (русча).
1978. «Пробуждение» — «Незабываемым проселком»: хикәя (русча).
1981. Казан утлары, № 5 — «Ерак араларны якын итеп»: очерк.
Казан утлары, № 11 — «Чыңгыз тауларының бөркете»: очерк.
Амудәрья, № 5 — «Кышкы жол»: хикәя (каракалпакча).
1982. Полымя, № 11 — «Кыш үткән юл буйлап»: хикәя (белорусча).
Казан утлары, № 11 — «Буранлы төндә»: хикәя.
1984. Казан утлары, № 12 — «Бәхетле язмыш»: очерк.
1985. Амудәрья, № 5 — «Буранлы төндә»: хикәя (каракалпакча).
1988. «Көзге ачы җилләрдә» — «Илнең беренче батырлары»: очерк.
1991. Казан утлары, № 2 — «Офыктагы рәшәләр»: документаль повесть.
Казан утлары, № 11 — «Мирхәйдәр Фәйзи эзеннән»: юлъязма.
1992. «Мәдрәсәләрдә китап киштәсе» — «Хөсәения» мәдрәсәсе.
1993. Казан утлары, № 7 — «Университетлар үрнәгендә»: очерк.
1994. Казан утлары, № 7 — «Гыйбрәтле шәҗәрәләр»: очерк.
1995. Татарстан, № 5–6 — «Мир тоткалары»: очерк.
Идел, № 11 — «Каргалыга сәяхәт»: юлъязма.
1996. Сөембикә, № 3 — «Зөһрә йолдыз — таң йолдызы»: мәкалә.
Казан утлары, № 6 — «Ике дәвер кешесе»: очерк.
Татарстан, № 11 — «Онытылган якын исем»: очерк.
1998. Казан утлары, № 3 — «Иске чаршауларны алыйк»: очерк.
1999. Казан утлары, № 12 — «Тыштан танылмыйдыр...»: очерк.
2000. Казан утлары, № 3 — «Үз кыйбласын тапкан...»: очерк.
2001. Татар хикәясе антологиясе — «Кыш үткән юлдан».
2002. «Бертуган Рәмиевләр» — ике очерк һәм төзү.
Мәйдан, № 11— «Бакыр һәйкәл»: юлъязма.
Казан утлары, № 11 — «Бәр, мылтыгым, бәр, бәр!»: очерк.
Идел, № 12 — «Йотып утларны китте яна-яна»: эссе.

2003. Фәнни Татарстан, № 1 — «Тынгысыз эзләнүче...»: очерк.
Казан утлары, № 3 — «Осталарның остазы»: очерк.
2004. Казан утлары, № 10 — «Әдәби фонд сәхифәләре»: очерк.
2005. Фән һәм тел, № 1 — «Энциклопедия нигезләре» (автордаш).
Казан утлары, № 5 — «Күпкырлы иҗат иясе»: очерк.
Идель, № 8 — «Буранлы төндә»: хикәя (русча).
«Гариф Ахунов» (кит.) — «Ярты гомер бергә»: очерк.
«Балачак әдипләре» — «Узган тормыш хатирәләре».
2006. Литературная газета, № 15 — «М.Җәлил мирасы» (русча).
«Матбугат йорты» (кит.) — «Өлкәннәр фатихасын тоеп».
«Хәсән Сарьян» (кит.) — «Үз кыйбласын тапкан шәхес».
Мәдәни җомга, февр. — «Муса Җәлил: тормышы, мирасы...»
2007. «Современная татарская проза» — «В метельную ночь»: хикәя (русча).
«Галимҗан Ибраһимов». — «Иске чаршауларны алыйк»: очерк.
Казан утлары, № 2 — «Милли мирас җәүһәрләре»: очерк.
Идель, № 2 — «Раздумья о наследии поэта».
Сөембикә, № 3 — «Әстерхан кызы»: очерк.
Ялкын, № 6 — «Әхмәт нигә елый?»: хикәя.
«Аккош күле — илһам аланы» (кит.) — «Илһам учагы».
Мәдәни җомга, 17 июль — «Әтил суы ака торур».
Мәдәни җомга, 10 авг. — «Якын кардәшлек эзләре»: очерк.
Казан утлары, № 8 — «Гармун, әй гармун»: документаль повесть.
Идел, № 11 — «Дәрдемәнднең соңгы көннәре»: очерк.
Гасырлар авазы, № 2 — «Ерактагы ак җилкәннәр»: очерк.
2002. «Татар энциклопедия сүзлеге»ндә мәкаләләр: Актүбә, Акчурина Зөһрә, Бабур Заһретдин, «Вакыт» басмаханәсе, Вәли Ярулла, Ибраһимов Шаһимәрдән, «Кәримов, Хөсәенев вә шөрякәсе» басмаханәсе, Колючев Илгиз, Куликово кыры сугышы, Әл-Мәсһүди, Мишәр йорты, «Өмет» газетасы, Татар сәүдә-сәнәгать ширкәтләре, Чанышев Касыймхан, Чанышев Хөсәен.

## БИБЛИОГРАФИЯ

Сарьян Х. Өч төрле өч адым // Социалистик Татарстан. — 1972. — 3 март.

Нурмөхәммәтов Т. Чуен юллар, күперләр аша... // Яшь ленинчы. — 1982. — 11 ноябрь.

Миңнуллин Ф., Даутов Р. Җылылык хисе // Татарстан яшьләре. — 1982. — 23 декабрь.

Морат Ә. Казан дигән каладан // Яңа вакыт. — 1995. — 11 август.

Ахунов Г. Ихтирам нигезләре // Ватаным Татарстан. — 1992. — 6 ноябрь.

Миңнуллин Ф. Лирон Хәмидуллин // Балта явызлар кулында: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. — 1994.

Максудова Ш. Салмак кеше сукмагы // Шәһри Казан. — 2002. — 15 ноябрь.

Лерон Л. Яшьрәк чакта вакыт кадерле // Таһир-Зөһрә. — 2002. — ноябрь.

Госманов М. Тыйнак табигатьле каләмдәшебез // Гасырдан — гасырга. — 2004.

Миннибаев К. Лирон Хамидуллин // Перевод — это искусство. — 2004.

# ЭЧТӘЛЕК

Аксакал әдипләребезнең берсе. *Р.Фәйзуллин* . . . . . . . . . . . . . . 5

ОФЫКТАГЫ ЙОЛДЫЗЛАР

Әй гармун, гармун . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
Ерактагы ак җилкәннәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 41
«Татар уянсын дисәң...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 67
Дәрдемәнднең Орскидагы тормышы . . . . . . . . . . . . 74
Есенин Тукайны каян белгән? . . . . . . . . . . . . . . . . 90
Милли мирасыбыз җәүһәрләре . . . . . . . . . . . . . . . . 95
Муса Җәлил: туган төбәге һәм мирасы . . . . . . . . . . 116

АЛ БАКЧА ҖИМЕШЛӘРЕ

Казан — татарның Мәккәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . 130
Әдәби фонд сәхифәләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 134
Әстерхан кызы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 150
Күзәтүчән, эзләнүчән әдип . . . . . . . . . . . . . . . . . . 156
Җырларда ил гаме . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 161
Беренче буразна яручы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 165
Осталарның остазы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 169
«Гыйбрәтләр алырлык үткән юл» . . . . . . . . . . . . . . 174
Оренбургның фидакяр заты . . . . . . . . . . . . . . . . . . 178
Күпкырлы иҗат иясе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 183

ТЕЛӘКТӘШ ТӘ, ТЕРӘКТӘШ ТӘ ИДЕК БЕЗ

Ике халыкның былбылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 188
Чыңгыз тауларының бөркете . . . . . . . . . . . . . . . . . 203
Якын кардәшлек эзләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 210
Күренекле якташларыбызның берсе . . . . . . . . . . . . . 218
Әдәби тәрҗемә дә бик кирәк эш . . . . . . . . . . . . . . . 224

ЯН БАКЧА ХӘЗИНӘЛӘРЕ

«Бәр, мылтыгым, бәр, бәр!» . . . . . . . . . . . . . . . . . 238

Биобиблиографик белешмә . . . . . . . . . . . . . . . . . 251
Библиография . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 254

Литературно-художественное издание

**Хамидуллин** Лирон Хайдарович

ВЕЧЕРНЯЯ ЗАРЯ

На татарском языке

Казань. Татарское книжное издательство. 2009

Әдәби-нәфис басма

**Хәмидуллин** Лирон Хәйдәр улы

КИЧКЕ ШӘФӘКЪ

Мөхәррире *В.Р.Камалиева*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Н.П.Клипова*
Корректорлары *Р.Н.Шакирова, Р.Н.Нуриева, С.Н.Галимуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 01.11.2008.
Форматы 84×108 $^{1}/_{32}$. Шартлы басма табагы 13,44.
Шартлы буяу-оттиск 13,86. Нәшер-хисап табагы 15,19.
Тиражы 1000 д. Заказ Т-1497.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.